ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

4. 1993



# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ БҮЛӘГЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ



Әмирхан Еники



Әхмәт Рәшит



Рәис Даутов

Быел Татарстан Язучылары берлеге идарәсе карары белән Гаяз Исхакый исемендәге бүләкләр:

Г. Исхакый исемен халкыбызга яңадан кайтарудагы эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасының бәйсезлеген яклап көндәлек матбугаттагы публицистик чыгышлары өчен язучы **Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникигә,**

«Сөембикә» (1991), «Колшәриф» (1992) поэмалары, «Иман яңарткан-да» (1992) исемле публицистик мәкаләләр җыентыгы һәм сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге өчен шагыйрь **Әхмәт Әхәт улы Рәшиткә,**

татар әдәбияты классикларының күптомлыкларын чыгарудагы һәм Г. Исхакый иҗатын пропагандалаудагы эшчәнлеге өчен тәрҗемәче, мөхәррир **Рәис Нәүширван улы Даутовка** бирелде.

Аларны чын күңелдән котлыйбыз!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**4**

**(846)**

**1993**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

А. РАСИХ. Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр. *(Трилогиядән икенче китап)* . . . . . 3
ЗӨЛФӘТ. Шом. *Шигырьләр* . . . . . . 107
Р. ГАТАШ. Гөлъяр. *Шигырьләр* . . . . . 113
Мин ШАБАЙ. Уйналмаган скрипка. *Хикәя* 119
ИДЕЛБИКӘ. Ак кәгазь. *Шигырьләр* . . . 124
Р. СИБАТ. «Йолдыз төшә сызылып». *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . 127

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тукайлар, Исхакыйлар юлы. *(Галим һәм тәнкыйтьче Ибраһим ага Нуруллин белән әңгәмә)* . . . . . . . . . . . 131

ДИСКУССИЯ
БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ, БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

К. ТИМБИКОВА. Энҗеле калфак. . . . . 144

ПУБЛИЦИСТИКА

М. МОСТАФИН. Тормыш бүләк итәм . . 150

КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

А. ЛИТВИН. «Милләтчеләр» эше. *(Һ. Атласый турында архивлар ни сөйли?)* . . . . 155

МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Г. САДӘ. Бәхетле кеше, бәхетле шагыйрь 167

Әрмиянең халыкның горурлыгы . . . . . 171
Тарих сәхифәләрендә — татар шәхесләре 172
Тукай — «Бәхет ачкычларын»да . . . . . 174
Уймак уйлар . . . . . . . . . . . 175

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Т. ГЫЙЗЗӘТ. Бишбүләх. *(Өзек)* . . . . . 176
М. ӘХМӘТҖАН. Хат калыплары . . . . 178

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ВӘЛИЕВ. Яктырта да яшен, яндыра да 182

УКУЧЫ СҮЗЕ

Г. НАСЫЙРОВ. Әдәби геройлар-замандашлар . . . . . . . . . . . . . . . 186

Бер сорауга — бер җавап . . . . . . . 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 53-07-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман-трилогия А. РАСИХА «Записи и память», рассказ Мин ШАБАЯ «Несыгранная скрипка»: стихи ЗУЛЬФАТА, Р. ГАТАША, Л. САДЫЙКОВОЙ, Р. СИБАТА.
«Литературная критика»: интервью с известным ученым и критиком И. НУРУЛЛИНЫМ.
«Дискуссия». Наша жизнь. Наша литература: Статья К. ТИМБИКОВОЙ «Расшитый жемчугом калфак».
«Публицистика»: статья М. МУСТАФИНА «Дарю вам жизнь».
«Выдающиеся личности»: статья А. Литвина «Дело «националистов».
К 70-летию М. Хусаина: статья Г. САДЭ.
Гордость армии, народа (встреча татарских генералов).
Навыки чтения на основе латинской графики.
Статья М. АХМЕТЗЯНОВА «Образцы писем».
«Книжное обозрение»: М. ВАЛИЕВ рецензирует книгу молодого поэта Р. Сульти.
«Слово читателя»: статья Г. НАСЫРОВА «Литературные герои — наши современники».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: антология татарской поэзии; писатель Г. Тавлин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 23.02.93 ел. Басарга кул куелды 29.03.93 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 26 369. Заказ Я-130. Бәясе 20 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1993 ел.



**Атилла Расих**

# КӘГАЗЬДӘГЕЛӘР
# ҺӘМ ХӘТЕРДӘГЕЛӘР

«ЕЛЛАРНЫ ЧИГЕРСӘМ» ИСЕМЛЕ ТРИЛОГИЯДӘН ИКЕНЧЕ КИТАП

Яшьлегем хатирәләре булып миндә йөз дә егерме жиде солдат хаты саклана. Вакыт аларга үзенең тамгасын шактый сиздереп салган: саргайган, кайберләренең почмаклары уала ук башлаган. Ул хатлар минем өчен бик, бик кадерле. Шул өчпочмаклы хатларны кулыма алган саен, узган тормыш юлымның иң хәтәр, иң сикәлтәле һәм дәртле чорын күз алдыма китереп бастырам. Һәм шунда ук бу хатларны саклаган кешегә рәхмәтләр укыйм.

Финляндия кампаниясеннән, ягъни армиягә алынган көненнән алып, Бөек Ватан сугышы беткәнгә кадәр мин язган ул хатларны әнием кадерләп саклаган. Нинди максат белән? Ихтимал, сугыш кырларында үлеп калсам, улымның бердәнбер төсе булыр диптер, исән-сау әйләнеп кайтса, үзенә бүләк итәрмен, ул үзенең сугышта узган юлын шул хатларга карап хәтерләр, диптер. Ләкин ни генә булса да, бер нәрсә бик ачык, әнием ул хатларны мине яратканга күрә саклаган. Монысы шөбһәсез. Ул хатны кырыгынчы елның мартында Куйбышев өлкәсендәге кечкенә генә Кузнецк атлы район шәһәрчегеннән, үзем хезмәт иткән запастагы полктан жибәргәнмен. Менә ул хат:

«30.III.40, Кузнецк

Сөекле әнием!

Синең һәм Суфия апаның 27 сендә язылган хатын алып, жавапны әле күптән түгел генә язган булсам да, тагы бер хат язмый булдыра алмыйм. Мине аптырашка һәм борчуга төшергән бер нәрсә бар, әни. Син минем хатларымнан илтифатсызлык табасың. Мин моны берничек тә аңлый алмыйм. Минем дөньяда иң якын, иң яраткан кешем син. Мин кайларга гына китсәм дә, сине йөрәгемдә саклыйм, синең белән бергә шатланам, синең белән бергә кайгырам, һәрвакыт син минем янымда. Һәм сиңа карата бер вакытта да илтифатсызлык күрсәтергә теләмим.

---

Атилла РАСИХ (1916) — *әдип, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. «Ике буйдак», «Сынау», «Ишан оныгы» исемле романнар һәм дистәләгән китаплар авторы. Казанда яши.*

Көннең уникe сәгатен өйрәнү белән уздырабыз, калган вакыт та вак-төяк эшләр белән үтә. Шуңа күрә, әни, син минем берәр хатымда ашыгучанлык тапкан булсаң, мине кичерерсең дип уйлыйм.

Синең киләсе уку елында берәр районга тел укытучысы булып китәргә теләгең турында менә нәрсә әйтәсем килә: Казанда урнашырга мөмкинлек булмаса, теләгеңне тормышка ашыруда тукталып калма. Берәр яхшы районны сайла. Армиядән тиз арада кайтып булса, мин дә шунда барып урнашырмын.

Безнең әле хәлебез бер дә билгеле түгел, шушы айларда берәр яңалык булырга тиеш дип өметләнәбез.

Хәзер монда аяк асты пычрак. Көн болытлы, яңгыр сибәләп тора. Күңел төшергеч, мәхәббәтсез көннәр башланды.

Бу хатны 30 ында яза башлап, әле бүген генә (4.IV.40) тәмамлый алдым. Шакир абыйдан посылка килгәне юк. Һәрберегезгә ялкынлы сәлам. Мине сораганнарга шулай ук сәлам әйтегез.

Йөзләрегездән үбеп: Атилла».

Бу хатны уку белән, күз алдыма шул көннәрдә булып узган вакыйгалар килеп баса. Аңлашылсын өчен моны тәфсилләбрәк языйм әле. Искә менә нәрсәләр төшә:

1938 елның көзендә мин Казан ветинститутының зоотехника факультетын тәмамладым. Безне эшкә билгеләү урыннары җәй көнендә үк хәл кылынган иде. Моның өчен безне, Мәскәүгә чакырып, һәрберебез белән танышып сөйләштеләр. Әйтергә кирәк, безгә киләчәктәге хезмәт урынын сайлау хокукы шунда бирелде. Мин Дагстанга китәргә булдым.

Дәүләт имтиханнарыннан соң, булачак хезмәт урыныма, таш-таулар иленә китеп бардым. Казанда ул елны кыш ифрат рәхимсез, үзенә бер төрле котсыз булды. Җир чуендай катты, әмма декабрь аенда да кар әсәре күренмәде. Мин эшкә китүче яшь белгечләргә бирелә торган акчага безнең капка төбендә генә һәр якшәмбедә гөрләп торган Сорочий базарыннан соры төстәге бумази тышлы кыска тун сатып алдым. Әйберләремне кечкенә генә фанер чемоданга салдым. Акча һәм документларымны әнием тегеп биргән күлмәк эчендәге кесәгә бик хасиятләп яшердем. Һәм, өйдәгеләр белән саубуллашып, Кавказ якларына мөстәкыйль тормыш көтәргә киттем.

Бу көннәрдә үземне бик-бик бәхетле итеп сиздем. Нигә бәхетле булмаска! Нинди киртәләрне җимереп үз дигәнемне иттем бит — югары белем алдым.

Инде Дагстанга барып җиткәч, башкайларыңны әйләндерерлек андагы табигать күренешләрен, канатларын җәеп һавада салмак кына очкан бөркетләргә кадәр күтәрелгән текә кыялы таш-тауларны тамаша кылгач, бәхетем икеләтә арткандай булды.

Менә мин Гунибта! Иленең бәйсезлеге өчен колонизаторлар белән озак-озак еллар сугыш алып барган легендар Шамилнең соңгы кирмән-крепостенда. Таулар арасында серпантиндай борыла-сырыла сузылган юл буйлап ат өстендә барам. Ә аста, борылып карасаң, дәһшәтләнерлек тирән тарлавыклар — төпсез упкыннар. Менә тиздән Каспий диңгезе буендагы сарык көтүләренең кышлау урыны булган кутаннарга барам. Каспийдан дымсу тозлы җил исә. Ә алдагы тигезлекләрдә ап-ак булып сарык көтүләре күренә.

Кутан корылмалары әле бөтенләй күренми, ә инде колаксыз, йөнтәс зур кавказ бурзайлары өерләре белән һау-һаулап миңа таба йөгерәләр. Этләргә кычкыра-кычкыра таяклары белән кизәнеп туктарга кушучы чабаннарга рәхмәт, юкса ул явызлар сине ат өстеннән өстерәп төшерергә дә күп алмаслар. Ә Кутанның бер катлы, акшарлы иркен өендә, сине якын итеп, үз күреп каршы алалар. Анда әле генә суелган сарык ите һәм кукуруз оныннан пешерелгән кайнар хыйнкал белән сыйлыйлар. Мин бит белгеч, миңа хәзер хөрмәт. Папахалы, буркалы аксакаллар да

минем белән олы күреп киңәшәләр. Нигә, бу бәхет түгелмени? Әйе, мина рәхәт. Кавказда яшәү дәверемдә саф һава, физик хәрәкәт, нык ашау аркасында, бу яшьтә артык үсәргә тиеш булмасам да, буйга ике сантиметрга, авырлыкка сигез килограммга юкка гына артмаганмындыр. Дагстан һавасы бик килешкән, күрәсең.

Ләкин никадәр оптимистик рух белән үз эшемне тырышып башкармыйм, мин хезмәт иткән оешма миңа бәләкәй генә булса да куыш оештыра алмады. Өйсез, җирсез дигәндәй, борынгы заман дәрвише яки качак абрек сыман авылдан авылга, кутаннан кутанга ат өстендә кыдырам. Паспорт та милиция идарәсендә беркетелмәгән, адресым да юк. Әмма шулай да эшлим, хәзергә авырсынмыйм. Бу өйсез, ятаксыз яшәүнең авырлыгы ярты елдан соң гына үзен сиздерә башлаячак. Һәм мин, җирле начальство бусагасын таптап алҗыганнан соң, Мәскәүгә, әле һаман фатир бирмиләр, дип язачакмын.

Архивымдагы язулар арасында дусларга язган берничә хатның карамасы сакланган. Шуларның икесеннән өзекләр күчереп, шушы истәлеккә кертим әле.

Бу хатларның беренчесе Гунибта, Шамилнең соңгы крепостеннан үзем белән бергә институт тәмамлаган ирле-хатынлы Моршенниковларга язылган. Аны татарча тәрҗемә итеп бирәм. Менә ул:

«Гуниб, 7/VII-1939 ел.

Хәерле көн, сөекле Валя һәм Саша!

Сашаның шелтәләр һәм эндәш билгеләре белән тулган хатын алгач, яшермим, мин бераз шүрләп куйдым. Чыннан да, дуслар белән хат алышу рәхәтеннән мәхрүм булып дәшми-тынмый яшәү ярый торган эш түгел. Узганнарны оныту өчен бер тун кучән булырга кирәк. Шулай ул.

Иң элек сезне балагыз белән котларга кирәк. Мин аның авырлыгы ничә кадак булганын белмим, ләкин сабый сау-сәламәт, таза һәм (Валя кебек) җылак түгелдер дип уйлыйм. Һәрхәлдә, мин аның шулай булуын телим. Мин ихлас күңелдән, якын дустыгыз буларак, сезнең гаиләгезгә бәхет һәм хезмәт куанычлары телим. Балаларыгыз ишле булсын, алар алма кебек тәгәрәсеннәр. Кышын Валядан бер хат алган идем. Ул хатында Ойраттурага китүеннән бик риза булуын белдергән. Хәзер ничектер, белмим. Әйбәт кенә урнашкан булсагыз, мин бик шат.

Үземә килгәндә, мин тыйнак кына гомер сөрәм, «ходайдан куркып» кына яшим. Йөрергә, эшләргә туры килә. Килеп төшү белән Дагстан манзараларыннан биһуш булдым. Искиткеч табигать минне бөтенләй әсир итте. Моннан да яхшырак булуы мөмкин түгел. Ә вак-төяк нәрсәләр (мәсәлән, яшәргә урын булмау) минем игътибарга лаек әйбер түгел иде. Хезмәт белән мавыктым, шуның белән юандым. Практикадан алырдай барлык нәрсәне алып калырга ашкындым һәм нинди нәтиҗә? Дөрес, Госплемрассадник бирердәй барлык тәҗрибәне тиз арада тупладым мин, әмма квартир дигән нәрсәне ала алмадым. Кинәт минем алдымда табигать гүзәллекләре дә тоныклана башлады. Хезмәт дәрте дә кимеде, алдымда бары кешеләр һәм шәрә экономика гына торып калды. Шулай килеп чыкты ки, мин гамәлдә матди базисның нәрсә икәнен аңладым.

Казанга кайтып китәргә булдым. Зоотехник булып эшләү белән бергә, үзем күптән хыялланган эш белән шөгыльләнергә исәп. Бәлки ни дә булса килеп чыгар әле. Бу минем өчен җан азыгы, күңел тынычлыгы булыр дип ышанам. Мин бит институтка да бары шуның өчен генә кердем. Әдәбият артымнан, күләгәдәй беркайчан да аерылмый йөрде. Тормышның караңгысы да, яктысы да мине шул эшкә этәрә кебек. Һәм мин кайчак, шул хәтәр эш белән ныклап шөгыльләнергә микән әллә, бәлки халкым өчен файдалырак кеше булырмын, дип уйлыйм.

Эшләр менә шулай тора. Зинһар сез фәлсәфә сатуымнан көлмәгез. Сезгә дә язмыйча кемгә языйм ди бу юлларны?!

Гунибка әле күптән түгел генә кайттым. Кышкы көтүлекләрдә, диңгез буенда булдым, чабаннар белән яшәдем, вюртемберг токымындагы сарыкларына бонитировка[1] ясауда шактый шәп күнегүләр алдым. Бирегә Гога да килеп киткән, әмма, бәхетсезлеккә каршы, мин аны күрә алмадым, унҗидесендә китеп барган. Ә хәзер минем янда кунакларым — әнием белән әтием...»

Әйтергә кирәк, Мәскәү Мәскәүлеген югалтмаган. Минем гозеремне бу юлы да аяк астына салып таптамаган. Бик тиз арада безнең оешма директорына аннан катгый фәрман килеп төште. Анда, без җибәргән белгечкә тиз арада квартир бирегез, инде андый мөмкинлек юк икән, аны эштән азат итеп, безнең карамакка озатыгыз, диелгән.

Миңа, җиде ай хезмәт иткәннән соң, үзенә бер төрле тантанага ия гүзәлләкләр иле Дагстан белән саубуллашып, Мәскәүгә китәргә туры килде.

Инде икенче, минем яшьлек дустым Троицк егете Морат Гибатдиневкә язган хаттан өзек китерим. Без Морат белән берүк елны институт тәмамладык. Ул — медицина институтын, мин ветеринария институтын. Бу хат 1939 елның 26 сентябрендә язылган.

«Морат!

Синнән хат алганга байтак вакытлар узган булса да, тропик бизгәк белән авырганлыктан, бүгенгәчә сиңа хат яза алмадым. Минем Казанга кайтып төшүемә озакламый ике ай була инде. Казанга кайткач, бирегә Җир эшләре комиссариатына урнаштым, чөнки барыбер озак эшләргә туры килмәс, армиягә китәсе бар.

Эшкә керешкәнгә бер атна вакыт узмады, мине районга йомыш белән җибәрделәр. Колхозларда бер айдан артык йөреп кайтырга туры килде. Сиңа, бәлки, колхозда булуның ни икәнлеге мәгълүм түгелдер. Ләкин ул коточкыч авыр нәрсә, әгәр мондый ризыктан авыз итмәгән булсаң — бик бәхетле. Мин командировкадан авырып кайттым. Кайткан көннән алып тоташ егерме көн яттым. Җитмәсә шундый врачка тап булдым (аны син, бәлки, беләсеңдер дә әле, ул ренгент кабинетында ассистент), минем авыруыма дөрес диагноз куймады, атна буена грипптан дәвалады. Ярый әле, без яшәгән малерия станциясе врачлары, кызыксынып, канымны тикшерделәр. Тропик бизгәк икәнлеге беленде. Алар уколлар кадап дәваларга керештеләр. Юкса хәл мөшкел иде, бик ябыккан идем, температура 40,3 кә җитте. Хәзер инде үземне әйбәт сизәм. Озакламый каралырмын, армиягә китәрмен дип уйлыйм.

Буш вакытларда әдәби иҗат белән шөгыльләнергә булдым. Эшкә дә керештем. Синең алда мактана алам, юмористик хикәяләрем редакторларга ошаган. Шушы көннәрдә алар «Совет әдәбияты» журналында басылачак. Шунысы начар, армиягә китү аркасында, әдәби хезмәтемне туктатып торырга туры киләчәк. Ә инде аз гына мөмкинлек булса, мин анда да язачакмын.

Син ничек яшисең? Синең армия хәлләрең ничегрәк тора? Мин инде, сиңа бу хат барып җитмәс, дип тә борчылам. Безнең егетләрдән Губанов китте, Быков хәрби академиягә керде, Шакулов озакламый алыначак, аннан чират миңа да җитәр. Гомумән, дөресен әйтим, армиягә бик рәхәтләнеп, теләп китәм. Анда бераз авыр булса да, начар булмас, дип уйлыйм.

Троицк ничек яши? Безнең таныш-белешләрдән кемнәрне күрәсең?Ниләр сөйлиләр? Троицкины бик күрәсем, комлы урамнарыннан үтәсем, тавыннан чанада шуасым, өй түбәләренә менәсем, су керәсем, ташу акканны күзәтәсем килә. Балачак елларым узган шәһәр ич. Аһ, нинди күңелле чаклар иде ул! Минем бала чактагы дусларым белән бер җыелып

[1] Бонитировка — терлекләрнең хуҗалык һәм токым сыйфатларын бәяләү.

бакай уйныйсым килә. Сиңа бик зур сәлам салып җибәрәм һәм бәхет телим.

Атилла.

26.IX.39».

Менә тагы үземнең туган өем — Казанымда яшим. Куптәнге таныш, аулак чарлакта, әнием, әтием янында. Мәскәү мине Казанга республиканың Җир эшләре комиссариатына белгеч итеп җибәрде. Монда — барысы да күргән, белгән кешеләр. Безнең терлекчелек идарәсендә хәтта шәриктәшем дә эшли.

Тыныч кына хезмәт итәм. Күбрәк районнарда булам. Мине идарә башлыгы иптәш Шәйхетдинов, күрәсең, яшь-житез диптер, республиканың әле бер почмагына, әле икенчесенә җибәрә. Ә алай да начар түгел. Тик илдә генә иминлек юк. Финляндия белән безнең арада каты сугыш башланды. Фронттан берсеннән-берсе күңелсез хәбәрләр килә. Биш миллион халкы булган фин иле безнең армиягә шундый көчле ударлар ясый, без шаккатабыз. Бу хәл, кыш кергәч, тагы да көчәйде.

Сугыш минем дус-иш арасына да үзен сиздереп канлы тырнакларын батыра башлады. Безнең белән аралашкан Сабынчы урамы малае Фәттери Якуповның фронттан яраланып кайтуы безгә ишетелгән беренче сугыш кәсәфәте булды. Чын исеме аның Фәтхерахман. Без аны шулай Фәттери дип йөртә идек. Ул Әҗем мәчете каршындагы бер йортта тора. Аның әле Харис исемле энесе бар. Анысының кулы рәсем ясауга бик бара, дип сөйлиләр. Ләкин ул бездән яшь, шуңа күрә ул безгә иш түгел. Сынык козыреклы иске кепка, ситсы тышлы тузган бишмәт киеп йөрүче «маңка малай» әле безгә тиң түгел...

Шулай итеп, безнең ил сугыш чорында яши хәзер. Без бу ак финнарның эшен тиз бетерерләр, дип уйлаган идек. Озаккарак китте. Күп тә үтмәде, мине һәм минем кебек тагын берничә комсомолецны комиссариатның партия оешмасына чакырдылар. Янәсе, бик хәтәр сугыш бара бит, егетләр, халкыбыз искиткеч батырлыклар күрсәтә. Безнең оешма да фронтка практик ярдәм күрсәтергә тиеш. Егетләр, сезнең арада фронтка ирекле булып китәргә теләүче юкмы?

Нигә булмасын икән! Мин рәхәтләнеп туган ил өчен фронтка китәргә әзер. Китәбез! Кайчан, кайда, кемгә барып үзебезнең теләкне рәсми рәвештә белдерергә?

Теләүчеләр бер мин генә түгел идем. Безне язып алдылар. Хәзергә сабыр итәргә куштылар. Бу эшнең азагы ел азагында гына беленде. 1939 елның декабрендә мин район хәрби комиссариатыннан чакыру кәгазе алдым.

Каралып, комиссия тикшерүләрен үткәч, пехотага билгеләнгәннән соң, миңа бераз көтәргә туры килде әле. Ниһаять, яңа ел керде, миңа тагын чакыру кәгазе килде. Бусы инде армиягә озату өчен иде.

Әле дә хәтеремдә, безне Куйбышев урамындагы клубка җыйдылар. Моннан чыгарга ярамый. Безне озата килгән әниләр, әтиләр, улларын тәрәзә яннарында күзәтеп, урамда көтәләр. Чәчләр кыркылды, без инде күңелебез белән армия сафында.

Мин ул клуб залында танышларымны да очратам. Шуларның берсе әлеге Фәттеринең энесе Харисны булып чыга. Харис хәзер таныр лык та түгел, үскән, житдиләнгән, чибәрләнгән. Үзе белән аның мәктәп дусты Лотфулла дигән егет тә армиягә алынган икән. Баксаң-күрсәң, без күрешмәгән арада алар сәнгать училищесын тәмамларга өлгергәннәр. Аларның льгота сроклары беткән һәм менә бергәләшеп, армиягә китәбез булып чыга... Кай яккарак җибәрерләр икән? Фронтка укмы, әллә берәр запас полккамы? Алла белсен. Армия хәлләрен, приказ булмыйча торып, белү мөмкинме соң?

Көн төшлектән авышкач, ике-өч сәгать көттергәннән соң, безне — төрле яшьтәге, төрле төстәге, төрле киемле егетләрне урамга чыгарып

тезделәр дә вокзалга алып киттеләр. Колонна артыннан әтиләр, әниләр, апалар, сөйгән ярлар, сеңелләр бара.

Вокзалда кызыл товар вагоннары тора. Бу состав солдат ташу өчен көйләнгән. Теплушкаларда тактадан сәкеләр ясалган, вагон уртасына буржуйка мич куелган, вагонга менү өчен тимер баскыч та эленгән. Кыскасы — комфорт.

Без, озакламыйча, озатырга килгән туган-тумачаны, дусларны калдырып, китеп тә бардык. Елау, үкерү кебек нәрсәләрне хәтерләмим. Әле ул чакта кешеләр сугыш дәһшәтен татып карамаганнар, һәм, шуңа күрәдер, армиягә озатуны гадәти бер хәл дип уйлыйлар иде.

Эшелон Куйбышев өлкәсендәге район шәһәрчегенә барып туктады. Бу — Кузнецк атлы, заманында татар байлары белән дан казанган, халкыбызга Шамил Усманов кебек гүзәл шәхесләрне бүләк иткән бер кала.

Без, эшелоннан төшкәч тә, шәһәр мәйданында ук, ихаталанган хәрби баракларга урнаштык. Димәк, фронтка юл тотмыйбыз икән әле, башта шушы запас полкта тиешле күнегүләр узачакбыз.

Урнашкан баракларыбыз күптән салынган иде булса кирәк. Һәр ротага бер барак. Ул сузынкы, шыксыз. Эчендә ике яклап сәке-сәндерәләр тезелеп киткән. Аста — салам тутырылган матрас, өстә — юка одеал. Баракның ишекле ягында дневальныйлар утыра, икенче очта Кызыл почмак, ә урталыкта — юыну бүлмәсе.

Минем өчен бу яңа тормыш шартлары беренче көннәрдә бик сәер һәм бик уңайсыз тоелды. Җайсызлыгы тагы шунда: бирелгән аш, кем әйтмешли, теш очына да йокмый. Күрәсең, шундый хәлне күздә тотыптыр, полк ишегалдында икмәк ларегы ачканнар. Һәр мөмкинлектән файдаланып, җан-фәрман шунда йөгерәбез.

Тик бу гуҗлык озакка бармады. Атна-ун көннән соң тамаклар бетеште, без солдат паегыннан тәмам риза-канәгать була башладык.

Солдат киемнәрен өләшү уелып истә калган. Мунчага алып бардылар, барлык кием-салымнарыбызны әйбәтләп төреп куярга куштылар. Юынып чыгуга, безгә дигән обмундированиене мунчаның алгы ягына китереп аударганнар иде инде. Өскә гимнастерка, галифе чалбар, аякка ыштырлы ботинка, билгә брезент каеш. Боларның барысы да — «Бу», ягъни файдаланылган, өченче категория киемнәр. Гимнастеркалар мылтык маена буялып беткән, чалбар, ыштырлар да пычрак, ботинкалар исә тупас, артык зур, чөенке борынлы.

Өләшенгән яңа форманы киеп алгач, шайтаннарга охшап калдык. Бер-беребезгә карыйбыз да егылып көләбез, чыдар хәл юк.

Менә шулай итеп, солдат «уенын» башлап җибәрдек. Хатта язылганча, иртәнге алтыда уяну, эчке күлмәкләрдән, чалбар ботинкадан тезелешеп ишегалдына чыгу, бәдрәфтә чират торып бушаганнан соң, физзарядка ясау, аннан казармага кереп юыну. Юынгач, саф белән ашханәгә ашыгабыз. Озын өстәл тирәсенә бөтен взвод берьюлы утыра. Калай ләгәннәрдә ботка килә, аны ашап бетерү белән старшинаның: «Поели?» — дип сораганы ишетелә. «Поели» авазы көчлерәк яңгыраса, «встать» дигән фәрман яңгырый. Дәррәү аякка басабыз.

Иртәнге аштан соң безне шәһәр читенә тактик өйрәнүләргә алып китәләр. Мин аннан эт урынына арып кайтам. Инде беттем, иртәгә үк врачка барырга туры килер дип ятам. Башны мендәргә салам һәм шундук йоклап та китәм. Менә әкәмәт! Бер генә җирем дә авыртмый ләбаса! Ничек инде, үзеңне болай шәп хис иткәндә, санчастьларга барып йөрергә ди? Ботинкаларым өстенә туп-туры сикереп төшәм һәм физзарядкага чабам. Тагын бер үк көндәлек хәлләр кабатлача: иртәнге зарядка, ашау, кырга чыгып киткәнче җиргә ятып мылтыктан пулясыз гына «ату». Ә аннан соң тагы өйрәнү, уку, тагын эт булып арып матраска сузылып йокыга талу. Иртәгесен тагы шулар ук. Безне шулай сугышка әзерлиләр.

Ротадагы егетләрнең күбесе — элекке студентлар. Моңарчы льгота белән файдаланган, ВУЗ тәмамлаган егетләр. «Мәмәй авыз, ак сөяк» дип ишеткәнем бар иде минем, ләкин андыйларны күргәнем юк иде. Андыйларны да күрергә туры килде. Хәер, монысы җәйгә табанрак булды.

Ничектер, дүрт-биш солдат, тактик өйрәнү вакытындагы бер тәнәфестә, елга буена төшеп майга катып беткән гимнастеркаларыбызны юарга булдык. Бик чибәр, ләкин үшәнрәк бер яһүд егете яр өстендә берүзе басып калды. Ә нигә, мөмкинлектән файдаланып, беләүләнеп беткән гимнастерканы юмаска, дибез. Ул безне хәйранга калдырып, ихлас күңелдән: «Мин андый эшне булдыра алмыйм, иптәшләр, мин аңа өйрәнмәгән», — ди. Әйе, монысы җәйгә таба, көннәр җылынгач, җирләр кипкәч булган хәл. Ә хәзергә кышкы чиллә. Һәр көн диярлек күкрәктән кар ярып һөҗүм итәргә өйрәнәбез, аннан чираттагы нарядларны үтәү, каравылда тору, яки ашханәдә бәрәңге әрчү, йә булмаса, ашханәдә поварга ярдәм итеп торучы эшче вазыйфасын үтәү белән мәшгульбез. Бу соңгысы нарядның иң әгъләсе санала. Чөнки анда эләккән кеше көне буе сыйлана, ашаганы ит тә май.

Хезмәт җитүнең беренче көннәреннән үк запастан алынган кече командирлар (безне) үрә бастырып, «арт сабакларыбызны» бик нык кына укыта башладылар. Рота старшинасы аерата явыз кеше булып күренде. Ул иелеп кенә, каш астыннан гына карап йөри. Ябык, төксе йөзен сиңа текәсә, чираттан тыш наряд эләкте дигән сүз. Кул-фәлән тидермәсәләр дә, кече командирлар кирәккә дә кирәкмәскә дә рәхәтләнеп җикеренәләр. Мәгәр без аларның бер йомшак якларын сизеп алдык. Алар комсомол җыелышларында шартын китереп, чатнатып чыгыш ясый белмиләр. Егетләр моннан бик оста файдалана башлады. Мәскәү ВУЗларын бетереп килгән егетләр, авылдан килгән кече командирларны җыелышларда шундый шәп тәнкыйть итәләр хәзер, теге мескеннәр, рота командиры каршында ык-мык итеп утырудан башка берни дә эшли алмыйлар.

Бераздан бу җыелышлардагы чыгышларның нәтиҗәсе дә күренде. Солдатны юкка-барга үрә бастырып әрләүче командирлар шактый инсафланды. Сүгенү сүзләре бетте, тиешле вакытта гына, устав рөхсәт биргән өстенлекләреннән генә файдалана башладылар.

Бераздан миңа взводта политдәресләр уздыру эшен йөкләделәр. Минем эшләр маңтый. Мине командирлар ярата. Мин сугышчан һәм политик хәзерлек отличнигы.

Менә, ниһаять, яз ае кергәч, күптән көтелгән көн дә килеп житте. Маршротасына күчерәләр. Без медицина комиссиясе узабыз. Минем сәламәтлек әйбәт. Кайда ул йөрәк авыртулары һәм азканлылык? Гаҗәп икән ул кеше организмы!

Дөя йонынннан бәйләнгән йомшак подшлемниклар бирелде. Бу — фин сугышы мәҗбүр итеп, армия обмундированиесенә үзгәреш керткән кием. Чөнки юка, очлы шлем-буденовкалар киеп төньяк суыкларына кем түзсен!? Киез итекләр дә өләштеләр. Үтәли күренмәле сидрәгән шинельләрне салдырып, әр-яңа яшел бушлат кидерделәр. Тик яңа гимнастерка белән чалбар бирергә генә өлгермәделәр. Уйламаган-көтмәгәндә фин сугышының тәмамлануы мәгълүм булды. Шулай итеп, фронтка бару, маҗаралар эчендә кайнау өметләре кинәт сүнде дә куйды. Өләшенгән киемнәрне кире җыеп алдылар.

Инде алда яңа юллар. Сугыш юллары түгел, ә хезмәт срогын тутырып, тизрәк өйгә кайту юлы.

Мин еш-еш Казанда уңышлы гына башланып та, өзелеп калган әдәби хезмәтем турында уйланам. Хәзер моңа вакыт та бар. Ротабызны каравыл хезмәтенә куйдылар. Хәзер инде без тиешле әзерлек узган, пешкән-житешкән солдатлар.

Менә Беренче май бәйрәме дә житте. Ул көнне көтмәгәндә кар яуды. Кузнецк урамнарында тубыктан кар ерып парадта йөрибез. Ә

мин әдәбият турында уйланам. Минем фикерләрем журналда басылган һәм әле басылачак хикәяләрем турында. Юкса ничек әйбәт башланган иде бит иҗат эшем. Бала чакта ук йөрәк түремдә сакланган максатым, иң изге, иң гүзәл, мавыктыргыч эшем, бәхет чыганагым иде ул минем.

Кавказдан кайтканда чемоданымда өч-дүрт хикәя саклана иде инде. Казанга кайтып төшү белән (аларны) әдәби журналга илттем. Ул чакны «Совет әдәбияты» журналының редакторы Тәхфәт Имаметдинов дигән кеше иде. Ул гәпне озакка сузмады, мине өстәленә кызыл комач җәелгән кызыл почмаксыман бер бүлмәгә алып керде дә, хикәяләремне укырга кушты.

Мин укыйм, ул тыңлый. Ниһаять, ул кулъязманы алды да үзе караштыра башлады. Бераздан мине чиксез шатландырып:

— Бу хикәяләрне басабыз,— диде. Һәм, күп тә узмады, алар журналда басылып та чыктылар. Алай гына да түгел, бу хикәяләрем турында, кайчандыр беренче өйрәнчек хикәямне «Октябрь баласы»нда бастырып чыгарган, хәзер инде Татарстан Язучылар союзының җитәкчесе Муса Җәлил докладында мактап сүз әйтте.

Инде менә шулай әдәбият мәйданында ясалган беренче адым армиягә алынуым белән киселде. Хәер, әгәр сугыш кырына эләгеп, шунда катнашырга туры килсә, әдәбиятны вакытлыча калдыруыма да үкенмәс идем. Чөнки, бик нык ышануымча, ил егете өчен дошманга каршы сугышудан да изгерәк нәрсә юк.

Әниемә әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы хатлар яудырам. Хәзер хатларны да еш рак язарга була.

«Кузнецк. 8.05.40.

Сөекле әни, әти, Суфия апа!

Бүген җибәргән посылкагызны, бәйрәм күчтәнәчләрен алу белән хат язарга ашыгам. Посылка исән-сау, бер нәрсәсе дә бозылмыйча килгән. Рәхмәт, бик тәмле мәмәйләр җибәргәнсез икән.

Үзем исән-саумын. Һаман бер көе хезмәт итеп ятам. Хәзер көннәр төзәлде, аяз, матур. Урманнарда, кырларда булабыз. Бик күңелле. Укулар да шактый җиңеләйде. Буш вакыт та табылгалый. Китап, журнал укыштыргалыйм.

«Совет әдәбияты»ның өченче саны чыкмадымы әле? Аннан тагын шул: минем 10—11 санда басылган «Карак»ны күргәнем юк бит әле. Буш вакыт тапсагыз, шуны укып карагыз әле. Миңа җибәреп тормагыз, үзегезнең фикерегезне языгыз.

Бүтән язардай хәбәрләрем юк. Сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: Атилла».

«19.05.40. Кузнецк

Сөекле әни!

Синең 15 endә язган хатыңны әле хәзер генә алып, сиңа җавап язарга ашыгам. Үзем исән-саумын. Синең хатың, белмим, яхшы кәеф белән язылганга күрәдерме, минем күңелемне күтәреп җибәрде. Гомумән, бу көннәрдә үземне яхшы хис итәм. «Күз тимәсен», тазарып та киттем (моны иптәшләр әйтә), бу инде җәй якынлашу уңае беләндер. Тик шунысы начар, безне һаман лагерьга чыгармыйлар.

Бездә әле кайбер яңалыклар булып алды. Безне башка ротага күчерделәр. Безнең эшләр инде хәзер каравылда торудан китте. Бу яхшыракмы, юкмы, хәзергә әйтеп булмый. Тик карт солдатларның әйтүенә караганда, безнең эш байтак җиңеләячәк. Ләкин бу яңалык өйгә кайту көннәребезне артка чигерә булса кирәк.

Синең Шакир абыйларга баруыңны мәслихәт табам. Тик шарты шул, ял итеп кайт.

Йөзеңне үбеп, улың: Атилла».

«Кузнецк, 27.05.40.

Сөекле әни, әти, Суфия апа!

Барыннан да элек сезгә ялкынлы сәлам. Үзем исән-сау. Әле бүген генә командировкадан кайтып, сез җибәргән посылканы, аннан хатыгызны алдым. Сезнең исән-саулыгыгызга мин бик шат, киләчәктә дә шулай булсын.

Әни, мин, узган хатымда язылганча, хәзер каравыл ротасында. Безнең бурыч — хәрби йөкне тимер юлда саклап, озатып бару. Әле 21 майда чыгып киткән идек, бүген генә кайтып кердек. Шунысы кызганыч, Казанга эләгеп булмады. Берничә иптәш шул якка китте. Мин исә Пенза тирәсеннән әйләнеп кайттым. Аннан йөреп кайтканчы монда зур үзгәрешләр булган. Бик күп кешене бездән Казанга җибәргәннәр. Ләкин моның Казан булуы гына кызыксындырмаса, башка әллә нәрсәсе юк, чөнки алар кече командирлар мәктәбенә киткәннәр — ягъни өч ел хезмәт итәргә тиешләр. Минем исәп исә, ике елдан өйгә кайту.

Юлда йөрүләре күңелле. Яңа кешеләр, яңа шәһәрләр күрәсең, казармадагыча тәртип тә каты түгел. Үз чиратыңны постта торып уздырдыңмы, аннан теләсәң нишлә. Бары шунысы начар, бу арада көннәр салкын булды. Вагон эчендә суык.

Казанга баручыларга мин синең адресыңны биреп, синең янга керүләрен бик үтенгән идем. Бәлки әле бер егет, җаен табып, кереп тә чыгар.

Минем теге хатымдагы «Карак» мәсьәләсенә килик. Ул хикәям мин киткәч басылды. Минем аны күргәнем юк.

Үзәк китапханәдән алынган китаплар түбәндәгеләр иде: 1. Чеховның юмористик хикәяләре, 2. Чарльз Диккенсның кечкенә генә бер хикәясе, 3. Мате Залке хикәяләре. Бу китапларның һәммәсе дә кечкенә форматта. Миндәге китап шул өч китапның берсе. Шуларның икесен (кайсылары икәне онытылган) мин илтеп биргән идем инде.

Әтинең зачетлары кайчан бетә? Ул инде шулай француз теле мөдәррисе булып чыгамы? Бик яхшы. Әле кайсы мәктәпкә билгеләнәсе билгеле түгелдер?

Әни, миңа әйбер җибәрсен дип, син Шакир абыйны артык борчыма инде. Сирәк-мирәк кенә яхшы була ул...

Син, папиросмы, җимешме яхшы, дип сорыйсың. Икесе дә яхшы.

Әни, әле син ял йортындасыңдыр. Ничек соң, ял итеп буламы? Бик тыныч ял ит. Минем өчен бер дә борчылма, минем эшләр хәзер җайланды.

Гариф Галиев хат язмый. Язмаса язмасын инде...

Фәттери кайткан бугай (аны Зиннәт белә). Аның энесе Харис безнең белән. Мин аны еш күрәм. Клуб тирәсендә чуала ул. Художник бит.

Зиннәткә һәм мине сораган башка кешеләргә сәлам. Рахман абыйларга, Ибраһим абыйларга беренче чиратта сәлам.

Йөзләрегездән үбеп: Атилла».

Соңгы хатымда мин, командировкам, бәлки, Казанга туры килер дип язганмын. Юраганым юшка килде, күп тә узмады, Казан янындагы Юдино станциясенә трофей әйберләр озату өчен команда төзелде. Ул командага мин дә эләктем. Менә бәхет! Хәзер без теплушкада, Казанга, туган якка барабыз. Казанлылардан командага без икәү эләктек. Мин һәм Галанин фамилияле грек кыяфәтле ифрат чибәр һәм тыйнак егет.

Күңел алгысына, чыннан да, бик сагындырган икән туган җир!

Юкса аерылганга нибары ярты ел гына гомер узган бит. Алай да сагындырган. Күрәсең, армия шартларында яшәүнең бер үзенчәлегедер инде бу. Үз өеңнең күнегелгән, иркәле тормышын күреп китәсе килә. Һич югында ул кадерле тормышның түмен татып чыгасы иде дип, ашкынасың.

Без бишәү. Команда башлыгы ярты юлда ук бөтен тапшырасы йөкне, аның документларын безгә биреп, төшеп калды. Аның туган

авылы барасы юл өстендә икән. Инде ул төшкәннең икенче көнендә үк аның урнына калган икенче егет тә үз авылы якынлаша төшкәч, составны безгә тапшырып, бер тукталышта калды. Шулай итеп без өчәү, Галинин, мин һәм тагы Крылов дигән егет трофейларны тапшырып, документларын формалаштыруны үз өстебезгә алдык.

Шулай итеп, җылы июнь кичләренең берсендә, Юдино станциясенең хәрби складына составны тапшыра башладык. Бу эш шактый озакка сузылды. Эш тәгәлләнгәндә, караңгы төшкән, төн уртасы якынлашып килә иде.

Йөкне кабул итеп алган старшина безнең командировка кәгазьләрен тутыра башлады. Теге төшеп калган иптәшләр турында ләм-мим сүз булсынчы. Без исә аңа Казан егетләре икәнлегебезне, туган шәһәрдә, җае чыккач, берничә көн булырга кирәклеген әйтәбез. Шәфкатьле кеше икән старшина.

— Ничә көн торырга исәп? — дип сорый. Галинин:

— Бер биш көн язгыз инде, — ди.

— Ике көн җиткән, — диде старшина. Числосын яза, имзасын куя.

Менә без шат, бәхетле кешеләр, беренче очраган товар поездының платформасында Казанга китәбез. Йөрәкләр ашкынып дөп-дөп тибә. Һич уйламаганда, көтмәгәндә Казанга кайтып барабыз диген, ә? Менә әкәмәт!

Казан вокзалына килеп төшү белән, азакты трамвайдан калмас өчен, җан-фәрман йөгерәбез. Патруль очрамагае тагын дип, курка-курка трамвайга чабабыз...

Без яшәгән чарлакка элә́гү өчен, башта ул учреждениенең контора өстәлләре тулган зур бүлмәсен узарга кирәк. Дежур апа төнге кунакларны хәйран калып каршы ала, без шыпырт кына өскә менәбез.

Безнең бүлмә ишеге фанердан гына корыштырылган, ул, гадәттә, бикләнми. Мин аяк очларыма гына басып эчкә узам да электр лампасын кабызам. Күрәм, әнием ялгызы гына. Ул безнең бүлмәдәге бердәнбер караватта тыныч кына йоклап ята. Мин мылтык түтәсе белән идәнгә сугып, солдатларча, ә хәзер җүләрләрчә дип әйтер идем, «Подъем!» дип кычкыруыма, ул чәчрәп аякка басты һәм минем кочагыма ташланды. Мин кыскача гына хәл-әхвәлне аңлатам, әни күлмәген киеп ала, ишек төбендә калган Крыловны эчкә чакыра.

Хәтеремдә: йокы туйдыргач, Крылов белән икәүләп гражданский киемнәрне киеп, мунчага барып кайттык. Аннан соң мин, урамга чыгарга курыккан иптәшемне өйдә калдырып, дус-ишләр янына, белемгә ычкындым.

Зиннәткә бардым. Ул минем брезент билбавымны үзенең армиядән алып кайткан менә дигән каешы белән алыштырды. Без аның белән берәр кружка сыра эчеп сыйландык та, якшәмбе көне булу сәбәпле, никадәр генә теләсәм дә, мин редакцияләр тирәсенә бара алмыйча өйгә кайтып киттем. Калган көнемне өйдә, Рахман абыйларда, энеләрем Шәүкәт, Рафаэль, Марат белән уздырам.

Әйткәнемчә, әнием өйдә үзе генә иде. Әти курсларын бетереп, эшкә тәгаенләнгән, авылга киткән. Суфия апа шулай ук Азнакай якларына кунакка киткән икән.

Санаулы ике бөртек көн сизелмәде дә. Менә Кузнецкига кайтып төштек. Ә анда мәхшәр. Казарманың асты-өскә килгән. Ротада бары бер-ике кече командир калган. Салам тутырылган матраслар идән уртасында, одеаллар ишек төбендә үк. Без аптырап калдык. Баксаң-күрсәң, полкны таркаталар икән. Артык илтифат итүче дә булмады. Штабка кереп документларны тапшырдык та, кайсы частька билгеләнүебез белән кызыксына башладык. Якташ Галинин белән шунда гомергә аерылыштык. Мин хезмәтемне дәвам итәр өчен Куйбышев шәһәрендәге хәрби складларның каразыл ротасына киттем, ә ул башка якка.

Хуш, сау бул, солдат хезмәтенең лаеш шулпасын беренче тапкыр ашаткан Кузнецк шәһәре! Хушыгыз, без мылтык күтәреп йөгереп, ухылдап йөргән аланнар һәм кырлар!

«Куйбышев, 20.08.40 (алдым 27.8)*
Сөекле әнием һәм Суфия апа!
Сезнең унбишендә язган хатларыгызны һәм посылканы бүген алып бик шатландым... Үзем исән-сау гына хезмәт итеп ятам.

Хәзер инде мондагы иптәшләргә тәмам ияләштем. Аларның гореф-гадәтләренә күнектем. Бәлки, артыграк мактанудыр, шулай да дөреслекне әйтүне тиеш дип табам — үзем гомуми ихтирам казанган бер кешегә әйләнеп барам. Минем белән дус булырга тырышалар, үзләренең кайгышатлыкларын уртаклашалар. Ә сиңа булган караш, синең рухи халәтеңә ифрат зур тәэсир ясый бит!

Кыскасы, мин үземнең тормышымнан зарлана алмыйм.

Үткән хатларымда да мин сиңа әдәби эшем турында язгалаган идем (бәлки туйдырып та бетерә торганмындыр), бу юлы да языйм әле. Хәзер мин «Каһәр суккан тел»нең караламасын язып бетереп киләм. Никадәр генә кысып язарга тырышсам да, ул бер 40 битлек хикәя булырга охшый. Башта мин аны әкият итеп язмакчы идем, хәзер исә минем бу фикерем үзгәрде, әсәр хикәягә әйләнде.

Мин аңлыйм, бу хикәям басылып чыккан тәкъдирдә дә, ул бер өлеш тәнкыйтьчеләргә ошамаячак. Ләкин аларның бәйләнүләре (әгәр ул шулай булса), һичшиксез, аларның тар фикерле һәм тормышны газета аша гына өйрәнүчеләр икәнлегеннән килеп чыккан бер «чыгымчылау» булачак...

Әни, син үзеңнең хатыңда, миңа бары бер мәктәптә генә калырга туры килер, ахры, дип язасың. Бу, һичшиксез, шулай. Син беренче чиратта үзеңнең сәламәтлегең турында кайгыртырга тиеш. Зинһар, әйбәтрәк аша, зинһар, миңа костюм-фәлән алам дип борчылма. Синең сәламәтлегең, озак яшәвең минем өчен иң зур бәхет, иң зур шатлык булачак. Мин хәзерге көндә сиңа ярдәм күрсәтә алмавыма зур хафаламын. Әгәр өйне, сине уйлый башласам, тизрәк Казанга кайтасым һәм эшли башлыйсым килә.

Кичә икенче кабат Аптекаевларга** барып кайттым. Беренче баруымда аларның кече улларын гына очраткан идем, бу юлы кечкенә кызлары Фәридә белән Гөлчәһрә апаны гына туры китердем. Мөхәммәт абый белән Сафия апа Куйбышевта якшәмбе көннәрен генә булалар икән. Үкенечкә күрә, сезнең ял көннәре бу арада дүшәмбегә туры килә. Киләсе ялда тагы шунда барырга уйлыйм. Барыбер башка эш юк.

Хатымның азагында шуны әйтим әле, шушы атна-ун көн арасында бәлки безне башка шәһәргә күчерерләр. Шундый бер гәп бар.

Посылка өчен бик зур рәхмәт, бөтен нәрсә исән-сау килгән. Рахман абыйларга күчтәнәчләре өчен рәхмәтемне тапшыр. Барысыннан да бигрәк «Беломор» ошады. Шәүкәт энемә дә, күчтәнәче өчен стройга бастырып, шулай ук благодарность белдерәм.

Үзеңә, Суфия апага, Рахман абыйга, Сәүдә апага, минем алмашчыларым Шәүкәткә, Рафаэльгә, Маратка ялкынлы сәлам. Мине сорашкан башка кешеләргә дә сәлам яудыра бир.

Г. Галиевкә моннан соң хат язмаска булдым. Минем сизенүемчә, аның миңа карата чукрак һәм сукыр булып кылануына нинди дә булса берәр сәбәп бар. Хат язарга вакыт юк, дигән кешегә дөньяда берәү дә ышанырга тиеш түгел. Теләк юк дигәндә — икенче мәсьәлә...

Йөзеңне үбеп, улың: Атилла».

---

* Монда һәм ары таба җәяләр эчендә — әнием искәрмәсе. (А. Р.)

** Язучы М. Галинең кода тиешле кешеләре. Мөхәммәт — М. Галинең кайнеше, Сафия — аның хатыны.

* * *

Менә мин, Куйбышевның Линдов шәһәрчеге дип аталган, кирпеч койма белән ихаталанып алынган урынында хезмәт итәм. Монда складлар гына урнашмаган, бу шәһәрчектә тагын (байтак хәрби бүлекчәләр бар әле. Ул чын мәгънәсендә үзенә күрә бер хәрби шәһәр. Ә мин хезмәт итә торган каравыл ротасы бары складлар саклау белән генә мәшгуль. Мондагы таш казармага килеп керү белән, тәртип һәм чисталыкка хәйран калдым. Кая ул моны Кузнецкидагы без яшәгән тынчу бараклар белән чагыштыру! Һавасы саф, үзе якты, караватлар ике катлы булса да, тимердән, аерым куелган. Һәр карават янында ике катлы тумбочка. Ап-ак мендәрләр, җәймәләр, җылы, тәнне иркәләп кенә тора торган йомшак одеаллар. Түшәкләр тип-тигез итеп шомартылган, матур итеп җыештырылган.

Бу хәрби бүлекчәгә килү белән, өр-яңа обмундирование бирделәр. Башка ялтыр козыреклы фуражка, өскә бер дә киелмәгән, гәүдәмә чамалап тегелгән, килешле гимнастерка белән чалбар, ә аякларга, ыштыр белән ботинка урнына, өр-яңа күн итекләр.

Мондагы егетләр барысы да яшь, югары белемле кеше үзем генә дисәм дә, хата булмас. Казанлылардан үзем генә түгел бирелә. Сузан буйлы, интеллигент йөзле Ступишин да монда. Шулай ук минем белән элек бергә хезмәт иткән, Казан художество училищесы студенты Әхмәтшакиров Мәҗит тә монда.

Әйтергә кирәк, бу рәссам булырга тиешле зур башлы, таррак маңгайлы, дегеттәй кара чәчле егетнең язмышы соңыннан бик күңелсез очланды. Маңгаена туп-туры аркылы сызык булып яткан кашлары аша каравыннан чыгып хөкем иткәндә, бу Мәҗит артык төксе кыяфәтле тоелса да, әйбәт, тәрбияле һәм беркатлы егет иде. Шул беркатлылыгы аның башына җиткәндер дә әле.

Безнең эш, әйткәнемчә, каравылда тору. Каравыл командалары Линдов шәһәрчегендәге складларны гына сакламыйлар, шәһәрнең икенче очындагы обмундирование складларын да каравыллыйлар. Көннәрдән бер көнне Мәҗит тә шул еракагы складларны сакларга китә. Ул егетләрне берәр пар кием кыстырып кайтырга үгетли башлый. Һәм бу җүләрләр, коткыга бирелеп, аның киңәшен башкаралар.

Без капчыкта ятамы соң? Берничә көннән соң ук бу җинаять фаш ителә һәм бөтен команда трибуналга эләгә, кулга алына. Шулай итеп, Мәҗит төрмәгә китеп барды

Мин исә хәзергә әйбәт кенә хезмәт итәм. Вышкаларда сакта торганда, күзлекне киеп алам да барлык игътибарымны җигеп һәр «келт»кә колак шаңкайтеп постта торам. Җиңел эш түгел, аерата төнге каравылда торулары артык нык киеренкелек сорый. Монда инде сиңа язылачак әсәрең турында баш ватарга ирек бирелмәгән. Әгәр абай булмасаң, дәррәү бәхетсезлеккә очравың бар. Ә андый «ЧП»лар булмый түгел. Күптән түгел бер кызылармеец, кәҗәсенә үлән йолкып йөрүче, һич гаепсез чукрак бер бабайны атып екты. Икенче солдат исә, пароль әйтүенә карамастан, постларны тикшереп йөргән командирга атты. Күрәсең, көтелмәгәндә килеп чыккан лейтенантны күргәч, каушап калган.

Кыскасы, постта корулы мылтык тотып тору ул уен эш түгел икәнлеген тиз аңладым. Җиңел түгел иде. Ләкин, шул ук вакытта, миңа каравыл ротасында хезмәт итү язу теләкләремне тормышка ашыру өчен дә зур мөмкинлекләр тудырды.

Нарядта булу — тәүлегеңне өчкә бүлү дигән сүз ул. Аның өчтән бер өлешен постта торасың, өчтән бер өлешен каравыл өендә йокламый утырасың, ә калган вакытыңны йоклыйсың. Мондый режим әдәбият белән шөгыльләнү өчен әйбәт.

Мин иҗатымны юмор-сатирадан башлаган идем. Сугыш алдыннан басылган хикәяләрем барысы да юмористик әйберләр. Шуларның берсе

«Каһәр суккан тел» исемле сатирик хикәя. Ул әсәр күп еллардан соң, без сугышлардан әйләнеп кайткач, нигезе үзгәрмәсә дә, яңа редакциядә татар һәм урыс телләрендә дөнья күрде. Хәтта күрде генә дә түгел, талантлы артист Рәфкать Бикчәнтәев башкаруында радио аша күп тапкырлар дөньяга яңгырады.

Бу тема Казанда ук, мин Җир эшләре комиссариатында эшләгәндә бөреләнде. Сюжет төрлечә туа. Язылачак темага сюжет эзләп азаплантанда, ничектер бер иптәшнең «тел өзелде әле» дигән сәер сүзләре колакка кереп калды. Шул сүзләр минем әсәр өчен ачкыч вазифасын үтәде.

Тел. Берәүнең теле өзелә. Ул тел бик лыгырдык кеше теле була, авыздан авызга кереп, шунда оялап, кешеләрне боза. Менә бит язылачак әсәрнең төп сюжет сызыгы. Шулай сюжет туды. Ул үскәннән үсте, эзләнә торгач, сатирага хас язу алымы да табылды, һәм мин кызып эшкә керештем.

Кырыгынчы елларда сатира безнең әдәбиятта бик назлы кунак иде. Ул чактагы прозабыз чынбарлыкны раслау — тормышыбызны мактау булырга тиеш дигән фәрманнан чыгып эш итте. Халыкара пропаганда өчен башкарылган бер эш иде бу. Чынбарлыкның ачысынтөчесен татып яшәгән безнең ил кешеләре өчен һич тә үтемле нәрсә булмады. Һәрхәлдә, миңа ул вакытта ук шулай тоелды. Минем карашымча, әдәбият иң беренче чиратта үз халкың өчен иҗат ителә. Шулай уйлап, мин язылачак хикәямдә тормышыбызның күләгәле якларын, безнең алга барышыбызга комачаулый торган якларын сатира утында көйдерергә булдым. Әлбәттә, тәнкыйтьнең, дөресрәге, редакторларның бу әсәргә кырын күз белән караячакларын да аңлый идем. Инде бәләкәй генә булса да әдәбият өлкәсендә тәҗрибәм (һәрхәлдә, замана әдәбияты белән танышлыгым да) моны аңларлык дәрәҗәдә генә тупланган иде.

Буш вакытларымда әдәбият белән генә шөгыльләнмәдем. Кызганычка каршы, скрипкам үзем белән түгел иде. Мин бу чорда музыкадан аерылып торырга мәҗбүр булдым. Аның каравы, мин буш вакытларымның байтак өлешен иптәшләремнең портретларын ясарга бирәм. Майлы буяуларым юк минем, акварель белән дә эшләмим, төп коралым карандаш белән тушь. Егетләргә рәсемнәр ошый, алар өйләренә җибәрәләр, йә армия исәлеге итеп үзләрендә саклап тоталар. Миңа исә бу шөгыль канәгатьләнү хисе бирә.

Атнага бер тапкыр увольнительный алып шәһәргә чыгабыз. Баксаң-күрсәң, биредә безнең бик ерак туганнар да яши, имеш. Бу — язучы М. Гали абыйның хатыны Сафия апаның туган энесе Мөхәммәт, Сафия апаның әнисе Гөлчәһрә апа. Мин кайчак ял көннәрендә шуларга барам. Казарма тормышын төрлеләндерү өчен гаилә, өй җылысын татыйсы килә, самавырдан чәй эчәсе, тәлинкәдән токмачлы шулпа ашыйсы, табын янында ашыкмыйча сөйләшеп утырасы килә. Шулай ук өй кәкер-чөкерләреннән дә авыз иткәндә күңелле булып китә. Башкалар миңе артык өнәмәсәләр дә, солдат дип түбәнсетеп карасалар да (аерата Гөлчәһрә апаның кызы Сафия апа белән улы), мин Гөлчәһрә апа белән сөйләшеп утырам, Куйбышев вакыйгаларын ишетәм. Ә Гөлчәһрә апа ачык, ифрат кунакчыл кеше.

Тагын миңа куаныч өстәгән нәрсә — Куйбышев шәһәренең Үзәк китапханәсе. Мин шәһәргә беренче чыгуымда ук шунда барып язылдым, һәм бер кочак китап алып кайттым. Бераздан әле мин Куйбышевның бер караңгы почмагында татар китапханәсе барлыгын да беләчәкмен. Шунда баргалап, үзебезнең телдәге газет-журналларны укыячакмын.

Тагы бер күңелле нәрсә бар: без сирәк кенә булса да иптәшләр белән бергәләшеп театрларга, культпоходларга йөрибез. Кыскасы, минем буш вакыт хәзер әрәмгә узмый. Мин моңа бик шат.

«Куйбышев. 16.09.40

Сөекле әнием!

Сиңа башта үземнең исән-сау һәм һаман бер урында торганлыгымны белдерәм. Син җибәргән акчаны һәм хатны алдым, исән-саулыгыңа, хезмәт урының җайланганга ифрат шатмын. Әле өченче көн генә Аптекаевларга тагын барган идем, исәп Гарифә апаны күреп бер сөйләшү иде. Кызганыч, аны күрә алмадым. Бары Сафия апа гына килгән икән. Аларга өзлексез йөрү минем өчен ифрат җайсыз, әйтерсең лә мин якынлыгымны аларга көчләп такмакчы булам.

Үземнең көннәр бер-бер артлы сизелмәстән үтеп торалар. «Каһәр суккан тел»не язып бетердем. Хәзер акка күчерәм.

Әтидән хатлар аласыңмы? Ул нигә миңа хат язмый? Әллә үпкәләгәнме?

Безнең әле монда күңелсез бер хәл булып алды. Әйбер урлаган өчен берничә кешене хөкемгә тартып, кайберсенә бишәр, унар ел бирделәр.

Мин монда калачакмын. Хезмәтемне Куйбышевта төгәлләргә туры киләчәк. Ә срок тулганчы кайту (син уйлаганча) мөмкин нәрсә түгел. Хәзер без монда бик аз калдык. Иркен. Минем хәзер язу белән шөгыльләнергә дә вакытым артты.

Әни, әгәр син «Сов. әд»ның адресын җибәрә алсаң, бик әйбәт булыр иде.

Хәзергә башка хәбәрләрем юк. Йөзеңнән үбеп, ялкынлы сәлам белән, улың Атилла».

«Куйбышев, 28.09.40

Сөекле әни һәм Суфия апа!

Сезнең ике хатыгызны да алдым. Исән-саулыгыгызга һәм җизнинең исән-сау кайтачагына бик шатмын. Моңа кадәр, чыннан да «Каһәр суккан тел» белән маташуым аркасында, сезгә хатларны сирәгәйткән идем. Инде хәзер хикәя язылып та, күчерелеп тә бетте. Иртәгә аны Казанга җибәрәм. Исәп моннан соң бераз ял итеп алу. Хатларымны да үз вакытында язармын. Хәзер кәефем яхшы, хикәяне язып бетергәч, тагын да яхшыра төште. Чөнки, дөресен әйтим, мин аңа бик күп көч түктем. Белмим, нәрсә диярләр Казанда. Мин анда лыгырдаучы, ялкау, утырышлар ясап, докладлар сөйләп йөрүчеләр, үз милекләре турында гына кайгыртып, идеясез, тормышта пассив яшәүчеләрдән көлдем. Хикәя байтак озын булып чыкты.

Хикәя язуның бер хикмәте бар икән — ул да булса, аның турында язгандагыңа караганда, редакциягә җибәргәч, күбрәк баш ватасың икән. Минем бурычым хәзер ничек булса да аның турында азрак уйлау, үземә берәр күңел юаткычы табып, шуның белән шөгыльләнү.

Көннәр монда әле һаман аяз. Кичә яңгыр булып алса да, бүген көн шундый матур, һавага чыгасы, урамнарда йөрисе килә.

Гогадан күптән түгел генә бер хат алдым. Бүген аңа хат язарга кирәк. Зиннәт тә миннән хат көтәдер инде. Әтидән әле хат алганым юк. Морат нишләп җавап язмый икән, син аңа хатны җибәрдеңме? «Тукай»дан башка Декадага тагын нәрсәләр әзерлиләр икән? «Тукай», гомумән, яхшы нәрсә, ләкин аның беренче күренеше уңышсыз. Аны прозада язу яхшырак булыр иде. Аннан, минемчә, андагы хәлфә, мулла типларында бер дә яңалык юк. Алар, кызганычка каршы, безнең драматурглар тарафыннан һаман бер шаблон буенча эшләнәләр. Ул типларны тамашачы сәхнәдә бик күптән күреп килә инде... Авторлар өчен бу шундый ансат эшкә әйләнде — аларның ахмаклыкларын, наданлыкларын һәммә автор берүк төсләргә буйый да сәхнәгә чыгара.

Җизни кайтмадымы әле? Ничек, бик ябыкканмы, картайганмы? Суфия апа шатланып бетә алмыйдыр инде. Аларга кай якка китү турында ачык бернинди дә киңәш бирә алмыйм, тик Ерак көнчыгышта бик кыйммәтчелек икән дигән хәбәрне ишеткәнем бар. Кыскасы, үз ихтыярлары...

Әни, син үзеңне артык ватма инде. Дәвалануыңны дәвам иттер. Мин әле, бәлки, ел башында бер ун-унбиш көнгә Казанга кайта алырмын. Шундый эшкә мөмкинлек чыгардай кебек.

Һәммәгезгә ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп:

Атилла».

Югарыда күчерелгән хатларны укучы, бәлки, андагы кайбер моңарчы аңлатма бирелмәгән кешеләрнең исемнәренә игътибар иткәндер. Алар: Гариф Галиев, Касыйм, Губанов, Гога.

Гариф Галиев — мәгълүм язучыбыз. Без аның белән Татарстан җир эшләре комиссариатында бергә эшләдек. Мин терлекчелек бүлегендә, ул шунда басыла торган авыл хуҗалыгы журналы редакциясендә. Без аның белән шул чорда бик якынайдык, дуслаштык. Мин армиягә киткәнче, һәр көнне диярлек, ул эшләгән бүлмәгә керми калмый идем. Һәрбер яңа әсәремне беренче булып аңа укыйм (безнең эш бүлмәләребез янәшә диярлек). Ләкин хәзер мине гаҗәпләндергән нәрсә шул булды: Гариф абый, мин армиягә алынгач, үзенә ничәмә генә кат хат язмыйм, берсенә дә җавап кайтармады. Бу мине борчый һәм уйландыра иде.

Хатларда телгә алынган Касыйм, Губанов, Гога — институт шәрикләрем.

«Куйбышев. 14.10.40 (алдым 18.10)

Сөеклем әни!

Сиңа, Суфия апага, җизнигә ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Үзем исән-сау. Сезнең хатыгызны, журналны алып, исән-саулыгыгызга бик шатландым. Әтидән бер хат алып, җавап җибәрдем, ләкин башка хат алганым юк әлегә.

Әни! Мин үткән хатларымда язарга оныткганмын, моннан демобилизацияләнеп бер Ширданин дигән егет Казанга киткән иде. Ул синең яныңа кереп чыгарга сүз бирде. Кердеме?

Әтидән, хаты килгәннән соң, 20 сум акча алдым. Монысы яхшы булды. Театрга бардым. Син посылка җибәрмәкче булам дип язасың. Моның кирәге юк. Бернәрсәгә дә нәфесләнмим (аннан, акчаң булса, сатып алырга да була бит). Шуңа күрә, син утын әзерләп, үз кирәкяракларыңны барлагач, миңа бераз акча гына җибәр.

Әле «Совет әдәбияты»ннан бернинди дә хәбәр юк. Җибәргәнемә унбиш көн була инде. Бу мәсьәләнең торышын Галиев яхшы белә торгандыр онытмасаң сора: минем хикәяне алдылар микән?

Җизниләр урнаша алмаганнар икән. Хәерле булсын. Җизнинең әтине күрми китүе күңелсез булган. Башка язардай хәбәрләрем юк кебек. Минем турыда борчылма. Мин бик яхшы яшим. Барлык туганнарга, дус-ишләргә, танышларга сәлам әйт.

Сине сагынучы улың: Атилла».

«Куйбышев, 20.10.40

Сөекле әнием!

Хатыңны алып, исән-саулыгыңа ифрат шатландым. Үземдә исәнлек, әйтерлек яңалыкларым юк. Бу арада синнән башка беркемнән дә хат алмадым. Әти дә язмый, вакыты юк, ахры. Суфия апалар киткәннәр икән. Хәерле булсын, барып яхшы гына урнашсыннар, бәхетле яшәсеннәр.

Үзең ни хәлләрдә соң? Шулай да, барысы да киткәч, күңелсездер? Тик мин синең ялгыз калуыңа кайгырмыйм. Син үзеңнең көндәлек эшеңнән ямь табасың, үзеңә һәрвакыт күңел ачкычы — эш таба беләсең, тормыштан ләззәт таба беләсең. Син бит, әнием, тормышка философларча карый белә торган акыллы ана. Шуңа күрә мин синең өчен үземне тыныч тота алам.

Монда әле көннәр һаман матур, ифрат сөйкемле алтын көз хөкем сөрә. Яңгыр да яумый, кояш та елмаеп кына тора.

Иртәгә минем ял көнем, исәп — театрга барып кайту. Монда минем хәзер эшләр җайланды, ял көне саен кино карамый калмыйм, сирәкмирәк театрга да баргалыйм. Шәһәрдәге Үзәк китапханәгә йөрим, шуннан китаплар алам. Моннан бер атна элек бер хикәя яза башлаган идем («Бохари хәлфә» исемле), тик әле бер дә бу көннәрдә үземне эшкә мәҗбүр итә алганым юк. «Каһәр суккан тел» тынгылык бирми. Бүген «Сов.әд»ына хат салам. Кәефем яхшы, үземне сәламәт сизәм. Касыймның хатына, үзе озакламый китәм дигәч, җавап язмадым.

Ялкынлы сәлам белән, йөзеңнән үбеп улың: Атилла».

Хатларымда искә алынмаган, ләкин хәтердә нык сакланган башка иптәшләр дә укыды минем белән. Җае чыкканда бәлки сүз алар турында да булыр. Ә хәзер үземнең әдәби көнегүләремә әйләнеп кайтыйм.

«Каһәр суккан тел»не журнал редакциясенә җибәргән булсам да, ул йөри торгач, Язучылар союзындагы проза секциясенә барып эләккән. Хәер, мин өзеп кенә ул вакытта секцияләр булгандыр дип әйтә дә алмыйм. Һәрхәлдә, аны бер төркем язучы тикшергән, миңа соңыннан шул утырышның беркетмәсен җибәрделәр. Ул утырышта, минем әнием дә була. Беркетмәне шәрехләү рәвешендә дип әйтик, мин аның бу турыдагы хатын да алдым.

Әлбәттә, әнием, ул утырышта тыңлаучы сыйфатында гына, сүзгә һич катнашмыйча утырган. Минем хәтердә калганы шул: әсәр хәзергә басарга яраклы түгел икән. Кави Нәҗминең әсәр турындагы җылы гына сүзләрен хәтерлим. Афзал Шамов мәсьәләне кабыргасы белән, бездә сатира булырга тиеш түгел, дип куйган.

Мин язучы агайларның бу карарын артык авырдан кабул итмәдем шикелле. Гариф Галиевнең утырышта бер сүз дә әйтми калуы гына аптырашка төшерде.

Әйе, әсәремнең тумас борын «суелуын» артык авыр кичермәдем. Ләкин бу вакыйга мине күп нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итте. Каравыл өендә йокламый ял иткән араларда яки казармада чакта гел әдәбият турында, аның урыны, әһәмияте һәм безнең заманда ул нинди булырга тиешлелеге турында баш ватам. Болай уйланырга русның бөек тәнкыйтьчеләре язган китапларны укып чыгуым да сәбәп булды. Мин Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Писарев әсәрләрен бик бирелеп укыдым.

Менә ничә елдан бирле инде үзебезнең телдә басылган хикәя, повестьларны укып барам. Русның шөһрәте таралган замана әсәрләрен дә укымый калмыйм. Мине аптырашка төшергән нәрсә хәзер шул: ни өчен укылган әсәрләрдә мин белгән тормыш барлык ягы белән чагылыш тапмый? Ни өчен без авырлыклар турында, тормышыбызның көләгәле яклары турында каләм тибрәтмибез? Ни өчен идея дошманыбызны кеше кыяфәтендә, үзенең кыйбласына инанган кеше буларак күрсәтмибез? Ә бит тормышта, минем белүемчә, һич алай түгел. Мин үземнең егерме биш еллык кыска гомеремдә андыйларны күрмәдем түгел. Һәм, әйтергә кирәк, аларның гамәлләре үз логикаларына туры килә.

Әгәр дә әсәр безне ышандырырга тиеш дисәк, ул тормыштан, анда булган хәлләрдән, андагы типажлардан аерылырга тиеш түгел. Юкса ясалма килеп чыга һәм җитди укучы аңа ышанмый.

Шулай уйлыйм. Бу мәсьәләгә үземчә төрле яктан килеп, өзлексез катлаулы мәсьәләләр чишәм. Ахыр чиктә, күп уйлана торгач, ике нәтиҗә ясыйм. Беренчесе: бернигә дә карамастан, чынбарлыкны үзем күргәнчә, үзем аңлаганча гәүдәләндереп, эпик жанрда күләмле әсәр язып карау. Икенчесе: «Каһәр суккан тел»дәге кебек шәрран ярып түгел, ә эзоп теле белән язып карау.

Сатира өлкәсендә әз-мәз тәҗрибәм булганга күрә, материал ансатрак бирелер, дип, мин икенче нәтиҗәне башта гамәлгә ашырырга булдым. Ул «Мәккәгә сәяхәт» булачак. Анда сүз догмаларга, катып калган

кануннарга буйсынучыларга каршы сатира рәвешендә барачак. Мин бу әсәремдә безнең заманның сектантчыларын күздә тотачакмын. Кыскасы, исәп — кыек атып, туры тидерү.

Ләкин бу әсәргә никадәр генә материаль тупларга тырышсам да, теләгемне тормышка ашыра алмадым. Дөресен генә әйткәндә, материалны мавыктыргыч рәвештә гәүдәләндерерлек сюжет таба алмадым.

Шулай ук беренче нәтиҗәгә китергән теләккә дә ирешә алмадым. Исәп «Токарь Харис Салихов» атлы реалистик бер роман язып карау иде. Анда әз генә дә иннек-кершән булмаячак, анда үзем күргән авыр Беренче бишьеллык чоры турында ачы хакыйкать кенә гәүдәләнәчәк.

Мондый әсәрне язам дигән теләккә дә ирешә алмадым,— дип яздым да уйга калдым. Бу бераздан «Дустым Зиннәт» булды бит. Ә аннан соң «Дустым Мансур»га әйләнде. Ул шул исемдә тәмамланып, бик зур үзгәрешләр кичергән хәлдә, әйтеп бетергесез түземлелегем, хәерхаһ кешеләрнең ярдәме аркасында дөнья күрде. Кыскасы, беренче нәтиҗәнең җимеше дип әйтик инде, өлешчә генә булса да тормышка ашты.

Минем роман жанрына мәхәббәтем бала чактан ук туган булса кирәк. Бу мәхәббәт, әниемнең миңа төрекчәдән тәрҗемә итеп укыган француз романнары, Галимҗан Ибраһимов әсәрләре, соңрак рус һәм бөтендөнья классикасы аркасында үсте, ахры. Хәтердә, мин әле Казанга күчеп килгәнче үк «Таулар итәгендә» исемле бер роман яза башлаган идем. Тик ул башланды да ташланды...

* * *

Күрәсең, минем постта күзлек киеп торуым белән исәпләшкәннәрдер, һич искәрмәстән, көннәрдән бер көнне мине каравыл ротасыннан янгын сүндерүчеләр командасына күчерделәр.

Минем хәзер җәмәгать эшләрем дә муеннан. Бушаган араларда склад территориясенең клубын бизәү белән шөгыльләнәм. Сәхнәнең ике ягына идәннән түшәмгә кадәр зурлыктагы Ленин һәм Сталин портретларын ясап куйдым. Лозунглар язам, стеналарга транспарантлар ясап эләм. Миңа еш кына склад мастерскойларында эшләүче ялланган эшчеләр өчен төрле темага докладлар ясарга кушалар, ул ара булмый, укытучылык вазифасы йөкләнә. Мин белемнәре түбән булган кызылармеецларны укытам.

Безнең складлар биләмәсендә зур-зур остаханәләр бар. Алар амуниция, өс һәм аяк киемнәре төзәтү тегү мастерскойлары. Анда шәһәрдән ялланган эшчеләр эшли. Безгә, комсомол активистларына, алар арасында булырга, алар белән дә сәяси эш алып барырга кушалар.

Шулай итеп, мин кышның узганын сизми дә калдым. Көннәрдән бер көнне «карт»ларга кайтырга дигән приказ килде. Кинәт күңелләр Казанны, җылы өй учагын сагыну хисләре белән бер җилкенеп алды. Эх, шул «карт» солдатлар белән өйгә кайтып дусларны, якыннарны күрсәң иде!

Демобилизациягә эләккәннәрнең күңел күтәренке хәзер. Алар өйгә алып кайтасы әйберләрен хәстәрлиләр. Командование аларга башта ук өр-яңа обмундирование биреп куйды. Тик бераздан яңа приказ чыгуы гына эшне бозды. Егетләргә бу яңа киемнәрне алып кайтырга туры килмәде. Маршал Тимошенконың приказында, өйгә кайтучы кызылармеецлар өченче категорияле киемнәр генә киеп китәргә тиеш, диелгән. Бу өченче категорияле обмундированиене мин Кузнецкидан ук беләм. Өйгә кайтучы солдатның нинди мескен бер кыяфәткә керәсен дә яхшы аңлыйм. Ләкин нишләмәк кирәк, приказ — приказ инде!

«Куйбышев, 10.11.40

Сөекле әни!

Синең 5 сендә язган хатыңны бүген алып ифрат шатландым. Үземдә исәнлек. Бәйрәм көненә котлау телеграммасы җибәргән идем, шаять,

алгансыздыр. Бу арада хат алышу мәсьәләсе бик кыенлашты. Үч иткәндәй, бирәү дә язмый. Синнән хатны, дөресен әйтим, дүрт күз белән көтеп алдым. «Сов.әд»ына һәм Галиевка хатлар язган идем, алардан да җавап ала алмадым.

Валлаһи син чәнчелеп кит,
Тончыгып үл, бет, кадал,
Шунда да һичкем дә күрмәс,
Валлаһи бер эт кадәр.*

Кыскасы, миңа димәгәе әллә ни кылансыннар, мин үземнең тынычлыгымны сакларга тырышачакмын...

Бу хатны бик усал итеп язмакчы идем, бары синең хатың гына фикеремне үзгәртеп җибәрде. Ул миңа кинәт тынычлык һәм сабырлык бирде. Шуңа күрә, син минем бу хатымда, бүген иртә белән булган кәефемне күрмәссең. Бүген әле, җитмәсә, монда танышкан, инде ияләшкән иптәшләр дә өйләренә кайтып китте. Бу да миңа тәэсир иткән булса кирәк. Тик син минем бу сүзләремә әһәмият бирмә. Була торган хәл. Мин һәрвакыт шулай, тора-торгач психланып китәм, гаҗәп, сәбәпсезнисез эч пошу белән азапланам. Һәм бу халәтемне бернинди хезмәт, бернинди китап җиңә алмый. Үз көчем генә җиңә. Буш вакытымны күбрәк китап укып уздырам. Мопассанны укыдым. Әле бүген китапханәдән Толстойның «Война и мир»ын алып кайттым. Үземнең бер дә яза алганым юк. Бәлки, бүген «Токарь Харис Салихов»ка тотынырмын. Бу темам бик зур, мин аны һаман киләчәккә калдыра килдем, ләкин хәзер түземем калмады.

Син чәй турында сорыйсың. Аны бүген үк белешермен, ләкин ышандыра алмыйм. Булса, тиз арада җибәрермен. Адресым алмашынды.

Фотога төшкән идем. Бу хатым белән шуның берсен җибәрәм. Сиңа эш планы теге якта.

Йөзеңнән үбеп, ялкынлы сәлам белән: Атилла.»

«Куйбышев. 15.11.40 (20 алдым).

Әни!

Сиңа әле күптән түгел генә хат һәм фото җибәргән булсам да, сезнең коллектив хатыгыздан соң, җавап язуны кирәк таптым.

Сиңа Әхмәтшакировның әтисе килгән икән. Эшне болай аңлатырга кирәк. Әхмәтшакиров Мәҗит (бездә аны Женя дип йөртteләр) кулга алынгач та, миңа үзенең кайбер кызылармеецларда акчасы булуын хәбәр итте. Аның әйтүе буенча, аларда сиксән сум акчасы булырга тиеш иде. Ләкин мин аның үтенечен башкара алмадым. Чөнки шул ук көннәрдә аңа бурычлы кешеләр бөтен взвод белән бүтән шәһәргә күчеп киттеләр.

Казанлылардан монда тагы Николай Ступишин дигән егет кенә бар, аның өй адресы Чехов ур. 28 нче йорт булса кирәк. Мин акчаларны җыю мөмкинлеген югалткач, бу эшне шуңа йөкләдем, чөнки ул да шул взвод белән китте.

Беләсең бит, кешеләрнең төрлесе була. Мәҗит кулга алынгач, аңа бурычлы кешеләр үзләренең бурычларын яшерә башладылар. Мәсәлән, Таубе дигән бер бәндә аңа 30 сум тиеш икән. Шул күзгә карап, мин аңа бирдем инде, дип алдады. Шунысын беләм: Ступишин Сергеев дигән егеттән 50 сум акча алып китте. Ул миңа, акча җыелу белән, Казанга җибәрермен, диде.

Инде чемодан турында. Аны мондагы начальство, Мәҗит кулга алыну белән, җыештырып куйган. Ул да взвод белән бергә китте. Мин Мәҗиттән бер хат алган идем. Ул бераз ачыга булса кирәк. Тик, кызганычка каршы, минем аңа передача илтергә мөмкинлегем юк. Хат

* Ш. Бабич шигыре.

яздым. Хатка җавап булмады. Әтисенә әйт, Мәҗиткә посылка салсын. Аннан Ступишинга хат...»

«Куйбышев. 15.XII.40...
Сөекле әни!

Сиңа бераз соңга калып булса да, хат язам. Әлегәчә язмавым өчен ачуланма — вакытым булмады. Үземдә исән-саулык. Көннәр сизелмәстән үтеп тора. Хәзер кыш үзенең хакимиятен алды, көннәр шундый салкын, колакларны чеметтерә башлады. Әле кичә генә син җибәргән акчаны (15 сум) алып, опереттага бардым. Тегеләй үзем бер дә салкын дип тормыйм, кирәкле җиргә бармый калганым юк. Көн аралаш диярлек чаңгыда шуабыз, кичә конькилар да алдык. Кыскасы, үземне бик яхшы сизәм, күңелем көр, уен-көлке белән шулай яңа елга да якынлашабыз. Ә яңа ел үтсә, аннан кыш та үтсә, Казанга кайту вакытым җитте дип хисаплыйм инде.

Йә, үзеңдә ни хәлләр бар? Синең узган хатың берникадәр күңелсез язылган иде. Хәзер инде кәефең яхшыргандыр дип ышанасым килә. Чөнки һаман эч пошу булмый бит ул, кайвакыт күңелле дә булып китә.

Син, әни, журналлар җибәримме, дип язасың. Миңа хәзер аның кирәге юк. Мондагы татар китапханәсенә алар кырык беренче елны килә башлаячак.

Ялкынлы сәлам белән, йөзеңнән үбеп: улың.»

«Куйбышев. 30/XII.1940.
Сөекле әнием!

Сиңа ялкынлы сәламнәр соңында тыныч, матур тормыш теләп калам. Бу хатым аз гына соңга калып барса да, сине Яңа ел белән тәбрик итәм. Яңа елда яңа бәхет, яңа куанычлар телим.

Үзем исән-сау. Синең соңгы хатыңны алдым. Исән-саулыгыңа ифрат шатмын. Хатыңда, инде кыш, туңа торгансыңдыр, дип борчыласың. Зинһар, минем өчен хафаланма. Минем өстем бик җылы, аякта яхшы күн итек (ике кат бумази чолгау), аның өстенә мин бит хәзер «карт» солдат, без күбрәк «җитди» эш белән мәшгуль, тышка чыгып, өйрәнеп, уйнап йөрергә миңа күп туры килми. Моңа кадәр җибәргән хатларымда язгалаган идем, материаль ягым (ашау-эчү, кием-салым) бер дә борчылырлык түгел.

Көннәр бер-бер артлы узып кына тора. Хикмәт шунда, шул ашкынып узган көннәр файдасызга үтмәсен иде. Мин шуны истә тотып, һәрвакыт «авызлык»ны ныграк тартам, үземне көчләп булса да, берәр эш белән шөгыльләнергә тырышам. Инде русның классик тәнкыйтьчеләрен укып чыктым, чиратта инглиз теле тора.

Кыскасы, шундый бурыч: көзгә кадәр инглиз телен үзләштерү, Марк Твенны оригиналда укырлык дәрәҗәгә җиту.

Монда да салкыннар башланды, 20—22 градус салкын. Син, Быковтан хат алдым, дип язасың. Ни өчендер ул минем хатыма җавап бирмәде. Әтигә дә язган идем, аннан да әлегә җавап юк. Туганнарның бөтенесенә сәлам. Мөхәммәт абыйга бүген язам. «Кызыл Татарстан»га яңа елга карата «Очрашу» исемле хикәя җибәргән идем, басылдымы?

Йөзеңнән үбеп, улың: Атилла».

«Куйбышев. 22.1.1941 (алд. 28.1)
Сөекле әнием!

Синнән бик күптән инде хат алганым юк... Үзем исән-сау. Көннәр бер дә сизелмәстән үтеп тора. Менә инде кыш уртасы да җитте. Берәр ай вакыт үтү белән карлар эри башлар, минем иң яраткан айларым март-апрель килеп тә җитәр.

Хәер, хәзер дә начар түгел. Кышкы салкыннарның да яме бар. Чаңгыда шуабыз, еш кына шәһәргә чыгарга мөмкинлек туа. Буш вакы-

тымны инглиз телен өйрәнүгә багышлыйм. Тик шунсы начар, бернәрсә дә яза алганым юк. Әле күптән түгел генә әтидән хат алдым. Ул мескен һаман минем үтенечемне үти башламаган икән. Менә тагын бер хат язып җибәрдем. Белмим, нишләр инде? Ничек булса да «Мәккәгә сәяхәт»не язарга иде. Билгеле, бу нәрсәне очлап чыгу өчен әтинең һәм синең материалларың белән чикләнү генә аз булыр, миңа байтак әдәбият укырга туры киләчәк. Монысын инде Казанга кайтуга калдырам.

Син хатыңда, кара аны, борчылма, дисең. Юк, сөекле әнием, әз генә дә борчылмыйм. Хикәянең шулай каршы алыначагын мин башта ук тойдым.* Минем хыялымда анда әйтеләчәк сүзләрнең һәммәсе дә җанлана иде. Бары аларның авторлары гына минем өчен мәгълүм булмады. Г. Галиевнең дәшми калуы миңа хәзер аңлашыла.

Быковтан бер ящик папирос алдым. Менә дус ичмасам, чын мәгънәсе белән! Рәфкатькә хат яздым. Шакир абыйның авырып китүе бик күңелсез нәрсә. Исән-сау авырудан котылса, аны Казанга кайтарырга иде инде. Рахман абыйларга һәм башка туганнарга ялкынлы сәлам.

Сәлам белән йөзеңнән үбеп: Атилла».

«Куйбышев, 3 III. 1941 (алдым 10.III)

Сөекле әнием!

Синең хатларыңны алдым. Үземдә исәнлек. Әллә ни яңалыкларым юк, һаман бер көе күңелле генә яшәп ятам. Шулай итеп, март ае да керде. Ләкин әле тышта һаман кыш. Кар ифрат дәрәҗәдә күп. Сирәк-мирәк булса да без әле һаман чаңгыда шугалыйбыз. Син хатыңда, егерме километрга барганда бик арымадыңмы соң, дип язасың. Бер дә арымадым. Өстә тулы боевой выкладка (мылтык, көрәк, скатка, сулы фляга) булуга карамастан, юлны бер сәгать тә илле тугыз минутта үттем. Үзебезнең кызылармеецлар арасында беренче урынны алдым, ә подразделениедә беренче урынны командир алды.

Синең үтенечне әле булса үти алганым юк. Дөресен генә әйткәндә, аның артыннан йөрергә вакыт таба алганым юк. Без шәһәргә ял көннәрендә генә чыга алабыз. Анда да чикләнгән вакытка. Шуңа күрә, соңга калмас өчен, сәгатькә карый-карый гына йөрергә туры килә. Шулай да мин берәр чара күрми калмам.

Әле күптән түгел генә Муллахмәттән** хат алдым. Ул Грузиядә Зистофани дигән бер шәһәрдә хезмәт итә икән. Хәзер аны өенә кайтарып җибәргәннәр. Аның рухы күтәренке, шатлыклы хатын алдым. Юлдан яза. Ә безнең монда төрле сүзләр йөри. Имеш, безне 1 нче майда кайтарачаклар икән. Тик бу сүзләргә бик ышанырга ярамый. Вакыты җиткәч, үзебез күрербез.

Әтидән кичә утыз сум акча алдым. Бер дә вакыт юк, дип яза. Иняз институтының читтән торып уку бүлегендә икән. Кичләрен зурларны укытам, дип яза. Син җибәргән беркетмәләрне укыдым. Аларны үзең дә укып чыккансыңдыр инде. Шуңа күрә бу турыда берни дә язмыйм: Редакциягә: «Сез әсәр турында сөйләгән язучылар фикеренә кушыласызмы?» — дип яздым.

Үземнең мондагы хезмәтемә килсәк, берни дән дә зарлана алмыйм. Бетеки генә начальник — ефрейтор иттеләр. Гомумән, монда мин почетлы кеше, хәтта округ газетасында да мактап, «Комсомолец Расулев» дип бер заметка бастылар.

Хезмәт срогым күп калмады инде. Шул арада мин «Мәккәгә сәяхәт» дигән әсәр язарга әзерлекне тәгәлләргә тиеш. Хәзер тарих белән шөгыльләнәм. Инглиз телен өйрәнүне һаман дәвам иттерәм. Тик эш акрын бара.

Йөзеңнән үбеп, ялкынлы сәлам белән: Атилла».

* Сүз «Каһәр суккан»тел турында бара.
** Муллахмәт — Троицк егете, бергә уйнап үскән егет.

«Куйбышев. 3.IV.41 (алдым 9.IV)

Сөекле әнием!

Синнән әле генә хат алып укыгач, кулыма кәлам алдым. Синең авыруына бик борчылдым. Ничек кенә сиңа ярдәм итәргә, ничек кенә синең чиреңне бетерергә? Мин нишләргә дә белмим. Зинһар өчен яхшы докторларга күрен, әйберләрне саттыр. Минем пальтомны булса да сат, мин аның өчен әз генә дә борчылмам, кайткач рәтләрмен әле. Ничек булса да акча рәтлә дә яхшы докторларга күрен. Ә җәйгә сиңа (монда нәтиҗә чыкмаса) Мәскәүгә барырга кирәк. Зинһар өчен берни белән дә исәпләшмә, мөмкин булырлык бөтен чараларны күр. Инде бер дә булмаса, мин «Сов.әд.» редакциясенә язып карармын, бәлки алар ярдәм итәр.

Үземнең көндәлек тормышымда бернинди дә яңалык юк, һаман бер көе хезмәт итеп ятам. Минем алты айдан кайтуымны көтәргә хаклы син. Нарком приказыннан соң, безне монда озак тотмаячаклар, китәсе кеше аз, (алмаш) көтмәсәк тә була.

Әтидән кичә утыз сум акча алдым. Хәбәре юк, исәндер дип уйлыйм. Аңа хат язган идем. Башка язарлык яңалыкларым юк. Мин бик яхшы яшим, минем өчен борчылма.

Ялкынлы сәлам белән, йөзеңнән үбеп, улың: Атилла.»

«Куйбышев, 17.04.41 (алдым 26.IV)

Сөекле әнием!

Хатыңны кичә алып, синең сәламәтлек хәбәреңә бик шатландым. Үземдә исәнлек. Кышны озатып, Май бәйрәмен каршы алырга җыенабыз. Соңгы атнада көннәр җылынып китте. Кар ифрат күп иде. Кыска гына вакытта эреп, урамнарны пычратты.

Моннан өч атна чамасы элек Казанга бер рус егете киткән иде. Ул безгә кереп чыгу өчен махсус адрес алып китте. Кермәгәндер, ахры, ул турыда бер сүз дә язмыйсың. Аннан үткән айда Казанда Касыйм булган икән. Аңардан шушы көннәрдә генә бер хат алган идем. Ул, Казанда унбер көн тордым, дип яза. Аңа вакытлыча ял биргәннәр икән. Ул сиңа керүен яза. Ләкин ишек бикле иде, башка керергә вакыт тапмадым, дип яза. Синең моннан элек язган хатыңны алгач, мин дә отпуск мәсьәләсен кузгаткан идем, ләкин барыбер берни чыкмас, диделәр. Чөнки аның өчен әниеңнең авыруын раслаган врач телеграммасы кирәк, диделәр. Шуңа күрә үзебезнең начальник белән сөйләшүдән ары китмәдем.

Үземнең тормышымда бернинди дә яңалык юк. Бу арада Урта гасырлар тарихын укыйм. Ул мәсьәләдә мин үземне бик көчсез сизә идем. Әтидән хат алганым юк.

Үткән ялның элеккесендә Мөхәммәт абыйларга бардым. Алар белән сөйләшеп, пирог ашап утырдык. Хәзер урамнарда йөрүе күңелле. Яз үз эшен эшли, күңелне тынычлыкка, кояшка таба тарта. Тик мин увольнительный алсам, тизрәк берәр китапханәгә ашыгам. Укыган саен үзеңнең наданлыгыңа борчыласың, күбрәк укыйсы килә.

Әни, минем сиңа бер киңәшем бар әле. Армиядән соң миңа ничек булса да укуны дәвам иттерергә, аспирантурага керергә кирәк. Син моңа ничек карыйсың?

Йөзеңнән үбеп: Атилла».

Менә яз да килеп житте. Һич уйламаганда, яңа алмаш килү белән, мине административ-хуҗалык бүлегенә өлкән писарь итеп күчерделәр. Мин хәзер склад конторасында эшлим. Казармадагы режим минем өчен хәзер закон түгел. Соң торам, ашханәгә төшеп ашыкмыйча гына ашыйм. Аннан конторага керәм.

Безнең бүлек аерым бер бүлмәгә урнашкан. Түрдәге өстәл артында начальнигыбыз утыра. Ул бик пөхтә, җыйнак, елдам һәм, әйтер идем, интеллигент кыяфәтле. Үзе татар, фамилиясе Габдрәшитов. Миннән башка тагын бу бүлмәдә урта яшьләрдәге, соры күзле, кара кашлы рус

хатыны — Кривицкая, анысы бухгалтер, ирекле хезмәтче. Тагы Зоя исемле машинистка бар.

Вазыйфаларым хәзер күпкырлы: складның административ хуҗалык эшләрен теркәүче мин. Ротага азык-төлек язып бирәм, склад башлыгының приказ кенәгәсен алып барам, ягулык, майлау материалларын исәпләү, җибәрү дә минем кулда. Һәм тагын Габдрәшитов приказларын үтим.

Миңа еш кына склад начальнигы янына керергә туры килә. Мин писарь булып конторага күчерелгәнче, склад башлыгы булып Линцер атлы бик мөгътәбәр кыяфәтле майор эшли иде. Аны алдылар, аның урнына фин кампаниясендә үзен әйбәт яктан күрсәткән, орден белән бүләкләнгән, бик озак еллар армиядә старшина булып хезмәт иткән тәбәнәк буйлы, соры, ач күзле капитанны куйдылар. Мин үземнең хезмәт чорымда аның якты чыраен күрмәдем дисәм, ялгыш булмастыр. Хәлбуки, аның өстәл артында утырган килеш кенә цех һәм склад начальникларын үрә бастырып, аты-юлы белән сүккәнен күп тапкыр ишеттем. Ул беркемгә дә үзенә каршы сүз әйтергә ирек бирми, кеше нидер аңлатырга теләп ымсынса, өстәлгә йодрык сугып, «молчать» дип кенә кычкыра. Ифрат матур яза, ләкин үзе бик-бик надан. Мин, татар малае, рус телен ничә ел өйрәнүемә карамастан, язуда хаталар җибәргәләсәм дә, начальник миннән дә күбрәк хата ясый, шуңа да карамастан, күп очракта минем дөрес итеп язылган сүземне бозып үзенчә итеп «төзәтә».

Көндәлек хезмәт бөтен барлыгыңны йота. Миңа һәркөн боерыкка кул куйдыру өчен начальник янына керергә туры килә. Мин аның шундый тупаслыгына, явызлыгына җаным-тәнем белән каршы. Сүгенмичә, җикеренмичә, өстәлне йодрыкламыйча җитәкчелек итеп булмый микәнни?

Авыр миңа мондый атмосферада хезмәт итү. Җитмәсә, складлар комиссары да кирәгеннән артык коры кеше. Кечкенә генә хатаңны да күпертеп, тәнбиһ ясарга тора. Мин аның үземне яратмавын бөтен күзәнәкләрем белән тоям. Ләкин берни эшләр хәл юк. Активист буларак, клубны бизәүче буларак, миңа аның белән гел бәйләнештә булырга туры килә.

Миңа авыр. Тик мин эштә кайныйм һәм бу миңа, күңел рәнҗүләренә бирешергә, газапланырга вакыт калдырмый. Хезмәт минем көндәлек тормышымны бизи. Хәер, бүлек начальнигым Габдрәшитов акыллы һәм гадел кеше, ул миңа карата ифрат игътибарлы, вакчыл түгел.

Ничек булса да көн артыннан көн уза. Ял көннәрендә увольнительный алып, шәһәргә чыгам. Менә язгы айларга да аяк бастык.

«Куйбышев. 14.06.41

Сөекле әнием!

Синең хатыңны кичә алып, бүген генә җавап язырга мөмкинлек таптым. Үземдә исән-саулык, бер дә ул кадәр әйтерлек яңалыклар юк. Хатыңда хәбәр ителгәнчә, «Очрашу», «Техника проблемалары» басылачак икән. Мин алар өчен борчылган идем.

Хәзер монда көннәр матурланды. Әле узган ялда Рождественога барган идек. Мөхәммәт* абыйны өйдә очрата алмасам да, көнне күңелле уздырдык. Табигать шулкадәр матур — мин эчмичә исердем.

Иртәгә ял көне. Тагын шунда барырга җыенам. Җәйне шулай «ял итеп» уздырырга уйлыйм. Кулыма китап алганым юк.

Ялкынлы сәлам белән, йөзеңнән үбеп, улың Атилла.»

Югарыда күчермәсе бирелгән хатларда Муллахмәт исемле кеше турында да сүз бара. Муллахмәт Галиев минем балачак дустым. Аның тышкы портретын һәм кайбер үзенчәлекләрен мин сугыштан соң дөнья

* Сүз М. Гали хатыны Сафия апаның энесе турында бара.

күргән «Дустым Мансур» исемле романымда яздым. Әлбәттә, прототибы Муллахмәт булган егетне Муллагали дип үзгәрттем, һәм аның язмышына үз фантазиямне дә шактый өстәдем.

Муллахмәт дустымның сугыш көчләп таккан язмышы, минемчә, бик кызыклы һәм гыйбрәтле.

Ул Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк алгы сызыкка эләгә. Камалышта кала. Аннан мең бәла белән котылып, Белоруссиядәге партизаннар отрядына эләгә. Совет партизаны татыган барлык газапларны үз җилкәсендә кичерә, үлем белән күзгә күз күп тапкырлар очраша, ачыга, күшегә, туңа. Көннәрдән бер көнне, дошман атакасы вакытында, боларга (алдан сөйләшү буенча) Муса Җәлил группасы әзерлеге аркасында безнең якка чыккан татар легионы кушыла. Легионерларның байтак өлеше безнең якка чыкканда немец офицерлары тарафыннан атыла, ләкин шулай да байтак кеше, ут сызыгын узып, партизаннар ягына чыгарга өлгерә.

Бу вакыйгаларны миңа Муллахмәт үзе бик тулы рәвештә сөйләде. Инде бу хәлләрдән соң булган вакыйгалар белән кызыксыныйк. Муллахмәт хезмәт иткән партизаннар отряды, көннәрдән бер көнне, Сталин приказы белән безнең тылга чыгарыла. Партизаннар, безгә ял бирелә икән, дип уйлыйлар. Ләкин бу нинди эш? Безнең якка аяк басу белән, аларны коралсызландыралар һәм барысын да Себергә озаталар.

Шулай итеп, Муллахмәт Себердән китмәскә кул куеп, Сталин вафатына кадәр гаиләсеннән аерылып, сөрелгән җирендә экскаваторчы булып эшли. Ниһаять, илдәге яңа җитәкчелек тарафыннан азат ителгәч, 1952 елны туган шәһәренә кайтып, хезмәт укытучысы булып мәктәпкә урнаша һәм вафатына кадәр (сиксәненче елгача) шунда эшли.

Әйе, бу — хатирәләремнең үзем турында барган юлыннан тагы бер чигенеш ясау булды.

Минем Куйбышев шәһәрендә армия хезмәтем дәвам итә. Менә гүзәл җәй айлары да килеп җитте. Армиядән кайтып китү көннәренә дә күп калмады инде. Мин түземсезлек белән Казаным, әнием, туганнар, дуслар белән күрешү көннәрен көтәм. Шулай да көтү көннәре, көндәлек хезмәт казанында кайнагач, җиңелрәк тоела. Без ял көннәрендә, һава әйбәт торса, Идел аръягына чыгабыз. Анда ап-ак ком җәелгән чиста пляж, коену урыннары.

Шулай көннәр бер-бер артлы узып тора. Көтелгән кадерле минутлар якынлаша, ул көнгә күпме калганын мин инде хәзер бармак белән саныйм.

Менә иртәгә егерме икенче июнь, якшәмбе көн. Әгәр һава аяз, җылы булса, без иптәшләр белән тагы Идел аръягына чыгачакбыз. Әйе, Армия хезмәте тәмамлануга күп калмады инде. Июньне узды дип исәплик. Июль, август, аннан көтелгән сентябрь дә килеп җитәр. Сентябрьдә приказ булыр. Ә аннан өйгә, сагындырган, төшләргә кереп интектергән Казанга юл тотачак абзагыз! Анда мине әдәбият мәйданы көтә, әнием, дусларым, каләмдәшләрем көтә һәм ирек көтә.

Мин шундый татлы уйлар дәрьясында агып, тирән йокыга талам. Иртәгесен без бер төркем хәрбиләр (күпчелеге сержантлар) иртәнге аштан соң ук, Идел ягына таба ашыктык. Көне дә, безнең бәхеткә каршы, искиткеч җылы, якты, җилсез. Без паромга утырып аргы якка чыгабыз да, өс киемнәребезне салып ташлап, трусиклардан гына йомшак комга сузылып ятабыз. Иртәнге кояшның нурлары тәнне иркәли. Кызудан бер заман аркалар чымырдый башлагач, бердән кубып, салават күперләре күтәреп, суга ташланабыз. Рәхәт тә соң колач салып Идел суларында йөзүе!

Суда җитәрлек юанганнан соң, дүрт тәмам почмаклангач, без киенеп, изү төймәләрен каптырмыйча һәм каешларны билгә бумыйча гына, стеналары чолтәрләп ясалган, Идел киңлекләренә караган павильонга кербез, икс өстәлне янәшә куеп шунда утырышабыз да калай банкалар-

дагы алсу диңгез крабы капкалап күбекле, бөҗырдап торган данлыклы Куйбышев сырасын эчәргә керешәбез.

Хәтергә бик нык булып сеңгән: без шулай шау-гөр килеп сыра эчкәндә, күктән төшкәндәй, кинәт өстәлебез янында таныш кызылармеец пәйда булды. Аның ашыгудан йөзе кызарган, сулышы капкан иде.

— Хәзер үк сезгә частька кайтырга приказ! — диде ул тотлыга төшеп.— Мине дежурный җибәрде.

Мондый хәлнең моңарчы булганы юк иде әле. Кыяфәтенә караганда, егет артыгы белән тетрәнгән. Ниндидер хәтәр хәл бар, күрәсең. Кемдер сорады:

— Нинди сәбәп соң мондый тревогага? Без бит увольнительныйда әле.

— Сугыш! — диде кызылармеец.— Ишетмәдегезмени, Германия безгә ябырылып керә. Фашист инде безнең берничә шәһәрне бомбага тоткан. Радиодан хәбәр иттеләр.

Без сырабызны оныттык, шундук сикереп урыннарыбыздан куптык, әйтерсең лә тревога сигналы яңгырады. Өс-башыбызны тәртипкә китерә-китерә йөгерешәбез. Менә сиңа Казан! Менә сиңа тиздән буласы демобилизация!

Илгә михнәтләр, күз яшьләре, дәрьялардай аккан адәм каны, ачы хәсрәт, газаплар алып килгән Бөек Ватан сугышы башлануы безгә әнә шулай мәгълүм булды.

Икенче көнне үк безнең склад хозурында яңа хәрби подразделениеләр оеша башлады. Башлыча алар фронт, сугыш өчен бик кирәкле хуҗалык бүлекчәләре, мунча-кер юу отрядлары иде. Безнең казармаларда, склад территориясендә шул хәрби бүлекчәләргә алынган кешеләр күп хәзер. Аларга хәрби кием-салым бирелә. Өр-яңа гимнастерка-чалбар кигән командирлар, пилоткаларын кырын гына киеп, партупея каешларын шагырдатып, безнең контора тирәсендә иртәдән кара төнгәчә яңа оешкан подразделениеләренең йомышларын юллап йөри башладылар. Аларны азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итү эше миннән башлана. Мин, отряд командирларының расланган докладнойлары нигезендә, аларга кирәк әйберләрне алу өчен язу бирәм. Ул отрядлар саны көннән-көн артып тора. Һәрберсен, формалашып бетү белән, хәрәкәттәге армияләргә озатабыз, яңа төзелә башлаганнарын киендерәбез, туендырабыз. Өзлексез эш, эш, эш! Ул иртәдән кара төнгә хәтле дәвам итә. Бу эш бездә формалаша торган отрядлар белән генә дә бетми әле. Без — фронтка, фронт тылларында оешучы хәрби бүлекләргә көн саен вагоннарга тутырып кием, кирәк-ярак озатабыз. Фабрикалардан товарлар килә, бездә исә аны шундук фронт ихтыяҗлары өчен эшкә җибәреп торалар. Эшем тавык чүпләп бетермәслек. Җитмәсә әле миңа һәр көнне төн уртасына кадәр чират торып, шәһәр хәрби комендатурасында иртәгесе көнгә безнең складларга ничә йөк машинасы кирәклеген белдергән заявка ясарга кирәк. Мин хәзер иртәнге алтыда торып, ашык-пошык капкалыйм да эшкә керешәм, контордагы эшләр беткәч, комендатурага чабам. Ә аннан күп вакыт төн уртасында гына кайтыла.

Әйе, әти, әни, туганнар, дуслар, әдәбият турында уйланырга бары комендатура коридорында чират көтеп утырганда гына вакыт кала.Ниләр бар икән хәзер Казанда? Иптәшләр, дуслар кайларга таралды микән? Әнием бу сугыш башлануын бик авыр кичерәдер инде. Ул минем өчен аһ орадыр, мескен. Хәер, мин аны тынычландыру өчен егерме икенче июньдә үк телеграмма суктым. Бер-ике көннән соң кош теле кадәр генә булса да хат җибәрдем. Ләкин ул минем холкымны яхшы белә бит. Минем фронтка китәргә атлыгып торуымны белмәс дисеңме?!

Казаннан хатлар килеп тора. Габдрахман абыйның олы улы, минем туганнан туган сөекле энем Шәүкәтне армиягә алганнар. Ул әле генә ун класс тәмамлаган иде. Мин аның турында уйланам, борчылам. Ул әле бала гына, тәҗрибәсез, хәйләсез. Мин Зиннәтнең хәзер авиация заводына

эшкә кучүе һәм шунда бронь белән армиядән азат ителүе турында хәбәр алам. Наил, кайчандыр пилмән бөгү автоматлары ясау турында хыялланган дус егет, армиягә киткән, хәбәре юк. Кайда ул, ни булган аңа?

«Куйбышев. 6/VII.41.
Сөекле әни, әти һәм Лалә* апа!
Башта барыгызга да, йөзләрегездән үбеп, ялкынлы сәлам. Белмим, минем хатны һәм телеграмманы алгансыздырмы, юкмы, ни өчендер һаман җавап юк. Ни эшләр бетереп ятасыз? Хәзер Казанда, табигый, яңалыклар бик күптер инде. Минем дуслар барысы да армиядәдер. Шәүкәт китмәдеме әле? Аның өчен бик артык борчылмасыннар, аны өйрәтмичә торып барыбер фронтка җибәрмиләр әле. Ә ул өйрәнгәнче бәлки, сугыш та бетәр. Без барыбыз да җиңәчәгебезне беләбез. Җиңелүнең булуы мөмкин түгел.
Үзем турында шуны хәбәр итәм: минем өчен борчылмагыз.
Ялкынлы сәлам белән: Атилла.»

«Куйбышев, 9.07.41
Сөекле әнием һәм әти!
Сезнең соңгы хатыгызны бүген алып, җавап язарга ашыгам. Үзем исән-сау. Әйтерлек ул-бу яңалык юк. Эш белән көннәр үтеп тора. Бу хатны бары справка җибәрү өчен генә яздым. Әти җибәргән 40 сум акчаны, хатларыгызны һәм журнални алдым. Хикәяне** яхшы басканнар, ләкин аны укуы хәзер күңелле түгелдер кебек тоела. Соңга калып басылган бер хикәя булып калды ул.
Әни, син хатыңда күпме акча салыйк, дип сорыйсың. Әгәр үзегезгә акча кирәкмәсә, миңа барысын да җибәрегез. Миңа папирос өчен кирәк.
Ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: Атилла.»

«14.07.41
Сөекле әнием һәм әти!
Бүген Казанга китәчәк иптәшем Сазанов аркылы сезгә үземнең исән-саулыгымны белдерәм. Миндә әйтерлек яңалыклар булмаса да, бу хатны, алып баручы кешегә сезнең адресны белдерү өчен җибәрәм. Моннан берничә көн элек сезгә белешмә салган идем, алгансыздыр. Минем тормышымны сорашып белерсез. Бу кеше белән без бергә торабыз. Ул да писарь.
Ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: Атилла.
Туганнарга, танышларга сәлам».

«Куйбышев. 22/VIII-41 (алд.31.VIII)
Сөекле әнием һәм әтием!
Сезгә кош теле кадәр генә хат язып салам. Мин исән-сау. Хатны озаклап утырып язарга бер дә вакытым юк. Авылга китәргә җыенабыз, дигән идегез. Мин моңа каршы түгел. Әле бездә хәзергә берничнди дә яңалык юк. Әгәр берәр үзгәреш булса, хәбәр итәрмен. Минем өчен бер дә борчылмагыз.
Туганнарга сәлам, йөзләрегездән үбеп: Атилла.
P. S. Әдәбият дөньясында нинди яңалыклар барын зинһар өчен языгыз әле. Газетада яңа хикәяләр басыламы?»

Эш, эш, эш. Иртәдән кара төнгә кадәр баш күтәрми эшлим. Ә радио гөлдерек мичкә тавышлы Ливитан басы аша көн дә берсеннән берсе күңелсез хәбәрләр китереп тора. Хәтердә, без ашханәгә барыбыз да, аягүрә басып, тын да алмыйча дигәндәй, Сталинның чыгышын тың-

---

* Лалә — туганнан туган апам.
** Сүз «Совет әдәбияты»нда басылга «Очрашу» исемле хикәя турында бара.

ладык. Мин бизәгән клубта бер лектор, безнең әллә ничә генералыбызның дошманга сатылып фашистлар ягына күчүе турында, фронтларда хәлләрнең чиктән тыш авыр булганлыгын, фашист гаскәрләренең бөтен тирә-юньне пыран-заран китереп, алга баруларын сөйләде. Шомлы авыр көннәр. Димәк, ил язмышы, социализм язмышы кыл өстендә. Ә мин тирән тылда, фронттан еракта, дары исен бөтенләй белмәгән хәлдә писарь булып җылыда утырам. Эшем күп, аның кирәкле эш икәнен дә беләм. Ләкин, ни әйтсәң дә, ил язмышы бүген тылда түгел, ә фронтта хәл кылына. Ә мин?

Түзмәдем, көннәрдән бер көнне үземчә бик нигезләп АХЧ начальнигы капитан Габдрәшитовка рапорт яздым. Менә мин аның каршында басып торам. Хәтерем ялгышмаса, ул бу чакны үзе аерым бер бүлмәгә урнашкан иде. Мин аңа рапортымны сузам.

— Бу нәрсә бу? — ди минем башлык, әле бөтенләй рапортны укымастан.

— Фронтка җибәрүегезне сорыйм. Минем урын хәзер анда булырга тиеш дип уйлыйм.

Габдрәшитов кара күзләрен кызу-кызу йөретеп, минем язуны укып чыкты да үзенең бездәй чәнечкеле карашын миңа төбәде.

— Син анда хәзер нинди гарасат икәнлеген беләсеңме?

— Беләм.

— Белсәң, менә шул, синең урының монда!

Ул, артык бер сүз дә дәшмәстән, мин язган рапортны зәһәрләнеп ертты да өстәл астындагы чүп әрҗәсенә ташлады.

— Кругом, шагом марш!

Армиянең законнары каты. Анда командирга буйсынмый булмый. Чыгып китүдән башка чарам юк иде. Үз өстәлем торган зур бүлмәгә кердем. Анда инде мине яңа оештырылып яткан отрядларның старшиналары солдатларына азык-төлек яздырып алу өчен чират торып көтәләр иде. Урыныма утырдым. Егетләрнең артык тавышланмавын үтенеп эшкә керештем. Әйе, керештем генә түгел, кара төнгә кадәр муеннан эшкә чумдым. Кулга корал тотып сугышырга туры килмәс микәнни инде миңа?

Ләкин атна-ун көн узмагандыр, язмыш миңа, сугышның нәрсә икәнлеген күрсәтергә теләгәндәй, бер кызык ясады. Фронт төбәгенә, дөресрәге Орел шәһәренә, кием-салым алып бару өчен предписание бирделәр.

Мин шыплап хәрби кием тутырылган ике вагонны Орелдагы хәрби бүлешмәгә озатып куярга тиеш. Наган бирделәр, бер капчык азык тоттырдылар, мин шул ук көнне станциягә барып, вагоннар кабул иттем һәм төнлә китеп тә бардым.

Хәзер юл мәшәкатьләренең барлык ваклыкларын хәтерләмим. Ләкин вагоннарымны станцияләрдә тоткарлау булмады. Ул — хәрби йөк, аңа яшел урам. Вагоннарны әле бер йөк составына, әле икенчесенә тагып һаман Орелга таба өстерәделәр. Тамбурда барам. Ярый көннәр җылы. Станцияләр халык белән тулы. Капчыклар аскан, чемоданнар, төенчекләр күтәргән сугыш утыннан качып килүчеләр, яралы һәм таза хәрбиләр, әбиләр, бабайлар, нәни балалар... Барысының йөзендә дәһшәт шәүләсе, барысында да гаҗизлек билгесе. Тавыш, гауга, җылау, юктан гына кычкырышу. Яралы гаскәриләр һәм качаклар нинди генә юллар белән булса да Көнчыгышка әле сугыш ялкыны җирне сыпырып узмаган якларга китәргә ашыгалар. Бары безнең фронт ягына китүче составлар тирәсендә генә тыныч, безнең составка сау-сәламәт хәрбиләрдән башка берәү дә ябырылмый.

Әйе, мин ут эченә, фронт ягына таба барам. Юлда бомбага тотылган җирләр, җимерек шоссе юллар, тимер юл станцияләре күренә башлады. Дошман самолетлары безнең күктә үзләрен хуҗа итеп тоялар, ни теләсәләр, шулай кыланалар. Дошман безнең авиацияне бар дип тә белми. Бомбага тотылган, чәрдәкләнеп, куырылып, янып беткән поезд

составлары да очрый башлады. Ләкин без әлегә тыныч барабыз. Алдагы вагоннарда хәрбиләр бара, андагы йөк минеке кебек кенә түгел, хәтәррәк. Платформаларда чехолланган зенит пулеметлары. Әмма, әйткәнемчә, аларга сүз бирергә туры килми әлегә.

Ниһаять, поезд туктап торган араларда Көнбатыштан шартлау тавышлары ешрак һәм ачыграк ишетелә башлады. Төннәрен күк йөзен фронт ягындагы янгыннар шәүләсе сәер һәм куркыныч итеп яктырта. Без алга барган саен сугыш галәмәтләре көчәя, шомландыра, ярсыта.

Составыбыз Орел шәһәренә бөтенләй якынлашты. Тик шәһәр станциясе безнең составны кабул итәргә ашыкмый. Без Стальной конь атлы бер разъездда тукталдык. Мин шундагы кечкенә таш бинага йөгерәм. Эш нигә терәлгән, ни өчен безне Орел кабул итми? Хикмәте шунда: дошман бу арада станцияне өзлексез бомбага тота икән.

Без түземсезлек белән Орелның рөхсәтен көтеп ятабыз. Орел ягыннан дәһшәтле шартлау тавышлары ишетелә, янгын һәм яктырткыч ракета шәүләләре айкалып-чайкалып күктә уйный.

Бер тапкыр дошманның «миссершмитт»ләре безнең разъезд өстендә әйләнеп йөрделәр. Хәтта бер көнне, бер немец пилоты көпә-көндез бөтенләй түбәннән очып, безнең состав өстенә пулялар сипте. Без, состав озатучылар, бергәрәк йөрибез. Алгы сызыкка, үз частьләренә кайтучылар арасында утны-суны кичкән егетләр дә бар. Алар, самолет күренү белән, тимер юлдан читкәрәк чабарга тырышалар. Әтәчләнмә, егет, батыр булып кыланма, немец рәхимсез, кешене кызгана торган җан түгел, синең гомереңне кисү өчен бер пуля җиткән бит, диләр алар миңа. Араларыннан берәү үзе күргән вакыйганы сөйли. Шулай фронт тирәсендәге бер станциягә хәрби эшелон килеп туктый. Ачык платформада диңгез пехотасыннан егетләр төркеме тора. Шулар арасыннан берсе, дошман самолеты килеп чыккач, һич куркуны белмәвен ачык күрсәтергә тырышып, автоматтан дошман самолетына ата башлый. Моны абайлап, фашист нишләгән? Юри егеткә таба очып түбәнәя дә, пулеметыннан атып, арсландай егетнең корсагын ертып, эчәгеләрен агызып китә. Ә егет исә, әле аны-моны сизми булса кирәк, һаман немецка яный. Ләкин бу хәлендә кеше дошманына йодрык янап озак тора аламыни? Бичара егет төптән киселгән имәндәй авып төшә.

Без хәзер немецның сәгать ничәләрдә һөҗүм ясау ихтималын беләбез. Самолетның өзек-өзек җан өшеткеч улавын ишетү белән вагоннарыбыздан сикереп төшәбез дә алдан ук үзебез билгеләп куйган аулак урынга йөгерәбез. Көндезләрен тынычрак. Мин бараклардан торган поселокка да баргалыйм. Андагы баракларның берсендә ашханә бар. Коры-сарыдан туйган чакларда, шунда кереп кәбестә шулпасы ашап чыгам. Ни сәбәптәндер, шул бәләкәй ашханәдә кеше аз була. Күрәсең, күпчелек эшче үз казаныннан ашауны яхшырак саныйдыр. Ашханәдә ашап утыручылар, күренүенчә, күбрәк йә буйдак, йә ялгызаклар. Хәер, ир-ат бөтенләй юк дәрәҗәсендә. Ул заттан кергәннәре дә карт-коры гына. Бусы инде табигый хәл, яшь ирләр хәзер барысы да армия сафларында.

Бер көнне олырак яшьтәге апа тышта, минем ашханәдән чыгып килешемдә, ашыгып миңа якынлашты. Аның йөзендә яшерен шомлану чагыла иде.

— Сез, хәрби иптәш, уң як почмакта утырган кешегә игътибар итмәдегезме? — дип сорады ул. Әйе, мин ул кешегә игътибар иткән идем. Ирексездән аның күзгә чалынып истә калуы шуннан: монарчы бу ашханәдә урта яшьләрдәге бер генә ир-атны да очратканым булмады. Кеше таушалган чүпрәк пинҗәк-чалбардан, аның йөзен пычрак җирән сакалмыек баскан, үзе урта яшьләрдәге кеше, тоена-тоена кабаланып шулпа чөмерә.

— Ул бик шикле кеше, — диде хатын. — Ул кичәдән бирле инде безнең поселок тирәсендә чуала.

— Тикшерергә кирәк,— дидем мин. Яңадан ашханәгә кердем дә кабурамнан наганымны чыгарып, аның янына бардым.

— Әйдәгез әле, сезне комендант күрергә тели.

Кеше куркынып, соры күзләрен миңа текәде.

— Әйдәгез, әйдәгез, чәегезне йотыгыз да...

Күрәсең, кулымдагы корал һәм тирә-юньдәге кешеләрнең безне бик кызыксынып күзәтүе моңа башка юл калдырмады, ул авыз эченнән генә нидер мыгырданып, урыныннан купты. Миңа явыз бер караш ташлап, ишеккә таба юнәлде. Ул берниндн каршылык күрсәтмәде, мин әйткәннәрнең барысын да төп-төгәл үтәде. Аны шул ук минутта паровозга утыртып, сак астында хәрби комендатурага, Орелга алып киттеләр.

Бу кешедән юкка шикләнгәннәр, мин дә артык рәхимсез кыландым, дип уйлаган идем, әмма юравым дөрескә чыкмады. Кичен миңа разъезд начальнигы бу шикле бәндәнең, чыннан да, дошман җибәргән сигналчы булып чыгуын әйтте.

Яңадан бер-ике көннән соң, Орел станциясен бомбага тоту беразга тукталды. Миңа йөгемне тиешле складка илтеп тапшыру мөмкинлеге дә туды. Хәтердә, эшне төгәлләп, тиешле кәгазьләрне формалаштыргач, инде беренче состав белән кайтып китәм дигәндә генә, фашист Орел станциясен тагын бомбага тота башлады. Дошман самолетлары өзлексез улый, составлар белән тулган станциянең әле бер, әле икенче очында бомбалар шартлый. Моңа кушылып зениткалар, пулеметлар үз тавышларын өсти. Ничектер үзенә бер төрле моңлы тавыш чыгарып күктән снаряд кыйпылчыклары ява. Мин товар вагоннары арасында. Без таныш булмаган нииндидер кызылармеец белән, бер-беребезгә сыенган хәлдә, бу гарасатның ахырын көтәбез.

Күрәсең, безнең зенитчиклар бик төз атканнардыр, шуңа күрә урталыкка бер генә бомба да төшмәде. Дошман самолетлары озакламый үз якларына очып киттеләр. Тирә-юньне әлеге күктән коелган кыйпылчыкларның моңлы зыңгылдап җиргә төшүе генә җанландыра иде. Без дә яшеренгән урыныбыздан чыгып, берничә минуттан соң кузгалырга тиешле үзебезнең поезд составын эзләп киттек.

* * *

Габдрәшитов теге вакытны мине хәрәкәттәге армиягә җибәрергә теләмәсә дә, мин командировкадан кайтыр алдыннан армиядә хезмәт итүче барлык тыловикларны фронтка озатырга дигән Югары ставканың фәрманы килгән икән. Хәзер инде начальникның мине үз янында калдырырга кодрәте җитми. Мин исә тантана итәм. Менә озакламый фронтка китәчәкмен. Анда корал тотып дошманга каршы көрәшәчәкмен. Нинди язучы һәм нинди гражданин ди мин, әгәр шундый вакытта да алгы сызыкта, ут эчендә булмасам?!

Мин приказ турында ишетү белән өйгә, әниләргә хат язып салам. Хатны тыныч тонда, алар борчылмаслык итеп язарга тырышам. Миңа өлкән сержант дәрәҗәсе бирелүен хәбәр итеп, петлицаларга өчәр өчпочмак беркетәләр, мин үз өемдәй якынаеп өлгергән казарма, контора һәм дуслар белән, бәлки мәңгегәдер, саубуллашам. Әйтергә кирәк, командировкада булып кайту күземне ачты. Бу сугышның инде тиз генә бетмәвенә тулысынча ышандым. Без, бер якка китәргә тиешле кешеләр, икәү идек. Минем кебек үк командировкада булган Твердохлебов фамилияле экспедитор — өлкән сержант белән бергә юлга җыендык.

Без поездда. Сәфәр — Саратовка. Анда җитеп, Округ штабына документларны тапшыргач, безгә байтак кына вакыт урамда көтеп торырга туры килде.

Сентябрь урталары якынлашуына карамастан, көн ифрат матур, җылы, кояшлы. Без Твердохлебов белән якындагы бер скверга кереп,

башларыбызны бер-беребезнең иңбашына куеп, эскәмиягә сузылдык. Шулай бераз черем дә иткәнбез булса кирәк.

Күтеп ятуның нәтиҗәсе шул булды: минем юлдашымны бригада штабында писарь итеп калдырдылар, мине исә Татищево лагерына озаттылар. Бу данлыклы хәрби лагерьда запас полк урнашкан икән, полкта фронтка җибәрелә торган марш роталары төзелә. Димәк, мин шул лагерь аша фронтка китәчәкмен...

«Куйбышев, 12/IX-41 (алдым 20.IX)

Сөекле әнием һәм әтием!

Сезгә башта ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Үзем исән-сау. Моңа кадәр сезнең хатларыгызга җавап яза алмадым. Сәбәбе — командировкада идем. Әле кичә командировкадан кайтып, монда бер яңалык белдем. Мине һәм тагы берничә иптәшне бүтән частька күчерәләр. Шуңа күрә, моннан соң хатларыгызны башка адрес белән язарсыз. Әле нинди часть икәнлеге, минем кем булып хезмәт итәргә тиешлегем билгеле түгел. Ләкин озын колаклардан ишетүем буенча, үз белгечлегем, ягъни ветеринар работник булып хезмәт итәргә тиеш булсам кирәк. Кыскасы, сезгә минем өчен борчылырга урын юк. Ул частька барып төшү белән сезгә тулы итеп язармын.

Әтинең хатына караганда, әни, син шәһәрнең читенә эшкә урнашкансың икән. Аннан шуны аңладым: әти хәзер укытучы булып эшләми икән.

Әни, сиңа эшкә йөрүләре бик кыен түгелме соң? Кышкы салкыннарда бик туңмассыңмы соң? Син җибәргән акчаларны һәм фотоны алдым. Бу турыда язган идем, сез ул хатны алмагансыз, ахры.

Бүтән язардай хәбәрләрем юк. Бүген кичкә Саратов ягына китәбез.

Йөзләрегездән үбеп, сезне сагынучы улыгыз: Атилла.»

«Татищево, 16.IX-41 (алдым 25. IX)

Сөекле әни һәм әти!

Сезгә башта үземнең ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Үзем исән-сау, үткән хатымда язылганча, командировкадан кайткач, бүтән частька күчтем. Хәзер лагерьда яшим. Минем белән хезмәт иткән бүтән иптәшләр дә монда.

Килешли Саратовка кереп чыктык. Саратовтан тимер юл белән ике сәгатьлек юл өстендә бу лагерь. Саратовта үземне ветработник итеп файдалану мәсьәләсен кузгаттым. Шушы көннәрдә аннан җавап булачак. Кыскасы, шул — мине бу частьтан бүтән бер частька, йә фронтка җибәрәчәкләр. Ләкин зинһар өчен минем өчен борчылмагыз. Фронтка эләксәм дә, борчылырга урын юк, чөнки мине штаб работнигы итеп аттестовать иттеләр.

Монда фронттан кайтучылар бик күп. Алар фронтта яраланганнар, хәзер савыгып, янә фронтка китәргә җыеналар. Алар аркылы без хәзер фронт хәлләрен бик яхшы күз алдына китерәбез. Бер мин генә түгел, минем кебек миллионнар бу сугышны үз башларыннан кичерәләр. Кешенең батырлыгы шушы вакытта гына күренә ала. Һәрбер хәлне тыныч каршы алырга кирәк.

Бу хатымнан соң, бәлки, сезгә озак вакыт хат яза алмам. Зинһар, аңа карап борчылып тилмермәгез. Минем көчемә, һәр нәрсәгә аек акыл белән карый алуыма ышаныгыз. Мин үземне иң беренче чиратта сезнең өчен саклармын.

Монда әле байтак кына вакыт яшәргә туры килер кебек. Кичә безнең иптәшләрнең байтагын җибәрделәр. Ләкин безне, командирларны һәм писарьларны, калдырдылар. Кайчан китәчәгебезне хәзергә белмибез.

Ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: улыгыз Атилла.

Адресым: Саратовский обл. Ст. Татищево, лагерь № 240. Распред. батальон. ст. сержанту Расулеву».

«Татищево, 21.IX.41.
Сөеклеләрем әни һәм әти!
Мин исән-сау. Үткән хатымда язганча, хәзер Татищево лагерында ятам. Кая һәм кайчан китәчәгем әлегә билгеле түгел. Минем белән килгән иптәшләрнең соңгы дүртесен бүген озатачаклар. Әйтүләренә караганда, монда писарьларга озак ятарга туры килә. Миңа монда бөтенләйгә калырга тәкъдим итәләр, ләкин бер дә ошамый, эшнең рәтечираты бер дә буласы юк. Сез минем өчен борчылмагыз. Йөзләрегездән үбеп: Атилла».

Мин командировкада вакытта ук безнең склад егетләре Татищевога килеп чатырларга урнашканнар иде инде. Менә мин дә данлыклы Татищево хәрби лагерында. Ара-тирә агачлыклары булган киң мәйдан. Ул мәйдан астыннан кәҗәләр кереп йөрерлек агач койма белән ихаталанган. Штаб һәм командирлар өчен ашханә бинасыннан тыш бернинди дә ныклы бина күзгә чалынмый. Аның каравы, һәр куак янында чатыр. Чатырлар эчендә киртәлек колгалардан ясалган сәкедән башка берни дә юк. Сәкесендә күңел өчен бер кочак салам булсачы! Матрас, мендәр турында уйлаган да юк, юыну өчен ару су табу хыялда гына. Без шундый шәп-шәрә сәкеле чатырда яшәргә тиеш.
Хәзер кичләрен шактый суык инде. Караңгы төшү белән шинельгә төренәбез дә, чолгау чорналган аякларны шинель җиңнәренә тыгып, бер-беребезгә бик нык сыенган хәлдә, йокларга ятабыз. Тик озаклап йокларга мөмкинме соң. Колга ботаклары янтыгыңа төртеп торган салкын чатырда? Кагыйдә буларак, төнге икеләр тирәсендә салкынга түзә алмыйча уянып китәсең. Суык эчкә үткән, теш-тешкә тими. Яшен тизлегендә итекне киясең, шинельне иңгә элеп, йөгереп чатырдан чыгасың. Ә тышта тагы да суыграк. Иңбашларыңны уйнатып, сикергәли башлыйсың. Ярый әле чатырлар тирәсендә өзлексез солдат учаклары янып тора. Һәр учакны солдат агайне әйләндереп алган. Анда безнең кебек дары иснәмәгән «сары авызлар» гына утырмый. Сугышның беренче көннәреннән үк ут сызыгында булып, яраланып өлгергәннәр дә бар. Ул карт солдатлар күпне күргән, күпне белә. Алар күргән-белгәннәрен һич тартынусыз, артын-алдын уйламастан сөйли. Монда безнең армия командованиесенә дә хурлау сүзләре эләгә, «монда даһи атабыз» Сталинга да өлеш шактый чыга...
Кыскасы, сүз күп. Монда, мин моңарчы төштә дә күрмәгән, барып чыккан «демократия» хөкем сөрә. Ләкин шулай да гәпне озаклап тыңлап утырып булмый. Утка алдың белән утырсаң, артың туңа, аркаң белән әйләнсәң — алдыңа «таракан йөгерә» башлый. Шулай кыбырсып, аратирә җылынып яки сикергәләп, бераз черем иткән дә булып, төнне уздырасың. Ә иртәгесен болай була. Старшина ротаны тезә дә иртәнге сигезләрдә ашханәгә алып китә. Ашханә дигәне, такта түбә белән өсте генә каплаулы, ким дигәндә бер унбиш метр озынлыктагы өстәл. Анысы да тупас такталардан корыштырылган. Аның ике ягында да артсыз эскәмияләр сузылган. Гадәттә, без иртәнге ашка ашарга барганда, ул өстәл буш булмый әле. Ашап утыручылар артына басып, түземле рәвештә урын бушаганын көтәбез. Ул арада старшина шулай ук ашыгыч кына эшләнгән кухня тәрәзәсе янындагы чиратка барып баса. Аның чираты якынлашыр алдыннан, безнең нарядка билгеләнгән иптәшләр, аштан бушаган ләгәннәр аулау белән шөгыльләнә башлыйлар. Ниһаять, без утырышабыз, бераздан зур калай подносларда икмәк тә килә. Берзаман егетләр ләгәннәрдә парлары бөркелеп торган ботка ташый башлыйлар. Ботка өстәлгә кунаклау белән, кулдагы кашыклар күз иярмәс җитезлек белән хәрәкәткә килә. Бөтен кеше бирелеп, барлык дөнья мәшәкатьләрен онытып ашарга керешә. Әнә ул тойгы, туклык рәхәте, әкренләп тәнгә талгын гына тарала. Без бәхетле хәзер, тирләп-пешеп кайнар, майлы ботка ашыйбыз.

Инде тәмам ләгәннәрне ялтыратып, үзебез туенып, өстәл тирәсеннән кузгалганда сәгать уникеләр була. Әйе, бераз аш сендереп чатырлар тирәсендә йөрибез дә тагын стройга бастырып безне көндезге ашка алып китәрләр.

Көндезге ашны ашау аерата катлаулы нәрсә. Ул бик озакка сузыла торган эш. Без бу очракта төш вакытларында китеп, ашханәдән кичке эңгердә генә кайтабыз.

Кайчан, кайчан соң безне фронтка җибәрерләр? Кайчан соң без, ил безнең кайнар яшьлек көчебезгә мохтаҗлык кичергән бер вакытта, мондагы эшсез, тәртипсез сорыкортлар тормышыннан котылырбыз?

Сүз тамак туйдыру хәлләренә кагылганда, минем киләчәк язмышымда билгеле бер мөһим роль уйнаган вакыйганы да искә төшереп узасы килә. Шулай көннәрдән бер көнне, калай ләгәннәрдә ризык килгәнен өстәл тирәсендә көтеп утырганда, минем каршымдагы бер танкист (белорус егете) кулындагы кыйбланамәсен, эш юктан булса кирәк, сүтә башлады. Аның пыяла капкачын куптарып алды. Эчен актарып тикшерергә кереште. Бераздан бу эш тә аны туйдырды булса кирәк, ул кыйбланамәнең барлык нәрсәсен, магнитлы угын да өстәлгә ташлады.

Кыйбланамәнең угы нәкъ минем алдыма килеп төште. Бу нәрсә, минемчә, әле дә эшкә ярый иде. Мин аның ярдәмендә төньяк белән көньякның кайда икәнлеген һәр минутта белә алам ич. Аның файдасы без поездга утырып киткәч тагын да күбрәк булуы ихтимал. Мин шул рәвештәрәк фикер йөрттем дә, ул магнитлы укны алып гимнастеркамның күкрәк кесәсенә салып куйдым. Салып куйдым һәм берничә көннән соң мин аны бөтенләй оныттым да.

Әйе, берзаман мин аны хәтерләячәкмен әле. Аны кесәмнән чыгарачакмын һәм, инә очына куеп, барасы юлларымны билгеләячәкмен. Кем белсен, бәлки ул минем исән-сау калуымның бер сәбәбе дә булгандыр.

Хәзер мин һаман Татищево лагерында. Туңам, ачыгам, тизрәк фронтка китү хыяллары белән дәртләнеп, солдат әйтмешли, «кояшта кызынам».

Әнием миңа, әле мин студент чагымда ук, акчасын юллап, бер кул сәгате алып бүләк иткән иде. Шуны сатарга кирәк дигән фикергә килдем. Чөнки туңып яшәү, тәртипсез туену — Куйбышевтан ук алҗып килгән кешене тәмам аяктан егу куркынычы астына куйды. Хәлбуки, биредә командирлар өчен үз акчаңа туену ашханәсе эшли. Әлбәттә, анда рядовойларны кертмиләр, ләкин минем шинель запастан килгән лейтенантларныкыннан кайтып түгел. Ул ашханәгә бер тапкыр кереп чыккан да идем инде. Анда шактый туклыклы һәм тәмле ашлар сатылганын белдем. Тик ул чакны минем акчам гына юк иде. Сәгатьне саттым. Хәзер мин акчалы. Үз вакытында ашыйм, мин тук. Бераздан миңа чырай да керә башлады. Хәзер ачлы-туклы яшәгәндәге кебек артык туңмыйм да.

Ниһаять, урра, мин марш ротасына эләктем. Без присяга кабул итәбез, ягъни ант эчәбез. Монда, син кайдан килдең, кадрданмы, запастанмы, дип кызыксыну юк. Барлык рота бер үк эшне башкара. Мин шулай итеп, икенче тапкыр ант кабул итәм. Зарар юк, аны йөз тапкыр кабул итәргә дә була. Андагы сүзләр минем күңелдә болай да намус эше булып саклана.

Безгә мылтыклар бирелде. Күрәсең, ул заманда төп пехота коралы булып кергән хәнҗәр сыман штыклы СВТ (скорострельная винтовка Токарева) җитәрлек булмагандыр. Безгә штыксыз карабиннар өләштеләр. Шулай ук без плащ-палаткалар, мех капкачлы ранец, противогаз, патрон, патронтажлар, медальоннар алдык. Присяга кабул иткән урман аланыннан ук безне сафка тезеп тимер юл тармагына алып киттеләр. Анда безне буш хәрби эшелон һәм тынлы оркестр музыкантлары көтә иде инде. Полк командирының строй алдында кыскача нотыгын тыңлаганнан соң, командаларга бүлгәләп безне вагоннарга утырта башладылар.

Менә миңа бик таныш теплушка. Солдат төяп йөртә торган товар вагоны. Роликларда шуып чиелдый-чиелдый ачыла торган авыр ишек. Миңа өчен асып куелган чайкалчык тимер баскыч. Вагон эчендә ике якта да сәндерә һәм сәке, ә алар арасындагы бушлыкта, уртада, тимер чиләк сыман чуен мич — буржуйка. Мин фронтка киттем.

«Орелга юлдан. 4.X.41 (8.X.алдым)
Сөекле әнием һәм әтием!

Сезгә юл өсли генә, ашыгыч рәвештә, кәгазьне мылтык түтәсенә куеп хат язам. Аңлашыладыр, мин фронтка киттем. Сәламәтлегем яхшы, үземне көр сизәм. Әле кая барачагыбыз мәгълүм түгел. Кайбер чыганакларга таянып, көньякка дигән нәтиҗәгә килергә була. Сезгә Татищеводан ике хат язган идем, алгансыздыр. Бу хатымнан соң, бәлки, байтак вакыт хат яза алмам, зинһар, өчен борчылмагыз.

Мин сезгә үткән хатымда, минем хезмәтем алгы сызыкта түгел, штабта булачак, дип язган идем инде. Шуңа күрә бер дә борчылмагыз, тыныч кына яшәгез. Барып җитү белән, мөмкинлек булса, хат язармын. Барыгызга да сәлам. Йөзләрегездән үбеп: Атилла».

Мине, өлкән сержант буларак, вагон башлыгы итеп билгеләделәр. Минем кулда исемлек, мин шуңа карап һәр көнне берничә тапкыр кызылармеецларны барлыйм. Эшелон башлыгыннан азык-төлек алып кайту, аны гадел өләшү оештыру эшләре шулай ук минем вазыйфаларыма керә. Эшелон начальнигы зуррак тукталыш саен башлыкларны чакырып тора. Кызылармеецларга җиткерелергә тиешле яңалыкларны җиткерә. Мин хәйран калып бер яңалык ачам: минем вагондагы егетләрнең барысы да моңарчы теге, йә бу сәбәп аркасында армиядә хезмәт итмәгән кешеләр, имеш. Араларында мылтыктан бер генә тапкыр да атып карамаганнары бар. Минем тирә-юнемдә тиз арада куштаннар да пәйда була башлады. Янәсе, сержант, синдә инде бөтен өмет, безнең язмыш синең кулда.

Без һаман алга, алга барабыз. Зур станцияләрдә андагы туклану пунктларыннан безгә азык бирәләр. Ләкин барасы маршрут һаман үзгәреп тора. Дошманның юлны бомбага тотуы аркасында, безгә әйләнгеч юллардан барырга туры килә. Әмма кая барабыз? Монысы бары эшелон начальнигына гына мәгълүм.

Күрәсең, без артык озак сәяхәт кылырга мәҗбүр булганбыздыр. Берзаман безгә аттестат буенча бирелергә тиешле азык-төлек бетте. Тукландыру пунктлары безгә продукт җибәрми башлады.

Буш вакыт табып, мылтык түтәсенә кәгазь куеп, өйгә хат язам. Борчылмасыннар. Мин бит үзем дә сизеп торам — миңа берни дә булмаячак, мин җәһәннәм утлары аша узсам да исән калачакмын.

Яшьлекнең гүзәл үзенчәлеге! Ул үлемне бар дип тә белми. Ашарга азык бетте. Егетләр капчык төпләрен селки, актара башлады. Бары комык хәстәрлеге белән яшәүчеләр генә төнлә яшеренеп плащ-палаткалар астында кара көнгә дигән азыкларын күшәп ачуны китерәләр.

Безнең барасы юлыбыз үзгәргән икән. Зигзаглар ясап булса да, Мәскәүгә омтылган дошман каршысына юл тотабыз. Тынлык, төкселек. Ачның ачуы яман, солдатларым дары кебек кабынып китәргә генә торалар.

Ниһаять, яңгырлы октябрь төннәренең берсендә без Тула өлкәсенә кергән кечкенә генә булса да зур тарихлы Белев шәһәренә килеп туктадык. Хәтердә: вагоннардан төшү белән безне ниндидер каберлеккә алып киттеләр. Офык яктылыгында безнең эшелон башлыгы һәм без белмәгән хәрбиләр күренде. Кызылармеецлар шаулаша, пыскак яңгыр плащ-палаткаларда шыбырдый. «Икмәк, икмәк бирегез безгә, безнең ике көннән бирле ризык күргәнебез юк»,— дип кычкыра кемдер. Аны хуплап, башкалар шаулашалар. Әз генә сабыр итегез, ди эшелон начальнигы,

килеп җиттек бит инде, урнашырбыз, барысы да булыр. Юк, юк, безгә хәзер үк кирәк, без ач, безнең анда барып җитәрлек хәл калмады, дип кычкыра кемдер.

Бу бәхәс шактый озакка тартыла. Ниһаять, шаулашудан бернинди мәгънә чыкмавын икмәк даулаучылар да аңлады булса кирәк, солдатлар тына төште. Каяндыр килеп чыккан, моңарчы күренмәгән хәрбиләр безне, колоннадан йолкып алып дигәндәй, үзләренә кирәк кадәр солдат җыя башладылар һәм тиз арада каберлек янындагы мәйданнан кешеләр караңгылыкта читкә китеп эри тордылар.

Мин дә шул төркемнәрнең берсенә эләктем. Хәзер пехота полкына баруыбызны һәм андагы взводларга өстәмә көч булып таратылачагыбызны төшенәм. Шундый күңелсез рәвештә һәм һич тә күз алдыма китермәгәнчә, үземчә бик изге урынга аяк басуыбыз гына борчый. Башкача, ничектер тантаналырак булырга тиеш иде кебек бу фронт белән очрашу. Күрәсең, фронт шартлары шундый була торгандыр инде, дип тынычланам эчтән.

Без юеш караңгылыкта, сөрелгән җирләр аша шактый вакыт офыктагы әледән-әле кабынып киткән яктылык шәүләләренә таба барабыз. Калкулыкларны уздык, иңкү урынга төшә башладык, тагын шактый текә үргә күтәрелдек һәм кинәт аркылыга сузылган окоп чокырына килеп чыктык. Без якынлашу белән окоптан берьюлы берничә кеше күтәрелде. Сизелмәстән генә пәйда булган плащ-палаткалыга безне алып килгән хәрби доклад ясады. Доклад кабул иткән кеше безнең булачак взвод командирыбыз икән.

— Йә, ничегрәк хис итәбез үзебезне? — дип сорады ул, безгә мөрәҗәгать итеп.

— Отлично, — дидек без.

— Арагызда кече командирлар бармы?

— Бар, — дидем мин, үземнең фамилиямне, хәрби званиемне әйттем.

— Полковой мәктәп бетердегезме?

— Юк, мин срочныйдан.

— Помкомвзвод?

Мин үземнең кайсы частьта һәм кем булып хезмәт иткәнлегемне әйтәм. Йөзе ачык кына күренмәсә дә, лейтенантның җаваптан ризасыз булып калуын тоям. Ул кискен генә башкаларга таба борылды да, аларга сорау бирә башлады. Бераздан бөтенләй күңелсезләнеп:

— Барысы да нестроевой. Җитмәгән иде алар миндә, — дип куйды. Бераздан үзен тынычландырырга теләгәндәй: — Нишләмәк кирәк, — дип өстәде. — Үзегезгә ячейкалар казыгыз да урнашыгыз.

— Ә ризык мәсьәләсе ничегрәк? — диде кемдер безнең төркемнән.

— Анысы иртәгә.

Шул сүзләрне әйтте дә лейтенант караңгылыкка кереп юкка чыкты.

Отделение командирлары кемгә кайда ячейка казырга икәнлеген күрсәтә башладылар.

Безнең окоплар помидор бакчасы өстендәге калкурак урында, тоньякка таба сузылган. Алда караңгы тынлык. Бирегә килгәндә күренгән офыктан кызгылт шәүләләр дә югалды. Әз генә хәрәкәт яки ут шәүләсе булсынчы! Фронт тирән йокыда. Хәер, дошман моннан шактый еракта булырга тиеш. Сержант безгә ячейкаларны ничек казырга кирәклеген аңлата, тәмәке тартуны каттый рәвештә тыеп, окоп буйлап үз ячейкасына юнәлә. Аның артыннан кемдер:

— Яшеренеп кенә тартырга да ярамыймыни? — дип сорый.

Сержантның тавышы ишетелә:

— Ячейкаларыгыз казылгач, шунда кереп, плащ-палаткага әйбәтләп капланып кына...

Ячейка дигәне — солдат өне. Әгәр алгы сызыкта блиндажлар юк икән, солдат шул ячейкасында яши. Ул йөрү юллары булган чокырга аркылы казыла. Эченә кереп, бөгәрләнеп ятарлык булсын, алды ярым

цилиндр рәвешендә, өстә дошман ягына караган өлешендә балчык өеме. Анысы бруствер дип атала.

Юл килеп бик арыган булсак та, инде караңгы булуга карамастан, барлык көчебезне туплап, ухылдап ячейкалар казыйбыз. Дошман күрмәсен өчен брустверны биек иттерәбез, балчык стенага патрон һәм башка кирәк-ярак куярлык итеп «киштәләр» тишәбез. Тизрәк, тизрәк эшне бетерергә кирәк, чөнки йоклап аласы да бар бит әле. Бездән элегрәк килгән «карт» солдатлар безгә үз ояларыннан алып бераз салам бирәләр. Без шул саламны аска түшәп, яңгыр үтмәсен өчен ячейка өстенә плащ-палатка каплап, өнебезгә керәбез. Менә ул дөнья рәхәтлекләре кайда! Йокы ястык сорамый. Бөгәрләнеп ятсак та, ячейкабызның әҗерен шундук күрә башладык. Балчык стенага баш төртеп сузылуым булды, мин тирән, рәхәт йокыга талдым.

Иртәгесен уянып ячейкадан чыккач, шуны искәрдем: тирә-юньдә хәзер бөтенләй башка күренеш, имеш. Мин төнлә чамалаган пейзаж бөтенләй юк бирелә. Яңгыр тынган, алда куаклыклар белән чуарланган бушлык, ә сул якта, уйсу урында, төнлә бөтенләй абайланмаган кечкенә генә бер авыл. Аның салам түбәле өйләре безгә бөтенләй якын икән. Авыл артында тар гына инеш. Ул, нәкъ авыл турысында кискен бер борылыш ясап, көньяк-көнбатышка китә.

Тамак ифрат ачкан иде. Беренче булып күзгә окоп алдында гына үскән кып-кызыл, пешеп өлгергән помидор йомрылары чагылды. Окоплардан чыгарга рөхсәт икән. Без помидор кырында. Ирексездән куллар авызларга су китерерлек булып өлгергән татлы помидорларга үрелә. Тоз гына юк, җен алгыры! Помидорны тозлап, ипине зур-зур умырып ашап җибәргәндә, иллә дә шәп булыр иде юкса!

Бәхеткә күрә, озак та узмады, аркасына термос аскан солдатны ияртеп, безнең янга рота старшинасы килеп җитте. Сай котелокларыбызны түбәләмә кайнар аш белән тутыра солдат. Старшина исә һәрберебезгә зур-зур икмәк телемнәре тоттыра. Ипине авыз тутырып ашарга була. Әле көндезгә аш алдыннан старшина йөз грамм аракы да вәгъдә итә. Яшибез болай булгач, безнең эшләр җайлана хәзер.

Безнең көн окопларда үтә. Дөньялар җимереп, гуждай ил өстенә ябырылып килүче явыз фашистны сагалыйбыз, шуның белән сугышырга әзерләнәбез. Килүебезнең икенчеме, өченчеме көнендә үк һавалар ачылып китте. Көндезләрен аяз, җылы, әмма аның каравы төннәрен суык хәзер. Иртән уянып ячейкадан чыкканда теш-тешкә тими. Артык туңылса, бераз җылыну өчен мин берәр иптәшне ияртеп безнең окоплардан йөз-йөз илле метр арада торган ялгыз өйгә керәм. Әгәр хуҗаларның чәй эчкән чагы булса, алар бездән берәр кружка кайнар су кызганмыйлар. Ул өйдә берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала, килен һәм бабай. Бабай безнең туңып, күшегеп килеп керүебезне күргәч, безгә карап башын чайкый. «Эх, ребятушки-и» — ди ул безне кызганып. Үзе дә, сөйләвенә караганда, солдат шулпасын җитәрлек чөмергән, сугыш михнәтен яхшы белә. Без, күчтәнәч итеп, балаларга берәр шакмак шикәр төртәбез.

Безнең взвод еш кына, үзебезчә әйтсәк, сугышчан сакка йөри. Әле моңарчы дошманны һәр көн диярлек көндезләрен өстебездә очып әйләнгән разведчик самолеты — «рама»ларда гына күрә идек. Бер сугышчан сакка барганда дошман гаскәрен җир өстендә дә күрергә туры килде. Немец бу юлы безнең алга ук танкеткада килеп чыкты. Без аны рәтләп күрергә дә өлгермәдек, машина җәһәт кенә борылды да тырылдап үз ягына китеп барды.

Бер вакыт, тагын шундый ук сакта торудан кайтканда, взводыбыз белән мина кырына килеп чыктык. Яшел сусыл чирәм белән өртелгән ерымны үзебезнекеләр мина белән тутырганын күзәткән идек. Мина куйганда ялгышуы аркасында, мина бер саперның башын өзеп атканын да белә идек. Менә хәзер без адашып нәкъ шушы хәвефле урынга килеп чыктык. Тукталып торабыз. Кайсыбызгадыр алдан барырга, юл сабарга

туры килә бит, егетләр, ди командир. Мин барам, дидем. Инде сугышка килгәнсең икән, куркып торма. Алдан киттем һәм, бәхеткә күрә, минем эзгә басып чыккан иптәшләр дә минага эләкмичә ерымны уздылар. Миналар арасыннан үткәндә мин нәрсәләр уйладым? Бернәрсә дә уйламадым. Миңа берни дә булмаячак дигән ышаныч минем шик-шөбһәләремне юкка чыгарган иде.

Мин өлкән сержант, ләкин строевик түгел, җитмәсә кесәмдә кирәге чыккан саен киелә торган минус дүртле күзлек. Мине взводта кем итеп куярга да белмиләр. Шулай да безнең взвод командиры уйлап чыгарды: мин, янәсе, үзебезнең отделение командирының ярдәмчесе булырга тиеш. Ә безнең отделение үзе бер взвод диярлек. Бездә егерме җиде кеше. Хәер, аларның берсе дә тиешенчә өйрәтелгән солдат түгел. Менә бередә генә, окоплар өстендә, дошман килгәнне көткән арада, сугыш гыйлеме алалар. Менә шулай. Безнең отделение коралга бай, анда ике Дегтяров системасындагы пулемет, һәр солдатта винтовка йә карабин, гранаталар, үзлегеннән кабына торган сыекча тутырылган шешәләр. Әмма гаҗәбе шунда: безнең полкка бернинди артиллерия беркетелмәгән, ә танклар турында әйткән дә юк.

Баш очыбызда һәр көн дошман самолетлары оча. Еш кына самолеттан безнең окоплар өстенә листовкалар ташлыйлар. Анда ниләр генә язылмый. Берсендә — Сталин төрмәләр өстендә аяк сузып утырган тиран кыяфәтендә төшерелгән, икенчесендә — дошман ягына, янәсе, үзе теләп әсир төшкән Сталинның улы бер немец офицеры белән чәкәшеп шәрап эчә. Фашист безгә үз ягына чыгу өчен пропускалар ташлый. Янәсе, әгәр безнең солдат шул кәгазьне тотып немец ягына чыкса, үзен җәннәткә эләккәндәй хис итәчәк. Җирдә аунап яткан листовкаларны җыеп яндырабыз. Дошман агитациясенә кызылармеецларның артык исләре китми, ул язуларны көлеп кенә, мыскыл аша гына укыйлар. Хәер, алай дип тә минем ялгышуым мөмкин. Безнең кайбер егетләр авыл өйләренә кергәч, чөйдә командир, солдат шинельләрен күргәләгәннәр. Алар хуҗаның иске бишмәтен киеп дошман ягына шылучы сатлык җаннар шинеле икән.

Соңгы көннәрдә безнең окоплар өстеннән чолганыштан чыгучы кызылармеецлар бик күп үтә башлады. Араларында яралылар да бар. Барысы да алҗыган бер кыяфәттә алар, күбесенең өстендә гражданский кием. Без чолганыштан чыгучыларны коралсызландырабыз. Аларның коралын җыеп командирга тапшырабыз, яки кирәк дип табылса, үз коралларыбыз белән алыштырып алабыз. Кайтучыларның бик сирәге генә ачынып, безнең эшнең бик хөрти икәнлеген әйтеп куя. Мәскәү безнең кулдамы әле, дип сорыйлар. Окопларга төшеп ятканнан бирле газета күргән юк. Ләкин башкалар алынмаска тиеш дигән ышаныч белән яшибез һәм сораучыларга: «Мәскәү бездә»,— дип кистереп әйтәбез.

Отделениебезгә тагы берничә кызылармеец өстәлде. Яңа килүчеләрнең берсе татар егете булып чыкты. Нури Гыйлемханов. Мин әле аның әдәби портретын киләчәктә үземнең фронт хикәяләремә кертәчәкмен. Түгәрәк йөзле, кара матур күзле, баһадир гәүдәле, ачык чырайлы егет ул, госпитальдән, ярасы төзәлгәч, җибәрелгән. Нурига сугыш башында ук дошман белән бәрелешергә туры килә. Үзе танкист, әмма хәзер, танклар җитешмәү аркасында булса кирәк, пехотага килеп эләккән. Аның хәрби дәрәҗәсе — сержант. Взвод командиры аны строевик буларак, минем урныма билгеләп, мине командир урынбасары вазыйфасыннан азат итте. Мин хәзергә дәрәҗәм рөхсәт иткән эштә түгел. Әмма бу хәл озак дәвам итми. Безнең батальонга беркетелгән хатын-кыз врач (кореянка булса кирәк) мине үзебезнең взводка санинструктор итеп билгеләде. Миңа медикаментлар һәм кызыл хач сурәте төшерелгән сумка бирелде. Карабинымны яңа кушылучыларның берсенә тоттырдылар.

Нури белән бик тиз дуслаштык, барлык эч серләребезне уртаклашабыз. Көннең җылы чагында, окоп кырына аяк салындырып утырган

килеш, татлы истәлекләргә биреләбез. Әйтүенә караганда, Нуриның абыйсы Казанда яшәгән, ул да әдәбият белән кызыксынган. Нури аларда еш кына булгалаган.

Дошман безнең позицияләргә якынайды хәзер. Көнбатыштагы ут шәүләләре бик ачык күренә. Авыллар, шәһәрләр, урылмаган иген басулары яна. Туп тавышлары, бомба шартлаулары безгә дә килеп җитә. Һәр көн миссер шмидт кәтүләре Мәскәүгә таба оча. Безнең өстә һәрвакыт асылынып торган «рама»лар бөтенләй азынды. Алар хәзер безнең һәрбер хәрәкәтне теркәп, баш өстендә торалар. Дошман кайчагында төннәрен күккә ракеталар кабызып элә. Бөтен тирә-юнь аяз көндәгедәй балкып тора башлый.

Безгә еш кына позиция алыштырырга туры килә. Бу — төнлә, караңгыда була.

Шулай берчак позиция алыштырып интегеп йөргәндә, без Нури белән сафлардан артка калып, ни булса шул, артык өстерәлерлек рәт барыбер калмады дип, бер өйгә кереп хәл алырга булдык. Тәрәзәләр барысы да томаланган, ләкин өлге читләрендә күренгән якты ярыклардан эчтә тереклек барлыгы, анда җылы, рәхәт булуы сизелә. Без тоттык та шундый матур бер өйнең тәрәзәсен чирттек. Озак көттермәделәр, капка ачарга бер олы гына агай чыкты. Без якты, җылы өй эченә кердек. Гаҗәп күренеш иде бу. Мондый җәннәт рәхәтләрен мин онытa башлаган идем инде. Безгә урнашырга идәннән урын күрсәттеләр. Ләкин, идәнгә сузылганчы, бераз чистарынырга булдык. Хуҗа ападан чыра пычаклары алып, өйалдында шинельләребездәге пычракны кыра башладык. Өйалды идәне балчык белән тулды, бөтен тирә-юнь каралып бетте, кырып юылган идәннең карарлыгы да калмады. Әмма моңа карап безнең шинельләр әз генә дә игә килмәде, алар һаман күкрәк тиңентен кап-кара иде. Ниһаять, бу эш артык озакка китәчәген, барыбер берни барып чыкмаслыгын белеп, без күзләр камашырлык, якты, җылы өйгә кереп плащ-палаткаларыбызны җәеп идәнгә яттык. Йокы никтер күзгә керми, үтереп тәмәке тартасы килә. Безгә соңгы көннәрдә тәмәке бирмәделәр. Без бөртекле чәй тарта башлаган идек. Аның бик йомшак төтене тәмәке тәме бирә. Ә менә хәзер анысы да юк бездә.

Өметебез хуҗа бабайда. Ул тәмәке тартучы түгел икән, ә булган тәмәкесен төреп тарта торган түгел, борын тәмәкесе, тузандай вак. Шулай да бабайның борын тәмәкесен төреп тартырга чамалыйбыз. Тик сигара аша төтен бер дә үтми, бары авызга тәмәке тузаны гына тула. Тәмәке тартудан өметне өздек, ул арада йокыга да киткәнбез. Таң атканда хуҗаларга рәхмәт әйтеп, капчык төбендәге күптән аунаган шикәр шакмакларын күчтәнәч итеп калдырып, үз позициябезгә юнәләбез. Моның өчен безгә ни булыр дип борчылам мин. Берни булмас, мин взводный белән сөйләшкән идем, ди Нури. Нәрсә дип сөйләшкән ул, алла белсен. Мин төпченмим.

Соңгарып килеп җитүебезгә взвод командиры ул кадәр аптырамады. Окоплар янында гына чәлтерәп, кәҗә сикереп чыгарлык таң инеш ага. Егетләр барысы да шунда кайнаша. Якындагы колхоз мал тарата, имеш. Кушу буенчамы, әллә үз белдекләре беләнме, колхоз хәрбиләргә расписка буенча сарык өләшә икән. Отделение солдатлары бездән сарык алып кайтуыбызны үтенәләр.

— Киттекме, Нури?

— Әйдә!

Йөгердек без якындагы авылга. Расписка калдырып бер тутас йонлы ак сарык алып кайттык та аны егетләргә тапшырдык. Сарыкны «эһ» дигәнче суеп, чапкалап, казандагы суга пешерергә салып та куйдылар. Тозын да тапканнар, чүмечен дә.

Ит пешеп чыкканчы без Нури белән инештә шинельләрне юабыз. Бераз адәм рәтенә кергәч, аларны кояш хараган калкурак чирәмле урынга җәеп куябыз. Октябрь кояшы әллә ни юмарт кыланмый. Безгә авырай-

ган шинельләрне юеш хәлендә кияргә туры килә. Хәер, өскә дә кояш төшә бит.

Взводыбыз сугышчан сакта чакны дошман бер тапкыр күренде. Биш-алты кеше дозорда идек ул вакыт. Окоплар казып әйбәтләп урнашырга өлгермәдек, дошман ягыннан тагын унлап атлы немец солдаты күренде. Тере немец солдатын шундый якыннан әле беренче тапкыр күрүем. Фашистлар безне абайлау белән туктадылар. Араларыннан берсе, командирлары булса кирәк, пистолеттан безгә төзәп пуля җибәрде. Безнең җавап кайтармавыбызны үзләренчә аңладылар булса кирәк. Тиз генә борылып кире киттеләр. Алар эре, симез атларга атланган иде. Мажар атлары иде булса кирәк. Мин, зоотехник буларак, моңа игътибар итми кала алмадым.

Бер-ике көннән дошман гаскәре төрле яктан һөҗүм итә башлады. Бу аз көч белән генә Белевне алып булмасмы дигән бер сынау иде булса кирәк. Чөнки флангларда ату тавышлары вакыт-вакыт куерса да, шәһәр һаман безнекеләр кулында иде әле.

Көтмәгәндә Нури дус авырып китте. Аның температурасы яман күтәрелде, эче китә башлады. Алай гына да түгел, эченнән күбекләнеп кан килә башлады. Мин үземдә булган даруларны бирәм, әмма әз генә дә файдасы юк. Нури хәзер ыңгырашып юеш ячейкасында ауный, һаман су сорый. Дизентерия чиредер. Мин Нурины, командир приказы буенча, тылга, шәһәр ягына, үзебезнең полк метсанбатына алып китәм. Ул бөтенләй хәлсез, бераз атлый да туктала, әз генә мөмкинлек булса, хәҗәтен үтәргә җайлаша. Без шулай бер-бер артлы сузылган, сөзәк, чирәм баскан ерымнар аша шәһәр читенә якынлашабыз. Медсанбат шунда иде. Минем анда бер авыру кызыларммеецны илткәнем булды. Бер тапкыр дару алырга да бардым. Әмма мин белгән өйдә хәзер миңа таныш кешеләр юк, бередә бөтенләй башка часть урнашкан. Мин полкның медсанчастен сорашам. Беркем берни белми. Без Нури белән шәһәр чите буйлап очраган бер хәрбидән сорашып, һаман алга барабыз. Уң якта ниндидер авыл күренә, сулда исә шәһәр йортлары. Ләкин тыкрыклар кызыларммеецлар белән тулы. Ул да булмады, авыл белән шәһәр арасындагы бушлыкта безнең атлы гаскәрләр күренде. Хәтердә калганы шул: күрәсең, авылга немец кереп оялагандыр, безнең атлы эскадрон шәһәр ягыннан чыгып шунда ташланды. Кылычларын уйнатып атларында җан-фарман чаптырып авылга таба очтылар, тик барып җитмәделәр, авылда ныклап урнашкан дошман аларга каршы пулеметтан көчле ут ачты. Шул чактагы мәхшәр, атларның җылап, иңрәп кешнәве әле дә минем колагымнан китми. Атлар гөрселдәп җиргә ава, кызыларммеецлар үрмәләп алга шуыша, күбесе атларыннан төшеп җиргә яталар, тагы торалар, иелеп кире чабалар. Ә бушлыкта миналар шартлый, пулялар сызгыра.

Бу хәл, күп булса, берничә минут дәвам иткәндер. Ләкин ул һаман минем күз алдымда җанлана. Ул вакытны шулай да немецне авылдан безнең пехота куып чыгарды. Без ул көнне медсанбатны таба алмыйча, Нури белән соң гына үзебезнең взводка кайтырга мәҗбүр булдык. Дусның эшләре бөтенләй хөртиләште. Безнең нәтиҗәсез йөрүләр аны бөтенләй аяктан екты. Әле бездә тынычлык хөкем сөрә иде. Взвод командиры аны, вакытлыча, якындагы авылга илтеп бирәр өйгә салырга кушты.

Миңа хәзер булган хәлләрне бөтен төгәллеге белән искә төшереп язуы авыр. Ләкин шунысы хәтердә, безгә Нурины медсанбатка яки башка дәвалау урынына озату мөмкинлеге булмады. Чөнки немец безнең позицияләргә каршы ут ачты. Мин үзебезнең взводта. Озакламый дошман белән очрашачакбыз, канлы бәрелеш башланачак. Без күп булсак та, көчләребезнең сыеграк икәне һәркемгә сизелә. Кызыларммеецлар, әйткәнемчә, тиешле өйрәнү дә, чыныгу да алган кешеләр түгел. Артиллерия юк, минометлар юк, авиация турында әйткән дә юк. Дошманның якынлашып килгәнен барыбыз да белә. Ләкин ул бу кадәр үк сиздермәстән ут

ачар дип һич кенә дә уйламадык. Һөҗүм иртәнге якта башланды. Һич көтмәгәндә позициянең алдында да артында да миналар шартлый башлады.

Ләкин мине өмет дигәнең бер генә минутка да ташламый: безнең җиңелүебез, йә булмаса минем яраланып, йә үлеп-нитеп калуым мөмкин нәрсә түгел. Андый уй башка да килми. Әйе, әйе, акыл белән безнең якның дошманнан көч-куәт ягыннан шактый кайтыш икәнлеген белгән хәлдә дә. Хәзер көлке тоела, әмма хакыйкатьтә шулай иде. Каты бәрелеш башланганда да сугыш картинасының бөтен тулылыгын күрми калмагаем дип борчылам. Ни өчен? Янәсе мин аны үземнең әсәрләремдә гәүдәләндерергә тиеш. Менә ул яшьлекнең үлемне инкарь итүе һәм артык мавыгуның куркудан көчлерәк булуы!

Шушы араларда гына безнең ротага тагын өстәмә көч килгән иде. Болары яшьләр. Өр-яңа киемнәрдән, шәмдәй төз, шома йөзле, чибәр егетләр. Егерме дүртенче елгы сабыйлар. Дошман һөҗүменә кадәр шаярдылар, окоплардан чыгып әүмәкләштеләр. Үзләре боҗыр кебек елдам, тере...

* * *

Дошманның җитди һөҗүме октябрьнең егермеләрендә башланды. Көзнең соңгы аяз матур көннәренең бер иртәсе иде ул. Без кателокларыбызны помидор яфраклары белән сөрткәләп иртәнге ашка әзерләнгәндә, кинәт окопларыбыз артына төшеп бер мина шартлады. Без аңга килеп өлгермәдек, тагын берсе төште, монысы инде безнең окопка тагын да якынрак иде. Бераздан командирыбызның «Приготовиться к бою!» дигән фәрманы яңгырады. Бруствларга сыендык. Мин яшеренеп кенә алга, дошман ягына карыйм. Уемча, хәзер дошман солдатлары күренергә тиеш. Ләкин алдагы ачыклыкта беркем дә күренми, бары төшкән саен безгә якынайган мина шартлаулары гына тирә-юньне тетрәтә. Бераздан миномет уты уңгарак күчте. Беләм, андагы окопларда әлеге егерме дүртенче елгы яшьләр урнашкан.

Менә дошманның бер минасы нәкъ шулар өстенә төшеп шартлады, ул яктан коточкыч тавышлар ишетелә башлады. Кайсысыдыр чәрелдек тавыш белән ярдәмгә әнисен чакыра, кемдер үкереп елый, ыңгырашкан тавышлар колакка керә. Мин андагы гарасатны күрергә тырышып аякка басам, ярдәмгә йөгерергә кирәк. Тик баш очымнан гына сызгырып очкан пулялар мине тиз арада чүгәргә мәҗбүр итә. Безнең якка да миналар төшә башлады. Дошманның минометтан бик төз атканлыгын мин Татищево лагеренда ук ишеткән идем. Инде хәзер үз күзләрем белән күреп ышандым. Чыннан да, миналар безгә якынайганнан-якыная баралар. Ә уң флангта миналар һаман әлеге яшь егетләр өстенә төшә. Анда һаман үкереш, елау. Мин тагы калкынам. Күзләремә ышанмастан, бер төркем яшьләрнең яныбыздан помидор кыры буйлап чабуын күрәм.

— Кая, кая сез?

Алар сул ягыбыздагы япа-ялгыз калкып торган салам түбәле әвенгә таба чабалар. Юк, никадәр кычкырма син аларга, аларның колаклары тонган, дәһшәт аларны тәмам чукракландырган. Алар тәгаен әвенгә кереп котылырга уйлыйлар.

— Ярамый, ярамый анда керергә!!

Без, карт солдатлар, җыйнаулашып кычкырабыз. Ләкин шартлау тавышлары безнең авазларны күмеп китә. Егетләр алны-артны белмәстән, шул әвенгә таба чабалар. Бераздан алар әвенгә җиттеләр. Уннан артык гүзәл егет шунда кереп ышыкланды. Ләкин нидән ышыкланды? Дошман аларны юрамалай сагалап торгандай, арттан йөгергән фуражкасыз яланбаш солдат әвенгә кереп күздән югалу белән, әвен өстенә бары бер генә мина төшерде. Әвен эченнән котчыккыч шартлау ишетелде, күз ачып йомганчы әвеннең салам түбәсен ут ялкыны чолгап алды. Бер генә

егет тә котыла алмады, ялгыз әвен урнында бераздан көл һәм кисәү өемнәре генә калды. Гүзәл яшьлек шулай үзенең үлемен тапты.

Бәхетле икәнбез: безнең окопларга турыдан-туры бер генә мина да төшмәде. Без бруствердарыбыздан ара-тирә баш калкытып, сулышларыбызны кыскан хәлдә, дошманның күренгәнен көтәбез.

Мин, менә хәзер инде бу вакыйгаларга кырык елдан артык вакыт узса да, шул мизгелдәге халәтемне хәтерлим. Бик еш искә алгангамы, аны әз генә дә онытмадым. Әлеге дә баягы ул минутларда мин, әйткәнемчә, әз генә дә үлем куркынычы тоймадым. Кабатлап әйтәм, кызыксыну хисе барыннан да көчле иде ул минутларда.

Менә немец солдатлары да күренде. Алар безнең алдагы ачыклыкта пәйда булдылар. Алдагы мәйданның байтак өлешен сарганнар да безгә таба киләләр. Башларында мөгезле каскалар, үзләре яшькелт френчтән, кояшта ялтырап күренерлек дәрәҗәдә чистартылган итекләрдән, җиңнәрен сызганганнар, автоматларын корсакка терәп безнең өскә ут яңгыры сиптереп киләләр. Безнең як, булдыра алганча түзәп, мылтыклардан дошманга ата. Ике ягымда да Дегтярев пулеметы, алар да кыска чират белән тырылдап куялар.

Бераздан, күрәсең, безнең як шактый тырышлык күрсәтте булса кирәк, дошман җиргә ятарга һәм хәтта чигенергә мәҗбүр булды. Ут та вакытлыча тукталгандай булды. Мин яралыларга ярдәм күрсәтәм. Хәзергә взводта авыр яралылар юк. Ләкин нәрсә бу? Безнең уң як калкулыктан кемдер безгә таба ата.

— Снайпер,— диде минем янда гына торган отделение командиры.— Сак булырга кирәк.

Чыннан да, бу немец мәргәне хәтәр иде. Ул төнлә үк килеп урнашкан булса кирәк. Берәм-берәм безнең командирларны мушкасына утыртып кына тора.

Сугышның үзенчәлеге шулдыр ахры: дәһшәтле бәрелешләр никадәр озак тоелса да, арадагы тынлык тагын да дәһшәтлерәк һәм озаграк булып күренә. Немец ниндидер бер мәкерле план кора. Без, брустверларга сыенган килеш, иртәнге кояш нурларында җәйрәп яткан ачыклыктан күзләребезне алмый дошманның яңа һөҗүмен көтәбез. Уң яктагы немец снайперының сирәк-мирәк атуыннан башка, колт иткән тавыш юк хәзергә. Эх, шул кабахәтне юк итәрлек снайперыбыз да юк бит ичмаса! Хәер, кайдан булсын — әгәр бөтен взводның !33 ВУСтан* диярлек җыелган икән!

Ни арададыр окоп буйлап безнең яңа взвод командиры үзе килеп чыкты. Яшь, буйчан, кыю һәм батыр егет ул. Мин аны беренче көннәрдән үк яраттым. Фронтка училище бетереп килгән.

— Чигенергә әмер булды,— ди ул отделенныйга,— оештыр!

Берәм-берәм окоплардан чыгып, авыл читендәге чокырда тупланырга. Мин дәррәү Нури дустымны хәтерлим.

— Ә сержант Гыйлемханов?

— Хәзер үк бер кызылармеецны үзең белән ал да, аны авылдан алып чык,— ди лейтенант.

Эш бик ашыгыч. Монда уйланып торып булмый, мин беренче очраган солдатны ияртәм дә окоптан үрмәләп өскә чыгам. Башта без шуышып, бөкрәеп барабыз, аннан җан-фәрман авыл өйләренә таба йөгерәбез.

Әйтерсең лә дошман шуны гына көтеп торган, без узасы юлда бер-бер артлы миналар шартлый башлый. Юк, барыбер дусны калдырып булмый. Мин кызылармеецка үземнән калмаска кушам, ут арасына таба йөгерәм. Кемнәрдер арттан кычкыралар: «Бетәсең, бетәсең бит, сержант!» Бетми генә торсын әле, миңа берни дә булмас! Миндә шундый ышаныч ки, тирә-юнемдә миналар шартлавына карамастан, алга йөгерә

* ВУС — сугышка әзерлеге булмаган солдат.

бирәм. Балчык, кыйпылчык яңгыры өстемнән уза. Миңа ияргән кызылармеец та миннән калмый. Ниһаять, без авыл урамына барып керәбез. Монда тыныч. Менә ул бәләкәй генә кызыл кирпечтән салынган авыл өе. Нинди хәлдә генә булмасын, без хәзер Нурины взводный әйткән авыл артындагы ерымга алып китәчәкбез.

Ишек бикле иде. Безнең бик каты дөбердәтүебезне ишетеп, ишек ачарга ниндидер зур башлы, акайган күзле гарип кеше килеп чыкты. Ул телсез, ләкин аның ризасызлык белдергәне безгә аңлашыла. Бу имәнгеч бәндәне минем монда күргәнем юк иде әле. Баксаң-күрсәң, аның урыны мич башында икән. Шуңа күрә күзгә чалынмаган, ахры.

Без атылып Нури яткан түр якка узабыз. Өйдә хуҗа хатыны юк. Нури исә тавышсыз-тынсыз гына түшәмгә карап ята. Ул, күрәсең, без килер дип өметләнмәгән дә.

— Нури, тор, тиз бул! Без чигенәбез. Медсанбат табылды. Сине санитар арбасында озатырбыз,— дим. Без аны торгызабыз да киендерәбез, аның мылтыгын кызылармеец үз аркасына аса, капчыгын мин алам. Нурины ике яктан култыклап, ишеккә таба атлыйбыз. Ә урамда, хәзер инде шактый еракта әле һаман миналар шартлаганы ишетелә.

Ярый әле, әкрен генә булса да, Нури йөри ала. Без өйалдына чыгабыз. Хәзер Нурины, өстерәп булса да, үзебезнекеләр ягына чабарга кирәк. Тышкы ишекне ачабыз һәм... безне каскалы, агарынган, мәкерле йөзләре калҗайган немец солдатлары чолгап ала. Аларның берничәсе безгә автоматын төзәгән. Без аңга килеп өлгермибез, иң башындагы мылтыкларыбызны йолкып алалар. Берсе, кирпеч өй почмагына бәреп, аларның түтәләрен сындыра. Безне бер-беребездән аерып, автоматлары белән төрткәли-төрткәли, үз телләрендә ниләрдер кычкырынып, авылның икенче ягына алып китәләр. Арттан бары мич башыннан төшкән гарипнең җан әрнеткеч үкерүе генә ишетелеп кала. Тәгаен фашистлар өйгә кереп бичараны яралагандыр...Безне якындагы өйләр арасындагы бер бушлыкка алып килделәр. Анда инде байтак кына әсир, аркаларын бер-берсенә терәп, җирдә утыра иде. Аларның күпчелеге гаскәри, ләкин арада штатскилар да күренә. Тирә-юньдә автоматларыннан атарга һәр минутта әзер торган немец солдатлары баскан.

Безнең өчебезне дә, автомат түтәләре белән тупас төрткәләп, шул әсирләр арасына кертеп утырттылар. Мин бу вакыйгаларны төштә күргәндәй, тонык акыл белән кичерәм. Юк, юк бу ул түгел, бу әле дөресе түгел, бу нәрсәдер шунда, бер саташу кебегрәк нәрсә, дигән фикер башымда чуала.

— Каптык,— диде, миңа аркасы белән терәлеп дымлы салкын җиргә утырган Нури. Мин дәшмәдем. Бары: «Чыннан да, шулай микәнни?» — дип кенә үземнән сорыйм. Тик, кызганычка каршы, бу төш тә түгел, саташу да түгел, чынбарлыкның нәкъ үзе иде. Дәртләнеп, батырланып ил каршында каһарманлык күрсәтергә җыенган егет хурлыклы рәвештә дошман кулына әсир төште әнә! Бу — котчыккыч аянычлы чынбарлык иде.

Без ике өй арасындагы бушлыкта байтак утырдык. Суык бөтен эчке әгъзаларга кадәр үтте, ләкин бу артык сизелми, сизелсә дә иректәге кебек җанны тырнамый иде. Тирә-юньдә автоматларын безгә төбәгән часовойлар йөри, алар вакыт-вакыт үзара сөйләшәләр, хәтта тыныч кына көләшәләр дә. Безгә исә әз генә селкенсәк тә яман җикеренәләр, ишарәләр ясап, әгәр арагызда партизаннар бар икән, шундук асачакбыз, диләр.

Ниһаять, безне, мал кугандай әйдәп, авылның зуррак бер өенә илтеп яптылар. Бу тәгаен колхоз идарәсе иде. Һәрхәлдә, ниндидер рәсми бер бина булуы ачык. Без барып кергәндә ул әсирләр белән шыгрым тулган иде инде. Мин һаман үзебезнекеләр турында уйлыйм. Алар, минемчә, фашистларны бу авылдан куып чыгарырлар да безне азат итәрләр кебек. Башкача булуы мөмкин түгел. Ватык тәрәзә аша сугыш тавышы еракларшканнан-ераклашкандай ишетелә.

Кызыл хачлы сумкам үзем белән. Бирелә берничә яралы ыңгыраша. Мин аларга ярдәм күрсәтәм. Хәтердә: бер лейтенантның тездән түбән балтыр сөяге сынган, икенче бер солдатның билдән түбән бөтен арт ягын мина кыйпылчыгы чуарлаган. Мич янында яткан агач кисәкләреннән файдаланып, лейтенантка шин ясыйм. Арт саны тетелгән солдатның яраларын марля белән бәйлим. Тагы берничә яралыга ярдәм күрсәтәм. Тик минем бәйләү материалым да, йодам да бетә. Яралының эчке күлмәген ерткалап, бинт урынына тасмалар ясыйм. Ниһаять, барысы да эшләнде. Мин бер солдатка үземнең сумкамны бүләк итәм. Ул бичараның противогаз сумкасы да юк икән. Противогазны, артык йөк итеп йөртмәс өчен, алгач та ташлаган идек шул. Миңа Татищево лагерында ук аркага аса торган ранец биргәннәр иде. Пластунча шуышканда ул әллә кайдан ук күренеп тора дип, без анысын да ташладык. Биштәрле, җайлы солдат капчыклары юк, шуңа күрә әйбер салу өчен хәзер иң җайлы һәм җиңел нәрсә противогаз сумкасы булып калды.

Менә караңгы да төште. Ә без яңгырдан соң аерата суынып киткән, тәрәзәләре ватык өйдә һаман бер-беребезгә сыенып утырабыз. Яралылар ыңгыраша. Ара-тирә кешеләр кыска-кыска җөмләләр белән аңлашалар. Һәркем хәзер үз язмышы турында уйлый. Мин дә уйлыйм. Нури да уйлый. Бәлки, качып булыр? Аякларын чак-чак өстерәгән Нури беләнме? Яки аны калдырыпмы? Бу мөмкин эш түгел.

Нури минем колакка пышылдый:

— Синең комсомол билетың үзең беләнме?

— Әйе, ул гимнастерка кесәсендә.

— Шуны бел, әгәр тентү булып, шуны тапсалар, сине шундук атачаклар.

Мин бу турыда уйларга өлгермәгән идем әле. Миңа учет карточкаларын Куйбышевта ук үземә биргәннәр иде. Татищевода учетка басарга туры килмәде. Ә менә фронтка килгәч, безнең ул карточкаларны бер егет штабка алып китте. Мин хәзер үземне учеттагы комсомолец дип исәпләп йөрим.

Ә хәзер? Нишләргә соң хәзер?

— Син нишләттең соң аны? — дип сорыйм Нуридан. — Бәлки аны итек олтырагы астына салыргадыр?

— Син күрмәдеңмени? Тегендә утырганда ничә кызылармеецның итеген салдырды немец?

Әйе, күрдем. Бер егетнең кирза итеген немец солдаты тәкәллефсезнисез генә салдырды да култык астына кыстырып алып китте. Теге яланаякка чолгау чорнаган килеш басып калды. Дошман кулына эләгү белән күпләрнең плащ-палаткаларын да йолкып алдылар.

Нишләргә соң? Ләкин минем уйларымны бүлдереп, кинәт ишек ачылып китте. Бусага аша бер унтер офицер белән рядовой солдат атлап керде. Рядовое тәрҗемәче икән.

— Үткен әйберләрегезне хәзер үк безгә тапшырыгыз. Тапшырмаган кешене — кых! — диде ул, имән бармагын ияк астыннан уздырып.

Минем Казаннан ук алып килгән яшел саплы пәкем бар, фронтка килгәч, әлеге кырда аның белән байтак кына кызыл помидор телеп ашаган идем. Пәкемне унтерга суздым. Ул аны ала һәм явыз елмаеп:

— Офицыйгь? — ди.

— Юк, — дим мин, — санинструктор, — бер кулым белән икенчесен бәйләгәләй итеп күрсәтәм.

— Мыдицина, — ди унтер. Мин аның йөзенә карамыйча гына читкә текәләм.

Пәкеләр, лизвиеләр, СВТ штыклары җыеп, кыскасы, тәмам «коралсызландырып» бетергәч, безне урамга алып чыгалар. Тезеп, авыл буйлап Көнбатышка таба алып китәләр. Мин шул арада комсомол билетын итек кунычына тыгам.

Йа хода, әллә инде бөтен полк әсирлеккә эләккән? Әсирләр колоннасы өстәлгәннән-өстәлә бара. Без авылдан чыкканда колоннабыз шактый сузылган иде. Немец солдатлары яралы һәм авыруларны плащпалаткаларда алып барырга куштылар. Бу эштән баш тартканнарны рәхимсез рәвештә таяклар белән кыйныйлар. Без Нури белән култыклашып атлыйбыз. Колонна, сакчылар белән әйләндереп алынган хәлдә, әкрен генә шулай алга шуыша.

Без тиешле урынга барып җиткәндә, көн тәмам караңгыланган иде инде. Безне элекке дворян өенә охшаган колонналы зур таш бина янына туктаттылар. Монда клуб кебек нәрсә булгандыр, дигән уй үтә баштан. Без килеп туктаганда, аның алдындагы мәйдан әсирләр белән тулган иде. Алар уртадагы дөрләп янган зур учак тирәсендә торалар. Учакка якынрак үтәбез. Утта исә безнең совет китаплары яна. Фашист шулай беренче адымнарыннан ук аларны юк итәргә тырыша. Ут ялкыны битләре ертылып, үзләре туздырылып пычракка ташланган китапларыбызны битараф бер шәфкатьсезлек белән ялмап юкка чыгара, бина колонналары белән ярышып өскә үрмәли. Ут шәүләсе балкып тирә-юньне әледән-әле яктыртып җибәрә. Шул чакларда ук боек, кызганыч кыяфәттәге әсирләрнең йөзләрен караңгылык чокырыннан өскә чыгара, ачыграк итеп күрсәтә.

Бинаның таш колонналары арасындагы ишектән немец офицеры күренә. Аның кыяфәте тантаналы, һавалы. Ул таш баскыч өстендә, аякларын аерып баскан килеш, бернинди акцентсыз саф рус телендә кычкырып әсирләргә сораулар бирә. Нинди хәрби частьтан сез, егетләр? Ничек коралланган иде сезнең хәрби берләшмә?

Әйтергә кирәк, әсирләрнең күпчелеге башларын аска иеп бер сүз дә дәшми тын гына тордылар, ләкин арада офицерга җавап бирүчеләр дә юк түгел иде. Әле бер почмактан, әле икенчесеннән бик батырланып кычкыручылар да табылды.

Озакламый барыбызны бер колоннага тезделәр дә сак астында шәһәргә таба алып киттеләр. Безнең арада хәзер носилкаларда килүче яралылар юк. Йорт янына килеп җитү белән аларны бездән аердылар. Колоннабызда салмак кына атлап, караңгы шәһәр урамнарыннан сөйрәлгәндә, немецлар безнең өчен урын әзерләделәр булса кирәк. Һәм, чыннан да, шәһәр читендәге помидор тозлау өчен корылган бараксыман такта корылмалар, без килеп җитүгә, чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алынган, алар тирәсендәге мәйданчыкның почмакларына такта вышкалар төзелгән, анда күп көпшәле пулеметлар һәм сакчылар урнаштырылган иде.

Безне киң ишекле шул иркен сарай эченә тутырдылар. Ишекләр бикләнде. Бу корылманың тәрәзәләре юк, электр лампалары янмый. Яктылык әз генә (күрәсең, тыштагы утлар аркасындадыр) ярыклардан гына саркый. Шулай да бераздан күзләр ияләшә төште. Аяк астында тубыктан пычрак чыпырдый. Әсирләр, бу яңа торакка ияләшә алмыйча, ниндидер бер шок хәләтен кичерәләр. Байтак тынлыктан соң кешеләр үзара сөйләшә башлады. Анда да башта шыпырт кына. Бу мыгырданулар, шактый вакыттан соң гына, көр тавыш белән сөйләшүгә әверелде. Димәк, халык айный төште. Әйе, нинди генә шартларга эләксәң дә, яшәргә кирәк бит. Димәк, үзеңә ял итеп алырлык урын табарга туры килә. Әмма мондый пычрак җиргә сузылып яту мөмкин түгел, хәер, стена буйларында җир калкурак һәм анда корырак та. Нури кайдадыр артта калды. Ул урнашты булса кирәк. Мин дә, стена буеннан бер коры урын табып, бөгәрләнеп җылымса тузанга яттым.

Бинаның стеналары юка такталардан ясалган, ярыклары күп, җил үтәли исеп тора, халык шыгрым тулы булуына карамастан, җылы тормый биредә. Урын, яткан шәпкә җайлы тоелса да, җил исә башлагач, юеш шинель аша суык эчкә үтеп калтырата башлады. Җитмәсә минем плащ-палатканы да бер немец солдаты юлда йолкып алган иде. Аны

бирмәскә тырышып тарткалашуым аркада бары таяк эзләре генә калдырды. Хәзер исә пилотканы колак йомшагына кадәр төшереп, шинельнең якасын бастырып, тезләрне ияккә кадәр күтәреп бөгәрләнгән хәлдә ятудан башка бүтән чара юк.

Рухи һәм физик халәт бик-бик нык алҗыткан. Шулай да бераздан җылына төшеп йокыга талам. Ярый әле, рәхмәт, минем ике ягыма да кемнәрдер килеп яткан, без шулай бер-беребезне җылытып йоклаганбыз.

Иртән кешеләр тавышлануына уянып киттем. Әсирләр уянган, көн яктырган, стеналардагы ярыклар аша яктылык тасмалары сарай эченә сузылган, бөтен әйбер аермачык булып күренә. Әсирләр шаннар тирәсендә кайнаша. Олы-олы шаннарның кайберсендә тозланган помидор калган. Әсирләр, шан кырыена бил тиңентен асылынып, аска үреләләр. Аргы очта, без кичә кергән ишек янына зур бер төркем кеше җыелган. Тышта, якында гына, сакчы тора булса кирәк, әсирләр шуңа кычкыралар, су сорыйлар, йә хаҗәтләрен үтәү өчен беразга тышка чыгаруын үтенәләр. Ләкин ишек ачылырга уйламый, немец хәзер саңгырау да, телсез дә.

Мин сарайның буеннан-буена узам. Нурины эзлим. Ул күренми. Йөрәгем жу итә, әллә бер-бер хәл булганмы? Шаннарны карап чыгам. Чыннан да, аларның кайберсендә тозланган помидор бар әле. Егетләр, шан кырыена ятып, котелокларын аска төшерәләр. Котелокка эләккән помидорны чәйниләр, тозлы суын эчәләр. Мин дә котелогымны чалбар каешына бәйлим дә помидор ауларга керешәм. Икебезгә дә житәрлек булсын дип тырышам. Кара, артык әче түгел икән лә үзе! Авызга ризык капмаганга бер тәүлек булды. Помидор кимерәм, әмма аның белән тамак ялганмый. Киресенчә, ашыйсыны гына китерә. Мин ары китәм.

Шаннарның бөтенләй бушлары да бар. Аларның төпләре коры, чиста.

Ишек янына җыелган әсирләр немец аңласын өчен, телләрен немецчага җайлаштырып, сакчының тышка чыгаруын, су бирүен бик зинһарлап үтенәләр. Арадан берәүсе немец телендә бераз сукалый булса кирәк. Ул: «Вассер, вассер»,— дип кычкыра. «Тринкен, тринкен»,— ди. Ләкин тышта бернинди дә җавап юк.

Мин Нурины ишектән ерак түгел стена буенда очраттым. Ул, миннән аерылгач, таралган вак кисмәк такталары өстенә ятып йоклаган икән. Безне бер генә минутка булса да очрашу шатлыгы канатландыра. Уртак хәсрәтне дә беразга оныттыра. Без сөйләшеп торабыз, мин аның хәлләрен сорашам. Нури бөтенләй суырылып калган, аның күз төпләре зәңгәрсу-кара, ләкин ул хәзер эч авыртуыннан зарланмый. Күрәсең, без кичергән экстремаль хәл чирне дә бәреп чыгарган. Ул миңа алдагы төндә, әгәр моннан куып чыгармасалар, үзе кебек кисмәк такталарында йокларга киңәш бирә. Стена буйларына урыны-урыны белән өелгән вак кисмәкләрне мин дә абайлаган идем. Ләкин аларның берәрсен сүтеп, такталарын җиргә аркылы тезеп, шуның өстендә йоклау башыма килмәгән. Без Нури белән төрлесен сөйләшәбез, ара-тирә мин китергән помидор суыннан авыз итәбез, помидор капкалыйбыз. Сусатыр бу каһәр, ди Нури, алай да тыела алмыйча помидор чәйни.

Сәгать уннарда ишек ачылып китте дә сарайга берничә коралы солдат һәм бер офицер килеп керде. Тәрҗемәче кычкырып тагын үткен әйберләр тапшыру турында әйтте. Немецлар тирәсенә әсирләр җыела. Су, бәдрәф, ашау турында сораулар, таләпләр яудыралар. Барысы да булыр, ди офицер, менә сез тиешле урынга барып урнашырсыз, ашарга да, эчәргә дә, башка комфорт та булыр. Сезнеңчә генә түгел, ә немец комфорты булыр. Һәркем үзенә тиешен алыр, ди.

Алар әсирләрнең үткен әйберләрен җыеп чыгып киттеләр. Халык бераз вакыт ярсып тавышланды да тынып таралышты. Һәркем үз эше белән мәшгуль. Ә без Нури белән һаман бер нәрсә турында сөйләшәбез. Ничек, ничек кенә ычкынырга соң бирелән?

— Моннан алып китәчәкләрен әйтте бит офицер,— диде Нури,— юлда инде, юлда, Атилла дус. Белмим, ниләр генә көтәдер безнең башларны?!

— Хискә бирелмә, Нури, реалист бул. Җаен тапмый калмабыз.

Шулай дидем, әмма үзем дә уйга калдым. Әйтүе генә ансат. Чыннан да, ниләр көтә икән безнең башкайларны?!

Көн, бик әкрен кыймылдаса да, уза бирә. Без, тора торгач, тагын шаннар тирәсенә «ауга» барабыз. Бу үзенә күрә бер мавыктыргыч эш булды. Әмма ашыйсы килә, рассол да, помидор да ачлыкны басмый. Шулай да хәзер мин иртә беләндәгедәй ачлык газабын кичермим. Күрәсең, бу хәл нервылар ярсуыннандыр. Кеше ачлыкта ризыкка карата үзенә бер төрле ваемсызлык хисс кичерә башлый, ахры. Мин әсирлек көннәремдә шуны тойдым.

Ишек тагын ачылып китте. Бер немец солдаты, ярым ачык ишек янына җыелган әсирләр арасыннан тазарак һәм яшьрәкләрен йолкып, ишегалдына ташлый башлады. Тышка унлап кеше чыгарылды, ишек тагын шыгырдап ябылды.

Ярыктан күзәтеп торучылар, сайланган әсирләрнең эшкә барачагын хәбәр итәләр, чөнки аларның эш кораллары алуын һәм конвой астында урам якка таба юл тотуын күзәтәләр.

— Күрдеңме?— ди Нури, миңа бик мәгънәле генә итеп күз кысып куя.

Күрдем дә, аңладым да. Димәк, безгә дә эшкә әләгергә кирәк. Белмәссең, бәлки шуннан ычкынып та булыр. Мин төнне, Нури әйткәнчә, кисмәк такталарыннан үземә ятак ясап, шунда йоклыйм. Әмма кәкре кисмәк такталары селкенгән саен чайкала, кымшынган саен аларның аралары үзгәрә һәм минем ятак тыныч йокыны бүлә. Юк, Нури әйткәнчә, рәхәтлек бирми бу кисмәк такталарыннан ясалган «караватъ». Нури кузгалмыйча, кымшанмыйча йоклый аладыр, ә мин йоклаган арада әйләнеп-тулганып бетәм.

Без урын алып калу өчен иртәгесен ишек янына ук барып бастык. Безнең вакыт хәзер җитәрлек, ашыйсы да, эчәсе дә юк. Ә шулай да җиңелчә баш әйләнүе мине борчый.

Без сабырлык белән ишекнең ачылганын көтәбез. Басып та көтәбез, чүгәләп тә көтәбез. Менә төш вакыты да җитте. Хәзер инде әсирләр «вассер» сорамыйлар, чөнки аннан файда юклыгын аңладылар. Гаҗәп икән ул адәм баласы! Нинди генә хәлләргә килеп эләкмәсен, барыбер үзе булып кала. Мин тирә-юнемдәге төркемләшеп әңгәмә коручыларга колак салам. Ниләр турында гына сөйләмиләр алар! Мәхәббәт маҗаралары да калмый, хатын белән булган низагълар да, күрше-күлән арасындагы яки хезмәттәге хәлләр дә. Начальство белән килеп чыккан бәхәс тә, мәҗлесләрдә ләх булганчы исергән чаклардагы әкәмәтләр дә — барысы да, барысы да сөйләнә. Кеше сүз белән мавыгып үзенең бүгенге хәлен бөтенләй оныта. Шуңа күрәдер, коточкыч тоткынлыктагы кешеләр дә ара-тирә шаркылдап көлә башлый. Әйе, гаҗәп икән ул адәм баласы, ул уен-көлкесез, юморсыз яши белми.

Без Нури белән көне буе ишек ачылганын сагалап чыктык, тик бәхетсезлеккә каршы, ул көнне безне эшкә чакыручы булмады. Мин кисмәк такталарыннан баш тартып, төнлә йокларга буш шан эченә төштем. Һәм, чыннан да, иң җайлы, җылы, коры урын шул булып чыкты. Уянгач, өскә менүләре җиңел булмады, әлбәттә, тик Нури ярдәме белән мин шулай да исән-сау өскә үрмәли алдым.

Мин инде тоткынлыкның өченче көнендә ишек ачылганын сагалауны кирәк санамаган идем. Тик Нури үзенең хаклылыгын исбат итте. Безгә кайда торсак та барыбер түгелмени? диде ул. Белмәссең, бәлки бәхетнең койрыгыннан эләктерербез шулай...

Нуриның күрәзәлеге бар икән. Без аның белән ишеккә сөялеп төшкә кадәр дә тормадык, кинәт ишек ачылып китте һәм Нурины, мине, тагы

бер рус егетен аюдай олы, аксельбант таккан немец якаларыбыздан өстерәп ишегалдына чыгарды. Анда безне автоматын муенына аскан кечкенә генә буйлы, бездәй үткен кара күзле яшь бер солдат көтә иде. Теге аюсыман җирән безне шуңа тапшырды да, аны кисәтүе булды, ахры, кабат-кабат бармак янап аңа ниләрдер әйтте.

Безне теге усал күзле бәләкәй солдат шәһәр урамы буйлап алып бара. Бөтен тирә-яктагы ишек аллары немец солдатлары, ат-арбалар, автомашиналар белән тулган. Капка төпләрендә кул кушырып торучы солдатлар, тамаша кылып, безне алып баручыга нидер кычкырып калалар. Аяк асты тубыктан пычрак, үзәкләргә үтә торган суыклык култык асларына кадәр үрмәли.

Менә безнең рус иптәшебез, җыелган суга басмас өчен, читкәрәк тайпылды. Немец шундук тегеңә каты селтәнеп, аның яңак төбенә чалтыратты. Минем белән янәшә генә барган Нуриның йөзенә кан йөгерде, ул тешләрен шыгырдатып куйды. Ләкин бу очракта иң хәерлесе дәшми калу. Мин аның терсәгеннән тоттым.

Без бер катлы өйнең иркен ишек алдына барып кердек. Монда походный пекарня арбалары, фургоннар күренә. Аларның көпчәкләре генә түгел, бөтен булганы баткакка батып беткән. Солдат безгә арбаларга төртеп күрсәтә, шуны чистартырга куша. Без эшне нидән башларга белми таптанып торганны күргәч, аның җен ачулары чыкты. Ул җирдә яткан таякны алып безгә селтәнә, бик каты җикеренә. Без чыбык-чабык белән коралланып, эленке-салынкы гына эшкә керешәбез. Мин Нурига карыйм. Нишлибез? Бу ишек алдының коймалары такта булса да, шактый биек. Солдат капканы бик нык итеп ябып керде, хәтта бастырыгын да эшерде. Әмма урамга чыгып йөгерүдән ни файда? Өй, үзе бер катлы гына булса да, шактый зур. Ике очында ике ишек күренә. Бераздан кечкенә өйнең ишегеннән бер әби чыкты. Ул да булмады, өйнең икенче, урамга караган ишегеннән берничә солдат башы күренде. Әби алардан шүрләде булса кирәк, шундук күздән югалды, ишекне нык итеп япты. Ә солдатлар исә безне күрү өчен чыкканнар. Алар өчәү. Бөерләренә таянып, безне алып килгән солдат белән ни турыдадыр гәп коралар. Ара-тирә кызыксынып безгә дә күз салалалр. Араларыннан берсе — милләте белән поляк, яки полякча белә торган немец, ахры. Ул безгә карап кычкыра. Янәсе, ашыйсыгыз киләме? Килсә, тырышыбрак эшләгез. Ул полякча дәшә, әмма рус сүзләрен дә бераз белә булса кирәк. Һәрхәлдә, без аның ни әйткәнен аңлыйбыз.

— Алдый,— дип куйды шыпырт кына рус иптәш.— Бирер сиңа немец ашарга.

Ләкин, аптыравыбызга күрә, эшебезне тәмамлагач, икмәк пешерүчеләр безне өйгә алып керделәр, кушуч зурлыгындагы бер түгәрәк икмәкне өчкә тигез итеп сындырып безгә тоттырдылар. Без ни әйтергә дә белмичә аптырап, теге полякча сөйләшүчегә текәләбез. Ашарга куша. Һәм тизрәк ашап бетерегез, юкса офицер килеп керүе бар, ди. Ул офицерның котсызлыгын күрсәтү өчен йөзен бик ямьсез рәвештә чыта, тешләрен ыржайта. Без ашап бетергәч, почмактагы әйберләр арасыннан бер шешә чыгара. Күз кысып: «Шпас тринкен»,— ди. Без шешәнең авызыннан берәр йотым аракы эчәбез. Ул, артык ярамый дигәнне аңлатып, ишарә бармагын күтәрә дә шешәне тиз генә элекке урынына яшереп куя. Бераздан ул үзләренең офицерларын хурлый башлый, аларны үртәп, аларча кыланып күрсәтә.

Бу сыйлану минутларында безнең сакчы өйдә юк иде. Ул, ашыгыч йомышын үтәргә киткәнлектән, безне икмәк пешерүчеләр карамагына тапшырган булса кирәк. Теге полякча сөйләшә торган мәзәк солдат, безнең сакчыны күздә тотып:

— Карагыз аны, ашаганыгызны тегеңә сиздерә күрмәгез,— ди.

Без, икмәк пешерүче солдатлар белән бергә, бераздан ишек алдына чыктык. Безнең сакчы әле күренми. Бая әби күренгән ишектән чандыр

гына, сакал-мыексыз бер карт кеше чыкты. Ул, безнең яндагы солдатларга сиздермәскә тырышып, арттан гына минем янга килде дә бияләй зурлыгындагы бер янчык тоттырды. Мин тиз генә аны шинель кесәсенә бушаттым. Бабай безгә чи борчак биргән иде. Бик мөмкин, картларның бу карап торган соңгы ризыгы булгандыр, авызларыннан өзеп шуны безгә бирәләрдер. Безнең яндагы икмәк пешерүче солдатлар бу эшне күрмәделәрме, күреп тә дәшмәделәрме. Бу турыда сүз булмады. Бабай кереп китте. Мин тиз генә кулымдагы бушаган янчыкны ишек тоткасына кыстырдым.

Без үзебез камалган урынга кайтышлый, сакчыга сиздермичә генә, берәмтекләп озак-озак чәйнәп борчак ләззәтенә кинәнеп барабыз. Әйе, безгә бу ирек үзенә күрә бәйрәмдәй тоелды. Ләкин без шуны да аңладык: әзерлексез-нисез монда әсирлектән качу мөмкин түгел.

Безне салкын сарайда яңадан бер төн кундырганнан соң, хурлыклы рәвештә шәһәрнең үзәк урамнары буйлап йөреттеләр. Аннан кәнбатышка сузылган шоссе буйлап алып киттеләр. Әсирләр колоннасы искиткеч зур. Мин борылып артыма карыйм, әмма колоннаның койрыгы күренми. Без камалып торган сарайдан гына чыкмагандыр бу кадәр әсирләр.

Безне автомат һәм таяк белән коралланган сакчылар ашыктыралар. «Шнель, шнель, лусь, лусь»,— дигән немец сүзләре уңнан да, сулдан да, алдан да, арттан да ишетелеп кенә тора. Ләкин сакчылар никадәр җикеренмәсен һәм таякларын армый-талмый эшкә кушмасыннар, барыбер колонна акрын сөйрәлә. Чөнки ул рухи яктан җәберләнгәннәрдән генә түгел, яшәүне газапка әйләндерүче ачлык дигән нәрсәне кичерүчеләрдән дә тора. Сабын һәм ару су күрмәгән, сакал-мыек баскан, пилоткасы кайтарылып колакларын каплаган месрен йөзләр, арт путасыз, якасы күтәрелгән лыпшырдык шинельләр, муенга асылынган буш противогаз сумкалары...

Авыллардан узганда безне урамнарда хатын-кыз каршы ала, аларның кыюраклары колоннага шактый якын килеп, ә кыюсызраклары ерактан торып, безгә пешкән бәрәңге, икмәк кисәкләре ыргыта, арагызда фәлән кеше юкмы, дип ачы тавыш белән ирләрен, улларын сораучылар да очрый. Әсирләр ташланган ризыкны эләктерергә тырышалар, бәхетлесе тиз генә аны сумкасына тыгып куя. Ә немец солдатлары мондый чакта бөтенләй котырыналар, автоматлардан һавага ату тавышлары яңгырый, немецчә сүгенү колоннаның бер очыннан икенче очына кадәр ишетелеп тора. Колоннадан әз генә читкә тайпылсаң да сине рәхимсез немец таягы көтә.

Без сибәләп яуган яңгыр астында барабыз. Төрле сүзләр йөри. Берәүләр фәлән шәһәргә, икенчеләр төгән шәһәргә юл тотабыз, дип сөйләнәләр. Соңыннан жирле кешеләрдән мәгълүм була — безне Болхов каласына куалар икән.

Караңгы төшкәч, тәмам күшегеп, хәлдән таеп Болховка барып життек. Колоннаның бер өлешен дыңгычлап, нииндидер бер таш өйнең подвалына керттеләр. Мин дә шунда эләктем. Нури исә ничектер арткарак калган, аларны башка урынга алып киттеләр. Без шунда аерылыштык.

Мин эләккән подвалда без кергәнче ябылган әсирләр дә бар иде. Подвал тула башлагач, алар аягүрә басарга мәҗбүр булдылар. Ә безнең колоннада килгәннәрне әле һаман дыңгычлап тутыралар. Ишек янында туктлып калучыларны солдатлар рәхимсез рәвештә таяк белән кыйныйлар. Алай гына да түгел, бик ачуы чыкса, мылтык хәнҗәрен дә эшкә куша ул. Нәкъ минем яныма йөзен чыткан бер әсир килеп басты. Ул ачы сызлана. Аның артына немец шул мылтык хәнҗәрен чәнчегән.

Без хәзер барыбыз да аягүрә торабыз. Утыру турында әйткән дә юк. Кая аяк куйсаң, шунда кеше аягы. Мин бераз вакыттан соң сул аягымның урынын югалттым. Хәзер сыңар аякта гына басып торырга мәҗбүрмен. Ярый әле кирпеч стена янына туры килдем. Ул юеш, үзе суык булса да, аңа арка терәргә, тез буыннары йомшарып аска чүгә башлаганга кадәр саплам-саплам черем итеп алырга була.

Төрле яктан ыңгырашкан, кай җирендер авырттырган күршесен яки язмышын кабахәт сүзләр белән сүккән әсирләр тавышы ишетелеп китә. Алдымда гына торган, битемә үзенең юеш шинель якасын терәгән кеше үзәккә үтәрлек итеп сыкрана. Аның яраланган җире шешә башлаган, күрәсең. Ләкин нинди генә ярдәм күрсәтергә була соң ана мондый шартларда?! Күршең үлсә дә аягүрә баскан килеш үләчәк, һәм син бу зинданнан котылганчы аны кочаклап торырга тиеш буласың.

Сасы, тынчу, дымсу. Тын кысыла. Каршы як стенадагы бүрек зурлыгындагы тишектән кергән һава бу кадәр халыкка җитәрлекме соң?

Шулай да без төнне исән-сау уздырдык. Иртәгесен ишек ачылды, димәк, ишек алдына чыгарга рөхсәт. Көн аяз, тәмам яктырган. Төне буе яуган яңгыр суларын әсирләр котелокларына җыеп чиратлашып эчәләр. Мин Нурины югалттым. Ахры, аны бөтенләй башка җиргә илтеп япканнар. Биредә дә без урнашкан подвал тирәсен чәнечкеле тимерчыбык белән камап алганнар. Кичә бу күзгә чалынмаган иде, әллә төнлә ясап куйганнар. Почмакларда калку вышкалар, анда безгә төбәлгән пулеметлар, сакчылар. Бәләкәй ишек алдының кыл уртасында ат үләксәсе ята. Анысын да мөгаен төнлә безнең өчен китереп ташлаганнар. Ләкин аның янына баручы юк. Үләксәнең эче купкән, тешләре ыржайган, эре симез, яшел чебеннәр аның авыз тирәсендә кайнаша. Кояшта җылынып, таш бинага арка сөягән хәлдә, җирдә аяк бөкләп, биш үзбәк агае утыра. Мин аларның нинди милләт вәкиле икәнлеген төсләреннән һәм сөйләшүләреннән таныйм. Алар котелокларын алларына куйганнар, әйтерсең лә ...әер эстәүчеләр. Аларның икесе ачлыктан шешенә башлаган инде. Күрәсең, биредә байтактан бирле торалар. Ара-тирә сөйләшеп, күбрәк бер-берсенә ләм-мим сүз дәшмәстән, кояш нурларына сөенгәндәй нидер көтеп утыралар.

Күрше йортның агач коймасы тирәсендә чүплектә казына торгач, берәү вак кына башлы суганнар тапты. Ул бер өем. Суганнар тыштан чери башлаган булсалар да аларның эче чиста, ашарлык. Мин дә йөгереп барып биш-алты суган эләктердем. Бар микән дөньяда чи суганнан да тәмлерәк ризык! Озаккарак җиткерү өчен әкрен-әкрен генә шуларны суырам.

Кояш төшлеккә таба шактый югары күтәрелә башлагач, урам якта шәһәр кешеләре күренде. Купчелеге хатын-кыз, бала-чага. Тимер чыбык киртә буйлап әрле-бирле йөренгән сакчылар сизмәгәндә, алар йөгереп безгә якынлашалар да пешкән кабыклы бәрәңге, йә берәр сыныг икмәк ташлыйлар. Кем бәхетле — ризык шуның алдына килеп төшә. Анда да йоклап торма, юкса янындагы әсир дә бик ач.

Минем ачлыктан баш җиңелчә әйләнә. Ләкин бернинди дә азап кичермим. Менә ничә көн инде тамак ялгаган юк. Бары хәлсезлек һәм башның ничектер артык сафлануын гына тоям.

Вакыт шулай уза. Безне төш вакытында тагын олы юл буйлап Көнбатышка таба куалар. Юлда авыллар аша узабыз. Колонна якынлашу белән, ул авылларда капка төпләренә хатын-кыз, бабай-әбиләр чыга. Безгә булдыра алганча алар ярдәм итәргә телиләр, булган ризыкларын ташлыйлар. Арагызда фәлән кеше юкмы яки шундый кешенең язмышын белмисезме, дип сорап кычкырулар безне тагын озата. Ә сакчыларда рәхим-шәфкать юк. Алар хатын-кызны колоннадан таяк белән куып җибәрү генә түгел, хәсрәтләре хәттин ашкан бу бичараларга автоматтан сиптерергә дә күп сорамыйлар.

* * *

Болхов шәһәреннән чыгып киткәч, безне бер зур таш чиркәүле авылда кундырдылар. Мин шул ташландык чиркәүгә эләктем. Идәне таш, тәрәзәләре ватык, шуңа күрә ифрат суык. Ләкин биредә иркен, һич югында монда сикергәләп, хәрәкәтләнеп бераз җылынырга була. Ир-

тәгесен без байтак вакыт тоткарланып тордык. Әйтүләренә караганда, берничә әсир үзләре кунган сарайда салам өеменә яшеренеп калырга теләгән. Сакчылар моны сизеп, саламга ата башлаганнар. Яраланган ике әсир кычкырып үзләрен фаш итә. Калганнарыбызга сабак булсын дип, немецлар менә шуларны безнең алдыбызда ук атып үтерделәр. Тоткарлану шуның аркасында иде.

Менә без тагын юлда. Юлны белүчеләрнең сүзенә караганда, без Орел шәһәренә барабыз. Халык ачлыктан һәм озын юлдан тәмам алҗыган. Шуңа күрә колонна ифрат әкрен кыймылдый. Колоннаны озатучыларның акырынуы көчәйгәннән-көчәя, алар әле беребезне, әле икенчебезне колоннадан йолып алып, рәхимсез рәвештә таяклар белән кыйныйлар. Әмма колонна моңа карап кызуламый. Авыллар аша узабыз. Шул ук күренеш, шул ук ризык ташлау, шул ук сорашу.

Без бер сафта баручы берничә әсир сөйләшеп киттек. Миннән башкалары — руслар. Шушы як кешеләре. Берсе аның төптән юан, кыска муенлы, җирән сакаллы Калинин дигән кеше. Ул сугышкача Орелда янгын сүндерүчеләр командасында хезмәт иткән. Икенчесе озын буйлы, тупас йөзле, мимикага фәкыйрь чырайлы. Аны армиягә төрмәдән җибәргәннәр. Ул да бу як кешесе, колхозчы. Сөйләвенә караганда, бер дә юк сәбәптән колхоз милкен урлауда гаепләп, төрмәгә япкан булганнар. Анысы Королев. Өченчесе Пахвостов. Кечкенә генә буйлы, чандыр, җиңел сөякле егет. Колхозчы. Була бит шундый иркен күңелле, юмарт җанлы кешеләр. Пахвостов та шундыйлардан. Ул, авылга якынлашу белән, сакчыга сиздермичә генә сафның кырыена күчә. Апалар безгә ризык атканда үзенең җитезлеге, елдамлыгы аркасында берәр әйбер эләктерми калмый. Барыннан да әйбәтрәк сыйфаты тагын шул: тапкан малын дүртебезгә дә тигез итеп бүлә. Без шулай дүрт кеше якынаеп киттек, үзара сөйләшәбез.

— Безнең башлар бетәр инде шулай,— ди Калинин.

— Шулай ук бетәр микәнни,— ди куркынып Королев,— төрмәдән исән-сау котылдым, инде монда бетәр микәнни?

— Ычкынырга кирәк,— ди Пахвостов.

— Ә качудан курыкмыйсыңмы соң? — дип сорыйм. Мин инде бу турыда күптән уйланам. Ләкин ничек? Һаман җае чыкмый бит каһәр! Һәр тукталган җирдә — без ябылуда. Төннәрне көчле сак астында уздырабыз. Калинин миңа мәгънәле генә итеп күз ташлый, шыпырт кына әйтә:

— Әгәр син оештыруны үз кулыңа алсаң, тәвәккәлләргә була.

— Вәгъдәме?

— Валлаһи, вәгъдә. Ни кушсаң, шуны эшләрбез, сержант.

Мин шул минуттан алып үземә йөкләнгән вазыйфаны үтәү әзерлегенә керешәм. Без бер-беребездән аерылмаска тиеш. Беренче мөмкинлек булу белән тәвәккәллибез!

Кыска приваллар ясап һаман алга барабыз. Әйтергә кирәк, бу тукталышлар ешайганнан-ешая. Алҗыган әсирләр, артык барырлык хәлләре калмагач, «Привал» дип кычкыра башлыйлар. Бу сүз, ялган булмас, бер километрга сузылган колоннаның бер башыннан икенче очына кадәр өзлексез яңгырый. Тегe очка житеп тына төшкәч, яңадан көчәеп бу очтан башланып китә. Җыландай өстерәлгән колонна өстендә бу тилмереп тә, янап та, ачынып та кычкырган авазны сакчылар берничек тә туктата алмыйлар. Алар һавага аталар, сүгенәләр, аерым әсирләрне колоннадан чыгарып кыйнап та карыйлар, әмма болар файдасыз, соңыннан колоннаны туктатмый чаралары калмый. Без шулай туктап-туктап алга барабыз.

Кичкырын, инде күзләр бәйләнә башлагач, билгеләнгән урынга барып җитмәдек булса кирәк, безне юл буендагы ачыклыкта туктаттылар. Бер ягыбызда бодай кыры, икенче ягыбызда җитен басуы. Без, күрәсең, әле генә салынган, өр-яңа, биек ашлык киптерү әвене янына туры килдек. Әвен тактадан салынган, ике катлы өй биеклегендә диярлек. Сакчылар безгә колоннадан чыгып шушы урында төн уздырырга рөхсәт итәләр.

Адәм баласы яшәү, ачтан үлмәс өчен ниләр генә эшләми! Әсирләр, тукталу белән, бодай басуына ташландылар. Эчкә керергә рөхсәт юк, ләкин ишелеп унган бодайның юл читендәгесе дә житәрлек. Учка жыеп башак уабыз. Барысы да гәрәбәдәй бодай бөртекләрен учларында ук җилгереп котелокларына салалар. Ул да булмый, бер зур төркем әсир, әлеге яңа салынган әвенгә ташлана, аның такталарын каерып утын әзерли башлый, һәм бу бинадан санаулы вакыт эчендә бары аның кысалары гына торып кала. Ачлык кешене эшләтә, булдыра алмас эшләрен булдырырга мәҗбүр итә икән. Әсирләрнең берничди коралы, һич югында кирәк кебек нәрсәләре дә булмаган хәлдә, әвеннең шома ак такталары шытырдап каерылды, сындырылды, чәрдәкләнеп вакланды. Тиздән юл буенча сузылып киткән учаклар дөрләп яна башлады. Әсирләр уйсу җирләргә җыелган яңгыр суларында бодай боткасы пешерергә керешә.

Без дә дүртебезгә бер котелок бодай астык. Ләкин никадәр озак кайнатмыйк, безнең бодай әз генә дә бүртмәде, йомшармады, һаман чи, каты килеш калды. Без эш арасында шыпырт кына качу турында сөйләшәбез. Моннан да җайлырак вакыт булмаячак, тәвәккәллик, дибез. Егетләр миңа карый. Минә ничек, дим, качканда берәм-берәм үк яктагы житен басуы ягына шылырбыз. Ул басуга киптерергә дип житен чүмәләләре тезгәннәр. Алар шахмат тәртибендәрәк торалар. Ә алар артында ерым. Мин аңа бирегә килеп житәр алдыннан ук игътибар иткән идем. Без чүмәләдән чүмәләгә күчеп ерымга төшәбез дә, шул сузынкы чокыр буйлап йөгерәбез? Булдымы? Шулай сөйләштекме?

Егетләрнең йөзләре житдиләнә, алар үзләренең алдагы язмышлары һәм минә шуны хәл итәчәк качу турында уйлыйлар. Ләкин шулай бирелеп сөйләшкәндә, тирә-юнебезнең кинәт яктырып китүенә игътибар итәбез. Күк йөзенә ай калка. Ул ашыгып агылган болытлар арасыннан әле ялтырап күренә, әле күмелә. Тирә-як андый минутларда тагын караңгылыкка чума.

Без кайнар бодай чәйнибез. Ләкин ул авызда да йомшармый. Шулай да чәйнибез, әз генә булса да тәнгә хәл керсен.

— Йә, тәвәккәллибезме, егетләр? — дим мин.

— Аллага тапшырдык, — ди Калинин. Без күк йөзен күзәтәбез. Анда болытлар хәзергә айны каплап торалар. Алар ашыга-ашыга Көнбатыш ягына агылалар.

— Мин әзер, — ди Пахвостов, — әзер.

Ул, утырган урыныннан торып, якындагы учаклар арасына кереп югала. Ә болытлар һаман агыла. Ай бер күренә, бер болытлар артына кереп кача. Түземсезләнеп Пахвостовның әйләнеп кайтуын көтәбез. Кая олакты инде ул шундый вакытта? Газаплы минутлар. Безнең күңелләр кузгалган хәзер. Булса хәзер була, булмаса юк инде. Житен басуы бер яктыра, бер караңгылыкка күмелә. Ай әле хәзер яртыкүкне каплаган кап-кара болыт астына кереп качты. Ә ул болыт узды исә, аның артында саф күк йөзе ачылачак. Белмәссең, бәлки калган төн гел ай яктысында узар. Без Пахвостовны артык көтә алмыйбыз, дигән уйга киләм мин, бәлки ул шүрләп, шулай безнең компаниядән аерылгандыр!

Әкрен генә, иелеп житен басуына таба атлыйбыз.

— Берәм-берәм, чүмәләдән чүмәләгә, дим мин.

— Аллам сакласын, ди Калинин, — үлсәк бергә үләбез.

Аның белән бәхәсләшеп торыр чак түгел. Королев белән Калининның кулыннан тотам, без бик нык иелгән килеш якында күренгән чүмәләгә таба йөгерәбез. Аның янына житеп бераз тынлыкны тыңлап торгач, тагын, тагын иелеп йөгерәбез. Минә калкулыкка менеп життек. Үрдән түбән чирәм белән өртелгән чокырга очабыз. Аннан уң кул якка ерым буйлап шулай ук барлык көчебезгә чабабыз. Артта тавыш күтәрелдеме-юкмы, мин бернәрсә ишетмим, белмим. Аны ишетерлек хәлдә түгел кеше. Барлык көч тизрәк колоннадан ераклашуга бирелгән.

Күпме чапканыбызны әйтә алмыйм, ләкин бервакыт без барыбыз берьюлы чирәмгә аудык. Күрәсең, барлык егәрлекне тәмам сыгып, шушы турыда бетергәнбездер.

Мин баш калкытам. Тирә-юнь тып-тын, ай нурлары бөтен җиһанны балкыткан. Шулай ук әсирлектән, караңгы хурлыктан котылдык микәнни?! Йә хода, Королев та, Калинин да тезләнеп чукынырга керештеләр. Минем баш калкытуымны күреп, алар миңа текәләләр.

— Рәхмәт сиңа, сержант, син булмасаң, без котыла алмый идек!

Без сулыш алуларыбыз бераз игә килгәнче юеш чирәмдә утырабыз. Калинин кесәсеннән курайсыман кипкән көпшәләр чыгара. Тәмәке сабаклары икән. Ул аларны сындыргалый, учында уа. Әзер тәмәкене, хөрмәт йөзеннән, беренче буларак миңа суза. Кәгазь дә бирә, шырпы да чыгара. Без тын гына, үзебезне иң бәхетле кеше итеп сизеп, тәмәке тартабыз. Аннан, арттан куа килүче юклыгына тәмам ышанган хәлдә, ерым буйлап ашыкмыйча гына юлыбызны дәвам иттерәбез. Әйе, явыз фашист солдатлары белән әйләндерелгән әсирләр колоннасыннан котылдык, шөкер. Ләкин бу шатлык артык озакка бармый. Безнең бит әле дошман басып алган, фашизм хакимлек иткән җирләрдән үтәсебез дә бар. Анда ниләр көтә безне?

Бик озын, берничә километрга сузылган ерым беткәч, ара-тирә вак куаклык белән чуарланган якты яланга килеп чыктык. Кайдадыр бик еракта, төнбяктарак эт өргәне ишетелеп китте.

— Авыл! — диде Королев.

— Безгә шунда юл тотмый мөмкин түгел. Бу киемнәрне алыштырмасак, безне бик тиз тотачак немец!

Бу сүзләрне Калинин әйтә.

Без шул эт өргән тавышка таба киттек. Өчебез дә үтә сак, еш кына дошман өстенә барып чыкмагаек дип як-ягыбызны күзәтәбез. Ләкин айлы төн үзенә бер төрле шомлы тынлык саклый. Суыктан тән җинелчә калтырана. Җан-фәрманга чапканда гына һаваның суыклыгы абайланмаган икән ул. Көз көзлеген итә.

Мин барачак юлыбыз турында уйланам. Алынгансың икән, егет, эшеңне ахырына кадәр җиткер инде! Юллардан бару хәвефле, киемнәрне алыштырганда да әле безне эләктерсәләр, баштан сыйпамаячак дошман. Димәк, иң кулае безгә юлсыз-нисез бару. Минем итек куныччымда — комсомол билеты. Мин аның турында уйланам. Юк, юк, безне тотмаячаклар. Ятсын ул үз урнында. Безгә юлсыз-нисез туп-туры көнчыгышка таба барырга кирәк. Әгәр шулай итсәк, барысы да уңышлы төгәлләнәчәк. Мөмкин кадәр кыскарак юл ясарга кирәк. Күрәсең, туры юл сабып бару, комсомол билеты һәм ул элек яткан гимнастерка кесәсенә бәйләнештә минем хәтергә Татищеводa булган бер вакыйга, кыйбланамә вакыйгасы, ул кыйблапамәнең угы минем шул кесәдә булырга тиешлеге хәтергә төшә. Шул магнитлы укны инә очына утыртсаң, ул бит синең кайсы тарафка баруыңны белдереп торачак. Булды бу! Мин үземнең ачышымны иптәшләргә әйтәм, алар да моңа шат. Хәер, алар бөтенләе белән үзләрен миңа тапшырганнар. Мин күкрәк кесәмнән күзлегемне алам, ук аста гына ята булыр. Әйе, компас угы исән-сау саклаңган. Шуны чыгарам да гимнастерканың кесә капкачына астан кадап куелган энәне алам һәм укны шуңа утыртам. Укның очы магнитлы гына түгел, ул фосфорлы да, аның кайсы якны күрсәткәнен караңгыда да күрергә була, ә хәзер ай яктысында болай да күреп була.

— Без хәзер төньякка таба барабыз! — дим мин. Юлыбызны дәвам иттерәбез, сирәк-мирәк сөйләшәбез, бездән аерылып калган Пахвостовны искә төшерәбез.

— Аның өчен ут йотма, сержант,— ди Калинин.— Ул куркак, минемчә! Ә куркак кеше белән мондый чакта эш итмәү хәерлерәк.

Эт өргән якка байтак кына вакыт барганнан соң, авыл читендәге бер өйнең бакча артына килеп чыгабыз. Анда салам кибәне, без шуның

янына утырышып хәл җыябыз, ачы җилдән сакланып куенга җылы җыябыз.

Әнә беренче әтәчләр кычкыра. Без артык ярсыган да, туңган да, аркаларыбызны кибәнгә бик нык терәп утырган килеш шыпырт кына киңәшәбез. Нишләргә? Төнне шушы кибән янында уздырыргамы, әллә тәвәккәлләп бакчаның аргы очындагы өйгә сугылыргамы? Ә анда немецлар булса? Хәер, немец булмаска тиеш. Чөнки өйдә немецлар булган очракта, сакчысыз йокламаслар. Ә сакчының барлыгын без күрмәсәк тә моннан ишетеп белер идек. Димәк, бу авылда дошман булган хәлдә дә, алар бу өйдә юк.

Урныбыздан торып, яшелчә бакчасы аша сак кына авыл урамына таба юнәләбез. Тынлык, тынычлык, хәтта этләр дә өрми. Без башкаларыннан читтәрәк торган фәкыйрь өйнең тәрәзәсен чиртәбез. Тынлык. Тагын сак кына чиертәбез. Бераздан ай яктысы төшеп торган шәрә тәрәзәдә чәчләре тузган рус хатынның куркынган йөзе күренә.

— Кем анда? Сезгә нәрсә кирәк?

— Хуҗабикә, авылда немецлар юкмы? Без үзебезнекеләр, пленнан качып киләбез.

— Немецларның күренгәне юк әле.

— Кунарга кертмәссең микән?

— И егетләр, өемдә энә төртерлек тә урын юк. Валлаһи. Бала-чага бик ишле. Әнә күршеләрнең өе бик иркен, анда ир-ат заты да бар. Шунда керегез, алар сезне кертми калмас.

Хатын тәрәзә яныннан китте дә юкка чыкты. Эчтән бары бала еламсыраган тавыш кына ишетелеп китә. Без күрше өйгә таба атлыйбыз. Бу өй, чыннан да, хатын әйткәнчә, иркен, алты почмаклы, үзе хәтта тимер түбәле дә. Безнең ишек шакуыбызга ук, озак көттермәстән, ишекне урта яшьләрдәге чегәндәй кара бер ир кеше ачты. Ахры, бер күз ташлау белән үк ул безнең кем булуыбызны чамалагандыр.

— Камалыштанмы? — Кеше үзе дә әле күптән түгел генә камалыштан котылып кайткан икән.

— Кереп бераз җылыныгыз, егетләр, тик иртән үк сезгә авылдан чыгып ычкынырга туры килер. Немец күрше авылда гына. Ул теләсә кайсы минутта килеп керә ала. Мин үзем дә алар күзенә күренмәячәкмен.

— Без моннан киткәндә киемнәрне алыштырасы иде, хуҗа. Юкса... — диде Калинин. Без өйгә кереп, алгы як бүлмәдә идәнгә утырыштык. Хуҗа өс-башны күздән кичерде, аннан миңа тукталып:

— Менә сержантның киемнәрен алыштырып бирә алам, — диде.

Моның сәбәбе, әлбәттә, барыбызга да аңлашыла иде. Чөнки минем шинель никадәр пычрак һәм йомарланган булмасын, иптәшләремнекеннән затлырак.

— Ә безгә? Безгә нишләргә? — диде борчылып Королев.

— Көн яктырсын әле, халык уянсын, сезнекен дә берәрсе алыштырып бирер. Ә сержантның киемнәрен, әгәр теләсә, мин хәзер үк алыштырып бирәм. Менә дигән, эче тиреле кыска пальто сиңа! Мин чолганыштан шуны киеп чыктым. Бәхетле кием.

Без артык арыган, талчыккан идек. Бу алыш-биреш эшләрен иртәгә башкарырга булып, хуҗа биргән икмәк катыларын капкалагач, шул утырган урныбызда ук идәнгә ятып йокладык.

Иртәгесен мин хәрби киемнәремне хуҗага биреп, аның киемнәрен кидем. Иске кара чалбар, якасы сидрәгән буй-буй зәңгәрсу күлмәк, тузган күн тышлы финка бүрек һәм әлеге тире эчле постау тышлы кыска кара тун. Хуҗа минем итектән генә баш тартты, чөнки аның авызы ачыла башлаган — «тамагы ачкан» иде инде.

Мин киенеп, хуҗа биргән зур бер телем икмәкне сөт белән ашап бетергәндә, юлдашларым да гражданский киемнәрдә кайтып керделәр. Без авыл халкы уянганчы, өйрәтелгән юл буенча хәвефсез саналган сукмаклардан алга, үзебезнең якка, фронт сызыгына таба киттек. Хәлбу-

ки, фронт бик, бик еракка китеп өлгергән иде инде. Бер генә ату тавышы ишетелсенче! Бары яңгын шәүләләренең генә күккә үрләп көнчыгыштагы офыкны яктыртуы алда дәһшәтле сугыш барганлыгын, кан коелуын хәбәр итәләр иде.

Без ике көн, булдыра алганча, кызу-кызу алга бардык. Юлдагы авылларга кереп тамак ялгадык, немец турында белештек һәм юл сораштык. Ашарга кергәндә өчебез өч өйгә керә торган булдык. Авылларда ир-ат күренгәли. Боларның күпчелеге чолганыштан котылып өйләренә кайткан кешеләр. Арада бөтенләй чит як кешесе булып та, берәр тол хатын өендә «кияүләп» калучылар да юк түгел. Андыйларны руслар «в зятья пристал» диләр. Әле, бәхеткә каршы, немец юлыбызда очрамый.

Юлга чыгуыбызга өченче көн киткәндә, мин дусларымның үземә ничектер элекке хөрмәтләре суына башлавын тойдым. Аерата Калинин минем белән юктан бәхәскә дә кергәли, хәтта минем җитешсезлекләремне дә тиешеннән артык күрә. Бераз баргач алар миннән сораша башладылар. Янәсе, мин авыл эшләрен беләмме? Җир сөргәнем бармы? Печән чаба беләмме, балта тотканым бармы, чабата тугу һөнәреннән хәбәрдармы һ. б. Мин юлдашларымның үземне командир буларак санга сукмый башлауларын абайлыйм. Ләкин нишли ала идем бу очракта? Мин алардан хәзер бары шикләнә генә ала идем. Һәм, чыннан да, табышмак бик тиз чишелде. Иртәгесен үк юлыбыздагы бер зур гына авылга җитү белән, алар миннән яшеренеп калдылар. Болай булды: без авылга килеп кергәч, гадәттәгечә, хуҗаларга җиңелрәк булсын өчен, кайсы өйләргә керәсебезне алдан сөйләшеп, өчебез өч өйгә таралдык. Шундый кагыйдә урнашкан иде инде, әгәр берәребез алданрак чыкса, ул мотлакан иптәшләре кергән өйләр тирәсендә көтеп торырга тиеш. Башта мин кереп киттем. Мин кергән хуҗабикә яңа пешкән бәрәңге белән сыйлады. Әлеге өйдән чыгу белән иптәшләремне алар чыгасы өй тирәсендә көтәм. Сабырлык белән бик озак көтәм, бераздан күңелгә шикле уйлар килә башлый. Шулай ук минем юравым дөрескә чыкты микәнни? Тотам да алар керергә тиешле өйләргә сугылам. Менә сиңа дуслар! Алар бөтенләй бу өйләргә кермәгәннәр дә. Барысын да аңладым. «Дуслар»ның яңадан сугыш кырына барудан куркып, кияүләп, дошман тылында калырга ният иткәнлекләрен аңладым.

Миңа бик авыр. Нигә шундый кешеләргә юлыктым соң? Ниемә хаҗәт булган миңа шул куркак җаннарны ияртеп хәвефле эшкә барырга. Үзем генә качкан булсам ичмаса. Ләкин минем бернинди дә чарам юк иде хәзер. Өйләр борынча йөреп, аларның миннән качып калуына тәмам ышангач, җаныгыз җәһәннәмгә чәнчелсен дип, артка карап юлга бер төкердем дә япа-ялгызым авылдан чыгып киттем. Бүтәнчә Калининны да, Королевны да беркайда да очратмадым.

Ярый әле көннәр аяз тора. Куаклыклар, калкулыклар, сай ерымнар аша узып, туп-туры көнчыгышка таба барам. Кирәгендә компас угын энәгә утыртып, барыр юлымны билгелим. Көзге кояш җылыткан ышыклыкларда кырын ятып ял итәм. Мин, һичшиксез, үз ягыбызга чыгачакмын. Тегe чакта, тирә-ягымда миналар шартлаганда, үземә аларның кыйпылчыгы тимәчәгенә ышанган кебек, мин әле дә исән-сау үз ягыбызга чыгуыма ышанам.

Туп-туры көнчыгышка таба барам. Тик шулай да юлсыз җирдән баруның бер җайсыз ягы бар. Ул да булса, һич көтмәгәндә үтә алмастай урыннарга, куе агачлыкка яки елгачыкка, йә инде тирән чокыр алдына килеп чыккалыйсың. Ул чагында синең туры сызыгың туксаң градуска сына. Әйләнгеч юл эзли торгач, әллә кайларга барып чыгарга туры килә. Ләкин шулай да маршрутымны бозмаска тырышам, әледән-әле компас угын энә очына утыртам. Ул миңа көнчыгышның кайда икәнлеген һич хыянәтсез күрсәтә.

Дошман басып кергән җирләрдән ялгыз гына узганда хәтергә бик нык сеңеп калган истәлекләрем бар. Һич онытасым юк, мәсәлән, бер

авылга көн карангылангач килеп кергәндә мине сәнәкләр белән коралланган авыл агайлары каршы алды. Алар эскертләрдәге ашлыкны каравыллыйлар, имеш. Һәм кемнән диген? Минем гаҗәпсенүемә каршы — партизаннардан. Янәсе, партизаннар яшеренеп авылларга керәләр дә колхоз ашлыгын яндыралар, халыкка бүлешергә калмый.

Икенче бер авылда мин гади кешеләрнең һәм аерата хатын-кызларның ни дәрәҗәдә шәфкатьле булуын күреп исем китте. Бер авылга, гадәттәгечә эңгер-меңгердә барып кергән идем. Инде күнелгә сеңгән кагыйдә буенча, авыл кырыендагы өй тәрәзәсен шакылдатып немецлар турында белештем. Аннан авылда дошман солдатларының юклыгын белгәч, иркенрәк күренгән бер өйгә тәвәккәлләп куна кердем. Анда кайнана белән яшь килен генә яшиләр икән. Ир-ат барысы да фронтта, алардан берниндн дә хәбәр-хәтер юк.

Хәтердә ачык сакланган: яшь килен җыйнак, ачык күңелле, тышкы матурлыктан да бигрәк, эчке гүзәллеккә бай хатын иде. Әле немецның бу якка аяк басканы юк икән. Киленчәк авыл советы депутаты булган кеше, үзенә ни булыр инде дип ут йотып яши. Без аның белән төрле нәрсәләр турында бик озак сөйләшәбез. Ни өчен шулай килеп чыкты? Ни өчен без — бер карыш җиребезне дә дошманнан таптатмабыз дигән кешеләр — хәзер хурлыклы рәвештә чигенәбез, фашистка халыкны коллык газапларын чиктерергә, авылларны яндырырга, шәһәрләрне бомбага тотарга ирек бирәбез? Ни өчен бу шулай?

Кайнана йоклый. Мин дә тәмам көне буе килеп арыганмын. Киленчәк исә, минем эчке күлмәкләремнең керле булуын күреп, шундук аларны кайнар суда юарга керешә.

Мин кем аңа? Ачлыктан, киеренкелектән, сагаю халәтеннән һәм хәвефле юлдан соң, тәмам алҗыган бер кеше. Мин аңа берниндн яхшылык эшли яки ярдәм итә алмыйм. Шулай да киленчәк төн йокламый минем күлмәкләремне юып киптерде. Менә бу вакыйгага кырык елдан артык вакыт узды инде, әмма ул яшь, якты чырайлы хатынның мөлаем йөзе минем күз алдымнан китми. Аны искә алган саен, гади кешеләргә карата булган ышанычым, мәхәббәтем күңелемдә арта гына бара.

Мин бара торгач, географик картасыз юлны дәвам иттерү бик уңайсыз, ярым сукыр килеш хәрәкәт итү икәнлеген аңладым. Шуңа күрә очраган һәр авылда карталары булырдай кешеләрне эзли башладым. Әмма бу эш тә алай җиңел түгел. Укытучылар, белгечләр армиягә яки партизан отрядларына китеп беткән, башка авыл кешеләре алай монарчы географик карталар белән артык кызыксынмаганнар. Шулай да миңа бер авылда карта белән коралланырга мөмкинлек туды. Аны миңа олы яшьтәге бер интеллигент, гыйльми хезмәткәр бүләк итте. Ул кеше үзенең бәләкәй гаиләсе белән авылның зур өлешеннән тирән чокыр белән аерылган берничә йорттан гына торган хутор сыман җирдә яши иде. Аларның яңа гына салынган йортлары читтә, агачлык янында. Мин аларга барып кергәндә хуҗа үзе күренмәде. Мине кап-кара чәчле, чибәр, яшь, интеллигент кыяфәтле хатын һәм аның нәкъ үзенә охшаган дүрт-биш яшьлек кызы каршы алды.

Өйләренә тәкәллефсез рәвештә килеп кергән хәрби киемле кешене күреп, алар каушап калдылар булса кирәк. Миңа аларны тынычландырырга, үземнең нинди максат белән аларга керүемне аңлатырга туры килә.

Хуҗа эчтә икән. Мин аның янына узам. Ул саргылт күперенке мыеклы, ябык йөзле, хатынына караганда байтак олы яшьтәге бер кеше караватта ята. Мин аңа үземнең ни өчен аларны борчып йөрүемне аңлатам. Тиздән без аның белән шактый якын мөнәсәбәттә идек инде. Безнен мөгамәлә дә шунда ук җылынды. Ул сораша, мин күргән-белгәннәрне сөйлим, сүз шулай җайлы гына куера. Нићаять, алар миңа үзләрендә бераз тоткарланырга, мине аш ашап китәргә кыстый башладылар. Хуҗа миңа шушы төбәкнең картасын бүләк итте. Мин исә аңа тәмәкедән өлеш чыгардым.

Безнең сөйләшүдән шул аңлашылды: бу гаилә сугышкача Орел шәһәрендә яшәгән, хуҗа югары мәктәп укытучысы булган. Әмма, сәламәтлеге артык начарланып китү аркасында, врачлар аңа авыл шартларында яшәргә киңәш иткәннәр. Һәм ул үзенең кечкенә генә гаиләсе белән бирегә күчеп килгән, өй салдырып шунда урнашкан.

Хуҗа тирән белемле кеше. Ул татар-башкорт халкын, хәтта аларның кайбер язучыларын да белә. Ул, мине шатландырырга теләп булса кирәк, әгәр безнең якка исән-сау чыга алсагыз, сезгә мотлак ике айлык отпуска бирәчәкләр, диде. Чөнки аның белүенчә, элекке патша армиясендә шулай булган. Әлбәттә, мин аның сүзләренә ышанмадым. Чөнки дошманга әсир төшкән солдатның бездә ничек бәяләнгәнен белмим түгел. Ләкин шулай да бу авыру галимнең сүзләре мине шактый җылытты.

Бу янтыкка сыенган хуторга немец солдатлары бер сугылып киткәннәр икән инде. Хуҗабикә миңа үзенең немец солдатларын очратуын һәм бер солдатның «О, иуда!» дип, үзенә җикеренүен бик борчылып сөйләде.

— Ходаем! — дип куйды хатын. — Нинди яһүдә булыйм ди мин. Әтием священник иде, мин рус кешесе.

Әйе, туган җирләреннән китеп дошман тылында калган бу гаиләнең язмышы бик мөшкел иде. Нәрсә көтә аларны? Тик минем юлымны дәвам иттерүдән башка бернинди дә чарам юк. Сыек кына кәбестә шулпасы белән сыйланганнан соң, киендем дә хуҗаларга исәнлек, иминлек теләп тагы юлымны дәвам иттердем. Хәзер кулда карта булгач, миңа юл шактый ачыкланды. Һәрхәлдә, мин хәзер үземнең кай тирәләрдә икәнлегемне, авылларга сугылмыйча да, чамалый алам.

Һавалар бозыла башлады. Көнбатыштан искән җил көчәйде. Күк йөзендә сәләмә соры болытлар йөзә. Ә мин һаман юлсыз, сукмаксыз барам. Вак куаклар, агачлар, ерак-еракларга сузылган, кайчак ялангач, кайчак агачлы ерымнар, чокырлар аша чыгам. Минем төп максат — көнчыгышка бару. Алда мине ниләр көтәдер, алла белсен! Ә хәзергә минем бердәндер ниятем — үзебезнең якка чыгу. Хәер, дөресен әйткәндә, мине үзебезнең якта ничек каршы алулары әз генә дә борчымый. Бәлки бу үземне тырнак очы кадәр генә дә гаепле санамаудандыр. Мин бары ут сызыгын кичеп, үзебезнең гаскәрләргә кушылу турында гына баш ватам. Төп борчуым шул хәзергә. Белмәссең, бәлки әле миңа үземнең баштан кичкәннәр турында берәр әдәби әсәр, һич югында, истәлек язу мөмкинлеге дә туар бер көн. Ял итеп салкын чирәмдә яткан чакларда шул киләчәкне күз алдыма китереп, татлы хыял канатларында очам.

Берничә көннән соң бөтен өс-башны чылата торган дәвамлы вак, көзге яңгыр ява башлады. Хәзер инде куаклык йә агач ышыгында гына бу үзәккә үткеч пыскак яңгырдан котылып булмый. Шулай күшегеп барган минутларның берсендә, үзем кебек үк көнчыгышка таба юл тотучы сәләмә киемле бер чуаш егетен очраттым. Ул үзен Николай дип таныштты. Инде без икәү. Барулары җиңелрәк, тик каһәр юешлек кенә үзәккә үтә.

Менә без ташландык сукмакка килеп чыктык. Бер-бер артлы барабыз. Икебезнең дә якалар күтәрелгән, куллар җиң очларына тыгылган, икебез дә алҗыган, ач. Ә көн инде караңгылана. Якында авыл-мазар күренми. Менә берзаман сукмак безне тирән чокыр янына китереп чыгарды. Ерымның очы-кырые күренми, ул көнчыгышка таба сузылган, чокырда куе агачлык, ә сукмак һаман ул чокыр буйлап бара да бара.

Эчке күлмәккә кадәр үткән дым тәмам күшектерде. Инде ул, муеннан аркага тамып, бөтен тәнне өшетә. Су җиң очларына керә, кулларны, беләкләрне күшектерә. Киемнәр авырайды, аяк асты тайгак. Ә итекнең авызы ачык, ул шапылдап бара, ичмаса, бәйләп куярга берәр бау кисәге булса иде, аяклар лычма су. Йа ходаем, шул яңгыр астында төне буе барырга язган микәнни безгә?

Бер беребезгә ләм-мим сүз дәшмәстән, көч-хәл белән генә аякларыбызны өстерибез. Озак барабыз. Ичмаса юлыбызда берәр ташландык

шалаш яисә әвен очраса иде! Юк, юк. Караңгы, офык яктысын җирдән аерып күрерлек тә түгел. Уң ягыбыздагы урманчык берзаман бетте, яңгырга көч биреп, ачы җил исә башлады. Хәзер инде безнең хәлләр бөтенләй мөшкелләнде.

Җил-яңгыр һәм ерак ара белән көрәшеп барганда кинәт сул яктан, чокырның теге ягыннан, әтәч кычкырганы ишетелеп китте. Мин Николайга борылдым. Ул да колакларын шәмрәйтеп тукталып калган иде. Менә бәхет! Димәк, чокыр артында гына авыл бар. Без шатлыктан бермәл тынып тукталып тордык. Гәүдәләр тураеп китте, аяклар да җиңеләйде кебек. Менә бу вакыйгага да кырык биш елдан артык вакыт узды, әмма мин бер дә әтәч тавышы ишетүдән туган шатлыклы кичерешемне оныта алмыйм. Әле дә әтәч тавышын ишетү миңа яңгырлы көзге төндә, гаҗизлектә кинәт туган куанычлы бер мизгелне — яшәү дәрте кабызган мизгелне хәтерләтә!

Без чокыр артында гына авыл барлыгын белгәннән соң да, аңа юл таба алмый аптырап байтак вакыт тирән чокыр тирәсендә тулгандык. Ләкин хәзер ничек тә берәр куышка эләгүебезгә ышана идек. Без, ниһаять, тәвәккәлләдек тә сукмактан чыгып, агачлык чытырманына, текә ярлы чокырга төшеп киттек. Мең бәла белән чокыр төбендәге суга бата-чума икенче ярга чыктык. Анысы, безнең бәхеткә, артык текә түгел икән. Өскә күтәрелүгә, без бер кечкенә генә авыл кырыена килеп чыкканыбызны аңладык. Авыл тирән йокыда хәзер, хәтта этләре дә тирән йокыда, бары әтәчләр хоры гына сугыш дип тә, дошман кул астында калу дип тә куркынып тормыйлар, үзләренең күңелле җырларын дәвам итә бирәләр.

— Нишлибез? — дип сорады Николай. Без авыл читендәге өйгә якынлашкан идек инде. Нишләргә кирәклеге мәгълүм инде. Башта үзебезнең хәвефсезлек турында уйларга кирәк. Әгәр немец авылда булса, бер өйгә дә кермичә, берәр әвендә ышыкланып ял итәргә. Ә инде немец юк икән — шушы өйгә кереп, киемнәрне киптереп черем итеп алырга.

Без чокырга караган ян тәрәзә алдында торабыз. Эчтә тычкан уты бар сыман. Батырчылык итеп тәрәзә чиртәм. Куркынып тәрәзәгә капланган ападан немец турында сорашам. Шөкер, әле бу кыргый янтыкка килмәгән ул. Без ападан үзебезне өенә кертүен үтенәбез. Рәхмәт төшсен шәфкатьле апаларга! Ничәмә көн инде мин дошман тылы юлларыннан киләм, бер генә авыл апасының да миңа авыр сүз әйткәнен, ишеген ачмаганын, булган ризыгын өстәлгә куймаганын күргәнем булмады. Аларның күңелләрендә бары кызгану һәм юлчыга ярдәм кулын сузу гына. Гел, гел шулай. Соңыннан дошман тылында калган апаларның чигенүче, чолганыштан чыгучы егетләрне әрләве турында китапларда укырга туры килде. Юк сүз, уйдырма! Мин моңа ышанмыйм!

Без Николай белән җылы коры өйгә кереп өсләребезне салгач, апа безгә икмәк белән дуңгыз мае бирде. Башка нәрсәм юк, пешергән бәрәңгем дә ашалып бетте, диде. Тәүлектән артык авызга ризык заты эләккәне юк иде. Без комсызланып ашарга керештек...

Иртәгесен уянып һавага чыкканда яңгыр тукталган иде. Без мәрхәмәтле рус апасының җылы мич башында йокладык, хәзер кәеф шәп, курыкмыйча тагын атларга була.

Үзебезне сыйлаган ападан соң Николай белән күпме җир узганыбызны хәтерләмим. Аның белән тагын төн кунарга туры килмәде. Алда коллыктан котылып чыгу шатлыгы көтте безне.

Чикне кичү болай булды. Көзге кыска көннең азагы иде. Без, минем гоман буенча, Зуша елгасына якынлашып килергә тиеш. Чирәм баскан тар гына юлдан барабыз. Аның ташландык бер юл икәне күренеп тора. Бу юлга ат тоягы яки адәм аягы күптән басмаган.

Каршыбызга кинәт атка атланган бер кеше килеп чыкты.

— Туктагыз!

Кеше олы бәдәнле, урта яшьләрдә. Өстендә гади кием. Башындагы кубанка бүреге һәм аркасындагы карабины гына аның хәрби эшкә бәйләнештә булуы турында сөйли. Без аның аяк очы турысында тукталдык.

— Сез кемнәр, каян киләсез?

Без кем икәнлегебезне, каян килүебезне әйттек. Ләкин кеше моның белән генә канәгатьләнмәде, бездән документ таләп итте. Без аның ул таләбен дә үтәдек. Ни әйтсәң дә үзебезнең кеше бит ул! Без аны күрүебезгә әйтеп бетергесез шат. Кеше безнең кызылармеец кенәгәләребезне шактый озак игътибар белән тикшерде дә янадан безгә кайтарды. Хәзер инде аның какча, мыеклы йөзендә һәм тавышында мин ниндидер җылылык, үз итүчәнлек тойдым.

— Туп-туры барыгыз, егетләр. Якында гына Зуша, анда перевоз булыр, ә теге якта Залегощ,— диде ул. Каерылып саубуллашкандай артка карап алды.— Карагыз аны, бүген үк райвоенкоматка! Анда дежурный булыр.

Ул шулай диде дә, башка берни әйтмәстән, атын шпоралары белән кыскалап юырттырып китеп тә барды. Безгә тояк һәм «бавыр» тавышы гына бераз вакыт ишетелеп торды. Кем иде ул? Күрәсең, әлегә ут сызыгы читләтеп узган коридор аша дошман тылына юл тоткан берәр партизанмазар иде булса кирәк.

Мин шулай, юлымда бер генә дошман солдатына да тап булмыйча, үзебезнең якка хәвефсез-хәтәрсез килеп чыктым. Мин бәхетле идем.

Кырык беренче елның фаҗигале көзендә дошман тылын кичеп, үзебезнең якка исән-сау чыгучы кеше, әлбәттә, мин генә түгел идем. Аларның саны йөзәрләп кенә дә түгел, хәтта меңәрләп, йөз меңләп булгандыр. Мин моны үзебезнең якка чыккач, җыелу пунктларында белдем.

Ә теге кичне без Зушаны бәләкәй генә көймәдә кичтек. Бу елга сай һәм тар. Көймә янында ук ярга ташланган колга ярдәмендә бу соңгы чик кичелде.

Дошманның бомбага тотуларыннан шактый тетелгән район үзәге Залегощның военкоматын тиз таптык. Өлкән лейтенант безне үз итеп, бик якын күреп каршы алды. Безнең документларны карап чыгу белән, безне тикшерүдән дә бигрәк дошман тылындагы хәлләр, әсирләрнең газаплы кичерешләре турында сораша башлады. Күренеп тора, дошманның якынлашуы, көннәрдән бер көнне биредә дә гарасат булачагы аны бик борчый, шул ук вакытта дошманның ниндиерәк булуы да аны бик кызыксындыра иде. Без күргәннәрне һич арттырмый һәм киметми сөйләп бирдек. Сүздән сүз чыгып, ул монда булып узган вакыйгаларны да сөйләп алды. Истә калганы шул. Бервакыт дошман самолетлары Залегощны бомбага тота. Шулвакыт бер бомба кечкенә генә өй өстенә төшеп шартлый. Өйне, әлбәттә, астын өскә китереп туздыра. Андагы кешеләр һәлак була. Ләкин иртәгесен бу өй хәрәбәсе астыннан бала җылаган тавыш ишетелә. Казып карасалар, кирпечләр астыннан тагарак белән капланган бер күкрәк баласы табыла. Лейтенантның сөйләвенә караганда, бомба шартлаганда мич башындагы бала егылып төшкән һәм аның өстенә шундук мичкә сөялгән тагарак капланган. Шулай бала берүзе исән калган.

Безгә военкоматта озаклап сөйләшергә туры килмәде. Озакламый машина булыр, шунда хәрби частька китәрсез, дигән иде лейтенант. Машина килеп тә җитте.

Минем алдымда үзем сызган схематик карта ята. Мин анда үземнең әсирлектән качу юлымны билгеләп сызарга тырыштым. Әлбәттә, әлеге хутордагы авыру укытучыдан алган карта миндә күптән юк инде. Ул чак сугышның башы гына иде бит. Миңа үз армиябезгә кушылгач, озын-озак сугыш юллары узарга туры килде. Ул карта югалган. Шуңа күрә, бу схема якынча гына, бары хәтер дигән иләктә калган әйберләргә генә нигезләнеп эшләнде.

Әйе, бәлки минем бүген картага төшерелгән юлым якынча гына булмас иде. Сугыштан өйгә кайткач та бер зур ахмаклык эшләдем: үземнең баштан кичкәннәрне әниемә бәйнә-бәйнә язып җибәргән хатымны ертып ташладым. Ни өчен шундый эш эшләнде, монысы турында мин вакыты җиткәч язармын. Ә хәзергә вакыйганың дәвамын хәбәр итим: көзге ачы җилдә, ач килеш йөк машинасында юлга чыгып киттек. Башта Николай белән кабина артына, ышык урынга, утырган идек, тик машина хуҗасы булса кирәк, һәрхәлдә, бик җылы киенгән, каеры тун өстеннән әйбәт брезент яңгырлык кигән, табак битле, кызмача кеше безне ул урыныбыздан кузов идәненә атып кына бәрде.

Әйдә, туңа бирик, без алай да шат. Без бәхетнең җиденче катына менгән кешеләр. Әсирлектән котылдык, үзебезнең якка чыктык. Калганы ничек булса да ил белән!

* * *

«28.11.41 (30/XII алдым)

Сөекле әнием һәм әтием!

Моннан алда берничә көн элек кенә ике хат язып җибәргән булсам да, бәлки ул хатларым барып җитмәгәндер дип, тагын хат язарга утырдым. Үземнең сәламәтләгем яхшы. Йөри торгач, 18 нче запас полкына килеп урнаштым. Әле хәзергә үземнең һөнәрем буенча урнашканым юк. Шулай да вакытлы рәвештә писарь булып эшләп йөрим. Монда килгәндә өс-башымны, хәрби киемнәрне алыштырырга туры килгән иде. Шуңа күрә хәзергә әле кием-салым алмадым, ярым хәрби киемнәрдән йөрим. Ашау мәсьәләсе әкренләп яхшыра. Әгәр мөмкинлек булса, исәбем шушы частьта калу. Үткән вакыт арасында бик күп нәрсәләр күрергә туры килде. Аларның һәммәсен яза башласаң, хатка гына сыйдырып булмас, китап язарга кирәк булыр. Хәер, күргән нәрсәләрнең берсе дә әрәм китмәс. Әдәби хезмәтемдә алар үзләренә урын табар. Тик шуны әйтәсем килә: Молотовның немецләрдәге безнең пленныйлар хәленә карата язган нотасы чын һәм бер дә арттырылмаган. Мин ул хәлләрнең күбесен үз күзләрем белән күрдем, үз башымнан кичердем. Хәзер фашист этләренә карата тирән нәфрәт белән янам.

Бәлки, фашист прикладын, фашист йодрыгын татымаган кеше белми торгандыр. Илне кан, күз яше белән батырып, ут һәм агу белән килүче немең фашистларына алар, бәлки, тыныч кына карыйлардыр. Хәзер мин бу эшне булдыра алмыйм. Әгәр дә исән калып, миңа тагы әдәбият белән шөгыльләнергә туры килсә, бу турыда татар әдәбиятында бик яхшы әсәрләр калдырачакмын.

Сөекле әнием һәм әтием!

Сез минем өчен борчыласыздыр инде. Үзем өчен борчылмыйм, борчылсам да сез борчыла дип кенә борчылам. Дошман кулында, тормыштан өметемне өзеп, ачлыктан көчкә аякларымны өстерәгәндә дә мин һаман сезнең турыда уйладым һәм сез борчыладыр дип борчылдым. Менә шуңа күрә сезгә мөмкин кадәр ешрак хат язарга тырышам. Үземнең котылу шатлыгымны сезнең белән юмарт уртаклашасым килә.

Сөеклеләрем! Минем өчен борчылмагыз. Мин хәзер үз өемдә. Менә күп тә үтмәс, нурлы Казанга кайтып керермен.

Йөзләрегездән үбеп, сезне сагынучы улыгыз: Атилла.

Туганнарга сәлам. Рахман абыйны, Шакир абыйны бик нык кочаклыйм, энекәшләрнең йөзләреннән үбәм».

Ул вакытта илебез котточкыч авыр көннәр кичерә иде. Әле Мәскәү янындагы данлыклы һөҗүм ясалмаган. Армия тетрәнгән бер хәлдә. Ата улны, ана кызны белмәгән чак. Без һаман чигенүдә, без һаман бер шәһәр артыннан икенчесен дошманга калдырабыз. Кайчан тукталырбыз да кайчан чигән тормыштан котылырбыз? Хәрби булып исәпләнүемә

карамастан, миңа корал тотып кына түгел, әле һаман тузган граждански чалбар-күлмәктән, тимерчыбык белән беркетелгән, авызы ачык итектән йөрергә туры килә.

Хәтерем ялгышмаса, мин Залегощтан Задонский исемле шәһәрчеккә эләктем. Анда озак тормастан, безне (без дигәнем — миндәйләр һәм армиягә яңа алынган карт-коры) Елец шәһәренә җибәрделәр. Елецтән без Липецкигә эләктек. Ниһаять, тагын кайлардадыр булганнан соң, мин Моршанскига барып чыктым. Күренгәнчә, без янәшә торган өлкәләр борынча байтак кыдырдык, дөресрәге, чигенә-чигенә урыннарыбызны өзлексез алыштырып торырга мәҗбүр булдык.

Шәһәрдән шәһәргә күченеп йөргән көннәрнең берсендә минем өчен әйтеп бетергесез куанычлы бер очрашу булуы турында язмый кала алмыйм. Бу очрашу Липецкнең Воронеж елгасы аша салынган озын, биек күперендә булды. Безнең ротаны колоннабыз белән Липецкидән башка бер шәһәргә алып баралар иде. Күпергә килеп керү белән, каршыбызга килүче үземнеке кебек үк кыска бишмәтле, колакчын бүрек кигән ялгыз кешегә игътибар иттем. Бу кеше миңа бик таныш тоелды. Бу минем дус Нури Гыйлемханов иде. Шатлыгымнан көлеп җибәрдем. Йә, хода! Бар икән могҗизалар дөньяда, бар икән сөенечле очрашу минутлары! Мин Нурины Болховта югалттым. Аның өчен һаман ут йотып яшәдем. Ул лагерьга эләккәндер, йә булмаса һәлак булгандыр, дигән уй мине өзлексез әрнетеп торды. Ә ул исән, исән! Менә ул минем каршыда. Әлбәттә, мин колоннадан шундук чыктым. Без аның белән күпер киртәсе янында кочаклаштык.

Без шатлыктан өнсез калып, бер-беребезгә карашып торабыз.

— Ашыйсың киләме,— диде ул кинәт. Бишмәт изүеннән зур гына ак икмәк кыерчыгы чыгарды. Мин көлеп җибәрдем.

— Рәхмәт, мин тук.

Ул арада колоннаны алып баручы командирларның берсе «Артка калмаска!» — дип кычкырды.

— Сезне кая алып баралар? — диде Нури. Барасы җиребезне белми идем. Колонна шактый ераклашты. Ул күперне дә узды инде. Мин Нуриның кулын кыстым да алга йөгердем. Без шулай, озаклап сөйләшә алмыйча, аерылышырга мәҗбүр булдык. Ләкин ул исән, ул котылган! Минем өчен иң куанычлысы шул.

Алгарак китеп әйтим. Воронеж күперендә очрашканнан соң Нурины бик озакка югалттым. Кызганычка, аның кайсы авылдан икәнлеген дә хәтеремдә сакламаганмын. Шулай егерме ел чамасы вакыт узды. Нури сугышта һәлак булгандыр инде, дип яшим. Ни әйтсәң дә, ул минем Расих кушаматы белән матбугатта күренгәләвемне без очрашканнан бирле белә бит. Басылган әсәрләрем буенча эзләсә, тапмый калмас иде. Аның әдәбият укый торган кеше икәнлеген беләм. Һич югында төп персонажларның берсе итеп үзе турында язылган «Якташларым» исемле хикәямне укымый калмагандыр. Инде үзе укымаса, укыган таныш-белешләре аңа әйтергә тиеш иде кебек. Ләкин аннан, әйткәнемчә, егерме ел буе диярлек бернинди дә хәбәр булмады.

Шулай, алтмышынчы елларның башында, Арча районында әдәби атналык уздырылды. Без, бер төркем язучылар Арча педучилищесында чыгыш ясадык, тагын башка мәктәпләрдә дә булдык, икенче көнне бөтен төркемебез белән Әтнәгә киттек.

Менә без Әтнәнең мәркәз урамыннан шау-гөр килеп, ашханәдән көндезге аш ашап кунак өенә кайтып киләбез. Инде кайтып җиттек дигәндә, каршыбызга түгәрәк кара сакаллы, бер аягы агач, таза ир килеп чыга. Ул аякларын аерып баскан, үзе юл уртасында тора.

— Әйтегез әле, язучы иптәшләр, сезнең арада Атилла Расих юкмы? Мин тукталып калган иптәшләрдән аерылып алга чыктым.

— Мин ул Расих!

Инвалидка таба атладым һәм хәйран калып ул кешенең Нури Гыйлемханов, минем фронтовик дус кеше икәнлеген белдем. Ходавәндә! Көтмәгәндә, уйламаганда аның белән тагын бер тапкыр, ләкин инде бу туган якта очрашу!

Билгеле инде, мин иптәшләремнән аерылдым. Шундук без Нуриларга киттек. Аның өе шул ук урамга аркылы тыкрыкта гына икән. Менә без ни гомер очрашмаган дуслар аның якты бүлмәсендә, эре-эре төрле җимеш сурәтләре төшерелгән ак клеенкалы өстәл тирәсендә утырабыз. Ул сөйли, мин тыңлыйм. Мин сөйлим, ул тыңлый.

Без Липецк күперендә аерылгач, ул танк частена эләккән. Озак та узмый, ул танкта сугышка керә. Шунда аның танкы шартлый, үзе янган танктан сикереп төшкәч, минага сөртенеп аяксыз кала. Бик озак, елга якын хәрби госпитальләрдә дәвалана. Ниһаять, инвалид таныклыгы алып, сыңар аякта Әтнәгә кайта. Сөлектәй чибәр егет башына төшкән бу фаҗигадән шашып кала, янган йөрәгенә түзә алмыйча, баштарак эчкечелеккә бирелә. Ләкин туганнары, дуслары ярдәме белән бераздан игә килә. Өйләнә, язмышына буйсынып, дөнья куа башлый.

— Онытмадыңмы соң безнең Белевта помидор рассолы эчеп яшәгән көннәрне? — дип сорадым мин. Нури ялт ишеккә күз ташлады, аннан мәгънәле генә итеп имән бармагын авызына аркылы куйды.

— Мин ул көннәр турында, Атилла малай, берәүгә дә әйтмәдем, хәтта хатын да белми аны.

Шулай да ул миңа, ишекне нык итеп ябып килгәч, шыпырт кына үзенең әсирлектән ничек котылуы турында сөйләп бирде. Болховтан киткәч, төн уздыру өчен тукталган урында бер төркем әсирне бер сарайга япкан булалар. Шунда Нури да салам өеме астына кереп яшеренә. Билгеле, яшеренүчеләр ул үзе генә булмый, аның белән тагын ике егет тә шулайрак итеп дошманнан котылырга уйлый. Ләкин аларны немец сизеп ала һәм атып яралый. Тегеләр салам өеменнән чыгарга мәҗбүр булалар. Алай гына да түгел, аларны әсирләр алдына бастырып, яралы булсалар да алда әйтелгәнчә, атып үтерәләр. Әсирләр бу урыннан киткәч, ул бик озак вакыт, немецка күренүдән куркып, шул салам арасында качып ята. Аннан төн уртасында гына чыгып, безнең якка таба юл тота.

Мин артык читкә киттем. Хикәятне элекке эзенә төшерик. Менә мин хәрәкәттәге Өченче армиянең унсигезенче запас полкында хезмәт итәм. Мине, вакытлыча булышырга писарь итеп, өченче батальон штабына алдылар. Мин әле элеккеге киемнәремдә йөрим. Шуның өстенә тунсыз да калдым. Анысы болай булды. Көннәрдән бер көнне, безне җыеп, Моршанскида мунчага алып бардылар. Шунда мин бет җафасыннан тәмам аптырап, эчке киемнәремне генә түгел, әлеге «бәхетле» тунны да кыздыру камерасына бирдем. Тиресе куырылачак бит, диделәр. Куырылмагае, теләсә генә нишләсен, дидем. Үзебезнең якка чыккан көннән бирле бет газабын кичердем мин ул тун белән. Ул паразитны башта, күлмәктәдер, дип уйлаган идем, көннәрдән бер көнне очраклы рәвештә тунымның эчен карасам, егылып китә яздым, йон арасында мыж тегеләр. Менә сиңа «бәхетле» тун!

Әйе, мин инде бер тапкыр үсмер чакта, әле Казанда ялгыз гына яшәгәндә, бетнең нинди хәшәрәт нәрсә икәнлеген үз җилкәмдә татыган идем. Шуңа күрә бу юлы «бет ачуын туннан алып» булса да аннан котылуны бердәнбер чара дип таптым.

Хәтердә, ул көнне һава бик салкын иде. Кырык беренче елның зәмһәрир суыкларын вәгъдә иткән көзге көннәр. Һавада ак «күбәләкләр» оча, каршыга ачы җил исеп тора. Миңа ул көнне дезинфекцион камерадан тун урынына постауга төрелгән бөрек зурлыгындагы бер нәрсә алып бирделәр. Куырылып беткән тирене култык астына кыстырдым, тунның постау тышлыгын өстемә ябындым, шулай итеп мунчадан казармага кадәр күмәкчән диярлек кайттым. Рәхмәт иптәшләргә. Алар мине стройда уртага алдылар, булдыра алганча кыскалап, каккалап-суккалап

җылытырга тырышып алып кайттылар. Хәзер хәйран калам. Яшьлекнең һәм армия тормышындагы киеренке халәтнең үзенчәлеге булгандыр инде. Егерме градус суыкта, мунча кергәннән соң, берничә километр араны күлмәктән генә узып кара әле син! Миңа суыкның сул канаты да кагылмады тагын.

Шулай да тунсызлык үзен бик тиз сиздерде. Элек тунымны идәнгә җәеп йоклый идем. Хәзер инде астымда көрәк зурлыгындагы тире кисәге генә. Аны күкрәк турысына куйсам, бил туңа, аскарак салсам — күкрәк, арка туңа. Алай да ярый, һич югында хәзер мин хәшәрәт бетләрнең үземне талавыннан котылдым.

Күнелем күтәренке. Көннәремне батальон штабында эшләп уздырам, ашаталар, эчертәләр. Кашык юк югын, әмма анысы да бераздан җайланды. Без урнашкан урамдагы өйләр борынча узып, бер кешедән кашык таптым. Тик аны кашык дип тә булмый, ул кырлары шактый кителгән агач чүмеч. Без штабтагы писарьләр (ә без берничә кеше) ашарга утырсак, мин котелоктагы ашны кашыгым белән бер генә чумырам, егетләрнең күзләре шар була. Хәер, монысын мин шаяртып кына әйтәм. Дөресендә, кашык зур булса да, мин беркайчан да авызны зур ачмадым.

Кыскасы, мин хәзер тулы хокуклы кызылармеец, бары обмундирование генә юк.

Көннәрдән бер көнне кулга безнең фронт газетасы килеп эләкте. Газета күрмәгәнгә, кем әйтмешли, биш былтыр. Укый башлагач хәйран калдым. Октябрь бәйрәме көнендә Мәскәүдә парад уздырылган. Кызыл мәйданда Ленин мавзолеенда Сталин үзе речь сөйләгән. Йотлыгып юлбашчының сүзләрен укыйм. Шатлыктан, дулкынланудан күзләремнән яшь бәреп чыга. Әйтерсең лә миңа бик якын, әнием кебек якын кешенең кулы орынды, иркәләп башымнан сыйпады.

Мин күңелем белән күптән инде тиешле хәрби кием һәм корал алу көнен түземсезләнеп көтәм.

Менә ул мин көткән көн, ниһаять, килеп җитте. Миңа рота каптинармусы киемнәр бирә башлады. Күлмәгемнең киярлеге калмаганын күргән штаб башлыгы ярдәмчесе алданрак үзенең иске гимнастеркасын бүләк иткән иде инде. Шуңа өстәп чалбар, шинель, бүрек бирелде. Көннәр артык суык булуына карамастан, ул чакны кышкы киемнәр (тун, киез итек кебек нәрсәләр) юк иде әле. Мин тәтегән кадәресенә дә бик шат. Ичмаса хәзер кеше кызылармеец кыяфәтендә. Бары бер генә җитешсезлек булды. Ул да булса каптеркада миңа яраклы аяк киеме табылмады. Мин әле һаман авызы тимерчыбык белән ябылган итек киеп йөрим.

Бу көннәрдә безнең армия Мценск шәһәре тирәсендә авыр сугышлар алып бара. Сөйләүләренә караганда, дошман яр өстенә, биеккә кунаклаган да, алдындагы Зуша елгасы өстенә барлык ут көчен төбәгән. Андагы һәрбер метр араны пуля чәрдәкли. Ә безнең гаскәрләр әле генә каткан боз өстеннән һөҗүм итеп дошманны ярдан бәреп төшерергә тиешләр. Бернинди артиллерия әзерлеге булмаган хәлдә, бары кул кораллары белән генә. Инде менә ничә рота шунда китмәсен, хәтта арысландай диңгез пехотасы егетләре барып карамасын, берсе берни майтара алмады. Беркем кире кайтмады. Менә шундый хәбәрләр йөри. Ләкин алар барысы да сүз генә. Бер иш кеше сугыш хәлләрен артык куертеп сөйләргә ярата. Менә минем шунда буласым, үз күзләрем белән күрәсем, шул эшкә катнашасым килә.

Шулай да берничә көннән соң марш ротасына эләктем. Ләкин бу юлы да эшем уңмады. Әлеге каһәр суккан итек аркасында стройдан чыгарып калдырдылар. Берничә көннән соң полк каптеркаларына аяк киемнәре килде. Үзем белән бергә күп юллар гизгән итегемне рәхәтләнеп урамга чыгарып ыргыттым. Хәзер минем аякта чолгау, озын ыштыр, тупа ботинка.

Мин тагын алгы сызыкка китәргә тиешле марш ротасы сафында. Фәрман көтәбез. Хәзер озату сүзләрен әйтәчәкләр дә, сулга борып, алгы сызыкка алып китәчәкләр. Хәер, мылтык юк югын, ләкин аны баргач өләшәчәкләр. Төш вакыты күптән түгел генә узган булса да, көн ничектер караңгы. Ишелеп кар ява. Безне кабул итеп алучы командир саф буенча узып карап йөри, безнең торыш-кыяфәтебез, кием-салым белән кызыксына, тикшерә. Кинәт олы начальникларның якынлашуы күренде. Кагыйдә буенча, аларның иң зурысына доклад ясала. Хәзер тагын сүз булырга тиеш. Алар безгә бөтенләй якын ук килеп бастылар. Арадан озын буйлы майор тагын да алгарак чыгып, кулындагы кәгазьдән исемлек укый башлады. Ул берәр фамилия әйткән саен, көтеп, стройга карап тора. Җавап булмый яки саңгырау тавыш белән кайсыдыр: «Ул юк» яки «Кичә китте» дип куя. Майор унлап кеше фамилиясен атады инде. Кинәт үз фамилиямне ишетәм.

— Расулев! Расулев бармы?

Бераз аптырап торганнан соң, бу мин булырга тиеш дип уйлап: «Мин» — дип кычкырам. Исемлектәге иң соңгы кеше булганмын икән. Майор миңа мөрәҗәгать итә.

— Стройдан чык. Минем арттан шагом марш!

Мин сүзсез аңа иярәм. Башымда әллә нинди шикле, шомлы уйлар. Без мәйданчыктан поселок урамына кереп киткәч, майор җилкә аша гына миннән сорап куя.

— Сез зоофак тәмамладыгызмы?

— Әйе.

— Кайда?

— Казанда.

— Моннан соң полкның ветеринария частенда хезмәт итәрсез.

Мин ни әйтергә дә белми өнсез калдым. Минем өчен көенечле дә, сөенечле дә иде бу яңалык. Мин марш ротасына эләккәч, бөтен барлыгымны сугыш атмосферасына көйләгән идем. Бу хәтта бер романтик ашкынуга әверелгән, үзенә күрә миңа канатлар куйган кебек иде. Майорның әйткәннәре ул канатларны бер мизгелдә «кыркып» ташлады. Ә шулай да үз һөнәрем буенча хезмәт итүем армия сафында кирәкле эш түгелмени? Кыскасы, мин тынычландым. Абзагыз бүгеннән башлап ветеринар! Аннан тагын белмәссең, бәлки, ветчастьта хезмәт итү — үземнең гомер буе җенләнгән әдәбиятым белән шөгыльләнү мөмкинлеген дә тудырыр. Язасы әйберләр күп бит, күп...

* * *

«29 декабрь, 1941 ел. (11/I алдым)

Сөекле әнием һәм әтием!

Сезгә башта ялкынлы сәламнәр. Мин исән-сау хезмәт итеп ятам. Хәзер инде бу урыныма бөтенләй ияләштем. Үземне ветеринарный частька күчерделәр. Бернидән дә зарлана алмыйм. Бер шәһәрдән икенчесенә күчеп, һаман Көнбатышка таба барабыз. Әгәр мондый темплар белән киләчәктә дә алга барсак, 2—3 ай да үтмәс, өйгә дә кайтып килермен. Сезне бик сагынам. Туганнарга бик күп сәлам сөйләгез. Йөзләрегездән үбеп: Атилла.

Минем адрес: Действующая Красная армия. Полевая почтовая станция 127. Ветчасть. Расулеву А. К.

P. S. Сезне Яңа ел белән котлыйм, бәхет телим. А.»

Кызыл армиянең Мәскәү янындагы уңышлы һөҗүмнәре безнең күңелләрне күтәреп җибәрде. Һичшиксез, бу башлангыч җиңү көннәрен без зарыгып көткән идек, менә бу килде! Хәзер корыч ташкыныдай безнең гаскәрләр алга барырлар, коллык газабын чигүче авылларны, шәһәрләрне бер-бер артлы азат итәрләр. Моны тоюның рәхәтен без рухи гына

түгел, хәтта физик, тән рәхәте итеп кичерәбез. Димәк, озакламый безнең җиңү белән сугыш тәмамланачак. Бу сәгатьләр якынлаша.

Үзенең кырык градуслы суыклары белән кырык беренче елның кышы килде. Безнең полк, шул исәптән безнең бәләкәй генә ветеринар бүлекчә эзлексез походта. Безне, кече ветфельдшерларны, аерым батальоннарга, атлы подразделениеләргә беркеттеләр. Без юлда атларның сәламәтлеген сакларга тиеш. Ә ат ул сугыш шартларында алыштыргысыз транспорт көче икән. Безнең юллар машиналар йөрүгә көйләнмәгән. Кар көртләренә кереп батучы машиналарны аз күрмәдем. Ат мескен күкрәктән кар ерып барса да, ак күбеккә батса да, үз эшен башкара бирә. Ә инде барырлык җае бер дә калмаса, йөге аның ул кадәр авыр түгел, солдат ярдәме белән тагын кузгалып китә.

Без бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр юлда. Чаналарга утырырга мөмкин булганда да, утырып барудан мәгънә аз. Суык сине тиз арада чанадан өреп төшерә, атлар артыннан тәпиләп бару кулайрак. Олаучылар гына утырып барырга мәҗбүр, чөнки дилбегәне тотмый булмый. Еш кына тукталырга, йә юлдан читкә чыгып машиналарны, танкларны, авыр артиллерияне уздырырга туры килә. Шуңа күрә олаучы солдатлар чаналарда утыра, алар ботинкалары өстеннән нинди дә булса җылы әйбер — йә калын постау, яки сарык тиресе чорнаган булалар.

Каршыга яралы гаскәриләр обозы очрый, димәк, алгы сызыкка якынлашабыз. Тукталган авылларда гаскәр шыгрым тулы, берәр куышка кереп чеңкәер урын тапмый аптырыйсың. Бер авылда шулай мич янына урнашып йоклап ятканда, минем яңакка чәп итеп өстән кирпеч килеп төште! Ул авылга караңгы төшкәч, соң гына килеп кергән идек. Без тукталган авылның өйләре, әйткәнемчә, солдат белән тулы. Мин, ничек туры килде шулай, мич янындагы бәләкәй бушлыкка шинель ташлап яттым, һәм ятып инде йокыга китәм дигәндә генә, әлеге хәерсез кирпеч минем яңакка сикереп төште. Мич башында гырлап йоклаучы солдатларның берәрсе аны тибенеп куптарган булса кирәк. Бу кирпеч вакыйгасының кызыгы шунда, кирпеч шулкадәр җайлы килеп төште, мин яңагымның артык әллә ни авыртуын да сизмәдем. Кирпечне баш астына салдым да шундук тагын йоклап киттем.

«7 январь, 1942 ел. (алдым 19.II )

Сөекле әнием һәм әти!

Иң элек сезгә ялкынлы сәлам. Кичә әнинең открыткасын алып, бүген хат язуны кирәк таптым. Үземдә хәзергә бернинди дә яңалыклар юк. Тормышым бер көе ага. Яңа ел да сизелмичә генә килеп, үтеп тә китте. Морат белән сездән генә хатлар алам. Быковтан, Зиннәттән бернинди хат-фәлән юк. Әдәбият мәхәлләсе дә хәбәр җибәрми. Алар сиңа ышаналар булса кирәк. Югыйсә берничә хатка каршы бер хат кисәге булса да алыр идем. Әле минем хикәяләр басылмаган, күрәсең. Син дә, хәбәр итмисең.

Сезнең күмәк посылканы әле булса тапшырганнары юк. Хәерле булсын. Сез шулай да аны тикшертегез әле.

Әле бу арада бер нәрсә дә яза алганым юк. Вакыт та, илһам да юк. Казанда нинди яңалыклар бар? Хатларыгызны бик кыска һәм бертөрле итеп язасыз. Миңа карамагыз. Сезнең тормыш минекенә караганда вакыйгаларга, хәбәрләргә баерак булырга тиеш. Сезнең исән-саулыгыгызга мин бик шат, ләкин Казан хәбәрләрен дә беләсем килә...

Яңа елны ничек каршы алдыгыз? Без дә күңелле генә итеп каршыладык. Күңелле дигәч тә әллә ни булмады инде. Шулай да 200 грамм аракыны кружкага салып, безнең җиңүебез өчен күтәрдек. Гармун уйнадык, белсәк тә белмәсәк тә сикергәләп алдык. Кыскасы, бер солдат бәйрәме булды.

Академия театры эшлиме? Анда нинди яңалыклар бар? «Кызыл Татарстан»да әдәби әсәрләр басыламы?

Әйе, Татарстанның 100 миллион сум акча бүләк итүенә мин бик шатландым. Сез дә калышмыйсыз икән дигән горур фикер мине шатландырды. Беләсез бит, мин бераз милләтче дә. Ярый, хәзергә җитәр. Сезне сагынучы улыгыз: Атилла.

Йөзләрегездән үбәм. Туган-тумачага һәм якын дусларга сәлам сөйләгез».

Без күп юллар узып, байтак авылларда, шәһәрчекләрдә туктала-туктала алга барганнан соң, Ефремов шәһәрендә озакка урнаштык. Безнең армиянең һөҗүме тукталды, алгы сызык ныклап оборонага әзерләнде, безнең участокта аерым вак сугышлар, аерым бәрелешләр генә була башлады.

Безнең ветчасть шәһәр ветлазаретына урнашты. Аның ватык-сүтекләрен төзәттек, эчен бик әйбәтләп тазарттык, дезинфекцияләдек. Манежга яралы атлар килә башлады. Без манеж белән янәшә, бер түбә астындагы өйдә яшибез. Бераздан өлкән ветфельдшерлар лазаретта калды, кече ветфельшерлар батальоннарга беркетелде. Мине үзем белән озак юллар узган өченче батальонда калдырдылар. Бу батальон исә шәһәр янындагы бер авылга урнашты. Минем бурыч хәзер иртәнге алтыда торып, үземнең батальон атлары янында булу. Өлкән олаучы белән бергәләп аларны эшкә билгеләү, авыруларын калдыру, аларны үземә йә лазаретка җибәреп дәвалау, әгәр кирәк булса, полк тимерчелегенә озатып дагалату, төрле профилактик эшләр башкару.

Ә атлар саны һәрвакыт тиешеннән артык була. Сугыш башлану белән барлык хәрби бүлекләр атсыз берни дә эшләү мөмкин булмаганын яхшы аңладылар. Төрле юллар белән атлар саны һәр җирдә арттырыла башлады, шуңа ияреп, без дә мөмкин булганда алгы сызыктан яраланып килгән атларны үзебездә дәвалап, полкта калдырырга тырышабыз.

Батальондагы эшләр башкарылгач, лазаретка кайтам. Ул шәһәрдән чак кына читтәрәк калку бер урында. Миңа ничек булса да ветеринария белеменең практикасын тизрәк үзләштерергә кирәк. Юллар гизгәндә, дөресен әйтергә кирәк, мин уңайсыз хәлләрдә дә калгалыйм. Институтта терлек физиологиясен дә, аның анатомиясен дә өйрәндем, ветеринария да махсус урта мәктәп программасыннан ким узылмады, ләкин дәвалау, хайванга ярдәм күрсәтү практикасына килгәндә, мин шулай да сай йөзә идем. Атның эче авыртса, сәбәбен ничек тиз генә белергә, нинди ашыгыч чаралар күрергә, ничек җиңел генә итеп атның бөят венасыннан кан алырга, тоякка ничек нык һәм килешле итеп бәйләм ясарга һ. б. һ. б. бик күп гамәли эшләрдә минем тәҗрибәм бик чамалы иде. Димәк, хәзер җиң сызганып шул эшләрне үзләштерергә кирәк. Өйрәнергә, өйрәнергә һич тартынып, оялып тормастан сорашырга, белергә, эштә кул ныгытырга кирәк. Мин өзлексез уку белән эшне бергә алып бардым, һәр процедураны үз кулларым белән башкарырга тырыштым. Рәхмәт аларга, миңа бөтен иптәш булышты. Әйтерсең, алар да үзләре яраткан һөнәрне минем тизрәк үзләштерүемне бик телиләр иде.

Без бик тату яшибез. Кичләрен мич янында чуенда бәрәңгенең пешкәнен көтеп гәпләшәбез. Кече ветфельдшер Николай гармунын кулына алса, моңлы итеп рус, украин көйләрен сузабыз. Фронт хәлләре турында сөйләшәбез, юрыйбыз, роман кылабыз, газеталар укып, шунда язылганнар турында фикер алышабыз. Ниһаять, йоклар вакыт җитә. Мин өстәл янына урнашып, хикәя язарга керешәм. Дәртләнеп, ямып эшлим. Мондый да татлы минутларның булуы мөмкинме соң? Ә иптәшләр йоклый. Мин снаряд гильзасыннан ясалган лампа яктысында эшемнән һаман аерыла алмыйм, язам. Хикәя «Якташларым» дип аталачак. Андагы вакыйгаларга нигез — үзем күргәннәр.

«28/1 — 1942

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сездән бер хат, бер открытка алып, ифрат дәрәҗәдә шатландым. Ул хатлар узган айда, узган елда язылган булуларына карамастан, мин байтак күп вакыйгалар кичергәннән соң алынган беренче хатлар. Шуңа күрә алар мине тынычландырдылар, сезнең исәнлек хәбәрегезне китерделәр. Ул хатларыгызда, тагын бер хат җибәрербез, дигән булсагыз да, мин әле аны һаман алганым юк. Шуны көтәм. Сез зинһар мине борчуга салмыйча, бу хатны алу белән җавап язып җибәрә күрегез. Хатларыгызга ачык һәм тулы итеп языгыз. Үткән (11.XI) хатыгызда, әни, син шәһәрдә яшәмәвең турында язган идең. Мин бит синең кайда эшләвеңне рәтләп белмим. Син кайда эшлисең соң? Ничәнче классларда укытасың? Әти стоматология институтында кем булып эшли? Хатыгызда шуларны да языгыз. Инде үземнең хәлләргә килсәк, миндә исәнлек-саулык. Һаман шул полкта ветфельдшер булып хезмәт итәм. Эшем артык авыр түгел, көннәр ифрат салкын, ләкин миңа алай артык туңарга туры килми. Өстем җылы, ашарга җитә. Күрәсез, минем тормыш бер дә зарланырлык түгел, тик бер нәрсә генә борчый, сездән даими рәвештә хатлар ала алмыйм. Тизрәк дөньялар тынычлансын иде дә, тизрәк өйгә кайтырга булсын иде.

Һәммәгезгә миннән ялкынлы сәлам. Исәнлектә күрешүне теләп, йөзләрегездән үбеп: Атилла.»

Мин кечкенә генә бер авыл өендә яшим. Хуҗа хатыны мич тәүмәле буйчан һәм юан бер апа. Таня атлы. Аның ире исә бәләкәй генә, чандыр гына, кара сакаллы, бик күпне күргән, хәтта беренче Бөтендөнья сугышында немецтә әсирлектә булган кеше. Филипп агай. Ул бик тырыш хуҗалыклы, ләкин шулай да хатынының күзенә генә карап тора. Андый-мондый ярамаган берәр эш кылса, тетя Таня аңа аяк тибеп «Тудыт твою мать!» дип кенә кычкыра. Андый дулаган чакларында тетя Таня миңа карап карты сизмәслек кенә итеп елмаеп күз кыса. Янәсе, ул юрамалый гына.

Филипп агай беренче Бөтендөнья сугышы вакытында Германиядә әсирлектә булган, дигән идем. Хәзер ул немецларның шулкадәр үзгәрүенә шаккатып йөри. Ул күргән немецлар, әйтүенә караганда, бөтенләй башка. Ә инде болары, әле күптән түгел генә Ефремов урамнарында хуҗа булып кукраеп йөргәннәр, һич танырлык түгел. Агайның сөйләвенә караганда, хәзер немец бөтенләй ерткычка әйләнгән. Мәсәлән, шушы өйгә килеп керү белән алар бөтен савыт-сабаны урамга чыгарып атканнар. Агай алар телендә сөйләшеп, никадәр үз кеше булып күренергә тырышмасын, барыбер аны хатыны белән бергә өеннән куып чыгарганнар. Инде килеп, күрәләтә халык алдында бер чал бабайны атып үтергәннәр. Филипп агай тәмам аптырашта, ни булган бу немецка дип шакката.

Агайның үзе үстергән самосад тәмәкесе бик зәһәр. Хуҗа башта хәсиятләп ул тәмәкенең сабакларын өстәлдә бик үткен пычак белән телгәли, аннан нәзек кенә сабакларны кетердәтеп турарга тотына. Усал тәмәкесе белән мине дә еш кына сыйлый. Бу тәмәке үзенә бер төрле сорттыр, ахры. Бу каты тәмәке каршында, безгә паекка бирелә торган махра, фамильный чәй кебек йомшак булып тоела.

Тетя Таня белән Филипп агайлар куышында яшәгән көннәремдә мин күп яздым, күп укыдым. Кичләрен күрше-күләндә яшәүче кызлар кереп тула безгә. Мин аларның портретларын ясыйм. Алардан оккупация көннәрендә күргәннәрен сөйләтәм.

Март башларында безнең башлыгыбыз булган майор лазарет манежында авыру атлар белән маташканда мине чакырып алды да:

— Армиянең Ветотдел начальнигы полковник Зенкевич сезгә хәрби исем бирергә кирәк, — ди. — Сезнең белемегез югары. Минем күзәтүемчә, сез инде хәзер җитәрлек тәҗрибә тупладыгыз. Сезгә кимендә лейтенант дәрәҗәсе бирелергә тиеш.

Әлбәттә, бу минем өчен куанычлы хәбәр иде. Димәк, командование минем хезмәтемнән канәгать. Тик шулай да...

— Бездә лейтенантлар җитәрлек бит, иптәш майор, нигә кирәк аларның санын арттыру?

— Әгәр звание бирсәләр, сезгә бездән китәргә туры килер, бәлки...

Шулай кирәктер, дип уйладым мин. Яңа урында тагын да файдалырак кеше булырмын. Бәлки, тагын да кайнаррак урынга эләгеп, вакыйгалары куерак урында булырмын. Ә ул минем өчен файда гына китерәчәк.

Әйе, анысы шулай, тик әгәр миңа звание бирелеп, мин бу частьтан китсәм, ни әйтсәң дә, бик нык ияләшкән иптәшләрдән аерылу авыр булачак. Миңа ветфельдшерләр Ефимыч та, Коля да, Ксенофонтов та, хәтта менә бу әрсез санитар Захар да жәл булачак. Ләкин мин, киткән хәлдә, алгы сызыкка якынрак булачакмын бит. Бу исә миңа романтик кызыклыгы, хәвефле хәлләрдә тагын бер булып карау ләззәте белән мавыктыра, алгысыта.

Мәгәр миңа бу юрау белән озак азапланырга туры килмәде. Ай урталарында ук майор миңа эшнең барып чыкмаганлыгын аңлатты.

Озын сүзнең кыскасы, мин атлар дәвалаудан тыш, үзем өчен иң изге саналган әдәби хезмәтемә тагын да ныграк, үҗәтләнебрәк керештем. Егетләрдән азрак йокласам да, язуны, башлаган хикәяләремне ташламыйм, аларга чат ябышып ятам.

Арада иң олыбыз Ефимыч миннән көлә. «О-о егет, болай булгач, сиңа орден бирәләр инде»,— ди. Байтак еллар узганнан соң, әдәби хезмәтләрем өчен миңа орден тапшырылганда, мин бу карт ветеринарның сүзләрен көлемсерәп искә алачакмын әле.

Шулай көннәр бер-бер артлы узып тора. Без иртәдән кичкә кадәр атлар арасында. Һәр көн диярлек үзебез төзегән сугым мәйданчыгында кухнялар өчен мал суйдырабыз. Түшкәнең бавырын, бизләрен, эчәкләрен тикшереп, аның ашарга яраклы икәнлеген билгелибез, яңа килгән атларга маллеинизация ясыйбыз һәм башка бик күп ветеринария чаралары уздырабыз. Ә кичләрен лазаретта гәп сугып утырабыз, Колядан гармун уйнатабыз яки кычкырып, яңа килгән газет укыйбыз. Безне аерата Эренбургның фейерверктай дөрләп, чытырдап, утлар чәчтереп, янган мәкаләләре дәртләндерә. Без бервакыт шулай ук бергәләп фикер алыша-алыша Корнейчукның «Фронт» исемле пьесасын укыдык.

Тиздән безгә тагын дислокацияне алыштырырга, яңа урынга күчәргә туры килде. Без, йөри торгач, ниһаять, җәй урталарында гына Тула шәһәренә якын Скуратова станциясе тирәсендәге Сабатеево исемле бер авылга барып урнаштык. Безнең армия күптән оборонада. Алга китү сизелми. Киресенчә, дошман активлыгын көннән-көн арттыра гына бара. Идел буйларыннан күңелсез хәбәрләр ишетелә. Дошман Сталинградка һөҗүм итә, Кырым ярыматавында, Воронеж якларында без уңышсызлыкка очраганбыз. Безнең өстә дә хәзер фашист үзен лачектер артык һавалы тота башлады. Төннәрен, бөтен тирә-якны көндезгедәй яктыртып, күккә ракеталар аса һәм узловой саналган Скуратова станциясен бомбага тота. Күктә самолетлар улый, прожекторларның яктылык тасмалары чайкала, кырлар, агачлыклар өстен кызыл, яшел, зәңгәр пунктирлар белән чуарлап трасса ясаучы пулялар сибелә башлый. Без андый минутларда йөгереп урамга ташланабыз, шомланып, тетрәнеп авыр бомбалар ярылуын күзәтәбез, дошманга ләгънәтләр укыйбыз. Әйе, бомбага тоту дигән әйбергә кеше беркайчан да күнегә алмый. Менә ничә тапкыр инде күктә дошман очкычлары улый. Менә ничә тапкыр инде дошман бомбалары җир шарын ярып җибәрердәй гөрселдәп шартлыйлар, күккә туфрак, таш, йомычка фонтаннары күтәрелә. Ләкин һәрвакыт күңелдә дәһшәт һәм тәннең оеп, катып калуы кичерелә. Мин бу халәтне беренче тапкыр сугыш башында ук, Орел станциясенә фронт өчен хәрби кием озата барганда кичергән идем. Истә калганнарыннан тагы Еф-

ремов шәһәрендә дошман самолетларының станциядәге пассажир поездлары өстенә бомба ташлавы булды. Анда, дошман очкычлары киткәннән соң, перрон тулы мәет ята иде. Хатын-кыз, балалар, карчыклар...

«22.06.42 (алдым 4/VII).

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезгә башта үземнең ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Үзем исәнсау. Бернинди дә әйтерлек яңалыкларым булмаса да, бәлки, хатыма җавап килер дип язам. Сезнең 5 майдан соң бер хатыгыз да юк. Сез исәнме, ни өчен хатларыгыз килми?

Без урыныбызны үзгәрттек, ләкин шуңа карамастан, иптәшләргә хат килеп торды. Тормышымда бер үзгәреш тә юк. Әкрен-әкрен мин чын ат докторы булып киләм...

Исәнлектә күрешүне теләп, сезне сагынучы улыгыз: Атилла.»

Безнең Сабатеевка авылында яшәү бик озакка сузылды. Чарлаксыз, яссы түбәле бер кирпеч өйдә торабыз. Бернинди каралты-кура кебек нәрсә юк. Өйнең эчке өлеше иркен бер бүлмәдән гыйбарәт. Идәне җир. Күрәсең, мондый идән бу яклар өчен табигый бер нәрсәдер. Без, кече фельдшерлар, санитар Захар һәм тимерче Герасим шунда бергә яшибез. Немец бу авылда булган инде. Алар да шушы өйдә озын өстәл тирәсендә утыра торган булганнар. Идәнгә салам түшәп йоклаганнар. Хуҗа хатынның җиткән өч кызы бар. Алар берсеннән-берсе чибәр, көләч нәрсәләр. Дошман килеп кергәч, немец солдатларының үзләренә күзләрен майландырып карый башлауларын сизгәч, кызлар өйдән чыгып сызганнар. Дошманны үзләренә каратмас өчен чәч тарамаганнар, өсләренә искемоскы кигәннәр, битләрен юмыйча, пычрак килеш йөргәннәр. Немецның да эшләре алай мактанырлык булмаган, күрәсең. Алар, һәр көнне кичке аштан соң, анадан тума шәрә калып өстәл тирәсендә бет багалар икән. Моны безгә хуҗабикә сөйли.

Безнең майорны дивизиягә җибәрделәр. Аның урнына тамбовлы Покровский дигән врач килде. Ул да майор. Әмма әз генә дә безнең элекке башлыкка охшамый. Эре сөякле, зур корсаклы, ап-ак чәчле сүлпән бер кеше. Чын мәгънәсендә борынгы интеллигентның коеп куйган бер типажы. Берәүгә дә каты эндәшмәс, ашыгучанлыкның, кабаланунын кан дошманы. Бик шәфкатьле һәм сабыр кеше. Килү белән ул миңа старшиналык вазыйфасы йөкләде. Тимерчеләр курсы ачылу белән, миңа тояк анатомиясе һәм физиологиясеннән курста дәрес алып баруны тапшырды. Уйлавымча, ул минем белән генә аераʼта якын бер сердәш иде. Безнең командованиенең сугыш башындагы зур ялгышларын, гомумән, безнең «на урра» эш итәргә яратуыбызны һич яшермичә хурлый. Минем әдәбият белән кызыксынуымны белгәч, ул бик аптырады. Бүгенге шартларда әдәбият һәм сәнгать кебек нәфис нәрсәләрнең яшәве мөмкин түгел аныңча.

«27.09.42 (7/X алдым)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Миндә исән-саулык. Бернинди дә яңалык юк. Әни, синең открыткаңны һәм 16 сында язган хатыңны алдым. Гоганың адресы табылуына мин бик шат. Адрес кулга төшү белән мин хат язып салдым. Моратның хатлары тәртипле рәвештә килеп тора. Аның хатыны — Наилә исемле бер татар кызы икән. Морат белән бергә укыган, хәзер Байкал артында госпитальдә хезмәт итә. Моратның язуына караганда, минем аны күргәнем бар икән.

Өченче көн «С. Ә.»тына хикәяне төгәлләп җибәрдем. Нәрсә килеп чыккандыр инде. Имаметдиневкә дә, Гумеровка да хатлар яздым, хикәям турында редакция фикерен язуларын үтендем.

Рахман һәм Мөхәммәт абыйларга хатлар язган идем. Алмаганнардыр. Җавап юк. Моннан атна-ун көн элек сезгә 500 сум акча салган идем.

Ул да барып җитмәгән ахры. Монда көннәр, сентябрь уртасына кадәр начар булып торганнан соң, яхшырды. Хәтта эссе булып китте. Көз быел соң килергә тиеш.

Мин үткән хатымда Зиннәт турында сораган идем. Синең аларга барырга вакытың юктыр шул. Ярар инде. Җибәргән кәгазеңне алдым. Аны син җибәргәнсең икән. Мин ул кәгазь редакциядәндер дип, аларга рәхмәт укып хат язам тагын. Җибәргән рәхмәтемне, аларның берәрсен очратсаң, кире ал. Ул рәхмәт сиңа тиеш, әни.

Минем өчен борчылмагыз, мин үземне яхшы хис итәм.

Сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: Атилла».

«8.11.42. (алдым 26/11)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезгә ялкынлы сәламнәрдән соң бәйрәм тәбрикләре җибәрәм. Синең хатларыңны, әни, тәртипле рәвештә алып торам. Ф. Хөснидән, Зиннәттән хатлар алдым. Фатих, «Яклашларым» ошады, октябрь номерына җибәрергә уйлыйбыз, дип яза. Зиннәтнең сеңелесе Фатыйма үлгән икән. Бүген аның да кайгысын уртаклашып хат яздым.

Тормышымда бернинди үзгәреш юк. Казанга тагын бер хикәя җибәрдем. Анысына ни әйтерләр тагын? Син очратсаң, сорашырга онытма...

Шулай буш вакытларда язгалый алам. Бу эш миңа кыйммәткә төшсә дә, зур канәгатьләнү хисе тудыра. Язган хикәям менә шушындый кәгазьдә 83 битле булып чыкты. Язган темам таныш булганга күрә, җиңел язылды. Әгәр басылса, укырга вакыт табыгыз. Аннан гонорар турында... Хикәя басылып чыккач та («Якташларым») сез миңа хәбәр итегез, мин сезгә доверенность җибәрермен. Ә хәзергә җибәрмим әле, чөнки кем белә аны, хикәянең язмышын анык белми торып, мәшәкатьләнү урынсыз.

Йөзләрегездән үбәм, ялкынлы сәлам белән: Атилла.»

* * *

Менә 1942 ел да узып бара. Көн дә без үзебезнең участоктагы хәлләр турында, алгы сызыктагы яңалыклар турында ишетеп торабыз, анда урыны-урыны белән бәрелешләр, разведка рейдлары булып тора. Сталинград якларыннан исә безгә хәвефле, шомлы хәбәрләр ишетелә. Алар безнең ярсу күңелләрне авыртыралар, рәнҗетәләр. Без һәр көн иртәнге алтыдан торып атлар янына чыгабыз. Авыру атларга термометрия уздырабыз, яраларына операция ясыйбыз, дәвалыйбыз.

Мин хәзер һәр буш минутымны дигәндәй язуга бирәм. «Якташларым» исемле хикәям турында Казаннан җылы хәбәрләр алу мине ифрат өметләндерде. «Ютазы егете» исемендәге хикәягә керештем. Мин анда фашистларга булган нәфрәтемне бүлдыра алганча тәэсирле итеп язачакмын. Хикәя укучыны көйдереп алырга тиеш. Фашизмның нинди афәт, нинди дошман икәнлеген әйтәчәкмен.

Ул кечкенә повестемны, чыннан да, дулкынланып, янып, тетрәнеп яздым. Алгарак китеп әйтим, ул әсәр журналда басылса да, соңыннан минем бернинди җыентыгыма кермәде. Күрәсең, башка хикәяләрдән кайтыш булып чыккандыр.

Әйе, язучы күргәннәренә битараф булырга тиеш түгел, авыр кичерергә, гаделсезлек өчен чын мәгънәсендә ут йотарга, янарга тиеш, әмма ул тойгыларын укучысына җиткерү өчен ак кәгазь өстенә иелгәч, һәрбер деталь өстендә тыныч кына уйланып эш итсен. Чөнки нәфис әдәбият ул — сәнгать әсәре, аны кылыч болгап тудыру мөмкин түгел.

«20.1.43. (6.II.43 алдым)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезгә башта ялкынлы сәлам. Үземдә исән-саулык. Бер дә алай әйтерлек яңалыкларым юк. Сез җибәргән посылка әле килеп җитмәде.

Әнинең 31 ендә язган открыткасын алдым. Әни яңа елны каршы ала алмаган икән. Дежур булып уздырган. Мораттан тәртипле рәвештә хатлар алам. А. Гомәр аркылы җибәргән кәгазь исән-сау килеп җитте. Тик бу арада язарга гына вакыт юк. Шәриф Камал үлгән икән. Чын реалист, зур язучы булуы өстенә, бик яхшы кеше дә иде. Әрәм булган мәрхүм. Таҗи Гыйззәттән хат алдым. Ул минем хикәятне укый алмаган әле. Иптәшләр яхшы фикердә. «Совет әдәбияты»нда басылачак, дип яза.
Башка хәбәрләрем юк. Йөзләрегездән үбеп: Атилла».

«7.02.43 (17/2 алдым)
Иң элек йөзләрегездән үбеп, ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Әнинең 21 январьда язган хатын кичә алып, сезнең тормышыгызны тулы рәвештә күз алдыма китереп бастырдым. Әни авыру булса да минем өчен бик мәшәкатьләнгән икән. Үткән хатым начар кәеф белән язылган иде. Сезне юк-бар нәрсәләр белән борчуым өчен гафу үтенәм. Үземдә бернинди дә яңалык юк. Көннәр сизелмәстән узып торалар. Кәефем яхшы. Син, әни, кайсыдыр бер хатыңда, туңмыйсыңмы, дип сорыйсың. Юк, әни, өстемдәге киемнәр бик җылы минем. Аннан эшем дә алай туңып-өшеп башкарыла торган түгел. Китап-газеталар укырга да вакытым юк түгел. Иптәшләрем бик яхшы кешеләр. Аз булгангадыр инде, без бертуганнар кебек дус, тату яшибез. Мин бу тормышымны кырык беренче елны кичергәннәрем өчен бер мәкяфәттер дип уйлыйм. Тормыш бит ул һәрвакыт начардан тормый, кайчак яхшысы да булып куя.
Әни, син соңгы хатларыңда, акча җибәрмә, дип язасың. Менә январь аенда акча сала алмадым. Ләкин синең киңәшеңә карап түгел, ачуланма, акчаны танклар колоннасы төзүгә бирдем. Ә киләчәктә булган акчаны сезгә җибәреп торачакмын. Чөнки аның миңа бөтенләй кирәге юк. Дәүләт минем көнкүрешемне тулысынча үз өстенә алган. Аның биргән акчасы сезгә җибәрү өчен генә дип беләм.
Әни, син, зинһар өчен, үзеңне сакла. Синең сәламәтлегең — минем шатлыгым. Әгәр мине шат, бәхетле итәсең килсә, минем бу киңәшемне тыңла. Күп калмады инде. Безнең өчен һәм башка миллионнар өчен булган җиңү туеның шатлыклы музыкасы ишетелә башлады.
Атилла».

«14.02.43 (алдым 15/III)
Сөеклеләрем әни һәм әти!
Кичә сез җибәргән посылканы алып, сезнең үзегезне күргән кебек булдым. Кичә бер яхшы иптәшем белән (мин шуның белән торам) кичкенә генә бәйрәм ясап алдык.
Ул иптәш әлегә азат ителмәгән яктан, аңа хат та, хәбәр дә җибәрүче юк. Минем турыда сөйлисе дә юк, ул да бик шатланды. Яхшы консерваны ачып җибәрдек, кичкенәнең бөкесен һавага очырып сезнең сәламәтлек өчен калай кружкаларны чәкештердек. Кыскасы, бик рәхмәт. Барыннан бигрәк төш яхшы барып чыккан. Андый сыйларны татымаганга бик күп вакытлар үтте бит инде. Аннан янчык та бик зәһәр икән. Аны кем әмәлләде?
Йөзләрегездән үбеп, сәлам белән: Атилла.»
Хатлар минем зур юанычым. Әнием бер вакытта да хат язарга иренми. Мин аның бу гүзәл гадәтен кече яшьтән үк беләм. Күрәсең, бу гадәт аның ифрат туган җанлы кеше булуыннан киләдер. Ул гомер буе апаларына, абыйларына, ахирәтләренә, хәтта ерак туганнарына хат язып торды. Әти исә хат язу мәсьәләсендә әнием белән ярышырлык кеше түгел. Әти озак-озак вакытлар бездән аерылып торды. Андый чакларда да хатларын артык еш язмады. Мин армиягә алынгач, миңа да сирәк кенә язгалады. Аның каравы әниләргә дә, дус ишкә дә, яңа гына аралаша башлаган әдәбиятчы танышларыма да хатны һич авырсынмыйча язам. Аның бәрабәренә минем почтам хәзер (әлбәттә, фронт, сугыш шарт-

ларын искә алып) бер кайчан да буш булмый. Мин рәхәтләнеп кулыма әле генә килгән хат алам. Ләззәтләнеп, кызыксынып укырга керешәм. Бу күпвакыт мине дәртләндерә, миңа яңа көч-куәт өсти.

Бер хатта әни минем өчен бик кызыклы хәбәр язган. Кызыклыгы аның шунда: Мөхәммәт абый әнигә: «Атилла нигә Язучылар союзына керергә гариза язып җибәрми?» — дигән. Ул үзе хәзер Литфонд директоры икән, әгәр Атилла союз члены булса, сезгә материаль ярдәм дә күрсәтеп булыр иде, дип өстәгән. Хаттагы бу сүзләргә мин башта артык әһәмият бирмәдем. Ләкин уйлана торгач, шулай да Казанга үтенеч язып җибәрергә булдым. Бу вакытта минем журналда «Якташларым» атлы озын хикәям басылып чыккан, «Ютазы егете» исемле кечкенә повестем, ишетүемчә, «Совет әдәбияты» редакциясе тарафыннан басарга кабул ителгән иде.

«11.03.43 (31/3 алдым)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Иң элек сезгә кайнар сәлам. Әнинең 17 сендә, әтинең 19 нчы февральдә язган хатларын инде яңа урынга килгәч кенә алдым. Исән-сау, тырышып-тырмашып яшәвегезгә мин шат. Үземнең шәхси тормышымда бер дә ул-бу яңалыклар юк. Элекке урнымда иске хезмәтемне үтим. Әни дә, әти дә Мөхәммәт абыйның киңәше турында язасыз. Белмим, юкка җилкенү булырмы, мин А. Гомәргә хат һәм үтенечемне җибәрдем.

Һавалар бездә шактый җылынды. Күк йөзе болытлар белән капланган, ләкин шулай да яз үзен сиздерә инде.

Ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп: Атилла.»

Бераздан без төпләнгән урыныбыздан тагын кузгалып киттек. Ияләшкән урын белән саубуллашу авыр булса да, безнең алгы позициядәгеләр Көнбатышка уңышлы бара башлаганга күрә, дислокация алыштыруыбыз шатлыклы бер вакыйга булып тоелды. Ул көннәрдә армиябез тоткан ут сызыгы буйлап байтак вакыт кыдырдык. Азат ителгән авылларда булдык, инде бер урында төпләндек дигәндә генә, тагын чигенергә туры килде. Аннары тагын алга юл тоттык. Ниһаять, кышкы авыр юлларны байтак гизгәннән соң, яңадан үзебез бик озак яшәгән Сабатеевкага кайтып егылдык. Бу авыл, андагы кешеләр безнең якын танышларыбыз булып бетсәләр дә, яңадан бирегә әйләнеп кайтуыбыз әйбәт фал түгел иде.

Тула шәһәреннән Сабатеевкага чана тартып кием-салымга ашамлык алыштырырга килүчеләр элек тә еш күренгәләде. Хәзер алар тагын да ешая төшкән. Узган җәйне колхозның кыр эшләрендә булышу өчен Туладан бер төркем кыз-кыркын да килгән иде. Безнең егетләр алар белән дуслашып, соңыннан хатлар алыша башладылар. Коля да бер кыз белән дуслашып алган иде. Инде ул кызының тагын Сабатеевага килеп чыгуын көтеп яши.

Мин, полк музыкантлары белән танышып, бер иске скрипка табып кайттым. Хәзер безнең эшләр мантый. Без кичләрен парлашып әйтерәбез. Коля — гармунда, мин — скрипкада.

Сергей исемле егетебез яз башында ук госпитальгә китте. Соңыннан аның армиядән бөтенләй азат ителгәнлеген, өенә кайтарып җибәргәнлекләрен ишеттек. Үпкә чире.

Көннәрдән бер көнне майор Покровский миңа: «Сезне армия Ветотделына чакырдылар», — диде. Мин, бәлки, академия мәсьәләсе кузгалгандыр, дип уйладым. Тик алай түгел икән. Безнең начальникка, берәр белемле кешегезне безгә еллык отчет төзүдә булышу өчен җибәрегез әле, дигәннәр икән. Киттем. Мине Захар Осипович илтә барды. Атларымнан, ияләшкән эшемнән аерылаcы килми килүен, тик шул ук вакытта бу командировка бер җилләнеп кайту да бит әле. Анысы начар түгел.

Армиянең тылдагы бүлекләре урнашкан авылга барып керү белән Ветотделны табып, начветарм янына кердем. Үкчәне үкчәгә бәреп, честь

биреп доклад ясыйм. Тәксерәк йөзле, буйчан бер белорус икән полковник Зенкевич. Ул мине өстәл артында утырган килеш тыңлый да, хәзер үк ярдәмчеләре янына, күрше бүлмәгә кереп эшкә керешергә куша. Мин аның әйткәнен үтим. Ярдәмчеләре икәү. Икесе дә майор. Берсе белорус, Сабуров фамилияле. Миңа шуның белән эш итәргә туры киләчәк. Эш шуннан гыйбарәт: ашыгыч рәвештә дивизияләрдән җыелган материалны тәртипкә китереп, мәгълүм форма буенча фронт штабына отчет эшләп җибәрергә кирәк. Вакыт чикле, шуңа күрә хәзергә йокыны онытып торырга туры килә. Башта майор Сабуров минем белән салкынрак мөгамәләдә булды. Ләкин, бергәләп эшли торгач, без бөтенләй дуслаштык. Чиннар, дәрәҗәләр онытылды. Төннәр буе йокламыйча эшлибез. Отчет дигәне, сугыш шартлары булуына карамастан, әллә ничә йөз графадан тора. Безнең каралама — бөтен өстәлне каплап алган җәймәдәй зур кәгазь. Без аны җилем белән ябыштырып ясадык. Күзләр йомыла башлаганчы эшләп, исәпләп утырабыз, ичмаса арифмометр да юк, бары счет. Үтереп йокы килә башласа, берәр чәркә спирт эчеп җибәрәбез. Хикмәти хода, мин моңарчы алкогольне йоклата торган эчемлек дип белә идем, бу очракта киресенчә булып чыкты. Йокы кача да без тагын эшкә керешәбез.

Майор бик чибәр кеше. Дулкынланып торган саргылт чәчле, ак йөзле, бөтен җире килешле. Ул минем белән тиешеннән артыграк нәзакәтле булырга тырыша кебек. Хәлбуки, аның тупаслыгы, дорфалыгы турында дивизиядән килгән бер егетнең миңа зарланып сөйләгәне булды. Ул дөресен сөйли иде. Әйе, дуамал командирлар һәм аларның һавалы ППЖлары турында да ишетергә, хәтта үзләрен күрергә дә туры килде. Алар, сирәк кенә булса да, армиядә очраштыргалый. Әмма андый ППЖларның булуы безнең армиябездә үзләре теләп хезмәт иткән хатын-кызларга тырнак очы кадәр дә тап төшерми. Армия сафларында хатын-кызлар героик эшләр башкарды.

Майор Сабуров миңа карата бик әйбәт мөнәсәбәттә булды. Без аның белән төннәребезне йокысыз үткәреп булса да, отчетны тиешле вакытка өлгерттек. Полковник эшебездән бик разый булды кебек.

Бер-бер артлы, хат арты хат күчереп, аларны әсәремә керткәннән соң, мин тукталып, тирә-юнемә һәм югарырак карарга да, офыгымны киңәйтә төшәргә кирәктер дип уйлыйм. Алдарак әйткәнемчә, мин кырык беренче елның көз азакларыннан бирле Өченче армиядә хезмәт итәм. Безнең армия моңарчы алгы сызыкта әллә ни активлык күрсәтә алмады. Кыскасы, язар өчен куанычлы, саллы вакыйгаларга бай булмады. Хәзер бик зур вакыйгалар алдында тора безнең армия. Бу ачык сизелә. Хәрби юллардагы җанлылык, андагы корал һәм техниканың өзлексез агыла башлавы, армия штабындагы аерым частьлардагы күтәренкелек, алгысыну билгеләре күзгә бик ачык булып ташлана.

Инде мин хезмәт иткән бүлекчәнең генә түгел, гомумән, безнең Өченче армиянең сугышчан хезмәтләре турында да яза башларга ярыйдыр. Мин бу эштә үзем күргән, үзем ишеткән, инде соңрак укыган истәлекләргә таяначакмын. Минемчә, бу укучыга шактый кызык һәм гыйбрәтле тоелыр дип уйлыйм. Чөнки, киңрәк даирәне күздә тотып язганда гына, Бөек Ватан сугышының искиткеч гигант яу хезмәте икәнлеген, дәһшәтле һәм сөенечле олы вакыйгалардан торганлыгын күз алдына китерергә мөмкин.

Безнең Өченче армия элек Үзәк фронтка керә иде. Соңгы вакытта ул Брянский фронты буйсынуына күчте. Хәзер безнең армия фронтының киңлеге алтмыш бер километр. Безнең армия алдында дошман тарафыннан бик нык ныгытылган Орел, Белхов, Мценск һәм Карачев шәһәрләре тора. Фашист аларның әйләнә тирәсен оборонага яраштырып егерме ай буе ныгытты.

Безнең армиядә барлыгы алты дивизия, шуларның өчесе алгы сызыкта. Ә калган өч укчы дивизия, Кырык беренче корпус дивизияләре, күршебез Алтмыш өченче армия артына сыенган.

Безнең армиянең командующие, белүемчә, моңарчы Корзун фамилияле генерал иде. Кырык өченче елның җәй урталарында аны генерал-лейтенант Александр Васильевич Горбатов алыштырды. Ул — утлар, сулар кичкән хәрби башлык. Беренче империалистик сугышта катнашкан, Гражданнар сугышында командир булып аклар белән сугышкан тәҗрибәле, батыр генерал. 1937 елда репрессиягә эләгеп, төрмәдә дә утырып чыккан. Аның безнең армиягә килүен хәрби бүлекләр шатланып каршылады. Һәм ул, чыннан да, әле алда күренәчәк сугышчан хезмәтләре белән үзенең данын аклады, соңыннан Советлар Союзы Герое дигән исем алды. Сугыш беткәнче безнең Өченче армия башында шул булды. Генерал Берзарин вафатыннан соң Берлин шәһәренең комендаты булып билгеләнде...

«22.06.43 (6/7 алдым)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Җибәргән хатларыгызны һәм журналны алдым. Бик зур рәхмәт. Журнал укыгач та илһамланып киттем. Моңа кадәр Әпсәләмнән бер хат алган идем. Аңа хат яздым. Җавап юк әле. Үземдә исән-саулык. Хәзергә ул-бу үзгәрешләр күренми. Үткән хатларымның берсендә академия турында язган идем. Әйткән сүз — эшләнәчәк эш. Хәзер минем укырга китүем вакытка гына бәйләнгән. Мине укырга җибәрергә дип, безнең армиянең иң зур начальниклары тиеш таптылар, кандидат итеп билгеләделәр. Укырга китә алсам, моның өчен сез дә шатланырсыз дип уйлыйм. Чөнки укып, үземне илгә күбрәк файда китерүче итеп әзерлим. Моңарчы ярты егәрлеккә генә хезмәт иттем сыман. Җитәр инде, ил миңа зуррак эш йөкләп, миннән күбрәк эшләр таләп итәргә хаклы. Бу минем матди, рухи, әдәби тормышымда һәм барыннан да битәр сезнең матди тормышыгызга өз генә дә комачау ясамаячак. Киресенчә, ярдәм итәр дип уйлыйм.

Сагынып, ялкынлы сәлам белән: Атилла.»

Язучылар белән хат алышу турында сүз кузгалгач, мин Төньяк фронтта хезмәт иткән Габдрахман Әпсәләмовны искә алмый булдыра алмыйм. «Совет әдәбияты» журналының кайсыдыр бер санын укыганда мин бу яшь язучының госпитальдә язган истәлекләрен күрдем. Мин аңарчы Әпсәләмовны шәхсән белми идем. Аның фронттагы кичерешләрен укыганнан соң, күрәсең, үземнең баштан да шактый хәлләр узганга күрәдер, мин Габдрахманны ифрат якын иттем. Аның белән бәйләнешкә керәсем, язышасым килде. Казанга Абдулла Гомәревкә Әпсәләмовнең адресын сорап хат яздым. Куанычка каршы, озакламый адрес килде. Мин шул ук көнне Габдрахманга хат язып җибәрдем.

Көннәрдән бер көнне Әпсәләмовтан миңа хат килеп төшүе үзенә күрә бер бәйрәм булды. Без шул көннән башлап аның белән даими рәвештә хатлар алыша башладык. Басылып чыккан хикәяләребез турында хат аша фикер уртаклаша торган булдык. Бу эш шулай сугыш беткәнгә кадәр дәвам итте. Архивымда әле дә егермеләп хаты саклана.

Хәзер инде мине армия Ветотделына квартал отчетлары төзешер өчен дә чакырталар. Полковник үзе дә миңа карата шактый җылыиды, кайчагында минем белән җиңелчә шаяртып сөйләшкәләүне дә үзенә рөхсәт итә башлады. Минем академиягә укырга киту-китмәү мәсьәләсе дә шушы көннәрдә хәл кылынды. Мине җибәрмиләр... Хәерле булсын. Мин ни эшли алам. Бу турыда артык сүз дә кузгалмады, ул шулай сүнде.

Елның беренче квартал отчетын төзегәндә миңа Ветотделда аерата нык эшләргә туры килде. Полковникның ярдәмчеләре әледән-әле дивизияләргә, полк һәм аерым атлы подразделениеләргә киткәләп торалар. Алар минем белән кайткан арада гына очрашалар, миңа ниләр эшләргә кирәклеген әйтәләр, һәм тагын китеп баралар. Ниһаять, мин аларның шундый өзек-өзек ярдәме белән квартал отчетын очлап чыктым. Ветот-

делның ирекле машинисткасы кара чутыр Мария Ивановна отчетны машинкада басты, полковник карап чыккач, кул куйды.

— Ярый, әйбәт булган,— диде полковник. Бик җитди генә итеп миңа текәлде.— Моның өчен сиңа награда бирергә була.

Мин рәхмәт әйттем һәм, наградадан бигрәк, мин өйгә кайтып килүгә бик мохтаҗ, дидем. Чөнки бу көннәрдә әнием больницада ята, аның язмышы өчен бик-бик хафалана идем. Шуларны полковникка әйттем. Ул миңа карап бераз уйланганнан соң:

— Полк командирыңа рапорт яз, әниеңнән килгән хатны шуңа теркә,— диде,— мин үзем аңа шалтыратырмын.

Мин көтмәгәндә мондый вәгъдәгә ирешүемә әйтеп бетергесез шат идем, частька кайту белән полковникның киңәшен башкардым. Һәм менә бер көнне миңа Казанга предписание бирелде. Азык-төлек складыннан капчык тутырып ашамлык алдым, документларны тиз генә әмәлләделәр. Июль иртәләреннән берсе иде. Егетләр белән саубуллашып, Скуратова станциясенә киттем. Ә Көнбатышта ул көнне бөтен офык буйлап туплар канонадасы гөрселдәде. Ул бер генә секундка да тынмый. Бу көнне безнең гаскәрләр тарихи Курск дугасы һөҗүменә кучкәннәр иде.

Менә мин Казаныма, өч елдан бирле төшләремдә күреп яшәгән Казаныма кайтам. Мин чиксез шат, бәхетле, күңелем ашкына, алгысына. Уенмыни, үлем үкчәгә басып йөргәннән соң, тагын кадерле кешеләрең янына исән-сау кунакка кайт әле?!

Мин өйдә беренче көнне әнием һәм әтием янында уздырганнан соң, икенче көнне иртәнге чәйне эчү белән үк Бауман урамына, Матбугат йортына киттем. Гази Кашшаф, Әнәс Камал белән таныштым, Абдулла Гомәр белән күрештем. Аерата хәтергә нык сеңеп калган кеше Фатих Хөсни булды. Ул мине туганыдай күреп җылы каршы алды. Гадәтенчә, авырттырмый торган чәнечкеле сүзләр әйткәләп, миннән фронт хәлләрен сораштыра башлады. Әйтергә кирәк, үзенең гадилеге, җорлыгы белән ул күзгә күренеп якыңайды. Минем аны җыелышларда, секция утырышларында очраткалаганым булса да, аның шәхси танышы түгел идем әле.

Хәтердә, Фатих Хөсни белән сөйләшеп утырганда, өстенә таушалып беткән френч кигән, кулына күпне күргән күн портфель тоткан атаклы язучы Кави Нәҗми килеп керде. Фронт хәлләре белән кызыксынганнан соң, Кави ага, Казанга кайчан килдегез, дип сорады. Мин җавап кайтарырга өлгермәдем, Фатих чәчрәп чыкты:

— Менә татар язучылары! «Килдегез» дип сорыйлармени? «Кайттыгыз» дип сора!

Кави ага чыгып киткәч, без сөйләшеп утырган бүлмәгә укалы лейтенант погоннары таккан, бик фырт киенгән бер офицер килеп керде. Аның кулында камыш сумка. Аңа ияреп килгән (алар култыклашып килделәр) бер бик чибәр блондинка марҗа артык эчкә узмады. Бу офицер исә бик кыю рәвештә килеп Фатих белән исәнләште, аннан чират минем белән күрешүгә җиткәч, ул миңа карап, «Йөзең бик ак, егет, син фронтта күләгәдәрәк утырасың, ахры»,— дип куйды. Лейтенант редакциядә озак тоткарланмады. Фатих белән ниндидер бер пьеса турында бераз сөйләшкәч, дамасын ияртеп чыгып та китте.

— Кем була инде бу? — дидем мин. Фатих кул гына селтәде.

— Гамир Насрый дигән берәү шунда. Бәләкәй генә бер пьесасы белән дөнья куптаргандай йөри шунда, ачуым да килмәгәе...

Көндезге тәнәфес вакытында Фатих Хөсни мине, кунакчыллык күрсәтеп, сыйларга алып китте. Сыйлау дигәннән, аның артык бер ашау-эчү талоны бар икән, мине ашханәгә алып барып шул талонга сыйлады.

Ул алып барган ашханә сугыштан соң «Восток» рестораныңа әверелде. Хәтердә саклаганы шул: мин аш белән бирелгән икмәкне ашап бетерә алмадым, калдырдым. Бу хәл исә Фатихны соң дәрәҗәдә аптырашта калдырды. Аның кашлары маңгаена менде.

— Бездә мондый гадәт юк, агайне,— диде ул,— без алай сынык калдырып ашауны белмибез!

Кайтканның өченче көнендә мин күптәнге дустым Зиннәт янына барып чыктым. Ул һаман Әҗем мәчете каршындагы ике катлы әллә кирпеч, әллә балчыктан ясалган чалшайган бер өйнең ярым подвалында яши иде. Алар хәзер әнисе белән икәүләре генә торалар. Бер бүлмәле тар квартирның шактый зур өлешен мич биләгән, түрдә ишек каршында ук бөтен бүлмә мәйданы кадәрле диярлек сәке. Зиннәтнең әнисе Камилә апа карт инде, ул беркайда да эшләми, гомере буена ирен, балаларын тәрбияләгән. Зиннәт үзе хәзер авиация заводында токарь булып эшли.

Зиннәт эчке кичерешләрен ачык сиздерә торган егет түгел. Ләкин беләм, ул мине күрүенә бик шат. Һаман элеккечә ябык, сузан һәм хәрәкәтчән. Аңа Әҗем мәчетеннән Ленин районының теге очындагы заводка һәр көн җәяүләп атлау берни дә түгел.

— Ателло,— диде ул минем белән исәнләшкәч тә (ул гомер буе минем исемне шулай атады),— өйдә ашарга рәт юк, әйдә без синең белән базарга барып кайтыйк башта.

Без гәпләшә-гәпләшә Тукай урамының вокзал очындагы колхоз базарына барабыз. Трамвайлар ни сәбәптәндер йөрми. Зиннәтләрдән чыгып китү белән юлда очраган кешеләргә карап барам. Өс-башлары бигрәк бетерешкән. Киемнәрнең «яңа модалысы» дөньяга килгән хәзер. Кешеләр барысы да диярлек сырмателогрейка кия икән, аннан мех читек — мехаушка. Мехаушка өстеннән автомашина тәгәрмәче камерасыннан ябыштырып ясалган калош. Телдә дә яңа, сугыш чоры тудырган сүзләр ишетелә. Мәсәлән, моңарчы мин ишетмәгән «чумара» дигән сүз бик нык хәтердә калган. Урысы да, татары да шул сүзне куллана. Кешеләр арасында бөтенләй скелетта калганнары да очрый. Минем кызыксынуымны аңлап Зиннәт мондыйларның Ленинград кешеләре булуын сөйли. Ладога күле аша юл ачылгач, камалыштан котылып безнең якларга килеп чыккан икән алар.

Сөйләшеп бара торгач, шактый ерак юл да сизелми калды. Базарга керү белән Зиннәт брезент яңгырлык кигән кызыл йөзле бер агайга үзе заводтан ясап алып чаккан зажигалкасын алтмыш сумга сатты да, шул акчага бер килограмм бәрәңге алды. Заводтан вак әйберләр ясап алып чыгарга мөмкинлек бирелә икән. Мин бәрәңгенең шул дәрәҗәдә кыйммәт булуына аптырыйм. Менә синең өйгә җибәргән акчаларыңның бәясе! Ә Зиннәтнең рух күтәренке. Сый булды, диде ул, җайлы килеп чыкты. Без кире Тукай урамы буйлап җәяү генә Зиннәтләргә, Әҗем мәчете ягына киттек.

Өйгә кайтып сәкегә утыргач, Зиннәт кул сузып кына сәке астыннан бер чәкүшкә аракы тартып чыгарды. Ашыкмый гына аның кәгазь бәкесен ачты, аракыны бик тигез итеп ике чокырга койды. Ул арада Камилә апа, Зиннәтнең әнисе, ярып пешергән кабыклы бәрәңгесен дә безнең алга китереп куйды.

Без сыйланабыз, сүз куерганнан-куера, телләр чишелгәннән-чишелә бара. Зиннәт Казан хәлләрен, завод хәлләрен, мин үземнең баштан кичкәннәрне сөйләшәбез. Рәхәт. Сыналган җан дус белән туарылып бер сөйләшүгә ни җитә!

Без шулай күләгәләр озынайганга кадәр утырабыз. Аннан мине дустым трамвай тукталышына кадәр озатып куя.

Казанда Язучылар союзына алдылар, билет тапшырдылар. Ул билет миндә әле дә бер истәлек буларак саклана. Идарә утырышының рәисе Тажи Гыйззәт иде. Минем иҗатым турында Гази Кашшаф сөйләде. Союзга алыну мөнәсәбәте белән мине мактады булса кирәк.

Икенче көнне без әнием белән Бакалтайга, аларның бәрәңге җиренә бардык. Әниемнең бу бер сутый җирдә өмете зур. Әмма, дөресен әйткәндә, бу өметнең акланмаячагы миңа ачык. Бәрәңгенең бер дә рәте-җүне күренми.

Казанда ун көннәр чамасы булдым. Тиздән күрешүне теләп, саубуллашабыз. Һәм менә мин тагын юлда...

Казаннан үзебезнең частька егерме җидесендә кайтып төштем. Безнең Өченче армия, Курск дугасындагы башка армияләр кебек үк, һөҗүмгә күчкән. Бәхеткә күрә, миңа үзебезнең Ветчастьны эзләп йөрергә туры килмәде. Алар һаман Сабатаевка авылында иде әле. Икенче көнне үк булса кирәк, алга киткән дивизияләрне куып җитү өчен кузгалдык. Бөтен хуҗалыгыбызны арбаларга төягән, авыру, яралы атларны ияртхән хәлдә, дошман хуҗалык иткән җирләрдән барабыз. Яндырылган, кара кисәүләре генә һәм морҗалары гына тырпаеп торган авыл урыннары, юл читләрендә дошманның зир-зәбәр китерелгән техникасы, мәетләр белән тулы кырлар, окоплар белән ермачланган, снаряд буранкалары шадралаган басулар, болыннар...

«27 июль, 1943 ел.

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезне күрүдән туган җылы хисләр белән дәртләнеп, үзебезнең полкка бүген исән-сау кайтып кердем. Юл бик җайлы булды. Беренче төннең уртасында үземә югары шүрлекләрнең берсеннән урын да таптым. Рәхәтләнеп йоклый-йоклый, Мәскәүгә җиткәнемне сизми дә калдым. Аннан утырып китүе дә ифрат ансат булды.

Казаннан китүем бик ашыгыч булды. Байтак кына туганнар, дусишләр белән саубуллашырга да өлгерә алмадым. Сез аларга күп сәлам тапшырыгыз. Моннан соң үзегезнең тормыш хәлләрен тулы итеп, буямыйнитми языгыз. Йөзләрегездән үбеп, ялкынлы сәлам белән: Атилла.»

Белоруссия җирләренә дә аяк бастык. Мине башка частька күчерделәр. Бу хәрби бүлек — Мең дә уналтынчы эваковетлазарет дип атала. Ул турыдан-туры армия штабына буйсына. Безнең бурыч хәзер, беренче ярдәм күрсәткәннән соң, дивизияләрдән килгән авыру, яралы атларны армия ветлазаретларына, тылга озату.

Безгә алгы сызыктан шатлыклы хәбәрләр килеп тора. Август башларында Өченче армиянең хәрби советы тарафыннан язылган мөрәҗәгать укыдык. Анда түбәндәге сүзләр бар иде:

«Сугышчылар һәм командирлар! Сезнең күз алдыгызда Гитлер бандитлары Орел шәһәрен җимерәләр. Сез аннан 6—10 километр ераклыкта гына торасыз. Ике-өч сәгатькә сузылачак кызу һөҗүм, безнең югалтуларны кимету өстенә, туган шәһәребезне дә ватылып бетүдән саклап калачак. Алга, каланы һәлакәттән коткару өчен, алга!»

Минем хезмәт урыным хәзер алгы сызыкка бик якын. Безнең частьлар зур авырлыклар кичереп булса да һаман алга баралар, бер-бер артлы авылларны, шәһәрчекләрне азат итәләр. Бу соңгы һөҗүмдә безнең хәрби частьлар Германиягә куылучы утыз мең совет кешесен азат иттеләр.

Армиябез хәзер ункөнлек резервта. Безнең эш күп, атлар дәвалыйбыз. Безнең армия Өченче сентябрьдә Людиново шәһәренең көньяк-көнчыгышында тупланды. Резервта булу озакка сузылмады. Тиздән Илленче армия частьлары белән берлектә тагын һөҗүмгә күчтек. Унынчы сентябрьнең кичендә дошман оборонасы өзелде. Армиябезнең алтмыш километр киңлектәге фронты дошманнан арчылган инде. Уң флангтагы дивизияләребез Бытош каласын азат итте, калган өч дивизия Людиново каласын алды.

Бер атнага сузылган каты сугышлар нәтиҗәсендә безнең Өченче армиянең уң канаты утыз километрга, сулы алтмыш километрга алга китте. Уң ягыбыздагы Илленче, сул ягыбыздагы Унберенче армияләр дә һөҗүм итеп алга баралар. Совет гаскәрләре Десна елгасын кичеп, Брянскины тылда калдыру куркынычын тудыргач, дошман шәһәрне ташлап кача.

Безнең армия Бесеدь елгасына чыкты, аның аръягында плацдарм булдыру операциясе алты көндә тәгәлләнде. Бераздан Мглин һәм Сураж шәһәрләре дә азат ителде.

«20.09.43 (3.X алдым)
Сөеклеләрем әни һәм әти!
Әнинең 31 августта язган хатын кичә алып, исән-саулыгыгызга чиксез шатландым. Әле хатны тулырак язарга вакыт юк. Һаман алга барабыз. Бер айдан артык юл килеп, исән калган өй күргәнем юк әле. Без узган авыллар һәммәсе яндырылган. Ниһаять, менә бу җирләргә житкәч кенә, исән калган өй-каралты күрү насыйп булды...
Моннан бер атна чамасы элек «С.Ә.»не бер хикәя җибәргән идем, алдылар микән? Исәнлектә күрешүне теләп, ялкынлы сәлам белән: Атилла».

«11.10.43 (28.X алдым)
Сөеклеләрем әни һәм әти!
Сезнең соңгы хатыгызны һәм «С.Ә» журналын (№ 6) алдым. Рәхмәт. Үземдә исән-саулык. Әле якын арада тукталып торырга мөмкинлек булды. Ләкин озакка булмас. Юлчының юлда булуы яхшы, диләр. Безнең алга баруыбыз хәерле фал. Хәзер инде Белоруссия җирләрендә йөрибез. Монда дошман барысын да яндырып өлгермәгән, партизаннар саклап кала алганнар.
Әни, син бакчадан бары бер пот бәрәңге казып алдык, дип язасың. Мескенкәйләрем. Бигрәк начар уңыш җыйгансыз икән. Сезгә 400 сум акча җибәргән идем. Алдыгызмы? Аннан «Ютазы егете» басылдымы? Аның акчасы да сезгә ярап китәр әле.
«Дошман тылында» дигән бер хикәя җибәрдем. Аның турында бер язган идем. Ни өчендер аның язмышы турында берни дә язмыйлар.
Ялкынлы сәлам белән, йөзләрегездән үбеп, Атилла».

Беренче октябрь көнне безнең армия Сож елгасы ярларына барып житте. Дошманның оборонасын туздырып, Самотечи һәм Костюковичи шәһәрләрен азат итте. Костюковичи — Белоруссиядәге безнең армия азат иткән беренче шәһәр.
Армия һаман һөҗүмдә. Дивизияләр, җиңүләр белән рухланган хәлдә, хәтсез катлаулы ныгытмаларны җимереп, фашистны иләп куалар. Бик күп авыллар, шәһәрчекләр азат ителде. Әйтми калу мөмкин түгел, бу эштә Брянск партизаннарының безгә ярдәме ифрат зур булды. Алар дошман тылында фашист гаскәренең чигенү юлларын җимерделәр, аның хәрби дирбия белән тәэмин ителүен какшаттылар, аерым штабларны юкка чыгарып тордылар.
Белоруссия җирләренә килеп кергән көнне үк без Өченче армиянең хәрби советы язган мөрәҗәгатен укыдык. Ул түбәндәгечә иде:
«Данлыклы пехотачылар, артиллеристлар, танкистлар, саперлар һәм элемтәчеләр! Бу көн безнең өчен бик истәлекле! Безнең гаскәрләр Белоруссия җирләренә аяк басты. Кабахәт гитлерчылар ике елдан артык вакыт Белоруссиянең канын эчтеләр. Алар кешенең яшенә, җенесенә карамастан йөз меңләгән белорус халкын газаплап үтерделәр. Ике елдан артык белорус халкы, аналар һәм балалар, үзләрен коткарачак Кызыл армия яуларын сагынып зар еладылар.
Җитәр! Фашист єрткычының кабергә керер вакыты житте! Тизрәк эшен бетерергә кирәк ул мәлгуньнең. Совет Белоруссиясен азат итеп, аны туган илебезнең иркле семьясына кайтару көннәре якынлашты...»
Бездә хәзер тагы үзгәреш: армиябезне Беренче Белоруссия фронты буйсынуына тапшырдылар.
12 нче октябрь таңында, ун минутлык артиллерия әзерлегеннән соң, безнең частьлар тагын һөҗүм башладылар. Өч сәгать эчендә Сож буен-

дагы Костюково, Салабута һәм Студенец торак пунктларын азат итеп, армия ике километр алга узды.

«23.10.43 (алдым 6.XI)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезнең 9 ында язган хатыгызны бүген алып, әтинең авырганлыгын белгәч, бик борчылдым. Үзем исән-сау. Ул-бу яңалык юк. Бераз тукталып ял итәбез.

Әтинең авыруы кай төшендә соң? Докторларга күренергә кирәк иде. Вакытында чарасына керергә кирәк. Әле бу арада яңа бер хикәя өстендә эшли башладым. Тиздән бетереп җибәрермен дип уйлыйм. Әпсәләмгә хат яздым. Моратның әбисе үлгән икән. Аңардан сезгә күп сәлам.

Сезгә сәламәтлек телим. Атилла».

«23.11.43.

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезнең бәйрәм көнендә җибәргән хатыгызны алып, исән-саулыгыгызга шатландым. Үзем исән-сау. Шулай итеп, Кыш бабай да килеп житте. Тышта кар ява, салкын җил исә. Мин авыру атларны лазаретка озатып (мин лазареттан ары өч кызылармеец белән бер авылда яшим), әле бер иптәш белән утырам. Ул көндезге ашка бәрәңге арчый, мин тәрәзә янында сезгә хат язам.

Әле кичә генә журналга «Казан хикәясе» дигән бер нәрсә җибәрдем. Җае туры килгәндә сорашыгыз әле, барып житте микән?

Әни, син хатыңда, Фәтхуллинны[1] күрдем, дип язасың. Очрашуыгыз бик ашыгыч булган, ахры. Ул армиядәме, юкмы? Адрес алырга сезгә кирәргә булдымы? Мораттан хатлар килеп тора. Соңгы хаты бик начар настроение белән язылган. Хатыны аның янына килергә тели икән дә, берни дә барып чыкмый, күрәсең. Күңеле шуңа төшенке булса кирәк.

Әпсәләмовтан хат алдым. Язучылар арасында аны моңарчы күргәнем булмаса да, хатларын укып үзен бик якын, дус күрә башладым. Ул да Казан абзыйларыннан зарлана. Берсе дә хат язмый, ди. Шулай инде ул, читтәге кеше онытыла.

Бүгенге информбюро хәбәрләрен укырсыз әле. Без тагы кузгалдык. Тизрәк, тизрәк үзебезнең җирләрне азат итик. Бу — халык теләге!

Әле бер озын көлке хикәя башларга уйлап йөрим. Тик язуы авыр булачак. Өйдә шау-шу, тавыш. Мин, колакларым барлыгын онытып, хикәя язам. Бу шундый бер эш инде. Бик татлы да, авыр да. Аның файдалы ягы шунда, үзеңнең җаваплы зур эш башкаруың шатландыра һәм сине тормыш ваклыкларыннан өстен тотарга өйрәтә. Болар барысы да узгынчы вак нәрсәләр дип карыйсың, үзеңә кирәксез нәрсәләрне онытырга өйрәнәсең.

Ярар, сез минем бу лыбырдауларым өчен пошынмагыз, минем янымда бу турыда сөйләшерлек сердәшем юк диярлек. Моратка язсам, ул әдәбият белән, бигрәк тә татар әдәбияты белән, кызыксына торган кеше түгел, ә Казандагы абзыйлар арасында минем әлегә якын дусларым юк.

Тормыш зарланырлык түгел. Мин ач та түгел, туңмыйм да. Тик бүген ни өчендер күңел төшенке. Бераз арылган булса кирәк. Соңгы айда өзлексез хикәя язып маташтым. Тырышлык бушка китмәсә ярый инде. Язылачак хикәяләр һәм «Казан хикәясе» яхшы дип табылса, мин бик шат.

Язуыңа караганда, әни, әтинең ашказанында катар булса кирәк. Бик вакытсыз килгән чир инде. Чөнки аңа бик яхшы тәрбия кирәк. Үзегезнең тормышлар ничек соң. Әти авырып егылгач, бик уңайсыздыр инде. Әтинең абзыйларга барып кайтуына сүзем юк. Ихтыяры бакый...

Йөзләрегездән үбеп, тиздән күрешүне теләп калучы улыгыз Атилла».

---

[1] Х. Фәтхуллин — «Күзләр» пьесасының авторы, врач.

22 нче ноябрьнең таңында ун минутлык көчле артиллерия әзерлегеннән соң Өченче армиянең алгы батальоннары тагы һөҗүмгә ташланды. Көн азагында Гомель районындагы дошман частьлары камалу куркынычы астында кала. Дошман Гомельдән чигенергә мәҗбүр.

Һөҗүм башланганның бишенче көнендә Мәскәү Гомельне азат итүчеләрне котлап салют бирде.

«8.12.43(20.12 алдым)

Сөекле әнием!

Синең 25 ноябрьдә язган хатыңны алып, саулыгыңа чиксез шатландым. Без һаман әкрен генә юлыбызны дәвам иттерәбез. Ниһаять, бүген кыш башланды булса кирәк. Чөнки аяк астындагы кар, бик аз булса да, эреми. Юкса бездә һаман көз, һаман баткак, епшек иде. Үземнең шәхси тормышымда әйтерлек берниндир дә яңалык юк. Хәзер көннәр бик кыска инде. Миңа тычкан уты яктылыгында гына язарга туры килә. Әле «Шат күңелле Галләметдин» дигән яңа әсәр эшләп утырам. Шат, һәрвакыт күтәренке күңелле, берниндир кыенлыкларга да бирешми торган, гади һәм кызыклы бер кеше образын тудырырга исәп. Белмим нәрсә чыгар, әле хәзергә бер хикәясен генә төгәлләп киләм. Ә. Камал җибәргән журналны алмадым әле. Әгәр кәгазь җибәрсәң, бик яхшы булыр иде. Ул биредә бик дефицит нәрсә. Әти кайттымы? Аның кәефе яхшыра дип язуыңа мин бик шат. Ул нинди хәбәрләр алып кайткан? Ф. Хөснигә дә язган идем әле. Рахман, Шакир, Мөхәммәт абыйларга атап сәлам әйтегез. Һәр икегезнең дә йөзеннән үбәм. Ялкынлы сәлам белән: Атилла».

* * *

Менә Бөек Ватан сугышының өченче елы — кырык дүртенче ел да башланды. Сталинград эпопеясы инде бик ачык итеп җиңүнең безнең якта икәнлеген күрсәтте. Хәзер вакыт безнең файдага хезмәт итә, без өзлексез алга барабыз. Күңелләребез көр, күтәренке.

Әмма хатларыма аңлатмамны дәвам иттергәнче бер искәрмә ясалырга тиеш дип табам. Хикмәт шунда: хатларга таянып кына күргәнишеткәннәрне язып бетердем дип әйтә алмыйм. Мәгълүм булганча, сугыш елларында фронттан килгән һәрбер хат тикшерелде, хәрби цензура аны сөзеп, фронт серләрен тылга чыгармаска тырышты. Бу хәл исә хат язганда артын-алдын уйлап, артык тәфсилгә бирелмичә, хәрби мәсьәләләргә бөтенләй кагылмаска тырышып, кагылганда да бик гомуми рәвештә, абстракт формада гына язарга куша иде. Ә хәзер бу дәһшәтле сугыш елларына бик күп вакытлар узды һәм бик күп нәрсә хәтер киштәләреннән тәмам югалырга да өлгерде. Бары күңелгә артык нык сеңгән, яки күп тапкырлар кабатланып хәтердә сакланган вакыйгалар, шәхесләр генә кәгазьләргә теркәлә ала.

Мин, мәсәлән, кырык өченче елның җәендә үзебезнең батальон замполиты һәм тагын берничә хәрби белән йөк машинасында Брянск урманнарында көне буе адашып йөргәнебезне бик нык хәтерлим. Минем аңарчы мондый калын, караңгы урман күргәнем юк иде әле. Дүрт-биш кеше тотынышып колачларлык, башлары болытларга җиткән агачлар, ул урмандагы җәйге челләдә дә кипми торган быкырдык юллар. Болытлы көннәрдә генә түгел, аяз көннәрдә дә эңгер караңгылыгы. Минем ул әкияти урманнарны мәңге онытасым юк. Хәзер нигә шулай адашып йөрүебез анык хәтердә сакланмаган. Без дисколацияебезне алыштырырга тиеш идек булса кирәк. Бу гадәти булмаган сәяхәт шул яңа урынны эзләү өчен иде, ахры. Адашуыбызның сәбәбе картабызның төгәлсезлеге аркасында булды. Шуңа күрә, без бер мичкә ягулык бетереп, иртәдән кичкә кадәр урман гиздек.

Мин шулай ук урман юлларын гизгәндә, ләкин бу юлы машинада түгел, ә атта гизгәндә, безнең каршыга каяндыр килеп чыгып бер телсез,

сәләмә киемле кешенең юлыбызны бүлдергәнен дә хәтерлим. Аның аңлатуы буенча, бу юлдан барырга ярамый, чөнки юлга немец миналар күмеп калдырган икән. Мин соңыннан үземнең бер хикәямдә бу турыда яздым да. Билгеле, без күргән вакыйга хикәядәгечә үлем-җитем белән бетмәде, әмма бик күп икеләнүләрдән соң, безнең бу телсез патриотка ышануыбыз һәм, чыннан да, юлда миналар ятканлыгы хак иде.

Тагын Женя атлы безнең белән хезмәт иткән егетнең фаҗигале һәлакәте һич истән чыкмый. Женя Ленинград егете иде. Буйчан, чибәр, кара матур күзле, мөлаем бер яшь кеше иде ул. Армиягә консерваториядә укыган җиреннән алганнар. Армиядә исә аны кыска сроклы ветфельдшерлар курсына җибәргәннәр. Безнең лазаретка ул без Белоруссиягә килеп кергәч кенә кушылды.

Гүзәл тенор тавышлы җырчы иде Женя. Шулай, бер җирдән икенчесенә күченә-күчене алга барган көннәрнең берсендә ул бер солдат белән, ат менеп, лазарет өчен яңа урын эзләргә китә. Болар икесе атларын юырттырып тап-такыр юлдан баралар. Юлда бер тар гына инеш очрый. Болар, күпердән чыгу хәвефле булыр дип уйлап, үзләренчә немец минасыннан саклану өчен күпернең икесе ике ягыннан сай елгачык аша чыга башлыйлар. Инде ярга чыгып җиттек дигәндә генә Женяның аты дошман калдырган минага китереп баса. Коточкыч шартлау. Ат урталай өзелә, күпернең теге ягындагы солдат шартлау дулкыныннан атыннан очып төшә. Ә Женяның исә бот төбеннән ике аягын да өзә. Женяның юлдашы, аңына килгәч шуны күрә: икегә өзелгән ат үләксәсе һәм кан эчендә комлы юлда аунап ятучы аяксыз Женя. Солдат аягына баса, йөгереп Женя янына килә, аның аккан канын туктатмак була. Ул арада ерактагы аркылы юлдан узучы атлы кешеләрне күреп, аларга кычкыра башлый, мылтыктан ата...

Гүзәл җырчыбыз, мөлаем Женяның җансыз гәүдәсен шулай крестьян арбасына салып, безнең частька алып кайттылар. Солдатның әйтүенә караганда, Женя әле арбага салганда үз аңында булган. Ләкин никадәр тырышмасыннар, кан агуын туктата алмаганнар. Женя саташа башлаган, аннан аңын җуйган һәм үлеп тә киткән.

Әйе, аерым, ләкин төгәл вакыйгалар булып фаҗигале истәлекләр генә калмады күңелдә. Мәсәлән, үзем белән хезмәт иткән иптәшләремнең яхшылыкларын һәм шуны исбат иткән вакыйгаларны мәңге онытасым юк. Соңгы вакытларда миңа ЭВЛ*ның үзендә күбрәк хезмәт итәргә туры килде. Күпмедер вакыт миңа хәтта аптека хуҗалыгы белән идарә итүне дә йөкләделәр. Андый вакытларда мин безнең частьның офицерлары белән бергә ашым. Офицерлар исә, кече командирлардан аерым буларак, күбрәк эш хакы алу өстенә, тагын аерым өстәмә паек белән дә тәэмин ителә. Аларга өстәмә рәвештә колбаса, йә тушонка, папирос һәм тагын башка продуктлар бирелгәне хәтердә. Моны шуңа гына искә алам, мин алар белән булганда алар бер генә тапкыр да ул өстәмә паектан мине мәхрүм итмәделәр.

Искә төшә. Белоруссиянең Березяки исемле бер авылында миңа егетләр скрипка табып китерделәр. Авылда башка музыка коралы юк иде. Скрипканы рәткә китереп, яшьләр җыела торган мәйданчыкта уйный башлавым уенга катнашучыларны ифрат куандырды. Мин белорус кызларын җырлатам, биетәм. Җәйге җылы кичләр хәзер безнеке, яшел чирәм баскан авыл урамында Левониха яңгырый. Әйдә, Көнбатышта туплар гөрселдәве ишетелә бирсен! Азат ителгән авылда тормыш үз кагыйдәләре белән дәвам итә. Кеше дигәнең һәр мөмкинлектән файдаланып, күңелен күтәрергә тырыша. Бу тирәдәге авылларны партизаннар саклап калган. Ләкин шулай да сугыш үзенең кара мөһерен барыбер суккан. Халык бик фәкыйрь яши, кием-салым тузып беткән. Кышкы суыкларда белорус хатыннары ялан тәпи йөри. Ашауга килгәндә халыкны шул бәрәңге коткара. Белоруссия — данлыклы «бульба» төбәге.

---

* Эваковетлазарет.

Шулай итеп тагын кыш керде. Кырык дүртенче ел кышы. Безнең ЭВЛ озагракка тукталган урыннарда, авыл өйләрендә яки немецтән калган төзек блиндажларда, һәр мөмкинлектән файдаланып, мин кулыма каләм алам, хикәя язам. Шунысы кызганыч, сугыш елларында көндәлек дәфтәре булдыра алмадым. Әлеге дә баягы, рөхсәт ителми торган эш дип, ул көндәлек дошман кулына төшсә, дип инде...

Алай да хикәяләр язам. Хәзер инде төнлә эшләү өчен снаряд гильзасыннан ясалган лампа якмыйбыз. Егетләр кальций карбиды таптылар. Шуны сулы консерва банкасына салабыз да аңа энә белән тишелгән капкачны нык итеп каплап ут кабызабыз. Тишектән чыккан газ шундый якты һәм матур яна — электр лампаларың бер якта торсын!

1943 елның икенче декабрендә безнең армия Бобровка елгасыннан Гадиловичи авылына кадәр сузылган фронтта Днепр елгасы ярларына барып чыкты. Әмма дошманның барысы да ул олы елганың аръягына куып чыгарылмаган иде әле.

Ул дошман плацдармы безнең армиягә зур уңайсызлыклар тудыра. Тиз арада аны юк итү планы корыла һәм бу операцияне башкару курку белмәгән капитан Тайвекайненга тапшырыла. Ул үзе белән ике йөз чаңгычы сайлап ала һәм, тиешле әзерлектән соң, өченче январь төнендә Днепр буйлап рейдка чыга. Башта алар үзәнлек буенча шуалар, аннан юлларын елга өстендәге боз буенча дәвам иттерәләр. Кызганычка күрә, бу көннәрдә һава җылынып киткән була, Днепр өстенә урыны-урыны белән туш чыга, су өстендәге боз да юкара. Шуңа күрә артык сак хәрәкәт итәргә кирәк. Рейдчылар алда барган иптәшләренә бау беркетәләр һәм бауның очын арттарак баручылар тотып бара. Алай да юл дәвамында берничә тапкыр суга чумып чыгучылар була. Аларның шундук киемнәрен алыштыралар, тизрәк җылыту чараларын күрәләр. Шулай отряд төн караңгылыгына ышыкланып һаман алга бара, көндезләрен яшеренеп тора...

Менә, ниһаять, алда дошман плацдармы. Отряд төн уртасында фашистларның штабы урнашкан урынга якынлаша, немец формасы кигән безнең тәрҗемәче егет алга чыга, сакчыга якынлаша. Аннан пароль сорала. Безнең солдат исә сакчыга яшен тизлегендә ташлана да, ул өнен җыйганчы, аны чәнчеп үтерә. Иптәшләре сигнал буенча штаб урнашкан бинага керәләр.

Көтелмәгәндә ясалган төнге һөҗүм уңышлы тәмамлана. Фашистларның ике йөздән артык солдаты, шул җөмләдән штаб начальнигы юк ителә, бездән исә алты солдат кына һәлак була. Шулай итеп, егетләрнең осталыгы, кыюлыгы аркасында армиябез өчен бер бәла-ле урын булып торган дошман плацдармы юк ителә.

Бу героик рейд турында соңыннан, кырык дүртенче елның февралендә, Совинформбюро бөтен дөньяга хәбәр итәчәк әле.

Безнең армия алдына хәзер Днепрны кичү бурычы куела. Бу җиңел түгел. Бу эшкә бик нык әзерләнергә кирәк. Армия ныклап төрле чаралар күрә башлый. Иң беренче чиратта дошманга сиздермичә генә, күперләр салырга кирәшә. Саперлар субайларны төнлә генә яшеренеп кагарга мәҗбүр. Каккан тавыш ишетелмәсен өчен алар субай өсләренә иске сырмалар каплап эшлиләр. Дошманны бутау өчен, елганың бөтенләй башка турысында субай каккан, күпер салган булып кыланалар.

Январь аенда ук фронт штабы безнең армиядән өч дивизиябезне ала. Нәтиҗәдә безнең армия бөтенләй сирәгәя, фәкыйрьләнеп кала. Ләкин моңа карап ул Днепр кичү өметен өзми, моңа хәзерлек әкренәйсә дә тукталмый.

«13.02.44 (28.II алдым)

Сөекледәрем әни һәм әти!

Әнинең 27 нче январьда язган хатын, әти җибәргән өч пакет кәгазьне алып, исән-саулыгыгызга бик шатландым. Һәм, моннан берничә көн генә

элек, хат язган булсам да, тагы хат язарга тотындым. Үземдә ул-бу яңалык юк. Кәгазь мәсьәләсен монда хәл иттем. Көннәрдән бер көнне Политотделга кергән идем, бик ансат кына 2 килограмм кәгазь алдым.

Әле бу көннәрдә бер хикәя төгәлләдем. Эш арасында ул хикәяне язуга сәбәп Г. Кашшафның хаты булды. Ул хат шулкадәр шатлыклы бер хат иде — аңа җавапны мин коры хат формасында гына язарга базмадым. Хикәяне рекорд срокта бетердем, өч утыруда 60 битлек нәрсә яздым. Исеме «Сагынылган мәхәббәт». Акка күчерү белән Казанга җибәрәм — күз-колак булыгыз.

Йөзләрегездән үбеп, сезне сагынучы улыгыз: Атилла».

Егерменче февральдә Днепр кичү өчен безнең әзерлекләр төгәлләнә. Димәк, озакка сузмыйча, һөҗүмгә күчәчәкбез. Иртәгә һөҗүм башланачак көнне солдатлар көнозын ял итәләр. Кичке ашны тәмләп, нык ашап туеналар һәм гадәттәгедән иртәрәк ятып йоклыйлар. Алай да ике батальонга азрак йокларга туры килә. Аларны төнге унбердә уяталар. Алар фронт сызыгын узып, сиздермәстән Рогачев шәһәренә бәреп керергә тиеш.

Таң атып килгәндә безнең армия тоткан тугыз километрлы фронт буенча тугыз йөз туп-минометтан атылган кононада бөтен тирә-якны дер селкетә. Пехота окоплардан чыга, күперләр аша танклар, туплар, алар белән бергә җәяүле гаскәр аргы ярга ташлана.

Сәгать унда дошманның оборонасы өзелә һәм плацдарм булдырыла. Беренче көнне үк аның киңлеге ундүрт, тирәнлеге биш километр чамасы була. Әлбәттә, дошман плацдарм бирмәү өчен барлык көчен куя. Туплардан, минометлардан өзлексез үлем чәчә, әледән-әле безнең гаскәр өстенә дулкын-дулкын булып иллешәр самолет җибәрә, безнең армияне бомбага тота. Мәгәр максатына ирешә алмый, безнең армия яуланган плацдармга чыкмас казыктай нык урнаша.

Өч көн дәвам иткән көчле һөҗүм сугышлары нәтиҗәсендә, безнең армия Днепр көнчыгышындагы плацдармны кырык биш километрга кадәр киңәйтте. Днепр аръягында зур плацдарм булдырды. Рогачев каласын азат итте. Егерме дүртенче февральдә Мәскәү Рогачев азат ителү мөнәсәбәте белән салют бирде.

«16.05.44 (31/5 алдым)

Сөеклеләрем әни һәм әти!

Сезнең йөзләрегездән үбеп, ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Үземдә исән-саулык. Әле хәзергә бернинди дә үзгәреш юк, бер көе торып ятабыз. Әтинең һәм, әни, синең 1 нче майда язган хатларыгызны алып шатландым.

Син, әни, хатыңда, минем хикәяләремнең язмышы турында язып мине шатландырдың. Әмма бүген үзем иҗат уңышсызлыгы кичергәнлегемне аңладым. 1 нче декабрьдән бирле төн йокыларымны калдырып язган «Шат күңелле Галләметдин» җилгә очты. 654 бит язып, инде бетерәм дигәндә, кызыксынып артыма әйләнеп караган идем — үземнең хезмәтемнән үзем курыктым. Бернигә ярамаслык, тозсыз бер нәрсә килеп чыккан. Аны яңадан башламый булмый. Димәк, әсәрнең икенче вариантын эшләргә туры килә. Ләкин аны болай озынга сузырга ярамый, ул 5 — 6 бүлектән торган бер хикәя булырга тиеш. Ярар, хәерле булсын, сез минем өчен борчылмагыз. Мин үзем бу хәлне артык авыр кичермим. Язучылык эшендә шулай буладыр инде ул. Һәрхәлдә, мин язу тәҗрибәмне арттырдым ичмасам.

Хәзер бездә тәмам җәй булды. Көннәр ифрат матур. Янныбыздагы урманда сандугачлар сайрый. Күңел әллә кайларга ашкына.

Туганнарга, дусларга ялкынлы сәлам тапшырыгыз. Улыгыз: Атилла».

1 март көнне дошман безнең алгы сызыкка туплардан ата башлады. Артиллерия әзерлегеннән соң, атакага күтәрелде. Көндез өч тапкыр,

төнлә ике тапкыр һөҗүм итеп карады. Дошманның бу һөҗүмнәре бик каты. Фашист безнең позицияләргә когырынып ташлана, урыны-урыны белән ул штык сугышларына кадәр барып җитә. Әмма дошман барыбер чигенергә мәҗбүр. Иртәгесен туплардан атты, күперләребезне җимерде. Әмма максатына бу юлы да ирешә алмады, аның атакалары барыбер тончыгып юкка чыгарыла торды. Ул бик күп солдатын югалта, тик чигенми чарасы юк. Кичен ул безнең позицияләрне тагы тупка тота, танкларын җибәрә, әмма һөҗүме бу юлы да мантымый. Ул ике сәгатьтән ике сәгатькә һөҗүм итеп карый, шулай канлы, рәхимсез сугыш төне буе дәвам итә. Иртәгесен сугыш кырындагы күренеш безнең исән калган егетләрне шаккатыра. Кыр ватык танклар, самоходкалар белән тулы, алдагы бушлыкта аяк басар урын юк, бөтен җир дошман солдатларының мәете белән тулы. Бу кан коюның азагы шуның белән бетә. Әмма дошман көчле әле. Без беләбез, безнең армия алдындагы дошман оборонасы биш катлы. Ул Добреца, Добыска, Ола һәм Берпзика елгалары буенча җитмеш километрга сузылган. Бу оборона Друть елгасында аерата нык. Анда корыч калпак астына яшеренгән дотлар, мина өстенә мина куелган кыр, өч рәт тимер чыбыклы киртә.

Дошманны саташтыру өчен, аңа һөҗүмне кайдан һәм кайчан башланачагын сиздермәү өчен төрле чаралар күрәләр, тупларны дошман позицияләренә сиздермичә генә якынайталар һәм шуның ише башка эшләр дә эшләнә.

Кырык дүртенче елның июнь башларында мине Армия Ветотделына тагы чакырдылар. ЭВЛ начальнигы миңа үзем белән барлык «байлыгымны» алып барырга кушты. Димәк, мин бу частьтан гомергә яки бик озакка киттем дигән сүз. Мин сорау белән бик егет җанлы майорның чибәр йөзенә текәләм. Дөресен генә әйткәндә, миңа бик авыр хәзер. Мин бит мондагы дусларым белән күп михнәтләрне бергә кичердем, куркыныч урыннардан ничәмә тапкыр яралы атлар озаттым, ничәмә тапкыр бомба һәм туп снарядлары шартлавы астында калдым. Әле миналары тазартылып бетмәгән юллардан ат өстендә узып, үзебезнең бүлекчәгә дислокация урыннары эзләп йөрдем. Байтак хәлләр булды. Кыскасы, мин биредәге дусларымны хәзер инде авыр минутлар кичерешендә сынадым, аларны тугандай якын күрә башладым. Алар да миңа ярдәм кулларын һәрвакыт сузарга әзер тордылар, миңа булышудан беркайчан да баш тартмадылар. Истә, ярасына туалет ясаганда таудай зур ат минем сул аягыма басты. Итек башы умырылып чыкты, а к йөзе дә нык кына яраланды. Шул минуттагы иптәшләрнең минем өчен кайгыртуын оныту мөмкинме соң! Мине күтәреп алып керүләр, сак кына итекне салдырып яраны бәйләүләр... Начальник ыбыз, майор, шундук миңа үзенең запас кирза итеген бүләк итте. Үзеңне шундый якын күргән кешеләр арасыннан ничек тыныч кына китәргә була?!

Безнең начальник минем кичерешләремне бик тиз аңлады булса кирәк.

— Борчылма,— диде көлемсерәп,— барысы да синең файдага гына булыр дип уйлыйм.

Мин юл капчыгыма барлык хуҗалыгымны тутырдым да лазареттагы иптәшләр белән саубуллашып, безнең өченче армия штабы урнашкан авылга таба юл тоттым. Анда мине полковник үзе кабул итте.

— Менә нәрсә, Расулев,— диде ул,— без сезнең вуз тәмамлаган югары квалификацияле зоотехник икәнлегегезне беләбез. Шуңа күрә әле күптән түгел генә оештырылган армиябезнең ярдәмче хуҗалыгына үз белгечлегегез буенча командировать итәргә булдык. Менә сезгә предписание.

Полковник миңа җентекләп юл өйрәтә башлады. Сүз тәмамлангач, ул миңа уңышлар теләп кулымны кысты.

Ялган булмасын, мин үземнең белемемә һәм әзерлегемә лаек хезмәт чыгуын көтмәдем түгел, көттем. Фикеремчә, колачлырак эштә мин арми-

ягə күбрәк файда китерə алыр идем кебек. Лəкин шул ук вакытта ил язмышы хəл ителгән алгы сызыктан да ерак китəсем килми иде. Мин моны Белоруссиянең безнең арттa калган тылына, əлеге армия хуҗалыгы урнашкан Уваровичи атлы район үзәгенә якынлашкан саен ныграк тойдым.

«7.06.44 (28/6 алдым)
Сөеклеләрем əни һəм əти!
Сезгə хатымның беренче юлларында ялкынлы сəламнəремне җибəрəм. Үземдə исəн-саулык, лəкин хезмəтемдə зур үзгəреш булды, һəм шуның аркасында, Казанга кайтырга җыенган чакта, яңа хезмəт урнына китəргə туры килде. Мин хəзер институтта алган профессиям буенча хезмəт итəм. Əле өченче көн генə монда килеп төштем. Хезмəт итү шартларым хəл ителмəгəн əле, приказ юк. Минем ышануым буенча, мондагы хезмəт җайлы булачак. Хезмəтемə һəм тоткан урыныма карап түлəүлəренə дə ышанам шикелле. Əгəр бу хезмəткə күчүгə ризалык белдергəн булсам, бары шул хезмəт хакы аркасында гына, чөнки сезгə аттестат җибəреп, сезнең тормышыгызда ярдəм күрсəтү мəсьəлəсе җинелəср дип уйлаудан. Бу эш мин уйлаганча барып чыкмаса, мин шул ук минутта кире китү мəсьəлəсен куерта башлыйм. Андагы хуҗаларымның мине бер дə җибəрəселəре килмəде.
Хезмəт иткəн яңа урыным сезгə адрестан билгеле. Ул тирəн тылда. Минем карамакта байтак мал-туар булачак. Əдəбият мəсьəлəсе турында əле берни дə əйтə алмыйм, лəкин язуымны дəвам иттерə алырмын дип уйлыйм. Əле хəзергə бик күңелсез. Яңа урын, ят кешелəр. Мəсьəлə хəл ителгəч, мин сезгə тулы итеп хат язармын.
Йөзлəрегездəн үбеп, улыгыз: Атилла».

Июнь аенда Беренче Белоруссия фронтына Югары ставкадан Г. К. Жуков килə. Бу вакытта инде фронт штабының һөҗүмгə əзерлəнергə дигəн директивасы безнең армиягə җиткерелгəн була. Һөҗүмнең тугызынчы көнендə без Березина елгасына җитəргə тиеш.
Һөҗүм алдыннан Армиянең хəрби советы өндəмəсе пəйда булды. Анда: «Фашист ерткычын пыран-заран китерү сəгате килеп җитте. Совет армиясенең җəйге һөҗүме башланды. Безнең иптəшлəр Ленинград фронтында уңышлы рəвештə немец-фин фашистларын дөмбəслилəр. Гитлер армиясе безнең армиянең ударларын калтыранып көтə. Без бу һөҗүмгə яхшы əзерлəндек. Бары техникадан тулысынча файдаланырга гына кирəк. Дошман оборонасын кыю рəвештə өзегез...
Армиянең хəрби советы сезне совет коралының данын арттырырга чакыра. Җирлəребезне немец баскыннардан азат итик, яраланган ерткычны үзенең өнендə дөмектерик. Алга, данга һəм җиңүгə!» — диелгəн иде.
Һөҗүм башланып китте. Күктə самолетларыбыз дулкын арты дулкын булып дошман яшеренгəн якка очалар. Алар фашист позициялəрен төне буе бомбага тоттылар.
Катюшаларның күк күкрəвен хəтерлəткəн бердəм кабатланган залпы сигнал хезмəтен дə үти. Безнең пехота окоплардан чыгып, кызу адымнар белəн алга, дошманга таба китə .. Алда танклар юлны миналардан койрык-траллары белəн тазартып җəяүлелəргə юл ачып баралар. Туплар исə, арттан һөҗүм итүчелəрне саклап, өзлексез дошман позициялəренə атып торалар.
Икенче көнне дошманның беренче оборонасы бөтен фронт буенча өзелə, плацдарм утыз биш километрга кадəр киңəйтелə, унөч километргача тирəнəйтелə.
25 июньдə Югары башкомандующий Беренче Белоруссия фронты гаскəрлəренə дошман оборонасын уңышлы өзгəне өчен рəхмəт белдерде. Һөҗүмнең өченче көнендə безнең пехота шоссе юлына барып җитə.

танкистларыбыз исә шоссе буйлап Бобруйск шәһәренә юл тоталар. Тугызынчы танк корпусы, юлында, Германиягә куылып баручы биш мең совет кешесен азат итә һәм кичкә Березина елгасына чыга. Дүртенче көнне Тугызынчы танк корпусы үзе ярым чолганышка эләгә. Әлбәттә, аларны коткару өчен ашыгыч чаралар күрелә. Хосусан, Кырык алтынчы һәм Кырык беренче укчы корпусларга һөҗүмне тизләтергә, безнең карамакка бирелгән авиациягә дошманны бомбага тотарга кушыла.

Бишенче көн 129 нчы укчы дивизия йөз ун километр ара үтеп күршедәге Алтмыш бишенче армия белән бәйләнешкә керә, Березинага житә. Бу исә Бобруйскийның чолганышта калуы дигән сүз. Шул ук көнне безнең Утыз бишенче корпус Ольса елгасын кичеп чыга. 41 нче корпус та Березинага килеп житә, елга аша узып, плацдарм булдыра, 8 нче танк корпусы белән берлектә дошманның үзен чолганышта калдырып, юк итә.

Һөҗүмнең алтынчы көнендә безнең гаскәрләр биш меңнән артык әсирне кулга төшереп, бик күп трофейлар алып, уңышлы рәвештә алга баруларын дәвам иттерәләр.

Гитлерчылар хәзер үлем дәһшәтендә көйриләр, алар барлык кабахәтлекләргә, хәйлә-мәкергә баралар. Кырык беренче корпусның бер частендә, мәсәлән, менә нинди хәл була. Бер немец батальоны күренә. Ул алда баручы солдатына ак әләм тоттырган, янәсе, алар әсир төшәләр. Алар шулай бу эшнең ихласлыгына ышанган солдатлар янына бөтенләй якынлашалар һәм кинәт ут ачалар.

Безнең армиянең һөҗүме Минск шәһәренә барып житү белән тәгәлләнде. Армиябезнең частьларе бу һөҗүмдә Минскиның көньяк-көнчыгышын азат иттеләр.

Инде үзем турында. Минем армиянең ярдәмче хуҗалыгына шундый вакытта килеп урнашуым әз генә дә күңелемә хуш килми. Юк, юк, мин бередә яшәү белән һич тә килешә алмыйм. Бәлки, минем хезмәтем монда да кирәктер. Әмма барыбер мин моңа риза түгел. Әйе, әйе, мин башкарган эшне бөтенләй белгеч булмаган кеше дә үти алачак монда. Инде һич югында элекке ветфельшерлык хезмәтемне теләсә кем башкара алмый иде. Мин анда кечкенә генә булса да бер белгеч идем. Ә монда?

Мин бу хуҗалыкта ике атна чамасы эшләгәннән соң түзмәдем, полковник Зенкевичка аңлатма хат язып салдым. Аның караламасы миндә сакланган. Менә аның татарчага тәрҗемәсе:

«Ветеринария өлкән сержанты Расулев А. К. дан. 19.06.44

3 нче Армиянең Ветотдел начальнигы полковник Зенкевичка

## Аңлатма хат

Сез жибәргән хуҗалыкка килеп эшли башлагач, мин сездән түбәнчелек белән үземне элекке белгечлегем буенча хәрәкәттәге армия частьларының берәрсенә күчерүегезне үтенәм. Бу хуҗалыкта зоотехник бар, минем бирегә килүем — ул штаттан тыш хезмәткәр арттыру гына. Минем зоотехник буларак монда бөтенләй кирәгем булмаса да, күрәсең, командование артык кеше зарар итмәс, дип гамәл кылгандыр. Мин хәзер 19 баш сыеры (шул исәптән аның тугызы брак), 280 баш сарыгы булган бер участокта.

Сезнең мөрәҗәгать итәргә мине асылда фронт тормышыннан аерылуым, аны якынча гына булса да күзәтә алмавым мәҗбүр итә. Сезгә мәгълүмдер, мин СССР Язучылар берлеге әгъзасы, соңгы көннәрдә даими рәвештә татар журналында басылам һәм билгеле бер популярлык белән файдаланам. Бәлки, бу тыйнаксызлыктыр, әмма мин бу юлы Сезгә кече хәрби фельдшер буларак түгел, язучы буларак мөрәҗәгать итәм. Чөнки миңа, соңгы ихтыяж кушмаганда, тылда «кызынып» яту кулай түгел.

Миңа ярдәм итүегезне бик үтенеп, в. х. өлкән сержанты: А. Расулев».

Мин ерак тылда. Безнең Өченче армия гаскәрләре исә һаман һөҗүм итәләр, алга баралар. Мин бераздан соң беләчәкмен: 8 июльдә дошман кулыннан торак пунктларын тартып алганда безнең армиянең Ике йөз алтмыш тугызынчы укчы дивизиясе аеруча зур батырлыклар күрсәтә. Ул бер көн эчендә алтмыш биш километр юл үтә, күп авылларны азат итә, зур бер күперне кулга төшерә.

10 июльдә тылыбызда камалып калган дошман төркемнәре тар-мар ителә. Унҗиде көн дәвам иткән һөҗүм вакытында безнең армия 350 километр җир үтә. Березина һәм Неман елгаларын кичә, күрше армияләр белән берлектә Бобруйск һәм Минск шәһәрләрен азат итә.

Мин бу яңа хезмәт урыныңмдагы үземнең ярдәмчем Захаровны бер да онытмам, ахры. Моңарчы миңа андый да житез, унган кешеләрне еш очратырга туры килмәде. Әйткәнемчә, бик ябык, бик аз ашый, әмма барысына да өлгерә, армый-талмый эшли. Алай гына да түгел, үзе ифрат акыллы. Аның какча чырае, барысын да аңлый торган кара озын керфекле зәңгәрсу-соры күзләре әле дә минем күз алдымда.

Без аның белән эшкә ялланган авыл хатыннарыннан сыерлар саудырабыз. Һәр көн өч тапкыр бидоннарга тутырып сөтне үзәк утарга озатабыз. Көтүлекләрдә булабыз, көтүчеләрнең эшен тикшерәбез, унбиш көнгә бер симертүдәге үгезләрне үлчибез, кирәк булган саен, сугымга яраклыларын сайлап, үзәк утарга җибәрәбез.

Эш күп. Җитмәсә бервакыт безнең сарык көтүенә ач бүреләр ияләште. Инде төнлә утарга кереп өч сарыгыбызны ертып та ташлады алар. Мин сарыклар камалган киртә янына үземә окоп казыдым. Төне буе бүре сагалыйм. Юк, тидерә алмадым каһәргә. Күрүен күрдем. Офык яктысында ул чак-чак карачкыл булып хәрәкәтләнде, тагаен сарыкларга таба шуыша. Мин түзмәдем, карабинымнан атып җибәрдем. Икенче көнне, яктыргач, Захаров белән карап йөрибез. Бүре килгән, монысы хак. Чөнки сөрелгән җирдә аның эзләре күренә. Бүрегә тидереп булмады, монысы да хак, тик шулай да ерткычлар моннан соң төнлә безнең сарыкларга тими башладылар.

Мин көндәлек эш белән мавыгам. Шулай да күңелем тыныч түгел. Үземне кемнәр каршындадыр гаепле сыман тоям. Кемнәр алдында соң? Мәгълүм инде, алгы сызыктагы кан коеп сугышучылар алдында. Начвтармга хат җибәргәнгә күпме вакыт узды инде, бернинди дә җавап юк. Гаҗәп, ни өчен юк ул?

Армия хуҗалыгында ике ай чамасы эшлим инде. Күңелем һаман тыныч түгел. Яңадан бер тамчы өстәлсә, мин мотлак моннан китү өчен хәлиткеч бер адым ясаячакмын. Һәм көннәрдән бер көнне андый адым ясау өчен саллы бер сәбәп тә табылды.

Миңа үзәк утарда яшәүче хуҗалыкның баш зоотехнигыннан язу китереп тоттырдылар. Ул миңа шушы язуны бирүче аша бер ящик алма җибәрүен (ә үзәк утарда алма бакчалары бар иде) һәм бүләккә бүләк рәвешендә миннән сарык йоны җибәрүемне сораган. Янәсе, син сарык кыркытасың, ә минем эвакуациядә хатын, бала-чагаларым интегә, зинһар, булыш миңа, дүрт пар киез итеклек йон җибәр!

Бу мине тетрәтте генә түгел, хәтта җен ачуларымны чыгарды. Мин ул тыл күсесенең алмасын алмадым. Ләкин йон җибәрмәдем. Әмма шул ук көнне хуҗалык начальнигына доклад яздым. Аның каралмасы шулай ук миндә сакланган булып чыкты. Менә аның тәрҗемәсе:

«Ветхезмәт өлкән сержанты
Расулов А. К дан, 2.08.44

Ярдәмчел хуҗалык начальнигы
капитан Шевченкога

## Аңлатма

Ватан сугышы фронтларында Бөтендөнья күләмендә тарихи әһәмияткә ия вакыйгалар бара. Хәлбуки, мин, СССР Язучылар берлеге члены,

ике ел буена милли матбугатта актив каткашкан кеше, ерак тылга әләгү аркасында миннән яңа хикәяләр, очерклар көткән укучыма Кызыл армиянең бөек һөҗүме турында берни дә яза алмыйм.
Мине яңадан 3 нче армиянең Ветотделына командировать итүегезне, шуның белән миңа, үз белгечлегем буенча, сугышчан подразделениегә эләгү мөмкинлеге тудыруыгызны үтенәм.
Минем үтенечемне кире какмассыз дип ышанам.
А. Расулев (А. Расих)».

Бәхеткә күрә, соңгы вакытта безнең хуҗалыкның үзәк утарында солдат агай-энене еш-еш комиссия аша уздырып торалар, һәм әз генә яраклы табылса да, аны фронтка озаталар. Хәтерем ялгышмаса, мин хуҗалык башлыгының резолюциясен дә көтеп тормадым. Шул медицина комиссиясен уздым да, барлык хуҗалыкны Захаровка акт белән тапшырып, китеп тә бардым.
Менә мин юлда. Юлаучы машиналарга утырып бер көн генә бармыйм, бер ил чиген генә дә узмыйм. Менә, ниһаять, Өченче армиянең тыл учреждениеләре урнашкан авылда мин. Ветотдел. Мине полковник Зенкевич дусларча бик үз итеп каршы ала. Корсакка төртеп куя.
— Нәрсә, тылда симереп яту ошамадымыни сиңа?
— Юк,— дим,— мине дивизиягә җибәрегез.
— Хәзергә әле ЭВЛыңа кайтып тор. Шунысын да бел, мин сине әллә кая җибәрмим. Синең миңа теләсә кайсы вакытта керәгең чыгуы бар.

«18.09.44 (28.9 алдым)
Сөеклеләрем әни, әти, Суфия апа!
Ялкынлы сәламнәрдән соң, үземнең исән-саулыгымны белдерәм. Бу хатны тагын яңа җирдән язам. Кәҗә тәкәләрен ташлап, яңадан «өйгә» кайттым. Кайтсам, анда зур үзгәрешләр булган икән, иске дусларның берничәсе киткән, яңа кешеләр килгән. Шулай да берничә дус калган әле. Бу җирләргә килеп җитү өчен миңа өч көн йөк машинасында тирбәлергә туры килде. Ике чикне (хәтта өчне) уздым. Ниһаять, Польша җиренә килеп чыктым. Хәзер инде поляк телен генә өйрәнәсе калды, аннан Казанга бикәч итеп поляк кызын алып кайтырга була.
Сезнең якларда нинди яңалыклар бар? Укулар башлангандыр инде. Монда бер кеше белән сөйләшкән идем, әгәр мөмкин булса, «Батырлар китабы»на бер әйбер язып җибәрермен әле. Ялкынлы сәлам белән, сезне сагынып калучы: Атилла».

Тиздән мине тагын Ветотделга чакырдылар һәм трофейлар җыю батальонына җибәрделәр.

Без һаман алга барабыз. 6 сентябрьдә безнең армия Нарев елгасына җитте, Остроленко шәһәрен алды, тик елганы кичә алмады. Бу операция иртәгегә көнгә калдырылды, аннан сигезенә күчерелде. Бу эш яхшырак әзерләнү өчен күчерелә торгач, 1 октябрьгә кадәр сузыла. Уникеләрендә безгә өстәмә көчләр килә башлады. Алар арасында кичәге партизаннар, госпитальләрдән савыгып кайтучылар, дошман тылында калган ирләр һәм әле яңа мобилизацияләнгән яшьләр.
7 сентябрь көнне Югары башкомандующий тарафыннан безгә Остроленко шәһәре өчен рәхмәт белдерелде. Хәзер безнең фронт командующие — армия генералы Г. Ф. Захаров.
Сентябрь аенда безнең армия сафлары уналты мең кешегә арткан. Ай башында ук безнең сул күршебез Кырык сигезенче армия гаскәрләре тарафыннан Наревның аръягында плацдарм булдырылган. Фронт штабының кушуы буенча сентябрьдә ул плацдармның өчтән ике өлеше безнең армиягә тапшырыла. Безнең гаскәрләр 6 октябрь төнендә шул

плацдармга барып урнашалар. Бу киләчәк һөҗүм өчен әзерлек йөзеннән эшләнә.

«21.10.44

Сөеклеләрем әни, әти һәм Суфия апа!

Яңа урынга урнашканнан соң, сездән бер хат та алмаган булсам да, сез исәндер дигән ышаныч белән тагын хат язарга утырдым. Үземнең тормышымда әйтерлек үзгәрешләр юк. Хәзер инде яңа хәлләргә иялəшəм бугай. Хезмәтем элеккечә, авыр түгел. Сездән хат алмауны, сезнең хәлəхвəлне белмәүне исәпкә алмасам, минем тормыш зарланырлык түгел.

Хәзер монда да яңгырлар ешайды. Көннәр салкын булмаса да, юешлек аның ямен җибәрә. Моннан элекке хатымда язганча, мин Казанга «П» дигән хикәя җибәргән идем. Бу арада бер дә кыймылдаганым юк. Беркемнән дә хат килми. Озын итеп бер хат язгыгыз әле. Ничек яшисез? Һич булмаса, кышлык утын әзерли алдыгызмы? Союзның аз-маз булса да ярдәмен күрәсезме? Шулай итеп, дүртенче кышны каршылыйбыз. Юк, бу дүртенче кышта канэчкеч дошманның эшен бетерергә кирәк. Югыйсә бик озакка китте.

Тагын ниләр языйм? Бер иптәшем гөмбә әрчи, икенчесе Ванда белән әңгәмә сата. Әле генә эштән бушап, гөмбә кыздырырга булдык. Мин тәрәзә каршында утырып сезгә хат язам. Тәрәзәдән иген кырлары күренә. Әнә бер пан, дугасыз җиккән атында, чиксез озын арбасына бәрәңге төяп безнең турыдан уза. Монда да явыз дошман бик күп бәла-казалар ясаган. Исән калган өйләр сирәк очрый.

Ялкынлы сәлам белән, сезне сагынып: Атилла».

«17.11.44 (алдым 1.XII)

Кыйммәтлеләрем әни, әти һәм Суфия апа!

Башта йөзләрегездән үбеп, ялкынлы сәламнәремне җибәрәм. Хәзер күңелем почмакланды, сездән әнинең хатларын тәртипле рәвештә ала башладым.

Әле бу араларда командировкада булу аркасында, сезнең беренче хатыгызны үз вакытында укымадым. Кайтуыма алар җыелып, мине көтеп зар җылыйлар иде. Соңгы хатка караганда, әти больницада ята икән. Табигый, мине беренче чиратта кызыксындырган нәрсә — аның сәламәтлеге. Мин үземне тынычландыру өчен һәр нәрсәне яхшыга юрарга яратам. Бәхетемә, моңарчы ул чынбарлыкка туры килеп торды. Бу юлы да әти больницадан савыгып чыккандыр дип юрыйм.

Әни, синең, үземне яхшы сизәм дип язуың, минем өчен шатлыклы хәбәр булды. Зинһар үзеңне саклый күр, берүк авыруың кабатланмасын.

Суфия апа да Казан мәшәкатьләренә күнегеп килә икән. Бу да күңелле нәрсә. Үземнең көндәлек тормышымда үзгәрешләр юк. Польшада кыш бик соңарып килә дигәннәр иде, юк сүз, ахры. Төшкән кар кичәдән бирле тырышып-тырмашып җирдә ята. Әле кичке сигез, суык җирне катыра башлады инде. Шулай кыш булуы да мөмкин.

Әле бу көннәрдә безнең фронт газетасында хезмәт итүче яшь талантлы шагыйрь Ш. Мөдәрристән хат алдым. Ул үзенең бик җылы язылган хатында миңа комплементлар ясаганнан соң, минем белән күрешергә теләвен белдерә. Хатына караганда, ул бик ягымлы һәм тыйнак егет.

Казанда нинди яңалыклар бар? Шакир, Рахман абыйларга, Фатыйма, Сәү апаларга, энекәшләремә һәм башка туганнарга миннән ялкынлы сәламнәр тапшырыгыз.

Исәнлектә күрешүне теләп: Атилла».

* * *

Шулай итеп, мин тагын яңа урында хезмәт итәм. Дөресен генә әйткәндә, үземнең тагын сугышчан частька эләкмәвемә канәгатьсезлегү

хисләре кичерәм. Әмма армия законнары каты. Анда бәхәсләшеп, начальствога каршы килеп, сатулашып, үҗәтләнеп булмый. Сиңа приказ бирәләр — син үтисең! Бетте китте. Шуңа күрә мин үземнең эчке яшерен тойгыларымны артык тышка чыгара алмадым.

Ләкин тора-бара, беренче тапкыр ишеткәндә исеме бик ямьсез тоелган трофей батальонының эшләре, мин уйлаганча ук, тирән тылда бармый икән. Ул, баскан-күрсәң, эшен алгы, һөҗүм итүче гаскәрләр белән бик еш очракта бергә атлап башкара икән.

Батальонның үзенә күрә кечкенә генә ветбүлекчәсе бар. Анда лейтенант дәрәҗәсендәге ветфельдшер һәм минем белән тагын ике кече ветфельдшер хезмәт итә. Безнең башлыгыбыз да урта мәгълүматлы өлкән лейтенант. Без транспорт ротасына беркетелгән, әмма, кирәккәндә, башка роталарга да хезмәт күрсәтәбез. Кыскасы, батальонның олау хуҗалыгы һәм сугымга китә торган маллары безнең карамакта.

Гужтранспорт ротасының командиры Талипов дигән казакъ егете. Эш минем монда да мантый. Тирә-юнемдәге егетләр белән бик тиз дуслаштым. Шул ук өлкән лейтенант рота командиры Талиповны әйтәсеңме, яки мин беркетелгән взвод командиры сөйкемле һәм мәнле Ковешниковны аласыңмы... Алар белән без беренче очрашуда ук берберебезгә якынайдык. Хәер, башта корырак күренгән безнең кәкре аяклы башлыгыбыз Никулин белән без бераз сынашкандай дистанция саклап маташтык. Ләкин ул алай озакка сузылмады, тиздән без аның белән дә һәм ябык чырайлы шадра лейтенант Симаков белән дә уртак тел таптык, бер беребезгә хөрмәт җепләре башладык.

Без, һөҗүмдәге армиябезнең үкчәсенә басып дигәндәй, һаман алга барабыз. Әледән-әле мине Ветотделда да искә төшерәләр. Отчет тәзисе булса, миңа чакыру килеп төшә. Ләкин төп эшем атлар дәвалау. Кулга төшкән трофей атларны тикшереп диагноз кую, төрле профилактик чаралар күрү. Әйе, аннан язу. Мин һәр буш вакытымнан файдаланып хикәя, новелла язарга тырышам.

Хәзер минем «Фронт хакыйкате» газетасы белән дә бәйләнеш ныгыды. Минем өчен якында гына үзебезнең телдә газета чыгуы, анда мине белгән якын әдәбиятчыларның булуы әйтеп бетергесез зур шатлык.

Бу бәйләнеш миңа ничек башланды. Көннәрдән беркөнне минем кулыма очраклы рәвештә үзебезнең фронтта чыгып килгән татар телендәге «Фронт хакыйкате» газетасы килеп эләкте. Аны йотлыгып укыганнан соң, озын-озак уйламастан, редакциягә хат җибәрдем. Янәсе, дуслар, мин монда, сездән еракта түгел. Бәхеткә күрә, тиз арада газетадан җылы бер хат та алдым. Ниһаять, мин аларның редакцияләрендә дә булдым. Алар белән рәхәтләнеп сөйләштем, берничә төнне алар белән үзебезнең татар әдәбияты, аның киләчәге, бүгенгесе турында кызык, татлы әңгәмәләр эчендә йөздем. Хәер, бу турыда минем озын барышлый гына әйтәсем килми. Бу вакытлар — минем фронт тормышымда бик кадерле, эчтән җылынып, җиңелчә елмаеп искә алырлык гүзәл хатирә.

Ә хәзер мин үземнең нинди батальонга килеп эләгүем, ул ниләр кыйрата дигән сорауга җавап бирмәкче булам. Моның өчен бераз алгарак китәргә туры килер. Миңа сугыш беткәч, әле армиядән демобилизацияләнгәнче, трофей батальонының тарихын язарга туры килде. Әлбәттә, бу эшкә үзлегемнән керешмәдем, моны командование кушты миңа. Бу эшкә керешкәнче, штаб башлыгы белән без материал тупладык, ул эш тәгәлләнгәч, мин язарга тотындым. Бәхеткә, ул язманың карамасы миндә сакланган. Кирәге чыккан саен мин ул язмадан файдаланырмын.

Трофейчылар батальонында хезмәт иткәндәге истәлекле очрашуларымны мәңге онытасым юк. Мин фронт шартларында үзебезнең татар язучылары белән «Фронт хакыйкате» газетасы оештырган очрашуны күздә тотам. Польша җирләренең карсыз кышкы көннәренең берсендә мин атлар дәвалап маташканда янымa рота командирыннан вестовой йөгереп килде.

— Сержант, хәзер үк сиңа ротный янына барырга!
— Нигә, ни булган?
— Анысын баргач белерсең. Өлкән лейтенант сине бик тиз алып килергә кушты.
Солдат, артык бер сүз дә әйтмәстән кискен рәвештә борылды да, арбалар, атлар торган иркен ишегалдыннан чыгып та китте.
Бармый булмый. Мин, арбага басып, авыру атның ашказанына борын тишеге аша катетер белән дару агыза идем. Эшемне төгәлләдем дә, атны хуҗасына тапшырып рота командиры урнашкан өйгә йөгердем.
Барып кергән шәпкә өй эчендә минем күзгә ул-бу чалынмады, мин тизрәк, хәрби кагыйдә буенча, үземнең килүем турында Талиповка доклад ясыйм.
Өлкән лейтенант ни өчендер миңа карап елмая. Ул да булмады, артымда гына кемдер ахахайлап көлеп тә җибәрде. Әйләнеп карасам, ни күрим, ишек янындагы караңгы почмакта әле мин узган елны гына Казанда очраткан яшь драматург Гамир Насыйрый утыра. Ләкин аның ни өчендер иңбашларын хәзер мин күргән путалы лейтенант погоннары урынына, гади яшел төстәге старшина погоннары гына бизи. Димәк, Казан өчен генә булган икән теге путалы лейтенант погоннары.
Гамир утырган урыныннан сикереп торды да минем янга килеп мине кочаклап алды. Ниһаять, без утырыштык. Ул үзенең «Фронт хакыйкате» корреспонденты булуын, хәзер мине чакыра килгәнлеген, редакциядә шушы якын арада татар язучылары өчен бер мөһим җыелыш-очрашу булачагын һәм минем анда мотлак булырга тиешлегем турында әйтте.
— Нинди җыелыш?— дидем мин аптырый төшеп.
— Баргач күрерсең,— диде Гамир. Ул тагын үзенә генә хас шаркылдавы белән бөтен бүлмәне яңгыратты. Безнең фронтта татар халкының шактый күренекле кешеләре булуын, язучылар, хәтта рәссамнар да барлыгын әйтте. Алар барысы да билгеләнгән көнгә газета идарәсенә чакырылачак. Гамир, безнең рота командиры белән сөйләшеп, аның ризалыгын алган икән инде. Мин аны үземә чакырсам да, ул артык тоткарлана алмавын әйтте. Әле керәсе җирләрем җитәрлек, дип, тиз арада китеп тә барды.
Гамирның чакыра килүе минем өчен искиткеч бер шатлыклы вакыйга иде. Берничә көн узгач, Талипов миңа, ат җиктереп, үзем белән бер олаучы алып редакциягә барырга рөхсәт бирде. Батальон штабына редакциядән шалтыратканнар, мине очрашуга җибәрүләрен үтенгәннәр.
Менә мин пар ат җигелгән такта әрҗәле бричканың түр башында Польшаның комлы юллары буйлап редакциягә кунакка барам. Бездән ул утыз километрлар чамасы арада булырга тиеш. Ат башында, дилбегә тотып, бик аз сүзле карт солдат утыра. Атлар бер җайга юырталар. Тирә-юньдә ямь-яшел булып сераделла кырлары безгә иярә. Алар тып-тын манзарага ниндидер язгы бәйрәм тантанасы бирәләр кебек. Ул да булмый, күңелле яшеллек көрән люпин басулары белән алмашына. Беләм, бу басуларда куян бик күп. Әле безне күргәч, юл читендә кояшта җылынып яткан куяннар корыган люпин сабакларын кыштырдатып үлән чытырманына кереп югалдылар. Ирексездән «һайт» дип кычкырып куябыз. Ә күңел шул куяннар кызулыгында алга чабарга теләп ашкына...
Бераздан без асфальтланган олы юлга чыктык. Салам яки чүлмәк түбәле җиңел материаллардан салынган фәкыйрь өйләр безне озата бара хәзер — авыл аша узабыз. Тагын бушлык. Аннан сыек кына агачлык башлана. Юл чатларында моңсу тәре баганалары безгә карап кала. Хач канатларына озын чәчле, сакаллы шәрә яһүд сынын кадаклаганнар. Анысы Гайсә пәйгамбәр. Әйтергә кирәк, поляк халкы ифрат динле икән. Минемчә, аның бу үзенчәлеге мөстәкыйльлек өчен көрәштә диннән файдаланып, ныграк оешырга теләвеннән килә.

Менә без тагын агачлыкка килеп кердек. Яфраклы урман бераздан соң безне озата баруны нарат урманына тапшыра. Наратлар яшь, ләкин алар шактый куе утыртылган. Олы юл аша шул агачлыкка тимер юл тармагының кереп киткәнлеге күзгә чалынды. Димәк, без барырга тиешле редакция шунда, шул агачлыкта. Алар бит тимер юл составында, вагоннарга урнашкан, шунда ук яшиләр дә.

Чыннан да, без бераз баргач, агачлар арасында, бик эчтә, тупикка кертелеп куелган пассажир поезды составын күрдек. Мин шул турыга житү белән солдатка атларны туктатып, юлдан читкә чыгарырга, шунда мине көтәргә кушам. Үзем вагоннарга таба ашыгам. Состав тирәсендә хәрбиләр күренә. Белмәссең, бәлки берәрсе миңа жылы хатлар язган Шәрәф Мөдәррисләр әле. Ләкин ул юк. Болар — руслар, украинлылар. Мин, сорашып, татар редакциясенең кайсы вагонга урнашканлыгын бик тиз беләм. Мине якты чырай күрсәтеп, гомеребездә беренче тапкыр күрешүебез булса да, күптәнге дусты кебек якын күреп «Фронт хакыйкате» газетасының редактор урынбасары Гани Гыйльманов каршы ала. Әле редакция егетләре кайтып житмәгән икән. Хәзер, озакламый барысы да — Шәрәф тә, Гамир да, безнең карт журналистыбыз Абдулла Әхмәдиев тә кайтып житәрләр, ди Гыйльманов. Син жәяүләп кенә килдеңме? дип сорый. Мин ат белән килүемне әйттем. Әйдә, әйдә, хәзер үк атларыңны монда алып килик, ди ул. Без атлар янына таба юнәләбез. Бу очрашуга дивизия газетасында хезмәт итүче Хатип Госман да, зенит батареясыннан шагыйрь Нур Гайсин да, аннан тагын бер татар рәссамы да килергә тиеш әле, дип сөйләп бара миңа Гани абый.

Мин бәхет манарасының иң югары чәмәкәендә хәзер. Димәк озакламый, әле үзләре белән шәхсән таныш булмасам да, язучы буларак, якын каләмдәшләрем белән туйганчы сөйләшә, рәхәтләнеп туарылып урталаша, фикер алыша алам икән. Болай булгач, моннан да күңеллерәк әйбернең булуы мөмкинме минем өчен?

Без Гани абый белән вагон купесында сөйләшеп утырган арада Шәрәф Мөдәррис кайтып керде. Мин шигырьләрен һәм үземә язган хатларын укып, аның ниндиерәк кыяфәттәге кеше булырга тиешлеген күз алдына китерергә тырышкан идем. Әмма күңелдә туган шагыйрьгә Шәрәф әз генә дә охшамаган булып чыкты. Ул чынлыкта бик дорфа, төрткеле, төскә дә сәнгать әһеленнән бигрәк, авыр физик хезмәт белән яшәүчегә охшаган бер зат икән. Ул, сүз башлану белән, минем кайбер жөмләләремә рус сүзләре кыстырып жибәрүемә бәйләнде. Янәсе, мин үзем татар язучысы, ә телне бозам. Кем турындадыр сүз чыккач, ул миңа билгесез кешене авыз тутырып «сволочь» дип хурлады. Юк, юк, гүзәл шигырьләр яза торган, миңа жылы хатлар жибәреп торган Шәрәфне мин һич мондый кешедер дип уйламаган идем!

Ләкин гажәп бер метаморфоза. Әкренләп Шәрәфнең кыяфәте үзгәрә башлагандай булды. Аның жәенке ямьсез борыны да, саргайган тешләр белән тулган зур авызы да тойгыны жәберләми башлады. Бары аның озын керфекле, ниндидер моңлы карый торган күзләре генә игътибарны жәлеп итте. Ихлас күңелдән әйтәм, мин аның кытыршы, коршаиган кабык астына яшеренгән нәфис, бик тиз яралганучан, шәфкатьле жанын күрдем.

Без аның белән бераздан күптәнге дусларча сөйләшә идек инде. Ул үзенең бер чуен баш капитан белән низагка килүе аркасында штраф батальонында яралануы госпитальдә ятуын сөйләде, мин исә үземнең немец кулында берничә көн әсирлектә булып, аннан исән-сау качып котылуымны әйттем. Сүз шул турыга житкәч, ул ялт-йолт тирә-ягына каранып алды.

— Син моны, Атилла дустым, башкаларга сөйләп йөрмә инде,— диде ул.

Әйе, мондый сүзне миңа Казанда да әйткәннәр иде. Нишлисең, хаклы иде алар. Заманасы шундый.

Карангы төшкәндә, киләсе кешеләр җыелып бетте. Беренче булып төз гәүдәле, пеләш башлы Гамир күренде. Дивизиясеннән Хатип Госман, зенит батареясеннән Нур Гайсин килеп төште. Кызганычка, теге татар рәссамын очрата алмаганнар. Соңрак, безнең гәп кызгач, бездән олы, төксе кыяфәттәге буйдак журналист Габдулла Әхмәдиев тә купега килеп керде.

Кыскасы, әлеге рәссамны исәпкә алмаганда, шуның белән килергә тиешле кешеләр барысы да җыелды.

Хатип Госман белән Нур Гайсинны да минем беренче күрүем иде. Беренче күрүдә үк Хатип миңа үзенең мөлаемлыгы, акыллылыгы, хәтта үзенең нечкә тавыш белән шаркылдамыйча гына хихилап көлүе белән ошады. Ул минем белән күрешкәндә, син шундыйдыр дип уйлаган идем, дип куйды. Мин үзенә абый дип дәшкәч, җиңелчә ачуланып та алды. Язучылар арасында абый дип дәшү юк, Хатип кына дип ата, диде. Гайсин исә бик мәзәк кеше булып чыкты, ул сүзгә бик аз катнашса да, үзенең беркатлы, самими икәнлеген беренче очрашуда ук сиздерде.

Менә без барыбыз да бер купеда утырабыз. Күңелле сөйләшү. Әдәбият дөньясын иптәшләрем миннән күбрәк беләләр. Сүз журналда басылып чыккан әсәрләр турында бара. Гадел Кутуйның «Рөстәм мажаралары» һәм башка нәрсәләр турында да һәркем үз фикерен әйтергә ашыга. Әңгәмә дулкыны бер ярдан икенчесенә күчә. Фронт хәлләре турында сүз башлана, аннан фронтларда ут арасында дары исе сулап йөргән татар язучылары язмышына кагыла. Хәтердә: сүз Муса Җәлил турында да булды. Шәрәфнең ачынып аның дошманга сатылган диган хәбәрне сөйләгәне әле дә хәтердә. Әйе, әйе, бу минем өчен дә коточкыч югалту иде. Чөнки минем әдәбиятка керүемдә Мусаның тоткан урыны, үземчә, бик зур. Ул минем беренче хикәямне Мәскәү журналында басты, ул минем иҗатым турында беренче булып җылы сүзләр әйтте. Әгәр инде ул, чыннан да, шулай дошманга сатылган булса, бу бик нык аянычлы хәл.

Мин шул әңгәмә вакытында Дәүли белән Алишның да юкка чыкканлыгын беренче тапкыр ишеттем. Алиш та минем өчен бик кадерле кеше. Инде Нәби Дәүлигә килгәндә, мин бу шагыйрьне дә белә идем. Ул әлбәттә, безнең кебек әдәбият тирәсендәге вак-төякләр белән алай ваклнмый иде. Башына кырын гына салып кубанка бүреген кияр, урамда очратып сәлам бирсәң, сиңа борыла төшеп күзләрен генә йомып ачар. Дәүлинең мин белгәндә бик текә күтәрелә башлаган чагы иде. Бер җыелышта аны мактап һәм яклап Хәсән Туфанның чыгыш ясаганын мин бик ачык хәтерлим.

Без ул кичне күңелле әңгәмә белән мавыгып бик озак утырдык. Икенче көнне вагонда озаклап минем «Сагынылган мәхәббәт» исемле хикәямне тикшердек. Хәер, бераз ялгышам, хикәя тикшергәнгә кадәр фронт штабыннан килгән бер татар майоры безгә Үзәк Комитетның Нәкый Исәнбәт җыеп бастырган «Идегәй» эпосы турындагы карарын, ул эпосның зарарлы нәрсә икәнен аңлатты. Ул көн шулай да бетмәс-төкәнмәс сөйләшүләр, фикер алышулар белән узды.

Кичен без барыбыз да үзбәк редакциясе оештырган зур тантаналы мәҗлескә чакырулы идек, шунда булдык. Үзбәгстанның ниндидер республика бәйрәме иде булса кирәк. Мәҗлесебез доклад сөйләгән салонда булды. Мин анда вагон буена сузылган өстәлләрдәге сый-нигъмәткә хәйран калдым. Тәмле пылау да, өрек тә, җимеш тә барысы да бар иде. Үзбәк үзенең миһманпәрвәрлеген кайда да күрсәтә белә!

Хәтердә яхшы сакланган, мәҗлеснең икенче бүлегендә (шулай әйтергә яраса) үзенең эреле-ваклы гармуннарында безнең Нур Гайсин чыгып концерт бирде. Әле бүген генә ул безгә зенит батареясына Ворошиловның килүе, үзенең аңа йөгереп барып доклад ясавы, чапканда сөртенеп егылып китүе турында сөйләгән иде. Мин аны шагыйрь һәм зенитчик дип кенә белә идем, кара син аны, ул менә дигән гармунчы да, имеш!

Шәрәф якындагы хәрби бүлекләрнең берсендә хезмәт итүче элемтәче дус кызы Римма белән янәшә утырды.

Банкет, күрәсең, артык озакка сузылмагандыр, чөнки мин кичен күршедәге еракка атучы туплар батареясе егетләренең землянкасында булуыбызны да хәтерлим. Анда да безне тупчылар яхшы гына сыйладылар. Әйе, шулкадәр әйбәт сыйландык ул көнне, безнең Нурыбыз вагонга кайткач, йоклау өчен башта чишенеп ятарга кирәклеген дә оныткан, ул элгечтәге шинельләргә төренеп, аягүрә йокыга киткән.

Ике төн узгач Талипов миңа атлар җибәрде. Мин яңа дусларым белән саубуллашып үзебезнең батальонга юл тоттым.

* * *

Бу күңелле очрашудан соң без Шәрәф белән бөтенләй якынайдык. Ул миңа еш кына хатлар җибәреп торды. Аларның дүрт-бишләбе миндә әле дә саклана. Мин исә дәртләнеп-канатланып «өйгә» кайткач, җиң сызганып, үзебезнең фронт газетасы өчен кыска хикәяләр, очерклар язу турында кайгырта башладым. Бер ике атнадан соң, мин аларның берничәсен Шәрәфкә җибәрдем. Шәрәф миңа җавап хаты язды. Менә ул:

«Расих!

Сиңа дусларча, туганнарча кайнар сәлам язам. Сиңа саулык-исәнлек һәм сугышчан эшеңдә уңышлар телим. Үзебез дә, аллага шөкер, исәнбез-саубыз. Һәм барысы да хәзергә үз көенә бара. Язган хатыңны алдым, сиңа моның өчен бик зур рәхмәт. Үзем 15 көн буена алгы сызыкта, командировкада йөрдем. Ә ул вакытта синнән хат һәм ике новелла килгән. Табигый ки, мин сиңа үз вакытында җавап яза алмадым, ышанам, син мине гафу итәрсең.

Новеллалар турында. Яхшы, бик яхшы әйберләр алар, Расих. Газета өчен, көндәлек матбугат өчен андый материал гаять кыйммәтле һәм кирәкле. Аннан битәр, гомумән, безнең әдәбиятыбыз өчен дә зур бер байлык алар. Ни өчен? Моңа син үзең дә җавап биргәнсең. Кабатлап тормыйм. Шигырьгә да минем карашым шундый. Солдат ниләр белән очраша, ниләр кичерә, көндәлек тормышында ниләр күрә, ниләр сизә — шуны язуны идеал итеп алдым. Беркадәр бу юлда эшләдем дә кебек. Ничек? Алла үзе хөкем итсен. Синең белән минем эш — язу.

Тагын бер тапкыр синең новеллалар турында. Оста һәм талантлы язылганнар. Кыска, җыйнак, гүзәл һәм саф тел.

Сугыш турында фронтта, гадәттә, шундый әйберләрне күбрәк һәм яхшырак язарга мөмкин. Повесть язуны мин авыррак дип саныйм. Синең караш ничектер. Ләкин бу кайчандыр мине сокландырган һәм әлегәчә вагы-тоягына кадәр онытылмаган «Ютазы егете»нә кагылмый.

Без синнән хәзер 20—25 чакрым җирдә. Озакламый очрашырбыз. «Кызлар»ны алгансың. 5 нче декабрьдә «Үлмәс йөрәк» басыла. Анысын да алырсың. Мин үзем хәзергә рәтле бернәрсә дә яза алмыйм. Бу кайчанга кадәр барыр, белмим. Ә хәзергә хуш, җаным. Сәлам, кабат сәлам белән: Шәрәф. 1/XII-44. Бель».

Әлбәттә, мәйдандашларымнан хатлар алу, җитмәсә Казандагы язучыларның да минем иҗат турында җылы-җылы фикерләре мине бик дәртләндерде. Һәм шундый көннәрнең берсендә минем «фронт хакыйкате» редакциясендәге утырышта макталган «Сагын алган мәхәббәт» исемле хикәямә карата Латыйф Җәләй аганың тәнкыйть мәкаләсе «Совет әдәбияты»нда басылды. Әйтергә кирәк, әгәр ул бүген басылган һәм минем тарафтан бүген укылган булса, мин тәнкыйтьчегә әз генә дә үпкәләмәгән булыр идем. Ләкин ул чакта мин әле үземнең иҗатым турында җылы сүздән башка берни ишетмәгән яшь бер кеше идем. Мин Латыйф ага мәкаләсен ифрат авыр кичердем. Янәсе, бу тәнкыйть түгел,

бу язучыны нахакка рәнҗетү. Әйе, минем ул көннәрдә хәтер калды. Канат каерылуын каерылмады, алай да мин язганнарыма үзем дә тәнкыйть күзе белән карый башладым. «Ай-һай ла, мин гади бер графоман түгелме соң?» — дигән уйлар да башка килгәләде. Фатих Хөснигә дә зарланып бер хат яздым. Әниемә дә үземнең ул тәнкыйть мәкаләсе белән һич килешмәвемне белдердем. Һай, дуамал, әз генә кул тидергәнгә дә каты авыртучан яшь калеб!

Шулай да көннәр һич төртелеп тормастан алга тәгәриләр. Без хәзер Польшаның Круле атлы бик фәкыйрь, әмма зур бер авылында яшибез. Мин взвод командиры Ковешников белән ике бүлмәле бер поляк өендә торам. Алгы якта иркен кухня, анда мич янына салам ташланган, шул саламда поляк бабае белән поляк әбисе яталар. Алар, немецтән качып, бу якларга килеп чыкканнар. Ләкин алар хәзер хәлсез, торып утырырлык та егәрләре калмаган. Алар түшәмгә тын гына карап көннәр буе чалкан яталар. Бабай русча сөйләшә белә. Ул кайчандыр патша солдаты булып, рус армиясендә хезмәт иткән. Әби исә бөтенләй өнсез. Ул бабайга беркем дә түгел. Юлда очрашканнар да бергәләп киткәннәр. Бабайның хәлләр мөшкел, ләкин ул әле бер дә бирешми, безнең белән сөйләшкәндә шаярткан да була, хәтта солдатта җырлаган җырларын да җырлап җибәрә. Берничә көннән соң әби вафат булды. Без уянганда аның мәетен чыптага төреп каберлеккә илткәннәр иде инде.

Бераздан безне тагы башка урынга күчерделәр. Мин Круле авылында «Бәхет орлыклары» исемле мажаралы повесть яза башлаган идем, кульъязмаларымны капчыкка салырга туры килде.

Казаннан минем өчен ифрат авыр бер хәбәр килеп төште. Шәүкәт энемнең фронтта үлеп калуы җитмәгән, аның әтисе, минем кадерле абыем Габдрахман абый да туберкулездан вафат булган. Бу миңа бик авыр тәэсир ясады.

Мин кайчандыр аларда берничә ай яшәп, аның канат астында дигәндәй Арча җидееллыгында укып яттым. Габдрахман (без барыбыз да аны Рахман абый дип йөрттек) абый турында минем алдарак бер язганым булса да, мин тагы өстәп әйтүдән тайчанмыйм. Ул чын мәгънәсендә хезмәт кешесе иде. Өч класслык белеме булган хәлдә, ул үзлегеннән укып, урта мәктәптә укытучы булырлык дәрәҗәгә җитә, аннан Казанда Мәгариф Комиссариаты инспекторы, соңыннан комиссариатның финанс бүлеге башлыгы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Алар, Казанга күчкәч, Достоевский урамындагы кечкенә генә бер флигельдә яшәделәр. Гаилә ишле, алган эш хаклары аз, җитми. Рахман абый эштән соң гына кайта. Ашык-пошык тамак ялгагач, бераз черем итеп ала да тәрҗемә эшенә, яки заказ буенча төрле темага брошюра язарга утыра. Һәм ярты төнгәчә, кайчак таң беленгәнгә кадәр шулай эшләп утыра.

Мин аның аттай эшли алуына шаккаты идем. Аннан тагы бер үзенчәлеге истә калган, мендәргә башы тию белән ул, җиңелчә гырлап, йокыга тала һәм нәкъ үзе билгеләгән вакыт җиткәч, уяныл эшкә керешә иде.

Декабрь азакларында безнең армия фронт штабыннан ашыгыч күрсәтмә ала. Анда дошманга каршы һөҗүм ачып, җиде километрлы полосада аның оборонасын өзү һәм дошманны куу бурычы куелган була.

Мин хезмәт иткән батальон кырык бишенче елның башында Көнчыгыш Пруссия чигендә иде инде. Армиябезнең, бүген булмаса иртәгә, дошман җирләренә бәреп керәчәге барыбызга да ачык. Алдагы куаныч һәм билгесезлеккә өртелгән тантаналы көннәр сулышы күңелләрне җилкендерә.

Без Көнчыгыш Пруссиянең Герман сугыш чукмарлары өчен бик җайлы плацдарм булганлыгын яхшы беләбез. Чөнки ул төбәк Көнчыгыш Европага, хәнҗәрдәй, кадалып тора. Ул шулай ук, Икенче Бөтендөнья сугышын башлап, Польша җирләренә шул ук Көнчыгыш Пруссиядән керә, ә ике елдан соң шуннан ук безнең илгә хаиннарча һөҗүм итә.

Без соңыннан кырык дүртенче елга кадәр Гитлерның «Бүре өне» дип аталган (Вольфшенца) баш ставкасы шунда, Ростенбург шәһәре янында булганлыгын беләчәкбез.

Безгә тагы шулар мәгълүм булачак: безнең һөҗүм башланыр алдыннан фашистлар Көнчыгыш Пруссиядә коточкыч зур көч туплаган булганнар. Анда 780 мең гаскәре әзер булып торган, алар кулында 8200 туп һәм миномет, 7000 танк, 775 самолет булган.

Без әлегә блиндажларда яшибез. Өстенә кат-кат бүрәнә салынган тәбәнәк җир өй һәм балчык сәке. Бу инде тәгаен безнең алга баручы укчылар тарафыннан ашыгыч кына ясалган корылмадыр. Без инде мондый җир асты сарайларының ниндиләрендә генә тормадык та, ниндиләрен генә күрмәдек.

Дошман блиндажларында да күп тапкырлар булдык. Белоруссиядә булса кирәк, без бер немец генералы яшәгән блиндажда кунып чыктык. Немец пөхтәлеген инкарь итеп булмый. Зур хәрби түрә өчен казылган блиндаж стильләштерелгән үзенә күрә архитектура җимеше иде. Аның эчендә барлык мебель тузы кубарылмаган каеннан ясалган. Ак каеннан ясалган креслолар, өстәл һәм утыргычлар. Карават та шундый ук. Немец һәркайда комфорт ярата.

Без урнашкан хәзерге блиндаж исә артык гади, үзебезчә гади, әмма нык, түземле. Без шул блиндажда. Ниһаять, менә зарыгып көткән көн дә килеп җитте. Без иртәгә таң белән юлга чыгып, Германия җирләренә, Көнчыгыш Пруссиягә үтәчәкбез.

Кичә көне буе олы юлдан башкорт кавалерия бригадасының төньякка таба узуы юкка гына булмаган икән. Алар безнең алдыбыздагы олы юлдан бардылар. Карабин мылтыклар, кылычлар белән коралланган егетләр ат өстендә җиңелчә чайкалып, эскадроннарга бүленеп баралар. Пулеметларын артка караткан тачанкалар кылтырый. Димәк, дошман җирләренә алар башта кереп китәчәк, алар артыннан без барачакбыз.

Кичен үзем беркетелгән взводта митинг сыман бер тантаналы җыелыш уздырабыз. Взвод командирыбыз, ифрат мөлаем, әле сугышка ун класс һәм кыска сроклы хәрби курс тәмамлап кына килгән кече лейтенант Ковешников, иртәгә безнең нинди тәртиптә дошман җирләренә аяк басачагыбыз турында аңлатты. Намусыгыз ни рөхсәт итсә, шуны эшли аласыз, ди. Бу Югары командование рөхсәте. Дүрт ел буена туган илебезне кан һәм күз яшенә батырган кабахәт дошманнан үч алу минутлары җитте, ди. Кыюрак солдатлар, шул җөмләдән мин дә алга чыгып сөйлибез. Кайберәүләр үз кичерешләрен сөйләп күз яшенә буыла, үксеп сәкегә ава, кайберсе йодрык төйнәп кулларын селки-селки дошманга ләгънәтләр укый. Кыскасы, мин моңарчы күрмәгән экстаз халәте. Безнең солдатларның дошманга булган нәфрәте шул рәвештә гәүдәләнер дип мин моңарчы күз алдыма да китермәгән идем.

Иртәгесен атларны җигеп юлга чыгабыз. Чикне узып кергәч, юл өстендәге беренче очраган авылның исемен хәтеремдә ничә ел буе сакладым. Әмма менә хәзер ул онытылган. Бары аның «Ф» авазына башланганын гына хәтерлим. Минем алдымда хәзер таушалып, сынып беткән немец картасы ята. Мин бу картаны Германиядә табып, үзем белән йөрткән идем. Ләкин анда да, кызганыч, ул авыл күрсәтелмәгән. Менә шулай бер дә онытылмас, дип уйлый кеше, әмма барыбер оныта икән. Мин шулай, хәтеремә ышанып, никадәр кызыклы, кирәкле, мөһим нәрсәләрне югалттым. Бу яшьләргә сабак булсын. Хәтерегезгә ышанмагыз, язып куегыз!

Шулай итеп, без чикне узып, беренче немец авылына килеп кердек. Барыбыз да кызыксыну белән тирә-юнебезне күзәтәбез. Әй, караллы башкачарак шул бирелә. Тәзек таш өйләр. Күбесе мансардлы. Барысы да чүлмәк түбәле. Киң урамның чит-читләрендә тар гына тротуар. Бер генә дә җан әсәре күренми, күрәсең, халык авылны ташлап качкан, яки аны куып алып киткәннәр. Урам уртасындагы юл буенча ак таплар булып сузылган ниндидер әйберләр күренә. Алар бик күп, урамның теге очына

кадәрле дип әйтерлек. Без якынрак барсак ни күрик? Бу ак әйберләр — муеннары борып ташланган казлар, имеш. Безгә хәзер аңлашыла: янәсе, алар безгә эләкмәсен өчен шулай буылган.

Без узышлый өйләргә дә сугылабыз. Бер генә дә адәм заты юк. Тәгаен дошманның зәһәрле пропагандасына ышанганнар. Фашистлардан да ялганчырак әһел булмастыр бу дөньяда! Без Польшага килеп кергәч, аларның безнең турыда, руслар мөгезле, кыска гына койрыклары да бар, дип коткы таратканлыкларын сөйләделәр. Сез ышандыгызмы соң? — дип сорау бирдек без. Кызганыч, бу чеп-чи ялганга ышанучылар да булган. Искитмәле хәлләр!

Авыл эченә керә төшкәч, кемдер авылда бер немец картының беркая китмичә, утырып калганлыгын хәбәр итте. Ул картны күрми калырга ярыймы соң! Без шул өйгә таба ашыгабыз. Зур гына бер катлы таш өй. Ишектән кергәч тә сул якта утыргыч, немец карты шунда утыра. Ул тулы гына йөзле, сакал-мыегы кырылган. Башында зур козыреклы постау картуз, өстендә кыска пальто. Немецчә яхшы белә торган яһүд солдатлары аның белән гәп кормакчы булалар, сораулар бирәләр. Әмма карт мәрткә киткән диярсең, авызына су капкандай, тавыш-тынсыз гына утыра бирә. Без бераз аның тирәсендә таптанганнан соң, берәр сүз ишетүдән өметләребезне өзеп, таралышабыз.

Барасы юллар озын әле. Безгә еш-еш юлыбызда авыллар, аерым утарлар очрый. Юллар бередә асфальтланган, атларыбызга җиңел. Авылларда кеше заты күренми. Аның каравы кырларда, басуларда сыер, дуңгыз кебек хайван еш очрый. Димәк, аларны хуҗалары абзарларыннан куып чыгарганнар да үзләре урманга шылганнар.

Ниһаять, без бер хуторга барып урнаштык, цементтан катырылган иркен ишегалды, биек абзар-куралар. Без атлар, арбаларны урнаштырабыз.

Иртәгесен иртүк олаучылар трофей-ганимәт ташырга чыгып китәчәк. Мин алардан да иртәрәк торып, баш олаучы белән атларның сәламәтлеген тикшерергә, дагаларын, тоякларын карап чыгарга тиеш. Үгәченә камыт сукканнарын, яралыларны дәваларга, дагалары бушаганын йә сынганнарын калдырырга һәм дагалатырга тиеш мин.

Берзаман безнең участокка ташлап калдырылган трофей атлар килә башлый. Дошманның атлы артиллериясендә нинди генә ил атлары юк! Монда француз, инглиз атлары да, монда Австрия, Италия, Венгриядән җыелган атлар да, тагын әллә нинди, мин моңарчы рәсемдә генә күреп өйрәнгән токымдагы атлар да очрый. Кыскасы, дошман бөтен Европа атын үзенә җыйган. Шуларны тикшереп, без, ветеринарлар, үзебезнең тылга озатабыз.

Мин немец картасына карыйм. Анда фронттан алып кайткан кырык бишенче елны үзем узган маршрут сызылган. Безнең батальон, чикне кичкәч, башта Найденбург исемле бәләкәй генә шәһәрчеккә юнәлгән икән. Аннан без Ортельсбургка киткәнбез. Анысын хәтерлим. Такыр асфальт юллар, юл тирәләренә утыртылган алма агачлары. Олы юл берәр авыл яныннан узса, мотлакан монда юл читенә эскәмия дә куелган булыр, бусы сөт бидоннары өчен. Сөт җыючы авылга кереп тормый, чыгарып куелган сөтле бидоннарны машинасына төйи дә алып китә.

Әйтергә кирәк, немец җирендәге тәртип, авыл, шәһәрләрдәге (сугыш булуына карамастан) чисталык, пөхтәлек безгә башта ифрат ошаган иде. Ләкин тора-бара моңа күзләр ияләште, алай гына да түгел, мондагы стандарт, бертөрлелек күңелне ярсыта ук башлады. Мин шунда табигый матурлыкның кадерен тагын да ныграк аңладым. Кеше кулы белән өф-өф итеп үстерелгән чәчәклекләр кыргый аландагы гүзәл, иркен чәчәклекләргә җитәмени!

Без дошман җирләре буйлап сугышчан дивизияләр артыннан һаман алга барабыз. Кайчак икешәр көн үледәй тын, адәм заты күренмәгән авылларда тукталып торабыз, аннан тагын, тагын алга!

Авылларда, утарларда һаман кеше күренми. Немецләр, без Көнчыгыш Пруссиянең эченә, шактый тирәнгә, үткәч кенә, күренә башлады. Көннәрдән бер көнне миңа иптәшләрем белән тылдагы ветлазаретка яралы трофей атлар илтергә туры килде. Артык караңгыга калгач, юлда очраган бер авылдагы буш өйгә кереп кунарга булдык. Атларны баштa ишек алдына урнаштырып, печәнгә куштык, үзебез мансардалы таш өйгә кердек. Беркем дә юк. Анда ниндидер шомлы тынлык кына безне каршы ала. Бу өйдә безгә кадәр кемдер булган, ахры, әллә хуҗалар качар алдыннан шулай өй җиһазын, кием-салымны туздырып идәнгә ташлаганнармы, алла белсен. Без үзебез кунып чыгарга тиешле урынны карап йөргән арада ишек алдында калган бер иптәшебез мине чакырып чыгарды.

— Әнә, малае белән бер немка килгән! Урманнан чыкканнар. Нидер бытылдый,— диде бу мин чыгышка. Чыннан да, ишек алды уртасында ун яшьләрендәге кыска чалбарлы бер ир бала иярткән йончыган, хәлсез бер хатын тора. Икесе дә таушалган киемнәрдән. Аларның ачлыкка һәм суыкка интеккәнлекләре ачык сизелә. Мине күрү белән хатын минем янымa ук килде:

— Һер сержант!

Ул ашыга-ашыга ниләрдер сөйли башлады. Мин аңа ашыкмыйча тынычрак сөйләргә кушам. Ул урман ягына күрсәтә һәм мин аңласын өчен сүзләрен бүлеп-бүлеп сөйли.

Аңлаганым шул булды: ачлык аларны урманнан куып чыгарган. Мин солдатка ашарга бирергә кушам, немецләргә өйгә кереп җылынырга рөхсәт итәм.

Кабахәт фашизм тудырган афәтләр өчен гаеплемени бу ябык мөлаем ана белән аның ун яшьлек улы? Мин шулай уйлыйм. Хәер, немец җирләренә кергәч, узган юлымда мин башкача фикер йөртүчеләрне дә күрмәдем түгел. Мәсәлән, бер белорус егете миңа ундүрт яшьлек немец кызын көчләве белән мактанды. Мин аңа үземнең нәфрәтемне сиздергәч, егет, немец бит минем өемне яндырды дип, акланырга тотынды. Тагын бер шофер солдат әсирлеккә бирелергә дип куаклыктан чыккан немец солдатлары төркеменә үзенең машинасын борып җибәрүен һәм байтак кына дошман солдатын таптатып үтерүен хәбәр итте. Ул миңа шундый бер детальне дә әйтте: машина астында калган бер яшь солдат шулкадәр каты кычкырды, диде, мин андый ачы тавышны гомеремдә кеше бугазыннан чыга ала дип уйлаганым юк иде. Хәзер аның колагына еш кына шул тавыш ишетелеп китә икән. Бу солдат та үзенең әлеге кылган эшен дошман кулыннан һәлак булган гаиләсе өчен үч алуым дип аңлатты.

Әйе, сугыш — сугыш инде! Ул, фаҗигале тетрәнүләр белән бергә, зур гаделсезлекләр, зур оятсызлыклар вакыты да.

Без Найденбурггтан Ортельсбур шәһәренә киттек. Аннан Бишовсбургка, аннан Ротхфлиескә. Хәтерем ялгышмаса, болар барысы да матур гына немесчә җыйнак, тәртипле стандарт шәһәрләр иде. Асфальтлы урамнар, таш өйләр, өйләр каршына рәшәткәле чәчәклекләр ясалган, очлы манаралы кирхалар...

Безнең солдатлар ул шәһәрләрне узганда буш, хуҗасыз өйләргә кереп, кирәк дип табылган әйберләр күрсәләр, алып чыгудан тартынмыйлар. Ниндидер шәһәргә кереп тукталгач, мин үзебезнең күпчелек солдатның кулында скрипка күрдем. Беләм, солдатларыбызның берсе дә скрипкада уйнамый, алар кызык итеп кенә алганнар ул уен коралларын.

Минем скрипка уйнавымны белүче рота командиры Талипов, күп уйлап тормастан, тотты да скрипкалы егетләрнең барысына да бу уен коралын тотып, бер сафка тезелергә кушты. Ул мине дә ишегалдына чыгарып бастырды.

— Әйдә, фельдшер (ул мине шулай атый иде), сайла шулар арасыннан үзеңә хуш килгәнен.

Мин көлемсерәдем дә аның әйткәннәрен үтәргә керештем. Үзем дә бер скрипка тапкан идем, ләкин ул мин теләгән уен коралы түгел иде.

Мин бер солдатка үземнең шул скрипкамны биреп, аның шәп скрипкасын алдым. Шул трофей скрипкам әле дә исән, әле дә миндә сугыш истәлеге булып саклана. Мин шул скрипка белән буш араларада үзебезнең көйләрне уйнап бөтен Германия җирен, Балтыйктагы Фришес-Һафф култыгыннан алып Эльбадагы Виттенберг шәһәренә кадәр юл уздым.

Уздым дигәннән, без Көнчыгыш Пруссиядә йөри торгач, Меһельзак дигән бер шәһәрдә шактый озакка туктадлык. Безнең рота ул көннәрдә шәһәрнең кунакханәсендә яшәде. Истә, ул таш бинаның урамга караган иркен балконы да бар иде. Мин һәр көнне, иртәнге эш тәгәлләнгәч, шунда чыгам да скрипка чалам. Татар көйләрен, үзем белгән моңлы татар көйләрен уйныйм. Шунда туган-үскән яклар бер тапкыр искә төшеп күңелне сызып үтә. Шундый бер тойгы кичерәм, әйтерсең лә, мин үземнең Казаныма, өемә, әниемә тагы да якынаям. Урамның теге ягындагы өйләрдә яшәүче немец хатыннары исә, бу вакытларда ишекләрен ачып, мин уйнаганны тыңлыйлар. О, гайгы, гайгы, дип башларын чайкыйлар, күрәсең, алар да ләззәтләнәләр.

Бу көннәрдә инде моңарчы бездән яшеренеп яткан немецләрнең күбесе өйләренә кайткан иде. Геббельс пропагандасының ялган булганлыгына, безнең армиянең, нигездә, кешеләрдән торганлыгына ышана башлаганнар иде.

Көннәрдән бер көнне Меһельзак шәһәрендә безнең элемтәчеләр урамнарга радио репродукторлары элделәр. Февраль киче иде, кинәт бөтен урамны яңгыратып үзебезнең җырчыбыз Мәрьям Рахманкулова җырлый башлады. Бу минем өчен җанны тетрәткеч бер җыр булып ишетелде. Меңнәрчә километрга сузылган газаплы сугыш юлларын узганнан соң, җиңүчеләр сафындагы солдат буларак монда килеп, дошман иленең бер шәһәрендә үзеңә бик-бик якын моңлы җыр ишет әле син! Мин кузгалырга, хәтта тын алырга да куркып, җырны ахырына кадәр тыңладым. Бер көнне исә шундагы шәһәр театрында безнең совет артистлары концерт бирде. Ул концертта җыр һәм биюдән тыш акробатик чыгышлар да бар иде. Минем куанычлы аптыравыма каршы, акробатик номер белән сәхнәгә Хөсәенов дигән бер татар егете чыкты. Хода-вәндә! Мин бит бу артистны беләм. Ике туган иде алар, Казан циркында чыгышлар ясыйлар иде. Беләм-беләм, алар бит Казаннан, Яна бистә малайлары!

Мин тамаша бетү белән сәхнә артына керәм. Артистлар арасыннан Хөсәеновне эзлим. Менә ул! Нинди күңелле очрашу! Мин аны шундук үзебез урнашкан госһаузга алып китәм. Минем чарлактагы кыек стеналы кечкенә генә бүлмәмдә утырабыз әле. Хөсәеневнең абыйсы үлеп калган икән. Хәзер ул үзе генә. Без аның белән бик озак чәйләп, сыйланып гәпләшәбез. Күп еллардан соң якташыңны чит җирләрдә очрату, узган көннәрне искә алып утыру ифрат күңелле.

Мин хәзер безнең Өченче армиянең дошман җирләренә ничек аяк басуы турында язмакчы булам.

Безнең Икенче Белоруссия фронтының командующие хәзер үзгәрде. Декабрь аенда безнең фронтка башлык итеп данлыклы маршал Константин Константинович Рокоссовскийны билгеләделәр. Армия дошман җирләренә һөҗүмгә җыена. Ул 1945 елның 14 январенда башлана.

Унсигезенче январьда безнең частьләр Красноселец торак пунктын алалар, йөз илле әсир, бик күп трофей кулга төшерәләр. Дәһшәтле сугыш дәвам итә, дошман чигенергә мәҗбүр.

Армиядә Көнчыгыш Пруссиягә беренче булып аяк басу бәхете Серягин командованиесендәге 1172 нче укчы полкка насыйп була.

Әйтергә кирәк, Германия чиге, югарыда язылганча, сугыш башланганга кадәр үк бик хәтәр ныгытылган була. Кеше бүе тирәнлегендәге өч рәт траншея, тимер-бетон калпаклы ут нокталары, катлы-катлы тимерчыбык киртәләр, алар алдында һәм арасында миналар.

Егерменче февраль көнне безнең армия Гудштадт шәһәренә барып җитте. Хәрәкәт дәвам итә. Безнең частьләр, ниһаять, Древенц елгасына җитәләр. Анда исә тагы көчле оборона сызыгы. Икенче көнне генерал Телков һәм полковник Абилов дивизияләре беренче булып Древенц суын кичеп, дошманның оборонасын өзәләр. Шул сугышлар вакытында Хәбибуллин фамилияле татар сержантының хуторда яшеренеп яткан СС солдатларын әсир итүе мәгълүм.

Дошман безгә каршы ике көн буена өзлексез атакалар ясый, мәгәр максатына ирешә алмый. Бу дуамал канкойгыч атакалардан соң, безнең фронтта тынлык урнаша.

Шул көннәрдә безнең армия тагы башка фронтка тапшырылды. Хәзер без Өченче Белоруссия фронты гаскәрләре. Безнең башкомандующий — армия генералы Черняховский И. Д.

Безнең хәрәкәт Көнчыгыш Пруссия җирләрендә һаман дәвам итә. Армиянең Кырык беренче укчы корпусы Меһельзак шәһәрен алу өчен уналтынчы февральдә Вальш елгасы аша чыга.

Ул көннәрдә Вормдит һәм Меһельзак шәһәрләрен алган өчен Верховный башкомандующий тарафыннан безнең гаскәрләргә рәхмәт белдерелә, Мәскәү туплардан атып салют бирә.

Унҗиденче февраль көнне күз алдыбызда диярлек тиктомалдан дигәндәй, безнең фронт командующие, бик талантлы яшь хәрби башлык, армия генералы Черняховский һәлак булды.

Дошман бирегә безнең гаскәрләрне якын җибәрмәс өчен булдыра алганның барысын да эшләгән. Хәтта үзен саклау өчен консерва банкалары, кофе савытлары тутырылган әрҗәләрдән ныгытмалар ясап маташкан. Хәзер исә ул дәһшәт утында дөрләп яна, кая керергә белми, үзе ясаган җинаятьләре өчен җавап бирәсен сизенеп, тизрәк диңгез аша шылырга ашыга. Яр буенда диңгездә вак баркаслар, пароходлар, көймәләр, үлем ачысын тоеп өзгәләнү, чәбәләнү.

27 мартта безнең армия гаскәрләре, бөтен сугыш дәверендә беренче тапкыр, үз алларында дошманның булмавын тоеп, тынычлап ял иттеләр. Безнең Өченче армия резервка чыкты.

* * *

«5.04.45. (19/4 алдым)

Кыйммәтлем әни!

Синең 23 мартта язган хатыңны бүген алдым, каты авырудан соң савыга башлавыңа шатландым. Ләкин шулай да синең 22 сенә кадәр больницада авырып ятуыңа борчылмыйча кала алмадым. Җанкисәгем әнием, зинһар, үзеңнең хәлеңне миннән яшереп маташма. Синнән кечкенә-кечкенә хатлар ала башлау белән минем күңелем нидер сизенеп сыкранырга керешкән иде инде. Ни өчендер һәрвакыт синең турыда гына уйлана башлаган идем. Бу хатыңның килүе миңа хәлне ачып салды. Борчылдырды да шатландырды да.

Әни, син үзеңнең хатыңда хәлеңне ачык итеп язмагансың. Йөрисеңме, әллә ятып кына торасыңмы? Кәефең ничек, яхшы ашыйсыңмы? Теләгән әйбереңне ашарга имканият бармы? Шуларның барысын да, зинһар өчен, ачык кына итеп яз әле. Югыйсә мин синең өчен бик борчылам. Күз алдымда син бик каты авырып түшәктә ятасыңдыр кебек.

Синнән яшермим, бүген шулай сине күз алдыма китердем дә күзләремнән яшь бөртекләре тәгәрәп төште. Әллә ни булды миңа. Мин Насыйри урамында, Гафифә апаларда торганда, сине Шәлегә озаткач, яшеренеп бер җылаган идем, бүген дә шулайрак булды. Соңыннан синең хатыңдагы «хәзер үземне яхшы хис итәм» дигән сүзләреңне тагы бер тапкыр уку гына мине юата төште.

Әни! Минем тормышым бик яхшы. Эшемне дә, үземне дә яраталар. Тәэминат мәсьәләсе яхшы. Әле бу хатны юл өстли генә язам. Шулай

хатларымны яза торырмын. Ә озакламый, җәй дә үтмәс, без барыбыз бергә, шау-гөр килеп, котелокларыбызны шалтыратып Казанга кайтып керербез. Күп калмады инде, күптән көтелгән очрашу бәйрәме кызу-кызу якынлаша.

Сине бик каты кочам, йөзләреңнән, күзләреңнән үбәм, чәчләреңнән сыйпыйм. Ялкынлы сәлам белән: улың Атилла.»

Кенигсберг шәһәренең хәрабәләре бер дә хәтердән китми. Без аның урамнарына инде караңгы иңгәч барып кердек. Дәһшәтле, шомлы иде күренеш. Тар урамның ике ягындагы таш өйләрнең эче чытырдап яна, төбенә кадәр ачылган тәрәзәләрдән очкын урамга сибелә, әйтерсең лә бөртекләре уттан торган кар ява җиргә. Янган, җимерелгән өйләр белән тулы урамнарны узып, тынрак урынга тукталабыз. Иртәгесен үз эшебезгә керешәбез. Трофей атлар, сыерлар китерәләр. Без аларны тиз генә карап, кирәксә, тиешле чаралар күреп тылга озатырга тиеш. Безнең эш шул: батальонныбыз бер төбәкне ганимәт малыннан тазарткач, икенче төбәккә күчә.

Без Көнчыгыш Пруссия буенча кыдырабыз. Бер торак урындагы коточкыч хәлгә юлыгуыбыз искә төшә. Бараксыман җиңел бер корылма эчендә немец хатын-кызлары, балалары үлем газабы кичереп ыңгырашалар. Алар бик күп, бөтен барак эче шулар белән тулган. Төенчекләрен күтәреп өйләренә кайтып баручылар икән. Агуланганнар бичаралар. Тел тибрәтерлек кенә хәлләре калган. Хатыннарның сөйләвенә караганда, алар монда ял итәргә тукталганнар. Ач кешеләр, әлбәттә, беренче чиратта, ял итәрлек урынга эләккәч, азык эзли башлыйлар. Араларыннан берсе сөт таба. Ул бик күп шешәләргә тутырылган, тәрәзә төпләрендә, шкафларда. Каймаклы куе сөт. Ач кешеләр ябырылып сөткә ташланалар. Белмиләр алар, үз гаскәрләренең чигенгәндә, һөҗүм итеп килүчеләрне, безне, үтерү өчен сөткә агу салып киткәннәрен...

Без ул баракка барып кергәндә агулануларның берничәсе үлгән иде инде. Исәннәрен шундук хәрби госпитальләргә озаттык.

Агулану дигәннән, Германиягә килеп кергәч, безнең солдатлар да андый бәлагә аз тармады. Әмма моның күбрәге үзебезнең тинтәклек аркасында, исерткечкә булган көчле хирыслыгыбыз аркасында килеп чыкты дияр идем мин. Немец җирендә һәр өйдә диярлек примус кабызу өчен агач спирте кулланалар (метил спирте). Исе аның этил спиртеннән хәтерләтә. Безнең агайне аракы эчүгә килгәндә тыела беләмени? Командирларның катгый приказларына карамастан, шул метил спиртен эчеп шактый кеше күзен бозды. Алай гына да түгел, алгарак китеп әйтим, безнең батальоннан гына да унсигез кеше шул нәрсә белән агуланды. Монысы Одер елгасындагы бер трофей танкерны саклаганда булды. Егетләр шул спирт тутырылган танкерны саклауга куелалар. Безнең үтә кызыксынучан агайне андагы сыекчаның исен шундук сизеп ала. Кешекара күргәнче дип, чөмерәләр тегеләр шул агулы агач спиртен. Нәтиҗәдә, унсигезләп егет сукырайды, сукырайманы гомергә ярым сукыр булып калды.

Без шулай яңа җирләрдә, яңа шартларда яшибез. Һич көтмәгәндә дошман безнең тылга, безнең турыга десант төшерде. Батальон тревога буенча аякка бастырылды. Без генә түгел, күршедәге хәрби частьләр дә, бергәләп, «капчыктан» чыгып котылырга омтылган дошманга каршы ут ачабыз. Атыш сәгать ярым чамасы дәвам итте. Десант бетерелде. Безнең часть тә диңгез ярларына килеп җитте.

Ак яллы диңгез дулкыннары шаулый, алар бер-бер артлы куышып комлы ярга ташланалар. Алар безгә, очсыз-кырыйсыз Балтыйк киңлекләрен күзәткән совет солдатларына, ярдәмгә киләдер сыман. Безнең күңелләр дә шулай ук ашкына бит, алгысына, тизрәк-тизрәк дошман җиңелсен дә тынычлык урнашсын, көтелгән, зарыктырган туган якларга кайту көннәре килсен...

Хәзер Европаның барлык көнчыгыш илләрендә диярлек каты, соңгы сугышлар бара. Безнең гаскәрләр Берлинга якынлашып киләләр инде.

Безнең армиягә дә резервта озак юанырга туры килми. Беренче апрельдә Өченче армиягә Берлин төбәгенә — Одердагы Франкфурт шәһәренә күчәргә фәрман булды. Димәк, димәк, безнең Өченче армия Берлин шәһәрен, Гитлер өнен штурмлауда катнашачак. Бу эш безнең өчен бик җаваплы һәм шатлыклы да.

Узасы юл аз түгел — 550 километр. Менә безнең армия юлда. Такыр шоссе юлларында дүрт маршрут. Атлылар юлына «Конь — 1» һәм «Конь — 2» дигән язу, машиналар өчен «Лев — 1» һәм «Лев — 2» дигән билге куелган. Безгә юлда, мөмкин булганча, кызурак барырга кушылды.

Безнең Өченче армия тагын башка фронтта. Без хәзер Беренче Белоруссия фронты гаскәрләре. Безнең командующий — данлыклы маршал Г. К. Жуков.

Беренче Белоруссия фронтының һөҗүме уналтынчы апрельдә иртәнге алты тулып утыз минутта башланды. Гаять көчле артиллерия әзерлеге бөтен тирә-юньне селкетте. Безнең танклар алга ыргылды, пехота аңа иярде. Дошман оборонасы бу кадәр дә тимер ташкыныдай һөҗүмне күтәрә алмады, аның оборонасы өзелде. Штурм уңышлы үрләде. Егерме икесендә инде фронт Зур Берлин алдындагы Штраусберг, Кинбаум, Дуһhельп, Белендорф шәһәрләре аша Франкфурт чигенәчә сузылган иде.

Безнең уң ягыбызда генерал-полковник Чуйков армиясе, сул ягыбызда генерал-полковник Калракчи армиясе хәрәкәт итә. Безнең максат хәзер Шпрее елгасын һәм Одер-Шпрее каналын кичеп, егерме өченә каршы төндә теге якка чыгу, егерме бишендә Берлин-Ессен шоссесын кисеп, дошманны камауны төгәлләү.

Фашистларның контр атакалары хәзер тагы да көчәя төште. Әмма алар, никадәр генә көчәнмәсеннәр, язмышлары хәл кылынган инде. Аларга бернәрсә дә ярдәм итә алмый. Каналларны чигенгәндә җимерүләре дә, артларында бик күп миналар калдыруы да, хәтта төрле «сюрпризлары» да. Мәсәлән, алар юлга бик күп шартлагыч сигарет пачкалары, шырпы тартмалары, теш пасталары, хәтта авторучкалар ташлап калдыра торган булдылар. Ул кызыктыргыч әйберне кулга алдыңмы, шартлау — һәм сиңа үлем...

Безнең солдатлар күлләрне һәм каналларны амфибия көймәләрдә кичәләр. Ә ул күлләр һәм каналлар бик еш очрый. Күлләр тирәсендә карт нарат урманнары, анда зиннәтле дача виллалары. Биредә байлар һәм Гитлер яраннары ял иткән. Хәзер анда хезмәтчеләр һәм бакча караучылар гына, хуҗалардан җилләр искән. Вилла тәрәзәләрендә ак чүпрәкләр җилферди.

Егерме алты — егерме җидесендә безнең армия частьләре тоташ күлләр төбәгенә килеп чыкты. Һәм без оборонага туктадык.

Бу урында безнең фронтның киңлеге егерме биш километр. Аның егерме ике километрын күлләр били, коры җир бары өч километрдан гына тора, анысы да әле эреле-ваклы каналлар белән кискәләнгән.

Егерме сигезендә һөҗүм тагы башланды. Безнең гаскәрләр күлләр кичеп коры җиргә сибеләләр. Дошман исә бөтенләй шашынып безнең частьләрне атакалый. Ул егерме тугызынчы апрельдә булган барлык көчләрен туплап, безгә ташлана. Ул бу юлы чылбыр булып кына түгел, ә сафлы колонналар белән килә. Безнең солдатлар ятып, йә мылтыкларын агачка сөяп, тыныч рәвештә, ашыкмыйча гына төзәп аталар. Дошман исә үрә баскан килеш ата-ата килә, ул төзәп атмый, ул безнең солдатларның кайда яшеренгәнлекләрен дә анык белми, ул акылдан язганнарча югалтулар, кирәксезгә кан коелу белән исәпләшми. Бу котырган, мәгънәсез атакалар нәтиҗәсендә безнең алдыбыздагы унике километрлы мәйдан дошман солдатлары мәете белән тула.

30 апрель көнне без һаман еракташа барган ату тавышлары ишетеп йокыдан уяндык. Димәк, безнекеләр дошманны шактый еракта куалар.

Тиздән безнең армия генерал Калпакчи һәм Цветаев армияләре белән кушылды. Ул көнне безнең егетләр Берлиндагы Рейхстаг түбәсенә кызыл байрак кададылар. Гитлер үзен-үзе үтергән диделәр. Шул ук көнне Беренче Украина фронты гаскәрләре Эльба елгасында америкалылар белән очрашты. Ләкин әле сугыш бетмәгән иде...

9 май көнне иртә белән без фашистлар Германиясенең берсүзсез капитуляцияләнгәнен белдек. Моннан да зуррак шатлыкның булуы мөмкин идеме соң безнең өчен?!

Германиянең сүзсез капитуляциясе хәбәр ителгән көнне безнең хәрби бүлекчә Берлин янындагы бер шәһәрчекнең дача өйләрендә урнашкан иде. Хәтердән бер дә чыгасы юк: сугыш бетү хәбәрен ишеткәч, без, бер төркем хәрбиләр, шатлыктан тәмам шашып калдык, телдән яздык, сүз әйтә алмыйча, диваналардай тик елмаеп торабыз. Андый олы шатлык минутларын кичергәндә гаҗәп икән ул кеше дигәнең, берәребез кузгалып китсә, барыбыз да шуңа иярә, күзләр зур булып ачылган, йөзләрдә рәхәт, талгын бер нур балкый. Бу халәт шулай без айнып чынбарлыкка, кыласы гамәлләребезне хәтерләү халәтенә әйләнеп кайтканчы бер ун минутлар, бәлки, артыграк та дәвам иткәндер. Үтә олы куаныч иде шул утлар-сулар кичеп исән калган солдат өчен бу хәбәр!

Мин хәзер, бер чигенеш ясап, үзем хезмәт иткән батальонның Көнчыгыш Пруссиядән Берлинга баруын искә төшермәкче булам.

Шулай көннәрдән бер көнне безнең батальонга да Берлин янына күченергә дигән приказ килде. Тиз арада әзерләнеп, үзебезнең атларда юлга чыктык.

Барасы юл ерак. Менә без үзебезнең арбаларда пар ат җигеп көнбатышка таба барабыз. Бераз алгарак китеп булса да шуны әйтим, филдәй эре, арбага менми торып камыт кидертә алмаслык биек, токымлы атлар никадәр көчле булсалар да, безнең кечкенә, әрсез абориген атларга чыдамлылык, түземлелек ягыннан җитмиләр икән. Безнең армиягә бер заман көтүләре белән монгол атлары килде. Без ул кыргый, асау атларны кулга ияләштерә алмый җаныбыз чыкты. Ә инде аларны буйсындырып, эшләтә башлагач, аларның түземлелегенә хәйран калдык. Ул атларның әйбәт сыйфаты озын юллар узганда аерата ачык беленә икән.

Менә бу юлы да без үзебезнең бәләкәй атларның чыдамлылыгын ачык күрдек. Трофейга алынган эре, токымлы атларның барысын да ташлап калдырырга туры килде.

Хәтердә, безнең рота Бромберг шәһәрен узганда минем өчен күңелле бер очрашу була язып калды. Мин шәһәр урамында «Фронт хакыйкате»ндә эшләүче бер татар солдатын очраттым. Шәрәфләр дә сәфәр чыкканнар икән. Әмма, кызганыч, алар бирелә тукталганнар, без исә һаман алга барабыз. Бу турыда Шәрәф Мөдәррис миңа болай дип язачак әле:

«Очрашкандай булдык, ләкин яхшылап берни сөйләшә алмадык. Әллә ничек шунда, ул вакытлар үкенечкә калды. Теге агай да бит ичмасам йөгереп килеп безгә әйткән булса, сине бик тиз куып тотар идек. Ул безгә берничә сәгатьтән соң гына әйтте. Исчмаса синең дә шунда күчәрең, яки камытың нык булган. Ярар инде, хәерле булсын. Шунда бетерәм. Сине кочып, дустың Шәрәф. ПП 47764»

Менә без, күп шәһәрләр узып, бетон плитәләр белән түшәлгән Берлин автострадасында. Ул юл яландай иркен, анда мәхшәр. Әйтерсең лә, кыямәт көне. Бөтен дөнья халкы урныннан кузгалган, диярсең. Берлин ягыннан килүче халык белән тулган. Нинди генә милләт вәкилләре юк бирелә! Һиндстанлылардан алып, итальяннарга кадәр, кытайлардан алып гарәпләргә кадәр. Нинди генә киемнәргә төренмәгән алар, буй-буй концлагерь киеменнән алып, шәрә тәнгә ак җәймә ябынганнарына кадәр. Аларның барысы да дип әйтерлек җәяүле, ләкин багажникка таудай чемоданнар өйгән велосипедлылар да күренә. Арба тартып килүчеләр дә, балаларын шунда утыртканнары да бар, сирәк кенә атлылар да очрый.

Минем өчен аерата сәер тоелганы шул булды: ике кеше резин көпчәкле бәләкәй арбага сарык тәкәсе җиккәннәр. Өйрәтелгән тәкәдер бу, юкса шул кадәр күндәм рәвештә тып-тып басып арба тартып бармас иде дип уйлыйм.

Мондый хикмәтле халык ташкынын минем гомеремдә күргәнем юк иде әле. Безнең батальон Берлинга 30 майда барып керде. Бу көннәрдәге күңел күтәренкелеген, дәрт-дәрманның ташып торуын әйтеп тә, язып та бетерерлек түгел.

Озакламый мин үзем белән Шәрәф кебек үк актив язышкан фронтовик каләмдәшем Габдрахман Әпсәләмовтан хат алдым. Үзем дә аңа котлау хаты җибәрдем. Габдрахман үзенең хатында миңа түбәндәге юлларны язды.

«Расих дус!

Шатлык эчкә сыймый. Гасырларга калачак, буыннардан-буыннарга бәйрәм ителәчәк Җиңү көнен үткәрәбез. Котлы булсын бу гүзәл бәйрәмебез, туган. Без исән, халкыбыз исән Ватаныбыз данга күмелгән. Яшибез, яшибез.

Башка әллә нинди матур, серле уйлар килә. Чын-чынлап иҗат эшенә чумасы көннәр якынлаша. Кем белә, алда, бәлки, тагын зур көрәшләр тора торгандыр. Тик шунысы ачык, иң явыз, иң мәкерле дошман юк ителде инде.

Синең мөбарәк хатыңны алдым, Аның өчен зур рәхмәт. Моннан алда сиңа хатлар язган идем. Алгансыңдыр. Монысын бик ашыгыч язам. Озакламый паровоз тагарга тиешләр. Юл ачык инде! Кая икәнен үзең төшенә торгансыңдыр.

Казаннан яңа бер әйбер алганым юк. Хәер, алар безнең үзебезне көтә торганнардыр инде. Хатлар яз.

Якын арада күрешүне теләп, Габдрахман. 10/V-45».

Германиядәге безнең батальон тормышын күз алдына тулырак китерү өчен мин тагын әлеге тарихи очеркка мөрәҗәгать итүне кирәк саныйм. Югарыда әйткәнемчә, мин аны штаб начальнигы ярдәме белән кайнар эзләр суынганчы ук язган идем. Менә аңардан кайбер өзекләр:

«1944 елның азагында, 45нең башында уздырылган нык хәрби һәм политик әзерлек эшләре үзен аклады. Трофей хезмәте буенча офицерлар, сержантлар һәм рядовойлар белән уздырылган дәресләр, узган сугышлар тәҗрибәсе бик уңай роль уйнады. Сугышчылар һәм командирлар, Кызыл армиянең уңышлары белән илһамланып, Көнчыгыш Пруссиядә һөҗүм итеп алга баручы частьләргә иярделәр. Элекке һөҗүмнәрдәгечә алда батальонның разведкасы хәрәкәт итте, ул трофейларны барлады, аларга сак куйды, аларны беркем кул тидермәслек дәүләт милке иттерде.

Хәрби техника, велосипедлар, өй кирәк-яраклары белән капланган юллар, ташланган корал, калдырылган атлар, сыерлар белән тулы басулар, зур хәрби складлар — трофейчеләргә бирелә эшләрнең җитәрлек күп булуы турында сөйлиләр иде. Боларның барысын да югалтмыйча җыеп туган илгә озатырга кирәк иде.

Кыска гына вакытта батальон берничә дистә хәрби җиһаз һәм азыктөлек складын алды. Батальон юлларны һәм территорияне трофейдан чистартып, аларны станцияләргә озатуны оештырды. Сугышчылар һәм командирлар курку һәм ару-талуны белмәстән эшләделәр. Әмма югалтулар да булмады түгел. Алгы сызыктан трофей алып чыкканда капитан Афанасьев һәм дүрт сугышчы батырларча һәлак булды.

Һөҗүм операцияләре чорында түбәндәге ганимәт малы җыелды: танк һәм самоходкалар — 49 данә, бронемашина һәм тягачлар — 26, автомашиналар — 28, туп һәм минометлар — 162, винтовка һәм автоматлар — 13000, авыл хуҗалыгы машиналары һәм башка халык хуҗалыгы җиһазлары, аяк киеме, өс киеме — берничә йөз вагон. Юк ителде: снаряд һәм миналар — 240 мең, мылтык патроннары — 1500 мең.

1945 елның апрелендә ганимәт батальоны Кюстрин белән Франкфурт арасында Одер елгасын кичте һәм әле генә булып узган һөҗүм сугышлары эзеннән Берлин шәһәренә таба юнәлде.

Батальон хәрби объектлар саклауны төп эш итеп алса да, башта трофей җыю, табылган корал һәм халык хуҗалыгы җиһазларын складларга ташу эшләрен башкарды. Бары беренче рота гына Швибус шәһәрендәге ике заводны демонтажларга җибәрелде.

Трофеялар җыю һәм демонтаж эшләренә җирле халыкны җәлеп итү дә башланды. Июнь аенда зур масштаблы демонтаж эшләре Берлинда җәелдерелде. Газ заводы, Телефункен, радиоаппаратлар заводы, шәһәр бензин колонкалары демонтажланды. Июльдә яңа чикләрне разведкалау, тикшерү башланды. 8 июльдә Либенвальте, Велтен, Виттенбург шәһәрләренә күчте. 25 августка 11 завод демонтажланды. Аннан чыгарылган җиһаз 1450 вагон күләмендә булды.

Хәзерге көндә өч объектта демонтаж эшләре башкарыла. Төяләргә тиешле әзер җиһаз һәм материаль 941 вагон күтәрерлек.

Белоруссиядәге Станисавово авылыннан башланып Берлинга җиткән батальонның юлы менә шундый.

26.08.45»

«13.06.45 (3/VII алдым)

Кыйммәтлеләрем!

Моннан бер ай элек хат язып салган булсам да, бу көнгә кадәр сездән хат-хәбәр алганым юк. Юравымча, сез минем тиз арада кайтып килүемне көтәсездер, шуңа күрә хат та язмыйсыздыр. Ләкин шуны әйтим, сугыш беткәннең икенче көнендә үк кайту мөмкин эш түгел икән. Шуңа күрә хатлар алышуны дәвам иттерик.

Үзем исән-сау. Шул ук хезмәтемдә. Әкрен-әкрен үзебезнең якларга юл тотабыз. Тик бөтенләй кайту кайчан булыр — билгесез. Сугыш беткәнче аның тизрәк бетүен теләп зарыктык, хәзер исә күңел аерата бер көч белән Казанга ашкына.

Дус-ишләр, таныш-белешләр бәлки кайта да башлаганнардыр инде. Казан да хәзер күңелле кичерешләр, бәхетле очрашулар белән гөрлидер. Озакламый мин дә шулай сезнең белән очрашу бәхетенә ирешермен дип өметләнәм.

Бу хатны үземнең исән-саулыгымны хәбәр итү өчен генә язам. Дус-ишләргә, бигрәк тә туганнарга сәлам әйтегез. Бу арада беркемнән дә хат алган юк. Хәер, моннан 15—20 көннәр элек Әпсәләмнән һәм Шәрәфтән котлау хатлары алган идем, тик үзләренә озын хат язарга кул тими йөри.

Ярар, хәзергә җитеп торыр. Йөзләрегездән үбәм, ялкынлы сәлам белән, тиз исәнлектә күрешүне теләп: Атилла».

Мин армиядә көндәлек язып бармадым. Ләкин шулай да минем үзем белән кайткан блокнотларда кайбер нәрсәләр теркәлгән булып чыкты. Күргән-белгәннәрем тулырак күз алдына килеп бассын өчен миңа ул язмалардан да файдалану зыян итмәс дип уйлыйм. Менә аларның кайберсе:

«9 июнь, 1945 ел. Кичә иртәнге дүрттә юлга чыктык. Сәгать икедән үк (Мәскәү вакыты белән) торган булсак та, иртәнге ашны ашарга да өлгермәдек, кузгалдык. Бераздан Плауз шәһәрчеге артта калды, без Бранденбург шәһәрен кичеп, Берлин магистраленә чыктык. Бранденбургта халык уянган иде инде. Немец халкы бик юаш булып күренә. Велосипедта баручы бер кыз безне хәтта яулык болгап сәламләде дә. Бернинди хәвеф-хәтәрсез 50 километр араны узганнан соң, без иркен бер болында кундык. Төн җылы, аяз иде. Без өчәү — Коля, Ваня һәм мин — бик озак әңгәмә корып, көлешеп яттык. Соңыннан йокыга киткәнемне сизмәдем.

Иртәнге бишенче яртыда тагын сәфәр башланды. Юл өстендә, Берлин янындагы шәһәрчекләрнең берсендә ял иттек. Мунча да яккан идек, тик юынырга туры килмәде. Шундагы трофейлар складыннан барып солы алырга да мөмкинлек булмады. Сәгать бишенче яртыда Франкфуртка таба

чыгып киттек. Юлыбызда ниндидер бер шәһәрчек үттек. Мәктәпләр эшли башлаган икән. Безгә балалар очрый. Алар икмәк сорый. «Каһәр суккырылар,— ди бер белорус егете,— безнең балалар немец солдатлары янына барырга да куркалар иде, ә болар күзенә керәләр». Янибызга байтак немец хатын-кызы җыелды. Алар тәмәке, сигарет китергәннәр. Бер хатын 50 грамм тәмәкегә ике кило ярым шикәр сорый. Без көлешеп таралыштык. Каршыга килеп чыккан автомашинада безнең совет балаларын алып киттеләр. Моңарчы Германиядә булганнар.

Франкфуртка 43 километр калды. Без кунарга тукталдык. Бу юлларны иркен болында, арбалар янында яткан килеш язам. Кичке аш вакыты хәзер.

14.06.45. Безгә Одерны кичәргә насыйп булмады. Барган җиребездән кире борып, Германиядә калдырдылар. Безне башка армиягә бирәләр, элекке армиябез илгә китә. Картларның борын салынды. Без дә борчулы. Шулай ук Германиядә озакка калырга туры килер микәнни? Иртәгә йә берсекөнгә комбатка отпуск сорап барам. Кичә өйгә хат яздым. Алардан хат та, хәбәр дә юк.

20.06.45. Бүген тагын «Бәхет орлыклары»на керештем.

22.06.45. Бик күңелле хәбәр: Саша — безнең писарь югары белемле кешеләрнең исемлеге штабка китте, диде.

30.06.45. Бүген Берлин урамнарыннан узарга туры килде. Кызганыч, үзәктә булырга туры килмәде. Мин булган районнар артык җимерек түгел. Урамнарда хәрәкәт. Биналар һәммәсе дә соры, асфальт төсенә буялган. Күпчелек өйләр 2—3 катлы, түбәләре, кагыйдә буларак, чүлмәк белән ябылган. 72, 99, 69 нчы номерлы трамвайлар йөргәнен күрдем. Трамвайлар, бездәге кебек кызыл төстә булмыйча, сары төскә буялган. Без — Никулин Андрей Иванович, Иван Осадчий һәм мин Гусеница һәм Чайканы җигеп, Берлин урамнарыннан тарантаста үттек. Юлда велосипедка атланган бер немец кызы безнең тарантаска килеп ябышты. Ул һәм күзлага утырган күзлекле немец егете безгә юл күрсәтеп бардылар. Мин тәрҗемәче хезмәтен үтәдем. Шулай бик озак Берлин урамнарын гизгәннән соң, ниһаять, оккупация гаскәрләре штабына барып җиттек.

Хәрби штаб бинасы дүрт төрле байрак белән бизәлгән. Лозунгны укып, Сталинга генералиссимус исеме бирелүен белдем. Без урамда калдык, Никулин Ветотделга җәяүләп китте. Бераздан ул кире кайтып, миңа бер чәлем бүләк итте. Ул тагын киткәч, мин Военторгка юнәлдем. Тик кибетне ябып өлгергәннәр иде инде. Бер чатта сыра саталар. Бик чибәр, ләкин бик усал рус кызы сату итә. Сыра эчтем. Ләкин бу эчемлек сырадан бигрәк икмәк квасына охшаган.

Кичкырын гына өйгә кайтып җиттек. Барасы юл 28 километр (Гросс Беһерен). Әле хәзер шушы юлларны язып утырганда, мин Креммен шәһәренең госһаузында. Ротабыз шул кунак өенә килеп урнашты. Озакламый, озакламый Казанга».

«6.07.45 (29.07 алдым)

Сөекле әнием!

Синең сугыш беткәннән соң язган хатыңны кичә алдым. Үземдә исәнсаулык. Моңа кадәр Германиянең бер почмагыннан икенче почмагына хәтле кыдырып йөрдек. Хәзер инде тукталдык, һәм мин шушы урыннан өйгә таба, күптән көтелгән сәфәргә чыгармын, ахры. Хәзер документлар әзерлиләр. Кузгалдык дигән сигналны түземсезлек белән көтәбез...

Әни, бу хатыма җавап язып торма инде, чөнки хат артыннан үзем дә кайтып җитәрмен кебек. Ниһаять, авыр еллардан соң, чиксез михнәтләр чигүдән соң, миңа туганнарым, дусларым янына, туган илемә кайтыр көн дә туар икән. Мин әле моны бер дә башыма сыйдыра алмыйм, бу хәлгә бер дә күнегә алмыйм, ышанмыйм, булмастыр ла, бу төш кенәдер, бу кинәт юкка чыгар, дигән ахмак уйлар һаман күңелне ярсытып, йөрәкне борчып торалар.

Сөекле әнием, сине бик сагындым, сиңа бик күп кайнар сәлам җибәрәм. Кайтышлый Мәскәүдән хәбәр итәрмен.

Туганнарга, дус-ишләргә бик күп сәлам әйт. Тиз көндә күрешүне теләп калучы улың Атилла».

«24.07.45 (15/9 алдым)

Кадерле әнием!

Синең 11 июльдә язган хатыңны алып, исән-саулыгыгызга бик шатландым. Үзем сәламәт, минем өчен бер дә борчылма, хатларым кайвакыт сирәгәеп китсәләр дә күңел төшерергә урын юк. Чөнки хәзер сугыш бетте инде, үлем үкчәгә басып йөрми.

Синең хатлар язып торуыңа ышанам. Аларның миңа килеп җитмәүсәбәбе шул, безнең соңгы айларда бер җирдән икенче җиргә күчеп, бер җитәкчелектән икенчесенә тапшырылып йөрүебездәндер.

Хәерле булсын, хәзер элемтә тагын тәртипләнде булса кирәк. Үткән хатларымда үземнең кайтырга җыенуым турында язган идем. Ул, әлбәттә, шулай, ләкин документлар, хәтта бүләкләр әзерләнгән булса да, приказның кайчан чыгасы әлегә билгеле түгел.

Әни, син ниндидер «Әдәби Татарстан» турында язасың. Ул нинди әйбер? Аны нәрсә белән «ашыйлар»? Әгәр ул газета яки журнал булса, җибәр. Әгәр ул альманах булса, җибәреп торма, кайткач укырмын.

Картлар өйләренә таралыштылар инде. Озакламый безгә дә чират җитәр дип торабыз. Исәнлектә күрешү насыйп булсын.

Әле бүген синең хатың белән бергә Әпсәләмнән дә хат алдым. Ул мескен Ерак Көнчыгышка барып эләккән икән. Аның өчен йөрәгем әрнеде. Моңа кадәр үземнең өйгә кайту хәбәрен ишетү белән (5 июльдән бирле) әллә ниләр уйлап, вакытның озак узуына түзә алмыйча, шул ук вакытта үзем дә адәм рәтле эшкә керешә алмыйча йөргән идем. Хәзер инде үземне кулга алып, өйгә кайту турында вакыты җиткәнгә кадәр онытырга булдым. Чөнки бик авыр, кеше тәмам акылыннан яза башлый. Кичә үземне, авызлыклап, хикәя язарга утырттым. Хикәя «Берлин янында» исемле. Анда укучыга үзем күргән һәм үзем урамнарыннан узган Берлинны сурәтләргә булдым. Бүген кичкырын тагын шул хикәямне кимерергә керешәм. Югыйсә Берлин медале тагып кайтып та, аның турында ләм-мим сүз язмый яту оят эш кебек тоела.

Казанда тормыш шартлары ничек? Сугыш корыткыч җиле шул килеш калдымы? Йә булмаса тынычлык үзен сиздерә башладымы? Кемнәр кайда? Кем кайткан? Туганнар, дуслар исән-саулармы? Барлык туган-дус-ишләргә, шул җөмләдән Суфия апага бик күп сәлам.

Ялкынлы сәлам белән сине үбеп, улың Атилла».

Озакламый, озакламый кадерле Казаныма кайтачакмын. Мине анда бала чагымнан ук үзенә билгән, авыр вакытларда миңа сабырлык биргән, якты өмет йолдызым, әдәбият дигән гүзәл бер мәйдан көтә. Мин туган илгә кайту белән, әлбәттә, җиң сызганып эшкә керешәчәкмен. Китап арты китап язып чыгарачакмын, үземнең баштан кичкәннәрне һәм тагы бик күп ишеткәннәрне сюжет калыпларына салып, роман, повестьларга әверелдерәчәкмен. Мине алда татлы иҗат куанычлары белән мөлдерәмә тулган бәхет ширбәтләре көтә. Мин бик, бик шат. Безнең сугышта җиңеп чыгуыбыз өчен шат. Үземнең утлы юллар аша узып исән калуым өчен шат, озакламый туган илемә кайтырга тиешлегем өчен шат.

Әйе, әйе, мин мең тапкыр кабатлыйм алам: мин бик бәхетле кеше! Бәлки, минем киләчәгем ал да гөл түгелдер, бәлки минем тормыш юлымда күңелсезлекләр, хәтта йөрәк өзгеч авыр көннәр дә бардыр. Шулай да мин бәхетле. Чөнки без җиңүчеләр. Без үзебезне генә түгел, барлык кешелек дөньясының якты идеалларын кара көчләрдән саклап кала алдык. Шул җиңүчеләр арасында үзеңнең булуыңны тою барлык шәхси кайгы- хәсрәтләрдән дә өстенрәк олы бәхет түгелмени?!

*1983—87 еллар.*



## Зөлфәт

### Шом

Гомеркәйләр, талгын болыт булып,
Серле якка табан акканда
Чирәмнәрдә чикерткәләр чырлый,
Юкәләрдән саркып бал тама.

Аланлыкта колын тояк чөя,
Күләгәдә йоклый әнкәсе,
Шомырт артларында чиләк чыңлый,
Күтәрелә кое сиртмәсе.

Тәтен менә мунча моржасыннан,
Төнбоектан бака «чулт!» итә,
Калын әрекмәннән — биек күккә
Рәшә булып зәңгәр чык китә.

Болындагы сусән арасыннан
Үрә басып йомран карана.
Кинәт «фыр-рлап» күтәрелә тургай —
Соңарган ла бүген сайраргa!..

Моңлы көйгә бер юлаучы җырлый —
Җигүле ат төшә иңкүгә.
...Шушы дөньяда бит яшәдем мин! —
Оның өчен болар — әкият...

Шул дөньяны белмәс балачакның
Ничек булыр олы чаклары? —

---

ЗӨЛФӘТ (1947) — *шагыйрь, «Язмышлар ярында», «Утлы бозлар», «Адашкан болыт» һ. б. китаплар авторы, М. Җәлил исемендәге бүләк лауреаты. Казанда яши.*

Тук болынны ач кыр ясап йөри
Замананың корыч атлары.

Соңгы мәлдә ни хәтерләр алар? —
Имәндерә уйлап карасаң...
Язмыш түгел лә бу, яшәү түгел —
Болгавыр бер кара тамаша!

Хушлашканда газиз дөнья белән
Күз алдына килер — мин беләм:
Әнә, офыклардан офыккача
Галәм нуры җиргә түгелгән...

Чирәмнәрдә чикерткәләр чырлый,
Юкәләрдән саркып бал тама —
Гомеркәйләр талгын болыт булып
Серле якка табан акканда...

## Коргылды

Яулар кичә алмас елгалар бар,
Инешләр бар — ташу кубарган.
Мәгърур гына ага данлы сулар
Дастаннарга кергән юллардан.

Дәүләтләргә исем биргән алар —
Тарихтай чал, бөек агымнар...
Тик, Коргылдым, сиңа эндәшәм мин
Дөнья аңлашылмас чагымда.

...Иң зур көчең — яфрак агызырлык.
Саегасың
тиен су эчсә...
Тик ярыңа гөл орлыгы төшсә
Ай үсәсен, никтер, көн үсә.

Мин ярата идем көзнең юка
Бозын өскә япкан чакларың...
Төпләреңдә синең — сары яфрак.
Мин ишетәм синең акканың!

Гомрем буе
урман төбендәге
Серләреңне синең тыңладым —
Шуңа упкыннарга егылмадым,
Бураннарда шуңа туңмадым.

Без төшәбез елга буйларына
Гармун тартып, җырлап уйнарга.
Гомрем буе
Синең ярга төшәм
Онтылырга... бары уйларга.

Исмең — гаярь! Әйтерсең лә анда
Кем каядыр ярсып ыргылды!

И Коргылды!
Минем өчен бит син
Керсез яшәтердәй сер булдың.

Гаҗәп мәгәр... Синнән читтә ничек
Яшәлде дә, ничек торылды?
...Сиңа охшап булмады шул инде,
Бу баланны кичер, Коргылды!

Әнкәемнең үзе иден бит син...
Син карыйсың һаман мөлдерәп.
Күкрәгемә кулым куям —
Бушлык!
Синдә калган бугай бу йөрәк...

## Сырынды

Бөтерелә бөдрә сырындылар[1]
Якын килергә дә шомлы ярда —
Гасырларның кара бураннары
Дулый бугай безнең карашларда...

Тәңре үзе җәзалыймы әллә
Сайлап җирнең кайбер кавемнәрен?
Ничә гасыр кайный кара буран! —
Ачыласы юктыр бу көннәрнең...

Ачыласы юктыр язмышларның!
Алгандыр ла тәңре безне сайлап...
Юл катысын эзләп кар астыннан
Изалана һаман күшеккән ат.

Иң гаҗәбе —
без һаман да исән!
Саклап килә безне нинди өмет?
Чынлап та бит — бер ачылыр еллар!
Безнең дә бит кояш чыгар көлеп!

Һаман юлдаш булган сырындылар
Эреп юкка чыгар ахыр чиктә.
Гел буранга күнеккән бу җаннар
Түзә алмас сыман ул бәхеткә...

Ә хәзергә... Безгә язган буран
Тынны буып, әйдә, дулап торсын —
Атла, аткай, юл булырга тиеш...
Эзлә генә, эзлә юл катысын!

## Чишмә сукмагы

Илләр искә төшкән чагында
Күз алдыма килә гел генә —

[1] Көрт кәрнизе, бөдрә кар сырты.

Сулар тибә чишмә төбендә,
Кызлар көлә чишмә янында
Илләр искә төшкән чагында.

Күз алдыма килә гел генә
Шул чишмәнең яшел сукмагы;
Каршыма ук килеп туктадың,
Чулпы чыңлый иде билеңдә —
Күз алдыма килә гел генә...

Сулар тибә чишмә төбендә —
Исеңдәме синең ул көннәр?
Ул көннәрдән калды төтеннәр...
Ләкин һаман әле күңелдә
Сулар тибә чишмә төбендә.

Кызлар көлә чишмә янында.
...Ул чишмәләр кипте ләбаса,—
Яңа заман — яңа тамаша!
Хыялымда бары, җанымда
Кызлар көлә чишмә янында.

Илләр искә төшкән чагымда
Утлы уйлар айкый күңелне:
Кемнәр җырсыз итте бу илне?
...Гүяки мин хөкем алдында —
Илләр искә төшкән чагында...

## Безнең болыннар

Кызларны без дәштек болыннарга...
Болыннарда атлар уйнаттык.
Шул болында кошлар
Җылысы бар —
Җылыйсылар
килә бер ятып...

Кыяр-кыймас атлап килде сылу.
Көттем аны болын түрендә.
Гөлләр исе бездән
Аңкып торды,
Балкып торды
дөнья күңелдә.

Кыяр-кыймас атлап килгән кызлар!
Сез кыюдыр дөнья көткәндә...
Беләм, ефәкләргә
Төрмәс идем —
Бирмәс идем
ләкин бүтәнгә!

Утка кагылгандай була идем
Сыйпаганда аның толымын...
Сөйгәнемне әгәр
Алсам үбеп:

«Аб-бау!» — диеп
тынды бу болын.

Сагышлымы сезнең яратулар?
Сөюләрдән бармы ярагыз?
Сезнең өчен яшим
Кимсенгән күк —
Мин сөйгән күк
сөеп карагыз!

Кызны болыннарга дәштек бит без!
Болыннарда атлар уйнаттык!
...Шул болында кызлар
Җылысы бар —
Җылыйсылар
килә бер ятып...

## Юл өзеге

*Рәдиф Гаташка*

Без өметле идек ул елларда...
Яндым, гашыйк булдым, саташтым —
Безнең адашкан, тын, кара якта
Шигырьләрен тыңлап... Гаташның.

Әйтте хәлфә: — Кара түгел бу як,
Шушында бит телнең оясы —
Кара булмый теле бай төбәк:
Сезнең кайбер сүзләр
Казаннарның
Ун сүзеннән хәтта көчлерәк!

Аксакал да иде безнең хәлфә
Һәм егет тә — кызлар сөйде ул —
Сезнең өчен Рәдиф Гаташ булса,
Безнең өчен хәлфә иде ул —
Төнен әйбәт шигырь яза алса,
Хәлфә түгел, хәтфә иде ул!

...Соңнан күпме үткелләрне кичтек! —
Кемнәр — кайда? Дөнья ни хәлдә?
Син әйткәнчә, бөек идеаллар
Одеалга калды бит, хәлфә!

Урәзмәтнең ак буранлы төне...
Кем йокысыз йөри төн ката:
— Торыгыз! Тор! Йоклар чакмыни?! — дип
Шагыйрь безне кереп уята.

Уята да... Мөслим түрендәге
Адашкан бер төнге авылда
Кар давылы дулый шигырь булып,
Әверелә шигырь давылга.

Бар иде бит безнең җанда өмет! —
Алда гел яз сыман тоелды —
Нишләп әле өзелделәр юллар,
Каршыбызда упкын убылды.

Кая гына барып чыктык, хәлфәм?
Инде кая барыйк, илдәшләр?
Без барасы юллар юкка чыкты —
Юл өзеге безнең бу яшәү.

Без өметсез, кара чорга кердек —
Дулый буран, ләкин ак түгел!
Инде үзем үрсәләнәм бүген:
— Торыгыз, тор! Йоклар чак түгел!

Әйт, мөгаллим — ник чор чорсызланды?
Кара карлар ява күңелгә —
Аксакал һәм егет була белгән
Чын ир җитми бугай бу илгә...

Хәер, ник шагыйрьдән җавап сорыйм?
Болай да бит сыкрый пакь күңел.
...Уяныгыз, адәм балалары!
Торыгыз, тор! Йоклар чак түгел!

## Терелербез...

Нинди садә, чиста булганбыз ла!
Уйларыбыз нинди пакь булган!
— Без сәгадәт өчен яратылган,
Бәхет өчен! — дигән чак булган...

Тезләнеп без дога кыла идек
Мәҗүсидәй карап бу таңга.
Без табына идек пар каенга,
Без ышана идек
Ватанга.

Матурлыгын тоеп, моңсулыгын,
Шигърилеген тоеп дөньяның —
Адәм улы! —
Табигатькә сеңеп
Гел яшәрмен диеп уйладың.

Әллә кеше акылыннан шашты,
Әллә инде дөнья тилерде? —
Кем уйлаган
Кеше булган өчен
Оялырдай көннәр килерне!

Юктыр, булмас,
Дөрес түгелдер бу!
Андыймыни, кешем, үзәгең? —
Син бит
Сөя,
Тоя белгән өчен
Фани дөньялыкны бизәдең.

Терелербез, савыгырбыз әле...
Китми калмас, китәр бу халәт!
Савыктырып сынган канатларын
Күңелләргә кайтыр мәхәббәт.

Тезләнешеп дога кылырбыз бер,
Мәҗүсидәй карап бу таңга...
Сокланырбыз тагын пар каенга,
Ышанырбыз тагын
Ватанга.



# Рәдиф Гаташ

## ГӨЛЪЯР

* * *

Галәмнең бу мизгеле —
Син пәйда булган көне —
　　Якты моңымы язның?!

Ә җыр, дисәм, яулыгың,
Аны кайда калдырдың? —
　　Гүя әләмен назның?

Эзләп эзләрдән үттек,
Тапмадык, кире киттек...
　　Сөйләнде сүзләр — азмы?

Яулык болгап бу көнне
Озаталмабыз инде —
　　Яулыкны... җуйдык аны...

Галәмнең гамьле өнен,
Ямь тулы бер мизгелен
　　Күңелгә уеп яздым.

Мәңгегә ул сөйләсен
Якты көн хатирәсен... —
　　Яулыгыңны да, язгөл!

---

Рәдиф ГАТАШ (Гатауллин) — *1941 елда туган, шагыйрь, «Ирләр булыйк», «Мәхәббәткә — мәрхәмәт», «Кар астында гөлләр» һ. б. татар, урыс телләрендә басылган уннан артык китап авторы. Казанда яши.*

* * *

Таллы ярда калган яр!
Үз-үзеңне сагынып,
Шул чакка хат салган яр!

Истә һаман сүзләрең:
— Кара, нинди яктырды
Синең моңсу күзләрең!

Бәлки, таплары беткән?
Иреннәрем, ахрысы,
Аларны юып киткән?

...Таплар, бәлки, еллардан?
Гүя таш ярып тапкан
Мең газаплы җырлардан?

Китсә тап күзләремнән,
Җанда моң эзләре лә...
Юылмаса гомергә?

Рас идеме сүзләрең:
— Үбүдән үзгәрдеме —
Йолдыз кебек күзләрең...

Тал янында калган яр!
Күңелемә яңа моң,
Яңа эзләр салган яр!

Мин ни әйтә алам, яр?!

* * *

«Карт куенында калач бар»...—
Калач, бәлки, язганым?..
«Яшь куенында камчы бар»...—
Аһ, үткән шул язларым!

«Калачыннан бизәрмен»...—
Шуңа җырда ачы моң...
«Камчысына түзәрмен»... —
Гомер, ник тиз агуың?!

Кирәкме син, чал акыл,
Базар узган — юнь хакың.
Мәйданда — яшь йөрәкләр,
Хислерәк, көчлерәкләр...

Өзә җанны бу җырлар:
«Карт куенында калач бар,
Яшь куенында камчы бар».

Яраткач, түзәсеңдер...—
Ник күзеңдә тамчы бар?
Ул да — бәхет яшедер?

Минем калач — ачы зар...

* * *

Ирennәрең утында дөрләде сүз:
— Хуплыйлармы? Тыңлыйкчы гөлләрне без.

Кечке җиләстә табигать тын калган.
Юк бер афәт гүя, шөбһә бер, ялган...

Күк омтылды Җиргәме? Минем йөзгә?
...Уй дәрьямда ике күз дөньяң йөзә...

Алышыңды анда төсләр, сурәтләр...
Тетрәнеп, читлеген шакый йөрәкләр.

Тоташты соң нинди утлар сулышы?
Үбүме бу — Җир һәм Күк омтылышы?

Шаулады карт тирәк — без, арып, сыенгач...
Сөендек — иренгә тамчы коелгач...

Төнне сызып үтте синең яшен-сүз:
— Бәхет түгелме? — Янабыз... яшибез!

* * *

Сизәсеңме, гөлъяр?

Көннәр кинәттән суытты...
Гөлләр күренеп боекты...
Осланда — күк монар...
Китәсеңме, гөлъяр?

Күмелә таныш сукмаклар,
Коела сары яфраклар,
Җил — җан өзгән моңнар...
Ник елыйсың, гөлъяр?!

Күпердән җәй үтте... Күздә
Югалырмы безнең эз дә?!
Күңел күнми моңар.
Син ни дисең, гөлъяр?

Яшьлеккә бит көз дә матур.
Алда күпме язың. Кайтыр
Кошлар... төсләр, нурлар, —
Синең гөлләр, гөлъяр!

Ә мин булмасам бу ярда,
Башкалар баш куяр талга,
Без яраткан җырлар
Гел яңгырар, гөлъяр!

Ә бүген... күзгә тамчылар,
Күңелдә яшь катыш гамь бар,
Сары төстә моңнар:
— Гөлъяр... Гөлъяр... Гөлъяр...

* * *

Үзең китсәң дә — табигатьтә сүзең:
Күзгә урманда йөрсәм дә берүзем,

Ишетәм сине, кыштырдап һәр үлән,
Һәр куак эндәшә синең өн белән...

Алтын төсләр — синең хисләр балкышы,
Таныш сукмакта — карашың яктысы...

Чаган яфрагы — ул йөрәк сурәтең...
Тибәр кебек — бары сулыш өрәсе.

Юк, һәр яфрак синнән сәлам — кулъяулык...
Миләшләрне үбәм (нигә?) кулга алып...

Бу матурлык — безнең җәйдән калганмы?
Вәхи көтсәм, намазлыгым — аланмы?

Дога укыйм тезләнеп — күктә күзем...
Өн ишетәм... валлаһи, синең сүзең!

## Әлвидагъ. Дүртьюллыклардан — кыйсса

* * *

Йә, бу алтын җырга хак та алтынмы?
Илһамчым, әйт: ничек түлим хакыңны?
Зурмы, нәниме — һәйкәлең куярмын,
Алтыннан булмаса, сүздән коярмын:

* * *

Җырда сине тагын күпме күтәрим?
Аштың җиденче катына күкләрнең...
Менгән саен ераклашсаң да миннән,
Төшә калсаң, бел: җирдә дә көтәрмен.

* * *

Ачы сүзеңә дә ачуым килми ник?
Яратуым гел арта, кимеми ник?
Салкынлыгыңнан ялкыным үсә тик,—
Дөньям яна — бер сиңа күренми. Ник?

* * *

Хистән исерек идем — һаман айнымыйм.
Яшьлегең җиңде — җиңелдем, аңлыйм мин.
Егылган килеш йолдызга кул сузам,
Бар бик сәер гадәтләре җанымның.

* * *

Аерылу һич көтмәгәндә булдымы?
Куркып уйлый идем күптән мин моны...
Барсына рәхмәт, үкенәм шунсына:
Гөлгә күмәлмәдем киткән юлыңны.

* * *

Күпме сер җанда — чишәргә хакым юк.
Гафу сорап баш исәм дә — хакым юк...
Хис кенә — аек уй өчен акыл юк...
Һәм акыл җуеп сөйсәм дә — хакым юк!

* * *

Сездә ниләр? Бездә көзләр, «нәзкәй бил»!
Кемгә ничек? Минем бәгърем кисә җил...
Соңгы сүзең кырау булса да җанга,
Үҗәтләнеп, анда әле үсә гөл.

* * *

Хат язармы яшьлек? Үткән — ни аңа?
Күпне кичергән йөрәк еш яза ала...
Үлемме йә ярлыкаумы — алиһәм,
Яз, бер хат-хөкемең белән җәзала!

* * *

Минем өчен язмыш кулы булдымы —
Чәчләреңнең тузгыды да дулкыны,
Ияртеп китте еракка... йөрәккә
«Саклан: упкын!» димәдең лә ул көнне!

* * *

Матур уенга маһир син, билгеле,
Беләм бу фәнне, димисең, билгеле...
Хава әбкәң ун мең елдан үрелеп,
Кайчан биргән горурлыкка өлгеңне?

* * *

Ярый әле калды миндә сурәтең...
Шуңа карыйм, килсә сине күрәсем...
Сөйлим аңа, шигырь укыйм, баш иям...
Дәшми рәсем: ачуың зур, күрәсең...

* * *

Сиңа каршы юләр хис баш күтәрде,
Көнләшүем, шигем дулкыны бәрде...

Хәзер тынган, бик юашланган күңел,—
Җәй узган шул, көннәр көзгә үзгәрде.

* * *

Бер «гөнаһлы» уй килә гел, көн туса:
Бүген хисем сиңа сәер тоелса...
Аңлар, дим, Киләчәк... Сине дә анда
Моңнарында алып барсын бу кыйсса!

* * *

Синең миңа ни әйтсәң дә — иркең бар...
Барсын да гафу иттерер күркең бар...
Әмма мин дә бәхетле, күр: сөюдә —
Шөбһә юктыр, шаһлык таҗым-бүркем бар.

* * *

Синең күзләр, ни әйтим, тиңсез алар...
Яшькелт-соры... тапсыз, гөнаһсыз алар...
Карашыңда гүя асылташ яна:
Артык горур... ә бәлки әрсез алар?!

* * *

Гашыйклар газәлләр язар, гүзәл яр!
Рәдифтән, газәл соңында, рәдифләр...
Исмеңне рәдиф алдыннан язмадым:
«Илгә фаш булсак», нәселең гаепләр!

* * *

Яшь табигатьне аңламыйм, янәсе...
Мүкләнгән-мыжык бу җаным, янәсе...
«Безнең — бәхәс, үпкәләшү, сүз,— дисең,—
Буыннар арасында — дау, һәммәсе!»

* * *

Бу акылсыз эндәшләрем куркытса,
Йә, оялтса сине — илдә сүз чыкса...
Ашыгып, баш тартма: гөнаһлы Җирдә
Чын бәхетең — нәкъ менә шушы булса?

* * *

Әллә каян килә аваз яңгырап:
— Барсы да үткәндә инде, бел, ерак...
Тезләренә баш куйган чагың уйлап,
Эзләренә яшь кой...— Бу көй — «Әлвидагъ»!

# Хикәяләр остасы



Татар әдәбиятында прозаның роман, повесть кебек күләмле өлкәсендә иҗат итүчеләр шактый булса да, хикәя жанрын үстерүдә җиң сызганып эшләүчеләр алай ук күп түгелдер.

Хикәя осталарының исемнәрен санаганда, Мин Шабайны урап узу һич мөмкин түгел. Аның әсәрләре, нигездә, авыл темасына карыйлар һәм революциягә кадәрге чордан безнең көннәргәчә дәверне үз эченә алалар. Һәр сүзенең эчке хасиятен яхшы белеп, искиткеч гади-халыкчан итеп, сурәтле тел белән язылган дулкынландыргыч хикәяләреннән күренгәнчә, язучының үз тормыш юлы, рух-күңел тибрәнешләре бай булганлыгын абайлау кыен түгел. Сез, хөрмәтле укучыларыбыз, моны журналда тәкъдим ителгән хикәясеннән дә ачык күрерсез.

Ә кыскача гына итеп әйткәндә, Мин Шабайның тормыш юлы болай. Мин Гариф улы Шабаев 1913 елның 28 апрелендә хәзерге Башкортостанның Кушнаренко районы Каратәкә авылында туа. Бик яшьли әтисез калып, ятимлек вә мөхрүмлекләр ачысын татый. Бәхет эзләп, читкә чыгып китә. Яхшы кешеләр аны урам малайлары арасыннан тотып алып, Мәскәү өлкәсендәге Хезмәт колониясенә урнаштыралар, юлдан язудан саклап калалар. Биредә ул укып белем ала, матур әдәбиятны ярата һәм үзе дә язгалый башлый. «Танып» (елга исеме) дигән беренче хикәясе матбугатта басылып чыгу яшь каләм иясен дәртләндереп, зур әдәбият мәйданына әйди.

Солдат хезмәтеннән соң, Мин Шабай Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Газетә редакциясендә, Татарстан радиокомитетында эшли, иҗат эше белән актив шөгыльләнә. 1936 елда аны Язучылар берлегенә әгъза итеп алалар. 1941 елда исә яшь язучының «Уйналмаган скрипка» исемле беренче хикәяләр китабы дөнья күрә һәм укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Ләкин ашкынып иҗат итеп йөргән бу әдипне башка күренекле әдәбиятсөягәть әһелләренә тигән шәхес культы шаукымы урап узмый. Ул яраткан хезмәтеннән, талантлы иҗатыннан, сөекле гаиләсеннән, якын дусларыннан, ниһаять, туган халкыннан аерылып торырга мәҗбүр ителә...

Әдип Себер сөргененнән Казанга 1955 елда гына әйләнеп кайта. Сәламәтлеге какшаган, рухы тапталган булуга карамастан, янадан иҗади эшкә чума. Бер-бер артлы «Бездә ел буе яз», «Тормыш баскычлары», «Тормыш чакыра» исемле очерк һәм хикәяләр китаплары, «Уяну» исемле тарихи-социаль романының беренче кисәге басылып чыга.

Яңа иҗат планнары белән яшәгән Мин Шабай-ның күп михнәтләр кичергән йөрәге 1963 елның 5 сентябрендә тибүдән туктады. Аның бик күп әсәрләре, уйналмаган скрипка шикелле, язылмыйча калды. Кызганыч, билгеле... Әмма ул кешеләргә, тормышка ихлас ярату белән сугарылган әсәрләрендә үзенең яшәвен дәвам итә.

**Мин Шабай**

# УЙНАЛМАГАН СКРИПКА

Мин яшьләй ятим калганмын һәм менә хәзер сукыр Зиннурны көннәр буе җитәкләп йөрим. Без, гадәттә, авылдан авылга йөреп, җәй буена бөтен өязне әйләнеп чыгабыз. Һәрвакыт диярлек җил-яңгыр астында яшәгәнлектән, минем бит-кулларым ярылып беткән, тавышым да карлыга бара. Ә бит әле кайчан гына:

— Ай, бигрәк моңлы бала инде, үзәкләрне өзә бит,— дип соклана торганнар иде.

Хәзер исә җитлекмәгән нәзек тавыш белән җырлап җибәргәндә, ничектер борчылып калам да башымны түбән иям. Миңа текәлгән кызганулы карашлар, сирәк кенә ишетелгән мактау сүзләре дә күңелемне күтәрә алмыйлар.

Еш кына миңа тиле Хәйрүш кушыла. Ләкин җырның иң югары ноктасына җиткәндә генә, безнең тавышлар кисәк кенә карлыга. Халык тарала башлый. Шулчак Хәйрүш үзе дә:

Алыр идем, сатар идем
Мәкәрҗәнең шәлләрен...

—дип җырлап, алар артыннан ваемсыз гына ияреп китә.

Дөрес булса, Хәйрүш кайчандыр чынлап та мәкәрҗә саен үзе скрипкада уйнап, үзе җырлап байларның күңелләрен ачып йөргән. «Тавышы гына түгел, чибәрлеге белән дә таң калдырырлык иде. Шуның аркасында харап та булды, мескен»,— дип сөйлиләр. Имеш, нindидер бер бай малае ниндидер бер мәҗлестә хатын-кызларны Хәйрүштән көнләшеп тавыш чыгарган да аңыннан яздырганчы кыйнап ташлаган. Шуннан соң, имеш, Хәйрүш юләрләнеп калган.

Дөресме-юкмы, анысын белмим. Мәгәр сирәк кенә үз акылына килгән чакларда ул:

— Савыгып җитсәм, сине дә скрипка уйнарга өйрәтермен дә, өчәүләп мәкәрҗәдән мәкәрҗәгә генә йөрербез,— ди торган иде.

Мин аның бу хыялларының эшкә ашуына ышанмый идем, әлбәттә. Бервакыт ул үзенең бозык кубызын миңа тәкъдим итте дә:

— Мә, өйрәнә тор, киләсе җәйгә мәкәрҗәгә чыгып китәрбез. Син уйнарсың, мин җырлармын, ә Зиннур абый акча гына җыеп йөрер,— диде.

Мин көлеп җибәрүгә, ул кубызын миннән җәһәт кенә тартып алды да әллә нинди ямьсез тавыш белән кычкыра-кычкыра йөгереп китеп барды.

Шуннан соң күп тә үтмәде, мин тагын сукыр Зиннурны җитәкләп авылдан чыгып киттем. Бу юлы без ераграк җирләрдән йөреп, озаграк торып кайттык. Мин инде Хәйрүшнең җырларын да, аның үзен дә сагынып беткән идем. Ләкин бездән соң ул да каядыр китеп барган, күрәсең. «Һаман хәбәр-хәтере юк, бер-бер хәлгә очрамагае, бичара»,— диделәр миңа. Ләкин ике-өч көн үтүгә, Хәйрүш тә кайтып төште.

Мин, аның кайтканын күреп, каршына йөгереп чыктым.

— Син мине көтмәгән идеңме? — дип сорады ул башымнан сыйпап. Безне бала-чага уратып алды. Кайсыдыр:

— Әй, дивана, курчак уйныйбызмы? — дип үртәргә тотынды.

Ләкин Хәйрүш аларга ачуланмады. Ул гадәттән тыш тыныч һәм мәрхәмәтле иде. Минем кулымнан йомшак кына тотып алды да ялварулы тавыш белән:

— Син тимә аларга,— диде.— Без бөтенебез дә алла коллары... Без бу дөньяда кунак кына...

Без бераз вакытка икебез дә ымсыз калып тордык. Хәйрүш миңа әллә ничек ерактан карый кебек тоелды. Аннан соң ул кинәт көлеп җибәрде һәм тагын шул сүзләрен кабатлады:

— Мине көтмәгән идеңме?

Мин җавап биреп өлгермәдем, баягы явыз малайларның берсе Хәйрүшнең аркасына чуерташ белән бәрде. Ләкин ул берни дә әйтмәде, төрле якка йөгерешеп качкан малайларның артыннан караңгы чырай белән чирканып карап калды. Шулай күпмедер вакыт үткәч, Хәйрүш аркасындагы озынча капчыгын капшап карады, аннары, кәефләнеп, җиргә төшерде. Минем гаҗәпкә калуыма каршы, ул аннан скрипка тартып чыгарды. Аның бөтен гәүдәсе калтырый, әмма йөзендә чиксез бәхет нурлары балкый иде. Ул скрипкасын миңа суза, үзе һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

— Мине көтмәгән идеңме? Юк, әйт, мине көтмәгән идеңме?

Скрипканың өзелгән кыллары чәбәләнеп беткән иде, мин аптырап:

— Бу килеш мин аның белән ни эшли алырмын икән,— дидем.

Бичара Хәйрүш бер миңа, бер скрипкага карап алды да тагын аркасын капшап куйды, аннары, нәрсәдер исенә төшерергә теләгәндәй, төпкә баткан күзләре белән бер ноктага текәлеп, хәрәкәтсез катып калды. Шуннан соң ул бервакытта да үз акылына кайтмады.

Скрипка турындагы хәбәр бик тиз арада бөтен авылга таралып өлгерде. Җитмәсә, имче Сәрбиҗамал арттырып та җибәргән: имештер, скрипканың кыллары кеше эчәгеннән ясалганнар. Алай гына да түгел, таң вакытында тәрәзә төбендә кеше булып ыңгырашып, өй иясен качыралар, имеш.

Көннәрдән беркөнне Сәрбиҗамал, урамда очрап, минем юлыма каршы чыгып басты. Әкияттәге убыр карчыгы диярсең: чәчләре коточкыч булып тузгыган, йөзендә кан әсәре дә юк, күзләре нурсыз. Ажгырып өскә ташланырга тора. Минем читләтеп узып китәргә теләвемне күргән:

— Кая качасың, эттән туган яман нәрсә? — дип кычкырып җибәрде ул.— Аягыңнан тотып, казыкка асармын, анаңа нәләт,— дип, беләгемнән эләктереп тә алды.— Хәзрәткә әйтеп, нәселең корыган нәрсә...— Ул ачуыннан буылып ютәлләргә тотынды, авызыннан әллә нинди әшәке исләр, төкерекләре чәчрәп тора башлады.

Скрипканың кыллары юклыгын аңлатмакчы булып авыз ачарга өлгермәдем, ул бөтенләй шашар хәлгә җитеп:

— Аһ, адәм актыгы... дөресен әйт, албасты, ул шайтан коралын сиңа кем бирде? — дип акырды.

Мин, каушавымнан булса кирәк, ачы аваз белән:

— Җибәр, Хәйрүштән башка кем бирсен! — дип кычкырып җибәрдем.

— Йә алла! Безгә тагын да нинди бәлаләр җибәрәсең бар икән инде. Балалар, сак булыгыз... илгә яман чир килә... Җен алмаштырган Хәйрүш аркасында юкка чыгабыз, анагызга нәләт... Хәзрәткә, балалар...— Карчык, тагын да әллә нинди сүзләр кычкыра-кычкыра, урам буенча йөгерде.

Мин, тиз генә өйгә кайтып, скрипканы тирес астына яшердем.

Әмма шуннан соң Хәйрүш үзе дә озак яши алмады, аяк өсте авырып йөрде дә, беркемгә дә авырлыгын салмыйча, тыныч кына үлеп китте. Дөньяда бичара булып кына яшәгән иде, үлгәндә дә ясин чыгучы булмады.

* * *

Бичара Хәйрүш! Әле дөнья куймас борын ук каберен киртә белән уратып алырга дип күңел беркетеп куйган идем. Төнлә белән тирес астында яткан кылсыз скрипканы казып алдым да уен кораллары төзәтүче Фәтхи бабайга күтәреп бардым. Авылда йогышлы авыру таралганлыктан, ул мине теләми генә, салкын чырай белән кабул итте.

— Аягыңны сөртәсең сөртүен дә, кием-салымыңа башка нәрсә ияреп килмәдеме икән,— диде. Әмма скрипканы күргәч, аның чырае ачылып китте.— Ишеткән идем, дөрес икән, әле үземнең дә күрәсем килгән иде,— диде ул, скрипканы кулымнан алып.— Әйе, әйе, нәкъ үзе... Шушындый ук берничә скрипканы моннан күп еллар элек Донбасста күргән идем мин. Берсен төзәтү бәхетенә дә ирештем. Шуннан соң уен кораллары төзәтүче булып киттем инде.— Ул скрипканы әйләндергәләп карады-карады да:— Юк, мин моны төзәтә алмыйм,— дип, кире миңа сузды.

— Миңа аны төзәтергә кирәкми, мин аны сатмакчы идем.

Фәтхи карт скрипканы кире алды, тагын чиерткәләп карады, нәрсәгәдер колак салып, озак-озак тыңлап та торды.

— Син моны черетеп әрәм иткәнсең.

Кайгы ачысы әйтерсең буыннарымны какшатып җибәрде, чайкалып куйдым.

— Хәер, бу караңгы елларда нәрсәләр генә, кемнәр генә әрәм булмый,— диде Фәтхи карт, авыр сулап.

Әлеге йогышлы авыру башка авылларга да таралган, имеш, дип сөйләсәләр дә, без йөреп кайтканда, тирә-якта хәзергә әле үлем-җитем яки бүтән хәвеф-хәтәр ишетелми иде. Тик шуннан соң күп тә үтмәде, безнең авылда берничә кеше үлеп китте. Өстәвенә, ни сәбәптәндер, терлекләр дә тояк күтәрә башлады. Басу капкасы төбенә сакчылар куелды. Авыл тынып, урамнар бушап калды. Аннары җәе дә артык коры. Дала ягыннан җылы җилләр искәндә, карт-корылар:

— Әй ходаем, бәла-казадан саклый күр инде бәндәләреңне,— дип, бөтенләй хафаланып калалар.

Ә бит андый чакларда, үч иткәндәй, балалык шаукымы үзен аеруча нык сиздерә. Өйдә бикләнеп яту да тәмам туйдырды. Мин тагын Фәтхи бабай янына киттем. Бу юлы ул мине җылы гына каршы алды.

— Үткәндә син бер дөрес фикер әйткән идең. Ул вакытта абайлап җиткермәсәм дә, үзеңне күргәч, тагын шул искә төште әле,— диде.— Чынлап та, шушындый аулак заманда, форсаттан файдаланып, мәрхүмнең каберенә киртә тотсак, саваплы бер эш булыр иде.

Анысын-монысын хәстәрли торгач, шактый вакыт үтеп китте; без күтәренеп урамга чыкканда, инде көн кичкә авышкан иде. Шулай да һава бөрку иде әле. Фәтхи бабай алдан төште.

Куанычымнан мин кая басканымны да белмим, берничә тапкыр сөртенгәләп тә алдым. Фәтхи бабай, җилкәсендәге такталарын бәйләмә белән җиргә төшереп, хәл җыярга туктагач:

— Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, сине, улым, җир күтәрми, ә миңа һава җитми,— дип, күңелсез генә көлемсерәп куйды.— Ай-һай, бигрәк аямый кыздыра бу, агай,— ул кулын маңгаена куеп, кояшка карап алды.— Бераз сабыр итәсе калган икән. Тынычрак та булыр иде, бәлки...

Фәтхи бабай сүзен әйтеп бетермәде, мәчет ягыннан тәкбир тавышлары ишетелде. Минем җегәрем үк китеп барды.

— Хәерлегә булсын...— диде Фәтхи бабай да ашыга төшеп.

Зират тыкрыгына җитәрәк, безнең каршыга бер төркем халык килеп чыкты. Арада имче Сәрбиҗамал да бар иде. Ләкин мин аның тузган чәчләрен генә күреп калдым. Кемдер беләгемнән кысып тотты да җан ачуы белән каядыр өстери башлады. Берничә кеше:

— Тотыгыз, тотыгыз шул бәдбәхетне, җибәрмәгез, авыз-борынын кара кан белән юыгыз,— дип кычкыра-кычкыра Фәтхи бабайга ташланды.

Күз ачып йомган арада, икебезне дә бәйләп ташладылар.

Ни сәбәптәндер, баштан мина тиюче булмады, Фәтхи бабай тирәсендә әүмәкләшә-әүмәкләшә:

— Кара син аны, ат азгыны тайга ияргән бит...

— Башына бир...

— Күкрәгенә менеп таптагыз...— дип зык куптылар.

— Җәмәгать, бу гына аз әле, һәркемгә гыйбрәт булсын, мәлгунь Хәйрүшне дә кабердән казып алырга, нәҗес мәетен утта яндырырга кирәк,— дип кычкырды берсе.

— Дөрес, бу хәвеф-хәтәрнең башы шуннан китте: әлеге кеше эчәгесеннән ясалган скрипканы да ул алып кайтты...

Мулла үзенең калын, көр тавышы белән тамак кыргалап алды да:

— Фатихасын да мин бирәм, гөнаһысын да үз өстемә алам,— диде.— Әмма ләкин иң элек тереләреннән башларга кирәк.

Берсе яңак төбенә тондыруга, күз алларым караңгыланып китте. Һушыма килсәм, дөм-караңгы. Бөтен тәнем тоташ сызлавыкка әйләнгән, бар җирем сулкылдап, суырылып-суырылып авырта.

Якында гына әтәч кычкырды. Димәк, тиздән таң. Сакчылар куйганнар булса кирәк:

— Теге карт пәрие эт җан икән, инде үлгәндер дип калдырып киткәннәр иде, өенә мүкәйләп кайткан бит,— дип сукранды берсе.

Аннары ачкычлар шалтырады.

— Мә, тот. Хәзрәттән фатиха алдыңмы?

— Хәзрәт күрше авылга туйга киткән диме шунда, мин староста кушуы буенча гына...

Баягы тавыш тагын кабатланды.

— Кара аны, күз буып кача күрмәсен.

— Качса, үз көнен үзе күрер. Ул да әдәм баласы ич,— диде икенчесе, авыр сулап.

Ә бит теге эчкерлесенең сүзләрендә дә дөреслек бар: мин чынлап та качу турында уйлап ята идем. Ләкин күз буып түгел...



## Ак кәгазь

Нинди аңга юлыгырсың, ак кәгазь?
Пакь җанлымы бирер синдә пакь вәгазь?
Бушка юрап, тезмәсләрме «шагыйрь»ләр
Аһ, вәземле... әмма тозсыз шигырьләр?
Йә ябышыр өсләреңә якты хат,
Эчке зарын уртаклашса адәм-зат.
Тагар бәгъзе — асыл җанга яманат,
Көнчеллеген җиңә алмый ничә кат.
Вәйранлыкка өндәмәстер зиһене бар —
Ун дистә ел гомернең дә чиге тар.
Чарлар өчен тәңре бирә үткен чар,
Корыч каләм... Эзен көтә кайчак... дар.
...Нинди аңга юлыгырсың, ак кәгазь?
Тормыш, фәкать тормыш бирер пакь вәгазь...
Өстәлеп көч — өзеп ябык калыпны,
Күтәр — кулын сузып чүккән халыкны!

## Синдә яшим

Син — аяз күк, тере йолдыз
күл төбендә,
Иң якын дус, тугры сердәш
төксе көндә.
Төрле уйлар, урын яулап,
синдә чыга,—
Кайгы-шомлык бүлешелә,—
чыда, чыда!
Канат җәеп, синдә очам,
уйныйм, уйлыйм.
Моңнарымны синең җайга
җайлап җырлыйм.
Синдә янам, синдә көям,
синдә сүнәм.

---

ИДЕЛБИКӘ (Лена Садыйкова) — *Ульяновск шәһәрендә яшәүче шагыйрә. Көндәлек матбугатта шигырьләре даими басылып килде.*

Язмышыма каршы төшәм
яисә күнәм.
Бата-калка бөтереләм
дулкынында,
Ай-йолдызга күтәреләм
кай чагында.
Туктый сәгать — онытылам,
галәм тына,
баштүбән мин чумсам сиңа,
шигъри дөнья!

## Сәлам көтәм

Өзелеп сәлам көтәм —
Килмәгән хатлардан,
Ялкынланган сәлам
Алсам да ятлардан...
Синсез бәйрәм итәм
Мартларны-майларны,
Ел җебенә тезәм
Көннәрне-айларны.
Утырсам, янымда
Син утырган төсле...
Талсам, хыялымда
Синнән алам көчне.
Сәлам көткәнемне,
Өзелеп, үзеңнән
Ук аткан таң белә
Йокысыз күземнән...
Бергә булган язны
Онытальмыйм, бәгърем.
Бәхет биргән язның
Үсә бара кадере...
Язмыйм, дидем, бүтән,
Язма, дидем, күптән,
Сулам үкенечтән —
Сәлам көтәм, көтәм!

## Тидермә иреннәреңне

Таң чыклары энҗе сыман
Ал кояшта җемелди.
Тик үтә бел — таң чыгына
Иреннәрең тидерми —
Яшьлек хисең йөрәгеңне
Ташлап китмәсен өчен,
Мәхәббәтең таң чыгыдай
Очып, китмәсен өчен,
Мәхәббәтең таң чыгыдай
Очып китмәсен өчен.

Көтеп яңгыр, кояшлы көн,
Үстер яшьлек гөлләрен.

Үрсен аллы-гөлле чәчәк
Язмышыңның көннәрен.
Ят иреннәр иренеңә
Тиеп, үпмәсә иде.
Үзәкләр көйдергән язмыш
Сиңа төшмәсә иде.
Бер аерылып, бер ялганып
Гомерең үтмәсә иде.

Таң чыклары энҗе булып
Ал кояшта җемелди.
Тик үтә бел — таң чыгына
Иреннәрең тидерми.
Син үтә бел таң чыгына
Иреннәрең тидерми:
Ялган энҗе — таң чыклары
Очып кибәр, сиздерми.
Ялган энҗе — таң чыклары,
Очып китәр, сиздерми...

## Була шундый көннәр

Була шундый көнең:
Үткәнне айкыйсың.
Сүтеп йөрәк серең,
Тик көлен таптыйсың.
Көтелмәгән мизгел
Йә таң булып ата,
Төшкә дә кермәгән
Зур хисләр уята!

...Йөрисең бер мәлдә
Җүләр кебек шашып,
Гамәлдә дә түгел,
Үзең дә адашып.
Уй-гамьнең атлардай
Син тартасың күбен —
Язмышың төягән
Көч җитмәслек йөген.
Йә күп еллар аша
Ал нур эзләп бары,
Үз чигеннән таша
Күңел дулкыннары.
Эх! Һәр көн гыйффәтлек
Булсачы ярдәмгә,
Ак бәхеткә батып
Яшәргә гамәлдә!

## Синнән качам

Сүзләреңнән туя алмыйм,
Йөзләрең дә, ай, чибәр.
Шулай да сиңа карамыйм,
Тылсымлы күзем тияр.
Утта, дисең, янам-көям
Куркам тагын, шунсыннан:
Үзем сабыр гына сөям —
«Үтә кызыл тиз уңа».
Син — һаман очкан күбәләк,
Мин кырда, кыргый чәчәк.
Ләкин синең юлларыңда
Булмас минем киләчәк.
Качам синнән, нигә димә,
Нигәлеген беләсең:
Чәчәк күмгән яшьлек гөлен
Син бит җиргә иясең...



## Рафаэль Сибат

# «Йолдыз төшә сызылып...»

*Рафаэльнең студент чакларында ук матур-матур шигырьләр язганын беләм. Яшьтәшләреннән Мөдәррис һәм Зөлфәтләр белән кайнашып, аралашып яшәде. Тулай торакта ярсып-ярсып шигырь укулар, туган тел язмышы өчен сызланулар... Аннары Рафаэль Сибат (Хуҗин) туган якларына — Киров өлкәсенә китеп барды. Туган ягы аны көткәндер. Анда да бит татар авыллары сибелгән. Бу авыллар күңел күзе белән һәрчак Казанга, татарның рухи мәркәзенә төбәлгән. Халыкта шушы җепләр өзелми, өзелсә дә аны ялгаучылар табыла.*

*Рафаэль сирәк-мирәк Казанга килеп чыккалый. Киров өлкәсендә «Дуслык» газетасында эшли икән. Папкасында — йә повесть, йә шигырьләр булыр. Тормыш юлы сикәлтәлерәк килеп чыкса да, әдәби мохитебездән күпмедер ераклашкан булса да, ул язуын ташламаган икән, шөкер. Провинциягә (начар мәгънәсендә аңлашылмасын!) киткәннәрнең, гадәттә, күбесе иҗади хезмәттән читләшә. Рафаэль исә тормышка, шигърияткә, матурлыкка ышанычын югалтмаган, дөресрәге, югалтырга теләмәгән икән. Аның өчен иҗат — үз-үзеңне, заманны аңларга тырышу, хакыйкать эзләү. Барлык шигырьләре дә камил дәрәҗәдә дип әйтергә җыенмыйм. Поэзия серләрен өйрәнүдән туктасаң, осталыкка ирешүдән дә туктыйсың лабаса. Рафаэльнең сызланулы җаны, шигъри күзләре бар. Тормышка ул күңел тәрәзәсе аша карый.*

*«Йолдыз төшә сызылып», — ди шагыйрь. Йолдыз атыла икән, моның хикмәте, мәгънәсе бар. Кеше күңелендә шигъри йолдызлар атыла икән, бу да юкка түгел. Моның шулай икәнен без авторның бер бәйләм шигырьләре белән танышканнан соң азмы-күпме тоярбыз дип уйлыйм.*

*Рашат НИЗАМИ*

### Тәрәзә аша

Адәмдә иң яман Каршылык:
(Ни әйтер, аңлатып, фән улы?)

Тән өчен яшәсәң — Җан сызлый,
Җан өчен яшәсәң — Тән дулый...

Явызлык, Яхшылык — тән һәм җан...
Ут һәм Су — һәр бәндә галәмдә,
Ник алай?
Бу җанга дигәнең — тән өчен,
Тән өчен — ул җанга, гамәлдә...

Янасың-туңасың бу Җирдә...
Гел шулай — калганчы Юк булып.
Дөрләсәң — сүндерә Су сибеп,
Бозлансаң — эретә Ут булып...

Тән — ир ул, Җан — хатын... Нинди пар?! —
Чыгармы алардан
Камиллек тишелеп?..
...Поездда мин барам.
Шәмәрдән —
Яңгырга шәбәргән...
Арчада кар төшә ишелеп...

## Юл чатында

Торам басып юл чатында...
Гомер — җилнең искәне...
Кемне эзлим үткәннәрдән —
Җаным белән сискәнеп,
Мөлдерәмә хисләнеп...

Торам басып юл чатында...
Ага дәһшәтле Вакыт.
Кемне көтәм киләчәктән:
Кем тора ишек шакып?
Керер ачып, йә ватып...

Торам басып юл чатында...
Йолдыз төшә сызылып.
Үткәннәр белән киләчәк
Арасына кысылып,
Яшәү тора ымсынып...

* * *

Заманнар болгавыр —
Чишелде Рәсәйнең
Чабата чолгавы.

Заманнар яман бик —
Кысканнар халыкны.
Кысалар һаман ник?

Заманнар табышмак —
Шушындый заманны
Безләрме табышкан?..

Заманнар болгавыр —
Өзелде Рәсәйнең
Чабата чолгавы...

## Кеше

Җир шарын Ат итеп
Атланып чабар бу!
Җир шарын: «Алма!» — дип,
Шатланып кабар бу!

Башканы җәлләрме? —
Үз-үзен үтергән
Бердәнбер җандыр бу!
...Иң сәер җанвар бу...

* * *

Томырылып чаба Вакыт —
Тавышсыз-өнсез Дәһшәт...
Ыжгырып барган чагында
Үлем чакырып дәшсә?..

Берни кылып булмый монда!
Бу — дарга бару сыман...
Бер утырып, бер төшәсе
Яшәүнең арбасыннан...

* * *

Җан — бер нур ул! Беркөн китәр
Рәсмем алып еракка —
Төн-галәмнең төпкеленә,
Мәңгелек төп торакка...

Тик ул торак нинди икән?
Охшармы Җир яменә?..
Бик кызганыч — без белмәбез
Мәңгелекне мәңгегә...

## Хиссият

Уйны куй!
Буй җитмәс шикелле —
Яшәүнең серләре сихерле.
Бу яклар
Шагыйрьсез булса да,
Һәр үлән, һәр чишмә шигырьле...

Уйны куй!
Хис бассын бер мәлгә —
Җан-рухың кояштай түгәрәк.
Күр әнә:
Бураннар эченнән
Киләдер ак шигырь тәгәрәп.

* * *

Шигърияттә булсаң ихлас —
Шагыйрь җаны, димәк, ислах...

Кер кердеме? Төшә тәшвиш —
Җан-Рух нинди? Яса тәфтиш...

Шигърият ул — шул ук Ислам,
Иман белән башта ыслан...

Тукай да бит — Алла колы,
Шагыйрь юлы — Тәңре юлы...



# ТУКАЙЛАР, ИСХАКЫЙЛАР ЮЛЫ...

70 ЯШЕ ТУЛУ УҢАЕННАН ГАЛИМ
ҺӘМ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬЧЕ ИБРАҺИМ АГА НУРУЛЛИН БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



*— Хәзерге ачыктан-ачык сөйләшү вакытында Сезгә бирәсе килгән сораулар күңел түрендә бик тә күп, әлбәттә, хөрмәтле Ибраһим ага. Нәкъ менә Сез булганы өчен ул сораулар аеруча күп. Ни өчен «Сезгә аеруча күп» дибез? Чөнки без Сезнең һәрчак үз күңелегездә булганны яшермичә, турысын әйтә торган кеше икәнегезне беләбез. Сез теге вакытта да, хәзер дә кемнәргәдер ярарга тырышып, ошарга теләп түгел — ә нәкъ менә үз иманыгызга, үзегез нык ышанган идеалларга аз гына да хилафлык кылмаска тырышып яшәдегез, эшләдегез һәм әнә шулай көрәштегез дә!*

*Нәкъ әнә шундый кеше булганыгыз өчен — үзегез ышанган позициядә үтә нык тора торган шәхес булуыгыз өчен — безгә Сезнең белән әңгәмә кору кызыклы да. Шулай ук, сүз уңаеннан әйтеп китик: бу баш астында басыла барган әңгәмәләргә без нәкъ менә Сезнең шикелле, баш бирмәс, принципиаль шәхесләрне тартырга тырышабыз да инде.*

*Ә беренче соравыбыз менә мондый.*

*Әдәби тәнкыйть өлкәсенә килүегез ничек булды. Моңа этәргеч ни иде?*

— 1942 елның ноябреннән 1943 елның октябренә кадәр мин Әстерхан госпитalендә яттым. Шушы бер ел эчендә бик күп әсәр укыдым. Шулар арасында Д. Писаревның «Реалисты» исемле зур мәкаләсен һәм В. Белинскийның мәкаләләрен яратып укыган идем. Әнә шул мәкаләләр миндә тәнкыйтьче булу хыялының яралуына сәбәп булды да инде. Әгәр Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты» романы турында мәкалә язсам, ничек язар идем икән, дип уйланып ятканым да булды.

Ниһаять, кырыгынчы елларда, Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә укыган чагымда, бу хыялымны тормышка ашыра башларга вакыт җитте. Мин Г. Әпсәләмов иҗаты буенча «Әдәбиятта алдынгы эшче образы» исемле мәкалә яздым. Күләме машинкада 40 бит булды.

Мәкаләне «Совет әдәбияты»на бирдем, чөнки мин аны үз журналым саный идем (моңарчы анда минем берничә хикәям басылган иде). Ул вакытта «Совет әдәбияты»нда баш редактор Кави Нәҗми иде. Беркөнне шулай, мәкаләмнең язмышын белешергә дип, журнал редакциясенә бардым. Шунда Кави Нәҗми мине күреп алды да, беркадәр балалар авызына охшаган авызы белән хәйләкәр генә елмаеп: «Мәкаләңне редакцияләдем, әнә Булаттан (Булат Гыйззәтуллин журналның секретаре иде) алып кара», — диде. Алдым, карадым. 40 битле мәкаләдән 7 бит калган! Кәефем китте, билгеле. Әмма тавыш куптарырга ул вакытта әле кыюлыгым җитмәде. Хрестоматияләргә кергән зур язучы Кави Нәҗми редакцияләгән дә булгач, бигрәк тә.

Мәкалә басылып чыкты. «Совет әдәбияты» кадәр «Совет әдәбияты»нда басылу ул вакытта, бигрәк тә безнең студентлар даирәсендә, зур дәрәҗә санала иде. Иптәшләр мине шаяртып безнең Белинский, дип йөртә башладылар.

*— Торгынлык чорында Сезнең чын Тукай өчен — бизәлмәгән һәм шомартылмаган, большевистик кызылга манылмаган Тукай өчен көрәшүегез дә, һәм соңгы елларда милләткә Гаяз Исхакыйны кайтарып бирү өчен җан-фәрман тырышуыгыз да, шулай ук башка адымнарыгыз да — алар һәммәсе безгә нык иманлы шәхесне белгертеп торалар иде.*

*Кеше шәхесенең үзәген, аның рухи, әхлакый тотрыклылыгын билгели торган принципиальлектән сүз башлап китү бер дә юкка түгел. Әлеге асыл сыйфат хәзерге кешеләрдә бик сирәк күренә. Инде, ниһаять, гаделлек чоры килде, үз фикеребезне яшермичә белдерә алу вакыты җитте дисәк тә гәрчә... Ул сыйфат шул хәтле сирәк очрый: хәтта без аны онытып та барабыз шикелле. Хәтта матбугаттагы язмаларда да ул хакта сүзләр кузгатылмый диярлек... Болай бару дөрес түгел бит! Шул мәсьәләдә Сезнең уй-фикерләр ничегрәк икән?*

— Соравың катлаулы, җавап бирү кыен булса да, тырышып карыйм. Синең әйтергә теләгәнең әхлак мәсьәләсенә карый булса кирәк.

Мөстәкыйльлегебезне тәмам ныгытып, халкыбызны мул һәм бәхетле тормышка чыгару өчен намуслы, вөҗданлы, нык иманлы кешеләр кирәк дип әйтергә телисең. Бу мәсьәләнең сине борчуы очраклы хәл түгел дип уйлыйм. Күп гасырлардан бирле әхлак мәсьәләсе безнең фикер ияләренең, зыялыларның, аерым алганда, язучыларның игътибар үзәгендә булып килгән. Ислам дине әйрәтмәләренең кимендә өчтән бер өлеше үк әхлак кодексыннан гыйбарәт. Әдәбиятыбызның борынгы дәвере әхлаклы һәм мәгърифәтле хөкемдарлар көче белән халыкның җәбер-золымнан, ачлык-ялангачлыктан коткару идеяләре белән сугарылган. XIX гасыр иҗтимагый фикерендә мәгърифәтчелек идеологиясе өскә чыга. Мәгърифәтчеләр фикеренчә, җәмгыятьне үзгәртеп кору өчен, беренчедән, фәнни-техник прогресс, икенчедән, халыкны әхлак ягыннан тәрбияләү кирәк. Әнә шул идеяләрне күтәреп чыккан һәм аларны халык аңына сеңдерү юлында арутталу һәм куркуны белмәс көрәшкән бөек шәхесләрдән Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Габдерәшит Ибраһимов, Ризаэтдин Фәхретдинов кебек фикер ияләре алдында без бүген маңгай җиргә тигәнче баш ияргә бурычлыбыз.

XX йөз башында татарның иң алдынгы кешеләре «халыкка ирек, крестьяннарга җир яулап алу өчен иң элек самодержавиене аударырга кирәк» дигән фикергә килсәләр дә, әхлак мәсьәләсен дә онытмыйлар иде. Чөнки җир һәм ирек белән генә эш бетми әле. Җирне икмәк урынына ашый алмыйсың, яисә әхлаксызлык хөкем сөрсә, кешеләр арасында татулык, бер-берсенә ихтирам булмаса, ирректән ни файда? Ул чорда Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан кебек яңа фидакарьләребез килеп чыкты һәм алар үз артларыннан меңнәрне иярттеләр.

Бүген без олы һәм кече буын мәгърифәтчеләренең төшләренә дә керә алмаган уңышларга ирештек. Бөтенхалык фатихасын алган, Конституция белән ныгытылган мөстәкыйль дәүләтебез бар. Бәрәкәтле җиребезгә, җир асты байлыкларыбызга үзебез хуҗа. Соң нәрсә җитми? Син әйткәнчә, әхлак... Әхлак җитми!

Дөрес, безнең Фәндәс Сафиуллин һәм, ара-тирә арттырып җибәрсәләр дә, Фәүзия Бәйрәмова белән Зәки Зәйнуллин кебек каһарманнарыбыз бар. Ләкин сүз аерым шәхесләр турында бармый. Сүз массаны тәрбияләү, халкыбызны бербөтен тату гаилә итү турында, кеше хакына керү, икейөзләнү, ялганлау, ялкаулык кебек әшәке сыйфатлардан тәмам арыну турында бара. Әхлак нормалары, гадәттә, ниндидер бер олы идеягә нигезләнә. Соң безгә нинди идея кулай?

Диннең әхлакка нигез булып ята алуына мин ышанып җитмим. Чөнки, беренчедән, христиан һәм ислам диннәре гасырлар буе кешеләрнең аңын биләп килсәләр дә, кеше хакына керүне, ялганны, җәбер-золымны бетерә алмадылар, икенчедән, дин фән белән үзара тискәре пропорциядә тора, ягъни табигать фәннәренең уңышы диннең сферасын тарайта һәм киресенчә. Югары белем турында әйтеп тә тормыйм инде, урта белемле кешене дә бүген җәннәт белән кызыктыра яисә тәмуг белән, ай-һай, куркыта алырсың микән?

Әхлакка нигез булырдай идея, димәк, дөньяви һәм реаль җирлекле булырга тиеш. Рус дворян яшьләренең яхшы, намуслы бер өлешен туплаган, аларга Сенат мәйданына чыгарга көч биргән идея нәкъ менә шундый дөньяви идея — крепостное правоны бетерү идеясе булган. Яки менә эшчеләр сыйныфын азат итү, яисә коммунизм идеясе миллионнарның аңын биләп алып, Октябрь революциясен ясауга һәм гражданнар сугышында җиңеп чыгарга көч бирде. Октябрь һәм гражданнар сугышына төрлечә карарга, аларны төрлечә бәяләргә мөмкин, әмма аңа карап алар идеянең нинди зур куәткә ия булганына мисал булудан туктамыйлар.

Соң безнең әхлак нормалары нинди идеягә нигезләнергә тиеш? Халыкка

хезмәт идеясенә, билгеле! XX йөз башының алдынгы кешеләренең әхлагын нәкъ менә шул идея билгеләгән, ул дәвердә шул идея хакына зур эшләр эшләнгән. Шул идея хакына Тукай янып үлгән, Г. Исхакыйның башы төрмәдән, сөргеннән чыкмаган. Г. Тукай «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» исемле шигырендә ул идеянең асылын һәм әхлак нормаларын аңнарга сеңдерүдәге ролен бик матур итеп ачып биргән. «Тормышта нинди эш чын ләззәт һәм тәм бирә?»— дигән сорауны куя да, ул аннары матур кызның билен кочумы, паратта җилдерүме, хәмер эчүдәме, сәүдәдән килгән табышны санаудамы, дип санап килә дә, түбәндәгечә тәмамлый:

> Бәнчә бу дөньяда һич чын тәм дә юктыр, ямь дә юк;
> Һичберендә буларның ләззәт тә юктыр, тәм дә юк.
> Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар,
> Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

Сәяси мөстәкыйльлегебезне нигыту җирлегендә күп гасырлар буе ачлы-туклы яшәп, изелеп, кыерсытылып килгән газиз халкыбызны хөр һәм мул тормышка чыгару идеясеннән дә зуррак һәм бөегрәк идея юк бүген. Урлама, дип үгет-нәсихәт укырга мөмкин, әлбәттә, әмма бу үгет әлеге бөек идеалдан чыкса, шуңа тыгыз бәйләнгән булса гына тәэсирле була алачак. Ягъни, урлама — ул халык милке, җәберләмә, ул синең туганың. Кыскасы, милләтнең, халыкның киләчәге хакына, үзенә тапшырылган эшне «миннән китканче» дип башкару, вәгъдәсезлек, икейөзлелек, ялганлау кебек сыйфатлар, шәрә килеш урамда күренү оят булган кебек, оят эшләр булып әверелергә тиешләр. Әдәбият һәм сәнгать, билгеле инде, югары әхлак нормаларын аңнарга сеңдерү эшендә җигелеп тартырга тиеш. Кыскасы, халык файдасына булган эш-гамәл әхлаклылык билгесе итеп каралырга, халык зарарына булганнары әхлаксызлык итеп тамгаланырга тиеш.

*— Югарыда әйтеп үтелгәнчә, Сез тормышта да, шулай ук фәндә һәм әдәбиятта да нык-лык, принципиальлек үрнәге күрсәттегез. Мондый позицияне гомер буена саклау, әлбәттә, җиңелдән түгел. Күпләр белән үпкәләшәсең, ачуланышасың... Ә менә Сез ничек итеп гомер буе принципиальлек позициясендә торып кала алдыгыз? Иң гыйбрәтле конфликтларыгыздан берничәсенә биредә тукталып үтмәссезме икән?*

— Ничек принципиальлек позициясендә торып кала алдым?

Намус дигән нәрсә канына сеңгән булу өстенә, үз-үземә хөрмәтнең дә җитәрлек булуы аркасындадыр дип беләм. Нинди дә булса бер ярамый торган эш эшләнә башлап, мин дәшми калсам, яисә икеле-микеле сүзләр белән генә чикләнсәм, үземнән-үзем җирәнә торган идем. Ә үзеңне хөрмәт итмәгән килеш ничек дөньяда яшәргә мөмкин?

Конфликтлар дигәндә, алар, билгеле, күп булды. Шуларның иң кискене һәм гыйбрәтлесе Тукай белән бәйле. Халкыбызның Тукайга мәхәббәте, мәгълүм булганча, чамасыз куәтле. Тукайга карата кечкенә генә хөрмәтсезлекне дә ул гафу итми. Шуның өстенә берзаман Тукайны мактау, күтәрү, данлау мода төсен алды, хәтта Тукай культы барлыкка килде. Кайберәүләр аның исемен сәяси капитал туплау өчен файдалана башладылар. Чөнки Тукайны мактау мактаучыны сәяси ышанычлы итә иде. Әнә шундый шартларда шагыйрьнең тууына 90 ел булуны билгеләп узуга әзерләнгән көннәрдә, ягъни 1966 елда, «Совет әдәбияты» журналында минем «Шагыйрьне өйрәнү юлында» исемле мәкаләм басылып чыкты. Мин анда Тукайның тормышын һәм иҗатын өйрәнү тарихына күзәтү ясыйм һәм, Тукайны ничек булганынча күрсәтү принцибын яклап, Тукайны атеист ясарга тырышкан З. Ишмөхәммәтовны һәм шагыйрьне большевистик позициягә бастырырга азапланган К. Фасеев белән Р. Нәфыйговны тәнкыйть итәм.

Бу мәкаләнең чыгуы бомба шартлау яисә аяз көнне яшен сугу кебек булды. Иң элек «Социалистик Татарстан» газитәсе М. Габдрахманов һәм К. Фасеев имзалары куелган, һәм 37 еллар стилендә язылган зур мәкалә белән минем башка сукты. М. Гайнуллин һәм Г. Халитның «Совет әдәбияты»ның үзендә чыккан мәкаләләре дә минем баштан сыйпый торган түгелләр иде. Әнә шул вакыттан мин Тукайны түбәнәйтүче, хәтта пычратучы исемен күтәреп калдым. ЖЗЛ сериясендә минем «Тукай» китабым чыгу да мангаема чәпәлгән ул ярлыкны юып төшерә алмады. Хәтта, киресенчә, күпләрнең ул ачуын китерде. Чөнки бу китапта мин Тукайны ничек булганча күрсәткәнлектән, ул Тукайдан икона ясау тарафдарларына тәнкыйть булып төште.

Бервакыт шулай телефон шалтырый. Трубканы алам. Эльс Гаделев тавышы белән берәү русчалатып:

— Сез иптәш Нуруллинмы?— ди. Мин:

— Әйе,— дим.

— Тукай турындагы китапны сез яздыгызмы?

— Мин яздым.

— Юкка язгансыз.

— Мин ул китап турында гомерем буе һәм тагын биш ел уйладым, һәм, юкка түгел, дигән фикердә торам. Ә сез күпме уйладыгыз?

Бу адәм татарчага күчеп:

— Шәп әйттегез, Ибраһим абый,— дип куйды.

— Сез кем соң?— дим.

— Мин бер эшче,— диде.

Бу турыда Эльс Гаделевкә әйткән идем, ул башта бик уңайсызланды, аннары, миндә шик калмасын өчен, минем белән сөйләшкән кешенең кемлеген ачыкларга тырышырга сүз бирде. Һәм сүзендә торды. Ул чакта яңа гына яшь язучылыктан чыгып килә торган, хәзер инде шактый мактала башлаган, бер прозаик булып чыкты теге адәм.

Тукай турында бик үк уңышлы булмаган әсәр язган икенче бер күренекле язучы фәнни конференцияләрнең берсендә: «Ибраһим Нуруллин Тукайны үз дәрәҗәсенә төшерә»,— дип әйткән иде. Моны ишетү җиңел булмады, билгеле. Әмма эчемнән генә үземне болай дип юаткан идем: Нуруллин дәрәҗәсенә төшереп язылган Тукай үз илебездә генә калмыйча, чит илләргә дә барып чыкты, рус һәм татар телләрендә генә түгел, бәлки үзбәк һәм казакъ телләрендә дә сөйләшә башлады. Ә инде теге язучы дәрәҗәсенә күтәреп язылган Тукайдан чыш-пыш чыкты. Рәфикъ Исмәгыйль улы Нәфыйговның китабын тәнкыйтьләп газитәдә мәкалә чыгаргач, аның миңа кул бирми башлавы, бер вузда эшләп, очрашканда сәлам бирми узып китүләренең рәхәтсезлеге турында инде, артык шәхси хәл булганга, әйтеп тормыйм.

Тагын бер конфликтка кыска гына тукталып китим инде алайса. Бусы минем тәнкыйтьчелек эшчәнлегем белән бәйле иде. Шәриф Хөсәеновның кайсыдыр повестенда, кирпеч калынлык романнар уку заманнары узды, чөнки вакытның темпы үзгәрде, хәзер кыскалык заманы, дигән мәгънәдәге сүзләр бар иде.

Мин, шулардан этелеп китеп, «Кыскалык турында» дигән мәкалә яздым. Мәкаләнең төп идеясе: хикмәт күләмдә түгел, кирпеч калынлыгы роман кыска булып, дәфтәр калынлыгы әсәр озын булырга мөмкин, дигән фикер иде. Мәкаләмдә мин безнең романнарны копшәкләндерә һәм күпсүзләндерә торган сәбәпләрне ачарга тырыштым һәм мисалларны Г. Бәшир, М. Әмир, Г. Әпсәләмов һәм Г. Ахунов романнарыннан китердем. Ул вакытта «Совет әдәбияты» журналының редакторы субординацияне саклый, дәрәҗәләргә мөкиббән киткән Абдулла Гомәр иде. Әлбәттә, минем мәкаләне кире борды. Шуннан соң мин Язучылар союзы идарәсенә мөрәҗәгать иттем. Идарә утырышы җыелды. Мәкаләгә каршы чыгучылар да булды, билгеле. Әмма мәсьәлә, ахыр чиктә, минем файдага хәл ителде. Моның белән мин башлыча абруйлы һәм сүзе үтүчән зур язучы мәрхүм Ибраһим Газига бурычлы. Мәкаләдә, диде ул үзенең чыгышында, басып чыгармаслык бер нәрсә дә юк. Монда бары тик погон мәсьәләсе. Мәкалә генералларга (ягъни зур язучыларга) тел тидергәне өчен генә тоткарланган. Мәкалә журналда басылып чыкты. Шунысын да әйтим, ул «генераллар»ның берсе дә, очрашканда кырысрак сөйләшүләрен искә алмаганда, үч алу омтылышы ясамадылар. М. Әмир икенче бер мәкаләмне хәтта мактап та чыкты. Бүгенге язучыларның берсе, студент чагында язып чыгарган бер хикәясен тәнкыйтьләгән өчен бүгенгә кадәр, җае чыккан саен үч ала.

*— Торгынлык чорында партия өлкә комитеты Татарстан кешеләре өчен иң биек каланча кебек булды, гаделлек урнаштырырга тиешле иң югары нокта иде ул. Ләкин, чынлыкта, андагылар тормыш тарафыннан чишелеше соралган, иң өлгереп җиткән мәсьәләләрне дә чиксез-чамасыз сузып килделәр, хәл итмәделәр. Милли мәсьәлә, татар халкы өчен файдалы проблема булса, бигрәк тә шулай иде. Аерым алганда, Гаяз Исхакыйны татар халкына кайтару буенча да нәкъ шулай килеп чыкты ич. Бу юнәлештә Сезнең никадәр түземлелек белән көрәшүегезне барыбыз да беләбез. Әмма Сезнең ул көрәшегезнең иң катысы өлкә комитеты белән ике арада булды, ахрысы. Әнә шул хакта бераз тулырак сөйләп китә алмассызмы? Бу мәсьәлә андагылар тарафыннан ни рәвешле «өйрәнелде» һәм ни төсле хәл ителде?*

— Г. Исхакый иҗатын кайтару өчен көрәш ул үзе бер эпопея. Әдәби ел йомгакларының берсендә Әмирхан Еники Г. Исхакый мирасын кайтаруны нигезләп, трибунадан сөйләгәч, озакламый «Советская Татария» газетасында Р. Мостафинның «Баткан байлыкларны күтәрү» дигән мәкаләсе, аннары «Вопросы литературы» журналында Г. Исхакыйның М. Горький белән хат алышуы турында минем публикациям чыккач, Г. Исхакый иҗатын кайтару мәсьәләсе тормышчан идея булып һавада йөзеп йөри башлады. Әмма бу мәсьәләне партия өлкә комитетыннан башка хәл итеп булмый иде. Шулай, ниндидер җыелышларның берсендә, ул чактагы беренче секретарь Г. Усмановтан: «Гаяз Исхакый мирасын кайтаруга ничек карыйсыз?» — дип сораганнар. Ул: «Бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел, Г. Исхакый — враг номер 1», — дип җавап биргән дип ишеттек. Г. Усмановның үтә чыккан милләтче, пантюркист дип тамгаланган һәм фашистларга кул биргән дип исәпләнгән язучының иҗатын кайтаруга фатиха бирә алмавы аңлашыла. Әмма ул чакта безнен бәла һәм фаҗига шунда иде: иң югарыда эшләнгән тимер кагыйдә буенча, беренченең сүзе закон булып, директива булып санала иде.

Республиканың вакытлы матбугатын һәм нәшриятын ӨК үз кулында кысып тотканлыктан, Г. Исхакый мәсьәләсенә өлкә комитеты җитәкчеләренең карашын үзгәртергә тырышырга кирәк, дигән фикергә килдем. Газета-журналлар белән командалык иткән беренче инстанциядән — пропаганда бүлегеннән башладым. Дәлилләрем дә, үземчә, бик саллы иде. Без, янәсе, Исхакыйны сәяси яктан акларга, аны коммунист ясарга җыенмыйбыз. Сүз аның революциягә кадәрге иҗатын кайтару турында бара. Г. Исхакыйдан башка татар әдәбияты тарихы чын тарих була алмый, ялган була... Ә алар исә жиз күзләре белән сиңа карап торалар, җинелчә генә тамак кырып куялар. Киттем югарырак. Кердем ӨКнең ул вакыттагы идеология секретаре Кадерметовка. Гаҗәпләнүемә каршы, ул минем белән һәйбәт сөйләште, бер сәгать буе бәхәсләшеп утырдык. Мин, мавыгып китеп, хәтта аңа кычкыргалап та алдым. Ничек куып чыгармаганнардыр, моныcына гаҗәпләнәм. Чөнки аннан элегрәк бер инструктор кисәге белән сүз ара сүз китеп, Язучылар союзындагы хәлләр турында сөйләп алгач, йөзенә боз салкынлыгы, тавышына куркытулы аһәң чыгарып: «Обкомга килеп, обком куйган кешене хурлап утырасыз», — дигән иде.

Кадерматов белән сөйләшүдән дә бер эш тә чыкмады, әлбәттә. Ул да Усмановның ӨК директивасы булып киткән сүзен узып берни дә эшли алмый иде. Беренчегә исә мин, төрле чаралар күреп карасам да, үтеп керә алмадым. Г. Исхакый өчен көрәшнең Татарстан, Казан һәм ӨКдән читкә дә чыкканын кыскача гына булса да сөйләмәсәм, эпопея тулы булудан ерак торыр иде.

ӨКдән тәмам өмет киселгәч, «Литературная газета» да мәкалә чыгару белән генә мәсьәләне хәл итеп булыр, дигән фикергә килдем. Яздым мәкалә, киттем Мәскәүгә. «Литературная газета»ның СССР халыклары әдәбияты бүлеге мөдире булып ул чакта күз күргән һәм ярыйсы гына дустанә мөнәсәбәттә булган Әхияр Хәкимов эшли иде. Хәлне аңлаттым, мәкаләне кулына тоттырдым. Мәкалә аңа ошаган булса кирәк, ул, тәвәккәлләп, аны үз бүлегендә эшли торган бер ханымга редакцияләргә, әзерләргә кушты. Күпмедер вакыттан соң аның эшен бетереп секретариатка тапшырдылар. Мин, бик шатланып, мәкаләнең чыкканын көтә башладым. Шулай канатланып йөргән көннәрнең берсендә Уфада чыга торган «Кызыл Таң» газетасында профессор Нургалиниың Г. Исхакыйны карага буяган интервьюсы килеп чыкты. Антисоветизмга каршы язып танылган, Башкортстанда туып үскән М. Абдуллин яки башка берәү оештырган дип уйладым. Җавап бирми калырга ярамый иде, коллектив мәкалә тексты яздым да Ә. Еники, Ә. Кәримуллин, Р. Мостафин һәм М. Мәһдиевләрдән кул куйдырып, «Кызыл Таң»га җибәрдем.

Озакламый «Лит. газета»дан хат килеп төште. Минем мәкаләмне редакцияләгән ханым имзасы куелган язмада: «Г. Исхакый әсәрләренең русчасын тапмадык, шуңа күрә мәкаләгезнең ни дәрәҗәдә объектив икәнен билгеләп булмаганга, баса алмыйбыз», — диелгән иде.

Мине бу язу саташтыра алмады. Хикмәт, әлбәттә, бүтәндә, әлеге «Кызыл Таң»да чыккан интервьюда иде. Милләте ягыннан башкорт булган Әхияр, минем мәкаләмне чыгарып, милләттәшләре белән арасын бозарга теләмәде, күрәсең.

«ЛГ»да мәкаләнең чыкмый калуы белән һич килешәсем килми иде. Үзәк Комитеттан басым ясатырга карар бирдем. Ул чакта ҮКта Казан университетын тәмамлаган бер таныш егет эшли иде. Нәкъ пропаганда бүлегендә. Кердем янына. Сөйләп бирдем. Әмма ул да ярдәм итә алмады. Чөнки ул вакытта ҮК боерык бирүдән туктаган иде инде.

Соң, коллектив мәкаләнең язмышы «Кызыл Таң»да ничек тәмамланды? Урынбасары кискен каршы булуга карамастан, редактор Муса Мөлеков чыгарырга тәвәккәлләгән. Мәсьәләне редколлегиягә куеп күпчелек тавыш җыйган да, мәкаләне наборга җибәргән. Әмма сүзен аска калдырасы килмәгән урынбасар КПССның Башкортстан өлкә комитетында идеология секретаре Дильмөхәммәтевкә шалтыраткан һәм мәкаләне полосадан алырга туры килгән. Бусын да үткәреп җибәрә алмадым. Беренче секретарьлары Хәбибуллин исеменә шикаять яздым. Аңардан бернинди җавап килмәгәч, Башкортстан өлкә комитетын тәртипкә чакырырга үтенеп, ҮК секретаре Медведевка хат яздым.

Соң, эпопеяның финалы ничек булды? Укучы бусы белән дә кызыксына торгандыр дип уйлыйм. Җәмәгатьчелек фикере йоклап ятмагандыр. Ирек мәйданындагы биек йортка да үтеп кергәндер, билгеле. Татар иҗтимагый үзәге съезды исеменнән Г. Усмановка мөрәҗәгатьнең тәэсире аеруча зур булды, ахры. Шуннан соң боз кузгалды. Борылыш үзен чагыштырмача бәйсез тота торган «Вечерняя Казань» газетасыннан башланды. Анда редактор урынбасары булып миңа кияү тиешле С. Сәлимҗанов эшли иде. Безнең гаиләдә Г. Исхакый турында еш сүз булып торганга, бу исем һәм аның турында мәгълүмат аның колагына гел керә торды, билгеле. Редакторы А. Гавриловны күндерү, редакциядә атмосфераны әзерләү аның өстенә дә төште.

Әле бит Г. Исхакыйның исемен уңай яктан телгә алу өчен Главлит дигән киртәдән дә үтәсе бар иде. Татарстанның баш цензоры Кадыйрова ханымның да роле зур булды, дисәм, хакыйкатьтән ерак китмәм. Ул «Вопросы литературы» журналының минем публикация басылган санын тотып, тиешле органнарның бусагасын таптап, Г. Исхакыйның әсәрләрен яшерен фондттан ачыкка чыгарды. Гаяз Исхакый исеменә матбугатта юл ачты.

Менә «Вечерняя Казань» газетасында «Возвращение Гаяза Исхаки» дигән баш астындагы сәхифәдә язучының «Шәкерт абый» исемле хикәясе минем кереш сүз белән басылып чыкты. Күпмедер вакыттан соң «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Р. Сабиров та, тәвәккәлләп, минем мәкалә, атаклы язучы һәм тәнкыйтьчеләрнең Г. Исхакый турындагы фикерләрен, язучының үзенең «Тормышмы бу?» романыннан өзекләрне эченә алган сәхифә чыгарды. Ул вакытта «Казан утлары» журналының редакторы булган Ренат Харисның ролен телгә алып китмәсәм, гаделсезлек булыр иде. Ул минем «Вопросы литературы» журналында басылган публикацияне татарчага тәрҗемә иттереп чыгарды.

Шуннан соң боз нык кузгалды бит җәмәгать! Редакцияләр Исхакый әйберләрен үзләре эзләп ала башладылар, җәнҗал белән булса да «Зиндан» исемле бер томлыгы да чыкты.

Сизгәнсеңдер, мин монда Г. Исхакыйга «Советская Татария» газетасыннан алып барылган һөҗүмнәрне искә алмадым. Аларны укучылар күзәтеп барганнардыр, сөйләсәм, бик озынга китә. Шуны гына әйтәсем килә, шул һөҗүмнәргә җавап итеп тагын бер коллектив мәкалә әзерләгән идем, аңа Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Әмирхан Еники кебек асыл затлар да кул куйган иде. Әмма «Советская Татария»гә аларның сүзе дә үтмәде.

*— Менә хәзер «үзебезнең үткәнебез һәм партия» дигән проблемага килеп чыктык. Сез ничек уйлыйсыз: коммунистлар һәм аларның җитәкчеләре Гаяз Исхакыйга ни өчен аеруча каныктылар? Урыс һәм башка милләтләрнең андый язмышлы шәхесләре аклангач та, Исхакый һаман «дошман» саналып йөрде бит...*

— Әйе, безнең шартларда аны кайтару аеруча читен булды. Украин язучысы В. Винниченко һәм үткәне Исхакыйныкыннан да куркынычрак булган башка бик күп язучылар акланган бер көндә дә, Г. Исхакыйга юл ачылмый торды. Синең бу хәлне безнең өлкә комитетының аеруча консерватив булуы белән аңлатасың килә бугай. Мин моның белән килешеп бетмәс идем. Чөнки безнең ӨКда, бүтән милли республикаларның ӨК һәм ҮКләре кебек үк, милләтчелектә гаепләнүдән коты очкан һәм интернационалист булып күренергә бөтен көчен куя торган комитет иде. Хикмәт монда күбрәк Г. Исхакыйның үзендә. Г. Исхакый, мәгълүм булганча, егерменче һәм утызынчы елларда ата милләтче, ягъни милләтчеләрнең лидеры итеп карала иде. Өстәвенә, ул әле ак эмигрант та иде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, менә бервакыт Юрий Корольковның «Через сорок смертей» исемле китабы чыкты. Ул Г. Исхакыйны да китабына кертеп җибәргән иде. Корольков аны фашистлар белән хезмәттәшлек итүче, татар әсирләреннән Кызыл Армиягә каршы сугышлар өчен легион оештыруга күп көч куючы итеп тасвирлый. Дөрес, Рафаэль Мостафин соңрак бу хәлнең дөрес түгеллеген, аңлашылмаучылык ар-

касында гына килеп чыгуын күрсәтеп бирде. Эш болай булган икән: Ю. Корольков, повестен язганда, җәлилчеләрне саткан хыянәтченең тикшерүчегә сөйләгән сүзләреннән файдаланган. Бу хыянәтчене легионга Исхаков фамилияле бер фельдшер тарткан икән. Хыянәтче, үз хәлен җиңеләйтә төшү теләге белән булса кирәк, аны Гаяз Исхакый дип сөйләгән. Шундый зур кеше үгетләгәч, ничек риза булмыйсың, янәсе. Тикшерүче, шиккә калып, кабат төпченә башлап, дөреслекне ачыклаган ачыклавын, әмма Ю. Корольков хыянәтченең баштагы күрсәтмәләре белән танышып өлгергән була инде. Менә шундый: үзе милләтче дә булган, үзе фашистлар белән хезмәттәшлек тә иткән кешене, беренче секретарь Усманов кебек гаделлек өчен бик үк тырышмаган секретарьга кайтарудан бигрәк кайтармау кулайрак иде бит. Г. Исхакыйга һөҗүм итүчеләр аны нәкъ менә шулай дип гаепләделәр, хәтта шпион да иттеләр. Хәтерлисеңме бер мәкаләнең исемен: «Гаяз Исхакый — он же Шольц».

*— Кайвакытта: «Партияне аның җинаятьчел җитәкчелеге белән тиң итеп карамаска кирәк»,— дигән фикер әйтәләр. Ләкин 70 ел буена әлеге партия әһелләре һичнинди каршылыксыз үз җитәкчеләрен постта тоткач, җитәкчеләр барган юнәлешкә һичнинди каршылык күрсәтмәгәч, алар, чыннан да, бер сүздә булганнар булып чыга бит инде! Аларны аерып карарга һичнинди нигез дә юк ич! Ә Сез болар хакында нинди фикердә икән?*

— Әйе, КПССның җинаятьче башлыклары белән аның гади әгъзаларын аерып карауны мин дөрес дип беләм. Сталин һәм аның шайкасының утызынчы елларда эшләгән җинаятьләре өчен бүген партия билетын ташламаган күпме намуслы кешене хөкем каршысына бастырырга кирәк булыр иде. Гаделлекме бу? Син гаделлек дип уйлыйсың, чөнки янәсе, ник ул әгъзалар аларны җитәкче итеп тотарга риза булганнар? Беренчедән, каршы чыгучылар булган. Рютин дигән кешенең, мәсәлән, Сталин һәм аның командасының дөрес линия үткәрмәве, илне һәлакәткә алып баруы, бу команданы куарга кирәклеге турында бөтен бер программа язганы һәм шуны партия әгъзаларына таратканы мәгълүм. Рютин һәм аның кебекләрнең язмышы ничек булганы бүген инде бик яхшы билгеле. Еракка барасы юк, аз язып, аз яшәп тә әдәбиятыбызда билгеле бер эз калдырган язучы Мәҗит Рафиков. Сталинның бәйрәмчә бизәлгән мәйданга эленгән зур портретына күрсәтеп: «идолопоклонничество» дигән бер сүз өчен генә дә биш ел буе Сталин лагеренда лаеш шулпасы эчеп кайтты. Бөек Ватан сугышыннан соң немецларга әсирлеккә эләккән кешеләрне хөкем итә, сөрә башладылар. Ничек эләккәннәре, объектив сәбәпләре дә искә алынмады. Янәсе, ник әсир төшкәннәр, ник үзләрен үзләре үтермәгәннәр. КПССның гади әгъзаларын бүген хөкем каршына бастыру, үзләрен атып үтермәгәннәре өчен Себер җибәрү кебек нәрсә булыр иде. Сталин режимын кайтарырга чакырмыйк инде без. КПСС эшчәнлегендә булган уңай эшләр нәкъ менә шул гади әгъзаларның тырышлыгы, фидакарьлеге белән башкарылган бит. Анысын да онытмыйк. Бүген намуслы гади кешеләр күзеннән, аларның фикереннән бөтенләй ычкынган демократлар нинди кабәхәтлекләргә баралар?

*— Бүгенге дөньядагы үзгәрешләрдән һәм үзебезнең матбугаттагы мәгълүм бәхәсләрдән соң биредә тагын бер мәртәбә Сезнең социализмга һәм коммунизмга карата фикерләрегезне беләсе килә. Ни өчен соң социализм дөньяның бер генә илендә дә тантана итә алмый? Кешеләрне сөендерә алмый? Инде тәҗрибәләр үздыра башлаганга шактый еллар узды бит.*

— Бу сорау иҗтимагый фән белгечләренә бирелсә, яхшырак булыр иде. Миңа бирелгән икән, җавапсыз калып булмас. Өстәвенә, әдәбият җәмгыятькә тыгыз бәйле булганга, мин, әдәбият белгече буларак, социализм язмышы турында да уйланмый кала алмыйм, әлбәттә.

Безнең илдә социалистик җәмгыять кору тәҗрибәсе Сталин һәм аның яраннарының социализм төзүнең Ленин сызган сызыгыннан читкә китүләре сәбәпле барып чыкмады. Сталин боерык, куркыту, көчләү белән социализм төземәкче булды. Чынбарлык исә ул юл белән гадел җәмгыятьне төзеп булмаганлыгын күрсәтте. Көнчыгыш Европа, Азия, Көньяк Америка тирәсендәге кайбер илләрнең исә, безгә ияреп, бездән күчергеч алып авызлары пеште. Әмма кытайлар һәм кубалылар чигенмәделәр, бүген дә чын күңелдән, социализм төзибез, дип эшләп яталар. Кая барып чыгарлар — анысын киләчәк күрсәтер.

Бездә һәм Көнчыгыш Европа илләрендә социализм эксперименты барып чыкмады дип, социализм мәсьәләсен бөтенләй көн тәртибеннән алып ташлау дөрес булырмы?

Бит социализм тәгълиматы нигезендә «һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә» дигән принцип ятканлыктан, ул җәмгыять социаль гаделлек җәмгыяте булырга тиеш. Коллык дөньясыннан башлап, хәзер бик мактала торган капитализмга кадәр, күпчелек үз кул көче белән яши. Азчылык исә шуларга боерык биреп, шулар хисабына яшәргә омтылганлыктан, социаль гаделлек, ягъни социализм идеясе, һәрвакыт игътибар үзәгендә булачак. Бүген дөньяда әллә ни чаклы социалистик партияләрнең һәм бөтен бер социалистик интернационалның яшәп килүе әнә шул турыда сөйләсә кирәк.

Мин социализмга гына түгел, бәлки коммунизм идеясенә дә ышанычымны югалтканым юк. Чөнки хәтта чын социалистик җәмгыять шартларында да социаль гаделлек тулысынча урнашып җитә алмый. Бит кешеләр анадан тигез булып тумыйлар. Берәүләр сәламәт, көчле, рухи яктан сәләтлерәк булып туалар, икенчеләре зәгыйфь, авыру яки сәләтсезрәк булып туалар. Шуңа күрә хезмәткә сәләтләре дә түбәнрәк, димәк, хезмәт хаклары да кимрәк була. Кайда монда гаделлек? Икенчеләрнең анадан шулай тууларына ни гаепләре бар? Соң бу каршылыкны ничек хәл итәргә? Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хаҗәтенчә, дигән принципны тормышка ашырып, әлбәттә. Ә бу — коммунизм принцибы. Менә ни өчен кешелек дөньясының күпчелегенә коммунизм идеал һәм юлкүрсәткеч маяк булып калачак.

*— Күренекле әдәби тәнкыйтьче буларак, Сезгә социалистик реализм турында сорау бирәсе килә. Хәзер аңа карашыгыз нинди? Бүгенге язучы өчен, гомумән, иҗат методы кирәк дип саныйсызмы? Тулы ирекле булган хәлдә, чын сәнгать кануннарына гына баш ию дөресрәк түгелме икән?*

— Социалистик реализм — социалистик җәмгыять өчен көрәш чорында мәйданга килгән иҗат методы. Аның төп билгесе — чынбарлыкны революцион үсешендә чагылдыру, ягъни җәмгыятьнең социализмга таба үсеш-үзгәрешендә туган яңалыкларны яралгы хәлендә үк тотып алып, тулы канлы образларда перспективаны күздә тотып сурәтләп бирү. Социализмга күчеш чорында нәкъ менә шундый иҗат методының кирәклеген аңлау өчен мондый бер чагыштыру ясарга мөмкин.

Зур бина салырга керештеләр, ди. Зур мәһабәт бина калкып чыгачак урында башта чокыр-чакыр һәм чүп-чардан бүтән нәрсә булмас. Бу чокыр-чакыр һәм чүп-чарны фотога төшереп алсаң, ул рәсемнән бу урында мәһабәт бина калкып чыгачагын һичничек күз алдына китереп булмас. Димәк, булачак зур бинаны хыялда гына булса да күрү өчен фотография ысулы ярамый, бүтән ысул, бүтән метод кирәк була.

Әнә шуның шикелле, социалистик реализм методы нәкъ менә социалистик киләчәккә күз ташларга мөмкинлек бирә, аны якынайту өчен көрәшер өчен көч бирә, оптимизмны арттыра торган иҗат методы иде. Чын реализмның яңа стадиясе иде.

Әмма Сталин режимы тудырган партократия аны үз максатларында файдаланды, үзенчә аңлап, чынбарлыкны матурлатып, бизәп күрсәтер өчен корал итте.

Утызынчы, бигрәк тә кырыгынчы елларда өреп тутырылган, бушкуык әсәрләр күпләп мәйданга килгән икән, бу социалистик реализм принципларының гаебе түгел, бәлки партия чиновникларының иҗат эшенә тыкшынуларының нәтиҗәсе иде! Әгәр чын социализм өчен кабат чын көрәш башланса, бу иҗат методына яңадан ихтыяҗ туачак, һәм ул иҗатка уңай йогынты ясаячак, дип уйлыйм мин.

Иҗат методы, гомумән, кирәкме дигән мәсьәләгә килсәк. Моңарчы беркайчан да, беркайда да язучылар билгеле бер иҗат принципларына нигезләнмичә иҗат итмәгәннәр. Нинди дә булса иҗат методы булмаган әдәбиятларны белмибез. Кайберләренең исемнәрен генә искә төшерик: классицизм, романтизм, реализм, натурализм. Синең: «Тулы ирекле булган хәлдә, язучы чын сәнгать кануннарына гына баш ияргә тиеш»,— дип әйтүең, үзе үк иҗат методының яралгысы бит.

Соң бүген безнең әдәбиятта нинди метод алга чыгарга һәм язучыларның эш коралына әверелергә мөмкин?

Безнең әдәбият та методсыз яшәмәс. Ул методның нинди булуы исә, җәмгыятьнең ничек һәм кая таба үсүе, әдәбият алдына нинди бурыч куелуына бәйлән-

гән. Әнә шул бурычтан чыгып, язучылар үзләре һәм тәнкыйтьче-теоретиклар кулайрак методның принципларын эшләп чыгарырлар.

*— Тулаем халык массалары кебек, татар язучылары да шәхес культы һәм торгынлык елларында авыр-авыр сынаулар аша үздылар. Һәм әнә шул вакытта шактый гына әдипләр, шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, зур гына ялгышлар да җибәргәннәр. Власть башындагыларга ялагайлану, тәгәл белеп һәм аңлап тормастан бер гаепсез кешеләрне сугудә катнашу, әдәбиятта бер-берен батыру һәм хөсетлек, хәтта куркыныч оешмалар белән хезмәттәшлек итү һәм каләмдәшләре турында ялган фактлар хәбәр итү... Сезнеңчә ничек: хәзер, хәбәрдарлык чоры килгәч, тормышта булган әлеге хәлләр өскә чыгарга тиешме? Әллә бүген аларны белүдән әллә ни файда юкмы? Сезнең фикер?*

— Бу сорауга әдәбият мәнфәгатеннән чыгып җавап бирергә кирәк дип беләм. Язучылар эшләгән әнә шул бик үк мактаулы булмаган гамәлләрне тикшерү әдәбиятыбыз тарихын дөрес яктыртуга хезмәт итә икән, аларны күтәрергә, тикшерергә, өйрәнергә кирәк. Әмма бу — галимнәр, әдәбият тарихчылары эше. Ә инде сенсация өчен, гайбәт сөючеләргә азык сыйфатында күтәрү, фаш итү һич кирәкми. Менә бер мисал.

Татарстан язучыларының соңгы съездында адашым Ибраһим Сәләхов минем яныма килде һәм: «Нәкый Исәнбәтнең органнарга язган хаты турында сөйләмәкче булам, ничек карыйсыз?» — дип сорады. Мин аның бу ниятен хупламадым. Соңыннан кемдер ул хатны миңа кулыннан җибәрми генә укытты. Ул һич тә органнарга язылмаган, бәлки үзе турында йөргән гайбәтләргә аңлатма биреп, СССР Язучылар союзы җитәкчеләреннән берсенә язган хат булып хәтердә калган. Әгәр адашым ул мәсьәләне күтәреп чыккан булса, Н. Исәнбәтнең вафатын күпмегәдер тизләткән булыр иде.

Ә бөек әдипнең иҗатын өйрәнүчеләр һәм әдәбият тарихының Н. Исәнбәт иҗаты чәчәк аткан чорын тикшерүчеләр ул хатны белергә тиешләр.

*— Менә хәзер, гаделлек чоры килгәч, кайбер каләм әһелләре шундый адымнар ясыйлар. Алар яшәүнең, кешелекнең олы таләпләре турында уйлап тормыйлар, андый югары таләпләргә кул селтиләр һәм «син — миңа, мин — сиңа» принцибын кулайрак күрәләр. Ягъни «бүген мин сиңа ярдәм итәм, ә иртәгә син мине ярдәмеңнән ташламассың, яме».*

*Менә Сез бик тә принципиаль кеше, әйтегез әле: без әдәбият дөньясында мондый караш белән ерак китә алырбыз микән? Тагын да вакланып бетмәбез микән? Олы таләпләр яшәмәсә, олы шәхесләр дә туа алмый бит!*

— Кода-кодагыйлык, «син — миңа, мин — сиңа» дигән принцип белән яшәү соңгы вакытларда гына түгел, ул Брежнев исеме белән бәйләп йөртелә торган торгынлык чорында бик тирән тамыр җибәрде. Бу күренешнең әдәбият үсешен тоткарлый торган зарарлы күренеш икәнлеге турында ике сүз була алмый. Әмма мин монда икенче нәрсәгә басым ясап әйтәсем килә.

Бу күренеш, бу принцип белән яшәү — иң элек язучыларның үзләре өчен зарарлы. Аларның иҗат колачын, илһам чишмәсен буа ул!

*— Сез, фронтовик әдип, үзе теләп яуга киткән кеше. Ә бүген үзләрен артык интеллигент санаучы кайберәүләр, үткән сугыш каһарманнарыннан көләргә тели. Сугыштагы фидакарьлекне һәм ихлас кыюлыкны санга сукмаска тели алар. Газинурлар, Александр Матросовлар (һәр икесе татар егете) фидакарьлегеннән көләргә телән көчәнә алар. Мондыйлар, гадәттә, үзләре куркак кеше була. Андыйлар хәйлә һәм ялагайлык белән көн күрә. Алар үзләре реаль тормышта адым саен, көн саен әллә ничә мәртәбә сатылып һәм кешене дә сатып яшиләр... Ләкин ир-ат заты өчен иң төп үлчәү булган «батырлык» дигән төшенчәгә төкерергә теләү — бүген тулаем тормыш бинасын астан җимерү булып аңлашыла. Шул уңайдан Сездә, фронтовик кешедә, нинди уйлар туа икән?*

— Әйе, соңгы вакытларда сугыш ветераннарына, йомшаграк итеп әйтсәк, хөрмәт кимеде, хәтта аларны яратмау, ачу хисе артты. Бу хөрмәтсезлекне идеологик яктан нигезләүчеләр дә бар. Ни өчен, янәсе, алар, ветераннар, «За Сталина!» дип атакага барганнар? Әмма ләкин мондыйлар сугышчыларның «За Родину!» дип тә ут эченә ташланганнарын әйтергә онытапар. Фронтовикларга шундый мөнәсәбәт олыраклардан яшьләргә дә күчте булса кирәк. Бер егет (татар

түгел) әйткән, имеш: әгәр ветераннар тырышып сугышмаган булсалар, без хәзер бавар сырасы эчеп рәхәтләнгән булыр идек. Коточкыч бит бу! Немец сырасын туган иленнән, атасының, бабасының канынннан өстен күрә!

Бәлки, зур сугышлар бүтән булмас та. Ә була калса? Туган илне баскыннардан сакларга кирәк буламы, юкмы? Әгәр ветераннарга мондый мөнәсәбәт булса, кем генә илне саклау хакына сугышка барырга атлыгып торыр икән?

*— Сезнең дингә мөнәсәбәтегез нинди? Исламның безнең милләтне саклап калудагы уңай ролен Сез, татар кешесе буларак, ничек бәялисез? Ә шанган коммунист буларак (билгеле булганча, коммунистлар татар милләтен юкка чыгару буенча бик нык тырыштылар һәм зур җиңүләргә дә ирештеләр) хәзерге чорда ислам диненә мөнәсәбәтегез? Аерым алганда, бүген безнең милләткә яңарган партияме, әллә динме күбрәк файда бирә ала?*

— Мин — атеист. Моны яшерергә кирәк тапмыйм. Һәм дин белән сату итәргә дә җыенмыйм. Әмма ислам диненә мөнәсәбәтем уңай.

Теге хәерсез елларда ук 922 елда болгарларның ислам динен кабул итүләрен студентларга уңай күренеш, тарихи прогрессив күренеш дип аңлата идем. Моннан соңгы дәверләрдә дә ислам диненең милләтне оештыру, туплау һәм саклап калуда зур тарихи роль уйнаганын таныйм. Мактанып әйтмим, ислам руханиларының (билгеле, прогрессив өлешенең) руслар тарихында дворяннар кебек үк, әһәмиятле мәдәни-прогрессив роль уйнаганнарын язып чыгучыларның беренчесе дә мин булдым.

Динме, партияме милләтнең үсеше өчен файдалы? дисез.

Диннең кешеләр аңын биләп ала алуының бер сәбәбе, мәгълүм булганча, аларның табигать законнарыннан хәбәрдар булмаулары. Бүген исә, халкыбызның күпчелеге урта һәм югары белемле кешеләр тәшкил иткән чорда, дингә зур өмет баглый алмыйм. Дөрес, кайбер дини гореф-гадәтләрнең файдасы юк түгел. Милли патриотизм идеясе — менә нәрсә милләтне яшәтә, тәрәккый иттерә торган хәлиткеч көч, минемчә. Хыялга бирелеп әйтсәм, әгәр милләт мәнфәгатен бар нәрсәдән өстен куя торган намуслы кешеләр партиясе (НКП) дигән партия оешса, ул хәлиткеч роль уйный алыр иде.

*— Коммунистик идеал бар иде, җитәкчеләр «тырышлыгы» белән ул юкка чыкты дияргә була. Ә менә милли идеал һаман әле яши һәм көчәя бара. Бүтән җирдә дә коммунистик идеал түгел, ә милли идеаллар чәчәк ата сыман... Сез моңа нәрсә дисез?*

— Җитәкчеләр тырышлыгы белән юкка чыккан коммунистик идеал турындагы сүзләрең — кызыклы һәм игътибарга лаеклы фикер. Чынлап та бит Сталин үзенең кешелексез һәм канлы сәясәте белән социализмның яманатын чыгарды. Хрущев «егерме елдан коммунизм булачак», дип коммунизмны юмор предметына әверелдерде. Брежневның эшчәнлеге тоташы белән коммунистик идеалга ышануны какшатуга юнәлгән иде. Ельцин һәм үзе җитәкләгән партияне үзе ташлап качкан Горбачев тегеләр алып барган кара эшне ахырына җиткерделәр. Түбәндәгерәк партия түрәләренең яшәү һәм ашау рәвешләре дә һич тә коммунистик идеал файдасына булмады.

Милли идеал мәсьәләсенә килгәндә, иҗтимагый фән белгече булмасам да, башыма килгән бер әрсез фикерне (дөрес булмаса, төзәтерләр) әйтеп китим инде. Бәлки, хәзер яңа бер тарихи законлылык урнашкандыр: хәзер башта милли мәсьәләне хәл итү, ә аннары сыйнфый көрәш ашамы, бүтәнчәме, социаль гаделлеккә корылган җәмгыять төзүгә керешү дөресрәктер? Бүген бик күп милләтләрнең бәйсезлек таләп итеп күтәрелүләре, бәлки, шуннан киләдер? Бу уңай белән тагын Гаяз Исхакый хәтергә килә.

1917 елда, февраль революциясеннән соң, Казанда аның шәрәфенә үткәрелгән банкетта, ул түбәндәге эчтәлекле фикер әйткән. Самодержавиене җимерү өчен көрәштә без (ягъни таңчы-эсерлар) сыйнфый байрак астында бардык. Хәзер исә милли байрак астында барырга тиешбез. Ә киләчәктә, җирне самодержавиенең җимерекләреннән чистартып, урынына яңа бина корырга керешкәч, без кайсы сыйныф яклы булырга кирәклекне үзебез белербез.

Бүген генә бор-лнлап килә торган фикернең Г. Исхакый зиһенен моннан 75 ел элек үк биләп ала башлаганына гаҗәпләнмичә мөмкин түгел.

*— Күренекле әдип һәм гаять оста психолог Әмирхан ага Еники белән Сезнең*

*озак еллардан бирле килгән дуслыгыгыз күпләргә мәгълүм. Торгынлык елларында Әмирхан Еники тормышыны гадел рәвештә, бизәмичә күрсәтү ягында булды. Сез дә әдипләр (бигрәк тә Тукай) турында чын дөресен генә язу, шуны гына раслау өчен көрәштегез. Шулай итеп, һәр икегез ул авыр елларда милләткә тугры йөрәк һәм тугры каләм белән, намуслы хезмәт иттегез. Шундыйлардан бередә тагын кайсы әдипләрне атый аласыз?*

— Милләте, халкы һәм иманы хакына сынса-сынар, ләкин бөгелмәс әдипләрдән мин тагын Салих Батталның исемен атар идем. Хөррият урнашудан күп еллар элек үк ул, Ленин әсәрләрен яттан белгән хәлдә, һәм шуларга нигезләнеп, милли мәктәбебезне, милли мәдәниятебезне яклап тавыш күтәрә башлады. «Сигезенче кем?» исемле милли горурлык хис-тойгылары белән сугарылган менә дигән повестен генә хәтерлик. Мондый чыгышлар аңа кыйммәткә төште. «Батый ханга ачык хат» шигыре өчен, дөресрәге, бер җыелышта КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Табеев белән милли мәсьәлә буенча бәхәскә кергәне өчен, ул партиядән чыгарылды. Партиядән чыгарылу ул вакытта гражданлык җәһәтеннән үтерелү белән бер иде. Язганнарын басмадылар, көн саен диярлек Черек күлгә (КГБга) чакырып азапладылар. Салих абый бирешергә теләмәде. Кат-кат апелляциягә бирде. Татарстан партия житәкчелеге, артыграк бөгеп җибәргәнен абайлап, әмма гаебен танырга теләмичә, Батталга яңадан гариза язып партиягә керергә тәкъдим иткән. Әмма С. Баттал, юк, дигән мин партиядән үзем теләп чыкмадым. Рәхим итеп, гафу үтенеп, членлыгымны кире кайтарыгыз. Эш Үзәк Комитетка барып житкән, күрәсең, С. Баттал аларның да теңкәсенә тигән. Бер көнне ҮКнең бер хатын-түрәсе, тавышын тимерләндереп: «Туктатыгыз права качать итүегезне, югыйсә начаррак булыр», дигән. Тагын болай дип тә өстәгән әле: «Мало били вас, татар».

Сүз уңаенда шунысын да әйтим. С. Батталның шагыйрь буларак бүгенгә кадәр тәнкыйтьтә үзенең тиешле бәясен алганы юк.

Мин, шәхсән, совет чоры татар поэзиясеннән иң яхшы өч шагыйрьнең исемен атагыз дисәләр, Такташ, Туфан һәм Баттал дияр идем. Ник М. Җәлил юк, дип гаҗәпләнмәгез. М. Җәлил, әлбәттә, талантлы шагыйрь. Тик аның дөньякүләм дан алуы шагыйрьлегенә фашизмга каршы батыр көрәше кушылу нәтиҗәсе булды. Ә мин өч шагыйрьнең исемнәрен атаганда шагыйрьлекләрен генә күздә тотам.

С. Батталның «Олы юл буйлап» поэмасының берниндн протекциясез «По столбовой дороге» исемендә «Новый мир» кебек журналда басылып чыкканлыгы очраклы хәл булмаса кирәк. Кыскасы, С. Баттал шигърияте үзенең тикшеренүчесен, тәнкыйтьчесен көтә. Нил Юзеев, яисә Рафаэль Мостафин кебек шигърият белгечләре, әйтик, бу эшне башкарсалар, С. Баттал талантына лаеклы бәя алыр иде.

*— Ибраһим ага, Сезнең белән ихластан сөйләшү булгач, күңел төбендәге Сезгә бәйле бөтен уйларны да ачыклап бетерәсе килә бит әле. Без университетның соңгы курсында укыганда «Казан утлары»ның әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире Фәрваз абый Миңнуллин оештырган яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенә йөри идек. Шул утырышларның берсендә Сезнең белән бик кызыклы бер очрашу истә калган. Без анда бик күп сораулар арасында менә мондыен да биргән идек: «Белинскийлар, Добролюбовлар чорында ни өчен әдәби тәнкыйть бик көчле булган да, ә хәзер (ягъни житмешенче елларда) нишләп алай түгел?». Ул чагында Сез безгә якынча менә болайрак җавап биргән идегез: «Әлеге чорда кешеләрне борчыган бөтен уйлар, фикерләр әдәбият аша әйтелгән. Информация, фикер үткәрүнең бүтән юллары ябык булган. Әнә шуңа күрә — бөтенесе әдәбиятка йөкләнгән булгач — әдәби тәнкыйть тә көчле булган... Ә хәзер (ягъни житмешенче елларда) халыкка информация күп төрле юллар белән килә. Халык әдәбиятка гына карап тормый...*

*Менә хәзер, 90 нчы еллар биеклегеннән караган вакытта, үзегезнең әлеге фикерегезгә кайбер өстәмәләр ясау кирәк дип санамыйсызмы?*

— Өстәмәм, әлбәттә, бар. Мәсәлән, иң элек мин бүген, ягъни 70 нче елларда информация төрле яктан килә, дигәннең хата булганын әйтәсем килә, ул фикерне кире алам. Чөнки ул чакта информация бары бер чыганактан — муеньна партия органнары элмәк салган масса-күләм информация чараларыннан гына килә иде.

XIX гасыр рус әдәбиятының һәм тәнкыйтенең күз житмәс югарылыкка күтәрелү сәбәбе турындагы фикеремне исә бүген дә хуплыйм. Азатлык идеясен үткәрергә мөмкин булган бердәнбер трибуна әдәбият булганга, әдәбиятка һәм

тәнкыйтькә талант артыннан талант, даһи артыннан даһи килеп торуы табигый хәл булган. Сүз чыккач, бусын да әйтим инде. XX йөз башында татарларда да шуңа охшаш хәл туды. Әдәбиятыбыз зур уңышка ирешү белән бергә, гаять куәтле әдәби тәнкыйть тә мәйданга килде. Моңа ышану өчен тәнкыйтьче булып чыгыш ясаган Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовның һәм таланты, фикер тирәнлеге ягыннан тиңдәше булмаган тәнкыйтьче Җамалетдин Вәлидинең исемнәрен атау да җитсә кирәк.

Бу очракта әдәбият һәм тәнкыйть шундый югарылыкка милли-азатлык хәрәкәте дулкыны сыртында күтәрелделәр.

Бүгенге милли хәрәкәттә дә әдәбият хәлиткеч роль уйный һәм уйнарга тиеш дип уйлыйм. Ә ул әдәбият, идея ягыннан саф һәм сәнгатьчелек ягыннан югары дәрәҗәдә булганда, әлбәттә. Моның өчен исә акыллы, гадел һәм курку белмәс, тәнкыйтьчеләр кирәк. Язучылар, аларның язуларыннан файда алу белән бергә, начар, димим, хәтта уртакул әсәр язып бастырудан котлары очып торсын.

*— XX гасыр башы әдәбиятын әтрафлы өйрәнгән галим буларак, Сезгә тагын бер сорау бирәсе килә. Ул чор белән безнең заман арасында охшашлык бик күп кебек: 1) илдә иҗтимагый-сәяси тотрыксызлык хөкем сөрә; 2) экономик-социаль, әхлакый кризис көчле; 3) милли-азатлык хәрәкәте бик көчәйде; 4) халык массаларының хәле чиктән тыш авырайды.*

*Ә менә шул чор әдәбияты һәм әдәби процессы белән безнең елларны чагыштырып карасаң, шундый ук уртак яклар табылмас микән?*

— XX йөз башы белән безнең көннәр арасында социаль-иҗтимагый, икътисадый-сәяси, бигрәк тә милли-азатлык хәрәкәтенең куәтләнүе ягыннан, минемчә дә, зур уртаклык бар. Әмма бу ике чор әдәбиятлары арасында уртак сыйфатлар күзгә ташланмый.

1905 елгы революциядән соңгы 5—6 елда татар әдәбияты кинәт һәм бик тиз үсеп китте. Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд кебек шагыйрьләр калкып чыкты. Ф. Әмирхан һәм Ш. Камалның кече проза жанрындагы, Г. Камалның драматургиядәге шедеврлары дөнья күрде. Г. Камалның «Беренче театр», «Бүләк өчен» кебек классик әсәрләренең тууы шуны күрсәтсә кирәк. Озак та үтми, Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», С. Җәлалның «Дим буенда» романнарының мәйданга килүе шул турыда сөйли.

1985 елгы яңарыш башланганга менә инде алты ел узып китте, әмма мин югарыда әйтелгәнгә охшаш хәлне күрмим.

Соң моның сәбәбе нәрсәдә?

Моңарчы чылбырдагы кул белән язарга күнегеп тә, чылбыр алынгач, илһам килми башладымы, әллә бүтән сәбәплеме, белмим. Моны әле өйрәнәсе, тикшерәсе бар, төбенә төшәсе бар.

*— Үзегезнең фәнни эшчәнлегегездә Сез төрле милләт әдәбиятларының үзара йогынтысына зур гына әһәмият бирәсез. Ничек уйлыйсыз: торгынлык чорында «совет халкы» дигән уйлап чыгарылган нәрсәне ныгыту өчен бу «йогынты» дигән шаукымга артык әһәмият бирелмәде микән? Хәзер ул өлкәдә дә яңа караш кирәк түгел микән?*

— Бер генә әдәбият та абсолют аерым яшәмәгән һәм яшәми. Әдәбиятлар һәркайда да һәм һәркайчан үзара бәйләнештә, үзара тәэсир итешеп яшәгәннәр, үсеш-үзгәреш процессы кичергәннәр. Бу бәйләнешләрне өйрәнергә кирәк. Әйе, кырыгынчы һәм илленче елларда кирәгеннән артык мавыгып китү булды. Ләкин бу бүтән рәвешле, бүтән сәбәпләр аркасында булды. Ягъни рус әдәбиятының гына татар әдәбиятына йогынтысын күрсәтү рәвешендә булды. Мондый темаларга язу мода төсен алды. Андый темаларны диссертация итеп яклау яисә китап итеп чыгару җинелрәк иде.

Күпсанлы шундый хезмәтләр нәтиҗәсендә, бөек әдибебез мәрхүм Нәкый Исәнбәт әйтмешли, татар әдәбияты рус әдәбиятына тагылган дегет чиләге булып күз алдына килә башлады.

Ләкин бу, әле әдәби бәйләнешләрне, йогынты һәм үзара йогынтыларны өйрәнүне туктатырга кирәк дигән сүз түгел. Тик истә тотарга тиешле шартлары бар. Беренчедән, бәйләнешләр күпъяклы булганлыктан, рус-татар әдәби бәйләнешләре белән генә чикләнергә ярамый, әле бит көнчыгыш әдәбияты, аерым алганда, төрек әдәбияты бар.

Икенчедән, әдәби йогынты (иярү түгел!) үсеш-үзгәрештә мөһим фактор

буларак, әдәбиятның милли үзенчәлеген тоныкландырмый, киресенчә, тулырак ачылуына булыша икәнне истә тотып, дөрес методология нигезендә өйрәнелергә тиеш.

*— Безнең әңгәмәбезнең башы да «Тукайлар, Исхакыйлар юлы...» дип исемләнгәч, Сез үзегез дә, яшәү рәвешегез һәм көрәшегез белән аларга бик якын кеше булганга күрә, яңадан да әлеге кадерле исемнәргә әйләнеп кайтыйк. Яңа чорның, алдагы гасыр башының, яңа Тукайлары, яңа Исхакыйлары туачакмы? Моның өчен нинди шартлар кирәк?*

— Тукай һәм Исхакый кебек даһилар гасырларга бер килсә дә һәм алар турында күрәзәчелек итү мөмкин булмаса да, андый бөек әдипләрнең дөньяга килүе өчен нинди шартлар кирәклеге турында фикер йөртергә мөмкин.

Иң элек милләтебез аналарының даһи балалар тудыруы, татар мәктәпләренең тәмам юлга салынуы, ул балаларның әдәби атмосферага эләгүе, җәмгыятьнең алардан күңел җимешләре таләп итүе һәм аларның милләткә, халыкка хезмәт идеалы хакына алны-ялны белми эшләүләре кирәк.

*— Бүгенге татар әдәбиятында сезгә ошаган сыйфатлар нинди? Ә нәрсәләр Сезне әдәби тәнкыйтьче буларак һәм гражданин буларак борчый?*

— Куандырганы — тарихи проза жанрының тернәкләнүе. Бер елны бүдәнә, икенче елны тартай симерә, диләр бит. Тарихи жанр үсеп, чәчәк атарга тиеш, дип йөри идем, күрәзәчелегем дөрескә чыкканга икеләтә куанам. Тик шунысы борчый. Хәзергә әле авторлар күбрәк уйлап чыгару, хыял белән эш итәләр. Тарихчылар кебек архивларны актарып, табылганны язучылык фантазиясе белән кушкан, чын мәгънәсендәге тарихи романнар көтеп калам алардан.

*— Ниһаять, соңгы сорау, Ибраһим ага. Традицион сорау. Әгәр сер булмаса, киләчәккә планнарыгыз нинди?*

— Хәзер Г. Исхакыйның тормышы һәм иҗаты буенча җыйган материалларымны публикацияләр рәвешендә газета-журнал укучыларга җиткезү белән шөгыльләнәм. Аларны архивымда яткырудан файда юк ич. Ераккарак караган планым — Г. Исхакый турында китап язу. Параллель рәвештә автобиографик әсәр язарга уйлыйм. Кулына каләм тота белгән һәркем тормыш юлын инәсеннән җебенә кадәр язып чыгарга бурычлы, дип саныйм. Балаларына, оныкларына гыйбрәт, тарихка материал булыр иде ул язмалар.

Мин, туган көнемнән башлап, көн артыннан көн дигәндәй, хронологик тәртиптә эзлекле итеп язарга уйламыйм, бәлки тормышымдагы әһәмиятлерәк эпизодларны аерым парчалар рәвешендә язып, дөньяга чыгармакчы булам. Соңыннан җыеп бер китап чыгарырга исәп. Укучылар игътибар иткәндер, берникесе дөнья күрде дә инде.

*— Эшегездә уңышлар телибез! Әңгәмәгез өчен рәхмәт!*

БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ. БЕЗНЕҢ ӘДӘБИЯТ

**Кояш Тимбикова**

# ЭНҖЕЛЕ КАЛФАК

Мин соңгы вакытта очрашу кичәләрендә, тантаналы җыелышларда һәм үземнең телевизион чыгышларымда маңгай өстенә әниемнән мирас калган энҗеле калфакны эләргә, әбиемнең озын чуклы ефәк шәлен бөркәнергә тырышам. Шул изге бизәкләргә орынуга күңелдәге өмет-хыяллар яктыра, җанга сафлык иңә, иман ныгый кебек. Шәлнең ифрат та зәвыклы үрнәкләренә карап-карап сокланам да, шагыйрәбез Флера Гыйззәтуллинаның серле сүзләре искә төшә:

*Мин барыбер йолдыз челтәремне*
*Синнән башка бәйли башламыйм...*

Шагыйрә «...синнән башка» дигәнендә, мөгаен, кызларның сөйгән ярларын, ир-егетләребезне күздә тоткандыр. Чыннан да, ир-атларның ярдәм-шәфкатеннән башка без, хатын-кызлар, нишли алабыз соң?! Алар — безнең беренче таянычыбыз. Безнең эшләр бары тик алар ярдәм кулын сузганда гына юл ала, алга китә. Һәм бу хәл бик тә табигый. Хатын-кыз, ир-егет ярдәменнән башка, дөньяның бөтен нужасын берүзе генә тарта башласа, шул рәвешчә дә көн күрә алса, аңардагы табигатьтән бирелгән иң күркәм сыйфатлар: назлылык, юашлык, самимилек һ. б.лар югалыр иде.

Бу хакыйкать тол хатыннарның авылдагы бәрәңге бакчасын сукалатуында, утын-күмер китертүендә яки, шәһәр шартларында, газ баллоны ташытуында, су кранын төзәттерүендә генә түгел, иҗат дөньясында да хөкем сөрә. Кызганыч ки, без бу хакта әлегәчә ачыктан-ачык, нигезле иттереп сөйләшә генә алмый идек. Социализмда барлык шәхесләр вә җенесләр бертигез, дигән гайре табигый хакыйкатькә омтылдык бит. Әдәби вә мәдәни даирәләрдә дә: «Иҗатта авторның кызмы-егетме икәнлеге исәпкә алынмый. Бөтенесен әсәр үзе генә хәл итә»,— дигән кырыс кагыйдә хөкем сөрде.

Мин үзем дә бу караш белән килешә идем кебек. Чыннан да, әсәр — әсәр инде. Кайбер кыз каләмдәшләремнең җыелышларда яки газета-журнал битләрендәге мәкаләләрендә хатын-кыз язучыларга ташлама сорауларын күңел кабул итә алмый иде. Янәсе, синең җенеснең әдәбиятка ни катнашы бар?! Яз да яз! Укучың ни дияр? Әсәрең гомум хуплауга ирешә икән, ир-ат язучылар яки тәнкыйтьчеләр нишли ала?!

Тора-бара минем фикерем катлауланды. «Азат хатын» (бүгенге «Сөембикә») журналы редакторы Асия Хәсәновaның, җае чыккан саен:

— Кызларны житәкче постларга күтәрик әле!.. Ни өчен бер генә хатын-кызны да депутат итеп күрсәтмибез? — кебек таләпчән сораулары ифрат урынлы күренә кебек иде.

Кайда булма, райком секретарьлары — ирләр, мәктәп директорлары — ирләр, колхоз рәисләре, совхоз директорлары — ирләр... Шул хәлләрне күрә-күрә гаҗиз булдым мин. Бөтен власть ирләр кулында чакта, хатын-кыз мәнфәгате турында ихластан фикер алышып буламы соң?!

Әдәби-мәдәни иҗат даирәләрендә дә хәл нәкъ шулай: беренче сүзне әйтүчесе дә, соңгы ноктаны куючысы да ир-ат иде. Хәер, нигә: «Иде»,— дим соң әле?! Бу

хәлнең бүген дә һич үзгәргәне юк. Әлеге бинибая җаваплы, кеше язмышын, әдәбият-мәдәният һәм хуҗалык эшләрендәге мәсьәләләрне гадел хәл итә килсәләр, без егетләребезгә рәхмәттән башка сүз әйтмәс идек. Алай гына да түгел, «сез бит — кыз бала», дип, безнең ишеләргә анда-санда кечтеки генә ташламалар да ясаштыргаласалар... И-и-и, без аларны Алла урынына күрер идек.

Ни кызганыч, егетләребез кызларны (мин бу очракта иҗат даирәсен генә алам әле) йә күрмәмешкә салышалар, йә бөтенләй тибеп узалар. Алай-болай игътибар итәләр икән, монысы — тискәре мисал кирәк булганга гына алына шикелле.

«Безнең тормыш. Безнең әдәбият» дигән дискуссия дә ир-егет Фоат Садриев романына нигезләнеп башланды. Сүзем юк. Шулай да булсын. Бигрәк тә шуңа куанам: әсәрнең төп каһарманы — хатын-кыз, Нуриасма. Нәкъ менә шул Нуриасма образы мине, хатын-кыз язучыларыбыз иҗатының язмышы турындагы катлаулы уйларга китереп тәрәде дә инде. Фоат Садриевның «Таң җиле» романының үзәгендә, безнең кебек үк, тормыш нужасының тәртәсенә җигелеп тартучы хатын сурәтләнмәсә, бәлки, әлеге сөйләшүгә игътибар итеп тә тормаган булыр идем. Нуриасма язмышы исә уйларны турыдан-туры үзебезгә, чәчмә әсәр язучы татар кызлары кичерешләренә дә китереп тоташтырды.

Минем Нуриасма образына тел-теш тидерәсем килми. Автор аны, үзе белгән кадәрле дәрәҗәдә, ихластан тасвирлаган. Хәтта, әйтер идем, әлеге сөйләшүгә беренче юл ярып җибәргән тәнкыйтьчебез Фоат Галимуллинча, аны күкләргә чөеп мактаудан, ягъни идеаллаштырудан да автор ерак тора. Ф. Галимуллин исә, Нуриасманы мөкәммәл хатын итеп раслау өчен, мәкаләсенең баш өлешендә үк хакыйкатькә хилафлык китерә. Ул бөтен әсәргә күз йомып, «Таң җиле»ндәге Нуриасманы, «Әсма», дип тәрҗемә итеп күрсәтә. Мәгълүм ки, «әсма» белән «асма» сүзләре арасында шактый зур мәгънәви аерма бар. Романдагы «Нури-асма»ны, фәнчә шәрехләсәң, бөтенләй башка мәгънә чыга.

Уйлавымча, авторның героинясына биргән исеме аның җисеменә дә бик туры килә. Моның өчен аның ата-анасы кушкан атына үзгәреш кертүнең дә, Нуриасманы идеаллаштыруның да һич кирәге юк. Заманында, яп-яшь чакта укыган кайбер әсәрләрдәге «уңай» образларны аңлый алмый интегә идем мин. Ни өчен Анна Каренинаны — иренә, ыруына хыянәт иткән хатынны — күккә күтәреп мактыйлар? Ни өчен «Гроза» дагы Катеринаны (ул да иренә хыянәт итә) бөеклеккә чөяләр? Боларны аңлар өчен бинибая гали вә нечкә булган мәхәббәт хисен кичерергә, халык гадәтенә кергән кырыс кануннарга да тәнкыйть күзлеге аша карый белергә кирәк булган икән.

Инде үзебезнең бүгенге Нуриасмабызга мөрәҗәгать итик. Минемчә, бу образ, автор аңлатуында ук, һич тә дөньяви гаделсезлекләрдән азат ителми. Аның язмышы да мең дә бер кыенлыкларга гына түгел, шактый катлаулы хәйләләргә, гаделсезлекләргә, хәтта ялганга да корылган. Һәм бу хәлдән кызыбыз һичничек котыла да алмас иде. Баштанаяк ялганга, тулы бер халыклар гаиләсен тоташтан алдауга корылган җәмгыятьтә бер Нуриасма гына ничек хәйләсез дә ялгансыз яши алсын?! Сез аның япь-яшь кыз чагында, шәһәр шартларында, Газия белән яшәгәндәге чорда үз-үзен тотышына гына игътибар итегез! Ни өчен әле ул яңа туган баланы яшереп азапланучы яһүдә карчыгын эзәрлекләп китә? Кайдан килгән аңа бу шикчеллек? Ахыр килеп, кеше тудырган сабыйда, ул сабый язмышын үзләренчә хәл итәргә йөргән хатыннарда аның ни катышы бар? Сонра Нуриасманың шуңа охшаш сыйфатлары тагын да калкурак ачыла. Ул үзен мәңгелеккә яр итеп алырга кайткан фронтовик егет Сәгыйдуллага куенындагы баланың кем икәнен дә аңлатып торырга теләми. Ирне ир итеп танумы соң бу? Татар кызына мондый тәкәбберлек кайдан килгән? Аннары аның кешеләрне эзәрлекләү сыйфаты тагын «куера». Ире белән Хәдичәнең аулакта очрашуларын күзәтеп йөри башлый. Бик туры күңелле хатын, мондый коточкыч хәлне, үз эченә йомылып кына, «уздырып» җибәрә алмас иде. Мин моны күз алдыма да китерә алмыйм: ире, Хәдичә белән «мунча кереп», кайтып керә. Хатын шуны да белмәмешкә салыша ала. Моның өчен, чыннан да, нәкъ Сәгыйдулла әйткәнчә, «бүрәнә» булырга кирәк. Инде бик тә җәнҗалчы җан түгел икәнсең, адәм баласында һәр мәсьәлә турында иплән кенә, сабыр гына сөйләшү алымы да бар бит. Юк. Безнең Нуриасмабыз бу ысулларның бар икәнен дә белми, белергә дә теләми, аның үз сиксәне — сиксән. Бары үз уйлары, үз балалары тирәсендә генә яши бирә. Аның бер генә сердәше дә юк. Бу күренеш, минемчә, шулай ук аның файдасына сөйләми. Хатын-кызның, бигрәк тә авыл кызларының, бөтен дөнья синнән ваз кичкән очракта да, бәгыреңне ачып салырдай бер генә булса да җан дусты табыла. Нуриасманың — юк. Яхшымы бу? Юктыр. Кемнеңдер, син үлем түшәгенә яткач кына, синнән бәхиллек сорап килүе яшәү мәгънәсе була алмый.

Ул гына да түгел әле. Нуриасманың, адым саен: «Гаделлек, гаделлек!» —

дип, башкалар белән дәгъвалашып йөрүе ачуны китерә. Балалы килеш иргә чыккансың икән, ирең сиңа хыянәт итүгә карамыйча син шул хәлгә күз йомып яшисең икән һәм үз улыңның иң нечкә хисләрен (әлеге дә баягыча, яшерен рәвештә, ифрат тупас рәвештә) «болгатып» җибәргәнсең икән — инде тыныч кына, кем әйтмешли, артыңны кысып кына, яши бир! Юк. Нуриасма һаман бөтен гаделлек кануннарын үз кулында тотмакчы. Хәдичә улының эчкәнен дә күрә ул, Бәриянең аракы сатканын да кычкырып әйтә, Хөснуллинны да фаш итәргә әзер. Үзенең гөнаһлары турында исә... төнлә генә уйлый, ялгыз калганда гына!

Бу сыйфатлары Нуриасманы Ф. Галимуллин сурәтләгән бөеклектән гап-гади хатыннар арасына, җиргә алып төшә. Шулай булырга тиеш тә. Чөнки ул кичергән барлык бәхетсезлекләр бер бу хатын холкына гына бәйле түгел. Болар безнең җәмгыятьнең нигезенә салынган һәм алардан берәү дә качып котыла алмый. Фоат Садриев иҗаты исә нәкъ менә шул каршылыкларны хыянәтсез ачып бирүе аркасында откан, образны бөтен килеш тасвир итә алган. Нуриасма — татар хатыннарының миллионнарыннан берсе. Минем карашымча, мөхтәрәм тәнкыйтьчеләребез укучыга шуны аңлатырга тиеш иде. Кызганычка каршы, алар бу изге бурычка, ягъни язучы белән укучы арасында аңлатучы-арадашчы булу роленә, һаман кереп житә алмыйлар. Тәнкыйтьче, кулына каләм алдымы, ул инде бер әсәрне йә күккә чөеп мактый, яки авторны эттән алып эткә сала. Аларга әдәбият фәне йөкләгән иң изге бурыч исә, безнең татар әдәбиятында бигрәк тә, бүгенге көнгәчә читтә кала бирә.

Тормыш Нуриасмаларыбызны уттан алып суга сала-сала, бәргәләп йөрткәне кебек үк, әдәбиятыбыздагы гадел, фәнни тәнкыйть тә бу даирәдәге фидакарь кызларыбызны читләтеп уза тора. Мин бу очракта чәчмә әсәр язучы берничә бөртек кызыбыз иҗатын күздә тотам. Чөнки шагыйрәләребез, миңа үпкәли күрмәсеннәр, башкарак шартларда иҗат итә. Беренчедән, Язучылар берлегендә дә, редакцияләрдә дә, нәшриятларда да аларга, прозаикларга караганда, игътибарлырак мөнәсәбәт яшәп килә. Миңа калса, тәнкыйтьчеләребез дә шигырь күгебездә кабынган яңа йолдызны тизрәк күреп алалар, аңа ярдәм кулы сузалар, иҗатын камилләштерергә дә теләбрәк алыналар кебек. Ахыр килеп, шигырьнең үз мөмкинлекләре дә кызларыбызга куш кулын сузып тора сыман: шигырьне бит, әле андамонда бастыргалаганчы, китап хәленә китергәләгәнче үк, теләсә кайда укып күрсәтергә була. Әдәби кичәләрдә, радио-телевидение тапшыруларында укы да бир — сине рәхәтләнеп тыңлыйлар. Күңелең бушап-юанып кала. Ә дистәләрчә-йөзләрчә биткә шыплап язылган прозаны, ягъни хикәя, повесть, романнарны, укучыңа житкерер өчен күпме кичерергә, кемнәр алдында йөз суы түгәргә, ничәмә еллар көтәргә туры килә.

Чәчмә әсәр язу үзе үк автордан күпне таләп итә. Күз алдыгызга гына китерегез: башта айлар-еллар буе укучыңа әйтер сүзне нинди вакыйгалар аша, кем образы аркылы житкерү турында уйланып, борсаланып йөрисең. Житә бер көн: сиңа утырып язарга кирәк. Прозаны бары тик бик тыныч, ялгыз, берни борчымаган шартларда гына иҗат итәргә мөмкин. Монда уй-фикер сөрешендә, образ яки вакыйгалар үстерелешендә генә түгел, хәтта ялгыз бер өтер төртүдә генә дә хаталанырга ярамый. Чөнки, нәкъ шул өтек өтер аркасында, синең әйтергә теләгән төп фикерең ялгыш аңлашылырга мөмкин. Шигъриятьтә бу хәл җиңелчә хәл ителеп килә: «тәрәзә» урынына — «тәрәз», «дип» сүзен «диеп» һ. б.ларны рәхәтләнеп кулланалар. Чөнки: «Бу бит ритм, рифма өчен кирәк!» — диләр. Прозада мондый «гөнаһ»лар кичерелми һәм кичерелергә тиеш тә түгел. Телнең кагыйдәләрен житди рәвештә саклаучы бер өлкә булырга тиеш ләбаса. Мин үзем, гомумән дә, Сталин чорының кысаларында үскәнгәдер, мөгаен, һәр өлкәдә гомум танылган мәгълүм кануннарның саклануын хуплыйм.

Мине каләмдәшләрем дөрес аңлый күрсеннәр иде: минем һич тә ике жанрны чәкәләштерергә теләгәнем юк. Киресенчә, әдәби жанрларны мөмкин кадәр якынайтырга, дуслаштырырга, кулга-кул тотындырып үстерергә иде! Әдәбиятыбыз башкача алга китә алмаячак. Шигърияттә прозаныкыдай тирән, саллы акыл хөкем сөрсә, чәчмә әсәрләргә шигъри нәфислек иңдерелсә, ничек шәп булыр иде! Бу очракта әйтергә теләгәнем шул: әсәрләргә, жанрларына карамыйча гына, гадел һәм үз вакытындагы бәя кирәк.

Баксаң, әлеге жанрларны Пушкин булып Пушкин да бер-берсеннән шактый нык аерып йөрткән. Исегездәдер: аның «Евгений Онегин» әсәрендә, Онегин белән Ленскийның икесен ике яр кешесе икәнлеген сурәтләр өчен:

*«...Они сошлись. Волна и камень,*
*Стихи и проза, лед и пламень»,—*

дигән юллар файдаланылган. (Мәскәүдәге «Правда» нәшрияты, 1981 ел, Әсәрләрнең IV томы, 34 бит).

Аңлашылса кирәк, монда проза боз һәм таш белән тиңләштерелә. Димәк ки, әдәбияттагы чәчмә әсәрләр боздай салкын канлы вә таштай авырлыкка-басынкылыкка ия булган фикерне күтәрергә мәҗбүр. Дөнья әдәбиятының прозасына да күркәм өлеш керткән Пушкин карашына мин ничек каршы төшим?! Тик бу фараз, чәчмә әсәрләргә тәнкыйтьчеләрнең мөнәсәбәте боздай салкын, күтәреп тора алмас таштай авыр булырга дигән юл күрсәтмидер бит?! Һич юктыр!

Мин, мәсәлән, үзем, тәнкыйди күзлектән караганда да, «Таң җиле»ндәге Нуриасма белән Бәрияне чәкәләштермәс идем. Ни өчен, дисезме? Чөнки Бәрия — шул ук социализм тудырып үстергән шактый татлы җимешләрнең берсе. Ул әллә кайчан ирешкән фикерләүләргә без әле хәзер, базар мөнәсәбәтләренә тап булгач кына, ияләнә башладык. Кешелектә исә отышлы сәүдә итү — мактаулы һөнәрдән саналган. Ник авылның бөтен хәлле кешесе Бәриягә керә? Бу бит — нәкъ менә без бүген омтылган гап-гади базарча яшәү галәмәте. Шушы дөньяви мәгълүм канунны бездән алдарак аңлаган Бәрияне нигә гаеп итәргә? Профессиональ тәнкыйтьчеләребез ничек уйлыйдыр, әмма мин «Таң җиле»ндәге образларны һәм вакыйгалар сөрешен Белинский, Чернышевскийчарак шәрехләү ягында. Коры җирнең алтыдан бер өлешенә урнашкан барлык халыкларны, дәүләт күләмендә, күз дә йоммыйча, оятсыз рәвештә, кычкыртып алдап килгәннәр икән, ни өчен без бүген, үз көнен күрү өчен, тегеннән-монда сәүдә итеп йөрүче Бәрияне генә дошмани зат, ялган белән көн күрүче итеп тамгаларга тиеш? Бер алъяпкычлык чүпрәк сатып алырга интеккән авылдашларына, Сәмәрканд һәм Ташкент якларыннан манфактура ташып, кыйммәтрәк сата икән — гаепмени бу?! Булдыра алсаң, син дә сат! Әмма бу эш авылдагы башка бер генә кешенең дә кулыннан килми. Бәрия исә — булдыклы сәүдәгәр токымыннан. Социализм бөлдергән миллионнарны бушка киендерергә, бер тиенсезгә аларны сыйларга социалистик йөкләмә алмаган ич ул! Ник керәләр аның аракысын эстәнеп? Чөнки авылда ни ашханә, ни ресторан юк, кибетендәге бер-ике бөртек ризык — талонга гына. Ә безнең кешеләр, урысның ничәмә гасырлык котсызлыгына бирелеп, аракы эчәргә өйрәнделәр. Менә Бәрия түгел, социаль шартлар гаепле. Минемчә, автор бу хакыйкатьне шәрәләндерүдән шикләнебрәк калган һәм Бәрияне «ялганчы» кебек сүзләр белән бәяләргә ашыккан.

Фоат Садриевның бу бәләкәй генә «куркаклыгын» укучыга аңлатып бирү галимнәребез өлешенә төшә. Мәсьәләнең бу ягына килгәндә, әлеге дә баягы, ир-егет прозаикларыбызның кайбер әсәрләре бәхетенә мондый игътибар эләгә әле. Аларга багышланган аерым монографияләр дә чыга, диссертацияләр дә яклана. Кызларыбызның чәчмә әсәрләре исә — бөтенләй читтә. Анда-санда берәр мәкалә күренсә, бу — йә әдибәнең юбилее уңаеннан, йә 8-Март көне якынлашканга гына басылган була.

Шөкер, бу җәһәттән дә, шагыйрәләребез иҗатын өйрәнү алдарак тора. Мисалга мөхтәрәм профессорыбыз М. Гайнуллин төзеп калдырган «Өмет йолдызлары» китабын һәм И. Юзеев төзегән «Кызлар җырлый» җыентыкларын китереп үтәргә мөмкин. Ә менә шул тәртиптә җыелган проза әсәрләребез, кызларыбызның хикәя, повесть, романнарын теркәп күрсәткән нинди кулланма бар?! Ерак тарихларга китеп эзләнүләрне әйтмим дә инде, әле чагыштырмача якында гына иҗат иткән Гайшә Шәрипова, Хәерниса Сафина кебек роман жанрында иҗат итүче җитди прозаикларны да, төрле сәбәпләр табып, күрмәмешкә салыштылар. Янәсе алар Татарстанда яшәми, янәсе алар татарча иҗат итми һ. б. Әсәрләренең үзәгендә чеп-чи татар тормышы ярылып ятса да, аларны анализлап күрсәтүче тәнкыйтьче табылмады. Нәтиҗәдә исә татар кызларының прозаик әсәрләр язу дәвере бинигаят тар бер кысага кертеп калдырыла килә.

Гаҗәп бит: үзебез, бер яктан, татар халкы бөтен дөньяга сибелеп яши, дип тәкърарлыйбыз, икенче яктан исә, алар Татарстанда яшәми, дип, иҗатларын кире кагабыз. Тагын да сәеррәге шул: ир-егетләрнең әллә кайсы төбәкләрдә яшәүчеләренә дә, татарча ләм-мим белмәүчеләренә дә — бөтенләй башка караш. Аларны Мәскәүдән, Күкчәтаудан, Чиләбе якларыннан табып-табып алалар, Казанга чакырып китерәләр. Язучылар берлегенә дә кабул итәләр, хәтта Тукай исемендәге Дәүләт бүләген дә тапшыралар. Дөрес караш бу. Нәкъ шулай булырга тиеш, без каләм осталарыбызны бөтен дөнья буенча эзләргә, табарга, әдәбиятка теркәргә, иҗатларын өйрәнергә, татарча яза белмәгәннәрен тәрҗемә итәргә тиешбез. Тик бу гадел мөнәсәбәт кызларыбыз иҗатын да читләтеп үтмәсен иде!

Әле алай гына да түгел, ир-егет язучыларның кайбер чиле-пешле әсәрләре, кай ягы белән дер бик «кыйммәтле» дип табыла да, башка бер олуг әдипкә: йә Гариф Ахуновка, йә Аяз Гыйләҗевкә, йә Барлас Камаловка биреп, «эшкәрттерелә», ягъни журнал битенә, китапларга басарлык дәрәҗәдә яңадан яздырыла. Кызларның кайсы бу «эшкәртелү»гә лаек табылган? Юк. Берсе дә. Һәм, минем иманым камил,

кызлар мондый юлга басмаслар да иде. Һәрхәлдә, проза язучы кызларыбызның горурлыгы мондый «тәҗрибә»не кабул итә алмас иде. Бу төр «эшкәртелү» минемчә, бары тик егетләр кулыннан гына киләдер...

«Таң җиле»нә бәйле рәвештә башланып киткән сүзнең беренчесендә үк тәнкыйтьче Ф. Галимуллин, ихтыярсыздан, Нуриасманы зур прозаикларыбызның моңарчы иҗат ителгән роман-повестьларындагы тиңдәш образлар рәтенә җитәкләп кертә. Мин дә нәкъ шул фикердә торам: Нуриасма Г. Бәширов, Р. Төхфәтуллин, В. Нуруллин, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, Н. Фәттах һ. б. прозаикларыбызның авылга кагылышлы әсәрләрендәге хатын-кыз образларына, кай яктан булса да, охшапохшап куйгалый. Башкача мөмкин дә түгел. Шул ук авыл инде ул, чоры-фәләне дә бер үк елларга килеп тоташтымы — кая китәсең, уртаклыклар үзеннән-үзе чыгып тора. Әмма Ф. Садриев авылыбызның иң авыр йөген тартучы бу образны бүгенге көнгә китереп тоташтырган. Нуриасма әлегә татар хатыннарына хас күркәм сыйфатларны да саклаган һәм инде бүгенге «бозыклыклар»га да шактый изләнеп бетеп. Бу шәхес ут белән су, чын вә ялган, изгелек белән гөнаһлар арасында буталып калган. Хатын-кызлар образындагы мондый капма-каршылыкларны иргегет язучыларыбыз берсеннән-берсе остарак күрә. Әләктереп кенә алалар да, бөтен шартына туры китереп, тасвирлап та бирәләр.

Әмма хатын-кыз язмышында ирләр башына бөтенләй кереп тә чыкмастай хәлләр дә бик күп. Кызларыбызның чәчмә әсәрләрендә исә әнә шулар зуррак урынны алып тора. Бер карасаң, тәнкыйтьчеләребез өчен, эзләп табалмаслык хәзинә ята монда. Иренмә генә дә, зиһенеңне эшкә җигәргә генә тырыш, әллә нинди «байлыклар» актарып чыгарырга булыр иде кебек. Тик, ни гаҗәп: кызларыбыз прозасын өйрәнергә алынучы тәнкыйтьчеләр бөтенләй күренми. Дөрес, безнең буынга өлкән каләмдәшләребез бик игътибарлы булды: Нәкый Исәнбәт, Мирсәй Әмир, Шәйхи Маннур, Афзал Шамов, Ибраһим Гази, яшьрәкләрдән Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Газиз Мөхәммәтшин, Барлас Камалов... Әле без Язучылар берлегендә дә түгел идек. Газеталарда беренче хикәяләребез, журналларда очеркларыбыз чыккалый иде. Олуг әдипләр шуларны күтәреп, елмаеп-көлеп янга киләләр, котлыйлар, хуплыйлар, кимчелекләр турында да иплән кенә аңлаталар иде. Афзал Шамовның: «Шулай да бик авыр чорга туры килде сезнең иҗат,— дигәне хәтердә.— Элек без сездәй кызларны әллә кайлардан эзләп йөри идек, кулларындагы язмаларын сорап алып, атна-ун көн эчендә китап итеп чыгарып бирә идек. Хәзер китап чыгарулар ирләргә дә авырлашты»...

Бер карасаң, прозаик кызларыбыз әле дә күп түгел бит: Рәисә Ишморат, Гөлшаһидә, Диләрә Зөбәерова, Мәдинә Маликова, Роза Хафизова, Фәүзия Бәйрәмова, Нәбирә Гыйматдинова... Мин монда укучыга яхшы таныш һәм бары тик олылар өчен проза язучыларны гына саныйм. Күрәсез: дистәгә дә тулмый бит. Инде карап карыйк — шул әдибәләрнең кайсының иҗатына әтрафлы бер анализ-язма яки монография бар? Юк. Язган һәр әсәрләрен, күтәреп алып, укучыга тәфсилләп тәкъдим итмәгәннәдер, мөгаен, аларның сафы әллә ни ишәюгә дә бармый. Мең бәла белән басылып чыккан әсәрләре исә көне-атнасы белән сатылып бетә, китапханәләргә эләксәләр, укучы, иң әүвәл шул кызларыбызның китабын сорап ала.

Хикмәт нәрсәдә? Ник укучылар кызларыбыз прозасын хуплап каршылый да, тәнкыйтьчеләребез генә аларны белмәмешкә салына? Мин әле генә Нуриасмага охшаш образларның барлыгына һәм бу охшашлыкның сәбәпләренә дә тукталган идем. Инде килеп сез хатын-кыз прозаиклар әсәрләрендәге кызлар образларын бәрәмтекләп тикшерегез. Табарсызмы, ичмасам, бер охшашлык? Рәисә Ишморатның Рәсимәсе («Чатнама суыкта» хикәясе), Рәйханәсе («Рәйханә» повесты), Фәһимәсе («Милиция лейтенанты» дилогиясе), Гөлшаһидәнең «кала алучы кызы» на («Минем кала алуым») яки Зөбәерованың Назирәсенә («Дустым авазы»), Маликованың Тәбриясенә («Кояш күпере» повесты) аз гына охшаганмы? Нәбирә Гыйматдинова белән Фәүзия Бәйрәмова иҗат иткән хатын-кыз образлары бөтенләй бүтән төрле. Һәм, өздереп, тагын шуны да өстисе килә: ир-егетләребез, кем әйтмешли, янадан тусалар да, андый кызлар образын иҗат та итә алмаячаклар. Чөнки кызларыбыз тудырган образлар бәгырьдән бөреләнеп чыккан, андыйны бары тик үзе хатын-кыз булган каләм әһеле генә тасвирлый ала. Бу хәл табигый. Шуны аңлап, шул хакыйкатьне танып, тикшеренәселәр, эзләнәселәр генә бар.

Гаделлеккә кагылып китермәс өчен мин тагын бер сер сымак нәрсәгә кагылмакчы булам. Гади укучы белмидер: язучының әсәре, китап хәленә килгәнче, нәшрият дигән оешмада, бинһаһа катлаулы, караңгы бер юл уза. Синең кульязманы «эчке рецензия» дигән сөзгеч аша үткәрәләр. Сөзгеч ролен бик абруйлы галимнәр, тәнкыйтьчеләр үти. Алар китапның чыгу-чыкмавын хәл итәләр. Бәя язма

рәвештә бирелә һәм автор бу кискен карарны иң соныннан гына белә. Минем «Тәңкәле тау» исемле романым сигез ел (!) буе нәшрият киштәсендә ятканнан соң, андагы кайбер җитәкчеләр алып ташлангач, ниһаять, гадел бер тәнкыйтьче кулына килеп кергән. Китапка редактор итеп билгеләнгән Наилә Вәлитова мина аның рецензиясен тоттырды. Күзләремә ышанмыйча торам. Рецензиянең беренче юлына: «Без хатын-кыз прозаикларыбызга бигрәк игътибарсыз икән...» — дип язып куелган иде. Гап-гади бер дөрес сүз генә бит инде, югыйсә. Әмма шул гаделсезлекне рецензентым Ринат Мөхәммәдиевнең дә аңлавы һәм шул хакта ачыктан-ачык язып та куюы күңелемнең астын-өскә айкап ташлаган иде. Ул чакта Р. Мөхәммәдиев өметле генә тәнкыйтьче буларак танылып килә иде. Димәк, кызларыбыз прозасына игътибар булачагына да ышанырга мөмкин, дип өметләндем. Юк. Шушы бер эчке («яшерен» дисәң дә була) рецензиядән тыш мин мондый гомумиләштерелеп һәм кызлар иҗатына аерым мөнәсәбәт кирәклегенә ишарәләгән чыгышлар да ишетмәдем, мәкаләләр дә укымадым. Ярый әле, өлкән каләмдәшләребез, тәнкыйтьчеләр башкарырга теләмәгән вазифаларны да өсләренә алып, кульязмаларыбызны укыйлар, фикерләрен әйтәләр, анда-санда хуплап та чыккалыйлар.

Тәнкыйтьчеләребезнең ялкаулыгы исә мине, гомумән, таң калдыра. Һәр яңа әсәрне тиешенчә бәяләп бару, укучыга аңлату — аларның төп бурычы лабаса! Язучылар берлегенә дә алар шуның өчен кабул ителгән. Күп очракта алар кызлар иҗатын гына түгел, ир-егетләребезнең уңышлы әсәрләрен дә «күрмиләр». Әллә укымыйлар да инде?

Әйтик, узган елгы әсәрләр арасында Җәмит Рәхимовның «Батырша» романы бар. «Казан утлары» журналы аны үзенең өч санында бастырып чыгарды (7—9 саннарда). Тарихыбызның ифрат катлаулы чорына багышланган, автор тарафыннан бик җентекләп өйрәнелгән мондагы вакыйгалар гади укучыны хәйран калдырды. Мин, әсәрнең беренче өлешен укуга ук, тәнкыйтьчеләребезнең мәкаләсен көтә башладым. Икенче өлеше дә чыкты, ниһаять, роман тулаем басылып бетте. Тәнкыйтьче әфәнделәрнең сүзе генә күренмәде.

Хәер, кайчак уйламаганда-көтмәгәндә, «төссез» генә тоелган әсәрне дә, әле чыгып җитәр-җитмәс, күтәреп алып мактый башлыйлар. Төрле телләргә тәрҗемә дә ителә андый әсәрләр. Зур-зур бүләкләргә дә тәкъдим ителәләр. Бәхеткә, кызларыбыз прозасы менә мондый гөнаһылардан ерак тора. Бу өлкәдә без чын-чынлап горурлана алабыз. Аның каравы, илнең әллә кай төбәгенә барып чыксаң да, синең әсәрне яратып укучы кеше очратасың. Исем-фамилияңне ишетеп алсалар, кырык эшләрен ташлап, үзеңне күрергә киләләр. Кулларында укый-укый тетелеп беткән китабың була. Автограф сорыйлар. Безгә шуннан да зур шатлык юк кебек.

Шулай да, әдәбиятыбызның проза жанрын чынлап үстерәсебез, аны башка зур әдәбиятлар рәтенә кертеп, телдән-телгә сөйләтерлек хәлгә китерәсебез килә икән, бу тармакның еракта йолдыздай балкучы кызлар прозасын да истән чыгармаска иде бит, егетләр! Бу фидакарьлекне күрмәмешкә-белмәмешкә салышу әдәбиятыбызга зыян сала, аны ярлыландырып калдыра.

Вакыт-вакыт күңелгә хыялый уйлар килә дә, канатланып куям: менә безнең күпсанлы, югары дәрәҗәле галим-тәнкыйтьчеләребез «уянып» киткәндәй булырлар да, кызларыбыз язган чәчмә әсәрләрне җентекләп өйрәнә башларлар, аларны башка төрки әдәбиятлардагы хәзинәләр белән чагыштырып-чагыштырып та карарлар. Төрки телдә иҗат итүче башка җөмһүрият кызларының бер-ике хикәя белән дан-шөһрәт казануларын, бездә исә дистәләгән хикәя, повесть, роман язганнарның да санга сугылмавын ихластан аңлап, тетрәнеп куярлар. Аңларлар шикелле: ир-егетләребезнең прозасы олуг әдәбиятыбызда нигез ташларын, бүрәнә-диварларын, ишек борысларын, матчаларын тәшкил итсә, кызларыбыз язган чәчмә әсәрләр исә капкалардагы, тәрәзә капкачларындагы челтәрле бизәкләр, өй эчендәге затлы чаршау-чыбылдыклар, чәчәкле-чуклы кашагалар булып тора ала. Моннан бүтән чагыштырулар да, бәяләмәләр дә табарга мөмкин. Теләктәшлек, бер-беребезнең хезмәтен олылау, ихтирам итү һәм әдәби байлыгыбызны барлау юлында ялкаулыкка бирелмәү, фәнни мавыгу гына кирәк! Тик, ни кызганыч, бүгенгәчә шушы гап-гади хакыйкатьне аңлаучы, кызларыбызның прозасын гомум чәчмә әсәрләребез маңгае өстенә энҗеле калфак итеп чөюче, иңенә озын чуклы ак ефәк шәл иттереп салучы гаярь тәнкыйтьчеләр генә күренми.

Дистә еллар буе кызларыбызның күләгәдә кала килгән прозасын яктылыкка алып чыгу нәтиҗәсендә, кем белә бит: бәлки әле, татар әдәбиятының чын бәясе дә ачыкланыр. Ул һич югында төрки әдәбиятлары киңлегендә, үзенчә балкучы бер яңа йолдыздай җемелди башлар. Минем ышанасым килә: күпләр, бу яңа йолдызчыкка карап, сокланыр иде!

# ПУБЛИЦИСТИКА

**Мөдәррис Мостафин**

# ТОРМЫШ БҮЛӘК ИТӘМ

Операциядән соңгы беренче көннәрем иде. Төннәр бик озын тоела. Таң аттыра алмыйча аптырап бетәм. Күзгә йокы керми. Йокымсырап китсәм, шунда ук куркып уянам. Унга да, сулга да борылырга ярамый.

Иртәнге сәгатьтә бүлмәгә иң башта шәфкать туташы килеп керә. Уколын кадый да «ялт» итеп чыгып та китә. Мин, караватт тимеренә электерелгән сәгатемә карый-карый, сигез тулганны көтәм. Шул тирәдә минем янга хирург керә. Башта ишек тоткасында кулын шәйлим, ул икәнен сизәм, аннары гәүдәсе һәм елмаюдан нур чәчеп торучы йөзе күренә. Ул килеп керүгә, бүлмәдә кояш балкыгандай була. Авыртулар онытылып китә. Яшибез болай булгач, яшибез! Минә ул минем янга килеп баса, күзгә туры карап, хәлне сораштыра. Сихәтле куллары минем тәнне капшый. Врачым җанга ягымлы тынычландыргыч сүзен кабатлый: «Әйбәт, төзәлә». Ә мин үземнең моң-зарымны сөйләп, күңелдә төн буена җыелган сорауларымны тәкърарлыйм. Ул исә: «Вакыт кирәк, барысы да узар»,— дип куя һәм чыгу ягына борыла. Беләм: аны минем кебекләр башка бүлмәләрдә дә зарыгып көтәләр...

Республика клиника шифаханәсенең урология бүлеге хирургы Ринат Харис улы Галиевнең эш көне һәрвакыт тыгыз, киеренке. Авырулар янында ул бер дә, ике һәм өч тә була. Кирәклегенә карап. Кайвакыт сиңа, киткәндә генә сугыла, чөнки аның иң күп вакытын операцияләр ясау ала. Бу бүлектә врачларның белемен күтәрү институтындагы урология кафедрасы да эшли. Ринат Харисович — шул кафедраның доценты. Ана төрле төбәктән Казанга белемен камилләштерергә килгән врачларга лекцияләр укырга да, алар белән әңгәмәләр уздырырга да, хәтта чит республикалар һәм өлкәләргә барып-барып кайткаларга да туры килә.

...Бераз рәтләнә төшкәч, коридорларга чыгып йөри башладым. Шифаханә коридоры — үзе бер дөнья. Адым саен, операция ярасы тартканлыктан, кайсы эчен тоткан, кайсы таякка таянган кешеләрне очратасың. Кайберләре әлегә дәвалана гына, башкалары операциягә чират көтә. Врачлар, шәфкать туташлары янгын вакытындагы кебек ашыгып узалар. Иртәнге мәлдә ыгы-зыгы аеруча күзгә ташлана. Яңа хәбәрләрне дә шунда ишетәсең: төнлә кемгәдер начар булган, кемнәргә операция билгеләнгән, кем ясый? Әлбәттә, Ринат Харисовичны телгә алмый калмыйлар: «Минә ул тотынса!.. Ул ясасын иде, ичмасам. Аңа эләксәң, бәхет инде».

Бер иртәдә, коридорның очына хәтле йөри ала башлагач, Ринат Галиевнең эш бүлмәсе каршына барып бастым. Бер-ике авыру көтә иде инде. Өстенә ак халат бөркәнгән олы яшьтәге бер марҗа тегеләргә бик дулкынланып үз хәлен сөйли: «...Чудо человек!» — дигән сүзләренә игътибар итеп, мин дә аңа таба борылдым. Чаллыдан икән үзе. Иренә Ринат Харисович операция ясаган, бәвел куыгын алыштырган. Инде ире, авыр көннәрен уздырып җибәреп, хәлләнә башлаган. Шуңа шатлыгы эченә сыймый.

Шифаханәнең бу бүлекчәсендә дәваланган арада мондагы хирургларның кешене сәламәтләндерү, яңадан тормышка кайтару буенча могҗизаларга тиң эшләр башкаруын ишетеп, хәйран калдым. Ә бәвел куыгын яңадан ясап кую турындагы сүз мине, гомумән, шаккатырды. Миндә Ринат Галиев белән кызык-

сыну тагын да көчәйде. Кайсы як кешесе ул, шундый мөлаем, кешелекле бала үстергән ата-анасы кемнәр? Барысын да беләсе килә. Җае чыккан саен тегесен-монысын сораштыргалый торган булдым. Иярләшә төшкәч, бушрак вакытын туры китереп, эш бүлмәсенә дә кергәләдем. Бервакыт ул миңа авыруларның бөер һәм бавырларыннан алынган, бирелә күргәзмә әсбап сыйфатында калдырылган ташларны күрсәтте. Арада йомырка сарысы чамасындагылары да, әллә ничә җәлпәкле иләмсезләре дә бар. Кайберләре диңгез ташкыннарында шомарып беткән матур чуерташларны хәтерләтәләр. Җәйге аяз күк гөмбәзе төслерәк ачык зәңгәрен, уч төбемә куеп, исләрем китеп карап тордым. Үзе матур, үзе кешене газаплый. Дөрес, хәзер бөердәге ташны операциясез, ваклатып чыгарту аппараты да бар икән. Ләкин аны һәр кешегә дә кулланып булмый. Әлегә күпләрне бу җәфа чигүдән һәм үлемнән хирург скальпеле генә коткара ала. Мин шифаханәдә андый операция кичергән кешеләрне хәтсез күрдем.

Бер сөйләшүебездә, докторымның кәефе аеруча яхшы икәнлекне тоемлап, мин кешегә бәвел куыгының яңасын ясап кую кебек четерекле ысул белән кызыксынуымны белдердем. Бу өлкәдә хезмәте зур икән аның. Сиксәннән артык шундый операция ясаган икән инде. Мондый операцияне, күбесенчә, кешенең гомере кыл өстендә калганда, бәвел куыгына яман шеш зарар салган очракларда гына ясыйлар. Ринат Галиев хезмәт юлы башында Вишневский исемендәге шифаханәдә профессор Э. Н. Ситдиков кул астында бүлек мөдире булып эшләгән. Беренче күнекмәләрне ул шунда алган. Хәзер инде үзе зур тәҗрибә туплаган. Республика шифаханәсендә мондый катлаулы операцияләр күп очракта аның тарафыннан яки аның җитәкчелегендә башкарыла.



**Рәсемдә:** *уңда Ринат Галиев, сулда урология кафедра мөдире Сергей Белых.*
*С. Биктимеров фотосы.*

Ринат әфәнде бу эшкә яңа ысул да кертә. Мәсәлән, бүтән белгечләр, бәвел куыгын алыштырганда, авыруның юан эчәк кисентесен файдаланалар. Галиев исә нечкә эчәкне куллана. «Кешедә нечкә эчәк шактыйга озынрак, аның 30—40 сантиметрын кисеп алуның зыяны азрак»,— дип фикер йөртә Ринат Харисович.

Казан — медицина өлкәсендәге бик күп башлангычлар шәһәре. Бу төр операцияләрне дә, әйткәнемчә, беренче булып, Казанда ясый башлыйлар.

Хәтта Америка Штатларында да мондый операциягә соңрак керешәләр. Әмма безнең үзәк матбугат, әллә юри, әллә надanlык аркасында, Казандагы казанышлар хакында эндәшми. Дөнья бу төр операцияләрне беренче башлап АКШта ясалды, дип белде.

Ринат әфәнде бер вакыйганы аеруча ачыргаланып исенә төшерде.

Ул, Татарстанда уздырылачак бер фәнни конференция алдыннан, бөердәге яман шешкә бәйле мәгълүматларын уртаклашу нияте белән, Мәскәүгә, онкология үзәгенә бара. Танышып йөргәндә ул берничә авыру турында: «Болары өметсез, бөвел куыкларында — яман шеш»,— дигән сүзне ишетә. Докторыбыз гаҗәпкә кала: Казанда аны уңышлы дәвалауларын, үзенең дә күп еллардан бирле шундый операцияләр ясавын әйтә. Башта ышанмыйлар, бу татар малае шаярта, дип уйлыйлар. Аннары сүзләрен раслап күрсәтүен сорыйлар. Ул ризалаша. Операцияләр ясый. Шикләнеп караучыларның борыннарына чиртә. Терелүчеләр (аның берсе — Игорь Писарев (Мәскәү пациенты) бүгенгәчә аңа рәхмәт хатлары яза. Игорьның бер хатын күрсәтте дә әле миңа Ринат Харисович. Ул үзен яхшы хис итүен, туристик походларга йөрүен, хәтта урманда агач кисеп, аны яруын, зур гына түмәрләрне күтәрүен тасвирлый.

Кыргызстанның Ош шәһәрендә яшәүче М. Морзаев, яшәүгә өметен бөтенләй югалткач, ГИДУВның урология кафедрасында курсларда укыган бер якташ врачыннан ишетеп, Казанга килә һәм Ринат Харисовичны эзләп табып, авыртудан нык интегүен сөйли, «Зинһар, ярдәм итегез»,— дип мөрәҗәгать итә. Шул кадәр ерактан килүченең үтенечен ничек кире кагасың?! Кеше сәламәтләнеп, чиксез рәхмәтләрен белдереп, кайтып китә. Үз иленә кайткач та, рәхмәт хисләре белән хатлар яза...

...Күпне күрергә, күпне ишетергә туры килде миңа урология бүлегендә яткан бер ай вакыт эчендә. Берсендә коридорда һәрвакыт шат кыяфәттә, җитез, хәтта чабып йөрүче унҗиде-унсигез яшьләрдәге кыз бала игътибарымны җәлеп итте. Казанныкы икән, Соколова фамилияле, һич кенә дә авыру кешегә охшамаган. Иплән кенә Ринаттан сораштырдым. Кайбер кешеләрдә бөвел куыгы, тумыштан, зәгыйфь була икән. Билгеле бер яшькә кадәр ул моны сизмичә-тоймыйча яши. Шул чикне узгач, авырый, интегә башлый. Хәзер ул, зур бәладән котылып, терелеп килә инде. Шатлыгының, очынып йөрүенең сәбәбе шул булып чыкты.

Кыска гына гомеребездә безгә нинди генә авырулар ябырылмый. Исән-сау чакта, гамьсез генә яши бирәбез. Шифаханәгә эләккәч, хәйран калдым, ай-һай, күп икән авыручы. Алар урология бүлегенең коридорларына да сыймый...

Менә яңа эш көне башланды. Мин операция блогына алып керә торган ишекнең каршы ягында тәрәзә янәгына сөялеп, язгы кояш нурлары җылысы һәм яктысы белән хозурланып, хәл алып торам. Бүген олы яшьтәге бер хатынга катлаулы операция булырга тиеш. Ринат Галиев ясый. Димәк, хирургым, озакламый, моннан узачак. Бер соравым бар иде үзенә. Көн гадәттәгечә уза тора. Сәгать көндезге 3 тә ял сәгате билгеләнгән, тик кайда инде ул урынга яту?! Минем күңелдән Ринат китми. Ничек икән анда эшләр? Блокка кереп-чыгып йөрүче шәфкать туташларыннан гел белешеп тордым. Кырт кисеп: «Операция дәвам итә»,— генә диделәр. Тагын таныш тәрәзә янына юнәлдем. Көн кичке якка авышты. Ләкин язгы кояш пыяла аша булса да ярыйсы гына кыздыра. Җылысы бөтен тәнгә йөгерә. Нурлары зәңгәрсу төстәге стенада уйный. Мин, сәгатемә карый-карый, берәрсенең операция блогыннан чыгуын көтәм. Дүрт тулды. Димәк, операция башланганнан соң, җиде сәгатьләп вакыт узган. Озак. Менә бүлмәнең ишеге ачылды. Аннан берәм-берәм врачлар, шәфкать туташлары чыга башладылар. Ниһаять, Ринат әфәнде дә күренде. Ул нәкъ миңа каршы килә кебек. Күзгә-күз очраштык. Хәйран калдым: минем хөрмәтле докторым ябыккан, суырылып төшкән, хәтта гәүдәсе дә бераз чүккән кебек, тик күзләре генә (мең шөкер!) элеккечә елмаялар. Аны мондый хәлдә күреп, башымда берьюлы әллә никадәр сорау туды. Ләкин: «Операция ничек узды соң?» — дип кенә сорадым. «Әйбәт». Шулай диде дә, салмак кына атлап, үзенең эш бүлмәсенә таба китеп барды. Коштай очып йөрүен күреп ияләшкәнгәдер инде, Ринат Харисовичны бу минутта хәтта җәлләп куйдым. Алтышар-җидешәр сәгатьлек операция дәвамында, авызыңа бер йотым су да капмыйча, адәм гомере өчен «тартышып» кара әле! Әлбәттә, операция барышында аның турылыклы ярдәмчеләренең эше дә җиңел түгел. Якынчан таныш булмагач, без — бәндәләр, моны белмибез. Кулыңа пычак тоткан хәлдә икенче берәүнең җанын тоярга, тәнен ялгап, тегеп, аңа яңа гомер бирергә тиеш бит ул. Аз гына ялгыштыңмы — бетте... Ялгышмаска, ялгышмаска, ялгышмаска!!!

Югарыда сүз күбрәк урология бүлегенең бер юнәлеше, бик әһәмиятле яңа бер өлкәсе турында гына барды. Авырулар күп булган кебек, аңа каршы көрәш чаралары да төрле-төрле. Кешене сәламәтләндерү өчен көрәштә ГИДУВның бирedәге кафедрасы, шәхсән, аның доценты Ринат Галиев башкара торган эшләр дә күпкырлы һәм киң колачлы. Кайбер операцияләрдә аның үзенә генә хас алымнары да бар. Шуларга багышланган фәнни хезмәтләре дә шактый аның.

Мәсәлән, ул бөерне һәм бөергә килә торган кан тамырларын өйрәнү буенча күп эшли. Мәгълүм ки, бөере авыру кеше кан басымының югарылыгыннан җәфалана. Дарулар ярдәм итми. Мәскәүдә мондый авыруны операция ясау, бөергә тоташа торган кан юлын юшкыннан чистарту юлы белән дәвалауларын ишетә Ринат Харисович. Һәм ул Мәскәүгә барып, башкала больницаларының берсендә профессор А. Кратовскийдан өйрәнеп кайта, аннары андый операцияләрне үзе дә ясый башлый.

Ринат Галиев Сарман районы, Муса Җәлил поселогыннан килгән шундый бер авыруны исенә төшерде. «Кан басымы 220 дән төшми. Түзеп тормаслык хәл бу. Дарулар ярдәм итми,— ди.— Операция ясарга туры килде. Менә сигезенче ел инде, ул әйбәт кенә яшәп ята.

Хирургның 1985 елда яклаган кандидатлык диссертациясе дә шушындый гамәлләрне эченә ала, 1989 елда ул Казан медицина журналында «Бөер артериясе кысылуга бәйле гипертония» дигән фәнни хезмәт бастыра. Шушы ук елда шул ук темага Ростовта уздырылган фәнни конференциядә доклад ясый.

Гамәли эш һәм фәнни тәҗрибә өлкәсендә Ринат Харисовичның хезмәтләре бәяләп бетергесез. Аның утыздан артык фәнни язмасы, дистәдән артык рационализаторлык тәкъдиме бар. Җиде фәнни ачышына элеккеге Союз күләмендә авторлык таныклыгы бирелгән. Хәзер ул докторлык диссертациясе яза.

Ләкин аны көндәлек гамәли врачлык вазифалары нык кыса. Җитеш кенә! Шифаханәдәге эшләр, врачлар сүзе белән әйткәндә, планлы операцияләр — бер хәл. Еш кына аңа санитария авиациясе белән, республика шәһәрләреннән һәм авылларыннан авыр хәлдәге кешеләрне китерәләр. Операцияләрнең күбесен, әлбәттә, Ринат Харисович үзе ясый. Кайчак авыруны урыныннан кузгатырга ярамый. Андый чакта санитария самолеты белән врачлар үзләре оча. Бер ай күп тә түгел кебек. Вакытның шул өзегендә дә Ринат, ашыгыч төстә Чаллы, Бөгелмә, Әлмәт шәһәрләренә барып, операцияләр ясый.

Бер очрак нык истә калган. Әлмәткә бер көнне төштән соң китте ул, ә икенче көнне иртән эштә, без — авырулар янында иде инде. Коридорда аны очратып, гаҗәпләндем. Түзмәдем, кызыксынуымны белдердем.

Аңа төн буе эшләргә туры килгән икән. Авыру, болай да, бер генә бөерле, ди. Икенчесендә — зур таш. Авыруның язмышы — кыл өстендә. Бу операция — сират күпере аркылы узу белән бер. Шуңа күрә дә Ринат Галиевне чакырганнар. Операция тәмамлангач, аны иртәнге дүртләрдә Бөгелмә аэропортына китерәләр, бераздан ул Казанга оча, башкала аэропортыннан өенә кайтып тормый, туп-туры безнең янга — «үзенекеләр» янына килә ул. Чөнки биредә шулай ук кичектерергә ярамый торган операция көтә икән аны. Тормышның мондый агышына ул күнгән инде: «Үзенә авыр булса булсын, кеше гомере генә саклансын!»

Без һәртөрле авырулар таралган заманда яшибез. Бу шактый дәрәҗәдә безнең тормыш шартларына, нинди ризык ашавыбызга, нинди су эчүебезгә дә бәйле. Ринат Харисовичны бөер авыруларының ешаюы борчый. Кайвакыт кешегә, бик теләсәң дә, ярдәм итеп булмый икән инде. Әйтик, кешенең бөерләре яки сынар калган бөере эшләми башлый... Дөрес, андый авыруларны ясалма бөер аппараты белән яшәтеп була. Ләкин моның чиге бар бит инде. Бер генә юл — башка берәүнең бөерен ку:о мөмкинлеге генә кала. Мондый операциягә мохтаҗ кешеләр безнең республикада шактый. «Дөньяда мондый операцияләр кулланыла инде,— ди Ринат,— ләкин бездә (ул Россияне, элекке союзны күздә тотып сөйли) хирургиянең бу тармагы җәелеп китә алмый әле. Алга киткән чит илләрдә бу мәсьәлә юридик яктан да, әхлак ягыннан да хәл ителгән. Аңлашылса кирәк: сүз бит чит кеше бөерен (әйтик, авариягә юлыгып, үлеме котылгысыз кешедән алынганны) икенче берәүгә күчереп утырту турында бара. Әйе, уйланырлык урын бар. Ринат Харисович хәзер шушы мәсьәләне өйрәнә. Мәскәүдә элеккеге Бөтенсоюз фәнни-хирургия үзәгенең бөерне күчереп утырту бүлегендә курсларда да укый, тәҗрибә туплап кайткан ул.

Ниһаять, ул үзенең күптәнге хыялын тормышка ашыра. Бөерләре начарлыктан, вакыты-вакыты белән бөтенләй эшләве туктау куркынычы янаудан җәфа чигүче ике хатынга Казанда яшәүче Г. белән Н.га, башка кеше бөерен беркетергә тәвәккәлли. Авырулар, әлбәттә, ризалыкларын белдерәләр. Бу катлаулы операцияне әзерләүдә һәм башкаруда күптөрле белгечләр, мәсәлән, шәһәрнең 6 нчы шифаханәсе врачлары, лаборатория белгечләре иң якыннан катнаша. Донор бөерен күчереп утыртуга әзерлек нәкъ менә шушы бүлектән — авыруга ясалма бөер аппараты белән ярдәм күрсәтүдән башлана. Бик күп сораулар туа. Чит кеше бөерен икенче берәүнең организмы кабул итәрме? Донор бөере дөрес сайланганмы? Тикшерәләр, ачыклыйлар һәм тәвәккәллиләр. Скальпель — Ринат Галиев

кулында. Мондый операцияне башкарып, ул үзенең сәләтен һәм осталыгын тагын бер кат раслый. Республика клиника шифаханәсенең урология бүлегендә ясалган бу операцияне Казан врачларының, моңарчы да бик күренекле ачышлар белән дан казанган Казан медицина мәктәбенең яңа җиңүе дип бәяләргә мөмкин. Мәскәүдә инде эшләнсә дә, Казанда һәм Идел буе төбәгендә мондый операция беренче тапкыр ясала.

Бу вакыйгадан соң байтак вакыт узды инде. Г. белән Н. ни хәлдә соң? Алар исән-сау, үзләрен яхшы хис итәләр.

Беркөнне мин врачымнан: «Сез бу һөнәрне үзегез сайладыгызмы, әллә берәрсе киңәш иттеме? — дип сорадым.— Читтән карап торуга гына мавыктыргыч, югыйсә, бигрәк авыр бит. Хирургларга аеруча кыенга килә...»

Ул, гадәтенчә, елмайды. Аннары күңелендә врачлыкка уку хыялының ничек уянуы турында сөйләде. Ринат Әлмәт районының Нәдер авылында туып-үскән. Әнисе Асия — укытучы, әтисе Харис урманчы була. Мин бу төбәкне Ватан сугышы чорыннан бирле беләм. Әлмәттә эшләргә туры килгән иде. Нәдер — гап-гади, борынгы татар авылы. Халкы эшчән, гаделлек һәм тәртип яратучан. 1944 елның язында хатын-кызларының хәлсезләнгән сарыкларны һәм бәрәннәрне, каз ояларына салып, күтәреп яки бәләкәй арба белән болынга, яшел чирәм чемченергә алып барган чакларын күргән идем. Яңарак кына госпитальдән кайткан, бер аягын төбенә хәтле өздергән, култык таякларына таянып йөрүче, колхоз рәисе булып эшли башлаган Һади Рахманов шул солдаткаларны һәм яшь кызларны: «Үскәннәрем, апалар-сеңелләрем, малкайларны, зинһар, саклагыз инде!» — дигән ялварулы сүзләр белән озатып кала. «Зәй» исемен йөртүче бу колхоз уннарча еллар дәвамында районда гына түгел, республика күләмендә дә яхшылар исәбендә булды. Ринат әнә шул фидакарьләр нәселеннән икән. Туган авылында сигезенче сыйныфны тәмамлагач, Иске Әлмәттәге 1 нче татар урта мәктәбенең интернатында яшәп, аны көмеш медаль белән тәмамлый. Шуннан Казан медицина институтына юл тота.

— Безнең авылда, фельдшер булып, күп еллар Шәрифҗан агай эшләде. Халык аны бик ярата, олылый иде. Мин, җае чыкканда, аның эшен, кешеләр белән ягымлы мөгамәләсен, авыруны терелтү өчен янып-көеп йөрүен, балаларча самимилек белән, сокланып күзәтә идем. Врач булу хыялын миндә, мөгаен, шул тәэсирләр уяткандыр,— дип сөйли хирург.

Бу урында укучының игътибарын бер нәрсәгә юнәлтәсем килә. Татар милләтеннән булган кайбер ата-аналар: «Татарча укыса, институтка керә алмас»,— дигән сылтау белән балаларын этә-төртә булса да рус мәктәбенә бирергә тырышалар. Беренче сыйныфка барганда бер кәлимә урысча сүз белмәүче бу балалар, әлбәттә, фәннәрне тиешенчә үзләштерә алмыйлар. Һәм тормышта ни татар, ни урыс булып калалар. Ринат Харисовичны бу яктан да үрнәк итеп күрсәтәсем килә. Урта мәктәпне татар телендә тәмамлау аңа институтка керергә дә, аспирантурада укырга да, фәннәр кандидаты булырга да комачауламаган бит!

Ринат Харисовичның институт тәмамлавына да чирек гасыр вакыт узган инде. Мөгаен, эше гел шома гына бармагандыр.

— Әлбәттә, кешегә сәламәтләнергә, авырудан котылырга ярдәм итеп булганда аның үзеннән дә болайрак куанасың. Уңышлы узган һәр операция көч өсти, канатландырып җибәрә. Үкенечкә каршы, кеше еш кына врачка соңарып килә,— дип сөйли ул.— Мондый очракларда медицина да көчсез. Бу бигрәк тә теге яки бу органы яман шешкә дучар кешеләргә хас. Бу мәкерле чирнең исеме дә «яман» дип атала. Ул астыртын гына үсә һәм тамыр җәя. Әлбәттә, врач, атап әйткәндә, хирург ярдәм итәргә бар белгәне белән тырыша. Уңышка да ирешә, ә кайбер операциянең ахыры барыбер, иртәме-соңмы, үлем белән тәмамлана. Узган ел мин бик үкенечле вакыйгага кичердем: әтием вафат булды.— Бу сүзләрне Ринат әфәнде ифрат борчылып сөйләде.— Үнәче яман шеш белән зарарланган булып чыкты. Ярдәм итә алмадым. Яман шеш мәкерле, агулы тамырларын җәеп өлгергән иде инде. Бу өлкәдә медицинада хәл ителмәгән проблемалар күп әле. Көчсезлекне тою — авыручы, аның туганнары алдында врачны гаепле кеше хәленә куя. Мондый фаҗигаләр, әлбәттә, бәгырьне ашый, күпмедер дәрәҗәдә хирургның үз гомерен дә суыра... Ярый әле тормышта шатлык хисе бар. Ул бер мәлгә кайгыны баса, сүрелдерә.

Ә хирург профессиясен сайлавы болай килеп чыга. Гомеренең чәчәк аткан чагында, кырык ике яшендә, катлаулы да саналмаган операция нәтиҗәсендә әнисе вафат була. Әнисенең вакытсыз һәм фаҗигале үлеме аны нык уйландыра һәм тетрәндерә. Шул чакта яшь студент Ринат әнисенең каберс каршында, үзенең намусы алдында миһербансыз үлемгә каршы, кеше тормышы өчен үзен аямыйча көрәшергә ант эчә һәм ул, бүгенгәчә, шул антына тугрылык саклый.

# «МИЛЛӘТЧЕЛӘР» ЭШЕ

(Һ. АТЛАСЫЙ ТУРЫНДА АРХИВЛАР НИ СӨЙЛИ?)

Революциягә кадәр үк яшәгән күренекле татар зыялыларының бер өлешен юк итү буенча жирле большевистик житәкчелек һәм ГПУ провокаторлары тарафыннан уйланылган жинаятьчел акция әле 19—20 елларда ук башланган булса кирәк. Һәрберсе кирпеч калынлыгы 20 томга «Атласовның контрреволюцион, милләтчел, фетнәчел шпионнар оешмасы эше»нә кагылышлы «дәлилләр» — әләкләр, сорау алу беркетмәләре һәм башка төрле тикшерү кәгазьләре тупланган.

Башта, кагыйдәләрдә каралганча, гаепленең аерым билгеләре: Атласов Һади Мифтахетдин улы, 1876 елда туган. Сембер губернасы Буа өязе Иске Чокыр авылыннан. Буе озын, гәүдәсе юан, йөзе түгәрәк, борыны зур, күзләре коңгырт, авызы зур, башындагы чәчләре кара, машинка белән алган, мыеклары чаларган, сакалына да шулай ук чал йөгергән, мыегы гадәти, акрын йөри һәм шулай ук акрын сөйләшә дә. (Мәгълүматлар 1922 елда, үлеменә 15 ел кала алынган.) Шунда ук бик тәфсилләп язылган биография. Советлар Россиясеннән киткән танышларының исемнәре астына сызылган. Шулай итеп, Атласов авыл мәктәбен һәм Буа мәдрәсәсен тәмамлый, Әлмәттә укытучы булып эшли (1903—1906), алман теле һәм әдәбияты (Гете һәм Шиллер), Дарвин тәгълиматы, сәясәт һәм революцион үзгәртеп корулар белән кызыксына. Авыл мулласы өчен кызыксыну даирәсе шактый киң. 1905 елда «Азат» һәм «Азат халык» газеталары белән хезмәттәшлек итә башлый, эсерларга теләктәшлек күрсәтә, Казанга барып йөргәндә Ф. Туктаров, Г. Исхакый, Х. Ямашев белән таныша. 1906 елда Атласов — Түбән Новгородта узган Бөтенроссия мөселманнары съезды делегаты, 1907 елның февралендә Самара губернасыннан икенче Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана.

Тәмам аптырашта калган кешенең Сталинга язган хатыннан. Атласов, 1935 елның 22 мае: «Мин, төрки-татар дөньясының карт җәмәгать һәм фән эшлеклесе, революционер, шушы өлкәдә узган гасырның соңгы елларыннан бирле эшлим... Мин — беренчеләрдән булып урыс самодержавиесенә һәм мөселман руханиларына каршы сугыш ачканнарның, беренче булып татар мәктәпләрендә география, табигать белеме, физика һәм астрономия кебек фәннәр укыта башлаучыларның, аз санлы татар революционерларының берсе.

Җәмәгать эшләрендә шактый дәрәҗәле урыннар биләдем. Икенче Дәүләт Думасы әгъзасы булдым һәм анда эсерлар фракциясендә тордым. Бу партиядә 1905 елдан 1918 елга кадәр тордым. Алардан китүемнең сәбәпләре — Брест килешүе һәм сугыш мәсьәләләре буенча социаль революционерлар белән карашларыбызның туры килмәве.

1906 елда язган брошюрам һәм революцион эшчәнлегем өчен 1909 елда мине крепостька ябарга хөкем иттеләр һәм шул ук елны эшемнән кудылар. 1908 елдан 1917 елга кадәр полиция күзәтүе астында яшәдем һәм хокукларымнан мәхрүм ителгән идем».

Үлем карарын игълан итүгә дүрт тәүлек кала, 1937 елның 24 октябрендә иртәнге сәгать тугызда Атласовның судта сөйләгән соңгы сүзләре: «Мин — карт җәмәгать эшлеклесе. Тарихчы, педагог. Революциягә кадәр үк пантөркизм хәрәкәте белән таныша башладым. Чит илләрдән газеталар алдырдым. Шушы газеталар аша пантөркистлар хәрәкәте белән таныштым. 1900 елларда Европа һәм урыс әдәбиятлары белән таныша башладым. Сәясәттән шактый мәгълүматлы идем... 1905 ел ахырларыннан социалистик әсәрләр белән кызыксындым. Мин зур ачыш ясадым һәм, барлык урысларны да мөселманнарның дошманнары дип

санарга ярамый, дигән карарга килдем. Мин изелгән сыйныфларның һәм милләтләрнең мәнфәгатьләрен яклаучы кешеләр бар дигән фараз ясадым. Акрынлап Маркс-Энгельс әсәрләре белән таныша башладым һәм үземдә зур үзгәрешләр барлыкка килүен тойдым. Мин — мулла малае, ләкин ятим үстем. Бала чакта крестьян эшен башкардым. 15 яшемнән социал-революционерларга теләктәш булдым. 1905 елга кадәр Ленинның әсәрләре белән таныш түгел идем. 1901 елдан үз әсәрләремне яза башладым. 1902 елда «Иҗтимагый тарих» дигән беренче китабымны бастырдым. Аннары тарих белән шөгыльләнә башладым. 1907 елда Дәүләт думасы әгъзасы итеп сайландым. Социалист-революционерларга кушылдым. Думада ике мөселман фракциясе бар иде, без, алты кеше, алардан аерылып чыктык һәм социалистлар белән бергә эшләдек... Самодержавие заманнарында китап яздым һәм шуның өчен 1909 елда җаваплылыкка тартылып хөкем ителдем. Брошюрамны яндырдылар.

Пантөркист булуымнан баш тартмыйм. Мин социалист идем, чөнки Энгельс, үз территориясе, үз мәдәнияте булмаган милләт социализм төзи алмый, ди. Без башка милләтләр өстеннән хакимлек итә торган дәүләт төзергә тиешбез, дип мин беркайчан да әйтмәдем. Яшермим, бөекдержавачылык шовинизмына каршы көрәштем. Тарихчы буларак, кавемнәрнең зәгыйфьләнүе һәм бетүе мәсьәләсе белән шөгыльләндем. Мин татар милләте акрынлап үлә бара дип исәплим... Аның һәлакәте совет власте чорында да дәвам итте. 1921 елда дүрт меңгә якын татар ачтан үлде... Хөкем ителүчеләр урындыгында татарларның утыруына горурланам... Мине монда нык рәнҗеттеләр, бигрәк тә татар коммунистлары. Хокукларымнан мәхрүм иттеләр. Мин — тарихчы. Совет власте килгәч, мәктәпләрдә тарих укытылмады... Дин кирәк дип исәплим, динне кискен рәвештә бетерү милләтнең үлеменә алып бара. Мин элеккеге кеше инде: элеккеге педагог, элеккеге эсер, элеккеге Дәүләт думасы әгъзасы, элеккеге тарихчы... Мин революционер, милләтче һәм пантөркист. Мин бердәм һәм бәйсез төрки-татар дәүләте төзү максаты куйдым, ләкин моңа эволюция юлы белән барырга теләдем. Мин — баш күтәрүчеләрнең дошманы. Шпионлык белән шөгыльләнмәдем һәм бу җәһәттән үземне саф дип исәплим... Мин үземне Совет властеның принципиаль дошманы түгел дип белдерәм, чөнки милләтләрне һәм бөтен пролетариатны азат итү өчен көрәшкән хакимияткә каршы кул күтәрү — җинаять дип саныйм... Контрреволюцион эшчәнлек алып бармадым».

Авторның шәрехләүләреннән башка, монда китерелгән документаль өзекләрдә кешелек дәрәҗәсен саклап гомеренең соңгы чигенә килеп җиткән һәм бөгелмәгән, гаепсезгә җәза алып та шәхес булып калган көчле кеше образын китереп бастырдылар...

1937 елның 23—28 октябрендә бригада хәрби юристы Микляев рәислегендә, әгъзалар: беренче дәрәҗәле хәрби юрист Тулин, хәрби юрист Кутушев, хәрби юрист Княжеский секретарьлыгында Идел буе хәрби округының күчмә сессиясе Казанда, ябык суд утырышында, Атласовның һәм аның эше буенча гаепкә тартылучы 24 кешенең эшен карый. Татарларны, башлыча укытучыларны, хөкем итәләр. Тәрҗемәче сыйфатында ВКП(б)ның Бауман райкомы секретаре Оланбәков чакырыла.

Тикшерүче, дәүләт иминлеге комитеты лейтенанты Мозаффаров тарафыннан төзелгән һәм республиканың эчке эшләр халык комиссары урынбасары майор Ельшин раслаган гаепләү нигезендә түбәндәгеләр теркәлә: «1937 елга кадәр Татарстан АССР территориясендә, чит ил (разведкалары) вәкилләре тапшыруы буенча, күп еллар дәвамында контрреволюцион эш белән шөгыльләнүче киң колачлы милләтчел, фетнәчел, разведка алып бара торган оешма яшәде һәм СССРда буржуаз-демократик рухтагы бәйсез төрек-татар дәүләте оештыру максатында совет хакимиятен бәреп төшерүне әзерләде. Бу оешманы шушы эш буенча төп гаепләнүче, СССРда мәгълүм татар буржуаз милләтчелеге эшлеклесе, пантөркист, элеккеге уң эсер, элеккеге икенче Дәүләт думасы әгъзасы, элеккеге актвардияче, контрреволюцион эшчәнлеге өчен элек ике тапкыр хөкем ителгән Атласов Һади үзе төзи һәм аңа җитәкчелек итә». Эш мөһим дип табылган шаһитлар катнашында, ләкин гаепләүчеләр һәм яклаучыларсыз тыңлана. Шаһитлар 16 була. Тикшерүчеләр тарафыннан алдан ук әзерләнеп һәм куркытып куелганлыктан, алар барысы да хөкемгә тартылучыларны пычракка салып бутыйлар һәм фаш итәләр. Ләкин әкәмәт хәлләр дә килеп чыккалый. Хөкемгә тартылган укытучы Фазыл Туйкин үзенең соңгы сүзендә: «Атласов йөзендә бәйсез татар дәүләтенең булачак җитәкчесен күрдем», — дип әйтә. Һәм шунда ук: «Атласовның фикере буенча, бу дәүләттә, татар мәктәпләреннән соң төрле югары уку йортларына керә алмаганга, татар балалары урыс мәктәпләрендә дә

белем алачаклар!»,— дип өсти. Суд рәисе гаҗәпләнеп кала: татар балаларын урыс мәктәпләрендә укытырга тәкъдим итә икән, Атласов нинди милләтче булсын?

Тикшерү Атласов эшмасында Уфа, Ульяновск, Казан, Мәскәү, Магнитогорск кебек шәһәрләрдә яшәүче кешеләр дә катнашкан дип раслый, ягъни эшне гомумсоюз күләмендә әһәмияткә ия процесс итеп күрсәтергә маташа. Имеш, Атласов төрки-татар дәүләтен Татарстан, Башкортстан, Үзбәкстан, Казагыстан һәм Төрекмәнстан территорияләреннән һәм аларда яшәүче халыклардан төземәкче булган. Атласовны чит илләр белән «шпионлык» элемтәләрендә дә гаепләүләр, Мәскәүдәге төрек илчелеге, чит илләрдә яшәүче мөселманнар һәм Гаяз Исхакый белән бәйләнеш тотасың, дип бәйләнәләр.

Тикшерүчеләр канәгать кала, бүләк көтәләр. Уен эшмени, алар шундый колачлы «процесс» уздырдылар, Союз күләменә «чыктылар» бит. Алар башлыкларга «операциянең» уңышлы тәмамлануын хәбәр итәләр. Тәмам бетерелгән, акылдан шашу чигенә килеп җиткән кешеләрнең кулларыннан тотып куйдырган имзаларына тикшерүчеләр үзләре һәм аларның НКВДдагы җитәкчеләре ышанганнармы-юкмы, әйтүе кыен. Кулга алынганнардан «кирәкле» материалларны нинди юллар белән булса да суырып алырга боерган күрсәтмәләр акылдан язган маньякның котырынуын хәтерләтә һәм моның цивилизацияле юриспруденциягә бөтенләй катнашы юк. Ләкин болар бар да булды. Ул чакта моңа гаҗәпләнмиләр, әмерләрне генә үтәргә тырышалар иде. Һәм әле ничек кенә...

1936 елның 4 декабрендә ТАССР буенча НКВД идарәсе башлыгы, өченче дәрәҗәдәге дәүләт иминлеге комиссары Рудь махсус бүлек башлыгы урынбасары Мозаффаровтан Атласовның «СССРдан аерылып чыгу турында татар халкы арасында эш алып бару өчен төрек илчелеге тарафыннан яллануын», «аның бу эшне оешма әгъзалары (һәрберсенең исемен атарга) белән соңгы вакытларга кадәр алып баруын» тануына (теләсә нинди юллар белән, кызганып тормыйча) ирешергә әмер бирә. Ул аннардан Шәфиевнең һәм Исхакыйның Татарстандагы агентларын әйттерүне таләп итә: «Атласов үзе белән эшләгән кешеләрнең барысын да атасын, җаваплы хезмәткәрләргә һәм зыялыларга аерым игътибар бирегез»,— ди.

1936 елның 27 декабрендә Рудь Казанда күренекле татар тарихчысы һәм язучысы Г. М. Атласовның кулга алынуы турында ашыгыч рәвештә халык комиссары Ежовка, аның урынбасары Агроновка һәм бүлек башлыгы Мироновка рапорт бирә. Ул, Атласов «контрреволюцион эшен Япониядәге һәм Германиядәге ак эмигрантлар үзәкләренең, Гаяз Исхакыйның турыдан-туры тапшыруы буенча уздырганга», үзенең бу эшкә зур әһәмият бирүен хәбәр итә. Рудьның фикеренчә: «Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» проекты белән Атласов планнарының тулысынча тәңгәл килүләре», Атласовның 1923 һәм 1926 елларда Мәскәүдә төрек илчесе һәм илчелек хезмәткәрләре белән очрашуларын «тануы», шулай ук «Гаяз Исхакыйның ярдәмчеләреннән берсе Шәфиев Габдрахман белән таныш булуы» аның гаебен дәлилләр өчен җитеп ашкан. Һәм шул ук Рудь, Солтангалиев өстеннән булган суд процессына таянып, сүзләрен куәтләр өчен, тапталып беткән җөмләләр белән: «Солтангалиев кулга алынгач, бөтен контрреволюцион эшкә Атласов җитәкчелек итте, милләтче һәм фетнәче кадрлар әзерләде»,— дип өсти.

Бармактан суырылган процессларны әзерләүдә Рудьтан тәҗрибәлерәк булган Миронов 1937 елның 17 гыйнварында Мәскәүдән Казанга җавап бирә: «Сезнең, Һ. Атласов татар эмиграциясе белән бәйләнгән контрреволюцион милләтчелек рухындагы подполье эшендә катнашкан, дигән нәтиҗәләрегез дөрес. Ләкин Атласовның гаебе соң дәрәҗәдә йомшак дәлилләнгән».

«Контрреволюцион эш алып баруда һәм ак эмигрант даирәләре белән элемтә тотуда» гаепләп, Атласовны 1936 елның 27 июлендә кулга алалар. Ул Казанның Эш урамында 32 йортта яшәп торган була. Тентү вакытында паспорт, (гарәп хәрефләре белән) татарча язып тутырылган иске дәфтәр, эшкә урнашырга ярдәм сорап Сталин һәм партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре Альфред Лепа исеменә җибәрелгән гаризаларның икенче нөсхәләре алына.

Мәскәү җәлладлары аның сүзләреннән канәгатьсез калырлык итеп, Атласов сорау алулар вакытында нәрсә сөйли соң?

Беренче сорау алу 29 июль. Махсус вәкаләтләр бирелгән Карпов эндәшә:

— Сез контрреволюцион эшчәнлегегез өчен кулга алындыгыз. Үзегезнең контрреволюцион эшчәнлегегез, фикердәшләрегез турында хәбәр итәргә тәкъдим итәбез.

— Мин бернинди контрреволюцион эшчәнлек белән шөгыльләнмәдем һәм андый эшләр белән шөгыльләнүчеләрне белмим.

Атласов үзенең хатыны, «Каменка» шифаханәсе директоры Җиһанша Дунаевка кияүгә чыккан кызы Сәлимә һәм Мәскәү химия-технология институтында укучы улы Габделбәр турында хәбәр итә.

1 августта сорау алу вакытында Атласов, боларның тикшерүчегә нигә кирәк булганлыгын белмичә, йөздән артык танышларының исемнәрен атый. Алар турында сакланып сөйли. Ильяс Алкин, профессор, Мәскәүдә яши, соңгы тапкыр 1923 елда күргән; профессор Фатыйх Мөхәммәдьяров белән 1929 елга чаклы очрашканнар, аннары аның хатыны өйгә кертми башлаган; укытучы Габдрахман Дәүләтшин — «шәхси дошман», Борһан Шәрәф турында — «бер генә начар сүз дә әйтә алмыйм, күптән күргәнем һәм сөйләшкәнем юк». Башкалар турында да шундый ук саран сүзләр. Ләкин болар да күпләрне саклап кала алмый. Атласов оешмасы әгъзалары дип гаепләнеп, бу исемлектәге кешеләрнең барысы да диярлек кулга алына. Алар арасында — татар мәктәпләре укытучылары, элеккеге муллалар. Атласовның Бөгелмәдәге, Әлмәттәге, Казандагы, Уфадагы һәм Мәскәүдәге танышлары. Исемлектә шулай ук беренче дөнья сугышы вакытында Германиядә яки Төркиядә әсирлектә булган татар солдатлары һәм офицерлары шактый. Аларга «шпион» мөһере сугыла.

16 августта Атласов: «Солтангалиев оешмасы турында белмәдем, ләкин бу оешмада әгъза булып торулары ачылган кешеләр белән таныш булганга, үземне шулай ук бу оешмада катнашучы дип хис иттем», — дип күрсәтә.

Бу беренче тану була. Ләкин тикшерүчегә болар гына җитми, чөнки ул чакта бөтен ил буйлап шпионнар эзлиләр. Бу очракта да Атласовны һәм аның эше буенча кулга алынганнарны япон, алман яки төрек разведкалары белән «тышаулап» куярга кирәк була.

19 август. Тикшерүченең сәяси карашлар турында соравына Атласов турысын әйтә:

— Мин Совет власте яклы, ләкин 1933 елга кадәр, ягъни сөргеннән азат ителгәнче, Совет властеның аерым чараларына каршы идем. 1929 елга чаклы күмәкләштерү сәясәте белән килешмәдем һәм бу мәсьәләдә Фрушкин, Бухарин карашларын уртаклаштым. 1930 елда, ун елга хөкем ителгәч, минем Совет властена карата канәгатьсезлегем артты, чөнки мондый авыр җәза һич тә гадел түгел дип исәпләдем. Мин башка совет республикалары белән бертигез хокукта ССР Союзына керә торган берләшкән мөстәкыйль төрки дәүләт төзү тарафдары идем. Төрки халыкларны берләштерү зарурлыгы турында фикер әле 1910—1913 елларда ук туган иде. Мин кайбер төрки милләтләренең һәм Себер халыкларының (башкортлар, татарлар, кыргызлар, нугайлар) югала баруы патша вакытында ничек булса, совет власте елларында да шул хәлендә дәвам итә дип исәпләдем. Мин бу фикергә 1896 һәм 1926 елларда халык санын алу буенча статистик мәгълүматларны чагыштырып карау нәтиҗәсендә килдем».

Тикшерүчене Атласовның ианулары аз кызыксындыра, аңа «советка каршы, шпионлык белән шөгыльләнүче, фетнәчел милләтчеләр оешмасы» кирәк. Шуңа күрә ул бертуктамый Атласовтан кемнәр белән очрашуы, нәрсә хакында сөйләшүләре, ничек «ялламы» турында сораша.

26 октябрь. Атласов: «Әйе, хәзер чит илләрдә яшәүче күпләрне элек белә идем. Садрый Максуди — зур белемле элеккеге кадет, ләкин революционер түгел; Зәки Вәлиди — тарих фәннәре өлкәсендә тирән белемле галим, сәяси мәсьәләләрдә тотрыклы, 1920 елдан бирле күргәнем юк; Гаяз Исхакый — күренекле һәм талантлы татар язучысы, элеккеге революционер, ләкин сәяси мәсьәләләрдә аумакай, 1917 елдан бирле күргәнем юк; Барый Батталны соңгы тапкыр 1920 елда күрдем».

Һәм шунда ук: «Галимҗан Шәрәф белән очрашканыгыз булдымы?» — дигән сорау.

— Әйе, 1934 елда Казанда очраштык. Мин аның фатирында булдым һәм бу бердәнбер очрашу иде.

— Шәрәф янына нинди максат белән бардыгыз?

— Эшкә урнашу мөмкинлеге юкмы икәнен белер өчен.

— Тагын нәрсәләр турында сөйләштегез?

— Шәрәф миңа Казаннан Ленинградка яисә Мәскәүгә күчеп китәргә киңәш бирде, анда тизрәк урнашырсың, диде.

Һәм яңадан Татарстан эчке эшләр халык комиссариатының махсус бүлеге тикшерүчесе Мозаффаров үзенең мәкерле җәтмәсен үрә башлый. Сүз уңаенда бу бәндәнең Атласовны иң нык җәберләгән кеше булуын да әйтеп үтү урынлыдыр.

Ул үзенә кирәкле тануларны каерып алу өчен тоткынга онытылып китәргә һәм сүз белән мавыгырга ирек бирә дә аннары янә тинтерәтергә керешә.

23 ноябрь. Атласов Мәскәүдәге төрек илчелегендә булуын һәм аңа гаиләсе белән Төркиягә күчеп китәргә ярдәм итүләрен соравын таный. «Нинди максат белән?» — дип сорый тикшерүче?

— Мин — тарихчы, — ди Атласов. — Ләкин тарихны сыйнфый карашлардан чыгып укыту яклы кеше түгел. Мин аны гомумкешелек һәм милли ясСылыкта аңлыйм. Шуңа күрә үземне совет шартларында артык кеше итеп тоям. Совет власте фән буларак тарихка тиешле игътибар бирмәде һәм мин тарихчы сыйфатында яшәп килә торган стройның төп программ кануннары белән килешеп бетә алмадым. Мин, Төркиягә күчеп киткән очракта, Зәки Вәлиди кебек фәкать тарихчы гына булып эшләрмен һәм шул өлкәдә фәнгә өлеш кертермен, дип уйладым. Төркиягә мин ачыктан-ачык күчәрмен дип планлаштырдым.

Атласов сүзен дәвам итә:

— Совет шартларында, тарихчы буларак, кирәгем калмаганга, озак еллар мәктәптә табигать белеме һәм география укыттым. Сезнең карашка, бәлки, «контрреволюцион фикерләр» үткәрү белән шөгыльләнгәнмендер. Мәсәлән, Дарвинның, кешеләргә буйсыну тойгысы булган хайваннар, ахыр чиктә, үлемгә дучар ителә, дигән законын аңлатканда, укучыларымны Бөекроссиягә карата шундый ук мөнәсәбәттә торучы төрки-татарлар да һәлак булачак, дип расладым.

Һәм шунда ук:

— Социалист булып китсәм дә, пантөркизм идеяләре, карашлары миндә суынмады, киресенчә, алар көчәйделәр генә. Мин пантөркизм социализм идеяләренә каршы килми, дип уйладым.

1937 елның 23 гыйнварында Атласовтан: «Мин контрреволюцион милләтчел оешманы төзедем һәм аның җитәкчесе идем», — дигән сүзләрне әйттерүгә ирешәләр. Мондый оешманың беркайчан да булмавын бик яхшы белсә дә, ул барысын да үз өстенә ала. Ләкин әле бу да җитәрлек булмый. Мәскәүдән Миронов Рудька: «Игътибарны Атласовның чит илләрдәге элемтәләренә юнәлтергә», — дип әмер бирә. Гимнастеркаларының күкрәк кесәләрендә партия билеты йөрткән җәлладлар, Сталин Конституциясе (1936 ел) нигезендә илдә социализм башлыча төзелеп беткән һәм шуңа күрә кешеләр берничек тә канәгатьсезлек белдерә алмыйлар, дип фикер йөртәләр. Эчке канәгатьсезлекне аңлату «хәвефле»! Ә менә кимчелекләрне чит илләрнең махсус разведка оешмалары хезмәтләренә сылтарга мөмкин һәм шулай кирәк тә. Ул чакта барысы да аңлашыла: дошманнар яши, алар иске зыялыларны үз якларына тарталар, милләтчеләрдән, гражданнар сугышында «үтереп бетерелмәгән» бәндәләрдән советка каршы эшли торган оешмалар төзиләр. Халык моны аңламый калмас. Дошман коралын ташламаган, бирелмәгән икән, аны юк итәргә кирәк.

Атласов үзенең шпионнар белән элемтәдә торуын кискен рәвештә кире кага. Шуннан соң җәзалау конвейерына кызының ирен, хатынының энесен һәм башка якын кешеләрен алалар. Тикшерүчеләр кушкан гаепләү кәгазьләренә кул куйганчы алар кичергән газапларны сөйләп бетереп кенә буламы икән? Алар Атласовның «буржуаз милләтче», «контрреволюцион оешма» җитәкчесе булуын таныйлар, хәер, моны ул үзе дә «таныган» була инде. Ләкин шаһитләрнең берсе дә аның «чит илләр белән элемтәләрен» расламый.

1937 елның февралендә Рудь Мироновка Атласовтан «контрреволюцион оешмасының разведка эшчәнлеге белән шөгыльләнүен танытачагы» турында хәбәр итә. Бер үк вакытта ул ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре А. К. Лепага да: «Безнең тарафтан буржуаз-демократик рухтагы бәйсез төрки-татар дәүләте төзергә әзерлек алып бару буенча күп еллар дәвамында Татарстанда контрреволюцион эш белән мәшгуль булган контрреволюцион-милләтчел оешма ачылды һәм хәзерге вакытта оператив төстә юк ителә. Оешманы күренекле буржуаз тарихчы Һ. Атласов җитәкли... Бүгенге көнгә бу оешмада торучы 50 гә якын кеше мәгълүм булды, шуларның әлегә 20 се генә кулга алынды», — дип яза.

1937 елның 4 апрелендә бөтен нәрсәдән өметен өзгән Атласов чираттагы сорау алу вакытында үзенең алман һәм япон шпионы булуы хакында белдерә. Ә тагын бер айдан соң сорау алуда катнашкан Рудька: «Мин һәрвакыт инанган милләтче һәм пантөркист идем һәм төрки-татар халыклары әүвәлгечә сәяси яктан хокуксыз, икътисади һәм мәдәни планда артта калган кавемнәр дип уйладым. Шуңа күрә аларның үлемгә һәм бетүгә йөз тотуы котылгысыз, дип исәпләдем. Халыкны фәкать буржуаз-демократик стройга нигезләнгән бәйсез һәм мөстәкыйль төрки-татар дәүләте генә бу афәттән коткарып кала ала», — ди. Атласов үзенең карашларын совет властеның халык өчен зарури булган мәдрәсәләрне һәм мәчетләрне җимертүе, төрки-татарларның авыр икътисади шартларда яшәве, аларның эреп югалып бетәргә дучар ителүе мисалларында расларга

омтыла. Рудь өчен болар бар да «контрреволюцион эшчәнлек алып баруны» тануга бәрабәр була. Июньдә Атласов тикшерүчегә үзенең Соловкида Солтангалиев белән бергә утыруы һәм тегесенең үзен «гадел булмаган яла ягуда битәрләве» хакында әйтә. Тагын күпмедер вакыт уза. «Барлык гөнаһларын таныган» Атласовны күпмегәдер тынычта калдыралар. Ул, бераз аңга килгәч, элеккеге сүзләреннән баш тарта.

Лейтенант Мозаффаровның: «Шәхсән сез үзегез төрки-татар ак эмиграциясе житәкчесе Гаяз Исхакый белән элемтә тоттыгызмы?» — дигән соравына: «Мин Исхаков Гаязны белмим»,— дип җавап бирә. «Ул чит илгә киткәнче мин аның белән шәхсән таныш идем, ә аннары безнең арада бернинди бәйләныш та булмады. Ишетүемчә, Исхакый Варшава университетында төрек теле укыткан, «Милли юл» дигән журнал чыгарган һәм аңа гаҗәпләнәсе юк, ул — Пилсудскийның күптәнге әшнәсе»,— дип өсти.

— Герман разведкасы агентлары белән бәйле идегезме?

— Юк, чит дәүләтләрнең агентлары белән элемтә тотмадым.

Соңгы елларда күп миллионлаган кешеләрнең исеме тупланган бердәм реабилитацияләү исемлекләре төзелә. Аларда Атласов кебекләр дә, Рудь һәм Лепа төсле бәндәләр дә бар. Чөнки ул чакта алар, корбаннарын һәлак иткәч, үзләре дә озак яшәмиләр. Мондый исемлек, кемнең кем булуына карамастан, кешеләр арасында татулык урнаштыру, узганнарны кабат күтәреп үзара дошманлык килеп чыкмасын өчен төзелә. Ләкин хәтер исән, коточкыч газаплар күргән кешеләр исән. Бу вәхшилекләр аларның төшләренә керә. Иисус Христос кешелек дөньясы өчен михнәт чигә, ә алар? Һәм бер үк исемлеккә корбаннар белән бергә җәллад-корбаннар да кертелгәндә, аларга карата әхлакый мөнәсәбәт тә үзгә булырга тиеш. Һәлак булган чекистларны, прокурорларны, партия функционерларын кызганырга мөмкин. Ләкин алар, үзләре якты дөньядан киткәнче, кешеләргә каршы явызлык кылуда шәхсән катнашканнар. Ә Атласов кебекләр катнашмаганнар. Алар — иң элек намуслы кешеләр иде. Атласов тарих укытырга һәм һәр көнне укучыларына ялган сөйләргә теләми. Ул табигать белеменнән, географиядән һәм алман теленнән дәресләр бирүне артык күрә, халкының аянычлы язмышы өчен янып-көеп яши. Билгеле, түрәләр арасында да оятлы һәм намуслы кешеләр булган, әйтүләренә караганда, алар «вәхшилекләрне» идеаллары хакына эшләгәннәр, ә кайберләре атудан да баш тартканнар. Ләкин, ничек кенә шомартсаң да, бу кешелексез системаны алар төзеде. Аларның һәммәсен дә бер исемлеккә кертергә була, тик шулай да җинаятьләр булмады дигәнгә бер кеше дә ышанмаячак һәм алар өчен җаваплылыктан котылу юк. Атласов һәм Рудь белән бер үк вакытта горурланырга һич тә мөмкин түгел. Бу — гайре табигый нәрсә. Моны — үзләре дә аңламастан кешеләргә явызлык эшләүчеләр өчен кисәтү дип аңларга кирәк. Яманлык куркыныч һәм аны кичереп булмый. Язмышы ничек кенә булып бетмәсен, җәллад, вәхши зат кешеләрдә фәкать җирәнү генә уята.

Беренче карашка Атласовның язмышы совет чынбарлыгында һәлакәткә дучар ителгән күп язмышларның берсе булып күренергә мөмкин. Ләкин бу шулай тоела гына. Һәркемнең тормышы үзенә бер, кабатланмас могҗиза. Әгәр дә ул гомуми акылдан язу шартларында үзенең карашларын һәм кешелек дәрәҗәсен яклап калырга, вакыйгаларны үз йөрәге аша үткәрергә күнеккән талантлы шәхес гомере икән — аны «күпләрнең берсе» дип атарга тел бармый. Дәүләт думасында мөселман депутатлары алай күп булмады, бөтен гомерен башта патша полициясенең, ә аннары совет органнарының ачыктан-ачык һәм яшерен күзәтүе астында уздырган, патша һәм совет төрмәләрендә газап чиккән кешеләрне дә бармак белән генә санарлык. Аның тормышындагы совет чорына бераз киңрәк тукталыйк.

1919 елның августында кайбер татар совет газеталары Атласовны милләтчелектә, колчаклылар белән хезмәттәшлек итүдә, хаинлектә гаепләп чыктылар. Татарстанның Үзәк дәүләт архивында (7779 фонд, өченче тасвирлама, 33 эш) Бөгелмә шәһәре гражданины Һади Мифтахетдин улы Атласовны контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнгән эш саклаган. Бу документлар газеталарга һәр очракта да сукырларча ышанырга ярамавы, анда язылганнарны тәнкыйть күзлегеннән үткәрергә кирәк икәне турында сөйли.

Документлардан күренгәнчә, 1919 елның язында Атласов Бөгелмәдә яши һәм шәһәрне колчаклылар алганда Бөгелмә җирле идарә рәисе урынбасары була. 1919 елның 4 маенда Колчак армиясенең икенче Уфа армия корпусы органы «Уфалы» газетасында Атласов имзасы белән колчаклыларга тәбрикләү басылып чыга. Анда: «Большевиклар тиранлыгыннан азат ителгән урыннарда янадан

эшкә керешеп, өяз һәм власть идарәләре йөзендә ирекле Бөгелмә үзенең Галижанәп Баш командующиен безнең фидакарь сугышчыларыбызның бөек җиңүләре белән котлый, закон һәм хокук нигезендә барлык намуслы гражданнарның тырыш хезмәте халыкның аяк астына салып тапталган һәм җимерелгән тормышын торгызырга һәм бөек Ватаныбызга үзенең элеккеге куәтен һәм даның кайтарырга мөмкинлек бирер дип ышанып кала»,— дип язылган була.

Котлауда милләтчелек рухының тәсмере дә булмавын һәм аның совет учреждениесе исеменнән җибәрелмәвен искәртеп китик. Атласовны 1920 елның сентябрендә Бакуда кулга алалар. Ул монда үзен эзәрлекләүләрдән куркып күчеп килгән була. Азәрбайҗан ЧКсында сорау алганда ул Бөгелмәдәге хәлне болайрак аңлата: аны колчак контрразведкасына чакырып алалар һәм җирле идарә оештырырга тәкъдим итәләр. Ул баш тарта. Ләкин хәрби комендант аның фамилиясе белән әмер бастыра һәм Атласовның имзасы куелган котлау оештыра. Әмма бу ике документка да аның бернинди катнашы булмый. Бөгелмәне калдырганда колчаклылар аңа үзләре белән китәргә тәкъдим итәләр. Ул алар белән Чиләбегә кадәр барып җитә, ә аннары Бакуга юл тота. Монда җирле нәшриятка тәрҗемәче булып урнаша.

Архив эшендә Азәрбайҗанның җәмәгать эшлеклесе И. Яһудинның Азәрбайҗан ревкомы рәисенә язган хаты саклана: «Һади Атласовны җәмәгать эшлеклесе, тарихчы һәм әдәбият галиме буларак беләм. Ул — Идел буе мөселманнарының күренекле вәкиле, икенче Дәүләт думасы әгъзасы, беренче булып мөселман хезмәт фракциясен оештырган кеше. Бакуның хәрби-диңгез чекасы, гаепләрен күрсәтмичә, аны кулга алды һәм 3 ай дәвамында сак астында тота. Алда бәян ителгәннәргә нигезләнеп, эшне карауны тизләтүегезне һәм суд булганчы аны берәрсенең җаваплылыгына төрмәдән азат итүне үтенәм». Хатка Н. Нариманов кулы белән: «Эшне тизләтергә»,— диелгән. Атласовны алырга Бөгелмә милиционеры Марк Германюк килә һәм алар Татарстанга кайтып китәләр.

Гаделлек тантана итсен дигән булып, күз буяп, Атласовны 1921 елда Чистайда хөкем итәләр. Районның революцион трибуналына газетада басылып чыккан теге ялган котлауны тапшыралар, Атласовның советка каршы эшчәнлеге шаһитлары сыйфатында укытучылар Закир Исхаков, Сәлих Рахманкулов, Сабир Шәңгәрәевне чакыралар. Атласов белән күзгә-күз очраштыргач, алар аңа каршы шаһитлыктан баш тарталар. Тикшерүче гаепләү актын: «Аның йөзендә хезмәт халкы белән кулга-кул тотышып баручы, әдәбият өлкәсендә зур мәгълүматка ия булуы белән аерылып торучы, мөселман дөньясында абруйлы карт революционерны күреп, партияле иптәшләр Атласовны фәкать яхшы яктан гына искә алалар»,— дигән сүзләр белән йомгаклап куя. Ул Атласовның эшен ябарга, ә Бөгелмәдә «Атласовка карата кузгатылган гаепләү эшендә икейөзлелек күрсәткән өчен» Исхаковны, Шәңгәрәевне һәм Рахманкуловны җаваплылыкка тарту буенча трибуналның күчмә сессиясен уздырырга тәкъдим итә. Чистай ревкомы карары нигезендә гаепсез табылып, Атласов 1921 елның 22 апрелендә азат ителә.

Үзенең тормышындагы бу вакыйганы искә төшереп, Атласов Сталинга җибәргән хатында (1935): «Үзем белән яхшырак таныштыру өчен тормышымдагы бер вакыйганы бәян итмәкче булам. 1920 елда, Сез Дагстанга килгән вакытта... юрист Госман Токымбәтов, Сезнең белән очрашканда, минем Бакуда кулга алынуым хакында хәбәр итә, минем Шәрык дөньясында тоткан урынымны күрсәтә, мине азат итүне сорый һәм Сез ризалык бирәсез. 1920 елда мине Бакудан илемә җибәргәндә (Бөгелмә шәһәренә) Н. Нариманов белән Г. Токымбәтов Сезгә минем турыда телеграмма һәм хат юллыйлар... 1921 елның апрелендә Бөгелмәдә (дөресрәге, Чистайда — авт.) мине хөкем иттеләр, ләкин кайбер партия әгъзаларының, бигрәк тә Сезнең, миңа карата булган уңай фикерләрегез аркасында, мине җәзадан азат иттеләр»,— дип яза. Бу соңрак булачак, ә 1921 елда, төрмәдән чыгарылгач, Атласов Зәй-Каратай авылында, Бөгелмәдә, Әлмәттә укытучылык белән шөгыльләнә. Ул табигать белеменнән һәм тарихтан, алмап һәм татар телләреннән, географиядән дәресләр бирә. Атласов һәр укучының системалы белем алуына омтыла, үз халкын мәгърифәтле итүне төп бурычы саный. Бу чорда ул Себер татарлары, Казан ханлыгы тарихы буенча әле революциягә кадәр үк башлаган һәм өлешчә бастырып чыгарган тикшеренүләрен дәвам итәргә тели. Чөнки Атласов шул көнгә кадәр Казан университеты каршындагы археология, тарих һәм этнография буенча Казан җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы булып калуын дәвам итә. Ләкин 1922 елда җирле ГПУчылар Атласовны кабат искә төшерәләр. Ник дигәндә, ул бит үзен җир дип атаган кеше. Ә Мәскәүдә ун җирләрнең лидерлары өстеннән «күргәзмә» суд процессы бара. Бу очракта Чистай ревтрибуналының аны аклавы кемгә хаҗәт, заманалар үзгәрә...

Атласов яшерен күзәтү астына алынуын һәм хатларының ачып укылуын бик тиз сизә. Ләкин ул үзенең һәр адымын, һәр әйткән сүзен органнарга житкереп торучы дуслар-шымчылар белән уратып алынуын күз алдына да китерә алмый. Ә бу «әшнәләр» исә аның «корткычлыгын», «советка каршы эшчәнлеген» сурәтләүдә буяуларны кызганмыйлар. Шул рәвешле, Атласовның күп томлы «эше» барлыкка килә һәм бу кәгазьләр, вакыты житкәч, аңа туптан аткандай тәэсир ясаячак. Шундый бер агентның 1923 елда ясаган доносыннан. Аның фамилиясе күрсәтелмәгән, ләкин документта «РКП әгъзасы» дип искәртелгән: «Атласов миндә кунакта булды, совет власте бер яктан яхшы, ләкин берничди милекне дә танымый, ә аңардан башка яшәп булмый»,— дип сөйләде. Икенче шымчы исә шул ук чорда: «Атласовның контрреволюцион гамәлләре сизелми»,— дип яза. Өченче агент исә ГПУга 1923 елның мартында Атласовның совет власте турында ниндидер тарих язуы, ләкин аның пролетар рухта булмавы хакында хәбәр итә. «Ул совет хакимиятен тәнкыйтьли, 1921 елдагы ачлык өчен большевиклар гаепле, алар меңләгән крестьянның үлеменә китерде»,— дип өсти. 1924 елда шул ук агент: «Атласов хәзерге көндә татар телендә «Иске һәм яңа Россия тарихы»н яза, дип әләгенә төгәллек кертә. Аннары: «Ул кәгазь битенең бер ягына гына яза. Шактый калын 3—4 ләп кәгазь өеме булыр. Бу китапны кем язарга кушты, дигән сорауга каршы: «Мин, җәмәгать эшлеклесе, әдәбият белгече һәм тарихчы буларак, мөселман халкы өчен истәлек калдырмакчы булам, чөнки бүгенге көнгә кадәр мөселман дөньясының тарих буенча яңа басмалары юк»,— дип җавап бирде. Җәза органнары басымының һаман көчәя баруын сизеп һәм алдагы көндә үзен фәкать өметсезлек көнә көтүен аңлап, 1923 елда Атласов ике тапкыр Мәскәүдә була һәм анда тәрек илчелегенә керә. Андагы хезмәткәрләр белән очрашу вакытында ул дин тотучы мөселманнарның аяныч хәле, мәчетләрнең җимертелүе хакында сөйли, татарларның эреп юкка чыга баруына көенүен әйтә. Ул чакта да, 1926 елда да, Атласов үзенең гаять авыр матди тормышыннан зарлана, рухының сүнүенә басым ясый һәм Төркиягә күчеп китүдә ярдәм итүләрен сорый, анда үзенең, тарихчы буларак, зур файда китерәчәге хакында әйтә. Илчелектә бераз акча биргәч, Атласов Мәскәүдәге тотылган китаплар кибетеннән Гете томнарын сатып ала һәм, бар дөньясын онытып, тәрҗемә белән шөгыльләнә...

Атласовның ГПУдагы «эше» көннән-көн калыная, әләкләр саны арта бара. Шымчылар, ау этләре кебек, борыннарын җил уңаена тоталар. Һәм үзләрен зур җәнлек артыннан кугандай тоялар... 1924 елның октябрендә ОГПУның Бөгелмәдәге вәкиле Атласовны үзенә чакырта.

— Сезнең Совет властена мөнәсәбәтегез нинди? — дип сорый ул.

— Мин совет властеның принципиаль тарафдары һәм минем бу инануым хакимият алдында куркудан түгел, ә шушы казанышларга ирешү өчен гасыр башыннан ук көрәшеп килүемнән. Мин һәрвакыт кешеләрдә хәятлек яшәгәндә шәхси милек кирәк, ә дин белән фәкать фән генә көрәшергә тиеш дип исәпләдем. Көч ярдәмендә мәчетләрне җимерүне, шәхси милекне юк итүне күңелем хупламый.

1925 елда ГПУның шушы ук вәкиле, «күренекле һәм зур белемле кеше» буларак Атласовны агент булырга өнди, хезмәттәшләренең һәм укучыларының иҗтимагый-сәяси карашлары хакында хәбәр итеп торуын таләп итә. Атласов эчтән чирканып китсә дә, тыштан рәхмәт әйтә һәм баш тарта.

1927 елда Атласов илдә һәм республикада барган вакыйгалардан һәм үзгәрешләрдән тәмам имәнеп кала, ачуын, нәфрәтен тыя алмас хәлгә җитә. Ул крестьяннарның тормыш рәвешен көчләп алыштыруга, татар имлясын латинлаштырылган «Яңалифкә» күчерүгә, фикер хөрлегенә рәхимсез кысылуына кискен каршы чыга. Аның тирәсендә бөтерелеп йөргән шымчы, партиянең XV съезды материаллары басылган газетаны укыгач, Атласов тиресенә сыеша алмыйча, аларны, «коммунистлар тәмам шыр ялганчыга әверелделәр, крестьяннар аларга барыбер ышанмаячак», дип шәрехләде, ди. Шымчы әләгендә Атласовның: «Эшчеләрнең һәм крестьян массаларының башын әйләндерү өчен коммунистлар менә 10 ел инде алдыйлар»,— дигән сүзләренең астына сызган.

Шул чорда ук Атласов Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты рәисе Шәйгардан Шәймәрдәнев исеменә зур хат яза. Ул анда халыкның тормыш дәрәҗәсе түбәнәюгә, авылларда мәктәпләр һәм хастаханәләр җитмәүгә, милли җирлектә низаг чыгу мөмкинлегенә, коммунистик пропаганданың берьяклы булуына һәм гел шапырынуга гына корылуына борчылу белдерә. «Сез, коммунистлар, үзегезне тәнкыйтьләгәнне яратмыйсыз бит. Сез, үзегездән башка да, дөрес сүзләр һәм гадел фикерләр әйтә алучылар булуына ышанып бетмисез. Сез бөтен хакыйкать-

не фәкать үзегез генә белгән кебек кыланасыз, әйтерсең, ул башкаларныкына калмыйча, тик сезнең башларга гына килә торган фикер. Безнеңчә, бу алай түгел»,— дип яза Атласов. Ачып укылган бу хат та гаепләү томнарындагы кәгазьләр арасына теркәлә. Атласов татар имлясын латинга күчерүгә кискен каршы чыга. Аның укытучыларга: «Яналиф» татар мәдәниятен һәлак итәчәк»,— дип белдерүен партия һәм җәза органнары яна сәяси этлек дип кабул итәләр. Шымчы ашыгып: «Атласов «Яңалиф» аркасында совет власте Көнбатышта үзенең бөтен абруен югалтачак, Төркия хәзергә дус, ә бераздан бу эшкә начар караячак»,— дип хәбәр итә.

Бернәрсә ачык, мең ел буена хезмәт итеп килгән имляны алыштыру халыкны борынгы мәдәниятеннән мәхрүм итте. Сөйләм теленә туры килми дип, японнарны һәм кытайларны иероглифлар куллануда гаепләргә мөмкин. Ләкин иероглифларны белсә, бүгенге японлы һәм кытайлы күп гасырлар элек язылган барлык нәрсәләрне укый ала. Ә хәзерге татар имлясына ия булганнар гасырыбызның 20 еллары ахырына кадәр гарәп хәрефләре белән язганны укый алмый. Бу җәһәттән Атласов һәм башка галимнәр ул чакта хаклы иделәр. Ләкин бөтен нәрсәне башыннан аягына әйләндереп куя торган сәясәт яшәгәндә, аек фикерләргә урын юк, ул гына да түгел, аларга тиешле марксистик бәя бирелә, ә иясе җәзага тартыла.

1929 елның мартында Атласов кулга алына. Тентү вакытында аңардан Солтангалиевнең хаты һәм алты телдә язылган өч мең томнан артык китаптан торган шәхси китапханәсе тартып алына. Сталинга адресланган хатында (1935 ел) Атласов үзенең Бөгелмәдә кулга алынуы һәм солтангалиевчелектә гаепләнүе хакында яза. «Солтангалиев белән таныш булсам да, солтангалиевчелекне якламадым. Бөек урыс шовинизмы киң җәелеп, тирән тамыр җибәрде, дип уйлавым белән мин милли мәсьәләдә үземә аерым бер мәсләктә тордым. Мин пролетариат диктатурасы, бөек урыс хакимлегенә чик куйса да, бөек урысларның башка милләтләр өстеннән хакимлек итү инстинктын бетерә алмады дип исәпләдем»,— ди ул.

Ул чакта Атласовны милләтчелектә генә гаепләп калмыйлар. 1927 елда ОГПУның Татарстан бүлеге башлыгы итеп билгеләнгән Дмитрий Кандыбин тәҗрибәле һәм мәкерле провокатор була. Борынгы татар әлифбасын саклап калырга тырышучылар аның өчен контрреволюционерлар, ә балаларын милли мәктәпләргә укырга бирүче ата-аналар милләтчеләр булып саналган. 1935 елда ул СССР Югары суды Хәрби коллегиясе әгъзасы итеп билгеләнә һәм, гаепсез кешеләргә үлем карарлары чыгарып, үзенең Тамбовта, Воронежда, Төньяк Кавказда һәм Татарстанда башлап җибәргән канлы юлын дәвам иттерә.

Бөгелмә кантонында Атласов җитәкчелек иткән советка каршы төркем турында «эш»не 1928 елда нәкъ менә Кандыбин раслый. Бу документтан күренгәнчә, төркемдә 7 кеше була (Атласов, укытучылар Кәбир Туйкин, Хәбиб Кадыйров һ. б.) һәм алар үз алларына укучылар арасында милли үзаңны үстерү, халыкта автономияле республика биргән ярым-йорты хокукларга, яшәп килгән строй шартларында төрки-татарларның хәлен яхшырту өметләренең нигезсез булуына карата ризасызлык уяту максатлары куялар. Нәкъ менә шушы Кандыбинның әмере белән Атласовның «эше» системага салына һәм аның тирәсендә иснәнеп йөрүче шымчыларның саны ишәйтелә. Профессиональ җәллад булып киткән элеккеге надан эшче зур канәгатьләнү белән шымчысының әләген укырга яраткан. беркатлы Атласов исә үзе тирәсендә бөтерелеп йөргән агентка: «Ленинның тәгълиматы тамырыннан дөрес түгел, ул тарихның агышын бозып «сикереш» ясый. Ә тарих көчле нәрсә, аның законнарын сикереп кенә үтеп булмый»,— ди.

Шәхси мөлкәтеннән мәхрүм итеп, Атласовны ун елга хөкем итәләр. Утыру вакыты 1929 елның 29 гыйнварыннан исәпләнә. Ул Кемь шәһәренә, ОГПУның Соловки лагерьлары идарәсенә җибәрелә. Ул чакта Соловкига философ-рухани П. А. Флоренский, адвокат Бобрищев-Пушкин, украинлы академиклар Рудницкий һәм Грушевский кебек илнең иң мәртәбәле зыялылары җыела, алар арасында Атласовның иске танышлары Солтангалиев һәм И. К. Фирдәвес тә була.

Сәламәтлеге нык какшау сәбәпле, табиблар аны физик хезмәткә яраксыз, дип табалар, Атласов лагерьдан вакытыннан элек азат ителә һәм 1932 елның 22 ноябрендә Архангельск шәһәренә сөрелә. Ләкин аның исәнлеге көннән-көн начарая бара. Икенче группа инвалид буларак, Атласов туганнары карамагына тапшырыла. 1932 елның 17 июнендә аны алып китү өчен Архангельск каласына хатыны килә һәм зур кыенлыклар белән авыру һәм тәмам эштән чыккан ирен туган җиренә, Бөгелмәгә алып кайтып китә.

1933 елның 18 августында Атласовны ОГПУга чакыралар һәм ул монда үзенең алман теле укытырга теләве һәм сәясәт белән шөгыльләнүдән баш тартуы хакында әйтә. Ләкин эшкә урнаша алмый. Озак каңгырап йөргәч, Атласов бу юлы ОГПУга үзе килә һәм хезмәт урыны эзләп Бөгелмәдән Азнакайга яки башка берәр җиргә күчеп китәргә рөхсәт сорый. Ул Берлинда яшәүче, 1926 елга кадәр Мәскәүдә төрек илчелегендә эшләгән Шәфиевкә матди ярдәм сорап, үзенең хезмәтләрен алман һәм инглиз телләрендә бастырып чыгару мөмкинлеген белешеп хат җибәрергә ярыймы, дип кызыксына. Аңа боларның барысын да рөхсәт итәләр. Ләкин аның активлыгын хәтер янчыгына алалар. 1933 елның октябрендә ОГПУның Бөгелмә бүлекчәсе Казандагы башлыкларыннан: «Тиешле агентура белән чолгап, Атласовны эшкәртергә кирәк»,— дигән күрсәтмә ала.

Хөрлек сөюче Атласовны, бүре аулагандагы кебек, бөтен халыкны кызыл флаглар белән уралган кырга куып керткән һәм шуннан борынын да чыгармавын күзәтеп, саклап торган сунарчылар бер-берсенә дә ышана алмыйлар.

1933 елның ахырында — 1934 елның башында шымчылар Атласовның Дарвинга нигезләнеп: «Әгәр дәүләт үзендә кылына торган җинаятьләр белән көрәшә алмый икән, ул юк ителергә тиеш»,— дип әйткән сүзләрен җиткерәләр. «Атласовның фатиры бик начар,— дип хәбәр итә икенче шымчы.— Ул тулай торакта яши. Бүлмәсе кечкенә. Аның янында хатыны һәм ике баласы да бар, олы кызына 12—14 яшьләр чамасы». Өченче агент та кеше хәсрәтеннән тәм тапкандай: «Атласов ГПУ мине элеккеге фикерләремнән баш тартыр дип ышанып чыгарды. Уйлый бирсеннәр, ә мин үлгәнче аларга турылыклы калачакмын»,— дип сөйли ди. Агент моңа шатланган булса кирәк. Чөнки «Бөкрене кабер генә төзәтә ала»,— дип өсти. Атласовны күпме газаплыйлар, ә ул һаман үзенчә каера, имеш.

1934 елның апрелендә Мәскәүдән милли республикаларга мөселманнарның бәйсез «Туран дәүләте» төзү өчен яңадан агитация башлап җибәрүләре, шул эшне оештырудагы үзәкне табу, фаш итү һәм юкка чыгару турында ОГПУ күрсәтмәләре җибәрелә. Казан ГПУчылары үзләре өчен абруй казаныр сәгать җитте дип исәплиләр, «үзәк» — Татарстанда һәм аның башында Атласов тора, дип карар кылалар.

Мондый акылга сыймаслык мәгънәсез уйлар бөтен барлыгын ауга, эзәрлекләүгә һәм җәза бирергә юнәлткән авыру кеше миендә генә туарга мөмкин. Дөрес, кешене тиле идеяләр, шул исәптән, теләсә нинди юл белән үзенең хакимлек итәргә хокукын һәм бу хакимиятнең зарурлыгын исбатларга омтылу бөтенләй җүләрләндерергә һәм аздырырга мөмкин. Әгәр мондый фикер бөтен җанны биләп алса һәм кешегә һәр көнне гомуми бәхеткә ирешү юлында дошманнар (кем булулары мөһим түгел: буржуазия, кулаклар, милләтчеләр, яһүдләр, татарлар, калмыклар) комачаулый, дип тукып торсалар, ул әйбәт адәмнән күршесен генә түгел, ә үзен, гаиләсен юк итәргә, атасын, сеңлесен һәм улын корбан чоңгылына бирергә әзер торучы бирәнгә, кыргый ерткычка әверелә... Болар — куркыныч нәрсәләр. Ләкин алар булды... Кешенең аңын томан каплый, бөтен барлыгын коточкыч мәхшәрләр биләп ала...

ГПУ эшне коры тота. Аларның фикер сөреше буенча, Атласов Соловки концлагеренда утырган. Анда солтангалиевчеләр, муссаватчылар, алашурдачылар белән очрашкан. Ул алар белән бергәләп эшләү турында килешә яисә тегеләре аңа үзләренең элемтәләрен тапшыра ала идеме? Ала иде! Мөселманнар арасында абруй казанган зат. Менә операция планы да әзер: барысын да ачыкларга, фаш итәргә, гаебен тануына ирешергә һәм юк итәргә. Моның өчен дистәләгән шымчыдан чебен дә очып чыгып китә алмаслык тыгыз һәм кое пәрәвез үрелә. Бәндәне кулга төшерергә, сорау алырга, аны үзен-үзе фаш итәрлек шартларга куярга гына кирәк...

1934—1935 елларда Атласов Бөгелмә, Әлмәт һәм Казан мәктәпләрендә алман теле укыта. Ләкин аңа тынычлап эшләргә ирек бирмиләр, берөзлексез хезмәтеннән азат итеп торалар. Ул, ярдәм сорап, Татарстанның Халык Комиссарлары Советы Рәисе К. Абрамовка мөрәҗәгать итәргә тели. Ләкин Атласовны кабул итмиләр. Ә ул аңардан тынычлап эшләргә мөмкинлек бирүләрен генә сорамакчы була. 1935 елның маенда ул Сталинга хат яза: «Хәзер мин эшсез, ач, мине хаксызга рәнҗетәләр»,— ди. Атласов Сталиннан эшкә урнашырга ярдәм итүен, пенсия бирүне, балаларына белем алырга комачауламауларын яки даими яшәү өчен гаиләсе белән Төркиягә күчеп китәргә рөхсәт итүен сорый. Ләкин җавап килми.

Ә «эш» шымчыларның әләкләре белән тула бара. Атласов тирәсендә йөрүчеләрдән өчесе аеруча активлык күрсәтә. Алар «алтын», «алтай», «икътисадчы» дигән имзалардан файдаланалар. Түрәләрнең күңелен күрү өчен бу бәндәләр

бөтен ишеткән һәм күргәннәрен сәгате-минуты белән житкереп торалар, еш кына күпертеп тә язалар. Пычрак әләкләр — һәрвакыт афәт, ә киң күләмнәрдә — чын мәгънәсендә милли фажига. Чөнки туйдырып бетергән күршеннән, үзеннән талантлырак хезмәттәшеннән котылу, көнчелегеңне, мин-минлегеңне, хәсетлегеңне канәгатьләндерү өчен ул чакта һәркемгә мәгълүм адреска имзасыз әләк язып жибәрү дә житкән... Менә шушындый әләкләрдән өзекләр.

1934 елның ноябре. Атласов очрашкач: «Хәзер мин барлык мөселманнар да берләшми торып аларның мәнфәгатьләрен якламаячакларына тәмам ышандым. Мәктәпләрдә татарча укыту бетерелде»,— диде.

1934 елның декабре: «Кировны үтерү, Зиновьевны һәм башкаларны кулга алу турында сөйләштек. Атласов, мондый хәлләргә юл куеп торгач, партия бик көчле түгел инде, дип белдерде». 1935 елның гыйнвары. «Атласов, ялган күрсәткечләр белән тулганлыктан, мин газеталар укымыйм»,— дип әйтте.

1935 елның апреле. Шымчы Исхакый һәм аның Туран дәүләте төзү идеясе турында Атласов белән махсус рәвештә сүз куерта — Атласов бу хакта читләтеп: «Егет белән кыз арасында, башта танышу, аннары култыклашып йөрү, соңрак үбешү, бераздан өйләнешү, балага узу һәм бала туу булган кебек, бу очракта да яралгысы бар, бәс жимеше дә өлгерми калмас»,— ди.

Шымчылар төрле провокацион сораулар белән Атласовның серен алырга маташалар. Ә бу сораулар ГПУ «осталары» тарафыннан алдан ук әзерләнеп куелган була. 1935 елның июнендә Атласов «Алтын» кушаматлы агент белән сөйләшкәндә ачылып китеп, үзенең бөтен гомере буена мөселманнар өчен, халкы өчен нәрсә дә булса эшләргә хыяллануы хакында әйтә. Ул ачынып 1917—1918 елларда Г. Исхакый кебек чит илләргә китүчеләрнең монда калганнардан яхшырак эшләүләре, зуррак мөмкинлекләргә ия булулары, аларның милләт өчен эшләүләре һәм исемнәренең тарихта калачагы турында сөйли. «Икътисадчы» исә әләгендә аның: «Хәзер гаделлек юк, кешеләр намусларын югалттылар. Мин социализмның хыял гына икәнен яхшы беләм инде. Аңарга ышану кызыл кар яуганны көтү кебек»,— дигән сүзләре астына сызган.

1935 елның ахырында Атласовның төшенке йөрүен, сәламәтлеге начараюын искәртәләр. Аларның берсе: «Атласов һаман эшсез. Кәефе бик начар. Соңгы вакытларда хәтта елый да башлады, элек бу хәл булмый иде. Хәзер Сталин һәм Лепа исеменә адресланган хатларына жавап көтми инде. Алар сүздә генә кешеләргә илтифатлы һәм игътибарлы булып кыланалар, ә чынлыкта исләре дә китми, дип сөйләнде»,— дип яза.

1935 елның 9 декабрендә, тәмам теңкәсе корыган Атласов Татарстан Эчке эшләр халык комиссариаты идарәсе башлыгына үзенең 1934 елда Казанга күчеп килүе, 12 нче мәктәптә алман теле укыта башлавы, ләкин 1935 елның 3 февралендә эштән куулары хакында яза. «Мактану дип уйламагыз,— ди ул,— ничек кенә булмасын, мин төрки-татар дөньясында карт жәмәгать һәм фән эшлеклеләренең берсе, ә хәзерге вакытта тарих, биология һәм филология өлкәсендә яхшы фәнни әзерлеккә иямен». Ул үзенең менә инде ун ай дәвамында эшсез йөрүе хакында хәбәр итә һәм хезмәткә керергә ярдәм күрсәтүләрен үтенә. Бу вакытта ул инде алтмышынчы яшь белән бара торган була. Кулга алынырга да ярты еллап кына вакыт кала.

1937 елның 1 маена Атласов хыялый оешмасының 107 әгъзасы кулга алына. Эчке эшләр халык комиссариатының социаль бүленеш күрсәткечләре буенча, алар арасында 54 зыялы, 35 мулла, 18 крестьян һәм сәүдәгәр була. Аларның барысын да советка каршы гамәлләрдә һәм буржуаз төрки-татар дәүләте төзергә маташуда гаепләлиләр. Моннан тыш, шпионлык эше алып бару, баш күтәрүгә әзерләнү, солтангалиевчеләр белән бәйләнеш кебек гонаһлар да тагыла. Кулга алулар соңрак та дәвам итә. 1938 елның ноябрендә Шөгер районында, «атласовчы милли оешма филиалының калдыклары»,— дип тагын 15 кешене сак астына алалар.

Атласов белән бергә бертуган укытучы Туйкиннарны, Баулыдан биология укытучысы Фәхрази Даутовны, Кәшаф Вәлиев исемле мулланы, укытучы Абдулла Бикбаевны һәм халыкның башка бик күп мәгърифәтчеләрен хөкем итәләр. Аларның күпчелеге атып үтереләчәк яки Гулагның иксез-чиксез киңлекләрендә һәлак булачак. Алар барысы да 1985 елда гына акланачак.

Ә ул чакта бөтен илгә шаулардык «олы» сәяси процесс барып чыкмый. Кулга алынучылар нәрсәне танырга һәм нәрсәне танымаска икәнен үзләре дә белмиләр, тикшерүчеләрнең дә фантазиясе житеп бетми, беренче кулга алулардан, бигрәк тә Атласовтан сорау алулардан соң, эш бер урында таптана башлый. Ана НКВД комиссары Рудьның, Мәскәүдән килгән тикшерүченең, СССР Эчке эшләр халык

комиссариатының тыкшынучылары да бернәрсә дә бирми. Алар барысы да Атласовтан «коралсызлануын» таләп итәләр. Ләкин гомерендә күпне күргән бу кеше юлыннан тайпылмый. Үзе өчен мөһим булмаган гаепләрен таныган була, аннары яңадан кире кага. 1937 елның җәенә таба Атласов һәм аның «якын фикердәшләре» барлык гаепләрен танышлар. Хөкем әзер була. Медицина тикшерүе уздыралар. Атласовта йөрәк чире табалар, аның хәрәкәтләнүе дә бозылган була. Р. Яруллинның тешләре юклыгы ачыклана. Барысын да хөкем утырышында катнашырга яраклы дип табалар.

Атласовны һәм аның иптәшләрен Казанда, 23—28 октябрьдә, ябык ишекләр артында чекист Менжинский клубында хөкем итәләр. Атарга хөкем ителгәннәргә ярлыкауны сорап гозер язарга мөмкинлек бирәләр. Өч айдан артык алар, бәлки котылырбыз, дигән зәгыйфь өмет белән яшиләр. 1938 елның 11 февралендә СССР Югары судының Хәрби коллегиясе исеменнән аларның гаризасына тискәре җавап килә. 1938 елның 15 февралендә Һ. Атласов, Р. Яруллин, К. Туйкин, Б. Фәттахов, Ф. Туйкин, Г. Алтынбаев, К. Исхаков, С. Уразманов, З. Фәттахов атып үтереләләр.

1985 елдагы реабилитация кәгазьләрендә Югары судның Хәрби коллегиясе аларны һәм башка меңнәрчә җәзалап үтерелгән кешеләрне аклый. Бу документта җанны өшетерлек сүзләр белән: «Яңадан ачыкланган хәлләргә бәйле рәвештә һәм гамәлләрендә җинаять дип әйтерлек эшләр булмаганлыктан...»,— дип язылган. Сәер җөмлә! Чынлыкта бу һәм башка шундый эшләрдә тагын нинди яңа хәл ачылды соң? Бу кешеләр беркайчан да гаепле булмады! Фәкать заманалар үзгәрде һәм бер гаепсез кешеләрне тончыктырып үтергән канлы чуан гына шартлады.

Атласов үлем җәзасын алыштыруны сорап биргән гаризасына җавап көткәндә һәм үзен атачак урынга атлаганда нәрсә хакында уйлады икән? Хәзер моны белеп булмый инде. Ул, мөгаен, тормышның бөтен асылын хасил иткән хыялын — үзенең халкы өчен яшәү һәм эшләү теләген сызып ташлаган аяусыз тәкъдиргә үпкә һәм әрнү хисләре белән янгандыр. Һәм, мөгаен, аның миен: «Ни өчен? Аның газапларының мәгънәсе нидә? Алардан кемгә файда? Бу саташу нәрсә хакына?» — дигән сораулар бораулагандыр һәм тынгы бирмәгәндер. Шул сорауларына җавап тапмагандыр...

**Алексей ЛИТВИН,**
тарих фәннәре докторы.

# БӘХЕТЛЕ КЕШЕ, БӘХЕТЛЕ ШАГЫЙРЬ

Күзләреңдә инде нур сүнгән дип,
Чал кергән дип синең чәчләргә,
Картайтмагыз мине, зинһар өчен,
Рухым белән мин тиң яшьләргә.

Шагыйрь күңелендә көз белән кышның мәңге буласы юк дигәнгә бик тә тәңгәл килә бу юллар. Әлеге шигырь юлларын бөтен гомере буена яшьлек юлдашы булып калган, үзен һәрчак егетләрчә хис итүче, һәрдаим хөр һәм оптимистик рухлы өлкән шагыйребез Мәхмүт ага Хөсәен иҗат иткән.

Югыйсә, шаулап-гөрләп аккан тау елгаларының да агышы, борылышлы-борылмалы юллар узып, тигез урыннарга, үзәнлекләргә җиткәч, ничектер тынычланып кала. Җил-давыллар да туктаусыз исеп тормыйлар — бер мәлне туктап ял итәләр.

Әмма мондый халәт Мәхмүт Хөсәенгә хас түгел. Ул, йөгерек-житез терекөмеш тамчысы кебек, бер урында гына утырып тора белми. Йә ул тиз генә җыена да ерак юлга сәфәр чыга, үз укучылары белән очрашулар үткәрә, йә кайнап торган сәяси тормышка кереп чума — көн кадагындагы нинди дә булса бер вакыйгага, милли мөстәкыйльлек өчен көрәшкән аерым бер шәхескә карата үзенең мөнәсәбәтен белдереп, үз бәясен биреп публицистик әсәр яза. Һич көтмәгәндә йөрәк ялкыны, гыйшык уты белән сугарылган мәхәббәт шигырьләре белән чыгыш ясый...

Ул башкача яши алмый. Бу — аның бар булмышы, яшәү һәм иҗат итү рәвеше. Бу — аның язмышы һәм бәхете. Менә шундый тынгысыз, кайнар дәртле, сулу һәм суынуны белмәс шагыйребез гомеренең тагын бер биеклеген яулый — 70 яшен каршылый.

Әйе, мин аны бәхет йолдызы астында туган кешеләрдән исәплим. Шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты ил-көн тарихыннан аерылгысыз. М. Хөсәен бик күп тарихи вакыйгаларның тере шаһиты. Ул вакыйгаларның уртасында кайнаган. Әмма нинди генә аяусыз һәм катлаулы чорларда да бәхет кошы анардан йөз чөермәгән.

Мәркәзләрдән бик еракта, казакъ даласында, дөресрәге — Җанакала төбәгенең Урда авылында якты дөньяга килеп, үсә төшкәч, Петропавел (Кызылъяр) шәһәренең татар мәктәбендә белем алып йөргән, иҗат «җене» кагылган малайның беренче мәкалә һәм шигырьләре өчен «Яшь ленинчы» (бүгенге «Сабантуй») газетасы тарафыннан Бөтенсоюз лагере «Артек»ка путевка белән бүләкләнүе — үзе үк күктән иңгән бәхет түгелме соң? Шул ук елларда балаларның сөекле язучысы Абдулла Алиш белән хат алышу, танылган шагыйрьләр Хәсән Туфан һәм Шәйхи Маннурларның хат аша юлланган беренче киңәш һәм фатихаларын уку — болары да бәхет түгелмени яшь иҗатчы өчен? Урта мәктәпне тәмамлауга, илгә фашист явы ябырылгач, дошманга чиксез нәфрәт хисе белән, кулына корал алып, Ватан иреген саклау, ничәмә-ничә тапкырлар үлем белән күзгә-күз очрашып та, авыр яралардан соң исән калу, озын-озак сузылган сугыш юлларын урап, күкрәгендә орден-медальләр чыңлатып, туган ягына җиңүче булып кайту — гвардия майоры, фронтовик шагыйрь өчен моннан да кадерлерәк бәхет була аламы соң? Утлар-сулар кичкән солдат өчен бәхетнең иң зурысы — әлбәттә, гомер. Сугыштан кайтуга тыныч тормыш дулкынына чуму, гыйлемгә омтылыш, югары уку йортының ишеген киң ачып керү, әдәби мохитта кайнау, иҗат түгәрәкләрендә чарлану, китаплар чыгару, күңеле теләгән эшкә урнашу, китап нәшриятында мөхәррирлек итү — шагыйрь язмышының бәхет баскычлары болар. Ахыр килеп, ил-көн каршында мөхтәрәм шагыйрь булып танылу, популярлык казану — иңнәренә фәрештәдәй бәхет кошы очып куну шулдыр, мөгаен. Шагыйрь үзе «Тормыш» исемле шигырендә бу хакта болай ди:

Дулкын аша кичтем, дулкын аша,
Тигәнәкләр телде теземне...
Йөз чытмадым ләкин!
Дөньяда мин
Бик бәхетле сизәм үземне.

Шигырь санын ишәйтү өчен генә язылмаган бу юллар. Аларда — шагыйрьнең ихласлыгы. Табигатьтәге сыман, тормышта да берни дә җиңел генә, көрәшсез яуланмый. Шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә дә әдәбият мәйданына илткән юлда яшел келәм җәеп тормадылар. Кыйналуның ни икәнен үзе генә белә. Ләкин шунысы хак: ул беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде, каләмен ял иттермәде.

Яшермим, аның хакында сүз-фикерләрнең төрлесен ишетергә туры килгәне бар миңа. Төрлесе дигәч, аңлашыладыр. Бу очракта Әмирхан ага Еникинең үзара гына әйтелгән бер фикерен искә төшереп узасы килә: «Хөсәеннең аның, шигырьләреннән узып, алдан холкы йөри». Хикмәти хода! Кайчан бездә холыкфигыленең ниндилегенә карап түгел, ә чын-чынлап иҗатына, язган әсәрләренә карап бәя бирергә өйрәнерләр икән? Сүгәләр, тиргиләр, кыйныйлар Хөсәенне. «Календарь», «кызыл» шигырьләр язуда гаеплиләр. Сүз дә юк, бу җәһәттән ул, әлбәттә, гөнаһсыз түгел. Әйдәгез, алар яшәгән чорга — кырыгынчы, илленче елларга күз төшерик. Кайсы әдип кенә социализм идеалларына, «даһи атабыз» Сталинга дан җырламады икән? Бу — бер Хөсәеннең генә чире микән? Шул чорларда чыккан кайсы китапны ачып карасаң да, мәдхия тулы әсәрләргә юлыгабыз. Әлбәттә, әлеге «чир» Мәхмүт ага иҗатында озаккарак сузылды бугай. Дүрт-биш ел элек кенә аның янында Сталинны хурлап бер сүз әйтсәң, шагыйрьнең дошманына әверелә идең. Гомер буена ышанып килгән «иман»нан тиз генә арынып булмый шул. Моны саклануның бер чарасы дип тә аңларга кирәктер. Вәләкин ул беркайчан да, беркем каршында да тәлинкә тотмады. Әйтәсен өздереп әйтте, әлеге дә баягы холкы алдан йөрде. Бу хакта аның үзеннән дә остарак итеп әйтеп булмый шикелле.

Чын шагыйрь ул — үзе мең бала,
Зирәк акыллы шыр дивана.

Әйе, әйе, шулай дип әйтүе белән шагыйрь мең мәртәбә хаклы. Ул бернинди кысаларга да сыя алмый. Диваналык, дәрвишлек аның канына сеңгән. Андыйлар үз фикерен кистереп әйтәләр. Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗмигә багышланган бер шигырендә әлеге фикерне тагын да үстерә төшә ул.

Тынгылыкның алып бар котын
Шаулый диңгез таңнан таңгача...
Хисең түгел, хәтта бар холкың
Диңгез белән охшаш лабаса.

Диңгез белән, шагыйрь, игез син!
Моңнарыңда — үзең диңгез син!

Мәхмүт Хөсәен, шул диңгез дулкыннарыдай, укучы күңеленә иң элек җырлары белән килеп керде. Дистәләгән композиторларны дәртле көйләр язарга илһамландырды. Аның халкыбызга, Татарстанга, Казанга, сөекле Тукаебызга, халыклар дуслыгына, тынычлыкны саклауга, яшьлеккә багышланган җырлары киң яңгыраш тапты. Ә мәхәббәт җырлары кайсы гына яшь егетнең һәм яшь кызның күңелен җилкендермәде икән. Шагыйрьнең бик күп җырлары олы бәйрәм тантаналарының күрке булды. Зур сәхнәләрдә башкарыла, көн саен диярлек радио һәм телевидениедән яңгырап тора. Әлеге жанр өлкәсендә М. Хөсәен кебек актив эшләүчеләр сирәк. Шагыйрь каләме белән иҗат ителгән җырлар саны ике йөздән артып китә. Бу — үзе үк зур хезмәт. Җыр-моң — халыкның гомерлек юлдашы, ул — күңел канаты. Шуңа күрә дә күпсанлы җыр сөючеләр шагыйрьгә рәхмәтлеләр. Аның «Шинель», «Идел дулкыннары», «Яңа Казан», «Бик сагындым», «Ак дулкыннар» кебек җырлары татар җыр-музыка сәнгатенең алтын хәзинәсенә керделәр. Шагыйрьнең нечкә юмор, шаянлык хисе белән өретелгән җырлары да халыкта популярлык казандылар. «Яшәсен кияүләрем», «Бәрәңге», «Ярап булмый хатынга» кебек җырлары әнә шундыйлардан. Автор үзенең нәни дусларын, мәктәп укучыларын да онытмый. «Укучылар вальсы», «Батырларга алмашка» исемле һәм башка җырлары моны ачык раслый. Иң яхшы җырларга уздырылган конкурсларда катнашып, ул күп тапкырлар лауреат исеменә лаек булды.



*Рәсемдә: шагыйрь Мәхмүт Хөсәен Татарстанның сәнгать осталары арасында. Апрель, 1979 ел. Уфа.*

*Фоторәсем шагыйрьнең шәхси архивыннан алынды.*

М. Хөсәеннең бөтен биографиясе — шигырьләрендә. Бөек Ватан сугышы темасы аның иҗатында аерым урын тота. Сугышның бөтен авырлыгын үз йөрәге аша кичергән кеше, фронтовик шагыйрь буларак, кешелеккә мондый фаҗигане бүтән кабатлауга юл куймаска әндәшә. Мәсәлән, «Юлдашлар» исемле поэмасында гади солдатның каһарманлыгына дан җырлый.

Тәүге җырым, тәүге илһамым да
Юлда шытты утта ысланып...
Тынгы бирми әле дә ул еллар,
Алга баса юлдаш дусларым.

Мәхмүт ага туган илебезгә җиңүче булып кайтуына чиксез горур. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтим әле: Җиңү бәйрәме якынлашкан көннәрдә ул үзе махсус тектергән хәрби киеменнән йөри. Күкрәге тулы орден-медальләр. Әйе, Кызыл байрак, Кызыл йолдыз, «Бөек Ватан сугышы» кебек дәрәҗәле орденнарны тикмәгә генә бирмиләр. Мәхмүт ага, чын мәгънәсендә, сугыш каһарманы. Тормышта да кыю, батыр кеше ул.

Шагыйрь тормышка, матурлыкка гашыйк. Бу аның иҗатында да ачык чагыла.

Яшькә-картка гыйшык карамый.
Алтмыш яшьлек йөрәк кабынса,
Уналтының бәгърен яралый.

Мәхәббәт ул — яшен, ук, җаным.
Мәхәббәтнең яше юк аның.

Шагыйрьнең китапларын укып чыккач, күз алдына нечкә лирика остасы килеп баса. Мәхмүт ага бөтен гомере буена яшьлек һәм мәхәббәт җырчысы булып калды.

Сөюемнән мәңге туктамыйм —
Синең хакка янам утта мин,

дип үзе үк шушы хакта раслый.

Шагыйрь иҗатының мактауга лаек бер тармагы — сонетлар. Шәрәф Мөдәрристән соң бу жанрны үстерүгә ул зур өлеш кертте. Үзенең якташы, батыр җәлилче Әхәт Аднашевка багышлап «Яшь каһарман» исемле сонетлар гөлтаҗы иҗат итте.

Дәръям булып, җырым, агылчы —
Тираннарның тетрәт тәхетен!..
Халык кулында — Җир язмышы,
Эштә яулый ул үз бәхетен.
Көл түгел, гөл илтә кешеләр
Тынгысыз һәм тыныч илларга.
Җәлил, Алиш, Аднаш ишеләр
Әверелә мәрмәр сыннарга.

Әнә шулай шагыйрь батырлыкка дан җырлый, Әхәт Аднашев истәлеген мәңгеләштерә.

Мәхмүт ага — трибун шагыйрь. Зур сәхнәләргә күтәрелеп, үзенең шигырьләрен чын артистларча яттан сөйли. Бу җәһәттән Татарстанда ул чыгыш ясамый калган авыллар сирәктер. Әйе, җиңел аяклы ул. Шунда ук җыена да, сәяхәткә китә. Туган ягы Казагыстанга барып чыга, Кырымны әйләнеп кайта яисә Әстерхан якларына юл тота. Уфа каласын әйтәсе дә юк. Кайда гына бармасын, аны анда дуслары көтә. Мәхмүт ага үзенең дусларын онытмый. Алар белән хат-хәбәр алышып тора. Мин аның чорыбызның зур шагыйре Наҗар ага Нәҗми белән дуслыгына сокланам.

Мәхмүт ага гаҗәеп ярдәмчел кеше. Ул бик күп яшь иҗатчылар белән якын элемтәдә тора. Мәсәлән, соңгы вакытларда гына да Уфадан — Салават Рәхмәтуллин, Рим Идиятуллинга багышланган мәкаләләрен бастырып чыгарды, аларның иҗатын Татарстан укучылары белән таныштырды.

Мәхмүт ага юморга искиткеч бай. Аның юмористик, сатирик шигырьләрен рәхәтләнеп укыйсың. Шагыйрь үзенең җитмеш яшен зур иҗат багажы белән каршылый. Ул — дистәләрчә китап авторы. Аның әсәрләре бик күп тугандаш халыклар телендә дә дөнья күрде.


Кыскасы, бәхетле кеше, бәхетле шагыйрь ул.

**Госман САДӘ.**

АВТОРДАН:

Әлеге мәкаләне язганда бер генә тапкыр да «иде» дигән сүзне кулланмадым. Хәзер инде «иде» дип әйтергә туры килә. 70 яшенә төп-төгәл бер ай кала, 15 мартта Мәхмүт ага мәңгелеккә күчте. Татар әдәбияты тагын бер зур улын югалтты. Һәр китү үкенечле. Ярый әле, дим, Мәхмүт ага бу мәкаләне үзе укып калды һәм рәхмәтен белдерде. Урының җәннәттә булсын, хөрмәтле өлкән дустым!

# АРМИЯНЕҢ, ХАЛЫКНЫҢ ГОРУРЛЫГЫ



20 февральдә Мәскәүдә элеккеге СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче татар генераллары һәм адмираллары белән очрашу булуын алдагы санда хәбәр иткән идек инде.

**Рәсемдә:** очрашу уңаеннан истәлек өчен фотосурәткә төшү. Утырганнар *(сулдан өченче)* — армия генералы М. Ә. Гәрәев; очрашуның спонсоры, күренекле экономист һәм эшмәкәр Н. К. Халикеев *(уңнан өченче)*.

**В. Виноградов** фотосы.
(«Татар-информ» информация агентлыгы).

**Мәскәүдәге очрашуда катнаштылар:**

Армия генералы Мәхмүт Гәрәев.
Генерал-полковник Рәсим Акчурин.
Генерал-полковник Эльдар Цоколаев.
Вице-адмирал Марс Искәндәрев.
Генерал-лейтенант Минюр Колахмәтов.
Генерал-лейтенант Мидхәт Салихов.
Генерал-майор Раил Әбраров.
Генерал-майор Александр Әдһәмов.
Контр-адмирал Әмир Бичурин.
Генерал-майор Руслан Нагайбәков.
Генерал-майор Александр Милушев.
Генерал-майор Таһир Сәйфетдинов.
Генерал-майор Дамир Тимерханов.
Генерал-майор Тәлгат Мәмәтов.
Контр-адмирал Рәфкать Чеботаревский.
Генерал-майор Рафаэль Йосыпов.
Генерал-майор Камил Мәхмүдов.
Генерал-майор Илмас Мифтахов.
Генерал-майор Марс Умеров.
Генерал-майор Мәхәсим Рафыйков.
Генерал-майор Марсель Әһлиуллин.
Генерал-майор Гайнулла Шакиров.
Генерал-майор Фильяз Ханцеваров.
Генерал-майор Юрий Ширинский.
Генерал-майор Әмиржан Гәрәев.
Полковник Фәнис Рәҗәпов.
Полковник Степан Хмельников.
Полковник Васил Шәрипов
Полковник Алмаз Суханов.

* * *

Очрашуга шулай ук
генерал-лейтенант Абрек Әюпов,
контр-адмирал Әбделхат Аббасов,
генерал-майор Әхмәт Бикбулатов,
генерал-майор Хөсәен Мөхәммәдъяров,
генерал-майор Гани Мөхәммәтҗанов,
генерал-майор Ренат Җаббаров,
генерал-майор Әхәт Юлашев,
авиация генерал-майоры Рәүф Яхин
һ. б. чакырылган иде.

---

Очрашуда катнашкан язучы Рашат Низамиевның язмасын алдагы саннарның берсендә укырсыз.

**Кадерле укучылар!**
**Мөхтәрәм милләттәшләр!**

Журналыбызның бу санында без яңа рубрика ачабыз. Ул «Тарих сәхифәләрендә — татар шәхесләре» дип аталачак. Без таныштырып барырга теләгән шәхесләр төрлесе төрле дәрәҗәдә татар дөньясы белән бәйле, татар халкы өчен кызыклы тарихи затлар булыр. Сез әле күптән түгел генә дошман яки дус итеп каралган, «аклар» белән «кызыллар»га бүленеп йөртелгән кешеләр белән танышырсыз: без тар сыйнфи карашлардан өстен булырга тырышырбыз. Халык үз ул-кызларының барысын да белергә тиеш. Чын хак тарих бары шул жирлектә генә туа ала.

Мөгаен, кайбер фоторәсемнәрдәге шәхесләр һәм аларга бирелгән аңлатмалар күп кенә укучыларыбыз өчен көтелмәгәнрәк тә булып тоелыр. Моңа кадәр бөтенләй билгесез яки алар турында махсус сөйләнми килингән күренекле затлар белән беррәттән, үз авылында яки мәхәлләсендә генә, үз урамында, хәтта үз йортында гына билгеле булган кешеләр дә булырга мөмкин. Алардан башка тарих шулай ук тулы була алмас иде.

Кайбер фоторәсемнәрне күргәч, укучыларыбыздан да хатлар килер, кемнәрнеңдер тарихи язмышларын ачыклауда безгә ярдәм итүчеләр табылыр дип ышанабыз. Үз чиратыбызда без теге яки бу шәхес турында мөмкин кадәр тулырак сөйләргә тырышачакбыз. Сезнең хатларыгыз да безгә яңа исемнәр ачар, яңа рәсемнәр китерер дигән өметебез бар. Ә, бәлки, без сөйләячәк затлар арасында татар халкынын рухи тормышына лаеклы өлеш керткән башка милләт вәкилләре дә булыр.

Бүген без сезгә сирәк очрый торган рәсемнәрнең берсен тәкъдим итәбез. Рәсемдә Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимнәре сурәтләнгән. Революциягә кадәр Россиядә иң дәрәҗәле — «Хөсәения», «Галия», «Госмания» мәдрәсәләре кебек үк абруйлы мөселман уку йортларының берсе булган ул мәдрәсә.

Мөгаллимнәрнең йөзләренә игътибар белән карагыз да уйланыгыз: ничәмә дистә еллар дәвамында «артта калган, надан-томана татар» саналып йөртелгән олуг халкыбызның йөзек кашлары түгелмени бу зыялылар? Алар арасында — күренекле галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре: Татарстанның булачак беренче мәгариф Халык комиссары Хәсән Солтанов, танылган дин белгечләре Кашаф Тәржеманов белән Габдрахман Галиев. Соңгысы — мәдрәсә ректоры Галимҗан Барудиның туганы. Булачак профессорлар Закир Шакиров, Хуҗа Бәдигый, танылган публицист, язучы Шәһәр Шәрәф һәм башкалар.

Бу рәсем 1917 елга кадәр алдырылган. Рәсемдәге затлар тиздән дөньяның астын-өскә әйкалдырачак фаҗигале хәлләрдән әле хәбәрдар түгелләр. Революция давыллары аларның да тормыш юлларын төрле якка аерачагын, язмышлары белән уйнаячагын алар әле сизенмиләрдер. Алар тыныч һәм киләчәккә ышаныч белән карап торалар.

Янә бер кат игътибар белән күз йөртеп чыгыгыз. Бу — халкыбыз тарихының бер генә сәхифәсе...

Сездән хатлар көтеп калабыз, мөхтәрәм укучылар!

Бу фоторәсем өчен без сугыш һәм хезмәт ветераны **Вәли** ага **Хаҗиевка** рәхмәтлебез!

Сәхифәне журналга тарих фәннәре кандидаты
**Булат СОЛТАНБӘК** әзерләде.



# ТУКАЙ — «БӘХЕТ АЧКЫЧЛАРЫ»НДА

Тукай рухы безнең күңелләргә ана сөте белән кергән. Аның шигырьләрен сабый чактан ишетеп аңыбыз ачылган, яхшыны яманнан, дусны дошманнан аера белергә өйрәнеп үскәнбез.

Тукай шигырьләрен укып без халкыбызның телен, күркәм сыйфатларын сакларга, туган илебезнең мөкатдәслеген, урман-кырларының, суларының матурлыгын тоя һәм кадерли белергә өйрәнгәнбез.

Тукайның бай иҗади мирасы, бигрәк тә үлемсез шигърияте бөтен мәдәни үсешебез юлында алга зур адым булды, күп гасырлар рәхимсез җәберләнгән халкыбызның иҗтимагый аңын, милли горурлыгын уятты. Хәзер дә ул безне хөррият һәм гаделлек өчен изге көрәшкә рухландырып тора.

Тукай һәрчак безнең белән. Аның фантазиясе тудырган үлемсез образлар: алтын тарагын урлаткан су аналары, бүреләр өерен өркетүче хәйләкәр кәҗә белән сарык, явыз дию пәриен җиңүче батыр Карәхмәтләр чордан чорга күчеп яшиләр; урман сарыгы шүрәлеләр, тапкыр егет Былтырлар сәхнәләрдә бииләр. Барыбызга да кечкенәдән якын, күңелләргә сеңгән «Туган тел» шигыре халкыбызны берләштерүче милли гимныбыз булып яңгырый.

Габдулла Тукай әсәрләре, аның исеме белән турыдан-туры бәйле һәр вакыйга, яңа табылган һәр документ безне дулкынландыра.

Җитмешенче еллар азагында, Татарстан китап нәшрияты музееn ачу максатында өйдән-өйгә йөреп экспонатлар җыйганда, мин бер кызыклы документка тап булдым.

Мәгълүм ки, Тукайның вакытсыз вафаты халкыбыз өчен зур югалту була, ул кайгылы хәбәр газета-журналлар аша да, телдән-телгә күчеп тә тиз арада бөтен илгә, барлык төрки халыкларга ирештерелә. Аның исемен мәңгеләштерү теләге белән күп санлы шигырьләр, бәетләр, хатирәләр языла, шигырьләре төрле телләргә тәрҗемә ителә, көйләргә салып җырлана, мәдрәсәләргә, китапханәләргә Тукай исеме бирелә, матбугатта, төрле рекламаларда портретлары чыгарыла.



Бу эштә, мәдәният әһелләре белән беррәттән, милләтпәрвәр промышленниклар, төрле коммерсантлар да катнашкан. «Альфа» кондитер фабрикасы хуҗасы, мәсәлән, 1913 елны «Бәхет ачкычлары» («Ключи счастья») дигән конфет чыгарган. Конфетны төргән кәгазь тышлыгына Тукайның сурәте бирелгән. Шагыйрьнең өстәлендә берничә китап, ак кәгазь, каурый каләм, шәм янып тора. Сул ягында көмеш фольгалы фонда гарәп әлифбасы белән: «Г. Тукаев. 1888—1913» дип язылган.

Бу фабрика Казанда Печән базары урамында урнашкан, аның хуҗасы В. Ибраһимов дигән кеше булган. Моны «Альфа» фирмасының «Путеводитель по Волге и Каме» исемле китапта басылган (1915 ел) зур рекламасыннан укып белергә мөмкин. Ә менә гарәпчә язылган «1888» саны берәр датага багышланганмы, әллә рәссам-график хатасы гынамы икәнен кызганычка каршы, ачыклап булмады.

Журнал укучыларыбыз игътибарына әлеге сурәтнең фотокүчермәсен тәкъдим итәбез һәм ул, аз гына булса да, шул көннәрне күз алдына китерергә мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

**Сафа САБИРОВ**

# УЙМАК УЙЛАР

(ГАИЛӘ ТУРЫНДА)

Ир белән хатын мәхәббәте меңәр очракны кичеп чыккан гап-гади бер нәрсәдер, ләкин аңардан да соклангыч матурлык юк.

Ф. МОРИАК

Үз бусагасыннан узмаган шәхси тормыш, никадәр генә күркәм тоелмасын, ул барыбер ярлы.

А. ГЕРЦЕН

Өендә бәхетле кеше — кайда да бәхетле.

Л. ТОЛСТОЙ

Тугры мәхәббәт авырлыкларны ансатрак җиңә.

Ф. ШИЛЛЕР

Никах зур мәшәкатьләр китерә, әмма гаиләсез яшәү кешене бик күп шатлыклардан мәхрүм итә.

С. ДЖОНСОН

Бернигә карамый өйлән. Яхшы хатын эләгә икән — бәхетле, начары эләгә икән, философ булырсың.

СОКРАТ

Картайганда гашыйк булудан курык.

КАБУС

Яшь хатынның тәненә карт адәм орынуга караганда укның килеп тиюе яхшырак.

СӘГЪДИ

Әгәр кеше кырык яшенә чаклы гашыйк булып карамаган икән, аңа инде алга таба гашыйк булуның хаҗәте юк.

Б. ШОУ

Өйләнү — хокукларыңны яртылаш киметү, бурычларыңны яртылаш арттыру дигән сүз.

А. ШОПЕНГАУЭР

Хатын-кызны кимсетү хисабына ирләр беркайчан да чын бәхеткә ирешә алмый.

В. ГЮГО

*Латин әлифбасы нигезендә*
*татарча уку күнекмәләре*

1939 елның гыйнвар аенда совет язучыларының зур бер төркеме хөкүмәт бүләкләре — орденнар белән бүләкләнә. Бүләкләнүчеләр арасында татар язучыларыннан шагыйрь Шәйхи Маннурга Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, танылган драматург Тажи Гыйззәткә «Почет билгесе» ордены бирелә.

«Совет әдәбияты» журналы бу уңайдан 1939 елгы 1 санында СССР Верховный Советы Президиумының Указын бастыра. Указ соңында «Орденлы татар совет язучылары» дигән баш астында Шәйхи Маннур белән Тажи Гыйззәтнең фоторәсемнәрен урнаштыра.

«Совет әдәбияты» журналының 1939 елгы 2 санында исә орденлы драматург Тажи Гыйззәтнең «Бишбүләк» әсәренә яңадан эшләнгән өченче пәрдәсе басыла.

Без журналыбызның бу санында, укучыларга үрнәк төсендә, шул әсәрдән бер өзек тәкъдим итәбез.

**РЕДАКЦИЯ.**

*Ordenlь dramaturg*

TAÇI ƢIZZƏT

# BIŞ BYLƏK

*Jaꞑadan eşləngən ɵcence pərdəse*

*Urman. Tav-coqьrlar arasь. Pərdə acьlƣanda ʙer tɵrkem partizannar kyrenə. Qajsь iər, qajsь ajaq kiemnəre tɵzətə. Jegor, asьlƣan qazan janьnda, aş peşerep jɵri. Aƣac ʙaşьnda saqta torucь partizan çьr ʙaşlьj.*

Partizan. Min yskəndə urman-ʙasularьn,
Bolьnnarьꞑ miꞑa jat ide,
Alpavьtlar siꞑa, ʙajƣuralar,
Alar xuça, alar ʙaş ide.
Xor. Biş ʙyləkkəj, qajtsam tarsьnmassьꞑ,
Tizdən qajtam, qunaq itərseꞑ.
Bezdəj ʙatьr jegetləreꞑ ʙirep,
Armiələrgə ʙylək itərseꞑ.
Partizan. Irtə torьp, eşkə ʙarƣan caqta
Tuƣajьnda moꞑlap çьrladьm.
Jəştən eşləp ʙajda, jalcьlьqta
Qol ʙuluƣa ərnep sьzlandьm.
Xor. Biş ʙyləkkəj, qajtsam tarsьnmassьꞑ,
Tizdən qajtam, qunaq itərseꞑ.
Bezdəj ʙatьr jegetləreꞑ ʙirep,
Armiəgə ʙylək itərseꞑ.

*(Quьştan Şahʙaz cьƣa, kierelə).*

Şahвaz. Dezurnьj, aşisь kilə.

Jegor. Beraz saвьr it, aşarsьŋ. Tuqta əle, Şahвaz, вezneŋ vzvod su aşa kyper sala, ə sin nigə eşkə вarmadьŋ?

Şahвaz. Avrьjm, malaj, Jegor, вizgək tota.

Jegor. Əllə ni вuldь siŋa. Kilgənnən вirle kəzge ceвeş təsle cirlisen.

Şahвaz. Mondьj et tormьşьnda cirləv genə tygel, ylərseŋ də. Çьlь aş, təmle joqь kyrgən juq. Şunьŋ əstenə qajan qьna kilep cьqarlar ikən dip qaltьrap qəmer itəseŋ.

Jegor. Sin, Şahвaz, ataŋnьŋ azan tavşьn saqьna вaşladьŋ axrь.

Şahвaz. Juq, saqьnmьjm.

Jegor. [illegible]gə soŋ alaj вuldьk, qort aşaqan teş keвek sьqrьjsьŋ?

Şahвaz. Bu sьqrav tygel, Jegor dus. Acь xəqiqətne əjty genə. Min yzeвezne kəcle вurannarda adaşqan julcьlarqa oşatam.

Jegor. Dəres tygel, вez jul adaşmaqan. Kiləcək matur kəneвez, jaqtь tormьşьвьz əcen jul salucьlar, di вezneŋ komissar.

Şahвaz. Ul əjter... Tel səjəksez вit ul. Tik menə yze kitte də juqaldь.

Jegor. Kitsə, qajtьr əle.

Şahвaz. Belmim şul. Ber şəhərgə вarьp urnaşqac, ni dip kenə monda qajtьr ikən.

Jegor. Sin juqqa caвata qajtarma, jəme? Bezneŋ komissar revolytsiə əcen kypne tatьqan, ike-əc tapqьr tərmədə, sərgendə вulqan keşe. Ul вezne hicвer vaqьtta da taşlamas.

Şahвaz. Taşlamasa вik jarar ide də, nikter minem kyŋlem şiklənə. Əc kənnən вirle Timerkəj də juq. Soŋqь kənnərdə Samat aвьj da вaltasьn suqa təşergən muzik şikelle ujlanьp jəri. Sin menə yzeŋ ujlap qara. Bezneŋ monda ikənlekne вelep doşman həçym jasasa, nişlif alaвьz?

Jegor. Suqьşьrвьz. Qoral вelən kəceвez çitmi ikən, jodrьq suqьşьna cьqarвьz. Alaj da вulmьj ikən, teşləreвez вelən cəjnəşerвez. Əmma alarqa вireşməвez. Siŋa, Şahвaz, qacmasqa kirək ide.

Şahвaz. Şulaj kirək ide də вit, nişliseŋ...

Jegor. Əle də vaqьt uzmaqan, qajtasьŋ da kitəseŋ. Ləkin şunь isendə tot: revolytsiə vaqьtlarьnda «Doloj qan eckec patşa, jəşəsen revolytsiə» dip soвranielərdə qьcqьruьŋ əcen azancь malajь вuluqa qaramastan, jez mərtəвə şompol вelən suqarlar. Avьl sovetьnda sekretar вulьp eşləveŋ əcen uram catьna вastьrьp atarlar. Ə inde вol'şeviklar вelən monda qacuьŋ əcen ataŋnьŋ qapqa вaqanasьna вəjləp asarlar. Ix, jegetlər, вezgə monьŋ keвek keşelərdən tygel, komissardan yrnək alьrqa kirək.

Şahвaz. Qaja, təməke вir əle.

Jegor. Jegetlər, nigə tьndьqьz, kyŋel acьp alьqьz. Menə ozaqlamьj aş ta əlgerə.

*(Muzьjka, çьr вaşlana).*

Марсель Әхмәтҗан

# ХАТ КАЛЫПЛАРЫ

Хат — кешелек дөньясында бик борынгыдан ук килеп чыккан аралашу чарасы. Әүвәл заманнарда, язу юкта, хат урынына төрле предметлар җибәрә торган булганнар. Борынгы юнан тарихчысы Геродот[1] скифларның иранлыларга хат урынына кош, тычкан, бака һәм уклар җибәрүләрен яза.

Татар халкында кошлар канатына хат язып җибәрү, күгәрченнәр аркылы хат алмашу һ. б. булуы мәгълүм.

Ничәмә дәүләтләр төзү, безнең эрага кадәр үк язу куллану, ерак җирләргә сәүдә белән йөрү, башка илләр белән аралашу ихтыяҗы төрки җәмгыятьтә хат язу традициясен барлыкка китергән. Хат язуның стильләре калыплашкан.

Соңгырак дәверләрдә шәкертләрнең туган йортларыннан аерылып ерак мәдрәсәләрдә укыган вакытларында хат эчтәлеген камилләштерү, күпмедер дәрәҗәдә калыплаштыру өчен мөмкинлекләр ачылган. Чөнки, ни дисәң дә, шәкертләрнең күмәк зиһен җимешләре хат язу даирәсенә керми калмаган. Ерак солдат хезмәтенә эләккән кешеләргә дә матур итеп өйләренә хат язу фарыз эшкә әйләнгән.

Татарча хат язу камилләшүгә күп төрле иҗтимагый сәбәпләр булган. Хат язу традициясе, жанр буларак, татар әдәбиятына да килеп кергән. Аның сакланып калган өлгеләреннән иң әүвәлгесе булып Алтын Урда шагыйре Харәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмасы (1354 елда язылган) санала булса кирәк[2]. Харәзминең бу әсәре назым белән язылган мәхәббәт хатларын хәтерләтә.

XVIII гасыр татар шагыйрьләреннән калган шигырьләр арасында да хат рәвешендә язылганнары бар. Бу очраклылык түгел, бәлки, татар әдәбиятында Харәзмиләрдән бирле килгән традициянең дәвамы булып тора. Мисал өчен XVIII гасырда язылган бер шигырьдән өзек[3]:

Гыйшык улдым сәүмәкдин
Гөл йөзеңне күргәли.
Күзләрең үзбәкенә, һай,
Бәндин сәлам айгали.

XIX гасырда бу традицияне татар шигъриятендә Габделҗаббар Кандалый дәвам иттерә. Археографик табышларыбыз арасында XIX гасыр ахырында күренекле татар педагогларыннан Фәхрелбәнат Сөләйманиянең шигырь белән фарсы телендә язган хаты бар. XIX гасырда язылган оригиналь хат үрнәкләре дә шактый санда тупланды.

Хат язуның бай традицияләре татар халкы арасында гаять киң тарала. Билгеле, шундый шартларда халык арасында хат язу калыплары да туа. Алар ярым назым, ярым нәсер рәвешендә язылганнар. Шулай калыплашкан хатларның төрле үрнәкләре бар. Ул үрнәкләрне рәсми хатлар, гаилә хатлары, мәхәббәт хатлары төркемнәренә аерып карарга мөмкин. Алар арасында иң кызыклылары — мәхәббәт хатлары.

Мәхәббәт хатлары татар әдәбиятының кече жанрларының мөһимен тәшкил итәләр. Искиткеч бай афоризмнар, метафоралар, каламбур рифмалар ярдәмендә язылган мәхәббәт хатларында гүзәл кыз һәм кайнар мәхәббәт тасвирлана. Без монда матурлык төшенчәсен гәүдәләндергән зур һәм бай материалга таянып фикер йөртә алабыз.

---

[1] Геродот. История в девяти книгах. Изд-во «Наука», Л., 1972, 219 б.
[2] Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963, 197—208 бб.
[3] Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен уку материалы. Казан, 1967, 6 б.

Хат язу үрнәкләре татар әдәбиятында XX гасырда киң файдаланыла. Шуна күрә аларның материалын тарихи үсештә анализлап, мөстәкыйль бер әдәби жанр итеп өйрәнү кирәк.

Без түбәндә XIX гасыр урталарыннан калган бер кульязма китаптагы хат язу үрнәкләрен текстологик хәзерләп китердек.

Кульязма үзе 1983 елгы археографик экспедиция вакытында Татарстанның Арча районы Яңа Ашыт авылында Шакиров Зиннурдан алынды. Төп нөсхәсе Г. Ибраһимов исемендәге институтның мирасханәсендә саклана.

## № 1. Хат.

Әссәламегаләйкем вә галә мән ләдәйкем![1]

Сез ки гыйззәтле вә хөрмәтле, вә бәлягатьле[2], вә фәсахәтле[3], вә шәрәфәтле улып торган газиз җан тик күргән былбылым, кара кашым, сандугачым, матурым. Әй җаным, кояш тик көнне йактырткан-балкыткан, ай тик төнне йактырткан нурым, бәгърем, җаным, ике күзем, әй сандугачым, кара кашым, әй күземнең нуры тик күргән җаным вә зифа буйың зифа күрдем, гашыйк булдым, бихуш булдым. Һич ни хәл итәргә белмимен. Аллаһе тәгаля мине гашыйк кылды, Аллаһе тәгаля үзе мине сиңа насыйп итсә иде. Сине табар идем, кичә-көндез синең зарыйлыгың илә Аллаһе тәгалядән телимен. Аллаһе тәгаля кавыштырсын иде. Амин. Йа мөҗиб[4] Алладин. Сәлам яздым сезләргә, кабул итсәңез безләрдән! Бу хатларны кабул итсәңез, Алла разый булсын сезләргә. Әлхәм укыр[5] карлыгач, тәсбих әйтер сандугач, дөнья малы һич кирәкмәс, син җанкаем булмагач. Бу хатымны кабул итеп ала күр, миңа бер кош теледәй хат яза күр!

Ике дә кашың арасы, әлиф-ләмнәр язасың, йар исмен барасы... аласы, әткәнә,— бирсә ярасы.

Ушбуны язгучының исме фәлән атлыдыр, агъзы шикәр-балдин татлыдыр, алдым каләм, яздым сәлам, син җанкайга чыдый алмагач.

## № 2. Хат.

Әл-хат нисфел мөлякат[6]

Әссәламегаләйкем вә галә мән ләдәйкем!

Сез ки фәсахәт былбылы, вә камалят[7] дөлделе, әй җанымның җаны, бәгъремнең пәрәсе, ике күземнең карасы, тәнемнең рухы, оҗмах хуры, изге исемле, гакыллы уйлы, ширин сүзле, камыш бармаклы, көмеш тырнаклы, алтын иякле, көмеш сөякле, дахтәрләрнең[8] изгесе, егетләрнең көзгесе, сәрвәрле заман[9] вә тәхсиле калям[10], җанымның җанына бик күп сәлам.

Сәлам яздым сиңа җаный ошатып,
Төп бу тулган эчләремне бушатып.
Сәлам яздым сиңа, җаный, бәгърем
пәрәсе, кабул әйләсәң, күзем карасы.
Сәлам яздым сиңа, җаный, гүзәлем,
Синең өчен өзеләдер бәнем үзәгем.
Сәлам яздым сиңа, җегет түрәсе,
Синең зифа буең кайдан күрәсе.
Сәлам яздым язган беләң кылма мөлламәт,
Ки булсын без фәкыйрьләрдин бер галәмәт.
Сәлам яздым сиңа, җаный, зифа буй,
Зифа буйыңны бәнем куйныма куй.
Сәлам яздым сиңа, җаный, утырып,
Ике күземне йәш иләң тутырып.

---

[1] Әссәламегаләйкем вә галә мән ләдәйкем — сәлам сезгә һәм сезнең янда булучыларга.
[2] Бәлягатьле — оста телле.
[3] Фәсахәтле — тәмле телле.
[4] Мөҗиб — җавап бирүче.
[5] Әлхәм укыр — Коръәннең алхәм сүрәсен укыр.
[6] Әл-хат нисфел мөлякат — хат-күрешүнең яртысы.
[7] Камалят — житешлек.
[8] Дахтәрләрнең — кызларның.
[9] Сәрвәрле заман — дәрәҗәле заман.
[10] Тәхсиле калям — «Коръән» өйрәнү дәвере.

Аклы ситсы күлмәгемнең өсте итәкле, шуңа ал кояр.
Сөймимен дә түгел, бик сөямен, өйдәгеләр бирми ихтыяр.

Талларга басып, тал тибрәтеп, анда гына сайрый бер тургай.
Көнләрдин көнгә саргаямын, синең гыйшкың саргайта бугай.

Йырактагы йәшелне — кем әйтәдер шуны үлән дип.
Мин сагынган тик син сагынсаң, сиң әйтер идең: «Үләм»,— дип.

Карлыгач кара, буйны ала, тилпенәдер микән очарга.
Алла безгә язган микән, үз хәлалем дибүк кочарга.

Карлыгач күрсәң атып ал, сандугачлар күрсәң сатып ал.
Сагынган чакта бер җырларсың, бу җыруларымны отып ал.

Бакылдый үрдәк, бакылдый пиби, бибигайшә дигән күлләрдә.
Утсыз да яндым, сусыз көям, син җанкаем исемә төшкәндә.

Ишек алларым биш киртә, сандугачлар куна кич-иртә.
Син җанкаем берлән бер кавышсак, гомерләребез үтәр бик иркә.

Алтын да ияр, ал да мендәр иярләп куйдым чаптарга.
Кара кашым, карлыгачым, әйләнә күрмә йатларга.

Карчыга каенның башында, канатлары айның кашында...
Сөешеп-сөешеп кавышмый калсак, ни әйтербез ходай каршында!

Питербург монда ничаклы, әйләнәсе шуның чачаклы.
Зөләйха Йосыфны ничек сүде, мин сөйәмен сине шул чаклы.

Бәнем дә чәчем — болындай, бөгәрләнеп яткан җыландай.
Бән сәне дә сагынамын, бишектә йаткан оландай.

Гөл бакчасының эчендә кемләр баскан камчат эзенә.
Ташламам дибүк вәгъдә куйдың, карама, җанкай, дошман сүзенә.

Тәрәзәләрдин карашыйк, бармаклардин балдак алышыйк.
Кара да кашым, карлыгачым, ни хыяллар берлән кавышыйк.

Гөл бакчаларында кемләр йөри ике кулларына гөл учлап.
Син җанкай берлән бер кавышсак, әллә йоклар идек тынычлап.

Камчат та бүркең күтәр, күтәр, ике каш араларындин җил үтәр.
Бу дөньялар бездин үтәр китәр, сөеп кавышканга ни җитәр.

Гөл бакчаларына керү берлән гөл чәчәгенә буйалам.
Син җаныкаем исемә төшкәч, йокыларым качып уйанам.

Бу хатымны кабул итеп аласың,
Кош теледәй (җавап язып саласың!)

Һавалардин очкан ике кош, берсе генә бәйле, берсе буш.
Дөшемдә күрсәм, күңлем хуш, уянып ла китсәм, куйным буш.

Атлар җиксәң, җик яхшысын, дугалардин биек башлысын.
Йарларны сүвсәң, сүв матурын, ханәфердин кара кашлысын.

## № 3. Хат.

Сез ки гыйззәтле вә хөрмәтле улан, җан тик улан күрекле әткәмез һәм раушанә[1] ак сүекле әнкәмезгә безки углыңыз Мөхәммәдкамал илән Әхмәтҗандин...

[1] Раушанә — нур иясе.

Һуаллаһи әл-мөстәган[1]

Әссәламегаләйкем вә галә мән ләдәйкем! Сез ки гыйззәтле вә хөрмәтле улан, җан тик күрүче әткәмез хәзрәтләренә бик саргаеп, бик сагынып бик күп догаи сәламләребезне ирсал вә тәблигъ әйләдем[2], вә Алла ушандак[3] сувекле мөшфика[4] әнкәмезгә...

## № 4. Хат.

Һуаллаһи әл-бари[5]

Сез ки гыйззәтле вә хөрмәтле, олуг мәртәбә иясе газиз әткәемез илән газиз әнкәемезгә мәзкүр углың Гомәрдән бик сагынып, бик саргаеп, бик күптин күп сәламнәребезне ирсал вә тәблигъ әйләдем, вә газиз... әбиемезгә сагынып бик саргаеп бик күптин күп сәламнәремезне ирсал вә тәблигъ әйләдем.

## № 5. Хат.

Әл-хат нисфел мөлякат

Әй фәсахәт былбылы, сез ки фәхриҗиһан[6] сәрвәре[7], заман дин тоткасы, гыйбадәт иясе, ике күземнең нуры, оҗмах хуры, бал-шикәр иренле, инҗү дешле, сөчих сүзле, тәмле телле, камыш бармаклы, көмеш тырнаклы, камил гакыллы, зифа буйлы, тал-чыбыктан зифа буйлы, кара кашлы, кара күзле, түгәрәк йөзле, ганҗә агызлы, нечкә билле, алтын иякле, асыл сөякле, ахак йөрәкле. Ай, җанашым, кара кашым, карлыгачым, алма битем, тәти кошым, син алтын битем, гөл йөзем, һәр кич көндезем, сән тагать[8] пәлләшәсендә[9], хәйрат[10] әндишәсендә[11] кулым оргучысән, әв хак әл-хамилә Гали[12] исмен әй газизем вә сахибе тәмиеземсән[13] газиз җанашымның чыннан вә чыннан илтифатыңызны үтенеп, сезләрнең җанәбе галияләремезне хәер фатихаларымызны китабәт кылып[14], сезләрнең хәер фатихаларыңызны үтенеп, бик сагынып, бер күреп сөйләшәргә зар булып, һәр кичәдә вә көндезендә син җанашымның гыйшкы илән бәгърем көеп, нурлы йөзем саргайып, ашамактан-эчмәктән мәхрүм булып, камил гакылларымдин мәхрүм булып, бихуш булып һаир догаи сәламләребезне күндереп, зинһар, һәрничек булса да, гаеп кылмайсызлар. Җаным җиһанымның әрвакы, җисемемнең шавкысы, җәннәт хуры нәбиеңез иш, һич тә йук сиңа тиңдәш. Әй җанымсән, кайсы багның гөл гөле сән? Кайу чар[15] багының былбылы сән? Кайу йыгачның[16] шәҗәре[17] сән? Вә су синең матур, гүзәл сыйфатыңны һич мөмкин дәгел телемездә фикер идеп вә күңлемездә фикер идеп бетермәккә һич мөмкин дәгел, телемез илән тәкърар кылмак һич мөмкин дәгел. Ак кәгазьгә дифтәр кылып бетермәгә, һич мөмкин дәгел, гәрчә агачлар каләм улса да, җир йөзендәге дәрьялар кара улса да, адәмиләр вә пириләр йазгучы улса да, һич төкәтеп бетерә алмагайлар, вә кинә мөмкин кадәренчә гаепкә бойурмасаңыз, үзем эчүмдәге серемне син газиз сылу җанкайыма мәгълүм кылмак өчен бер-ике хәреф кенә улса да бер кош теледәй намә йазып җибәргән идем, һәр ничек улса да, гаепкә бойурмаңыз. Хак тәбарәкә вә тәгаляне бер дип белмәй, үзеңезне зур күреп, без фәкыйрь әл-хакыйрьне хур күреп, Газраил кеби тәкәбберлек кылып, перпуайлык кылмайсән. Әчтерханларның чиясен, ачы була, диләр,— пешмәсә, бу кадәр...

---

[1] Һуаллаһи әл-мөстәган — Алладан ярдәм көтүче зат.
[2] Ирсал вә тәблигъ әйләдем — җибәрдем.
[3] Ушандак — шулай ук.
[4] Мөшфика — шәфкатьле.
[5] Һуаллаһи әл-бари — юктан бар итүче алла.
[6] Фәхриҗиһан — хөрмәтле дөнья.
[7] Сәрвәре — дәрәҗәле кешесе.
[8] Тагать — буйсыну.
[9] Пәлләшәсендә — үлчәү тәлинкәсендә.
[10] Хәйрат — хәер.
[11] Әндишәсендә — борчылуда.
[12] Хак әл-хамилә Гали — хаклыкны өскә күтәрүче Гали.
[13] Сахибе тәмиеземсән — аралый белүче син.
[14] Китабәт кылып — язып.
[15] Чар — патша.
[16] Йыгач — агач.
[17] Шәҗәре — агачы, ботагы.

Китап күзәтү

# ЯКТЫРТА ДА ЯШЕН, ЯНДЫРА ДА...

Яшь шагыйрь Рөстәм Сүлтинең 1992 елда Казанда басылып чыккан «Мин — шигырьдән» исемле беренче китабы турындагы сүзне менә бу әсәреннән башлап китәсе килә:

*Чатыр корыйк, әйдә, казан асыйк.*
*Кадап куйыйк әле яшел әләм.*
*Күздә шатлык яше...*
*Иделкәйдән*
*Су китерәм кәләпүшем белән.*

Китаптагы байтак әйбәт шигырьләр арасыннан нәкъ менә шунысына тукталуыбызның сәбәбен кайберәүләр, бәлки, бүтәнчә аңлатуны көтәдер. Чөнки биредә безнең күңелне публицистика юлына алып кереп китәргә ымсындырып торган «яшел әләм», «кәләпүшем» һ. б. гыйбарәләр бар. Ләкин, газета-журналларыбызда соңгы елларда шактый актив рәвештә алга сөрелгән милли идеяләргә һич тә кырын карамастан һәм бу шигырьдә андый «үтә милли» сүзләрнең кулланылуын бер генә дә артыксынмыйча, шулай да әсәрнең иң төп уңышы башка нәрсәдә дип аңлатасы килә.

Ә нәрсәдә соң? Минемчә, эш шунда: яшь шагыйрь безнең чор тормышында һәм күңелләрдә кайнаган идеяләрне, уйхисләрне бик тә шигъри, тәэсирле **күренеш итеп** җанландыра алган. Автор публицистик чакырулар, өндәүләр һәм мөрәҗәгатьләр яссылыгыннан өскәрәк күтәрелгән һәм әйтер сүзен югалтмаган хәлдә, шигъри кичерешләр, күренешләр биеклегендә поэтик яшәү таба алган.

Мөгаен шуңа күрәдер, яшь шагыйрьнең беренче китабын ачып җибәрүче иҗаты да чын публицистик әсәрләр түгел, ә җанга, бәгырьгә, җырга, моңга багышланган шигырьләр. Шулардан берсе — «Мәрхәмәт» дип исемләнгән:

*Учагына, кочагына алган,*
*Таныш-туган түгел, чит кеше.*
*Даны да юк, малы да юк аның,*
*Ул бит бары — Вәли-читекче...*

Сәяси гарасатлар һәм экономик кризислар чоры шагыйре Рөстәм Сүлти әнә шундый юллар белән безнең игътибарыбызны Тукайны тәрбиягә алган Вәли абзыйга юнәлтә. Менә шушы хәл үзе үк яшь иҗатчы хакында күп нәрсә сөйли түгелме?! Иҗатчының ныклы иманы, әхлакый мәккәсе, гуманистик идеалы — барысы да ачык чагыла түгелме шушы күренештә?

Юк, көндәлек тормышта безне борчыган сәяси һәм социаль вакыйгаларны да икенче планга күчерми Сүлти. «Мәскәү феномены» шул хакта сөйли:

*Саумы, Мәскәү, килдем менә сиңа.*
*Мин әле бу — «Казан феномены».*
*. . . . . . . . . . . . . . . .*
*Кем теләге кабул?*
*Саумы, Мәскәү,*
*Гаҗәпләнмә, бу мин — феноменың.*

Биредә шигърият ягыннан алганда әллә ни мактанырлык урын күренмәсә дә, укучыны гадел һәм намуслы сүз пафосы, ялкыны җәлеп итә. Монда без Маяковский һәм Евтушенколар, Такташлар иҗатында балкыган көрәшче йөрәк ритмын тоябыз. Әнә шундый йөрәк дулкыннары укучы күңелен битараф калдырмый.

Өченче бер мизгелдә инде Р. Сүлти гасырларны кичеп, гаять зур акыл-тәҗрибә туплаган аксакал тавышы белән сөйли башлый:

*Олы юлдан килә ялгыз кәрван,*
*Алыслардан бугай, бигрәк арган.*
*Ашыгасың кая, юлың кайдан,*
*Әйтче, зинһар, әй, адашкан кәрван.*

Шигырь сөючеләр өчен бу кәрван — гади төркем генә түгел. Бүгенге сәяси хәлләрне истә тоткан укучы өчен әлеге кәрван, барыннан да бигрәк — милләт! Биредә дә яшь шагыйрь үзе әйтергә теләгән фикерне чакыру-өндәү юлы белән түгел, ә бәлки шигъри күренеш аша җиткерә. Милли моңга, шәрык аһәңенә төреп бирә ул үз идеясен! Әнә шуңа күрә — татар укучысының милли хасиятен һәм аның шигъри «организмы»ның аерым үзенчәлекләрен нык искә алып эш иткәнлектән — аның безгә йоттырырга теләгән «ризыгы»да теләбрәк кабул ите-

лә һәм безнең аңыбыз тарафыннан яхшырак үзләштерелә.

Менә шушындый күзәтүләр бу китаптагы байтак әсәрләрне укыганда күзгә ташлана. Вакыты-вакыты белән, кайбер башка яшь шагыйрьләрне дә искә төшерә-төшерә, шулай уйлап куярга да җөрьәт итәсең: «Безнең әдәбиятта һәм шигърияттә милли тематиканы үзләштерүнең икенче баскычына күтәрелү процессы бара, ахрысы... Сүзләр һәм өндәүләр яссылыгыннан, шигъри кичерешләр һәм күренешләр биеклегенә күтәрелү...»

Әйе, китапка «Мин — шигырьдән» дигән бик тә янача яңгырашлы һәм кыю исем куелса да, гәрчә бу исем үзенең эчтәлеге белән шигъриятькә таба гына ымласа да, ләкин, чынлыкта, андагы әсәрләр — бүгенге сизгер күңелле кешенең йөрәк тибешен киң чагылдырган шигырьләр. Анда замананың гамьле шәхесен борчыган бик күп кичерешләр сыйган, урын алган. Әмма шулай да, иң урталагысы, иң үзәккә үткәне — милләт язмышы.

Бу язмабызны башлап киткән «Зимагуркай, кайт иленә» шигырендә тагын менә мондый юллар бар: «Кайт иленә, кайт денеңә. Кайт телеңә, зимагур».

Игътибар итәсезме: безнең бүгенге газеталарда адым саен диярлек кабатлана торган «манкорт» дигән төшенчә яшь шагыйрь иҗатында нинди авылча, нәкъ үзебезчә яшәү таба алган. Чыннан да, әлеге әсәр манкортларга багышланса — коры бер өндәмә генә булып калыр иде. Ә яшь шагыйрь аның, әлеге манкортның, безнең авылларга килеп ялганучы язмыш сукмагының башын таба алган.

Зимагурлык, манкортлык... Татар халкының кара язмышыннан килеп чыккан кара сакалы... Без үзебезнең язмаларда: «Нишләп соң безнең милләт бик тә чәчелгән?» — дип сорау куябыз да, ни өчендер шул соравыбызга җиңелчә генә җавап биреп үтәбез. Янәсе, безнең бабайларга акыл җитмәгән... Ә бит биредә шактый объектив сәбәпләр дә күренеп тора. Галимнәрнең өлешенә кермәстән, сүз уңаеннан үз фаразымны белдереп китим. 1. Безнең геннардагы күчеп йөрү традициясенең чагыштырмача озак саклануы. 2. Төрле кабилә һәм ырулардан оешкан милләтнең тарихи шартлар мөмкинлек бирмәү һәм моңа вакыт житмәү сәбәпле, тәмам укмашып, ныгып бетә алмавы. 3. Татарның урыс өчен бик көчле һәм мәңгелек көндәш булу сәбәпле, урыс хакимияте тарафыннан аның аеруча нык изелүе, кысылуы — шуның аркасында төрле җиргә чәчелергә мәҗбүр ителүе. 4. Зур халыкның, күпсанлы татарның үзенең дә кечкенә Татарстан республикасы кысасына гына сыеп, сыешып бетә алмавы... Менә шушы дүрт зур сәбәп, минемчә, татарның бик нык чәчелүен китереп чыгара. Язмыш. Тәкъдир!

Шагыйрьнең зимагурлар турындагы бер шигырен укыганда күңелдән әнә шундый уйлар йөгереп үтә. Шул ук вакытта бу әсәр безнең һәммәбезнең кечкенә чагында Идел, Чулман буйларында көймә көтеп, учак ягып, казан асып ятуларыбызны да күз алдына китерә. Ягъни без дә кайчандыр нәни зимагурлар булмадыкмыни да, һәм менә хәзер, үсә-үсә генә чын татарга әйләнә бармыйбызмыни?! Шушы шигырь мисалында без поэтик фикернең төрле яссылыкларда үсүен, яшәвен күрәбез. Алар бер-берсен тулыландыра, көчәйтә, баета.

Тематик яктан алып караганда Рөстәм Сүлти китабында бик зур яңалыклар бар дип әйтеп булмыйдыр, мөгаен. Һәм моның өчен аны битәрләргә дә ярамый. Чөнки вакытлы матбугатның давыллар куптара-куптара шаулаган мондый чорында, инде беркем тарафыннан да әйтелмәгән сүзләр, кузгатылмаган темалар калдымы икән? Юктыр!

Шулай да, яшь шагыйрьнең бу китабында чор тормышының социаль каршылыкларына һәм милләтебезнең хәленә аерым игътибар бирелгәнен күрми калу мөмкин түгел. Иҗатчының социаль һәм сәяси фикерләү сәләте дә көчле, андый мәсьәләләр күтәрелгәндә, уйлар гел дә гаделлек һәм объективлык бизмәне аша үткәрелә. Ниндидер субъективлык төсмерләре сизелми. Чын иҗатта бусы да мөһим. Югыйсә, вакыт узу белән әсәрләрең искерергә дә мөмкин.

Шагыйрьне үзенең һәм милләтенең өч төрле бәйләнештәге урыны, хәле кызыксындыра: галәм тормышы һәм без, ата-бабалар юлы һәм без, башка милләтләр яшәве һәм без. Күренеш һәм вакыйгаларны әнә шундый күпьяклы бәйләнештә карау һәм тикшерү аңа үз әсәрләрендә дөрес кыйбланы табарга да булыша.

Арадан берсе — аталар һәм бабалар юлына тугрылык — әсәрләрдә бигрәк тә еш күтәрелә.

*Баса җирне иманбуар туфан*

. . . . . . . . . . . . . . . .

*Исән калсын халкым.*
*Әй, пәйгамбәр,*
*Коткар безне, коткар, Рух көймәсе!*

Тереклек иярен су басудан саклап калган Нух пәйгамбәргә аваздаш итеп, Р. Сүлти әнә шундый яңа образ — Рух пәйгамбәрне иҗат итә. Безнең татар

милләте өчен бигрәк тә кирәк бу. Чөнки матди яктан бик алга киткән Көнбатыш та бүген рухи кризис кичерә. Алар күбрәк товар житештерүдән башканы белмиләр. Рухи кыйблалары юк. Рәсәй дигән йөгәнсез ил, стихия безне дә әнә шундый юлга таба тарта, этәрә.

Ә менә чын ижатчыларыбызның һәм, аерым алганда, Р. Сүлтинең әлеге шигырьләре безнең милләтне дөресрәк юлга юнәлтә. Матуррак, иманлырак юлга. Гаделрәк яшәү юлына. Ата-бабаларыбыз юлы да рухи яктан бай һәм иманлы яшәүгә таба ымлый, чакыра.

Гомумән, яшь шагыйрьнең иң яхшы әсәрләре безнең халкыбызга һәм традицион поэзиябезгә хас булган асыл сыйфатлар белән бизәлгән.

*— Күбәләк булып кайтырмын,*
*Елама, балам,— диде.*
*Җәй җитте... Сабый һәрвакыт*
*Нәрсәдер эзли иде.*

*Көз инде... Шыксыз зиратның*
*Почмагына чүгәләп,*
*Кайнар тынын өрә сабый —*
*Учларында күбәләк.*

Барысы дүрт куплеттан торган шигырьнең уртадагы ике строфасы гына бу. Күргәнегезчә, автор кайбер яшь каләмдәшләре шикелле, гади халыкның гади яшәешеннән дә читләшми. Кайбер ижатчылар «примитив» тамгасы сугарга ашыккан, яисә «мелодрама» бәһасен бирергә теләгән күренешләргә Р. Сүлти өлкәннәрчәрәк, сабыррак карый. Кылтымлыктан һәм «отышлы» позалардан ерак торган әнә шундый холкы белән ул ижатта зуррак перспективалар турында уйлата, күңелне әнә шундый ераклыкларга ымсындыра...

Хәзерге шигырь турындагы уйлануларда бу темага шактый еш кагылырга туры килә. Моны тормыш үзе дә мәжбүр итә шикелле. Чөнки без бүген реаль чынбарлыкта да, әдәбиятта да иң чын, иң ышанычлы һәм иң үзебезчә булган юлларны эзлибез. Элеккерәк елларда өзелгән юлларның кайсысын дәвам итеп китәргә, дип баш ватабыз. Әмма соңгы еллар чынбарлыгы ышанырлык итеп шуны раслый: татар халкы өчен дә, татар әдәбияты өчен дә иң ышанычлы юл — традицион юл, аталарыбыз һәм бабаларыбыз барган юл! Һавадагы торнага кызыгу безне бары тик адаштырачак кына, читкә генә алып китәчәк! Без үз халкыбыз белән бергә һәм аның юлыннан барырга тиеш!

Әйе, мондый теләк матур, билгеле. Ләкин менә ул чынлыкта ничек тормышка аша соң? Соңгы елларда поэзиягә килгән яшь шагыйрьләр безнең поэзиянең халыкчанлык, тормышчанлык көчен арттырдыларммы? Хәзерге татар шигъриятенә тагын да тирәнрәк һәм драматиграк Моң алып килдеме алар? Шигъриятнең үзәге булган Хисне, Кичерешне көчәйттеме?

Бередә кыска гына итеп әйтсәк: без теләгәнчә үк түгел! — дияргә туры килә. Замананың кырыслыгы, рациональлеге, артык практиклыгы — яшь шагыйрьләребез ижатында үзен бик нык сиздерә шул. Мөдәррис Әгъләмовлар һәм Зөлфәтләр язган беренче шигырьләр белән Ркаил Зәйдуллиннар, Газинур Моратовлар һәм инде менә безнең Рөстәм Сүлтиләр язган әсәрләрне чагыштырып, янәшә куеп карасаң — хисләрнең нык саегуын, гармониянең шактый җимерелүен, моң дигән тирән дәрьяның да «логик фикерләү» дигән салкын таш ярга таба авышуын чамалыйсың... Әйе, моңа тормыш агышы гаепле, ул сәбәпче. Ләкин мондый аңлату гына әсәрләрдә шигърият җитмәү дигән яман чирне аклый аламы соң? Бу инде шәһәр җирендә кислород җитмәгән шикелле. Сәбәбен дә белеп торасың — ләкин түзүе, шуңа күнегүе кыен!

Шәһәр җире дигәч, җәйге дачалар искә төшә... Җәйге болыннар хәтердә яңара... Чын яшәү, чын тормыш күз алдына килә! Безнең бүгенге поэзиядә кызлар ижаты да әнә шулай: тынчу һавалы шәһәрдән табигать кочагына чыгу кебек тәэсир калдыра! Бередә табигыйлек, гүзәллек, ихласлык. Моң һәм сөю, моң һәм чын трагедия дә, кешечә кайгыру һәм кешечә сөенү дә бередә күбрәк, мулрак!

Шуңа күрә Р. Зәйдулланың әдәби ел йомгакларында хатын-кыз шагыйрәләр ижатына карата әйткән сүзләре белән күпләр килешмәс дип уйлыйм. Хатын-кыз шагыйрәләр хискә-кичерешкә сизгеррәк алар. Нечкәрәк һәм тирәннәнрәк килгән моң саркый аларның әсәрләрендә. Салкын акыл һәм рационализм да (яшь шагыйрьләр ижатына иң зур зыян китерүче нәрсә!) аларда бөтенләй булмый диярлек!

Сүз уңаеннан, быел телмәр тоткан шагыйрьнең тагын бер фикере белән килешмим. Безнең бүгенге шигърияттә һич кенә дә кризис юк! Тормышта кризис бар, Рәсәйнең сәясәтендә кризис бар. Әмма безнең татар әдәбиятында һәм бигрәк тә поэзиясендә андый хәлнең булганы юк. Бик күп тавыш куптарган «Шигъри бушлык» исемле мәкаләдә дә, байтак шагыйрьләрнең көпшәк әсәрләре телгә алынуга карамастан, хәтта торгынлык елларына карата да андый нәтиҗә ясалмаган иде! Ә бередә Р. Зәйдулла

соңгы елларны «поэтик кризис чоры» дип атамакчы! Монын дөрес түгеллегенә ышану өчен «Казан утлары»нда басылган шигырь тәлгәшләрен һәм «Ватаным Татарстан» алып барган «шигъри бәйге»не белү дә житә... Кыскасы, байтак кимчелекләре булган хәлдә, татар поэзиясе, барыбер әдәбиятның иң көчле тармагы ул! Бу — бәхәссез хакыйкать!

Рөстәм Сүлтинең без сүз алып барган бу китабында яшьлек рухы нык сизелә. Һәм ул рух менә мондый рәвештә дә күренеп ала:

*Күк карынында яшен тыпырчына,*
*Туасы шул килә, күрәсең...*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

*Гомер — мизгел... Тик туасы килә*
*Япь-яшь яшен, яшә...*
*Һай, әрсез,*
*Мизгел гомере белән мең яшәгән*
*Иманнәрне штә гомерсез.*

*Кичерегез, беркемнең дә гомерен*
*Күпсенмимен...*
*Ләкин ян, иман.*
*Шушы дегет — төннең бер мизгеле*
*Көндә кушылганда*
*«эх» димәм...*

Бирелә, иманнәр януын хуплауны күргәч, безнең матбугатта кырмыска оясын туздыруның зыяны турындагы бәхәс искә төшә. Т. Миңнуллин бер яшь шагыйрьне төзәткән иде. Ул чакны мин үзем дә өлкән әдип ягында булдым. Әмма менә хәзер, икенче бер яшь шагыйрьнең тегенә аваздаш бүтән әсәре уңае белән, мондый фикер дә белдерәсе килә: «Яшьлек» дигән ташкын ул, күрәсең, яхшылык һәм гаделлек кысаларына, ярларына гына сыеп бетә алмый. «Файда» яисә «зыян» дигән кануннар яшь кешегә күп чагында ят тоела. Аның боларга баш иясе килми, баш бирәсе килми! Әле ул тәртә арасына кермәгән яшь тай бит! Шагыйрь бер дә юкка гына: «яшиселәр килә, күрәсең!» — дими ич... Димәк аның өчен һәм, гомумән, яшьләр өчен, яшәү процессы үзе мөһим, үзе кадерле! Ә инде «дөрес яшәү» — монысы инде соңрак!

Тормышның төрлелек белән матур булуын истә тотсак, без дә яшьлекнең байтак гөнаһларын кичерергә тиеш булырбыз...

Монысы шулай, ләкин менә яшь шагыйрь иҗатында мәхәббәт хисенең көтелгәннән азрак күләмдә булуын кичерергәме соң?! Сүз чыкканда, тагын бер гомумиләштерү ясала: ә бит бүтән яшь шагыйрьләрдә дә хәзер мәхәббәт тематикасы бик тә саекты! Куркыныч дәрәҗәдә саекты! Ә менә кызларыбызда бу агым, ходайга шөкер, көчле. Алар поэзиясенең иң көчле ягы да әнә шулдыр әле — мәхәббәттер. Мәхәббәт бәхетләре һәм трагедияләредер.

Безнең кайбер шагыйрьләребез аларны әнә шул мәхәббәт шигырьләре өчен яратмыймы икән әллә? Алай дисәң — бу бит ясалма тормыш китереп чыгарырга маташу сыман! Тормыш мәхәббәткә нигезләнеп, табигый рәвештә һәм матур дәвам итә алганда, нигә әле салкын акылга гына таянган яңача «тормыш» уйлап чыгарып маташырга икән?!

«Мин — шигырьдән» дигән китапта, көчле мәхәббәт һәм аның трагедияләре хакында әсәрләрнең бик аз булуы автор тарафыннан исем итеп куелган сүзләргә бераз шик тә уята. Мәхәббәтсез шигърият була ди мени?!

Табигать турында да шундыйрак нәтиҗә ясарга туры килә. Яшь шагыйребез татар милләтенең «яшел бишеге»н бөтенләй диярлек күрми. Әллә аның табигатькә багышланган гүзәл әсәрләре булганмы? Алар бары тик бу китапка гына керми калганмы? Ай-һай, моңа ышануы кыен...

Туган табигатьтән аерылганлык һәм мәхәббәт темасының үтә сайлыгы — болар икесе дә бүгенге шигъриятнең бер үк авыруы. Дөресрәге, болар бер авыруның ике төрле исеме. Ә ул авыруның исеме: табигыйлек, ихласлык, эчкерсезлек кимү... Иң олы кешелеклелек тә әнә шулар янәшәсендә генә. Югалып баручы шул асыл байлыклар, хәзинәләр янәшәсендә генә...

Яшь шагыйрьнең бу китабында «җырлап торган» шигырьләрнең азрак булуы, көтелгәннән кимрәк күренүе дә, әлеге дә баягы табигыйлек, гармония, шигърият кимрәк булганга күрә. Замана баласе!

Китапта урын алган зур күләмле әсәрләрдән «Кый-гак-к!» дигән балладаның һәм «Тәрәзә» дигән поэманың уңышлы чыгуын әйтергә кирәк. Р. Сүлтинең эпик жанрда эшләү сәләте зуррак дигән нәтиҗә ясарга да мөмкин. Бу юнәлештә аңа кыюрак иҗат итәргә кирәктер.

Соңгы сүз дип нәрсә әйтергә?

Әйе, безнең алда замана шагыйре үзенең бөтен кимчелеге һәм яхшы яклары белән — ул менә шундый. Рөстәм Сүлтинең шигырьгә, иҗатка җаваплы каравы күренә. Хәтта артыграк җаваплы карап, ул үзенең беркатлы һәм иң саф, иң садә хис-кичерешләрен йөгәнләмиме дә икән әле?! Кайвакыт шундый тойгы да туып куя. Әдәбият ул — күңел дөньясы — анда берничди дә чикләү, курку һәм үз-үзеңне тыю булмаска тиеш! Безнең чорда көчле акылның тыюы — бигрәк тә начар! Хисләрнең табигый ташкыны гына булырга тиеш шигырьдә!

Әнә шул чагында ерактагы яшеннәр безне җылыта торган утка әверелер. Әнә шул вакыт шигырь үзе дә җылырак һәм моңлырак булыр...

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# ӘДӘБИ ГЕРОЙЛАР — ЗАМАНДАШЛАР

«Казан утлары»н мин күптән һәм яратып укыйм. Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәш, татар халкының фәнни, объектив чыганакларга таянып язылган тарихы, милләттәшләребезнең иҗтимагый-сәяси тормышы һәм әдәби эшчәнлеге турындагы материаллар үзләренә аеруча җәлеп итә.

Зур күләмле әсәрләргә караганда, документаль фактлар китерелгән, мемуарсыман нәрсәләрне укырга яратсам да, журналның үткән елгы 9—10 нчы саннарында басылган Әнәс Галиевның «Авылдашлар»ына күзем төшкәч, ул романны укырга керештем.

Мин авылда туып үскәнгә, бәлки, романның исеме кызыксындыргандыр. Әллә әсәрнең баш геройларыннан берсе Әлфиянең унынчы классны бетереп, өлгергәнлек аттестаты алгач, бер чиләк йомырка күтәреп, Казанга имтиханнар бирергә дип тимер юл станциясенә кадәр егерме чакрым җирне җәяү баруымы? Бусы безнең башлардан да үткән хәл... Әллә башка нәрсәме?.. Белмим, тик бер укый башлагач, туктый алмадым.

Романда сүз бер авылда туып-үскән кешеләрнең күп сәбәпләр белән илебезнең төрле почмакларына таралышып, һәркайсының үзенә генә хас булган юллар белән Казанга кайтулары, андагы сәүдә, финанс органнарында, базарда хезмәт итүләре, үзара мөнәсәбәтләре турында бара.

Кемнәр соң алар, авылдашлар? Шуларның берничәсенә генә тукталып китик.

М а н с у р. Утызынчы елны «кулак, сәүдәгәр», дип авылдан сөрелгән Сабит исемле кешенең улы. Малайга ул вакытта ун яшь була. Аның әтисен Енисейск шәһәреннән конвой астында урман кисәргә йөртәләр. Әтисе дә, әнисе дә үлгәч Мансур туган якларына кайта, ләкин бәхет күрми. 1940 елны Совет армиясенә алына. Фронтта ике мәртәбә җәрәхәтләнә. 1945 елны рейхстаг стенасында имзасын калдыра. Казанда институт бетерә. Шук ук институтта хуҗалык мөдире булып эшли. Диссертация яза, ләкин «халык дошманы» токымыннан булганга, төрле сәбәпләр табып, аңа байтак вакыт диссертация якларга мөмкинлек бирмиләр, хезмәтеннән дә куып чыгаралар. Ул төрле оешмаларда, шул исәптән йөкче булып эшләргә мәҗбүр була.

Г ө л с е м — тугыз балалы гаиләдә иң олысы. Аның әтисе Сәфәр абзый үтә уңган, бик тырыш авыл кешесе. Революциядән соң җир җан башыннан (хатын-кызларны да исәпкә кертеп) бүлеп бирелде. Үзенең тырышлыгы аркасында ул ел саен югары уңыш ала. Бер елдан атлы-сыерлы була. Тора-бара атны ике, сыерны өч үк итә. Кием-салымнары әллә кем булмаса да, тамаклары бөтәя. Нарат бүрәнәләрдән алты почмаклы йорт сала. Иске йортны келәт итәләр. Мунча да салып куялар. Зур өметләр белән, ару-талуны белмичә эшләгәндә, ап-ак дөнья караңгыланып китә: утызынчы елның җәендә Сәфәрләрнең бар мөлкәтләрен тартып алып, аларны гаиләсе белән авылдан сөрәләр. Тик житкән кызлары Гөлсемне генә, саклап калу өчен, тормышка бирергә булалар. Ул авылда кала, Колчак тылында партизан булып йөргән, гражданнар сугышында катнашкан партия әгъзасы Фәтхигә тормышка чыга. Кулак кызын сөргеннән йолып алганы өчен, Фәтхине кат-кат районга чакырталар, партизан дип тормыйлар, партиядән куалар. Аның түземлеге бетә һәм ул Гөлсемен житәкләп шәһәргә китә. Анда алар йорт салалар, сыер сатып алалар, сөт-майлы булалар. Сугыш башлангач, Фәтхи фронтка китә һәм аннан «ирегез батырларча сугышып үлде» дигән кәгазь китерәләр.

Гөлсем ике бала белән утырып кала. Алар икесе дә югары белем алалар, әйбәт кенә үз гаиләләре белән берсе Себер ягында зур заводта эшли, икенчесе

Ташкентта яши. Гөлсемнән хәзер авылдашлары өзелми. Аның йорты зур, күңеле киң. Аңа кем тели, шул килә. Кинәш кирәкме, балалар бакчасына урнаштырып булмаганда, баланы карап торучы кирәкме, башка йомышларың бармы,— син Гөлсем апага килә аласың. Дөньяның ачысын-төчесен татыган, күпне күргән бу акыллы, түзем татар хатыны сезне ачык чырай, тәмле чәй белән каршы алыр, кайгыгызны уртаклашыр, файдалы киңәшләр бирергә тырышыр.

Югарыда исеме аталган Әлфия яшь әле. Тик аның тормышында да каршылыклар очраштыргалый тора. Базарда бераз эшләп караганнан соң, андагы башбаштаклыкны күргәч, ул аннан китәргә мәҗбүр була. Үзе теләгән институтка керә алмагач та, белем алудан баш тартмый, изрәп төшми, билен бөкми. Читтән торып булса да, финанс-экономика институтына укырга керә һәм шул ук вакытта инспектор ярдәмчесе булып, райфода эшли башлый. Аның тормышы җиңел түгел. Тик ул да авылдашы Гөлсем апа кебек тырыш. Теләгән нәрсәнең очына, авыр булса да, үзе барып чыгарга тырыша һәм теләгәненә ирешә.

Аның тормыш юлында яхшы, ышанычлы кешеләр очрый, кирәк вакытта алар аңа ярдәм кулын сузалар. Ул кешеләрнең берсе — Мансур. Әлфия белән Мансур өйләнешеп, яңа гаилә корып җибәрәләр.

Ә. Галиев романында Бөек Ватан сугышы елларыннан соңрак вакытта булган тормышыбызның кайбер яклары бик ачык, реаль итеп күрсәтелә. Анда кайберәүләрнең бер-беренә усаллык эшләве, үзара алдашу, спекуляция, ришвәт алып торулар, фахишәлек һәм башка шундый безнең бүгенге чорда да бөтенләй үк сирәк булмаган нәрсәләрне очратырга мөмкин. Аерым фактлар, моннан кырык еллар элек булуына карамастан, шундый дөреслек белән күрсәтелгәннәр ки, гүя алар бүгенге тормыштан алып тасвирланганнар, диярсең. Ә әсәрдә китерелгән фактлар, чыннан да, булды. Аларны Казанда гына түгел Самарада да, Мәскәүдә дә, Петербургта да, Барнаулда һәм башка шәһәрләрдә дә очратырга мөмкин иде.

Тискәре геройларның берсе — Юныс Гыйльметдинов. Әлфиянең апасы Зәйтүнә әйтмешли, ул «бик зур нәчәлник. Райфода өлкән инспектор. Безнең барыбызны да тикшерүче». Әлеге «бик зур нәчәлник» үзенең хезмәт урыныннан законсыз файдаланып, кыз-хатыннарны эшеннән кудырам, судка бирәм, дип куркыта, алар белән бертуктаусыз эчеп, зина кылып йөри. Ришвәт алудан да баш тартмый. Шуның өстенә — хәйләкәр дә, алдакчы да. Белемсез һәм осталыгы чикле булса да, үзе һаман райфо мөдире булу турында хыяллана. Соңгы чиктә финанс министрлыгы ясаган ревизия материаллары буенча аны эшеннән куалар.

Роман чынбарлыкны дөрес чагылдыра. Анда укучыга тирән тәэсир итәрлек вакыйгалар китерелгән. Композициясе уңышлы. Теле халыкчан. Шул ук вакытта әсәрнең житешсезлекләре бөтенләй үк юк дип тә булмый. Кайбер урыннарда автор йә үзе ашыга, йә вакыйгаларны ашыктыра. Менә берничә мисал:

1. «Казан утлары»ның 9 нчы санында (116 бит) «Мансур өч дистәне тутырды, өйдән сөрелгәндә (1930 елның апрель аенда) аңа нибарысы ун яшь иде»,— диелә.

Димәк, сүз 1950 елда булган хәлләр турында бара. Моннан биш ел элек, 1945 елда Мансурның Берлинда булуы, анда рейхстаг стенасына имза куюы укучыга билгеле. Әйтик, шул ук елны Казанга кайтып, имтиханнар биреп, ул финанс-экономика институтына керде, ди. Дүрт ел укыганнан соң, 1949 елда институтны бетерә, ә бер ел үткәч, диссертация яклый, имеш. Иң кимендә өч еллык аспирантурада укып, диссертациянең башыннан чыгарга кирәк бит әле! Бер ел эчендә моны эшләү бик шикле.

2. Шул ук санның 55 битенә күз салыйк: «Ятим шул Әлфия, ятим. Әтисе сугыштан каты яраланып кайткан иде, үлгәненә быел ун ел тулды. Алар әниләре итәгендә берсеннән-берсе кечкенә биш бала белән калдылар».

Туктап, бераз тын алыйк әле. Санап карыйк. 17—18 яшьлек кыз урта мәктәпне бетереп институтка керү теләге белән Казанга килә, Мансур белән очраша. Алдан күргәнебезчә, бу хәл 1950 елга туры килә. Әлфиянең әтисе үлгәненә ун ел тулган. 1940 елны аның әтисен җирләгән булалар. Ә Бөек Ватан сугышы 1941 елда башланды. Бәлки, ул фин сугышыннан яраланып кайткан булгандыр? Ни генә булмасын — шикләнергә урын бар.

3. Әлфия хәзер генә читтән торып институтта укый башлады. Райфода инспектор ярдәмчесе булып эшләвенә берничә ай үтте. Кыз, һичшиксез, тырыш. Ләкин аның эш тәҗрибәсе бик аз әле. Шулай булуга да карамастан, ул Юныс Гыйльметдиновичны эшеннән куып чыгаруда башка хезмәткәрләргә караганда үзен активрак тота, принципиаль итеп күрсәтергә өлгерә. Конфискацияләнгән әйберләрне бәяләп, магазинга озаткач, ОБХСС подполковнигының

— Кем рөхсәте белән аларны сатуга чыгардыгыз? Сез мине, милиция подполковнигын санламаска маташасыз икән! — дигән сүзләренә каршы:

— Сез подполковник кына, ә мин үз эшемдә бүгеннән генерал! — ди Әлфия.

Монда чамадан чыккан батырлык, масаючанлык, тәвәккәллек сизелә. Белмим, тыйнак кына кыз, тормыш юлы әле генә башланып китүче кешенең шулай сөйләшә башлавы мөмкин микән? Исебезгә төшерик: ул елларда МВД, КГБ башында Берия утыра иде әле!

Ярый, боларын куеп торыйк. Кыска гына арада Әлфия берничә четерекле, аеруча җаваплы мәсьәләләрне хәл итә. Әлфиянең абруе берьюлы үсеп китте, ди автор. Озак та үтми, аны берләштерелгән дәүләт доходлары инспекциясенең начальнигы һәм бер үк вакытта райфо мөдиренең урынбасары итеп билгелиләр. Мондый ашыгуның кирәге бар иде микән? Ни генә сөйләмә, вакыйга Казан кебек үзенең финанс-экономика институты булган, югары белемле экономистларга бай булган калада бара түгелме?

Ә. Галиевның финанс эшләрен яхшы белүе әсәрнең һәрбер битеннән күренеп тора. Ул финанс хезмәткәрләренең тормышын, үзара мөнәсәбәтләрен зур осталык белән күрсәтә. Ләкин романны тәмамлау стадиясендә ул ашыккан сыман тоела. Тизрәк язып бетерергә тырыша кебек. Бу әсәр китап булып чыгар һәм күрсәтелгән кайбер кимчелекләр анда бетерелгән булыр, дип ышанасы килә.

«Казан утлары»нда басылган әдәби әсәрләр һәм башка материаллар татар халкы киләчәктә үзенең милли традицияләрен тагын да ныгытыр, туган телебезне саклап калыр, Татарстанны бәйсез, мөстәкыйль дәүләт дәрәҗәсенә күтәрер, дигән өметләр тудыра.

Шул ук вакытта журнал битләрендә тарихчылар, язучылардан яңа сүзләрне күбрәк ишетәсе килә. Үткән ел Казанның Явыз Иван илбасарлары тарафыннан яулап алынуына 440 ел тулды. Ләкин ул чорда татар халкының героик көрәшен тасвирлаган тарихи материаллар әллә ни күренмәде. Ренат Харисның «канда батмас, туңда катмас, ут алмас татар халкым» дигән сүзләренә минем дә шигем юк. Ләкин моннан дүрт гасыр элек булган вакыйгалар бер Сөембикә тирәсендә генә әйләнәләр. Әллә, чыннан да, татарның үзенең Сусаниннары булмады микән? Үзләренең аз санлы булуына карамастан, көтелмәгән һөҗүм ясап, илбасарны чигендерү фактлары да табылмады микән? Күңел моңа ышанмый. Аларны эзлисе, документаль материалларны табасы, чынбарлыкта булган ул геройлар турында романнар, опералар язасы, драматик спектакльләр, балетлар куясы иде.

Муса Җәлил белән Гаяз Исхакыйның үзара мөнәсәбәтләре ничегрәк булуы турында да соңгы сүз әлегә әйтелмәде бугай.

Безнең әдәбият һәм аның флагманы булган «Казан утлары» тормышны һәрьяклап һәм мөмкин кадәр тулырак итеп күрсәтү эшенә зур өлеш кертә. Бу юлда киләчәктә дә яңа казанышлар булыр, укучыны дулкынландыра торган, милли аңны тагын да күтәрердәй, халыклар дуслыгы рухында язылган тирән эчтәлекле әсәрләр туар. Моның өчен кирәкле шартлар барлыгын журналда басылган материаллардан да күреп була.

**Гарифҗан НАСЫЙРОВ,**
Калининград шәһәре.

## БЕР СОРАУГА—БЕР ҖАВАП

Журналыбызның быелгы 7—8 нче саннарында Фәрит Яхинның «Ахырзаман пәйгамбәре» исемле әсәренең Беренче китабы урнаштырылачак. «Пәйгамбәрләр тарихы», «Иман» һәм ислам дине һәм тарихына карата язылган башка китаплары белән укучыларыбызга инде таныш булган бу авторыбызга мондый сорау белән мөрәҗәгать иттек: «Бездә басылып чыгачак, Мөхәммәд пәйгамбәр турындагы әсәрегезне язуга нәрсә этәргеч ясады һәм нинди материалларга таянып эшләдегез?».

**Фәрит Яхин:** Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын һәм тарихи урынын билгеләү буенча эзләнүләрем күптәннән башланган иде. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли башлаган чагымда мина мәгърифәтче язучы, татар дәһриләренең башында торган Галиәсгар Гафуров-Чыгтай (1867-1942) иҗатына багышланган фәнни доклад белән Гыйльми шура алдында чыгыш ясарга әзерләнергә кушылды. Әдипнең кульязмаларын, басма әсәрләрен өйрәнгән вакытта аның «Исабәт» («Туры юл») китабы минем игътибарымны аеруча биләде. Аның бу әсәре 1909—1910 елларда Казанда «Бәянел-хак» матбагасында дөнья күргән. Совет чорында әсәрнең икенче китабы—Коръәнгә багышланганы басылып чыккан. Ә өченче китабы Болгарларда дин кабул итү һәм татар халкында ислам дине мәсьәләләрен яктыртырга тиеш булып та, ул язылганмы-юкмы икәнлеге билгесез.

Галиәсгар Гафуров-Чыгтайның «Исабәт»ендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы материалистик рухта, дәһрилек белән сугарылып язылган, галимнәр аның дәһрилек асылы нәрсәдә икәнлеген аңлата алмый йөдәгәннәр булып чыкты. Чыгтайның денсезлеген Нәҗип Түнтәри, Габдулла Тукай тиз сизенеп, тотып алганнар һәм аны моның өчен тәнкыйтьләп тә чыкканнар. Дини нәзарәт үзенең махсус бер утырышында «Исабәт»не тикшергән һәм анда ни өчендер денсезлек, дәһрилекне күрмәгән.

Чыгтайның дәһрилеге шунда ки, ул Мөхәммәд пәйгамбәрне тарихи шәхес дип раслау юнәлешендә Коръәнне дә аның үзенә генә кайтарып калдырып, Аллаһы тәгаләнең барлыгын шик астына алган. Икенче бер автор Сөнгатулла Бикбулатовның да «Хәзрәте Мөхәммәд» исемле әсәре булып (Казан: Мәгариф, 1913), ул да тарихилык принцибына таянып, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын яктырткан китап бастырган.

Китапның дәһри Чыгтайга каршы язылганлыгы эчтәлектән күренеп тора. Бу әсәрләрнең икесе дә киләчәктә халыкка барып ирешер дип уйлыйм. Соңгы вакытларда В. Ирвингның «Жизнь Магомета», В. Ф. Пановаһың һәм Ю. Б. Вахтинның «Жизнь Мухаммеда» исемле китаплары бастырылып, халык арасына таратылды. Әмма татар телендә Мөхәммәд пәйгамбәр хакында кулга тотып карарлык китап күренмәде. Аның зарурлыгын күздә тотып, һәртөрле ислам җәмгыятьләре мина мөрәҗәгать итеп тә карадылар. Алар соравы белән мин борынгы китапларга чумып, эзләнә башладым. Пәйгамбәребез турында безнең көннәргә кадәр шактый күп риваятьләр һәм хәбәрләр килеп җиткән икән. Бу җәһәттән, бигрәк тә «Алты бармак» әсәре кызыклы булып чыкты. «Мөхәммәдия», «Әнварел-гашыйкыйн», шәригать вә тәфсир китаплары мина таяныч булдылар. Шулай итеп, шактый кызыклы материаллар җыелды һәм әсәрнең төп умырткасы табылып, Мөхәммәд пәйгамбәр турында язарга булдым. Әлбәттә, бүгенге көндә барлык чыганаклар һәм иҗат процессы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бетерергә мөмкин түгел, әмма мин вакыйгаларны дөрес сурәтләргә, хакыйкый мәгълүматлар бирергә омтылдым. Укып чыккан язучыларга, галимнәргә ул ошады.

Мөхәммәд пәйгамбәр—тарихи шәхес кенә түгел, ул Аллаһы тәгаләнең сөекле колы һәм илчесе дә. Хак тәгалә аның аша җиргә «Коръән»не тараткан, кешелекне рухи һәлакәттән коткарып калган. «Ахырзаман пәйгамбәре» дигән әсәрем нәкъ менә шушы фикерне алга сөрә һәм аны ачыклап бирү юнәлешендә язылды. Максатка ирешә алганмындырмы—монысын укучы үзе әйтер.

## ПРЕЗИДЕНТ РАМАЗАН БӘЙРӘМЕ БЕЛӘН КОТЛАДЫ

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев 19 мартта мәркәзебез үзәгендәге Мәрҗани исемендәге җәмигъ мәчетендә, аннары Әҗем мәчетендә булды. Ул Мәрҗани мәчетендә өлкән имам Габделхәбир хәзрәт Яруллин белән сөйләште. Илбашы һәр ике мәчеттә дә дин тотучыларны изге Рамазан бәйрәме белән котлады.

Очрашу һәм әңгәмәләр барышында дин әһелләре Президентка Татарстан дәүләт органнары үткәреп килә торган сәясәтне яклауларын белдерделәр.

М. Шәймиевны Республика Министрлар Кабинеты каршындагы Дин әһелләре советы рәисе И. Хәбибуллин озатып йөрде.

## ИСТАНБУЛГА ЭШЛЕКЛЕ СӘФӘР

Төркиягә эш визиты белән килгән Татарстан Республикасы Премьер-министры М. Сабировны Төркия Республикасы Президенты Т. Озал кабул итте.

Дусларча узган бу очрашу вакытында ике як җитәкчелеге Төркия белән Татарстан арасында сәүдә-икътисади һәм шулай ук мәдәни элемтәләрне ныгыту, тирәнәйтүгә кагылышлы мәсьәләләр хакында сөйләштеләр.

## ӘДӘБИЯТ АКСАКАЛЛАРЫ ЯНЫНДА

18 мартта Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин татар әдәбияты аксакаллары Гомәр Бәширов һәм Әмирхан Еники белән очрашты. 92 яшьлек Гомәр аганың хәлен парламент җитәкчесе хастаханәгә барып белешсә, 84 яшьлек Әмирхан аганы ул, өенә барып, туган көне белән котлады. Очрашулар барышында халык язучылары Татарстандагы сәяси, икътисади хәлләр турында сөйләштеләр, фикер алыштылар. Бер уңайдан өлкән әдипләр әдәбиятыбызны һәм сәнгатебезне һәрвакыт күз уңында тотулары, милли мәдәниятебезне торгызу эшендә зәлекле хезмәтләре өчен республика җитәкчелегенә рәхмәт белдерделәр.

## ЯШӘ, «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»!

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Ватаным Татарстан» (газета төрле елларда төрле исемнәр белән дөнья күрде) газетасының чыга башлавына 75 ел тулу уңаеннан тантаналы кичә булды. Анда газетаның якын дуслары, фикердәшләре, киң катлам җәмәгатьчелек җыелган иде.

Матбугат өлкәсендә нәтиҗәле эшчәнлеге өчен газета Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Әлеге бүләкне Татарстан Вице-президенты В. Лихачев тапшырды һәм коллективка киләчәктә дә уңышлар теләде.

Юбиляр адресына «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры Р. Галиев, Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Ф. Сибгатуллин, Татарстан матбугат һәм информация министры И. Әхмәтҗанов, Татарстан газета-журналлар нәшрияте типографиясе директоры урынбасары З. Иванишин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары З. Мансуров, Балтач районы, «Татарстан» колхозы рәисе урынбасары Г. Латыйпов, Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсе генераль директоры урынбасары З. Шәрәфиев, «Татарстан хәбәрләре» газетасы баш мөхәррире Р. Харис, «Советская Татария» газетасы баш мөхәррире Е. Лисин һ. б. котлау сүзләре белән чыктылар, бүләкләр тапшырдылар.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталарының зур концерты булды.

Кичәдә Татарстан Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары З. Вәлиева, Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин катнашты.

## БӨТЕНТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ III КОРЫЛТАЕ

19—20 март көннәрендә Казанда, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында, Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең (БТИҮнең) III корылтае булып узды. Аның эшендә татар диаспорасының БДБ илләреннән килгән күпсанлы вәкилләре, Америка, Төркия, Кытай, Япония кебек чит дәүләтләрдән күзәтүчеләр катнашты.

Корылтайда Татарстан Республикасы гражданнарының хәрби хезмәте, качаклар һәм күчеп кайтучыларның хокукларын яклау, җәмһүриятебездән читтә яшәүче милләттәшләребезгә Татарстан гражданлыгын бирү, хосусыйлаштыру, җир турындагы һ. б. җитди-мөһим мәсьәләләр каралды.

Корылтайда бик күп документлар, шул исәптән Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең яңа платформасы кабул ителде. БТИҮнең рәисе итеп (президент вазифасы бетерелде) Чаллыдагы иҗтимагый үзәкнең рәис-координаторы Зиннур Әһлиуллин сайланды.

## АНСАМБЛЬГӘ ХАЛЫК РӘХМӘТЕ

Халкыбызның горурлыгы, мактанычы булган Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешуга 55 ел тулды. Шул чор эчендә данлыклы коллектив (ул Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясенә, «Халыклар дуслыгы» орденына лаек булды)

дөньяны аркылыга-буйга инләргә өлгерде һәм чит мәмләкәтләрдә яшәүчеләрне халкыбызның бай рухи мирасы, дәртле җырбиюләре белән таныштырды.

Истәлекле вакыйга уңаеннан, күптән түгел М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры бинасында зур кичә-концерт үткәрелде. Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Л. Кустабаева житәкләгән атаклы ансамбльне олуг бәйрәме белән котларга, җыр-бию яратучы тамашачылар белән бергә, предприятие-оешмалар, иҗат берлекләре житәкчеләре дә килгәннәр иде.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ КЛУБЫНДА

Күренекле шагыйрь Мостафа Ногманның тууына 80 ел тулуга багышлап, бирелә әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Әдипләрдән Н. Хисамов, М. Мәһдиев, Г. Зәйнашева һ. б. чыгышлары һәркемдә тирән кызыксыну уятты. Кичә барышында шагыйрь сүзләренә иҗат ителгән күпсанлы җырларның яраткан артистларыбыз тарафыннан башкарылуы нур өстенә нур өстәде.

* * *

Халыкара хатын-кызлар көне уңае белән, язучылар клубында тагын бер кызыклы очрашу булып узды. «Шагыйрәләр йолдызлыгы» дип исемләнгән ул кичәдә (аны Татарстан Язучылар берлеге һәм «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар ассоциациясе оештырган иде) бүгенге көндә актив иҗат итүче төрле буын татар шагыйрәләре катнашты.

Һәр ике очрашуны да танылган шагыйрә Лена Шагыйрьҗан алып барды.

## АФЗАЛ ШАМОВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Танылган язучы Афзал ага Шамовка атап, Казанның Маяковский урамында ул яшәгән йортка истәлек тактасы (авторы — скульптор Ә. Әбдрәшитов) кую тантанасы булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты. Әлеге тантанада җөмһүриятебезнең мәдәният министры М. Таишев, әдипнең якташлары, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

## ЯҢА ПРЕМИЯНЕҢ БЕРЕНЧЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Лениногорск шәһәр администрациясе калада яшәп иҗат иткән язучы Шамил Бикчурин исемендәге әдәби премия булдырды. Ул ел саен бирелеп барылачак. Быел әлеге истәлекле бүләккә, беренчеләрдән булып прозада Ә. Галиевның «Көн яктысы» китабы, поэзиядә — Н. Рочайте әсәрләре, публицистикада Җ. Рәхимовның язмалары лаек дип табылды.

Лауреатларга премияләрне тантаналы шартларда шәһәр администрациясе башлыгы, Татарстан халык депутаты Исхак Садриев тапшырды. Бүләкләнүчеләргә, диплом белән бергә, 10 мең сум күләмендә акча да бирелде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» — ҺӘР ГАИЛӘДӘ

Җөмһүриятебезнең Мамадыш районындагы Норма урман хуҗалыгында эшләүчеләр елның-елында «Казан утлары» журналына бик теләп язылалар. Әлеге урманчылыкның баш урманчысы Илдус Мөхәммәтшин үзе дә милләтебезнең төп әдәби журналы булган әлеге басманы аеруча ярата һәм хезмәт алдынгыларын «Казан утлары» белән бүләкләүне үрнәк төстә оештыра белә. Шуңа күрә, хәзер әлеге урман хуҗалыгында эшләүче һәр гаиләгә журналлар үз вакытында килеп тора.

«Казан утлары»на 1993 елның икенче яртысы өчен язылу да зур оешканлык белән үтте — мөштәриләр (подписчиклар) саны кимемәде.

## УЛЬЯНОВСК ЯҢАЛЫКЛАРЫ

Соңгы елларда Ульяновск өлкә администрациясе милли мәсьәләләрне хәл итү уңаеннан кайбер эшләр башкарды. Инде менә берничә ел рәттән 10000 тираж белән «Өмет» газетасы чыгып килә. Өлкә телевидениесендә һәр ай саен 3 сәгать кенә булса да татар тапшырулары алып барыла. Шәһәр үзәгендә мәдрәсә, Халыклар дуслыгы йорты, педагогия училищесында татар группасы ачылды.

Бу көннәрдә Ульяновскида яшәүче милләттәшләребез өчен тагын бер сөенечле вакыйга булды — Ульяновск радиосы буенча татар тапшырулары бирелә башлады. Аны журналист Рамис Сафин алып бара.

Апрель аеннан башлап шәһәр тамашачылары игътибарына татарча телевизион тапшыруларның вакытын тагын 2 сәгатькә арттыру күздә тотыла.

* * *

Күптән түгел Ульяновск шәһәре үзәгендә төзелгән яңа мәчеттә беренче Җомга намазы укылды. Әлеге мәчет, башлыча, халык акчасына салынды. Кайбер эшмәкәрләр ярты шар миллион сум акчаларын бу изге эшкә бүлеп бирделәр. Әлбәттә, өлкә администрациясе дә бу эштән читтә калмады — төзелеш материаллары белән дә, акчалата да һәрчак ярдәм итеп торды. Бу ике катлы мәчет берьюлы меңнән артык кешене сыйдыра. Ул матур келәмнәр, төсле шамаилләр белән бизәлгән. Аның эчен яктырту өчен Төркиядән бәллүр люстра кайтарылды. Мәчет эчендә ерактан килүчеләр өчен кунакханә дә булдырылган.

Ә иске мәчет картлар һәм инвалидлар йорты булачак. Яңа мәчет белән янәшәдә генә 2 катлы мәдрәсә бинасына да нигез салынды. Тагын шунысын да әйтергә кирәк: 200 меңнән артык татар яши торган Ульяновск өлкәсендә моннан 3 ел элек нибары 5 мәчет булса, бүген аларның саны 56 га житте.

Яңа мәчетне рәсми ачу май аенда булачак. Анда илебезнең төрле төбәкләреннән һәм гарәп илләреннән дә кунаклар көтелә.

# ЯҢА АНТОЛОГИЯ — ШИГЪРИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫ

Шигърият сөючеләргә татар шигыре антологиясенең 1956 елда дөнья күргәне яхшы таныштыр дип уйлыйбыз. Әмма аннан соңгы 30 елда ил, халык тормышында булган зур үзгәрешләр, әдәбият тарихына, шигъри мираска караш, аны өйрәнү, дөньяга чыгару юлындагы яңалыклар антологиянең яңасын чыгару мәсьәләсен дә алга куйган иде. Бу зарурилыкны аңлап, сиксәненче еллар уртасында ук аны төзүчыгару эшенә керешелгән иде. Төрле сәбәпләр аркасында, ул шактый көттереп, 1992 елның ахырларында гына икетомлык рәвешендә басылып чыкты: татар шигыренең яңа тарихы, халкыбызның бер рухи энциклопедиясе дөньяга килде. Антологиянең төзүчесе — шагыйрь Гәрәй Рәхим. Нәшрият мөхәррирләре — Ф. Зөлкарнәев, Г. Гыйльманов һәм Х. Әюповлар, әсәрләрне, белешмә-искәрмәләрне әзерләүдә Н. Юзиев, М. Гайнетдинов, М. Әхмәтҗанов, Н. Хисамов, А. Фәтхиләрнең күп көч куйганлыгын әйтергә кирәк. Шагыйрьләрдән И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, М. Шабаевлар да бу эштә шактый ярдәм күрсәткәннәр.

Бу антологияне Н. Хисамов һәм Т. Галиуллиннарның тәфсилле зур күзәтү мәкаләсе тәгәлли. Әдәби сүзлек тә урнаштырылган... Антологияне дөньяга китерүчеләр әдәби-мәдәни тормышыбызда эз калдырган, соңгы елларда дөнья күргән фәнни басмалар — «Кыйссаи Йосыф», Г. Утыз-Имәни, Акмулла, Г. Кандалый, Ш. Бабичларның китапларын чыгару тәҗрибәсеннән дә, галимнәребезнең фольклор әсәрләре тупланмаларыннан һәм төрле төрки-татар шигърияте чыганакларыннан да киң файдаланганнар. Нәтиҗәдә, антология телебез, ил-дәүләтчелегебез, шигъриятебезнең үсеш юлы, «коллык җебен өзгән» аң-фикер, фәлсәфә, дин-әхлак һәм рух тарихыбыз юлы булып күренә.

Бу юлда без «Котадгу белек» кебек уртак ядкарьләр, Ясәви, Бакыргани кебек зур шагыйрьләр; язма әдәбиятыбыз башы Колгали, Алтын Урданың асыл шагыйрьләре С. Сараи, Котб, Х. Кятиб, Харәзми һ. б. белән очрашабыз. Ә «Идегәй» кебек дастаннарыбыз теле, шигърилеге! Чәчәннәр, жыраулар да, каберташлардагы шигъри язулар да халкыбызның шигъри көчен раслый. Антологиядә күп яңа исемнәрнең билгесез әсәрләре урын алган: Казан чорыннан Мөхәммәдъяр, Колшәриф, Мөхәммәт Әмин, Мәҗлеси, Максуди кебек тарихи шәхесләр; Суфи Аллаһияр, Габди кебек «яңа» шагыйрьләр; яңа дәвер шигъриятендә Габдессәлам Урай улы, Кол Мөхәммәт, Мөхәммәт Шәриф кебек исемнәр бар һ. б. Ә Г. Вәисев шигырьләре? Акмулла, Ш. Зәки, Ә. Каргалый, Кандалый кебек, шигырьне фән, дин белеме һәм матурлыкны данлау чарасы да итүчеләр? Күп санлы шагыйрәләребез дә бик кадерле исемнәр.

Ә XX гасыр шигърияте? Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Гафури, Думави, Бабичлар янына да бик күп яңа исемнәр өстәлгән. Совет чоры шигърияте бүгенге укучыларыбызга яхшы таныш булганга, Һади Такташтан алып, Л. Леронга кадәр шагыйрьләребезнең һәр буыныннан үрнәкләр бирелгән, дию белән чикләнәбез. Әлбәттә, кульязмасы 10 ел элек төзелү бу чор әсәрләренең сайланышында нык сизелә — аннан соңгы демократик үзгәрешләр дә юк кебек...

Тиражы (1500 данә) — аз, бик аз. Ә, гомумән, антологиянең дөнья күрүе — мөстәкыйль Татарстаныбыз тормышында зур бәйрәм вакыйгасы ул!

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы Гурий Тавлин.

**М. КОЗЛОВСКИЙ** фотосурәтләре.

Бәясе 20 сум Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог